# Мансур Шаһимәрданов

## Хикәяләр һәм повесть



# 3 том

*Аһ, шәп әйтте бу! Ләкин, алайга китсә, мин дә бик төшеп калганнардан түгел, мөдирнең бәләкәй, өтер күзләренә текәлеп:*

*— Мин... пре-зи-дент кия-ве! — дидем.*

*— Нәр-сә-ә?*

*— Мин президент кияве-е!*

*Мөдир гүя телдән язды.*

СП ТАТАРСТАНА
Ул.Муштари,14
236-97-71

# ЭЧТӘЛЕК

## Х и к ә я л ә р


Беренче мәхәббәт....4
Очрашу....17
Күзге кичтә....35
Сөенәм....42
Кызыл розалар чәчәк атканда....45
Шүллер....49
Агач аяклылар....51
Кымыз химәтләре....55
Өметбикә.... 56
Күңел нечкәргәндә....61
Рәхмәт, иптәш генерал!.... 63
Сәләхетдин бабай.... .66
Хәерлегә булсын....69
Сабакташлар.... .75
Ришат ничек итеп кунак кызны көлдерде.... 78
Хушлашмый калдым....80
Хәсрәт....82
Кыек авыз.... 85
Фәрхия апа.... 90
Идеал.... 97
Тормыш чәчәкләре....106
Килешү....109
Беренче хикәя....112
Людмила....116
Эт....118
Гафу итегез, иптәш подполковник!....120
Кәрәш....122
Зәңгәр томаннар артында....126
Язмыш....127
Югалган кыз....134
Мин болгар?....142
Зимагур кибетче һәм шофер....144

Рәхмәт, сандугач.......................................................................................147
Тирес...........................................................................................................149
Фатир......................................................................................................... 152
Интуиция.................................................................................................... 173
«Блат» кирәк............................................................................................. 178
Мин ничек итеп карьера ясадым..............................................182
Чокыр..........................................................................................................183
Без әле шулай яшибез.................................................................. 186
Елмаю.........................................................................................................191
Икәү............................................................................................................193
Бер картлыкта, бер яшьлектә..............................................................196
Өч чакрым юл.............................................................................................199
Бер шатлык та бер кайгы................................................................. 210
Китап хикмәтләре.................................................................................... 218
Яшәү мәгънәсе.......................................................................................... 221
Гөлсәрия.................................................................................................... 222
Марфа әби................................................................................................. 224
Өч баҗай.................................................................................................... 225
Тәңре хөкеме............................................................................................. 227
Чыпы............................................................................................................ 228
Юлда............................................................................................................ 231
Кемгә нәрсә............................................................................................... 232
Очрашу........................................................................................................ 234
Сызгырып бию.......................................................................................... 236
Мунча........................................................................................................... 238
Мин кем?..................................................................................................... 239
Солтан буласың килсә............................................................................ 241
Галим хәсрәте........................................................................................... 242
Инженер...................................................................................................... 243
Яшь шагыйрь маҗаралары ( Повесть).................................. 245

# Хикәяләр

## Беренче мәхәббәт

Без — шифаханәдә йөрәк чиреннән дәваланучылар, кичке аштан соң, гадәттәгечә, бакчага чыгып утырдык. Минем уң һәм сул ягыма — төрледән-төрле кызыклы вакыйгаларның иң үзәгендә нәкъ менә үзләре генә кайнагандай итеп сөйләргә бик әгъва Илгизәр белән Ризван туры килде.

— Әйдәгез, әфәнделәр, беренче мәхәббәтебезне искә төшереп, бушанып алыйк әле, — диде Илгизәр. — Шуннан соң...

Ерак авылдан килгән зооинженерның яхшы ниятен ярты сүзеннән үк аңлап:

— Сөйлә шул! Тизрәк сөйлә! — диештек.

### 1

— Мин — алтынчы класста укучы малай, экранда барган һава сугышы күренешләренә җаным-тәнем белән бирелеп утыра идем, — дип башлап та китте Илгизәр беренче мәхәббәте мажарасын. — Кинәт лента өзелде дә, агач клуб эче шау-шу, сызгыру авазлары белән тулды. Шул форсаттан, тәвәккәл малайлар юашрак кызларны чеметкәләргә, чәчләреннән тарткалап, эчләрендә йоклап яткан гыйфритләрен уятырга керештеләр! Усал кызлар исә, иптәшләрен яклап, “егетләрнең” тап-такыр башларындагы бүрекләрен йолыккаларга тотындылар! Кайсыдыр: “Итекче, юньләп көйлә аппаратыңны”, — дип кычкырып, гомуми шаукымга “көч” өстәргә азапланган малайның, ягъни минем башымнан да салдырып алып китте, — әнием кичә кибеттә озын чират торып кулга төшергән өр-яңа ак куян бүрекне!

Эшләр алайга таба борылгач, сер бирүчеләрдән түгел инде мин, юлымдагы ыбыр-чыбырны як-якка тибәреп, тимер мич артындагы “һай-һау” арасына чәчрәп барып та кердем! кул астына эләгеп, карышып маташкан берәүне җен булышлыгы белән әйләндереп тә салдым. Артыграк тырышып ташладым бугай, үземнең дә тезләрем бәрелеп, ни яшел, ни зәңгәр

күзләремнән әтием чарда балта кайраган чакта гына була торган утлы очкыннар чыгып очты! Идәннең дөберт итеп куюыннан төшендем, теге сыек аякның да хәле минекеннән ким түгел сыман! Күңелемне шундук кызгану хисе биләп алды. Торырга булышыйм әле дип аңа таба кулымны сузган идем, утларны дәррәү кабызып җибәрделәр дә, кадерле яктылык безнең тарафка да сыек кына булып үтеп керде. Каршымдагы таныш түгел йөзгә текәлебрәк карасам, бер кыз кисәге теге! Үзе шәһәрчә киенгән искиткеч чибәр һәм, әлбәттә, минем уйлавымча, авылыбызның һәммә чәчбиләреннән дә затлырак шикелле! Мин аңа гаҗәп дәрәҗәдә сокланып һәм үземнең сыткы басып бетергән сипкелле битләрем өчен оялып, шул ук вакытта йөрәгем түрендә “өф-өф”ләп кенә йөртә торган иң кадерле өметемнең көннәрдән бер көнне чынга ашарга мөмкин икәнлеген дә искәреп, елмайдым. Ул исә көлеп үк җибәрде һәм ялт кына сикереп торды да: “Мә акыллым, ал шапкаңны”, — дип, минем кулга йөнтәс бүрегемне атып, иптәш кызлары янына китеп барды.

Шуннан соң мин бу кичне кино беткәнче гел шул “җанкисәк” турында гына уйланып утырдым. Бигрәкләр шәп кыз инде, бахыр, мин әйтәм, кәттә кыз. Кәттә булса да теле татлы үзенең. Әйтсә, берәгәйле әйтә икән, йөрәккә үткәрерлек итеп. Юкса, мондый нәзек билле кала фәрештәләре элек минем ише алама сала малаена авыз да ачып тормыйлар иде бит. Акаеп бер карарлар иде дә: “Фу, еще этого не хватало”, — дигәндәй, нәфис борыннарын җыерып китеп барырлар иде. Ә бу, алар кебек түгел, бөтенләй үзгә кыз. Әллә, мин әйтәм, кайда да булса аның мине күргәне бармы икән? Югыйсә ул миңа, күптәнге танышына сәлам биргән кебек, елмаймас иде. Кыскасы, минем башыма һич уйламаган җирдән, шатлыгын ияртеп, кайгы-хәсрәте дә китеп җиткән иде инде бу вакыт.

Кино азагында мин күрше эскәмиядәге малайлар сөйләшүеннән ул кызның Казанныкы булуын, кылый Мәфтухаларга кышкы каникулга кунакка кайтуын белдем. Шуннан соң, чибәркәй өчен кимсенеп, уйлап та куйдым: “Кылый Мәфтухаларга кайтмаса, авылда юньле кеше беткән иде микәнни? Мәсәлән, без! Юк, безгә булмый. Минем әни, тәм-томга караганда, күбрәк сөтле аш пешерә. Ә бу тәрбияле, нәзәкатьле кыз сөтле ашның бар икәнен дә белми торгандыр, мөгаен”. Шулайрак гөман кылган булам инде үзем. Алайса, дим, нәрсә ашый икән соң бу гүзәлләрнең гүзәле, ягъни яраткан ризыгы бардыр ич инде аның?!

Мин үзем, әйтик, шоколад тышлы, ә эченә йөзем җимеше салып ясалган татлы туңдырма белән, ысланган колбасаны — дөньядагы иң күркәм һәм туклыклы ризыклар рәтенә кертәм. Ләкин бу кыз мин яраткан әлеге ризыкларны, калада яшәве сәбәпле, көн саен диярлек авыз итеп карый ала лабаса! Аның миннән өстенлеге әнә шунда инде! Хәер, минем дә кыздан өстен якларым юк түгел. Беренчедән, һәрчак чишмә суы гына эчәм. Икенчедән, гел саф һава гына сулыйм. Өченчедән, йомырка, ит, сөт, бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимеш үзебезнеке. Дүртенчедән, һаман табигать белән аралашып яшәве сәбәпле, авыл баласы хыялга да баерак була! Ләкин шулай да, малай, кызың уйлаган саен йөрәгемә таба якыная бара. Мин инде хәзер экранга бик карамыйм... Әһә, әйтәм ич, кунак кыз белән дә нидер булырга ошый. Әнә искиткеч сөйкемле йөзе белән борылып, гел миңа карап куя! Аның ымсындыргыч чем-кара күзләреннән миңа таба берсеннән-берсе ак уклар атыла!

Шул мәлне “нәкъ Бэкки инде” дигән җып-җылы уйдан җаныма-тәнемә үтә рәхәт булып китте. Минем атна чамасы элек кенә бик кызыклы бер китап укып, маҗаралар тулы шул романдагы нечкә күңелле, зыялы Әмрикә кызына гыйшык тотып йөри башлаган чагым иде бит.

— Кара әле, бер тамчы су кебек охшаган бит болар бер-берсенә, — дип чак-чак кына кычкырып җибәрмәдем мин, кино бетеп, кыз баскычтан төшкәндә сизелер-сизелмәс кенә җиңемә орынып үткәч. — Каян беләсең, бәлки Казанныкы түгелдер бу, шул китаптагы кыздыр. Романны укып үзенә минем гашыйк булуымны белгәндер дә, монда килергә уйлагандыр. Һәм шулай булса-а-а... Ул кыз бары тик мине генә яратырга тиеш булып чыга түгелме?!

Мин әнә шулай уйланып бара торгач, олы гына бер төркемне куып җиттем. Теге чибәркәй янына һич кенә дә якынлашырга мөмкинлек юк. Як-ягында иптәшләре бара, ә артта... малай-шалай!

Кылый Мәфтухаларга җитәрәк мин уңайлы вакыт табып фонарь утын туп-туры Бэккига юнәлттем. Кыз, туктап, ут ягына борылды һәм матур күзләрен кыса төшеп, карап торгач кына мине танып:

— Ә, бу синмени әле! — диде. Һәм көтмәгәндә генә такыр башымнан бүрегемне алып артына яшерде.

Миңа искиткеч рәхәт иде, күңелле иде. Соң, шулай булмыйни... Бэкки, әнә, минем белән шаярырга тели ич.

— Фонареңны бирмәсәң, бүрегеңне алмыйсың, — дип челтерәде кыз, ниһаять, җитди тонга күчеп. Һәй, мондый чакта егет кеше фонарь кызганып торамы инде кызлар өчен, бигрәк тә

Бэкки өчен! Әгәр мөмкин булса, мин Бэккига йөрәгемне дә уртага ярып бирер идем әле.

— Мә, җаныем, кинән яндырып! — дидем мин. Эчемнән генә әйттем, билгеле.

Кулына кытай фонаре эләккәч, кала кызы миңа бүрегемне сузып:

— Мә Гекелеберри Финни, күгәрченем, ал шапкаңны! — диде.

Тутырып әйтәсе иде бит миңа, күңелдәгенең барысын да ачып саласы иде. Ләкин кая ул. Гекелеберри Финни, дип аталуымны ишеттем дә, телдән язгандай булдым. Шул тамашадан соң, җебегән малай янында нинди кыз торып калсын икән, җә? Күз ачып йомганчы, Бэкки да, ягъни минем сөекле Бэккием дә капка келәсенә үрелеп өлгергән иде инде.

Ләкин шул хәлдән соң да Бэккиның минем белән кызыксынуы сүрелмәде бугай. Мәгәр миңа аның үзе белән һичьюгы бер генә тапкыр булса да икәүдән-икәү генә калып сөйләшергә насыйп булмады бит. Ә өметем зурдан, бик зурдан иде минем. Соң, әгәр уйласаң, җиңел машина йөртерлек клуб эчендә, яр халык алдында, бер-беребездән күз алмый утырулар да, клубтан кайтканда кызның, җаен-чарасын табып, миңа гына елышуы да, тагын сүзсез, бары тик сиземләү белән генә тоя торган нәрсәләр дә байтак иде ич безнең арада. Әмма барыбер мин Бэккины озата алмадым. Һәм бер көнне Бэкки, гәрчә үзе бик теләсә дә, мәгълүм сәбәпләр аркасында, сөекле Гекембберие белән бер генә мәртәбә булса да, капка төбендә бәхетле минутлар кичерә алмыйча, күңелсезләнеп, моңланып Казанына китеп барган...

Ул киткәч, Финнине оныткамы? — миңа билгесез иде. Ә мин менә Бэккины мәңге онытмаячакмын. Таң туды исә хәтергә Бэкки килеп төшә, кич җиттеме — ул. Ә төннәрен исә төшләремә кереп йөдәтә ул кыз. Һәм кая гына барма, кайда гына булма, һаман Бэкки да, Бэкки... Мин тәмам аптырадым, йөдәдем һәм гаҗизлектән сабырым төкәнеп, Мәфтуха ападан кызның адресын сорап алып, аңа озын гына хат язып җибәрдем.

Хатка каршы җавап көтә-көтә аһ итеп беттем мин ул елны. Беләсездер инде, кышның төннәре озын була. Җитмәсә, әти белән әни иртә йокларга яталар. Алар яткач, билгеле инде, мин дә утны сүндереп ятарга тиеш. Мәгәр мин күзләремне йомдым исә, әллә кайдан гына Бэкки килеп чыга да: — Ә, бу синмени әле, минем Гекемберрием, — дип пышылдый-пышылдый, төрле хәрәкәтләр ясап бөтерелергә, биергә керешә.

Шундый михнәт-газаплар эчендә, дуылдык җилләре, әче бураннары бөтен кыш дигәнең узып та китте. Инде түбәләрдән тамчылар тып-тып итеп тама башлады, әти кеше ясап куйган яңа ояга ике нәни сыерчык килеп кунды бер көнне, ә хат һаман юк та юк...

Ә мин әле дә булса көтәм ул хатны, — дип, көлемсерәп тәмамлады Илгизәр хикәятен. Һәм, сүзләренә йомгак ясагандай итеп, өстәп куйды: — Менә шуннан бирле минем ул кызны беркайчан да очратканым булмады. Ә очратасы, күрәсе килә иде үзен, бик килә иде!..

## 2

—Миңа беренче мәхәббәт бераз соңгарак калып, миңа унтугыз тулгач кына килде, — дип башлады Ризван үзенең хикәятен. — Болай булды инде ул... Башкалабыз читендәге ярым авыл, ярым поселокны хәтерләткән станциягә мин (авиация техникумының икенче курс студенты) еш килеп-китеп йөри идем. Мине бирегә, чынлап торып уйласаң, кардәшләремнең киң күңеллелеге дә, яшьлек романтикасы да тарта иде бугай. Бигрәк тә романтика дигәне тарткандыр, мөгаен. Чөнки биредә кызларның иң чибәрләре, иң кәттәләре генә яшидер сыман тоела иде миңа ул чакта. Һәм миңа ул вакыт, алда әйткәнемчә, яңа унтугыз тулган булып, минем нәкъ менә кызларны сөяр һәм алардан сөелер чагым иде.

Бер мәлне шулай кичке алтылар тирәсендә микән, Казансу елгасында рәхәтләнеп су коенганнан соң, атлый торгач, вокзал тирәсенә барып чыктым. Шундый чакка туры килдем ки, вокзалның эчендә дә, тышында да һәм перронда да, киләсе поездлар килеп, үтәселәре яңа гына үтеп беткәнлектән, кеше-кара юк иде әле. Хәер, сары агач бинаның ике-өч кенә юкә үсеп торган кечкенә генә бакчасы эчендә, зәңгәр эскәмиядә ялгызы гына, шыпырт кына миңа текәлеп, нишләр, кая таба барыр икән бу? — дигән сыман, әллә ниткән уйлар эчендә моңаеп утыручы бер кыз бар иде барын. Мин шул кызны күреп алдым да, аңа сүз кушмыйча гына китәргә теләмәгәнлектән, ә бәлки ул миңа ошагандыр әле, болай дип сорадым:

— Бу поселокта клуб-фәлән юк ахры... Кичләрен күңел ачарга кая барып йөрисез соң сез?

Кыз соравыма каршы үзе сорау биреп куймасынмы шунда.

— Сез абый гармунда уйныйсызмы әллә?

Гаҗәп! Каян чыгып әйтә икән ул минем гармунда уйный белгәнне? Миңа һич аңлашылмый. Шулай да:

— И мәтәштергән булам инде, — дидем мин һәм, карашымны аксыл күктән — очып барган самолеттан алып, кызга төбәдем.

— Шулай шул, — диде кыз җиргә, аягына менәргә азапланучы ниндидер бөҗәккә караган көе, — студент халкы күңел ачарга һәвәс була инде ул.

Мин аңа, тагын нинди әкәмәт сүз әйтер икән бу чибәркәй дигәндәй, кызыксына төшеп һәм төбәлебрәк карап тора башладым. Әйе, җанга ял, күңелгә дәва бирә торган ягымлы, җылы карашлы, коңгырт бөдрә чәчле, нечкә билле, таза да, ябык та түгел кыз иде бу. Өстендә аның җәйге кыска күлмәк, яланаякларында босоножкалар, ә ачык беләкләре кояшта янып, шәфәкъ төсенә кергәннәр иде.

Ул миннән, көтмәгәндә генә, вакытны сорады. Анна-ры беләкләренә ымлап:

— Бүген бакчада эш күп булды... Төнлә ничек йоклармын инде, авыртыр инде болар, — дип куйды.

Кызларның ниятен шәп аңлыйм мин, әлегә мәхәббәт өлкәсендә тәҗрибәсез шайтан булсам да! Кызларның күңел түрендә һәрчак егет-фәлән булыр инде аларның! Һәм мин шулай уйлап, һәм тел чарларга тырышып:

— Егетләр кочагында чакта сызламас, җан кисәгем! — дип җиффәрдем. Аннары янә шаяртырга исәп итеп авызымны ачкан идем, кызның әнисе булса кирәк, кызын өйгә чакырып алды.

— Нишләп утырасың анда? Кайт әйдә...

— Хәзер әни... — диде кыз. Һәм урыныннан торды. Аннары минем якка таба карап:

— Син Ризван, матурым, безнең ничек күңел ачканны күрәсең килсә, кич белән әнә теге беседка буена кил! — диде дә, әле генә әнисе басып торган тарафка китеп күздән югалды.

Ә кичен мин инде вокзал бакчасы янәшәсендәге беседка янында, таныш егетләр арасында басып тора идем. Әйе, таныш булмаган егетләр дә күп иде биредә. Аларның кайберләре миңа кызыксынып, кайсылары исә үтә сынап һәм кашлары астыннан гына сөзеп карап-карап алгалыйлар иде. Әнә шул авыр, салкын карашларны җиңел генә күтәрә алсам икән мин! Юк шул, булмый, табигатем кабул итми минем мондый шөкәтсез карашларны. Һәм бу карашлар мине талкый, изә, тагын әллә нишләтә, әллә нишләтә иде.

Мин үземнең шактый гына кыен хәлдә калуымны сизеп һәм торган саен куера барган киеренкелекне сыегайтырга теләп, кесәмнән папирос алып кабыздым. И шуны гына көтеп торгандай, егетләрнең берсе миңа якынлашты, кулы белән ымлап, тартырга сорады. Бирдем, әлбәттә, өстәвенә әле кабызган шырпымны, учлап, тегенең борыны төбендә тотып тордым. Ниһаять, тырышлыгым бушка китмәде бугай, егетең миннән алган тәмәкегә минем яндырган шырпымнан ут элдергәч, башын чайкап, миңа рәхмәт әйтте дә читкә китеп басты. Аннары, чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, тәмәке сорап, яныма икенче егет килде. Аннары өченчесе... Бирдем, аларга да бирдем тартырга, гәрчә үзләренең кесәләрендә тартырларына булса да! Ни өченме? Алар мине саран дип уйламасыннар, юмарт икән бу дип уйласыннар өчен! Ә аннары, беләсездер инде, нәрсә була?..

Әйе, шулай көтмәгәндә генә, чит-ят егетләр арасында үз кешегә әверелеп китә язып, кукыраеп кына тора башлаганда, бер мәлне бирегә таба кызларның килгәне күренмәсенме! Киләләр, җаныйлар, йорт казлары сыман бер-бер артлы тезелешеп, вак-вак кына атлап киләләр... И елмаялар үзләре, и көләләр; и чибәрләрдер, и бизән-гәннәрдер; и заманына күрә шәп кенә итеп киенгәннәрдер, мин сиңа әйтим. Һәм, әлбәттә, араларында, ни хикмәттер, гармун күтәреп килүче — теге кыз да бар иде. Юк, ул үзе уйнамый, иптәш кызлары белән сөйләшә генә иде.

Менә кызлар безгә таба якынлаша төштеләр. Инде хәзер таныш кызым беркем белән дә сөйләшми иде. Кызның дикъкатен нәрсә җәлеп итте икән, белмим. Әнә ул, бер заман, җанланып китеп әле бер егеткә, әле икенче егеткә карап-карап ала башлады. Димәк, ул кемнедер эзли! Тик беләсе иде: кемне эзли икән? Бәлки, минедер...

Шулай дип уйлавым булды, кыз кинәт кенә мине күреп алды. Күреп алды да, башта тулган айдай, балкып, елмайды. Аннары, очынып, ашкынып, миңа таба килә башлады. Килеп җитәрәк, гармунны, ипләп, ике кулы белән тотты һәм тиз-тиз генә:

— Мә, Ризван бәгырем, синең өчен генә алып килдем мин бу гармунны, — диде.

Нәкъ вакытында әйтелгән бер җылы сүз таш эре-терлек була, диләр бит. Яшермим, мин дә эреп агардай булдым кызның әлеге җылы, наз тулы сүзләреннән. Миңа әле бер генә кызның да алай иркәләп, җайлап әйткәне юк иде ич!..

Шуннан мин ничек итеп гармунны кулга алуымны да, ничекләр кыланып, сырлап-бизәкләп уйный башлавымны да, әле һаман да

булса ап-ачык күз алдына китереп бастырырлык дәрәҗәдә төгәл хәтерлим.

Әнә мин уйныйм гармунда, яшьләр бии, кызым бии, мин уйныйм, кызым һаман бии, яшьләр бии... И биеп тә күрсәтте соң яшьләр бу кичне! үзенә күрә бер туй сыман булды бу кич! Аннары мин гармунны тагын бер оста уйнаучы егеткә бирдем дә, кызымны култыклап, читкә алып киттем. Озакламый без, Казансу елгасы каршында, хуш исле болын печәне арасында сөйләшеп, серләшеп утыра идек инде.

Менә шуннан башланды инде безнең бәхетле кичләребез, башланды... Бу — беренче кар төшкәнчегә тикле, ягъни минем армиягә китеп баруыма чаклы дәвам итте. Ә аннары без эч-серләребезне бер-беребезгә хатлар аша юлларга тотындык. И саный китсәң, күпме матур хатлар язылмады да, күпме кайнар җаваплар алынмады ул хатларга.

Ләкин (ун, йөз, юк мең мәртәбә нәләт төшсен бу сугышка!) безнең частьне көннәрнең берендә Әфганстанга китереп керттеләр: интернационал бурыч үтибез, янәсе, биредәге хезмәт ияләрен әллә кемнәрнең изүләреннән коткарабыз. Шулай дип аңлаттылар безгә. Ә без, билгеле инде, ышандык, ышанмыйча кая барасың? Хәзер генә ул, “Әфганстанга керергә кирәк булмаган безнең гаскәрләргә”, дип, бик җиңел генә әйтеп куялар. Һәм, чынлап торып уйласаң, алар хаклы булып чыга. Ләкин монда безнең, солдатларның ни гаебе бар? Хәер, бардыр, булмаса, “гаепләре бар”, дип сөйләмәсләр иде. Мин үзем, әйтик, әфган бандалары белән сугышырга туры килгән чакларда авыз ачып карап тормадым, аттым да, шартлаттым да үзләрен. Һәм бу турыда хатларымда да кызыма тәфсилләп яза торган идем. Ә кызым — физмат студенткасы — акыллы кыз, минем чит илдәге батырлыкларыма әллә ни исе китеп тормаган, тоткан да, химфакта укучы студент егет белән йөри башлаган һәм, озакламый аңа кияүгә дә чыгып куйган, — дип төгәлләде Ризван үзенең хикәятен.

## 3

Ниһаять, чират миңа килеп җитте.

— Мин, җәмәгать, сагынудан башлармын инде, — дидем мин, җиңелчә генә кызарып. Һәм санаторийдаш-ларымның, сүзләремне җөпләп, баш кагуларын күреп, кыюланып, сөйләп алып киттем.

— Менә мин әйтәм, яраткан хатыныңнан башка бер генә көн дә яшәмә икән, гүр газабы белән бер икән ул, җәмәгать... әле өйләнгәнемә туксан көн дә тулып җитмәгән иде, хатыным,

сагындым, дип, әтиләренә юл тотмасынмы! Бер генә көнгә, дигәч, карышмадым инде: барсын, күреп кайтсын, җирсүләре басылып китәр дә, тагын да матуррак итеп яши башларбыз, мин әйтәм. Өмет, дигәнең, канатлы кош сыман инде ул, кем әйткәндәй, очкан саен биеккәрәк очасы килә. Шулай ич, җәмәгать?

Ярый, хатын китте. Бер көн үтте. Ә мин көтәм зарыгып моны. Икенче көн дә үтте. Юк, кайтмый бу. Өченче көнне исә, чынлап торып, хафалана калдым. Һәм аптырагач-йөдәгәч, инде әйтергә бүтән сүзләр табалмый башлагач, ишекле-түрле киләп сарып, бер урысчалатып, бер татарчалатып, “вот ты черт побери а, менә син ә шайтан алгыры”, — дип, сөйләнеп йөрергә керештем.

Аһ, Ходаем-Аллам, янә сагыну сүзен телгә керткәч, хатыным кабат искә төшеп, тагын үзәкләрем өзелеп киткәндәй булды. Чөнки мин инде хәзер хатынымны гына түгел, әнисенең яралып килүче сөекле малаемны да сагына башлаган идем бит... Менә шуларны көчле бер сагыну белән сагынуым, озакламый күзләремнән, вак-вак энҗе бөртекләредәй елтыраша-елтыраша, тамарга тотынма-сынмы! Тып... тып... Гаҗәп! Тавышы үзе бер сихри музыка авазы шикелле, йөрәкне әллә нишләтә. Юк, ул йөрәкне ярсытмый да, тилертми дә. Хәер, бу турыда нигә сүз озайтып торырга? Кыска гына итеп әйткәндә, сагынам мин аларны, бик-бик сагынам! Шулай дип үз-үземә пышылдыйм да, утны сүндереп тагын йокларга ятам. Һәм күзләремне йомуым була, каршыма, көлемсерәп, янә хатыным килеп баса. Мин, ниһаять, үзем дә бу минутта әтиләрендәге хатыным каршында елмаеп басып торуыма төшенәм. Аннары шунысын да сизәм: хатыным каушый, дулкынлана төсле. Баксаң, ул үзе дә, мине сагынуына чыдый алмыйча, ут сулап ята лабаса! Шунда хатыным миңа бик-бик кызганыч булып китте. Һәм мин аның хәленә керергә тырышып: “Бик тә үтенеп сорыйм синнән, өйгә кайт инде багалмам!” — дидем. Ә ул, юашланып, чак-чак кына ишетерлек итеп: “Үзең кил, Гамбәр акыллым”, — диде. Һәм бераздан өстәп куйды: “Чәчәк белән кил, яме?!” Ә мин: “Ярар, акыллым...” — дигәнемне сизми дә калдым. Һәм икенче көнне чынлап та эштән кайтышлый базардан чәчәк бәйләме алдым да поселокка таба титакладым. Баярак кына, батырлык өчен дип, иптәшләрем белән кәгеп җибәргән идем, ярап куйды бу, мин сиңа әйтим: барам шулай җилле-җилле генә атлап, үземне арсландай хис итеп. Ләкин барыбер, зәңгәр рәшәткәле, биек нарат өйгә якынлашуга, йөрәгем дөп-дөп сикереп тибәргә тотынды.

“И-и, каушадың инде, ние бар соң моның, — дип эчемнән генә уйлап куям, — чәчкәләрне әнә теге чак кына ачык тәрәзә алдына куясың да, вәссәлам”. Дөрес, анысы шулай. Әмма мин бу юлы ашыкмыйм әле, чөнки шундый чакларда кирәгеннән артык кабаланып, күп мәртәбәләр авызым пешкәне бар инде минем. Шуңа күрә, кем әйткәндәй, бүрегем белән киңәшләшәм элек: хәзер үк керергәме бакчага, юкмы? Керсәм, анда кеше-кара булмасмы? Бит кайчакта кешесез дип кергән бакчада да, өстеңә ташланып, өзгәләп атарга әзер торган бульдог яки овчарканың булуы мөмкин түгелмени! Хәер, болай үзе бу бакча миңа шәп таныш. Кайда ничә төп алмагач, кура җиләге, күпме чия, карлыган барлыгын да беләм. Аннары боларның этләре юк та ич әле. Шулай булгач, ниятем минем хәзер кыю гына хәрәкәт итеп карау инде.

Ниһаять, менә мин инде бакчада, сәрви куаклары эченнән кызыксынып тирә-юньне күзәтеп утырам. Әһә, миңа кирәкле тәрәзә Көнбатышка караган булып, аңа сүнеп барган кояшның кызгылт нурлары төшкән. Әле иртәрәк булыр төсле, сабыр итәргә кирәк, дигән бимазалы фикер, кайнар хисләремне йөгәнләп, чабуымнан тартып тормасамы, һи, бая ук инде җимешемнең җылы коча-гында, назга сусаган җанымны сихәтләндерергә керешер идем. Мәгәр шунысы да бар, мин бу дөньяга мизгеллек утта янып һәлак булыр өчен туган күбәләк түгелмен. Мин, кыска гына итеп әйткәндә, кеше дигән серле зат булам лабаса!

Шул рәвешчә, үз-үзем белән бәхәскә кереп, күпме торылгандыр, берзаман көн тәмам караңгыланып, минем җанкисәгем бүлмәсендә дә ут алынуга, — бусында чынлап та түзмәдем, — тиз генә йөгереп чыгып, сак кына тәрәзәгә чирттем. Һәм шуны гына көткәндәй, бакча эчендә мәхәббәтле итеп бер кош сайрап җибәрде. Аннары, — беләм минем хәләл җефетем, — чак кына алга иелә төшеп, биек тәрәзә капкачларын як-якка каерып ачып куйды да, нәфис гәүдәсен яртылаш бакчага сузып, нәкъ мин посып утырган турыга, текәлә-текәлә карап тора башлады. Мин шундук берничә яфрак өзеп авызыма каптым, чөнки үзем дә сизмәстән, кинәт кенә аңа эндәшеп, эшне бозып ташлавым да бар иде. Нинди эш соң ул дисезме? Анысын менә бераздан күрерсез инде, бәгырькәйләрем!

Чү! Тагын бер кошның сайравы ишетелә башлама-сынмы, мин сиңа әйтим. Чут та чут, өзми-куймый сайрый бит, ә. Әллә бу да, минем кебек, гыйшкы янына сагынып килгәнме? Чү! Әнә алар парлашып сайрарга тотындылар бугай. Әйе, әйе...

Минем хатын шул кошларны, ягъни былбылларны күрергә теләп ахры, әсәренеп, карашын агачтан агачка күчерергә кереште. Ә мин аның таза ак беләкләренә, ачык изүеннән шәйләнеп торган йомры пакь күкрәкләренә янә бер мәртәбә исем китеп карадым. И гөлем, дим эчемнән генә, син мине үчекләгән сыман һаман яшәрә, һаман чибәрләнә генә барасың лабаса! Тик чит-ят адәмнәрнең күзе генә тия күрмәсен инде үзеңә!

Әһә... кошлар да минем уйларымны сизеп, — әллә бер-берсенә мәхәббәт уклары яудырып арыдылар инде, — тынып калдылар. Алар тынгач, хәләлемә дә кызык нәрсә бетте булса кирәк, ул тәрәзә каршыннан капылт кына кубып китеп барды.

Кулымдагы ал розаларның таҗларын йомшак кына сыйпаштыргалап куаклыктан чыктым һәм әле генә хатыным басып торган тәрәзәгә таба якынлаштым. Күрәм, хәләлем инде өстәл каршында утыра, алдында ачык китап, әмма ул китапка карамый бугай — укыйсы килмәүдән түгелдер, минемчә, баягы тәэсирләрдән соң тынычланып җитә алмый мөгаен — каядыр текәлеп уйга талган.

Карлыгачыма үземнең биредә инде килгән булуымны сиздерү өчен, чәчкәләрне җәһәт кенә тәрәзә төбенә куйдым да, тирә-юньгә әчкелт-татлы ис таратып торучы карлыганнар арасына кереп постым. Шулай яхшырак булыр кебек. Чөнки, болай эшләгәндә, чәчкәләрне китерүче кешенең кемлеге, хатыным өчен беразга гына булса да, табышмакка әверелергә мөмкин. Ә табышмак ул, билгеле инде, серле нәрсә, аның серен чишәр өчен ярыйсы гына уйланырга, баш ватарга кирәк. Һәм ничаклы озак баш ватсаң, шулхәтле күп шикләр күңелгә килә ки, кыскасы, мондый очракта табышмак дигәнеңнең чишелә алмастай катлаулы булуы — кем файдасына сөйлидер, белмим. Шулай да мин көтәргә булдым әле. Инде әнә күктә, биектә-биектә, йолдызлар балкып яна. Аларның һаман саен, бер-берсенә кысышкан сөрмәле һәм сөрмәсез күзләр кебек, җем-җем килеп куюлары гүя үзе бер табышмак инде менә.

Кинәт кайсы тарафтандыр салкынча җил исеп куйды. Ул йомшак кына сыйпап кытыклагандай итеп тәннәрне калтыратып җибәрде, борынга яшь үлән исе катыш, өлгергән чия исе килеп керде. Ай, мин әйтәм, рәхәт тә соң, күңелле дә соң биредә җәйге кич! Әнә, җитмәсә, төн уртасында яки таң алдыннан яңгыр буласын хәбәр иткәндәй, аҗаган да шаяра башлады. Яусын, әйдә, яңгыр кирәк безгә. Яңгырсыз яшәп булмый, шайтан алгыры, дип фәлсәфә корып маташканда гына, кинәт әллә каян бер көтү яшьләр, егетләр, кызлар килеп чыктылар да, бакча буеннан,

көлешә-көлешә, үтеп киттеләр. Җәйләүгә, кичке уенга баруларыдыр инде боларның, дидем мин, көнләшүгә охшаш бер хис кичереп. Һәм аннары, аңышып, ялт кына теге тәрәзәгә карадым. Гаҗәп! Мин алып килгән ал розаларны инде хатыным күкрәгенә кысып өлгергән... Беравык ул: “Бу кем эше булган соң әле?” — дигәндәй, ә бәлки кемнедер күрергә теләптер, бакчадагы караңгылык эченә текәлә-текәлә карап торды. Мин шунда, чынлап та бакча эчендә кеше барлыгын сиздерергә тырышып, үзем кереп поскан карлыганның бәләкәй генә бер корыган ботагын чытырдатып сындырдым.

— Кем бар анда? — дип, сәер генә итеп сорап куйды карчыгым.

— Бу... Мин... Гамбәр! — диюемне сизми дә калдым.

Минем тавышымны гына ишетте дә хатыным, шатланып. “аһ, Гамбәр... Гамбәр килгән...” — дия-дия, ашыга-кабалана әле бер аягын, аннары икенче аягын тышка салындырып, бакчага сикереп тә төште.

Карлыганнарны аралый-аралый яныма керү белән, мин аны биленнән эләктереп, үземә таба тартып та китердем. Аһ, гөнаһ шомлыгы, аның тылсымлы кара күзе елтырый, ялтыркыч бөҗәк шикелле; ирене татлы шәраб кебек, ә тәннәре, тәннәре, бәлеш пешергән мич сыман, кап-кайнар! Мәгәр үзе ни өчендер бөтен гәүдәсе белән калтыранып-калтыранып куя. Һәм күп тә үтми, аның калтырануы миңа да күчә...

— Н-н-ник кайтмыйча интегеп, бетеренеп ятасың син биредә, бәгырькәем? — дип, йомшак кына итеп сүз башлыйм мин шунда. — Әгәр дә эшләр алга таба да шушылай дәвам итә торган булса, син үзеңне дә юкка чыгарасың, мине дә харап итеп ташлыйсың: белмәсәң бел, җаныкаем!

— Әти җибәрмәде бит, бөркеткәем, — дип акланып маташмакчы була әле җефетем. Аннары минем тыныч-ланып калуымны тоеп, батыраеп, өстәп җибәрә: — Са-гындырган мәхәббәтнең кадере күбрәк була бит, Гамбәр-кәем, алтыным!

Чынлап та шулайдыр, ахры. Өч көн аерым торган хатынымның чак кына сулган йөзеннән һич кенә дә күземне ала алмыйм. Әйтерсең лә без бер-беребезне йөз көн күрмичә торганбыз.

Чү! Янәшәдә — куаклыкта нидер шартлап китте. Хатыным әллә куркуыннан, дерт итеп куйды, ә мин аның йомшак кулына орындым.

— Тс-с-с! Кемдер йөри... Ул буялган тырнаклы бармагын борыным төбендә уйнатып алды.

Әйе шул, безгә таба, кулына күсәк тоткан берәү якынлашып килә!

— Төнлә йөриләр, бизабразий, көндез килсәләр үзем дә кертеп ашатырыем, — дип, тыңкышрак тавыш белән сөйләнә үзе.

Мин һичкемнән курыкмавымны әйтә башлаган идем, мәгәр ул минем сүзләремә колак та салып тормады: "Аһ, мин бик куркам шул, Гамбәркәем!" — дип, тизрәк бөдрә чәчле башын күкрәгемдәге "карурман"га яшерде. Юк ла, курыкмый хатыным, кылануы гына бу аның, ягъни шаяруы, мине сынавы. Ә миңа нәрсә? Мин көтәм: тагын ни булыр?.. Ә тагын менә ни булды. Теге кеше безне күрепме-күрмичәме, әллә зирек, әллә карама күсәге белән җиңелчә генә аркаларыбыздан сыйпаштыргалап үтеп тә китте. Ул чак кына ерагая төшкәч, без икебез дә җиңел сулап куйдык. Мәгәр тынычланып калырга ярамый әле, чөнки тегенең тагын әйләнеп килүе мөмкин. Шуңарга күрә хатыным мине җиңелчә генә шелтәләп:

— Бар инде, Гамбәр бәгырем, син капкадан гына кер, — дип, үзе кача-поса гына тәрәзәгә таба юнәлде.

Хатыным әнә тәрәзәләрне ябып, затлы пәрдә белән корып та куйды һәм, мине каршылар өчен, кече якка чыгып китте шикелле. Ә мин капка баганасына сөялдем дә, ләззәтләнеп тәмәке көйрәтергә керештем. Их, төне, һавасы, җылы, рәхәт. Рәшәткәләр каршында ятучы тага-рактагы суда айның ак шәүләсе чагыла. Җәйләү тарафында чикерткәләрнең сайрашкан авазлары ишетелә. Менә бакчадан әллә алма, әллә туйра күсәген күтәреп бабай килеп чыкты. Ул мине танып, күрешергә кулын сузды.

Хөрмәтле бабакаем мондый очрашуга канәгать иде бугай. Мин дә, эчемнән генә көлемсерәп, өйгә кереп киттем. Анда мин кадерле әбкәйнең "кияүкәем килгән!" дигән шат авазын ишеттем, сөекле хатынымның "бәлеш тә пешеп чыккан, әни!" дигән сөенечле тавышын ишеттем.

...Мин хикәятемне тәгәлләп, хәләлемнең өч чорда төшкән өч фотосурәтен чыгарып күрсәттем. Илгизәр үсмер кыз сурәтен тиз генә кулына алып:

— А-а, бу — мин гашыйк булган Фирая ич! — диде.

Ризван студент кыз сурәтенә үрелде:

— Бу — мин гашыйк булган Фирая шул! — диде.

— Алайса, бу сурәтләр сездә калсын, егетләр, — дидем мин, — истәлек булып!..

Илгизәр белән Ризван сораулы карашларын миңа төбәделәр.

— Фирая юк инде! — дидем мин. — Бала тудырганда вафат булды ул!
Шуннан соң палатадашларым, йөрәкләрен учлап, торып киттеләр. Мин дә алар артыннан иярдем.

## *Очрашу*

Автовокзалга килеп, бикле касса алдында торган бөкре егетне күргәч, бөкре кызның тигез ак тешләре елтырый башлады.
— Килмим, дип киткән идең, килгәнсең бит!
Бөкре егет майлы эшләпәне кая куярга белмәгәндәй кулында әвәләп:
— Килдем инде менә, — диде. — Килми кая барасың... Вакыт инде...
— Нәрсәгә вакыт?
— Өйләнергә дим. Күпме мөмкин. Мин, эш калдырып, һаман болай килеп йөри алмыйм ич инде... — Аннары ул, төрлесе-төрле якка тырпайган кап-кара чәчле башы белән, тәрәзәгә, урамда торган зәңгәр тракторга таба ымлады. — Киттекме?!
— Кая-а?
— Безгә, авылга!
Бөкре кыз әллә шаяртып, әллә чынлап егетнең бөкресенә төртеп куйды. — Кит, исәр! Мондагы җәннәтне ташлап, авылыгыздагы тәмугка кайтып керергәме? Уйлама да! Әгәр теләгең булса...
Бөкре егет, кая барырга белмичә кычкырып йөргән сары мәче баласына карады.
— Мин монда торырга килгәч, авыру әниемне кем карар? Аннары трактор да кызганыч! Бөтен бәхетем, тапкан табышым шуннан гына бит инде...
— Алайса, авылыңда гына яшә! — диде кыз. Һәм бик хәтәр җилләнеп ишеккә таба борылды.
— Туктале... — диде бөкре егет һәм, кыз артыннан калмаска теләгәндәй, берничә адым алга атлап куйды. — Монда килгәч, мин кайда эшләрмен соң?
Бөкре кыз, ишеккә җиткәч, егеткә таба борылды:
— Мин бухгалтер-хисапчы булып эшли торган сәүдә берләшмәсенә экспедитор кирәк. Уйла!

— Ә андый эш, — диде егет исе китеп һәм башын чайкап куйды. — Юк, миннән булмый... счет төймәләрен тартырга түгел, трактор рулен борырга гына өйрәнгән шул минем куллар, Салиха!

— Чао! — дип, кинәт кычкырып җибәрде бөкре кыз һәм, урамга чыгып бераз барганнан соң, артка таба борылып карады да, егетнең тракторын “биетә-биетә” китеп баруын күргәч, усал итеп елмаеп куйды: “Утызга чаклы ирсез яшәдем — үлмәдем әле, утыздан соң да үлмәм, боерса!.. Кама буенда җиләк-җимеш бакчам бар, ә янәшәсендә, дөньяның иң көчле ике көрәшчесен кертеп көрәштерерлек дәү, яңа йортым тора!..”

Йокыдан уянгач, тәрәзә каршына барып басам. Мин өйдә көзге тотмыйм һәм аның миңа кирәге дә юк... Әйе һәм... текәләм Камага! Төнозын сандугачлар чутылдашкан бакчам тарафыннан хуш исләр килә... Офыкта, кеше канына манган сыман кып-кызыл булып, кояш уянып маташа. Кама дулкынлана, моңлана. Кояш күзләрен ачканчы, су эченнән бер бөкре баһадир килеп чыгар да мине көймәсенә утыртып, әнә теге утрауга алып китәр кебек... Еракта ак теплоход күренә... Әнә шул утрауда, сусыл үлән эчендә ятам, имеш, мин, бөкре баһадир кочагында... И хыял! Егерме яшьлек чагымдагы кебек тилертәсең син мине — утызга җиткән кызны!.. Чынлыкта исә бөкре егет мине, Кама эчендәге яшел утрауга түгел, авылындагы өенә, авыру анасы янына алып кайтырга килгән иде... Аһ, бу нинди көлке, нинди түбәнлек! Юк! Юк! Мин, иң яхшысы, хыялымдагы баһадир егет белән генә яшәп калачакмын!.. Мин бай бит! Минем байлыгым — бәхетем ул! Мин әле тагын да череп байыйачакмын...” — Бөкре кыз яр буена килеп чыккан иде. Түбәндә, зур көймә янында, балыкчылар кайнаша. Араларында бер бөкре ир дә бар. Бөкре ир тураеп, Салихага карап куйды. “Чиләгенә күрә капкачы...” — дигән әйтем килде кызның күңеленә. Һәм ул, яр буеннан, тиз-тиз генә китеп барды. “Әлеге ир өйләнгән микән? Баймы икән ул? Бәлки, өйләнмәгәндер дә... бәлки, бай да түгелдер. Чөнки бай булса, хурланмыйча, мопедка гына атланып йөрмәс иде, — матайның затлырагына йә булмаса автомобильгә үк утырыр иде. Ә үзе, минем кебек үк, бухгалтер-хисапчы... Дөрес, мин — сәүдә берләшмәсендә, ә теге ир — комбинатта! Һе, кызык инде: комбинат... бухгалтер — хисапчы һәм мопед кына, — дип көлеп куйды бөкре кыз. — Бик белеп әйткәннәр инде: иртә уңмаган кич уңмас, дип, бик белеп... Шулай шул, һөнәрең өлкәсендә иртә профессиональләшә белмәсәң, ач тамагыңны туйдырыр өчен, балык тотып ашарга кала инде аннары. Ә мин менә... Салиха куркынып як-ягына каранып куйды. Юк

икән, берәү дә аның күңелендәге уйларын укырга җөрьәт итми... — Әйе, эшли башлавымның икенче елында ук... Дөрес, бу турыда миңа берәүнең дә әйткәне юк иде. Мин аны үзем... Мескен, тәҗрибәсез кибетче абзый, сыерын сатып, мең тәңкәне китереп түләде. Ә ул мең тәңкәне мин склад мөдире белән уртак иттем. Шуннан башланды инде минем байлык артыннан кууым... Кибетче абзыйдан соң, тәҗрибәсез кибетче апайны төп башына утырттым. Элек ул фермада сыерлар сауган икән. Эшләп-эшләп тә байый алмагач, бәхетен сынар өчен, сәүдә өлкәсенә аяк басып караган, мескен. Тормыш тарафыннан кыйналган мондый кеше, гадәттә, кибеткә кереп эшли башлау белән үк, тизрәк баер өчен, сатып алучыларны уңлы-суңлы алдарга тотына. Бу апа да... ләкин үзенең склад мөдире яки бухгалтер-хисапчы тарафыннан алдануын белмәгән! Менә мин башны эшләтә белгәч, бай яшим, рәхәт яшим!” Сәүдә берләшмәсенә җитәрәк, бөкре кыз кинәт туктады, йөзен кара болыт баскан сыман булды, күзләреннән нур качты. Баскыч култыксасына сөялгәннәр, торалар...

“Кара, кара... авызга авыз куйганнар... кочаклашып үбешәселәре генә калган инде. Оятсызлар!”

Бөкре кыз баскычтан менеп барышлый янә тегеләргә бораулап карады... Сәүдә берләшмәсендә кадрлар буенча инспектор булып эшләүче Вәлидәне җаны-тәне белән күрә алмый иде ул. Кыз яшь, искиткеч чибәр һәм зифа буйлы. Аннары, егетләрнең асыллары да аның өчен утка-суга керергә әзер бугай. Менә шул асыл сөяк янына кичә бер матур егет килгән иде. Бүген тагын да матуррак егет килгән!.. Әмма тегеләр, бөкре кызның бар икәнен дә белмичә, авызга авыз куеп диярлек, гәпләшүләрендә булдылар. Дөньяда алар гүя икесе генә...

“Һай, мәхәббәттән күзләрегез томаландымы? Исерешеп беттегезме? Ярар, һаман күктә генә очып йөри алмассыз, берзаман җиргә дә әйләнеп кайтырсыз һәм шунда минем кем икәнлегемне... Юк! Юк! Мин сезгә кемлегемне үзем танытырмын! Чао!..”

Салиха, биек үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, хисапханәгә керде. Кайсы аңа күзлеге астыннан гына төбәлде, кайсы күтәрелеп бакты, кайсылары исә борылып карады. Һәммәсе дә эш белән мәшгуль иде. Әйе, өлкән бухгалтер эшләтә белә аларны!

Бөкре кыз “здравствуйте!” диде. Кемдер “здраствуйте” дип, аның сәламен алды, кайберәүләр исә башын кагып кына куйды.

Салиха үз өстәле янына килеп утырды. Кәгазь тавын бер кырыйга этте дә буш урынга редикюленнән көзге һәм бизәнү

әйберләре чыгарып салды... Тирә-юньдә шалт-шолт счет төймәләре тарталар, механик хисаплау машинкаларын зеңгелдәтеп алалар, ул да түгел, автомат аткан тавышлар чыгарып, электрон язу машинкаларын шакылдатып җибәрәләр. Һәм кыштыр-кыштыр кәгазь актаралар... Кызылга буялган озын тырнаклар, зәңгәр күз кабаклары, сөрмә тарткан керфекләр, ясалма рәвештә алсуландырылган битләр һәм кара чәчне — сарыга, коңгыртны — бакыр төсенә манып бөдрәтелгән башлар ялт-йолт күренеп кала. Мондагы исләрне иснәгәч син үзеңне парфюмерия фабрикасы цехлары буйлап йөргәндәй хис итәсең. Монда һичнигә ис китү һәм гаҗәпләнү юк. Әнә, баш бухгалтерның киявеннән аерылган яшь һәм чибәр урынбасары кәгазьләр тотып каршында басып торган экспедитор егеткә матур итеп елмаеп маташа.

— Син миңа менә мондый ни алып кайтып бирә аласыңмы, җаным? — дип аңа нидер күрсәтте дә бугай әле.

Егет кып-кызыл булып кызарды. Аннары үзен кулга алып:

— Ярар... Универбазага баргач сорап карармын, — диде. Һәм кәгазьләренә кул куйдыргач, ишеккә таба китте. Чыгып китәр алдыннан туктады да, нидер көткәндәй, артына таба борылып карады. Баш бухгалтер урынбасары тагын елмайды һәм өстәл артыннан чыкты: хезмәттәшләре алдында башын горур гына тотып, егет артыннан бара башлады. — Алайга киткәч инде... киноларга йөрербез. Син миңа шоколадлар алып килерсең, яме, — дип шаяртырга ук кереште.

Менә нинди алымнар белән дә капкынга эләктерә белә хатыннар заты ир-егетләрне!.. Бөкре кыз бизәнеп бетерде дә, кинәт үрелеп, товаровед Луизаның күкрәкләрен капшап алды.

— И кызый, бюстгальтер кимәгәнсең икән ич син! Әйтәм аны...

— Кимәдем шул. Эссе бит. — Һәм Луиза башын борып, Салиханың колагына нидер әйтте. Бөкре кыз шаркылдап көлеп җибәрде. — Кит җүләр! Урамнан барганда җил ачып җибәрсә?

Татар кызы Луиза җавабының яртысыннан күбрәген русчалатып әйтте. Русчасы да шома чыкмый иде... Салиханың күңеленә кыю фикер килде. Әгәр дә бу әкәмәт кызны котыртып, Вәлидәгә гашыйк булган теге егет белән уртак тел таптыра алсам — йөрәгем тынычланыр иде аннары. Чөнки, миңа өйләнергә килгән баягы бөкре егет Вәлидәнең абыйсы иде бит. Ул барыбер минем сүземне тыңламады — бәхетле итәргә теләмәде. Кашки, Вәлидә сеңлесе дә бәхетле булмасын!..

Бөкре кыз Луизага ниятен кыскача гына сөйләп бирде.

— Ә-ә-ә... син аны әйтәсеңмени, — диде Луиза куе коңгырт күзләре белән томырылып карап. — Мин беләм ул егетне. Таңнур исемле ул. Көмеш Елгада туган. Сәүдә техникумын тәмамлаган. Армиядә хезмәт итеп кайткан. Хәзер монда урнашырга йөри. Әмма аның һөнәренә яраклы эш юк әле. Корбан Хөснуллович аңа безнең авыл кибетендә сата торырга кушкан!

Бөкре кыз кара янып килде. “Ай-һай, күп белә бу!.. Таңнур диме? Үземнеке итәм диме?.. Тфү!.. Вәлидәгә әйтеп куярга кирәк әле: Таңнурны Луизага бирмәсен!.. Һәм... Вәлидәгә дә булмасын ул егет!.. Миңа бик ошый Таңнур. Дөрес, миндә егет-караның күзе төшәрлек буй-сын юк! Ләкин, аның каравы, Таңнурны пан итәрлек байлыгым бар!..”

Бу вакытта Вәлидә болдырда Таңнур белән саубуллашып тора иде. Соңгы сүз итеп кыз егеткә бухгалтер-хисапчы Салиха белән әчеләшмәскә киңәш бирде. Таңнур бая бухгалтер-хисапчының тәбәнәк кенә бер бөкре хатын икәнлеген күреп калган иде. Көлемсерәп, мускуллары кабарып торган беләкләренә ымлап:

— Миңа, тик торганда, явызлык кылсалармы?! Аларны басып, бөҗәк урынына сытачакмын! — дип, йодрыкларын селекте.

Сүз дә юк, егетнең тәннәрендә көч ташып тора. Әгәр дә ирек бирсәң, ул, мөгезеннән тотып, үгезеңне дә әйләндереп салыр шикелле.

Вәлидә тыныч кына итеп әйтте:

— Көчеңне сабантуйга калдырып тор, Таңнур, хәзергә акыл һәм сабырлык канатлары юлдаш булсын үзеңә, яме!

Егет кызга: “Өф итеп өрсәм, мамыктай очып китәсең инде син, ә кочагыма алып кыссам, майдай эреп төшәчәксең”, дигәндәй, шаяртып күз кысты. Ләкин Вәлидә җитди иде. Һә ул: “Син минем турыда теләсә ни уйла, Таңнур, ә мин, барыбер, бая әйткән сүзләремне сүз итәм”, дигән шикелле, ялт кына, ишектән кереп югалды.

Таңнур, товаровед Луизаның туган авылына, Чакмагышка кайтты. Авыл советы рәисе аны фатирга ялгызак әбигә керткән иде. Әбинең эшләргә хәле юк, һаман авырый, урын өстендә ята... Егет, райүзәктән алып кайткан күчтәнәчләрен өстәлгә куйгач, самавырны кайнатып чыгарды. Кыстый-кыстый әбигә өч чынаяк чәй эчертте.

***

Эшли башлавына ике ай булган иде. Кич кибеткә берләшмәнең йөк төяүчесе, алкаш Абдул килеп керде. Кайчандыр институт

тәмамлаган, җинаять кылып утырып чыккан һәм эчүе аркасында түбән тәгәрәгән адәм иде бу.

— Здорово, брат! — дип гадәттәгечә урысчалатып кына сәлам бирде Абдул Таңнурга. — Как поживаешь?.. Еще не женился, а?!

Чәй, шикәргә килгән Вәлидәнең әнисе, ни әйтер икән дип ахры, ялт кына Таңнурга карап куйды. Ләкин егет Абдулга эндәшмәде, сузган кулын бик җитди кыяфәт белән кысты да, Вәлидәнең әнисенә көмеш акчалар кайтарып бирде.

Кибеттә алар икесе генә калгач, йөк төяүче прилавкага таянды һәм Таңнурга таба башын сузып, саф татар телендә:

— Сине кодаларга (өйләндерү максаты белән) килдем мин, — диде. — Кемгәме? Үзең чамала!

— Луизага?!

— Юу-у-ук!

— Вәлидәгә?!

— Түгел лә инде!

— Алайса... кемгә?

Абдул карашын тәрәзәгә төбәде, ишек буена барып тыңлап торды, аннары янә прилавкага таянып, Таңнурга туп-туры текәлде:

— Сиңа... бухгалтер-хисапчы Салиха гашыйк булган!

Таңнурның кулыннан өч литрлы сок банкасы төшеп китә язды. — Бөкере ич ул?!

— Ба-а-ай ул... Аңа өйләнсәң пан буласың, беләсеңме шуны!

— Төкерәм мин аның кеше талап җыйган байлыгына!

Абдул, пуля кебек, тышка атылды.

Иртәгесен Таңнур капкадан чыгып бераз баргач, күр-ше карчык очрап:

— Мәскәү конфеты белән тәмләп чәй эчтек бүген... И тырыш та егет булып чыктың син, рәхмәт яугыры... Инде үзеңә бик акыллы, эшкә уңган бер кыз туры килеп, кавы-шырга насыйп итсен, — диде.

“Шул сүзләрне әйтер өчен генә көтеп торган инде бу хәйләкәр түти мине”, — дип уйлады егет. Бу таза кар-чыкның төпчеге сәүдә берләшмәсендә товаровед булып эшли инде. Ул — Луиза! Кичә кич Таңнур райүзәккә Вәлидә янына баргач, Луизаның бер егет кочагында эреп утыруын күргән иде. Җавап бирмичә, тиз-тиз генә тыкрыкка борылды.

Таңнур автобустан төшеп райпога килеп кергәч, кори-дорда кешеләрнең юклыгына, контора хезмәткәрләренең тыз-быз йөреп тормауларына гаҗәпләнмәде. Чөнки бүген яңа айның беренче көне. Ә отчетларын сатучыларның күпчелеге иртәгәсе көнне генә

китереп тапшырырга тиешләр шул. Әмма Таңнур иртәгәсе көнне көтеп тормады инде.

Менә ул ишекне ачты. Калын көр тавыш белән: — Исәнмесез-саумысыз! — диде.

Таңнурны күргәч, кемнәрдер елмаеп җибәрде, кемнәр-дер сагая төште, ә бөкре кыз исә, гүя овчаркага әверелде: егетнең кулындагы кызыл папканы тартып диярлек алды да, ачып, эчендәге кәгазьләрне өстәлгә таратып салды һәм бер кәгазьне шундук иясенә таба ыргытты.

Бухгалтер-хисапчы:

— Дүрт йөз тәңкәне кесәңә салып куярга ният-ләгәнсең, безне алдап, — дип кычкырды

Таңнур, сабыр һәм акыллы булырга тырышып, әйтте:

— Мин машинага төп-төгәл егерме капчык шикәр комы төягән идем, үзем төядем: артык та түгел, ким дә түгел...

— Нигә минем башымны катырасың: утыз капчык төягәнсең бит инде-е-е!..

Таңнурның яңак мускуллары тартышып куйды.

— Кем әйтте аны?

— Склад мөдире!.. Тиз бул! Алып кил син аны мон-да! — дип ыржайды бөкре кыз.

— Хәзер, хәзер алып киләм, — дип, бәйдән ычкынган үгез бозау кебек, ишеккә карап куйды Таңнур. — Сез мине белмисез әле... Минем шаһитлеккә шоферым бар... Мин керем-чыгым кәгазьләренең күчермәләрен амбар кенәгәмә терәп барам... Мин сезгә әле...

Мәгәр бөкре Салиха аңа игътибар да итмәде.

Сатучы егет уйга бирелде. Әйе, ул көнне кырда Луиза белән чәчәкләр җыеп йөргән иде шул. Баштарак үтә әдәпле булып күренгән иде аңа чибәр кыз. Ә инде җил исеп китеп, күлмәк итәген күтәреп җибәргәч һәм Луиза сагыз кебек аңа сылана башлагач, сагая калды егет. Шуннан шул! Кибеткә кайтып сата башлагач, Таңнурга: районнан шалтырату-ларын да, бухгалтер-хисапчының килүен дә әйттеләр. Ләкин, ни өчен шалтыратканнар? Ни өчен килгән? Бусына берәү дә җавап таба алмады. Дөрес, сатучы егет хәбәрләрнең сәбәбенә соңыннан бераз төшенде-төшенүен. Чөнки, шикәр комына бирелгән кәгазьдә сумма дөрес чыгарылмаган, шуны төзәтергә кушулары булгандыр!.. Ә чынлап торып баксаң, тегеләрнең ниятләре бөтенләй бүтән булган икән!

— Йә, ни эндәшмисең?.. Бездән качып йөреп, вакытны үткәреп, дүрт йөз тәңкәне отарга уйладыңмы?! Әзмәвердәй егет тамагына утырган төерне йота алмый азаплана иде.

— Күз көеге булып торма монда! Бар склад мөдире янына: гаебеңне таны! Юкса, бу эшеңне азагы хәерле булып бетмәс!

Керосинга манган кәгазь кебек, Таңнур кинәт дөрләп кабынды:

— Алдакчылар! Кеше талаучылар!.. Өйрәнеп беткән-нәр... — Сатучы егет имән бармагын түшәмгә таба төр-теп: — Анда Совет власте бар әле! Гадел суд бар! — дия-дия чыгу юлына борылды. Ишекне ачып җибәрүгә ул алкаш Абдул белән йөзгә йөз очрашты.

— Нәрсә булды? Ник болай тавышланасың? — дип сорады югары белемле йөк төяүче.

Буйдак Абдул үз карьерасына төкереп караса да, бәхетсезлеккә тап булган кешеләр өчен киңәш-табыш итәргә ярап тора иде әле. Ул, Таңнурны бик бирелеп тыңлагач, тыныч кына әйтеп куйды:

— Шул инде, Салиха маташтырган эш бу! Теге сүзләрең өчен үч алуы! Ләкин бу бәладән котылуның бер юлы бар-барын...

— Нинди юл?

— Сиңа Салихага...

— Өйләнергә? Юк! Анысы булмас!

— Алайса, дүрт йөз тәңкәне чыгарып түлисең инде, егетем! — Алкаш Абдул, ат кешнәгән тавыш чыгарып, эре сары тешләрен күрсәтеп, хихылдап көлеп җибәрде. — Районыбыздагы Совет власте нәкъ менә Салиха абыйсының кулында инде ул! Ә склад мөдиренең энесе — сәүдә министры! Аннары райкомда да, прокуратурада да аларның туганнары... Так шту, дустым... шулай, — диде дә алкаш Абдул, куеныннан бөкләнеп беткән ниндидер кәгазь чыгарып һәм аны бик җитди кыяфәт белән кулына тотып, хисапханәгә кереп китте.

***

Алкаш Абдулның кәгазенә (хезмәте өчен) кул куеп җибәргәч, бухгалтер-хисапчы телефонга ябышты:

— Ә, Җәбраил абый?! Әйе, син кирәк идең миңа! Теге малаймы? Килде! Аңлаттым! Инде хәзер, Җәбраил абый, бөтен өмет синдә... Ә? Ничек? Ие, ие, аңладым!.. Димәк, боларын да аңа түләтәбез. Яхшы... хәзер язып куйыйм әле: йөз егерме капчык он, тәк, йөз егерме кило чүпрә... булды... шулай эшлә. Әһә... төяп китеп баруга ук шалтырат: үз кешеләребез булсын... Акт төзесеннәр... Ярый, чао!

Бу вакытта Таңнур, яңарак кына нечкә билле экономист кыз чыгарып элгән ярыш экраныннан үз исем-фамилиясен эзләп, бармакларын түбән таба шуыштырып маташа иде.

Шул мизгелдә председатель бүлмәсенең ишеге ачылып китте:

— Ай-һай, нинди кояшның нурлары коридорны яктырткан икән дисәм, Таңнур елмаеп тора икән әле... — Корбан Хөснуллович яныннан чыгып килүче товаровед Луиза шат иде. Һәм ул, егеткә орынып ук диярлек туктап, карашын экранга төбәде. — Ә менә икән хикмәт нәрсәдә?! Котлыйм, Таңнур... — Кызның кайнар тән җылысына бу юлы да алданмады егет. "Рәхмәт!" диде дә, читкәрәк китеп басты... Егетнең күңеле нидән боегып калганлыгын кыз белми иде. Һәм аңа бу турыда егет берни дә әйтмәгән иде. Шуңа күрә Луиза Таңнурга булган элеккеге үпкәләрен онытып, тик үз гаменең генә колына әверелгән кебек иде бу минутта. Чөнки ул әле генә Корбан Хөснуллович бүлмәсеннән дөньядагы иң бәхетле кеше сыман булып чыкты. Председатель аңа, бүгеннән башлап районың өлкән товароведы итеп хис кыл үзеңне, диде ич. Үсү бит бу. Күтәрелү. Мондый чакта акыл белән хисаплашып торалар димени?

Луиза янә егеткә елышты һәм: — Әйбәт иттең, Таңнур, безнең Чакмагышта да яхшы кешеләр яшәвен исбатлап бирдең, молодец! — дип, сандугачтай чут-чут итеп сайрарга кереште.

Күренеп тора, күпме өмет тә итми инде кыз: азга гына, бик азга гына менә шушы дегеттәй кара бөдрә чәчле кибетче аны көчле күкрәгенә кысып сары майдай эретсә аңа шул җитә... Аннары Луиза сөенә-сөенә үз бүлмәсенә кереп китәр һәм илһамланып өлкән товаровед булып эшкә керешер... "Һәм аннары ул мине онытыр, — дип гасабиланып уйлады егет. — Чибәр кызларның хисләре тотрыклы буламыни. Аларның җилбәзәк күңелләре чәчәкләрнең күп һәм төрледән-төрлесен тели ләбаса. Ә минем күңелем, киресенчә, чәчәкләрнең иң асылы бер генә, минем чәчәгем булуын гына тели. Ул — Вәлидә!"

Вәлидә инде бу вакытта Корбан Хөснуллович бүлмәсендә утыра иде.

Таңнур армиядә чакта взвод командиры увольнениегә чыгарга әзерләнгән солдатларга әйтә торган иде: "Егетләрнең кайберләре чит кызлар яки хатыннар янында йөреп таушалып бетәләр дә, өйләнгәч, аннары аларның үз хатыннары да..."

"Ләкин мин Вәлидәмнең андый әшәке булып чыгуын теләмим", — дип уйлады Таңнур һәм бөдрә чәчләрен тараган булып, Луизадан читкәрәк китеп басты, шул ук вакытта сөйләшүен дәвам

итте. — Чакмагышта да кешеләр безнең Көмеш Елга кешеләре кебек үк икән. Араларында, әлбәттә, чикерткәләр дә юк түге, әмма кырмыскалар күбрәк...

— Мин менә Чакмагышта тусам да, читтә үскәнмен, шуңа күрә... — дип Луиза, русча белән татарчаны бутап, күзләрен сәер елтыратып, әллә ниләр сөйли башлады... Кичә кич кенә бу — автобус тукталышында бер сакалбай кочагында тора иде. Ә бүген менә Таңнур каршында чытлыклана кыз. Моны ничек аңларга? Әллә, бетәсе баш бетә дип, кызның теләген кабул итәргәме? Юк, юк... Таңнурның күз алдына җитди йөзле лейтенант Фәрманов килеп басты. Фәрмановта хатын-кыз затын һуштан яздырырлык чибәрлек юк, әмма хәләл җефете аның акыллы күзләренә генә карап тора иде шикелле.

"Өйләнгәч, Вәлидә алдында үкенмәс өчен чынлап та алдан хәстәрен күреп куярга кирәк миңа да", — дип уйлады Таңнур һәм Луизаның шаян соравын җавапсыз калдырды, монда килгәндә тузан кунган дигән булып, иелеп чалбар балагын каккаларга кереште.

"Егетләрнең бер ишләре биләгән постлары буенча үзләреннән югарырак урында утыручы кызлар каршында бигрәк тә җитди булып күренергә тырышалар. Хәтта ки җай чыкканда чак кына шаяртып алырга мөмкин икәнлеген дә белмиләр. Белсәләр дә белмәмешкә сабышалар, күрәсең", — дип, төшенкелеккә бирелеп уйлады Луиза... Аларны баядан бирле ашардай булып, каршыдагы бүлмәнең ачкыч тишегеннән, бөкре Салиха күзәтеп тора иде.

Шул мизгел Корбан Хөснуллович бүлмәсеннән Вәлидә килеп чыкты. Луиза ни өчендер кып-кызыл булып кызарды һәм кырт борылып китеп барды... Вәлидә Таңнурга беренче мәртәбә күргәндәй игътибарсыз гына карап, кырыс, катгый итеп:

— Автобиографиягезне язып кертерсең әле миңа! — диде дә, үтә эш кешеседәй ашыгып, үз бүлмәсенә кереп китте.

Керсә — кадрлар начальнигы булып эшләп күптән түгел генә пенсиягә чыккан Харитон Храмышевич үз бакчасыннан бер кочак роза өзеп китергән дә өстәлдәге сулы вазага утыртып куйган. Чәчәкләр арасына кәгазь дә кыстырган икән. Кәгазьдә язу:

"Сеңелем Вәлидә! Кадрлар начальнигы булып эшкә керешүеңне кайнар котлыйм. Киләчәк тормыш күгең һәрвакыт аяз, саф һәм кояшлы булсын".

— Рәхмәт Харитон Храмышевич! — диде кыз авызы белән кош тоткандай сөенеп. Бераздан: — Менә инде бүгеннән башлап мин сезнең урында утырып эшләячәкмен, — дип, Харитон

Храмышевич урынына килеп утырды Вәлидә. Кулларын бер-берсенә кушырып чак кына тын утыргач, кызның күзләре үзе утырып эшләгән урынга төште.

— Ә минем урында кем?! — Кызның күз алдында мәһабәт гәүдәле Таңнур җанланды. Әйе, кадрлар инспекторы булып Таңнурның эшләвен тели Вәлидәнең күңеле. Ләкин бу мөмкинме? Таңнур үзе теләп алынырмы бу эшкә? Баярак кына ул коридорда Луиза белән әнә ничек елмаеп сөйләшеп тора иде. Ә миң, сөйләшү түгел, күтәрелеп тә карамады. Юк, яратмый ул мине, — дигән карарга килде кыз. — Әгәр яратса, минем аның өчен генә тырышып йөрүләремне күрми калмас иде. Ярый... Таңнур мине яратмасын да ди. Һәм ул минем урында кадрлар инспекторы булып эшләргә дә риза ди. Әмма ул егет Харитон Храмышевич сыман һәрвакыт ачык йөзле, шат күңелле була алырмы? Яки пеләш башлы председатель кебек итәгатьле, яки югарыдан килеп районның эш-планнарын тикшереп йөрүче түрә шикелле: "Гаҗәеп сөйкемле туташ сез. Затлы сез. Сезгә сокланмый һич мөмкин түгел!" — дип, Вәлидәнең кулын үбәрме Таңнур?!

***

Таңнур контордан чыккач туп-туры складларга таба юнәлде. "Луиза болай әйбәт кенә кебек, ләкин искиткеч чибәр. — Мине күбрәк кызыйның әнә шул ягы куркыта бугай!..

Таңнур складка килеп кергәндә чөгендердәй кызыл йөзле Җәбраил Исмәгыйлевич "Галиябану"ны көйләп, бармагын фактурадагы саннар өстеннән шудыра-шудыра, счет төймәләрен тартып утыра иде.

Кычкырып сәлам биргән авазга ашыкмый гына башын күтәрде, зәп-зәңгәр күзләрен егеткә төбәде. Сыный карап торгач, телгә килде:

— Син конторда булдыңмы?! Ник алайса, Мәскәү конфетына яңа бәя килүен белмисең. Ә, ничек сатып бетердең? Дефицит әйберне шулай тиз саталармыни! Без бит сезгә андый җитешмәгән товарны пайга гына сатарга бирәбез!..

Җәбраил Исмәгыйлевич көчәнеп кычкырудан зәңгәр-ле-кызыллы булды. Муен тамырлары бүртеп чыкты. Ул урыныннан торды. Таңнурга текәлеп карап куйды һәм тавышын күтәреп, дәвам итте.

— Ничә тапкыр кисәттеләр сине, егетем: дефицит товарны алып кайткач ук сатарга керешмә, райподан хәбәр иткәнне көт дип...

Менә максатыңа ирешкәнсең икән. Килосына сиксән тиеннән. Тәк... йөз алтмыш сум зыян! Үз кесәңнән чыгарып түләрсең, яме!..

"Теге ялган дүрт йөз турында аны-моны әйтми әле бу, хатасын таный, ахры! — дип уйлады сатучы егет. Аннары конфет темасына әйләнеп кайтып: — Монда минем тамчы да гаебем юк! — диде. — Мин конфетларны складтан сез язып чыгарган бәядән саттым. Шулай булгач...

Җәбраил Исмәгыйлевичның сары керфекләре дерт итеп китте. Ләкин ул эчке каушавын тиз җыйды. Үзеннән бу егеттән гаять көчле икәнлегенә ышанып һәм шул ук вакытта кисәтеп әйтте:

— Шырпы тотып бензин тирәсендә йөрисең, Ярмиев. Сыздың исә беттең. Миңа очкыны да төшмәячәк. Әмма...

Азык-төлек склады мөдиренең бу сүзләрен Вәлидә Нурулловна да ишетте. Ул баярак кына ревизор кыз белән кием-салым складына таба китеп бара иде. Җәбраил Исмәгыйловичның хаксыз сүзләре колагына ирешкәч, ревизор кыздан аерылып калды Вәлидә.

Таңнурның: "Гаеп миндә түгел, сездә, күсәкнең юан башы сезнең җилкәгә төшәчәк", дигән җавабы, уйланып җитмәгән, бары тик кызулыктан гына әйтеп ташланган шикелле иде. Бит гаеп Җәбраил Исмәгыйлевичта да юк кебек", — дип уйлады Вәлидә Нурулловна. Шулай да бу күңелсез эшнең төбендә Таңнурдан үч алу теләге яшеренеп ятмыймы икән. Бит Таңнур күп белә, ишетә дә, күрә дә, имеш. Өстәвенә ата шикаятьче дә әле ул, һи, булмагае, шунда... Җәбраил Исмәгыйлевичның туганы әнә база директоры. Ә база директорының хатыны? О-о!.. Бәс шулай икән инде, монда хәлләр арсланның филгә каршы көрәшкә ташлануы кебек кенә... Димәк, Таңнурга йөз алтмыш тәңкәне...

Яшь кадрлар начальнигының уйларын склад мөдире бүлдерде. Ул күкрәгеннән чыккан калын тавыш белә сатучы егеткә әйтте:

— Олылар сүзен тотмыйча хаталанасың, егет. Моңар-чы күп ялгышларыңны, яшьлегеңне кызганып кичерә кил-дем, бу юлы да гафу итәм, әмма моннан соң...

"Нәкъ төлке! Төлке дип бик белеп кушканнар аңа... — дип уйлады ачык ишек артында күренмичә басып торган Вәлидә Нурулловна. — Югыйсә каян килсен ул агач аякка Чулман буенда ике катлы өй, машина, гараж, дача..."

Әнә ул Таңнурга нәрсә ди: — Кибетчеләргә пайга сатарга кайтарылган йөз алтмыш чүпрә бар суыткычта. Хәзер үк машина алып килеп чүпрәләрне төя дә Әхнәфкә кит!

— Ни өчен Әхнәфкә, Чакмагышка түгел?

— Әхнәфтә ике ай инде кибет эшләми. Анда халык "ач!" Нинди товар алып барсаң да ябырылып алачаклар Чүпрә ише дефицит әйберне бигрәк тә...

Яшь кадрла начальнигы шаккатты. "Карасана, склад мөдире тәҗрибәсез кибетчегә чүпрәне арттырып сатарга әйтә, шулай эшләмәгәндә, теге җитмәүчәнлекне түләргә йөз алтмыш тәңкәне каян аласың, янәсе... Кызы, кибетче егет риза булырмы икән? Әһә, килеште бугай. Әйе шул, Таңнурның да хәлен аңларга була. Туган авылында авыру әнисе. Ике сеңлесе белән бер энесе дә бар әле. Аларны да тәрбияләргә, үстереп кеше итәргә кирәк. Ә йөз алтмыш тәнкәне тиктән генә түләп торырга Таңнурның башына тай типмәгән дә!

Шулаен шулай да, Таңнурның, уптым илаһи кубып, чүпрә сата китәргә ризалык бирүенә Вәлидә Нурулловна җаны-тәне белән каршы бит әле. Аның эче поша, ниндидер бер яман хәл булачагын сизеп, йөрәге дөпелди. Ләкин нишләргә?..

Шул вакыт якынлашып килгән аяк тавышлары һәм акрын гына сөйләшкән авазлар ишетелде. Вәлидә Нурулловна качкан урынынннан чыгып янәшәдәге складка таба китеп барды.

— Җәбраил Исмәгыйлевич, җаным! — дип инәлеп килеп керде бухгалтер-хисапчы складка. Кеше-кара юклыгын искәргәч, барып тумбалы өстәл янына, мөдир каршына утырды һәм шефының зәп-зәңгәр күзләренә сорау белән текәлде. — Киттеме теге?

— Китте, Салиха Сириновна!

— Уф... Җәбраил Исмәгыйлевич! Малайга йөз капчык онны биреп җибәрдеңме: һәр капчыгын дүртәр тәңкәдән арттырып нитәргә?

— Нинди он? Ә, ие... телефоннан шулай сөйләшкән идек шул. Ләкин малаең теге дүрт йөз тәңкә турында минем исемә төшермәде. Шулай булгач, мин дә аңа ул дүрт йөз тәңкә турында әйтеп тормадым. Соңыннан чәкәләшербез әле. Хәер, барыбер түләтәм мин аңа ул дүрт йөз тәңкәне! Әлегә менә бу йөз алтмыш тәңкә белән, бик матур итеп, аны акылга утыртыйк, яме!

— Молодец та инде син Җәбраил Исмәгыйлевич! — дип сөенеп әйтте бухгалтер-хисапчы. — Болайга киткәч, Таңнурга теге дүрт йөз тәнкәне түләтеп тормабыз инде! Көмеш Елгада аның авыру әнисе, ике сеңлесе, бәләкәй энесе бар икән! Кызганам мин аны...

Склад мөдире маңгаен җыерып тыңлап торды да, кинәт кызарынып-бүртенеп кычкырып җибәрде. — Алай бик кызганырлык булгач, ниемә дип бу уенны оештырдың соң син: йөрисең шунда миемне черетеп!

— Үзем дә белмим инде, Җәбраил Исмәгыйлевич... — дип мыгырданды бөкре кыз, гаепле төстә, күзләрен түбән текәп һәм керфек очларында җемелдәшә башлаган яшь бөртекләрен кулъяулыгына сеңдерергә тотынды. Бераздан исенә килде булса кирәк, склад мөдиренә карамыйча гына әйтте: — Яратам бит мин аны!

Җәбраил Исмәгыйлевич, менә сөйләш син бу дивана белән дигәндәй, шаккатып кулларын җәеп җибәрде һәм аннары тыныч кына итеп:

— Шулай да бу уенны ахырга чаклы хәвеф-хәтәрсез генә уйлап бетерергә кирәк! — диде. — Әгәр дә, ул егетне кызганып, ярты юлда тукталсак, бары тик үзебез генә көлкегә калачакбыз.

Ярты сәгатьтән Вәлидә Нурулловна склад янына әйләнеп килде. Таңнур монда юк иде инде. Җәбраил Исмәгыйлеви, дөньясын онытып, каядыр шалтыратып утыра. — Алло! Әхнәфме бу? Ә? Юк, миңа секретарь Тәбәнәкев кирәк. Ә... Тәбәнәкев иптәш, исәнмесез! Минем хәлләр? Шөкер! Карале, иптәш, әле генә бер кибетче егет сезнең авылга чүпрә сатарга китте, диделәр миңа. Ул чүпрәләрне... Әйе, дөрес аңлагансың. Әйе, шулай эшләгез...

Вәлидә Нурулловна егылып китә язды. "Кара син бу оятсызны! Җинаять өстендә тотып акт төзегез, имеш..." — дип уйлады һәм каударланып конторга керде. Аннары, Таңнур белән ниләр булганын, егетне алда ниләр көтәчәген нурлы йөзле председательгә түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Һм... — диде Корбан Хөснуллович тәрәзәдән азык-төлек складына ягына чак кына елмаюлы караш ташлап. Председательнең бу елмаюы нидер аңлатты бугай, ләкин Вәлидә төшенеп җитмәде. Бераздан соң председатель телгә килде:

— Бар, сеңелем, кассадан йөз алтмыш тәңкәлек пай маркалары ал да, минем машинага утырып, Әхнәфкә юл тот!

Райпо хуҗасының үзенә текәлеп сынап каравын күреп, кыз дерт итеп китте, әмма сер бирмәде:

— Болай булгач, йөз алтмыш тәңкәне Таңнурга барыбер түләргә туры киләчәк бит, Корбан Хөснуллович!

Председатель кресло артына ята төшеп, тырышып-тырышып күзлек пыялаларын сөртә башлады:

— Бу хакта соңыннан уйлашырбыз!

***

"Райпо хуҗасы тәгаенләп кенә җавап бирә алмады, — дип машинада уйланып барды кадрлар буенча яшь начальник. —

Димәк, председательнең кодрәте бухгатер-хисапчы белән азык-төлек склады мөдиренең кодрәтеннән кайтышрак икән. Әйтәм председатель Салиха Сириновна белән Җәбраил Исмәгыйлевич алдында суда җебегән ипи була да куя. Димәк, райпо хуҗасы бу ике дустан шүрли...

***

Җиңел машина Әхнәф урамына тузан туздырып килеп керде дә авыл уртасындагы мәйданга җыелган кешеләр төркеме янына килеп туктады. Кабинадан, чырае агарган Вәлидә Нурулловна чыкты.

Борчулы йөзле кешеләр чолганышы эчендә йөк машинасы тора. Машина өстендә Таңнур. Участок инспекторы. Тәбәнәкев.

Авыл советы секретаре Тәбәнәкев нәзек тавыш белән һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

— Шулай инде, шулай... Әхнәф халкын... ие, безнең Әхнәф халкын талап-талап, баеп китәргә җыенган бу, җәмәгать... Көтүгә бүре ияләшсә нишли әле? Андый чакта бүрене нишләтәләр? Ничек? Ие, хак әйттең күрше: түңкелдәтәләр андый чакта бүрене!..

Участок инспекторы озынча ач яңаклы, нәзек муенлы, какча гына гәүдәле төнтек бер кеше икән. Сөйләшми: телен йоткан диярсең. Ләкин ул Таңнурга, ата бер бандитка карагандай, усал итеп карап-карап куя. Күренеп тора, нияте яман... Шуңа күрә сатучы егет тә аның турында әшәке итеп уйлый: "Ай-һай кабахәт бәндә икән!.."

Таңнурның халәтен сизгәндәй, өлкән лейтенант егеткә янә бораулап карап куя һәм, тезләре өстендәге планшетына иелә дә, мыегын ялый-ялый, акт язарга керешә.

Тәбәнәкев әле һаман чыпчыктай сикеренә, каргадай каркылдый. Ләкин сатучы егет үзенең читлектәге кош хәленә төшүенә Тәбәнәкевнең дә, участок инспекторының да гаебе юк икәнлеген белми һәм гаепле кешенең бухгалтер-хисапчы Салиха булуын башына да китереп карамый.

Вәлидә Нурулловна күрде: берничә авыл куштаны яңа гына сатып алган чүпрәләрен баш өсләренә күтәреп, Таңнурга кычкыра:

— Үзенеке шикелле итеп, арттырып сатып ята .

Кешеләрнең күпчелеге Таңнур яклы.

— Калага бар... анда чүпрәне дарма-шармага гына саталар икән.

— Өй буена ук чүпрә алып килеп саткач, ярамаган тагын.

— Нишләп чүпрәнең бәясен арттырып сатсын, пайга сата бит ул аны, — дип елмая бәлеш авызлы бер хатын.

— Алай булгач, аның маркасы кайда? Ник безгә пай маркалары бирми ул? — дип зәһәрен чәчә каршы төркем эчендә, күлмәк итәген бөрмәсеннән ычкындырырга онытып, басып торган бер түти.

— Бар ул марка! Менә, мәгез! — дип Вәлидә Нурулловна чүпрә алган кешеләргә марка өләшә башлады. Һәм шулай итеп бу сәер тамашаның кызыгын бетерде. Кешеләр таралыша башлады. Кайберәүләр марка алырга сузган кулларын, нәрсәдәндер шикләнеп, кире тартып алды. Ә өченчеләре исә кулларын да сузып тормыйча: — Кирәкми, нәрсәгә ул безгә марка! — дип, башларын гына чайкады.

— Алыгыз инде, берсен дә калдырмагыз! — дип кыстады Вәлидә халыкны.

— Ярар алайса... алмасалар... безгә бир инде син аларны, — диештеләр сакчыга әбиләр.

Вәлидә маркаларны өләшеп бетергәч, машина өстенә менде. Тәбәнәкев белән өлкән лейтенант Таңнур эше буенча акт төзеп бетереп торалар иде. Вәлидә Нурулловна, тегеләрнең исен китәреп, актны кичекмәстән юкка чыгарырга кушты. Тегеләр ишетелерлек итеп кенә сәбәбен дә әйтте. Ниһаять, авыл советы секретаре белән участок инспекторы, ялган фәрман иясен сүгә-сүгә, актны ертып вак-вак кәгазь кисәкләрен җилгә очырткач, Вәлидә Нурулловна көтмәгәндә генә Әхнәф халкы күз алдында гүя тылсым иясенә әверелеп (чөнки ул халыкны сихерләгәндәй итте бит!) Таңнурны председатель машинасына утыртты да авылдан алып чыгып китте.

Бормаланып-бормаланып Чакмагыш кырыеннан үтә торган елга буенда Таңнур шоферга туктарга кушты. Арттан, соры болыттай өерелеп килгән тузан, кояшны каплап, алга таба үтеп киткәч, сатучы егет җиргә төшеп басты.

— Син ни өчен эшләдең бу эшне? — дип, кызыксынып, сорау бирде кибетче кадрлар буенча яшь начальникка.

Кыз сорауга каршы сорау белән, Чакмагыш ягына ымлап:

— Син монда каласыңдыр инде, иеме?! — диде. Һәм ул егетнең җавап биргәнен дә көтмәстән, шапылдатып ишекне япты.

Кузгалдылар: машина — райүзәк тарафына, ә егет — Чакмагышка!

***

Шулай итеп, Салиха Сириновна башлап җибәргән хәтәр уеннарның берсе (бәлки, иң соңгысыдыр!) кинәт кенә мәхәббәт уенына әверелеп китәр дип, Җәбраил Исмәгыйлевич башына да

китереп карамаган иде. Чөнки аның мондый сәер уенда сыналып туплаган тәҗрибәсе ташка үлчим генә иде. Шулай да Җәбраил Исмәгыйлевич бик белеп тора: мәхәббәт уенында җиңүче яки җиңелүче булмаячак. Димәк, аңа бу юлы дүрт йөз тәңкә тудырырга тиешле шатлык-куанычларны бары тик төшендә генә кичерергә туры килер!

Җәбраил Исмәгыйлевич катлап-катлап сүгенде. Аннары, тыңлап тормадылармы икән дип, як-ягына каранып куйды. "Бөтен тырышлыгыбыз йөз алтмыш тәңкәлек кенә бит! Анысы да райпо файдасына әле!..

Азык-төлек складь мөдире каударланып телефонга үрелде.

— Алло! Әхнәфме бу? Ә, Тәбәнәкев икән әле, үзе. Исәнмесез! Карале, иптәш, теге гаугалы вакыйга прокурорга ишетелгән бит, малай...

Ике көннән Җәбраил Исмәгыйлевич Таңнурга карата язган жалоба белән юкка чыгарылган актның яңартылган вариантын председатель өстәленә кертер салган иде инде. Шул ук көнне кадрлар буенча начальнигының калын журналында мөгезле фәрман пәйда булды.

***

Җәй уртасы. Таңнур башын түбән иеп, уйланып, Кама буйлап каядыр китеп бара. Кая? Шайтан белсен!.. Салиха карлыганнар өстенә иелгән җиреннән башын күтәрде, Луизаны күреп алды. — Туктале! — дип кычкырды ул аңа. Һәм тиз генә, бакчадан чыгып, каршына барып басты. — Озатасыңмыни-и?!

— Озатып тордым ди, исем китте-е, — дигән булды товаровед кыз, сер бирәсе килмичә.

— Озатасың бит, әнә күзләрең үк әйтеп тора, — дип төпченә бирде усал кыз.

— Озатса-а... әллә синнән куркып торамммы?! — дип кинәт дөрләп кабынды Луиза.

— Баржадан ташыганда юкка чыккан аракыларның счет-фактурасы әле һаман табылмадымы? — дип, сүзен шактый ук саллыландырып җибәрде Салиха.

Товаровед кыз ык-мык итте, тирләп чыкты хәтта. Һәм ул үзенең Салиха янәшәсендә пешка гына икәнлеген сизеп, кире борылды да, әкрен генә райпога таба атлап китте...

***

Бу вакыйгаларга утыз ел үткән иде инде. Ап-ак кыска чәчле бөкре ханым калага килгәч, оныгына китап алырга дип, кибеткә

керде. Шүрлекләрнең берсендә — аның алтын кысалы күзлек астыннан бораулап караучы су күзләренә сәер исемле юка китеп чалынды. "Бөкре" дип атала иде ул.

Шул мизгелдә ханым китапның авторы — шагыйрь Таңнур Ярмиев булуын искәреп, корт чаккандай өтәләнергә кереште һәм, бирегә ни өчен керүен дә онытып, чыгарга кузгалды.

Менә бу очрашу иде, ичмасам!

## *Көзге кичтә*

Зимагурлар-башкисәрләр
Төрле эштә йөриләр;
Кышын алар кар көриләр,
Төнен эчеп йөриләр... —

дип күңелле итеп җырлый-җырлый (бу җырны малай зимагур абзасыннан отып калган иде)  як-ягына алак-шалак каранды да, кеше-кара күренмәгәч, таза нарат бүрәнәләрдән салынган авыл кибетенең диварына ышыкланып зажигалка кабызды һәм Шүрәле дигән хуш исле папироска ут үрләтте. Ул моны бернichә көн элек кенә, — Тукай һәйкәле каршындагы киосктан сатып алып кайткан иде. Улының “кәчтүн” кесәсенә күчкән шул матур тартмалы кабахәт нәрсәгә кадак ярым шикәрлек акча түләнгәнен белгәч тә, һәрвакыттагыча, әнисе тавыш чы-гармаган иде; түзде, а вылга кайткач та ул-бу сиздермәде; бердәнбере бит! Әйтәләр ич әле: җаны теләгән — елан ите ашаган, дип. Бәс шулай икән, аның “җимеше” генә фани дөнья рәхәтлекләреннән колак кагып яшәмәс ләбаса! Киресенчә, булдырып булырлыкларның барысын да татысын, татып калсын ул!

Шуларны уйлагач, үз яшеннән күпкә кайтыш буйлы малайга илә дә рәхәт булып китте. Ә этрафта — күкнең төбе тузып тишелгәнмени — шыбырдап-шыбырдап яңгыр коя. Җиле... шәрә урманнан чыккан ач бүреләрдәй канга тоз салып улый: у-у-у-у!!!

Малай усал җилне һәм хыялындагы ачулы бүреләрне мыскыллап көлде, аларга телен чыгарып күрсәтте, өсләренә утлы кисәүләр ыргытты, мылтыктан атты, гранат та тондырмакчы иде, салкын инде тәненә таралып өлгергәнлектән кинәт дерелдәп-калтыранып куйды. Һәм ул өстәге эре, астагы вак тешләре белән “барабан каккалап”, ихатасыннан ук төрле тәм-том исләре аңкытып, шул сәбәпле, бакыр-көмеш тиеннә-рнең зеңгелдәүләрен,

кәгазь акчаларның кыштырдашуларын искә төшереп торучы кибеткә аяк басты.

Яңгыр күпме генә тырыша-тырыша яумасын, кибет эченә үтми, шөкер. Монда коры, җылы һәм рәхәт иде. Әнә киштәләрдәге нәрсәләр гүя малайны танып куаныштылар, аны тиз генә үзләре янына чакырдылар. Малай яхшы белә: мондагы һәммә тәм-том арасында, иң элек үзен аңа татытыр өчен, кызу ярыш бара! Ләкин малай аларның бик күбесеннән туеп беткән инде, кайберләренә хәтта аның карыйсы да килми! Ә менә анауы шоколад һәм "Карлыгач" дигән конфеттан, аннары кызыл миләш настойкасыннан күңеле һичбервакытта да кайтмаячак аның! Мул табынлы өйдән — мавыктыргыч дәресләр әзерләвеннән бүленеп, кызыклы китабыннан аерылып, сап-салкын, юеш урамга чыгып — тая-шуа кибеткә килүе дә әнә шуларны татыган саен татып туя алмавы сәбәбеннән генә иде бит!

Малай янә ымсындыргыч шул өч нәрсә ягына карады, елмайды һәм аларга соры күзен кысып, уе белән: "Мин — килдем!" — диде дә, кысан кибет эчендә төрле рәвештә урнашкан кызмача ир тәганәләренә төбәлеп, сүрән генә сөйләшүләренә колак салды.

— Бабам да зимагур булган, әтием дә зимагур, ә мин зимагур түгел! — диде бусагага кәгазь җәеп утырган телбистәсе кушаматлы каравылчы Радик. Аның сул кулында сынган сигарет, уңы исә йомарланган иде.

— Киресенчә дә булырга мөмкин заманына күрә! — диде заправщик Рим һәм башланмаган селедка мичкәсе өстеннән торып аягүрә басты да, керфексез күзләрен йома-йома, каклаган каз боты кимерергә кереште.

"Запое" озакка сузылу сәбәпле, ябыгып, яңаклары чыгыңкыланган кибетче цирк шамакае сыман мәзәк елмаеп, яшел шешәләрне чеңләтә-чеңләтә һәм уң күзен, аннары сул сүзен кыскалап — сакчыл яһүд-әптикәчегә охшарга тырышыптыр инде — йомрырга ак сыеклык тамызып эчте дә, заправщикка теләктәшлек итәсе килептер ахры:

— Илә дә дөрес әйтте, шайтан алгыры! — диде.

Малай, күсе чиелдавын хәтерләтеп, көлеп җибәрде. Кибетче ялт борылып карады.

— Ә... килдеңмени?! — диде. Кулын урта киштәдәге теге тәмле һәм аякларны үзләреннән-үзләре йөгертә торган хикмәтле эчемлеккә таба сузды, ләкин юан бармаклары белән бүтән төрле шешәнең озын, сырлы муеныннан кысып алды; баягы йомрыга

бүлт-бүлт итеп серле, кара сыеклык агып төшәргә тотынды: — Кил, эч! Бусы моның шомырт чәе, җылынып китәрсең!..

Чегән кушаматлы Рим күзен челәйтеп, сүзен аркан чаклы сузып:

— Ма-ла-ди-и-и-и-ис! — дип мактап куйды.

— Ганс абый... ык... билләһи, улың... ык... инвирстит бетереп туган... ык... туганда ук... — диде Радик ычкылык тотып.

— Һы, пәрәмәч! Данлыклы катюша командиры урынбасары ефрейтор Ганс улы икәнлеге аның маңгаена ук язылган ич! — дип кабарынды кибетче. — Шул нисбәттән, улыма тагын бераз салдырам әле! Кил әле...

— Килдем, әти! Менә...

— О-о-о, шәп пионер бу-у-у-у! — дип сузды Рим гадәттәгечә иң кирәкле кешесенә ярарга тырышып һәм шул ук вакытта озакламыйча ниндидер кызыклы хәлләр булачагын күз алдына бастырып, мыскыллы елмайды.

— Кызыл чебеш-әтәч! — диде Радик турыдан ярып, эченнән исә: “Юньле әтәч бу вакытта кунакчасында ял итә, ә бу...” — дип уйлады. Мәгәр уен мондагыларга сиздермичә: — Хәер, белмим тагын... — дип кенә куйды.

Олылар зурдан кубып каядыр барырга әзерләнделәр: очсызлык костюм, блузка кесәләренә папирос, шырпы тыктылар, куеннарына шешә, закуска кыстырдылар... Теге “чәй”ләрдән кызмачалана башлаган малай, әтисеннән яшереп, Рим белән Радикка “Шүрәле”сен күрсәтеп алды, — менә ул нинди үскән, тарта да инде!.. Шешәдән ике дус кибетче малаеның “файдалы” бу эшен хуплап аркасыннан каккаладылар: безнеңчә — ристаннарча кыланып яшәсәң, һичкайда югалмассың, янәсе!..

Кибетнең эчке ишеген ачып чыктылар. Җил тагын да әрсезләнә төшкән, яңгыр да оттыры көчәйгән. Кибетче “контрольный” дигән йозакны ябып бикләгәндә бармагын кысып булса кирәк, яман итеп сүгенеп алды.

— Минем әнинең кабер тактасына кагылма инде, данлыклы катюша командиры урынбасары булган ефрейтор абый, зинһар! — диде Радик әллә рәнҗеп, әллә шаяртып, — монысын малай аңлап җиткермәде. Радик кесә фонаренең өйдә онытылып калганлыгына үкенүен белдереп, шырпы сызган иде, шырпысы шундук сүнде.

— Ммм... миеңне әйтер идем!.. — диде Ганс. Һәм янә сүгенеп куйды.

— Әллә кайчан вафат булган бабакаемның кабер балчыгын актармасаң суң, — дип Радик бусында икеле-микеле фикерләргә урын калдырып, биек баскычның юеш сайгакларын аягы белән кармалап, сакланып кына төшәргә кереште.

Кибет ихатасының ишекләрен ябып, аркылы тимеренә дә йозак салгач, Ганс, ниһаять, җиңел сулап:

— Булды бу! — диде.

Шул мизгел түбәндә гөрс иткән тавыш ишетелде. Кемдер нәрсәгәдер абынып егылды шикелле. Һәм чыннан да Рим, — Ух, каһәр, эчкә типте! — дип, мыгырдана әнә...

Тимер саплы гаять салмак чүкечне уң кулына кысып тоткан кибетче су чыпырдаган якка таба текәлде. Радик тиз-тиз генә унлап шырпыны берьюлы кабызды, бусында алар сүнмәде. Мескен ут яктысында ачык шәйләнде: баскыч каршындагы болганчык су өстенә тезеп салынган автомобиль шиннары өстендә, бөкшәеп, бер исерек ята иде. Йөзенә таба иелсәләр — мәктәп директоры керәшен Мэлс теге! Ул бу авылга узган ел килеп, мәктәпне дә, барчасын да ошатып, җиңнәрен сызганып эшкә керешкән иде керешүен, дүрт ай үттеме икән, яшел еланны үз итәргә тотынды. Андый чакта салпы якка салам кыстыручылар да табылып кына тора шул. Директор-фәлән дигәч тә, аның авызы юкмыни, имеш. Гадиләр — укымаганнар рәхәтләнеп чөмергәндә, гади түгелләр — укыганнарга нишләргә соң?! Мэлс уйлады-уйлады да, катлаулы тормышка һәм аның бихисап мәсьәләләренә кулын селтәп, җиңел юлдан китте дә барды! Нәтиҗә — әйбәтме, әйбәт түгелме, монысын малай чамалый алмады әле. Дөрес, ул олы гәүдәле директор абыйның анда — кибет эчендә борыны очына ук озын бармагын китереп селкә-селкә: — Укы син, Макс, укы, укы! Мин сине үз яныма зам итеп алам аннары! — дигән сүзләрен ап-ачык хәтерли. Ул сүзләрне әйткәндә директор абыйның зур булып ачылган тонык күзләре кибеткә әле яңа гына килеп кергән яшь бер хатынның шәрә балтырларына хиссез-нисез генә төбәлгән иде; авызыннан спирт катыш кара ипи, суган һәм кильки исе бөркелеп тора иде...

Авырлыгы йөз килодан ашкан Мэлсны — үз кешене, башына юеш, пычрак эшләпәсен кигереп, таза-таза өч ир — шешәдәшләре күтәреп алды. Директор иптәш бу очракта интеллигентлыгын яшереп-нитеп тормады, табигатенә хас рәвештә дуңгыз булып, дуңгызның да атасы сыман калынча тавыш белән, үҗәтләнеп-үҗәтләнеп, мыркылдарга тотынды. Ул лыкынып өенә — хәзер яши торган вакытлы фатирына кайтып, күп очракта үрмәләп кайтып

кергәч тә, хатыны каршында әнә шулай мыркылдапмы-мыркылдый икән!

Һәм менә әле лыкынулары җитеп бетмәгән безнең каһарманнарыбыз борынгы мәчет янындагы янгын йортының салам келәтенә таба үзен дуңгыз итеп хис кылучы Мэлсны күтәреп баралар, гөрләтеп көлешәләр! Ниһаять, заправщик Рим — кәҗә, каравылчы Радик сарыкка охшатып бәэлдәргә кереште. Кибетче Ганс исә карлыккан тавышлы ата каз сыман каңгылдады. Малай да олылардан калышырга теләмәде, чын көчек кебек чәңгелдәргә тотынды.

Келәткә кертеп яңа салам өстенә ташлагач, берничә йөз укучының һәм ике дистәләп укытучының бик тә “абруйлы” җитәкчесе — Мэлс иптәш өемә кайтып җиттем диптер инде хатынына эндәште:

—Жанна! Мырык-мырык... Күгәрченкәем? Мырык-мырык...

— Роза! Мики-ки... Багалмам? Микики, — дип ирештерә башлады аны каравылчы Радик.

— Зания! Бә-ә-ә... Өрек җимешем? Бә-ә-ә-ә, — дип мыскыллады аны Чегән Рим.

— Лаура-а! Ка-ка-кук... Тормыш чәчәгем минем? Каң-ң, — дип үкерде кибетче Ганс.

— Венера-а! Һау-һау... Өметем минем? Һау-у, — диде малай Мэлс абыйсына ишетелмәслек итеп кенә. Һәм үзеннән бер баскыч түбәндә укучы чибәр, оялчан кызны күз алдына китереп, канатлы хыялга бирелеп, елмайды.

Олылар директорның тыныч һәм коры урында ятуына инанып, келәттән чыктылар. Эчтә Мэлс аңа дуңгызга охшатып чиный иде инде.

— Вәйт, артист! — диде Радик.

— Аек чакта сандугачка охшатып та сайрый ала ул, — дип сүзгә кушылды малай.

— Хэ-хэ-хэ... болай булгач, озак сайратып тотмаслар аны, креслосыннан очыртырлар, ә?! — диде Рим.

— Югарыдагыларга жалу кермәсә, кагылмаслар! — диде Ганс.

Алар җилнең нәкъ оясында — тау читендә басып торалар иде инде. Чак кына түбәндәрәк җиргә казып урнаштырылган зур чаң янәшәсендә икешәр центнерлы ике мичкә ята һәм шул тирәдә генә җигүле ат калтыра-калтырана хуҗасын көтеп маташа иде.

— Бу мичкәләрдәге “курмы”ны “капчыкка” хәзер үк бушатасыдыр, иеме!

— Хәзер үк!

— Алайса башладык, егетләр!

Малайның борынына керосин исе килеп керде.

— Тс-с! — диде дә кинәт үрә катып, тынып калды Радик.

— Ни булды? Ник алай иттең? — дип, куркып, пышылдады Рим.

— Әнә ич... Павлик Морозов карап тора!

Телбистәсе, чукынчык, шаярта икән: Чегәннең эченә җылы кереп китте.

— Түгел ич... булачак бизнисмин, — дип күңелле гөлдерәде ул.

Кибетче Ганс гадәттәгечә соңыннан гына: — Әйе, ми-лианир булачак минем улым! — дип дөресләп-мөһерләп куйды

Олылар эшне тиз тоттылар; бушап калган мичкәләрне арбага салдылар.

— Боларны паркка хәзер үк илтеп ташлагыз, иртән кеше-мазар күзенә чалынуыгыз бар, — диде Ганс.

— Баш өсте, тәкъсир, — дип, китаптагыча итеп, җавап кайтарды Радик.

Аннары Газ-52 кабинасы эченә барчасы да кысыла-этелә кереп урнаштылар.

— Мә улым... — дип Ганс абый малаена йомры суз-ды. — Бусы моның ни инде, катырак, Зверовой атлысы!

***

Бормалы-сырмады пычрак юлдан күз-башы тонган үгездәй авылга килеп кергән зур, авыр танк күл буена җитәрәк шып туктады. Механик-йөртүче экипаж командирына эндәште:

— Виталий Петрович, абзый белән күрешеп чыгарга биш кенә минут вакытыгызны кызганмагыз, зинһар!

— Бу бит... бу бит... — дип мыгырданды командир ачык люк аша биникольдән мәчет манарасына төбәлгән көе.

— Абзыкаем шушы авылда директор йөген тартып-нитеп яши дә инде, Виталий Петрович!

— Аңлашылды! Кайтышлый, яме! Ә хәзер барлык куәткә — Леля Гансовна янына...

Лял-Ләйлә кибетче Гансның район үзәгендә, — техникумны тәмамлагач, — төпләнеп калган олы һәм бердәнбер кызы иде.

***

Лаура апа ашыкты-кабаланды; аягы таеп китте, егыла язды; йөзенә шакшы су чәчрәде, сул күзе күрмәс булды, ә ул һаман

тизлеген киметмәде: күңеле нидер сизә иде. Бая Чегән Радик “ефрейтор” Гансны сөйрәп-күтәреп өйгә алып кергәч үк эшнең төбенә төшкән кебек булды ул. “Эшләп тапкан акчага түгел, Лаура жаныкаем, керосин “эчтек” без колхоз керосинын!” — дип мактанды ич каравылчы-телбистәсе. Лаура Макс улы турында сорагач: “Арбада, безнең янда килә иде... белмим инде... күл буендагы салулы урында нитмәсә, мыркылдап калмаса!” — диде дә, тәкатьсезләнеп, көләргә тотынды, хайван! Аннары кинәт кәҗә булып микелди-микелди чыгып китте!..

Лаура тиз-тиз генә киенеп, каравылчы артыннан чыккан иде, ул исә “каеш” атын куалап китеп үк барган!.. Лаура хәзер, әнә, Радик әйткән “җенле” урынга таба элдерә!..

Авыр танк авылга кереп күл ягына таба борылгач, хатынның үпкәләре гүя һава сулаудан туктады, йөрәге дә тәмам хәлсезләнеп, туктарга җитеште! Әмма бераздан — Ана йөрәге түгел — Танк шып туктады, Лаура чытырдатып күзләрен йомды. “Юк, юк... ышанмыйм... моның булуы мөмкин түгел...” — дип иңри-иңри, Күктән ярдәм көтеп, пышылдады ул. Һәм — ни гаҗәп — тынычлана төшеп, күзләрен кабат ачып җибәрде: танк инде... кузгалып китеп бара!

Ана кеше агарынып, канатканчы иренен тешләп, көпшәле “дәҗҗал” туктап торган урынга ашыкты. Һәм менә — киң чылбыр эзеннән чак кына читтәрәк — чирәмле төштә, бөкшәеп, бәләкәй бер гәүдә ята... аның улы!

Малай, әйләнеп, чалкан ятты һәм хәлсез, инәлүчән тавыш белән:

— Әнием! Уф-ф, башым... өч-дүрт йотым чамасы гына миләш “чәе” юкмы? — диде.

Шулчакны бик якында гына заправщик Римның хатынына эндәшүе һәм сарык булып бәәлдәве ишетелде.

## *Сөенәм*

Сөенәм, җәмәгать, бик сөенәм мин, чөнки хатыным чибәр — дәрәҗәле! Шахмат сөючеләр клубында җыештыручы булып кына эшләсә дә, “Мерседес”ка гына утыртып йөртәләр үзен! Аның сүзен тыңлап, мин дә шунда эшкә урнашырга киттем бер көнне. Мин дә бит шахматлар атаклы ясаучы оста гына түгел, матур итеп ясаган шахматларымда шахмат җене кагылганнарны сокландырырлык

дәрәҗәдә уйный белүче дә! Шундый июнь һөнәрне кемнең инде тиешле урында камилләштерәсе килмәсен?! Шулай уйлап барып кердем директорның мәрмәр идәнле, өр-яңа компьютерлы иркен бүлмәсенә. Ә ул — яртылаш ак башлы һәм “с” урынына “ш” әйтеп сөйләшүче Шамат, тфү, Самат — мине генә көтеп торган кебек, әйдә, беренче йөрешне син яса! — димәшен... тьфү, димәсенме.

Тәвәккәлләп мин бу йөрешне ясадым. Уен уртакка тәмамланды. Аннары тагын уйнадык, тагын: нәтиҗә һаман уртак! Унбишенче уен да уртакка төгәлләнгәч, директор компьютер экранында пәйда булган кызыллы-аклы билгеләргә бакты:

— Чыннан да хикмәтле икән син! Эшкә биш куллап кабул итәм! Сөяркәң бармы?

“Юк”, дип әйтмәсәм дә, эчемнән генә “булыр Саматулла бирсә” дидем.

Шуннан мин “Ялкын” дигән ял йортында Шаматтан, тфү, Саматтан башка гына гөрләп үткән шахмат турнирыннан, җилкенеп, өйгә кайтып кердем дә хәләлемнең көпә-көндез эшкә бармыйча, чишенеп, йоклап ятуын күреп, кычкырып җибәрдем:

— Вир-ра!

Флотта флагман булып хезмәт иткән кемсә бит мин!

— Ярый алайса, майна! — дидем дә, дөбердәп, кухняга барып кердем.

Берзаман нечкә тавышлы җефетем өч иякле сөяркәм белән тоткан шикелле чиелдап кычкырып җибәрмәсенме:

— Ә-ә, майлымыни? Майлыдыр шул!..

Җаныма җылы булып китте. Белми икән әле! Мине элеккечә су буенда, вакыт әрәм итеп, балык тотып утырган дип кенә уйлый икән. Мин бу юлы ул балыкларны сатып алып кайттым ич!..

Чү! Хатынкаем шыпырт кына ишеккә таба бара? Әйе, аның шулай ничәдер көнгә өйдән китеп югала торган гадәте юк түгел!

“Ярар!” дидем дә, уң кулыма шахмат тактасын, сулына калын гына теория китабын тотып, идәнгә, палас өстенә утырдым.

Шомарган тиендәй ялт итеп, сөекле хатыным кайтып кергәндә минем кызылча йөзем партизанныкы шикелле йонга төренеп беткән иде инде. Хәләлем-бәгырькәемнең нindидер сөенечен минем белән бик теләп уртаклашасы килә, ахры.

— ...шул уңайдан файдаланып, янашым, авылга кагылдым да балаларыбызның хәлләрен белеп килдем бит әле! — ди. Аннары муенымнан кочып, җилкәмнән какты һәм: — Ий, акыллы да соң син! — дип, букчасыннан тегесен-монысын чыгарып салгач,

хәләлем ак беләгендәге сары чылбырлы бүләк сәгатькә текәлде. Шул мизгел телефон шалтырады. Шамат, тфү, Самат лабаса!

— Туганкаем, нинди теләгең бар, әйт, үтим! — ди. — тавышыннан кызмачалык сизелә!

Нидер тоеп өлгергән хәләлем нәзек билле гәүдәсе белән миңа елышты:

— Парижны күрәсем килә, әтисе! Парижны...

Мин аның кап-кайнар сүзләрен суытмыйча директорга җиткердем.

— Булыр, көт! — диде хөрмәтле түрәкәем.

Ике атна да үтмәде, без инде менә Көнбатышка... Без дигәнем: мин, Самат һәм җефетем инде! Әтрафымдагы чит ил кешеләренең сөйләшүләренә караганда, Афинага очабыз бугай! Ни өчен Парижга түгел?.. Анысын белмим. Хәер, минем өчен Мадридка очсак та барыбер инде! Чөнки мин ул илләрдә яшәүчеләрнең телләрен аңламыйм: шахматчылары белән акыл көчен сынашыр өчен, үз телемдә уйлый алуым бик җиткән!..

Әнә Шамат, тфү, Самат та, уйларыма теләктәшлек иткән сыман, елмая! Хәләлем исә, ачуымны китереп, гел бер сүзне тәкрарлый:

— Африкада җәй уртасы икән! Бу — бүлеккә бирелгән — калын, авыр ак бозау туным белән нишләрмен инде анда?!

Бәхеткәме, әллә бәхетсезлеккәме, лайнерыбыз кинәт Төньякка таба борылып оча башлады! Озак та үтмәде, без, исән-аман гына, Мурман каласына килеп төштек! Монда кыш шул әле! Хатыным сөенә: чын, тере ак аюны күрдем бая, картым, ди. Шуннан без “Морж” атлы кунакханәдә төнне үткәреп, иртәгесен аэропортка килдек. Билетлар кулларыбызга эләгүгә үк, директорым шундагы бер зур лайнерга менгереп утырткан иде, йоклап киткәнмен! Уянсам, малай, күзләрем әллә нинди якты нурлардан чагылыпмы чагыла! Баксаң, ул нурлар Сөембикә манарасы очындагы алтын айдан кайтарыла икән! Бәрәч, Казан ич бу!.. Ә тегеләр: җефеткәем белән түрәкәем кайда?! Хи, кичә алар мине югалткач, Парижга очучы лайнерга утырып, ап-аяз күккә күтәрелгәннәрдер дә...

Чү! Хатынкаем кайтып килә? Әйе, ул!.. Баксаң, кичә җефетем утырган лайнер кинәт кенә Көньякка борылган да, Волгоградка барып төшкән, имеш. Шахматчылар башлыгы исә, яңадан-яңа шартнамәләр төзү нияте белән, Көнчыгышка төбәлеп очкан!.. Ярый әле сары кашкаемның бирегә ялгызы гына кайтырга башы җиткән, теге шакмакларда “шах”, “мат”лар кычкырып уйнаучыларның иң кәттәсенә ияреп, җәһәннәмдәге Токиога китеп бармаган, шуңа сөенәм!

## *Кызыл розалар чәчәк аткында*

Классыбызда сүзгә иң тапкыр, телне иң әйбәт белүче кыз иде Гөлия. Ул Тукайга мөкиббән, Такташны ярата, Муса Җәлилгә соклана иде. Ә менә мине — туган мәктәбенең яшь шагыйрен тамчы да хөрмәт итми — гел үрти, гел үрти... Аптырагач-йөдәгәч мин Гөлиягә багышлап, аны мактап, зурлап, олылап шигырьләр язарга керештем; иң әйбәт дигәннәрен генә сайлап алып, үзенә дә укыдым. Кычкырып бер көлде дә:

— Болар Дәрдмәндтә күптән бар ич инде, җаныкаем! — дип, курнос борынын бик югары чөеп, китеп барды. Дөресен әйткәндә, мин Дәрдмәндне укымаган идем әле. Аның юка гына бәп-бәләкәй китапчыгын табып укыдым инде. Һәм шуңа төшендем: безнең авыл бик уңайсыз төшкә, күрексез урынга салынган икән! Мондый “шаблонный”, “банальный” авылдан Дәрдмәнд кебек мәшһүр шагыйрь түгел, районыбыздагы барча атаклы затларның биографияләрен язмаларына тутырып та, шул районның тузанлы юлларыннан ерак китә алмаган кәлтә такмакчылар гына чыкса чыгар инде, валлаһи-билләһи!..

Шулай да мин Дәрдмәнд булыр өчен түгел, ә Гөлиягә, бары тик Гөлиягә генә ошарга теләп, кәлтә-мәлтә шигырьләрне яза бирдем. Чөнки беләм: Гөлия каләм каш минем ул җитлекмичә туган гарип шигырьләремне тыңлап, иркенләп елмая, рәхәтләнеп көлә башлады! Минемчә, сөйгән кызыңны әнә шулай матур итеп көлдереп күңелен күрә алган өчен генә дә шигырьче булып туарга кирәк шул!

Кызганычка каршы, югары классларда укыган вакытта кичергән мондый бәхетле мизгелләр тиз үтеп киттеләр. Инде менә кулда аттестат, иртәгә — Казанга! Мин бу турыда көнозын илһамлана-илһамлана җитмеш баганалы поэма яздым да аны иркәкәемә сөйләп, бу юлы җитди, әтрафлы фикер ишетергә кыҗрап, клубка таба титакладым. Инде менә миңа чаклы бик күпләрне табыштырган, кавыштырган һәм кайчакларда исә аерылыштырган атаклы күпер тыкрыгы! Чү, әнә — ул! Мин дә егетләрдән ялгызым гына әле биредә, шөкер! Һай, кәттә сабакташым, поэма язганымны белгән шикелле, кинәт тәртәләрен минем якка таба борып йөгерергә тотынмасынмы?! Баксаң, каршыңда баржа хәтле аклы-каралы үгез пәйда булган ич!

Биек үкчәле бер пар яшел туфли тузан туздырып янәшәмнән узып китүгә, мин дә аның артыннан йөгерергә керештем. Бераздан

аңыша төштем бугай: мин кызны куам, ә үгез — мине! Ай-йәй, Гөлияне әйтәм, бигрәк үҗәт икән, үзенә кирәксә галәмәт елгыр колыныңны да куып тотачак, нинди җитез җилкәйне дә узып китәчәк, валлаһи!

Уф, тирләтте дә инде, — орден-медальгә узышабыз диярсең! Үпкәләрне әйтәм, бигрәк тиз биреште: гыж-гыж итә, сызгыра, йөрәк тә, зинһар, мине бүтән төшкә күчер, юкса бетәм, дигәндәй, тамак төбенә җитеп дөпелди.

Аh-h, үгез... мине куып җитеп, узып бара түгелме?! Әнә ич... мәгъшукамны да узып китте бу! Мескен үгез үзе дә берәр нәмәкәйдән шүрләп чаба, ахры!..

Әh-hә. Ай яктыртып куйган мәлдә шәйләдем: Гөлиям кызыксынулы карашын Чәберчек Мөршид капкасы төбенә туктаган сәер җан иясенә юнәлтте.

Бәләкәй капкадан тәбәнәк, юан Мөршид тә каударланып килеп чыкты.

— Нәрсә, Дон Кихот, Дульсинияне сагынып кайттыңмы?!

— Му-у-у, — диде абзар патшасы. Ягъни: “Әйе, шу-лай...”

— Ярар, бар, кер! — Чәберчек малкайны ишегалдына озатты да, көтүдә шартлатып сыер халкының тынычлыгын качыра торган чуклы чыбыркысын ваксылап ялтыратылган күнитегенә суккалый-суккалый, минем каршыга килеп туктады. Бу чакта инде мин уртачадан кайтышрак буйлы, йомры гәүдәле чибәркәйнең Гөлия булмавын, каладан кунакка кайткан кемсә икәнлегенә төшенеп, гаугачы Мөршид телгә килгәнче, тыкрыкка таба җилдердем!

Чү, ни хикмәт бу! Язмыш дигәнең биредә дә миннән көлеп, шөкәтсез-котсыз капчык китереп ташлаткан түгелме?! Әйе, ич... Капчык селкенә дә, чайкала да әле!

Ниһаять, дәп-дәү капчыкны тырыша-тырмаша күтәреп баручы бәләкәй гәүдәле, әмма тере, елтыр кара күзле, озын кара чәчле, баллы телле сабакташымны — Гөлияне танып, ләкин баягы кәмит хәлдән соң үземне аңа танытмаска теләп, үтеп китмәкче идем... кыз миңа эндәшмәсенме:

— Миңлегайсә!

Дәрес вакытларында карандаш йә бетергеч сораганда мин аның “бир әле” сенә игътибар итмәсәм, ул аннары әнә шулай тәмләп кенә исемем белән дәшә торган иде.

— Миңлегайсә... исәнме! Чибәр шигырь язарга материал туплап йөрисеңме?

— Һә-hә-hә. Гөлия, син шигырь язып вакыт үткәр-мисең анысы! Күрүемчә, материаль якны күбрәк кайгыртып йөрисең бугай?

— Мөршид җизнинең кыр бакчасыннан безнең бакчага чыгып үскән кыярларны җыйдым әле, — диде сабакташым, турыдан ярып.

— Әйе, андый уңайлы мөмкинлекне кулдан ычкындыра торган кыз түгел инде син, Гөлия!

— Ий Миңлегайсә, капчыгымны күтәреп капкабыз турысына чаклы алып барсаң, нинди зур савап булыр иде сиңа! Минем бабакаем бер чакны синең бабакаеңа нинди изгелек кылган бит, әнә...

Гөлия үҗәт каравылчы бабасыныкыдай кыска бармакларын бөгә-бөгә: әтисенең — минем әтигә. Әнисенең — минем әнигә, әбисенең минем әбигә ярдәм иткәннәрен санап, дөресрәге, үсмер аккоштай какылдап килә торгач, шомырт-балан-миләшле яшел йорт янына кайтып җитүебезне дә toймый калганбыз.

— Мин хәзер... — диде Гөлия күккә яңа калыккан тулган ай белән ярышырга теләгәндәй, кызгылт сипкелле йөзен балкытып, елмайды. Ул озак тормады, кыярлар салынган коштабак күтәреп килеп тә чыкты! Яшел рәшәткәләр янындагы каен урындыкка утырмакчы идек тә, монда көндезләрен күбрәк карт-коры җыелып гайбәт чәчә торган булгач, яңа сарайга әзерләп куелган ап-ак юкә бүрәнәләр өстенә менеп кунакладык!

— Күккә бак әле, Миңлегайсә: ничаклы йолдызлар! — дип хисләнеп әйтеп куйды яшелчә бакчасы бригадирының “таш астыннан чыккан” кызы һәм олы гына бер кыярның башын тешләп чәйнәргә тотынды. Сусыл кыяр исенә чыдый алмыйча, минем дә кул коштабакка үрелде. Гөлия беләгедәй йомры, нәфис кыярның каты калын тәненә сау-сәламәт тешләремне батырып, ярты йомырка хәтле кисәкне умырып алып, ашыкмыйча гына чәйнәп йоткач, сул кулымны күккә таба сузып (чөнки мин сулагай), бүген иҗат иткән поэмамны сөйләргә керештем:

Һавада бихисап йолдызлар...
Диңгездә айкала, чайкала йолдызлар;
Күлләрдә, елгада, инештә —
Йолдызлар, йолдызлар, йолдызлар!

— Миңлегайсә?!

— Әү-ү!..

— Дөресен әйтсәм, ачуланмыйсыңмы!

— Юк?

Гөлия кинәт йомшак, кайнар тәне белән күкрәгемә сарылды да, куллары белән муенымнан кочаклап, иреннәремнән суырып үпте. Аннары кыз күктә балкыган йолдызларга сүзсез генә бармак янап,

капкаларыннан кереп китте.

Шушы кичтән соң биш ел үткәч — Гөлия университетны тәмамлап газетта эшләгәндә — мин мөхәррир-сабакташыма “Йолдызлар” дигән хикәямне укыдым.

Мин укып бетерүгә үк авылдашым:

— Миңлегайсә! — дип эндәште. — Дөресен әйтсәм...

“Кирәкми...” — дип әйтергә дә өлгермәдем, кызың өермәдәй ябырылып иреннәремнән үпте дә ишеккә күрсәтте.

Бүтән бармадым анда. Мәгәр җиде елдан, Гөлия театрда режиссер булып эшләгәндә, “Йолдызлар” дигән драма илтеп бирдем үзенә.

Чит ил драматургларның спектакльләренә миннән билетлар саттырып йөртте-йөртте дә, шул арада минем пьесамны язучылар берлегендәге драматурглар секциясенә җибәрттереп куйган бу! Анда барсам, минем пьесаны югалтып ук куйганнар, имеш.

Инде менә, Гөлиянең нәшриятта җаваплы урында эшли башлаганын ишеткәч, (Йолдызлар” дигән роман сырлап илтеп тапшырдым. Бусын тиз тотармын, укып чыгуга ук хәбәр итәрмен, дигән иде...

Әһ-һә... телефон шалтырый! Гөлия! Идел буена очрашырга чакыра! Киттем...

Һәй-йәй, олыгайган, түти була язган!.. Шундагы озын агач урындыкка чүмәштек тә сарылы-яшелле су өстендәге сөт күбегедәй назлы дулкыннарга текәлеп, уйга талдык.

Һичкөтмәгәндә Гөлия:

— Кочакла әле мине! — дип ташламасынмы.

Гомеремдә беренче мәртәбә кочакладым моны.

— Инде, җаным, үп!

Беренче тапкыр үптем — кулыннан.

— Яхшылап тыңла, Миңлегайсә. Син гомерең буенча йолдызлар турында яздың. Язуын яздың, әмма үзең йолдыз була алмадың, мине дә йолдыз итә алмадың! Аннары Чулман “йоткан” авылыбызны да әдәбият тарихына кертеп калдыра алмадың!.. Ни үкенеч!..

Шулай диде дә Гөлиякәй (карт гөлкәй) парик кигән йөнтәс башын күкрәгемә куеп, тынып калды. Аның бу юлы буялмаган керфек очларында чын, тере яшь бөртекләре җемелдәшә иде.

## *Шүллер*

— Әссәламегаләйкем, кияү! — дигән бик тә таныш авазга борылып карадым. Тора горуранә басып. Башында мин элек яратып киеп йөргән бүрек. Муенындагы шарф һәм өстендәге тун да минеке әле, — яшьлегемне хәтерләтүче затлы нәрсәләр!

Танымаганга сабышып, фанер көрәкне карга батырдым. Аһ, шәп аяклы бер мәтке килә! Чү, минем хатын булып чыкты ул!

— Нихәл, әти!

— Кхм. Ни дим икән инде, кызым?!

Хатын шундук иннекле иреннәрен колагыма якын ук китереп, ап-ак фарфор тешләре арасыннан сүзләрен йомырыландырып чыгара-чыгара:

— Бүгенгә ничек тә түз. Картым! Сугыш ветераннарын быел нитәчәкләр бит! Үзең беләсең... — диде.

— Тротуарыңның бозы, ай, калын икән, кияү!

Тагын эндәшмәдем: юкка кыйланып маташа бабай. Ул барыбер миннән өстен була алмый. Чөнки...

Кердек. Миңлегәрәй карт авылда абзарда йөри торган сучинкәсенең калушын гына салды да, өстәл буена барып утырды. Ә өстәл өстендә быел мин төшемдә дә күрмәгән сый-нигъмәт инде.

— Болай үзе әйбәт кенә яшәп ятасыз икән әле, — диде бабай, кеткелдәп һәм бер котсыз нәрсәне алып кимерә дә башлады. Хатыным-күгәрченем әйткәч кенә төшендем, ананас булып чыкты тегe! Ә бәясе... Чүп трубалары чистартып азапланганда ишетсәң, чалбарың түбән төшеп китәр, валлаһи!

Бабай тагын бер ананасны бөкләп куйгач, мандаринга үрелде:

— Йә ничек соң анда өстәгеләр?!

— Һи-и, әти, сөйләмә инде! — диде хатын.

— Ә-ә, түбәндәгеләр??? — Бабай миңа сәлперәйгән кашлары астыннан гына сөзеп карап алды да, янә кызына таба борылып: — Авылда без дә нитеп маташкан идек бит әле, кызым, — диде. — Гөлчәчәк апаңның кияве акчаны күп таба ич, Мәрфугаттәйнең кияве дә! Шуннан болар акча янчыкларын сеңлекәшләренә, ягъни безнең киленгә китергәннәр сакларга. Киләчәктә ниләрдер төзергә, нәрсәләрдер сатып алырга хыялланалар! Чыннан да, мин әйтәм, акча кирәккәндә килен янәшәдә генә ләбаса; тоттым да бирдем акчаларымны моңа! Ә иртән киленем тәрткәләп уятмасынмы мине!

— Әти! Әти! Анда акчаларыңны крис ниткән, — ди.

Тиз генә торып, өй базына башны тыгып карасам, өч литрлы банкы буп-буш тора! Менә шулай... акчасыз-нисез калдым инде мин, хәзер нишләргә дә белгән юк! — дип Миңлегәрәй карт уфылдый-уфылдый диванга барып чүмәште. Хатыным да атасыннан калышмады, йөрәген учлап тахтага барып ятты. Ә мин гаиләмне тук яшәтер өчен өстәмә акча кирәк булганга, җиләк-җимеш базасына ялланып вагоннар бушатырга киттем. Аннан тирләп-пешеп һәм арып-талып кайтып керсәм, ишек төбендә миңа таныш түгел ир-ат ботинкасы һәм хатын-кыз сапожкие тора! Авылыбыздан хатынымның төпчек энесе белән техникум белемле "банкир" килене килгән, имеш, теге идән асты "демократлары" ашаган акчаларны ияләренә кайтарып бирер өчен, миннән әҗәткә шул чама акча сорап алып китәргә ниятлиләр! Кайгы-хәсрәтләрен күз-яшьләре белән дә мөһерләп күрсәткәч, кызгандым инде үзләрен, чыгып, дәүләт банкысындагы акчаларыбызны кырып-себереп алып тоттырдым кулларына! И сөенделәр болар, и шатландылар, рәхмәтләрне безнең өстебезгә яңгыр сыман итеп коялар гына, мин сиңа әйтим!..

Куанычларыннан, кунып та тормыйча, кайтырга ук кузгалдылар болар. Аларга нилектәндер кеткелди-кеткелди бабай да иярде. Аның көрән күзе очкынланып, чыгынкы яңаклары алсуланып киткән иде бу минутта.

Куанычларыннан, кунып та тормыйча, кайтырга ук кузгалдылар болар. Аларга нилектәндер кеткелди-кеткелди бабай да иярде. Аның көрән күзе очкынланып, чыгынкы яңаклары алсуланып киткән иде бу минутта.

Иртән, без йокыдан торуга ук, телефон шалтырады. Гөлчәчәк апа шалтырата икән. "Тегеләр" бездән әҗәткә алган акчаны да кушып, белгән кешеләреннән "Жигули" сатып алганнар да, шуңа утырып, төн уртасында авылга кайтып кергәннәр, ди.

— Төпчегемә мин алып бирдем инде бу машинаны! — дип мактана икән Миңлегәрәй карт.

Бу хәбәрне ишеткәч, хатынымның аксыл йөзе күкле-кызыллы булды һәм ул мин ишетмәслек итеп кенә ниләрдер әйтте. Әмма мин аның бер сүзен ап-ачык ишетә алдым:

— У-у, шүллер! — диде ул.

## *Агач аяклылар*

Закир ага уянып китте. Очсызлык пәрдә арасыннан кысылып кына сүрән яктылык керә. "Таң атып килә, ахры", — дип уйлады.

Янәшәсендә арык хатыны мыштым гына йоклап ята! “Дөяне уятмыйм”, — дип, сак кына борынгы тимер караваттан төште. Аш бүлмәсенә керде. Алан-ялан каранды. “И шайтан”, дип эченнән генә сөйләнеп куйды. Кичтән эмаль кәстрүлдә калган чикмәнле бәрәңгеләрне төнлә торып сыптырган ич! Болайга киткәч, колхоз кырына тагын казынырга бармый булмый. Чөнки аңа тормыш иптәше бу арада базардан бәрәңге сатып алырга да акча бирми башлады. “Өметләнмә карт гүәрдин, бетте пинсәң, түтү...” ди.

Закир ага зур тәрәзә каршына барып, өй янындагы мәйданчыкка автобуслар килә башламадымы икән дип, юа-юа төсе уңып беткән пәрдәне ачып җибәрде.

— Менә сиңа, мә! Тышта асфальт юлларны, урамга чыккан кешеләрнең зонтикларын, киоск түбәләрен юешли-юешли яңгыр сибәли... Болай булгач, кырга бәрәңге ала бармаячаклар инде. Их-х-х...

Закирны күршеләре “Сәер Закир”, дип йөртәләр. Чөнки ул кибеттән тәмәке алып тартмый, шәраб алып эчми. Болай үзе тартырга сузсалар тарта, эчәргә кыста-салар эчә.

Аларның балалары да булмады. Шулай алар бала үстерүнең ни икәнлеген дә белмичә картайдылар. Яшьлегендә беренче хатыны — Аннушкасы ике атналык баласы белән ташлап качмаган булса, Закир хәзер оныклар үстереп юаныр иде. Оныклар, әлбәттә, урысча гына сөйләшерләр, яныңа килерләр дә: “Бабай, деньги давай!” — дип, йөдәтеп бетерерләр иде.

Абзый пәрдәне томалап, урынына килеп ятмакчы иде, ишектә кыңгырау чылтырый башлады. Мамык Мәфтуха ялт сикереп торды. Бергәләшеп ишекне ачып җибәрсә- ләр — таныш түгел ир! Янәшәсендә биш-алты яшьлек малай басып тора!

Карчык нидер сизенеп, тиз генә ишекне япмакчы иде. Теге ир бусагага аягын куеп өлгерде һәм урысчалатып:

— Закир Бакирович монда яшиме? — дип сорады.

— Менә мин ул! — диде карт чак кына каушый төшеп.

— Ә мин — Заһар Закирович! Сезнең улыгыз... Бу — Игорь, минем улым!

Закир ага һәм аның карчыгы тәмам югалып калдылар, ни әйтергә дә белмәделәр. Захар шуннан файдаланып:

— Күптән түгел генә хатыным вафат булды! Мине командировкага җибәрергә телиләр иртәгә! Игорь сездә калып торсын әле, әти! — диде.

— Калсын. Калдыр, — диде Закир ага һәм күз кырые белән карчыгына карады. Мәфтуханың йөзе һични аңлатмый иде әле.

— Бар, улым, кер! — диде Захар.
— Минем бабакаем шушымыни! — диде Игорь ата-сына.
— Мин! — диде Закир бәләкәй Игорьда да үз чалы-мын  танып.
Моның шулай түгел икәнлеген Мәфтуха да кире кагарга җөрьәт итмәде һәм ул, читкә авышып, малайга юл бирде.

***

Билгеләнгән вакыт килеп җитте, Захар юк та юк! Игорь инде “әби” белән бабайга ярыйсы гына иялэшеп өлгерде. Ул хәзер — олылар үзара гөрләшеп татарча сөйләшкәндә — читтә посып утырмый, яннарына ук килеп, елмаеп, аларны тыңлый; аңлагандай итә, хуплап башын кагып куя, хәтта исә кайчакта көлеп тә җибәрә.
Кысыр Мәфтуха менә хәзер генә чын бәхетнең балалы булуда икәнлегенә төшенеп, моңаеп, Закирга карый. Ә бит карчыкның яшьлегендә ике яки өч бала табып үстерергә дә теләге юк түгел иде. Моның өчен врач кушканнарны җиренә җиткереп үтәргә — ниндидер ванналар алырга, кайларгадыр барып дәваланырга кирәк иде. Әмма эш акчага терәлгәч, буы чыгып бетеп суынган мунча шикелле, дәрте тәмам басыла да, бу турыда бүтән сүз кузгатырга кыймый иде яшь хатын. Чөнки алар бу вакытта акчаны кысып кына тотарга, аны — баер өчен — оекка җыярга омтылалар иде. Һәм бу турыда һичкем һични белми иде.
Кем әйткәндәй, ашкынып-кабаланып  җыя  торгач, ниһаять, акчалары икенче оекка да сыймый башлады. Шуннан уйлана башладылар: акча кәгазь генә бит ул! Өстәвенә, власть-фәлән алышынып китеп... Барысы да булырга мөмкин! Иң ышанычлы юл — кәгазь акчаларының барысын да борынгы алтын акчаларга алыштырып-нитеп...
Озак та үтмәде, хан заманында сугылган ишле генә алтын акчаларны бүгенге кәгазь егерме бишлекләр — иллелекләр белән шыплап тулган ике оек “байлык”ка алыштырырга теләүче кемсә дә табылды. Ул — йөзенә ясалма сакал-мыек ябыштырган кемсә — үзенең кем һәм кайдан булуын әйтмәде, билгеле.
Закир ага белән Мәфтуха түти — мәңгелек кыйммәткә ия алтын-фәләннәрен борынгы шкафның үтә яшертен төшенә салып куйгач, җилкәләреннән авыр таш төшкәндәй, җиңел сулап:
— Бусын да булдырдык бит! — диештеләр.

***

Захар Закирович ике ай үткәч кенә пәйда булды. Барган илдә — сугыш чыгу сәбәпле — тоткарланган икән.

Бәләкәй Игорь әтисен күргәч, пышын-пышын гына еларга тотынды, — шактый ук ябыккан, нечкәргән һәм... кечерәеп калган иде малай! Кылчык Мәфтуханың арбасына утыру бәласеннән булмыйча нәрсәдән булсын инде бу? Ни әйтсәң дә, ул — үги әби бит! Ә үгилек итү вә үгисетеп тинтерәтеп җыксындырып бетерү ише яман гадәтләрнең таза тамырлары ерак-ерак гасырларга барып тоташа ләбаса!

Захар үзе дә ярыйсы гына ябыккан, йөзе караеп, озынчаланып киткән иде. Баш өстендә газраил кылычы айкалып торган төштән көрәеп кайтып булмаганны Закир ага бик белә, шуңа күрә ул онытгы Игорьның туклыклы һәм витаминлы ризык җитешмәүдән кибеп корыша башлавына да аптырамаган иде. Кем әйткәндәй, сугымга симертәсе мал түгел әле, пычагым булсынмыни аңа! — дип кенә уйлады. “Мин сугышта чакта әле...” — Закир үзенең сугышта чагын еш исенә төшерә һәм: “Нинди эсседә, яралы килеш, ярадан түзә алмаслык авыр ис килеп торган мәлдә, су эчмичә, ашамыйча бит!.. Барыбер исән калганмын ич!.. Менә ич, бөтен төшем исән-сау, шөкер!” — дип, эченнән генә сөенә-сөенә тантана итә. Аннары: “Юклык белән артык муллыктан бозыла инде адәм баласы, бозылса! Ә ярым ач яшәүдән кеше үлми, киресенчә...” — дия-дия, карчыгының саранлыгына, хәтта кирәгеннән артык саранлыгына да күңеле булып:

— Бик тә дөрес эшли! Кешеләргә генә түгел, үз-үзеңә дә саран була алу — сирәк һәм зирәк бәндәләргә генә бирелә шул ул! — ди.

Кайчакта — саруны кайнарлык итеп әйтәләр: имеш, ул бик әйбәт, кеше күңелле кеше, чөнки юмарт! Теге — тагын да әйбәтрәк, чөнки бигрәк тә юмарт!.. Шулаен шулайдыр да, юмарт булуның сәбәбен ачыкларга керешсәң, аның төбендә курку ятканын сиземләмәү мөмкин түгел!..

Дөрес, саран да курка! Әмма саранның куркуы башкачарак, ягъни саран бүредән ун-унбиш мәртәбә артыграк өркә! Моның шулай икәнен юмарт түгел һәм саран да түгелләр күптән исбатлаганнар инде! Шуннан соң кемнең гомере — саранныкымы, әллә юмартныкымы — озынрак булачагын хисаплап чыгару гына кирәк...

Кыскасы, төлке дә тук, тавык та кук яшәсен дисәң, урынын-нием чамалап кына юмартланырга һәм, әлбәттә, саранлана белергә кирәк! Әйе, әйе, саранлана белергә!.. Саранлана белү ул әле талантлы язучылар телендә чын сәнгать дип атала икән. Монысын Закир ага урамда аунап яткан газеттан укып белде. Мәфтуха да

укымый тормый анысы. Эскәмияләрдә онытылып калган, урам чатла-рында, куак төпләрендә аунап яткан китап-журналларны өйгә байтак ташыды инде ул! Әйе, укыйлар!.. Белемнәре арткан саен, саранлыклары да өстәлә генә бара!.. Ан-нары, телевизорны да көнгә бер яки ике сәгать, радионы да ярты яисә бер сәгать тыңламыйча яшәми алар! Мондый бәхет Игорьга да елмаеп куйгалады, билгеле; җаны теләгән мульт сериалларны туйганчы карый алмаса да, күңеленә авыр эчпошыргыч тапшыруларны әллә ничаклы карарга туры килде аңа! Ул тапшыруларның һәр-кайсында “экономия”, “выгода”, “файда”, “янга калдыру” дигән сүзләр өстенлек итә иде.

Шундый сүзләр яңгырап киткән мәлләрдә карт белән карчык бер-берсенә мәгънәле итеп карап алалар яисә, ләззәтләнеп, киң сөякчел кулларын кулга сугып, “ах” та “ух” килеп куялар иде. Ә Игорь — нишләсен инде ул — көлә иде! Ярым ач, хәтта ач килеш тә көләргә мөмкин булганын малай менә шул чакта белеп калды инде.

...Захар әтисенә һәм... апага рәхмәт әйтте дә, күчтәнәчләрен дә калдырырга онытып, Игорьне фатирдан алып чыгып китте. Захарның бу кыланышы турында тегеләр ни уйлаганнардыр, бәләкәй Игорь:

— Әти, минем бу бабакаемның сул аягы агач икән! — дип куйды. Бераз баргач янә өстәп җибәрде: — Ә әбекәемнең уң аягы агач!..

## Кымыз хикмәтләре

Башлыгыбызның урынбасары Рево Артурович бер көнне мине дә үзләренә дәште: “Пианино күчерәбез!” — ди.

Рево Артурович әйткәч эшлибез инде аны, хәтта Каф тауларын да күчереп куярга риза.

Таксидан төшкәч, Рево Артурович миннән кымызга йөз тәңкә акча сорап алды. Ә Рево Артуровичның бухгалтер баҗасы илле тәңкә сорады. Аңа да бирдем.

Йөзлек белән иллелек кулларына кергәч, Рево Артурович белән баҗасы рәхәтләнеп көлештеләр. Мин дә елмайдым, Элекке урынбасар зерә дә юаш кеше иде, мәрхүм, урыны җәннәттә булгыры. Ә бу — Рево Артурович — усал шул. Без хәзер эш урыннарыбызда озаклап тәмәке тартуларны, җәелеп утырып симәнке чиртүләрне, кинәнеп ләчтит сатуларны төшләребездә дә

күрмибез: эшлибез дә эшлибез. Аның каравы, ай азагында уч тутырып акча алабыз. Шулай булгач...

Өчәүләшеп, чалбар кесәләрен кымыз салынган шешәләр белән бүлтәйтеп килеп кердек Рево Артуровичның өр-яңа фатирына!

Биш бүлмәле икән. Бердәнбер мебельсез бүлмәдә, кыйммәтле палас өстендә гаять көр ана овчарка йокымсырап ята!

— Элек кымыз йотып куйыйк, — диде Рево Артуро-вич. — Тәннәргә көч керә торсын!

Рево Артурович фәрман биреп торды. Мин чит илдә ясалган шкафтан рюмкалар чыгардым, “Атлант” дигән суыткычтан — гөмбәләр, каклаган каз, кара уылдык! Вәйт, яшәп тә карый инде Рево Артурович...

Ниһаять, без эшкә керештек. Рево Артурович, көмеш балта тотып, ишек янәшәсендәге киемнәр элгечен сүтеп ташлады. Ә мин җайланманың тәти-тәти детальләрен залга ташый тордым. Зал дигәнем кунак бүлмәсе инде. Кунак бүлмәсендә, анархистлар кебек булып, төрле-төрле төенчекләр, әрҗәләр өелешеп ята. Мин бу төенчекләрнең, әрҗәләрнең кайберләрен идарә складында күргәләгән дә идем бугай!

Рево Артурович безне янә кымыз эчәргә чакырды. Иллә дә күңелле булып китте соң! Тик кием шкафы кече бүлмәдән чыгарып маташканда люстрага бәрелеп бәлале була яздык. Люстра идәнгә төшеп көл була иде, ярый әле Рево Артуровичның баҗасы тотып калды.

Шкафны эткәләп-төрткәләп коридорга чыгарып маташканда, хаталык белән, диварда эленеп торган бер әби портретын да кадагыннан йолкытып алдык. Портрет шап итеп идәнгә төште.

— Минем хатынның әбисенең әнисе инде бу! — диде Рево Артурович, портретны аягы белән читкә этеп.

— Мөселманнарга сурәткә төшәргә ярамаган бит. Каян килгән бу портрет? — дип сорадым мин.

— Минем хатынның әбисенең әнисе удмурт булган! — диде Рево Артурович, көлемсерәп.

Шкафны аралык буйлап ишек ягына таба этеп барганда диварда эленеп торган болан мөгезенә эләгеп күзем чыга язды. Рево Артурович мөгезне дивардан йолкып алып, шкаф эченә тыгып куйды. Пианиноны урта бүлмәгә урнаштыргач, безнең эш тә бетте. Шуннан соң без аш бүлмәсенә үтеп, тагын кымыз эчәргә тотындык.

# *Өметбикә*

Куе караңгылыкка чумган авыл өстендә Азан яңгырарга тотынды; гүя айсыз һәм йолдызларсыз күк йөзеннән җиргә ниндидер яктылык сибелеп төшә башлады.

Шәмсуар хәзрәтнең хаҗ сәфәреннән алып кайткан Азан тавышымы бу?!

Әмма көтү куган чакта түтиләр имамның хатыныннан сорашып, иртәнге Азанны Казаннан кайткан яшь мулла — Мөхәммәт әйткәнен белеп, сагайдылар.

***

Берничә көннән инде Мөхәммәт авыл буйлап дәгъвәт кылып, ягъни кешеләрне дингә чакырып йөри иде.

— Иман китереп намазга басыгыз, мәчеткә йөрегез, шәригать кушканнарны үтәп яшәгез!

Казанда югары мәдрәсәдә аны нәрсәгәдер укытканнар, өйрәткәннәр, ул хәзер шуларны биредә авыл кешеләренә сеңдерергә маташа! Әмма... диннең кирәклеген кире кагучы да, аңа керергә ашкынып торучы да бик сизелми әле. Шәмсуар хәзрәт кенә ара-тирә:

— Син, Мөхәммәт, үзең өйләнеп, чын мөселман балалар үстереп күрсәтмичә, бу авылны игә китереп булмас, ахры, — дип куя.

— Өйләнергә! Ә кемгә өйләнергә?

— Минем Әлмәттә яшәүче кызымның кызына! — ди элекке парторг.

Мөхәммәт кырда үскән нәфис ромашка чәчәген күз алдына китереп:

— Синең ул оныгың шәригатьчә киенеп йөриме? — дип сорый.

— Аюны да өйрәтәләр, энә! Өйрәтерсең! — ди Шәмсуар.

Мөхәммәтнең исенә мөфти әйткән сүзләр төшә:

— Безнең милләтебез дә күз буяп түгел — чын-чынлап яшисе һәм башкаларны да шуңа өйрәтәсе иде!

— Йә... өйләнәсеңме? Тирә-юньдә ис-уш китәрерлек туй үткәрәчәкбез! Минем кияү нефть чыккан төштә зур кеше бит!..

Мөхәммәт сәгатенә төбәлде дә:

— Азан әйтер вакыт җиткән ич! — дип, манарага менеп китте.

***

Атна арты атна үтә торды. Шәмсуар мулла да яшь имамга бәйләнүдән туктамады:

— Өйлән! — ди.

— Мин бик яшь бит әле! Аннары минем өйләнүем сиңа нигә кирәк тә һәм ул сиңа ни бирә? — дип мөәзиннең авызын томаларга тели Мөхәммәт.

Элекке усал мулла төксе рәвештә:

— Оныгым бик дәртле, бер ахмагына кияүгә чыгып куймагае! — ди.

— "Ахмак" дигәнең кем инде ул?!

— Соң, шуны да белмәскә: дин өлкәсендә уңны сулдан аермаучы бер ишәк инде!

— Син гайрәтле бабай ич, өйрәтерсең!..

— Андыйларны бөгеп булмас инде, энем: кем әйткәндәй, эш үткән, поезд киткән!..

— Монда мин нишли алам? Мин үзем дә мөфти кызына гына өмет баглап йөрим әле! — дип мыгырдана-мыгырдана яшь хәзрәт Азан әйтергә манарага менеп китә.

— Һе, мөфти кызы, имеш! Кая үрелә, ә? Менә мин сиңа, энем, сүземне тыңламасаң.

Икенче көнне Шәмсуар "Мерседес"ка — түрә улы янына утырып, Казанга чыгып китте.

***

Мөхәммәтнең гайбәтләргә исе китми хәзер. Ачыктан-ачык янауларга да төкереп бирми ул. Чөнки аның әтисе танылган көрәшче — мөселман, намаз укый, мәчеткә йөри! Авылга кайткач,

динне үгисетүче ирләр аның күзенә чалынсалар да, юлына очрамаска тырышалар. Сәбәбе: Шәмсуардан өркәләр! Ул кызыл авыз парторг чагында “гаеплеләрне” сүксә, мулла булгач — вәгать укып, үгет-нәсыйхәт тукып теңкәләренә тия иде! Дөрес, ул моны — яшь имамнан аермалы буларак — кешеләр дингә якынайсыннар, намазга бассыннар, мәчеткә йөрсеннәр өчен эшләми иде, киресенчә, диннән читләшеп бетсеннәр, мәчеткә якын да килмәсеннәр дип тырыша иде бугай! Чөнки болай эшләгәндә авылда изге кеше берәү генә — Шәмсуар хәзрәт кенә булачак! Әгәр дә кешеләр өерелешеп дингә керсәләр, намазга бассалар, мәчеткә йөрергә тотынсалар һәм тора бара, хәдисләрне өйрәнеп, Коръәнел Кәримнең гарәп шрифтлысын укырга керешсәләр?! Аннары мулла абзагызның кирил хәрефле китаплар буенча үзлегеннән генә укып өйрәнгән дини гыйлеменә сокланулар йә бетәчәк, йә бик нык кимиячәк! Моны күрәләтә булдырырга Шәмсуар хәзрәтнең башына тай типкәнмени?!

Казанга барып, югары мәдрәсәләрдә йөреп, азакта мөфтияттә булып, ниләрдер майтарып кайткач, Шәмсуар Мөхәммәткә оныгын кияүгә бирү турында бүтән сүз кузгатмады.

***

Берничә ел вакыт үтте. Мөхәммәт озын буйлы, таза гәүдәле һәм калынча көр тавышлы егеткә әверелде. Ул әйткән Азан хәзер күрше-тирә авылларга да яңгырап ишетелә инде. Авылда хәзер озын итәкле күлмәк киеп, башына яулык ябып йөрүче яшь, чибәр кызлар да күренгәләми түгел!..

— Менә тагын чираттагы декорация (күз буяу), — дип мыгырдана яшь хәзрәт шундый кызлардан берәрсе юлына очраган вакытта. Һәм ул янә мөфтинең ак йөзле, сары чәчле, зифа буйлы уртанчы кызы турында самими уйлар уйлап: — Нәкъ ромашка чәчәге инде! — дип куя. — Җитмәсә, нур өстенә нур дигәндәй, Коръән Китабын яттан белә! Их, шул затлы кызның кияве булырга!.. Ничекләр итеп кенә кулга төшерергә аны?!

Яшь хәзрәт әтисе туып үскән йортта әбисе янында яши. Йорт алты почмаклы итеп нарат бүрәнәләрдән салынган! Зур бакчасы, абзар-курасы һәм мунчасы бар! Һәм әби кеше элекке шикелле утын кисеп, су ташып интекми: су, газ — өйдә!.. Эштән бушаган чакларда алар радио тыңлыйлар, китап укыйлар, телевизор карыйлар. Мөхәммәткә әбисе:

— Авылда да каладагыча яшәп була; калада авылдагыча яшәп буламы?! Шуның өчен, авылда авылча гына яшәргә кирәк инде, — ди.

Яшь хәзрәт аңлый. Аннары мөфтинең сөекле уртанчы кызын — нәфис ромашка чәчәген — исенә төшереп:

— Ул назлыкай да авыл казыннан әллә ни ерак китмәгәндер әле, аның да тамыры авылга барып тоташа лабаса! — дип уйлый.

Мөфтинең остазбикә анасы да вәгазе саен:

— Безнең тәннәребез калада булса, җаннарыбыз — авыл-да! — дип сөйләргә ярата ич.

Мөхәммәтнең әтисе дә:

— Мин һаман үземне авылда чакта — калада, калада чакта авылда итеп хис кылып яшәргә яратам! — ди.

Бу — кешенең табигате шундый тынычсыз, юксыну-чан, сагынучан булудан киләдер, күрәсең!

Ә назлыкай — ромашка чәчәге — Мөхәммәтне оныт- мадымы икән?!

Егет югары мәдрәсәнең дүртенче курсында укыганда практиканы мөфтияттә үтте. Ул анда секретарь булып эшләде. “Ромашка чәчәге” бирегә — әтисе яки әнисе янына көн аралаш килә иде. Коръән сүрәләрен бик оста укучы дигән аты таралган тырыш шәкерт — Мөхәммәт тора-бара чын иманлы кызның сөйкемле йөзен яки челтерәвек тавышын ишетеп калу гына түгел, аның белән кайбер мәсьәләләр хакында фикер алышырга да җөрьәт итә башлады.

Бер көнне Мөхәммәт назлыкай килер алдыннан гына компьютер экранына: “Мин сине яратам! Ә — син?..” — дип язып куйды.

“Ромашка чәчәге” килгәч, язуны укыды һәм компьютер клавишлары өстендә бармакларын тиз-тиз генә йөгертеп:

— Ә мин Аллаһы Тәгаләне яратам! — дип язды да ни өчендер иннектәй кызарып, әтисе кабинетына да кермичә, бүлмәдән чыгып китте.

Янә берничә көн үтте. Назлыкай мөфтияттә бүтән күренмәде. Аның каравы, икендедән соң, мөфти бүлмәдә яшь хәзрәтнең ялгызын гына туры китереп, моңарчы беленмәгән кискен, коры тавыш белән:

— Калебеңне үзгәрт! Башка кара таракан төшермә ашка, ярыймы?! — дип, хәтәр генә җилләнеп, кабинеты ишеген дә ябып тормыйча, эчкә чумды.

Ә ике атнадан мөфтияттә Шәмсуар пәйда булды.

— Сине, энем, имам-хатыйп итеп авылыбыз мәчетенә эшкә билгеләтергә килдем! — диде ул Мөхәммәткә.

***

Төнге куе караңгылыкка чумып утырган авыл өстендә Азан яңгырый, бик тә моңлы Азан!

— Азанны кем әйтә? — дип сораучы юк хәзер, — барысы да беләләр. Хәтта Азанның яңгырашына колак салып, Мөхәммәтнең күңелендәге үзгәрешләрне дә дөп-дөрес итеп әйтеп бирә белүчеләр бар. Андый чакларда алар:

— Аһ, бигрәкләрдә өзелә инде безнең яшь хәзрәтебезнең үзәге шул мөфти кызы өчен! — диләр.

Менә бу кичтә дә...

Мөхәммәт айсыз һәм йолдызларсыз күккә багып, сагыш һәм әрнүләре аерым ачык сизелеп торган Азанны яңгырата!

Яшь хәзрәт белән ни булганын Шәмсуар мөәзиннән дә яхшырак белүче юк. Әнә ул йомшак палас өстенә сызлаулы аякларын бөкләп утырган да, кирил хәрефле дога китабын укыштыргалаган кебек кыйланып:

— Шулай, энем, каймакка гына риза булмыйча, маена ук нәфесләнсәң, эремчегеннән дә колак кагасың аны! — дип, ачы елмаеп, уйлый.

Ә Мөхәммәт тәне белән — манарада, җаны белән назлыкайны эзләп изалана. Аңа баярак кына бер иптәше нокталы телефоннан хәбәр иткән иде инде. Әмма никтер егетнең күңеле ышанмый бу хәбәргә. Һәм ышанмый да булмый. Чөнки кыз аңа вәгъдә бирмәгән иде.

Ике атна үткәч, мөфтиятнең яңа, иркен бүлмәсендә сәркатип егет Мөхәммәткә яшертен рәвештә генә бер конверт тоттырды.

— Кемнән?! — дигән тойгылы сораугa, ул:

— Мөфтинең кече кызыннан! — дип җавап кайтарды.

— Өметбикәдәнме?! — Мөхәммәт ни уйларга да белмичә, тамгасыз-нисез зур, ак конвертның читен ертып, эченнән... сары ромашка чәчәге белән, кечкенә кәгазь тартып чыгарды.

Анда:

“Бу — ул түгел инде — мин, Мөхәммәт абый, Өмет-бикә! Син мине бик белмәсәң дә, мин сине — апам сөйләгәннәрдән чыгып — бик беләм! Калганын очрашкач сөйләшербез! Көт!” — дип, латин хәрефләре белән сыр-лап-бизәкләп язылган иде.

## *Күңел нечкәргәндә*

Минем бабам мулла булган әбием — абыстай. Риволүтсә ясалгач, эшче-крәстиән сыйныфына теләктәшлек йөзеннән, бабам муллалыгын, әбием абыстайлыгын ташлаган. Гаҗәп тә юмарт булганнар үзләре, өйләренә ярлы гаиләләрне урнаштырып, безгә монысының эче дә җәннәткә тиң, дип, бакалы мунчаны йорт иткәннәр. Дәү әтием шунда зәһәр төтен вә кипкән яфрак исен иснәп, бакалар сайравын тыңлап үскән. Мунча пәриләрсез булмый бит инде. Менә шул пәриләрнең берсе көннән көн явызлана барып, ниһаять, дәү әтиемнең сул кулындагы ике бармагын тешләп өзгән. Шул сәбәпле дәү әтиемне сугышка да алмаганнар. Ләкин колхоз рәисе киң күңелле булган, өйләрендә яшәгәнгәдер инде, дәү әтиемне сугыш вакыты дип тормыйча сәфәргә җибәргән, Колымага. Анда алтынны ничек чыгаралар икән, белеп кайт әле дип. Барган дәү әтием, танышкан алтын чыгаручыларның тормышы белән, ошап киткән булса кирәк, үзе дә шунда яшәп калган. Ун ел яшәгән ул анда. Аннары, иптәшләре туган якларын сагынып кайтып киткәч, дәү әтием дә, яшьрәк чакта кайтып калыйм дип, туган авылына кайтып төшкән — теге атаклы мунчага! Ел ярым егет булып, алай гына да түгел, егетләр бүресе булып йөргән дә, элекке колхоз рәисенең төпчек кызына өйләнеп җибәргән. Һәм дәү әтием минем дәү әнием белән мулла бабаемның йортында яши башлаган. Өч ел буе көткәннәр алар беренче балаларын. Аларга бәхет тик дүртенче елны гына елмая: дөньяга минем әти аваз сала!..

***

Әтием бик үҗәт, тырыш кеше булса да, сүзләрен үлчәп кенә әйтә иде. Сатучы иде ул. Шуңадыр инде мине дә бәләкәйдән үк гел-гел үлчәү тирәсендә генә бөтерелеп йөрергә мәҗбүр итте. Әмма мин аңа карамадым, бүтән юлдан киттем: укып, шуфир булдым!

Әнием минем бик еш авырый: укымаган, белемсез калган. Дәү әнием дә: “Кызыбыз укыса, калага китәр дә кыяфергә кияүгә чыгар”, — дип өреккән, имеш. Дәү әтием исә укымыйча да колхоз хәтле колхозны җитәкләгән!..

Әйе, әнием! диюгә үк күзләремнән яшьләр тама башлый. Кызгана идем шул мин аны. Миңа әнием һаман:

— Син, улым, күз нурым, ананңны тыңла!.. Әтиеңнең кибете аякланып йөгермәс, колхозың да тилгәнгә ияреп очып китмәс, миңа булыш! — дия иде.

Менә шулай күрше-күләннең исен китереп яшәп ята идек әле. Өйләнер вакыт җитте. Моны сизгән авыл кызлары бәйләм-бәйләм булып, минем тирәдә бөтерелергә кереште.

Кәпәчем белән киңәшләшә торгач, югары белемле мондый сала ялкауларына өйләнмәскә булдым. Иң әйбәте, мин әйтәм, кызның кызын Мәскәүдән сайлау!..

Бу турыда әтигә тишкән идем, ул икенче ияген капшап:

— Районнан да ярап торырые әле, — диде.

Һәрвакыттагыча соңгы сүзне әнием әйтте:

— Ниткән район ди ул? Күрше Имәнкискәдә генә булдыклы кыз барында! Булхактер! Яшь чакта әтисе белән дә йөрмәдем түгел. Менә шул кызны алдырам улыма!

Әнием сүзе миңа закун инде. Ул кушканча эшләргә булгач, әтием әллә ни карышып маташмады.

Туйны зурдан кубып үткәрдек без. Мин гел хәләлемә карап утырдым.

Һәрхәлдә, яхшы беләм, туйдан соң зөфаф кичәсе була. Әмма бу төнне хәләлем эчен тотып ыңгыраштыда ыңгыраштыы.

— Ни булды сиңа, акыллым! — дип сорыйм, өзгәләнеп.

— Оныт-тың-мыни, Кама өстендә, көймәдә... — ди бу.

— Аһ, әйе, исемә төште кебек. Мин аның белән булган ул хәлне төштә күрдем дип, Имәнкискә тарафына борылып карарга да оялып йөри идем ич, димәк...

Менә шулай... Өйләнүемә биш ай дигәндә, хатыным бәбиләп тә куйды.

***

Безнең биографияләрдә ак таплар күп! Бабамның йөзе Чыңгызга, холкы Сөембикәнекенә охшаган булган. Ә минем әти — дәү әтиемә, мин — әтигә, улым миңа охшамаган. Кыяфәт бер хәл әле, холык-фигыльләребез нисбәтендә дә капма-каршы без.

Әйтүләренчә, дәү әтиемнең йөзе Феликс Эдмундовичка тарткан, холкы Горькийга көндәш булырлык булган, имеш. Әтием — анысын үзем дә беләм — тышкы яктан нәкъ Черчильнең нөсхәсе, ә эче — Ворошиловныкы! Мин үзем суйган да каплаган... Кем? Юк, белмәячәксез; Лермонтов! Улым, теге кемдәй, чабата кашлы иде. Иде дим, чөнки ул Әфганстаннан яраланып кайтты да,

тазарып беткәч, бусында чечен сугышына китеп барды. Шунда ул Даниядән маҗара эзләп килгән кылган чәчле туташка юлыккан. Теге журналист туташ та минем улыма битараф түгел икән. Кыскасы, өйләнешеп, Стокгольмга кыякламак-чы була болар!

Менә мин дә, дөньяның чите кителмәсә, Кытайга сыпыртмакчы булам әле.

## *Рәхмәт, иптәш генерал!*

— Мин белештем, әти, милиция ВУЗын быел тәмамлаганнарның күбесен районнарга җибәрәләр икән! Ерак районнарга! Тәлгат тә шулар арасында булып чыкты!..

Юрист булып эшләүче кызының телефоннан ашыгыч кына

тапшырттырган бу хәбәреннән Таһир абый тамактан кала язды хәтта! Чөнки соңгы вакытларда ул төпчеген үз янына район милициясе бүлегенә эшкә кайтарттырырга бик тырышып йөргән иде. Баксаң?!

Юк, бусына һичничек түзеп булмый инде!

Ата кеше озын, авыр төнне ничек кирәк алай үткәреп җибәрде дә, кырынып-чистарынып, парад мундирына орден-медальләрен тагып, һәм ашап та тормыйча, үз машинасында калага юл тотты.

Ул туп-туры Кремльгә килде. Эчке эшләр министры-ның нечкә билле секретаре:

— Сезгә кем кирәк? — дип, компьютер экранынннан карашын алмыйча гына сорады.

— Министр!

— Министр килмәде әле, — диде кыска сары чәчле кыз татарчалап. — Менә... креслога утырып торыгыз! Мин хәзер урынбасарга әйтеп чыгам!

Таһир абый киң күңелле сәркатип кызга зур өметләр баглап, тәкъдим ителгән күн креслога утыргыч, компьютер экранында пәйда булган латин хәрефле язуларны укыштыргалаган арада, тырнакларын кызыл кынага буяган чибәркәй кояштан балкып килеп тә чыкты.

— Керегез! — диде ул баягыдан да назлырак, йомшаграк тавыш белән.

Форма кигән ир аңа рәхмәт әйтте һәм, хуҗа йомышымны белмәде әле, белгәч ниләр булыр икән дип, биек, ялтыравык ишекне һәм тагын шундый ук бер ишекне сакланып кына ачып, ак түшәмгә бәллүр шәмдәлләр асып куелган иркен генә бүлмәгә керде.

Бу искитмәле җыйнак, пөхтә кабинетның диварлары да ялтыравык иде. Шома паркет идән буйлап түргә таба кызыл палас җәелгән. Тумбалы озынча өстәл түрендә: көрән костюм, зәңгәр күлмәк кигән, ак галстук таккан зур пеләш башлы кеше телефоннан кем беләндер сөйләшә иде.

Таһир абый, тавышым яңгырап китмәсен тагын дигәндәй, акрын гына итеп:

— Исәнмесез! — дип куйды.

Урынбасар нилектәндер күтәрелеп карамады. Симез гәүдәсе белән уң кулының терсәгенәрәк авыша төште һәм сөйләшүеннән бүленмичә генә сул кулы белән ишарәләп утырырга кирәклекне аңлатты.

Капитан йомшак урындыкларның иң кырыйдагысына утырды. Каршы як диварда олы дәрәҗәле хәрби түрәләрнең зурайтылган портретлары эленеп тора иде. Ул кинәт бөек шәхесләр турында уйлап, министр урынбасарының колагы төбендәге яра җөенә текәлеп-текәлеп карарга кереште. Капитанның төсе үзгәрде, йөрәге еш-еш тибә башлады. Чак-чак кына ул: “Никифоров!” — дип, кычкырып җибәрмәде. Кем белә, бәлки, Никифоров түгелдер, аңа охшаган гынадыр? Ә бәлки...

Таһир абый кайда утыруын да онытып, ничәдер еллар элек булып узган вакыйганы исенә төшерде. Тирә-юньдә сугыш бара: авыр бомбалар төшеп җирне дер селкетә, снарядлар текә кыяларга тиеп шартлый, баш өстенә потлап-потлап корыч һәм гранит кыйпылчыклары сибелә.

Менә өстә, югарыда кул пулеметлары текелди... Шул мәхшәр эченнән чыккан берәү сикереп сукмакка төшә дә, пистолетын башы өстенә күтәргән килеш: “В перед, за дело правое!” — дип, алга ташлана. Таһир да аның артыннан йөгерә. Ул һични тоймый, засадага эләгүен дә сизми, үлемнең янәшәдә генә булуын да искәрми кебек; аның бөтен игътибары юл ярып алдан баручы батальон командирының киң аркасына гына текәлгән иде шул!

Чолганышны өзгәндә Никифоров авыр яраланды. Ярый әле Тәфкилевнең җилкәсе нык иде! Командир исән калуы белән Таһирга бурычлы, бик бурычлы! Әгәр бу — шул кеше икән, Тәфкилевне һичничек онытмаска тиеш! Теге чакта да бит... Анысы — ике ел узгач булды. Кызыл байраклы безнең дивизия дошман частьләрен эзәрлекли-эзәрлекли Кабулга якынлашып килә иде. Таһир да үзйөрешле орудияләрнең берсенә утырып бара иде. Көн кояшлы, эссе. Сугышчыларның йөзе сүрән, чикәләреннән юл-юл булып яшел десантчы киемнәренә тозлы тир ага иде.

Үзйөрешле орудияләр ачы төтен һәм янган май исе таратып, артларыннан биек-биек тузан баганалары күтәреп бара торгач, уң тарафта солы кыры шәйләнде. Юньләп солысы да

калмаган инде бу янган-көйгән кырның. Кая күз салма — мәет, кая төбәлмә хәрби техника аунап ята! Иң гаҗәбе шул: кырның юлга якынрак төшенә сибелеп, олы яшьтәге кеше сурәтләре төшерелгән яшькелт акчалар ята! Әмма, яшь солдатлар ул акчаларны барып җыярга уйлап та карамыйча, шул төштән битараф кыяфәттә үтеп китәләр! Әйе, аларның мондый рәвештә дә сыналганнары күп булды!..

Бара торгач, офицерлар утырган машиналарның берсендә дивизия командиры чалынып китте. Менә ул, яшел картуз кигән зур башын борып, колоннага карап куйды һәм аның очлы карашы Таһирныкы белән очрашты.

— Тәфкилев!

Сержантның башыннан:

“Таныды!” — дигән уй йөгереп узды.

— Тәфкилев! — дип кабатлады подполковник. Таһир абый сискәнеп китте. Янында министр урынбасары басып тора иде.

— Исәнме, капитан?! — диде Никифоров, күкрәгендә орден-медальләре балкып-балкып куйгалаган парад формасы кигән иргә көчле кулын сузып. — Сине яңа звание белән котлыйм! Шушы минуттан син — майор!

— Рәхмәт, иптәш генерал!

Алар күрештеләр. Шул мәлне Таһир абыйның кешеләрдән качып кына үкереп елыйсы килеп куйды. Биредә ул бу халәтен — йомшаклыгын сиздермәскә теләде. Әмма күңеле тулып өлгергән иде инде.

## *Сәләхетдин бабай*

Сәләхетдин бабай кара сатин чалбарының киң балакларын җилфердәтә-җилфердәтә килә. Аягында калош. Өстендә күк күлмәк, җиңнәрен сызганган. Башында киң кырлы испан эшләпәсе! Сул кулы чалбар кесәсендә. Уң кулында агач чүкеч.

Без — малайлар гадәттәгечә аның килүен, дөресрәге, аның җәйләүлеккә таба китеп барганчы, яныбызда туктап, ни дә булса сөйләвен түземсезләнеп көтеп утырабыз! Утырган урыныбыз заманасында әвен базы булып, еллар үтү белән аның түбе саеккан, стеналары сөзәкләнгән һәм базның һәр төшен чирәмдер, кычыткандыр, әремдер шикелле чүп үләннәре басып бетергән.

Баздан егерме адым чамасы читтәрәк кенә кулга кул тотынышып җырлый-җырлый түгәрәк әйләнүче егетләрнең-кызларның дәртле көйләре ишетелә. Менә тавышлар көчәяләр дә көчәяләр һәм урам читендә генә торып кала алмыйча, ай яктырткан кырларга, ындыр астындагы биек-биек тупыллар, өянкеләр янына да китеп яңгырыйлар. Анда булган кеше ишетмичә калмас аларның җырларын! Һәй ул яшьлекнең хис-тойгылар белән тулып ашкан моңлы да, көлкеле дә кичләре!..

Без менә хәзер Сәләхетдин бабайның чираттагы шаян хикәятен рәхәтләнеп тыңлаячакбыз, ә горур һәм чая күңелләребез — үзебез кебек үк матур гына өлгереп килүче тәти-тәти кызлар янында!..

— Һе-һе-һе-е-е... мине көтеп утырасызмы, наныйла-рым, интегеп!

— Утырабыз, ләкин интегеп түгел! — дип башкалар өчен дә җавап кайтардым мин.

Сәләхетдин бабай безнең каршыга — чирәмнең куерак төшенә ятты да, җырчы кызлар ягына карап:

— Их, Мария әбиегезнең дә ут чаклары бар иде бит! — дип куйды.

Сәләхетдин бабай безнең янга тукталган саен Мария әби турында ни дә булса сөйләмичә калмый иде. Шунлыктан без Мария әби турында кайбер нәрсәләрне белә идек инде. Ул — Испаниядә эшче гаиләсендә туган. Сугыш башлангач, әтисе эшчеләрдән отрядлар тупларга керешкән. Мария — әти-әнисе фашистлар тарафыннан һәлак ителгәч — безнең илгә, Казанга килеп эләккән! Аннары аның белән ниләр булган? Безне күбрәк мәсьәләнең шул ягы кызыксындыра инде. Әмма бабабыз нигәдер бусын сөйләми, йә җитез генә сикертеп уза, яки... әһәмиятсезрәк вакыйга турында хикәяләргә керешә иде. Ә бүген ул һичкөтмәгәндә:

— Мария апагызга минем ничек өйләнүемне белергә телисез бугай, наныйларым? Ярар, сөйлим алай булгач, тыңлагыз! Түлке кисәтеп куям, бүлдергәнне яратмыйм мин, — дип ташлады.

— Килештек, Сәләхетдин бабай, башла тизрәк! — дип гөрләштек без, яшь әтәчнеке сыман нәзек тавышыбызны мөмкин хәтле калынайтырга тырышып.

— Әйе, ул вакытта немецны җиңгәннән соң килгән өченче кыш иде, — дип ашыкмыйча гына башлады бабай сүзен. — Мин Армиядән узган ел кайтсам да, әле өйләнмәгән егет идем! Мәгәр... өйләнергә исәп юк түгел! Шундый матур хыяллар белән эшләп-яшәп яткан чак инде! Менә аръяк Фәрхенур үзе белән Казаннан

кунакка испан кызын ияртеп кайткан! Күрдем дә гашыйк булдым мин бу кыйгач кашлы, кара тутлы, ут карашлы усал кызга! Һәм

шул кичне аулак өйдә авылыбызның иң таза, иң көчле ике егете арасында шәйләп, Марияне хәзер үк алардан йолып алып үземнеке итәр өчен, туп-туры кызга таба атладым! Башта... биергә чакырам, аннары күз күрер, янәсе.

Ә теге ике егет, әле авызларында ана сөте дә кибеп җитмәгән, кем әйткәндәй, ямь-яшел ике алма нишлиме? Билгеле инде, Армия уставын бозмакчылар, ягъни гражданкада булгач, нишләсәң дә килешә дип, ахры, мине акылга утыртмакчылар!

Мин бит сугышны Албаниядә тәмамлап, капитан дәрәҗәсендә кайткан кеше! Колхозда ферма мөдире! Ә болар дары исен иснәү түгел, солдатта да булырга өлгермәгәннәр әле. Буй-сын, мускул-фәлән һәм тагын тел дигән сөяксез нәрсәдән гайре чуртлары да юк! Ә минем күкрәктәге орден-медальләрнең хисабы юк! Аннары, сизәм, буыннары да сыек шикелле. Кыскасы, боларның касыкларына төрткәләп, кычыткан йодырыкларымны әйбәт кенә кашып алдым мин ул чакта! Соңыннан беленде, берсе ян тәрәзәдән, икенчесе түр тәрәзәдән чыгып очкан икән урамга!

Шул мәлне Көртлек Җәләй борсаланып:

— Сәләхетдин бабай, ул чакта син үзең дә, гим-настерка түшең умырылып, ике-өч медалеңне югалткан-сың бугай! — дип куймасынмы.

Ә аңа җавап итеп Әтүш Гали янтыгына күчтәнәч та-мызды һәм:

— Янә дә авыз ачсаң, сөягеңне көл итәм! — дип янады.

Кәртүш Садрый гына аралап калды үзләрен, сугы-шасылар иде.

Көртлек Җәләй башындагы кәпәчен чирәм өстенә томырып, билендәге каешына да тотынган иде. Җитмәсә, гәүдәгә-гәүдәчә, буйга-буй төсле булмаган берәү, Җәләй-нең кәпәчен кычыткан арасына ук тибеп очырган. Шул кәпәчне табып алганчы, байтак кына минутларыбыз әрәм-гә үтеп китте. Без тетепме теттек Җәләйне:

— Чүпрәкче алмастай кәпәч өчен җәнҗал куптар-масаң, Көртлегең көртләми калыр идеме әллә? — дидек.

Ә Җәләйнең һаман үз иллесе илле инде, туздырган мендәр йоны ише иттереп барчабызны да шунда әрләп ташлады. Әгәр көче-куәте җитсә, безне берәм-берәм култык асты суына да болгап атып бетерер иде, бакалар янына! Нәселе шундый хасталы ич аның!

Сәләхетдин бабай әле һаман сулышын җайга сала алмыйча мышнап утырган Җәләйгә хәйләкәр карашын ташлап, крокодил

сурәтле төрепкәсенә самосад салды да, чакмасыннан ут элдергәч:

— Сез, наныйларым, чуртым да сугыша белмисез! Менә мин сугыша идем ул... анадан тума калганчы! Шуңа күрә, хәзер мин хикәятнең дүрт колибри ярымын кыскартам, тагын да ачуымны кабартсагыз, дилбегә буе могу кыскартырга, — дип, сәлперенке кашларын көян-тәләндереп, көлеп куйды.

— Юк, бабай, бүльше сугышу булмас инде, бүле-шерлек медальләребез дә юк ич! — дип, безгә кушылып, Җәләй дә көлде.

— Ярый алайса, наныйларым, мин китим, ә сез кызлар янына барыгыз! — дип Сәләхетдин бабай урыныннан калыкты.

Без — һәммәбез дә түгәрәк әйләнүче кызлар янына барып бастык. Җәләй:

— Сәләхетдин бабай дөрес сөйләмәде! Шыттырды бит ул, — диде.

— Кайдан беләсең? Кем әйтте? — дидем мин.

— Әниемнең сөйләгәне бар иде: теге чакта ме-дальләрне Сәләхетдин түгел, минем әти югалткан бул- ган!

— Ничек?! — диде Әтүш Гали ышанырга да, ышан-маска да белмичә.

— Шулай менә... Сәләхетдин капитан да булмаган әле, минем әти булган капитан!

— Ничек?! — диде Кәртүш Садрый кысык күзләрен чет-чет йомгалап.

— Сәләхетдин бабайның хатыны Мария әби дә испан кызы түгел әле, мари кызы гына! Сәләхетдин бабай шыттыра ул!

Без барыбыз да берьюлы урамыбыз тарафына тө-бәлдек. Сәләхетдин бабай инде ак кәҗәсен җитәкләп тыкрыкка кереп бара иде.

Ялганчы Сакалетдин!!!

## *Хәерлегә булсын*

Ниһаять, кала читендә генә төзеп куелган өр-яңа йортка күченеп, без буйдак ир тәганәләре дә яңача, ягъни кешечә яши башладык!.. Әнә егерме катлы йортыбыз каршында гына диярлек, ямь-яшел чирәмлек, арырак “Мәхәббәт аланы” дигән мәшһүр урынны чит-ят кавемнәрдән яшереп саклый торган куе таллык башланып китә! Без, ирләр иртә таңнан шул йомшак чирәм өстенә чыгып утырабыз да (кырын ятып кына симәнкә чиртүчеләр, хәтта ки, йокымсырап китеп, борын сызгыртучылар да була әле), әйе,

шул чирәм дигән яшел җәймә өстенә чыгып утырабыз да, и тотынабыз элек шәһәр уртасында, атаклы базар урамында торганда сөйләргә кыймаган нәрсәләр турында кайнарланып сөйләргә!..

Дөрес, без тегендә эшли идек. Ә бирedә, үзегез күреп торасыз — эшсезләр! Мәгәр бу афәт безнең йортыбызда яши башлаган ялгыз ханымнарга янамый! Болар үзләренең кемлекләрен бик белеп, шушы таллыклар артында гына бик борынгы шөгыль белән рәхәтләнеп, гөрләтеп кәсеп итеп яталар, булдыралар! Шуңарга аларның тамаклары тук, өс-башлары бөтен, тик без генә...

Бер көнне арабыздан бер тәвәккәле:

— Болай гел күккә төкереп кенә ятып кесәләребезгә акча үсмәс, җегетләр, әйдәгез, без дә анауы туташлар сыман төшемле кәсепкә керешик! — дип сүзгә керешкән генә иде, без егермеләп ир берьюлы аңа таба кырыклап кулыбыз белән сузылып, мескеннең ап-ак күлмәген кырык төштән кап-кара итеп умырып төшердек. Әмма ул безне ачуланмады, киресенчә ул үзе бездән гафу үтенде. Менә ичмасам зыялы кеше! Шуннан соң андый затлы темага сүз кузгатырга җөрьәт итүче табылмады. Зыялылыклары җитенкерәмәде ахры. Ә бу — кыю адәм — бераз тынып торганнан соң:

— Ял итеп ята торган урыныбызга “ирләр базары” дигән табличка куйыйк та, көтик! — ди.

— Кесәләребездә долларлар үскәннеме? — мин әйтәм.

— Аһ! Юк, сез нәрсә... Акчалы дамочкалар килгәнне зур түземлелек саклап көтик, — ди бу.

— Алайда була мени әле ул? — мин әйтәм.

— Була каничны, Маниты бит ике яклы. Мин бер дамочкада сакчы булып эшләдем. Беләм...

— Ә синең үзеңә калҗа эләгә идеме соң?

— Гафу итегез, темадан читкә китәсез. Әйдәгез, табличка куйыйк та, — дип, зыялы бәндә минем соравыма җавап бирүдән баш тартты.

— Күпме түли иде? — дип кызыксынды минем күршем.

— О, бу иң бөек сөр! Андый серне чишәргә мөмкин түгел, — дип зыялы адәм безгә таба якынлашучы Опельгә таба атлады. — Рәхим итегез, мадам! Кайсы ошый, сайлагыз!..

Унбиш минут үттеме икән әллә алтмыш биш, әллә җитмеш биш яшьләрендәге көяз кортка минем каршыда басып тора иде инде. Ул нәзек туфли очы белән минем

аякларыма тибеп карады, касыгыма төртте, авызымны ачтырып тешләремне санады да, зыялы хәчтерүшкә башы белән читкә

ымлады. Шунда күчеп, сөйләштеләр-аңлаштылар да, аннары кортка мине машинасына утыртып каядыр алып китте. Мин үзем бик яшь, ә бу... олы! Миңа әби тия бит инде бу!.. Хәер, зыялы тәганә ”маниты ике яклы” диде ләса.

Шулай берсеннән-берсе күңелле уйлар һәм шик-шөбһәләр эчендә килеп җиткәнне, әллә кайтып җиткәннеме, тоймый да калганмын.

“Мунча” дип язылган җыйнак кына бинаның кечерәк кенә ишеген ачып, әби миңа:

— Бар!.. — диде.

Эчемнән генә ләхләүләне укып кереп киттем. Артымнан ишекнең шапылдап ябылганын ишетүгә, сискәнеп, борылып карасам, өрлектәй нык, таза, ап-ак сакал-мыеклы бабай, кулына айбалта күтәреп, басып тора.

— Әйт тизрәк: җаныңмы, малыңмы? — ди бу миңа.

— Җаным! — дидем инде. Мондый чакта бүтән сүзләр башка килә мени.

— Алайса, азгын зат, хәзер үк эшкә кереш, — ди бабай айбалтасын айкап.

— Эшлим, бабай, эшлим. Тик...

Ике тәүлек ярым гомер үткәрдем мин монда: иске кирпечләрне кыргычлап, чистартып, менә дигән мич чыгардым! Аннары өч тәүлек керләр кайнаттым, юдым, киптердем, үтүкләдем. Янә өч көн чүгендер басуында чүп утап чиләндем. Соңыннан мине, унберенче тәүлеккә киткәндә, бәрәңге бакчасыннан айбалталы бабай сөреп чыгарды. Кызларының тәмам башын-күзен әйләндереп бетерә язган идем, шуны сизенделәр булса кирәк.

Аз гына акча белән кайтып киттем инде егерме катлы йортыбызга таба! Мәгәр ярты чакрым җир киттемме икән, арттан:

— Зөфәр! Зөфәр! — дип алагаем кычкыра-кычкыра килә теге кыз.

— Анауы тау башына менеп, синең арттан карап кем килә, — ди.

Минем өчен шулай өзелеп торгач, бу илаһи зәгыйфь җан иясенең сүзен тыңларга кирәк инде.

— Ярар, Зиночка, кил, муеныма менеп атлан... — дим шаяртып.

— Хәзер, Зөфәрчик! Хәзер, таяк кына сындырып алам да...

— Анысы нәрсәгә инде?

— Атны ныклап куарга! — ди Зиночка.

Урыс исемле булса да безнең милләтнең бер парәсе шул Зина-Зәйнәп. Телебездә дә, йөз-кыяфәтебездә дә һичнинди кимчелек

юк: икебез дә татар, икебез дә... Әйе, икебездә бу гаҗәп сәер илдә сәп-сәер интернационал тәрбия җимешләрен татып үскән яшьләр ич без! Менеп атланды бу муеныма. Авыр, каһәр: билем сыгылырга кереште, аякларым чалшаеп-чалшаеп китә башлады! Минем кебек мәчетле авылда сарык, бозау итләре генә ашап үсмәгәнлеге әллә кайдан сизелеп тора, — мырык-мырыкларның симез ите байтак көрәйткән моны, биллә-һи!..

— Нә-ә! — ди бу, таягы белән җилкәмә сугып та куя әле.

Без — мөселман исемле татарлар шикелле — ат итен ашамый шул болар, тай итен дә ашамыйлар бугай, ә менә куян итен...

Тфү, кайдан килә шундый бер күзәнәкле уйлар башка, — елан итен дә, бака итен дә ашамаганлыкларын яхшы беләм ләбаса, ашасалар, ашап үлмәсләр иде анысы, — без чучка салосын ашап үлмәгән шикелле!..

Юлым үргә таба китте. Шактый ук тирләтте һәм йончытты. Ә Зина-Зәйнәп муенымнан төшәргә уйламый да, киресенчә, баш түбәмә үк менеп утырырга чамалый сыман!

— Юк инде, монысы булмас! — дим эчемнән генә. — Нинди чыдам хайван дөянең дә башына менеп утыр-мыйлар, биленә генә менеп атланалар!

Шуннан, малай, ике кулым белән җиргә таяндым да, торам көтеп моның нык билемә менеп атланганын! Әйе, атланды, атланмый кая барсын соң ул? Киттем гайрәтле ташбакадай кызу-кызу гына юыртып. Ниһаять, Зиночка-Зәйнәбечкә түзмәде, хисләнеп-кайнарланып җырлап җибәрде:

Кара, кара... Караны кияләр дә,
“Минеке генә бул”, диләр,
Яныма киләләр дә.
Кызыл, кызыл... Шулай дими ни диим? —
Синеке генә булырга,
Дурак что ли мин? — дим.

Зиночка-Зәйнәбечкә илә дә матур җырлый икән. Мин — түзмәдем, аңа кушылдым:

Коены буралатырмын,
Куйдырырмын ак чыгыр! —
Йолдызлы кечтә Зина-Зәйнәп
Көянтә асып суга чыгар.
Чылтырар чулпылары;
Елтырар алкалары, —

Җемелдәр тешләре —
Гөрләп баргач эшләре!
Күккә ай калкыр.
Коеда ак чыгыр.
Яфраклардан чыклар
шыбыр-шыбыр...
Җиргә коела алмалар, —
Вакыт — җиткән:
Әнә, гомер параходы, —
Гү-ү, гү-ү! —
причалдан киткән!..
Сау бул яшьлек! дип
хушлашмыйм аның белән, —
аның хыялымда яңадан
кайтачагын беләм!..

Шул мәлне Зина-Зәйнәп касыгыма типте. Авыртты, билгеле.

— Әй, ты... с ума сошел, что ли?! — ди.

Аның шикелле урысчалатып әйттем бусында:

— Никак нет–с! — мин әйтәм.

— Алайса, ник елыйсың? Тинтәк! — ди.

— Күзгә нәрсәдер кереп, яшь чыгарды, бары шул гына, — дип акланмакчы булам инде.

— Мин анысын әйтмим! Күңелсез җыр җырлап, саруымны кайнатуың турында гына сорыйм ләбаса! — ди бу. Бераз баргач, үземне кызганып булса кирәк, башымнан сыйпап алды да: — Гомер бер генә килә, күңелле җырлар гына җырлап яшәргә кирәк, — дип җырлап җибәрде:

Көрән, көрән... Көрән кисәм, килешә;
Бер елмайсам янәшәмдә
Унбиш егет биешә!

— Ә бер көлсәң?.. — дип төрттердем моңа.

Җырлап кына җавап кайтарды бу.

Зәңгәр, зәңгәр... Зәңгәр төс һаваныкы!
Без — кызлар, егетләр — Адәм илә һауванықы!

Инде мин дә монынча гына җырларга тотындым, малай.

Сары, сары... Сары төс кайгы төсе.
Шулай булса да сарыны ярата күпме кеше!

— Ие, ярата, тот чәшкеңне! — дип үчекләде мине Зина-Зәйнәп. — Алайга китсә, кызыл белән яшелне дә кайгы китерүче иттереп була! Хикмәт бүтәндә, әйтик, сары — кояш төсе...

Без тау башына менеп җиткән идек инде.

— Аңлашылды! — дидем, мыш-мыш сулап, гәрчә күп нәрсәне Зина-Зәйнәпкә хас рәвештә аңламасам да! Аңарга — өстә, югарыда утырып кына баручыга — җиңелдер ул; миңа, утыртып баручыга авыр шул, һай, авыр: һични уйлыйсы килми!..

Зина-Зәйнәп җиргә төшеп басты да:

— Гудбай, мин шушында калам, сине озатып! — диде.

— Чао! Мине сагынган чагында айга кара, хисләреңдә һич тә ялгышмассың, — дип, дулкынланып, китеп бардым инде.

Озак та үтмәде, тауның теге ягында Зина-Зәйнәпнең үзенә генә хас ачык, яңгыравык тавыш белән җырлаганы ишетелде.

Шартлаткыч, пәке һәм кармак
утырган ди очкычка;
Пәке, кармак төшеп калган:
Кем калган очкычта?!

— Шартлаткыч!!! — дип кычкырдым мин.

Һәм шул мизгел, күкләрне-җирләрне дер селкетеп, нидер шартлады да, коеп-орып яңгыр яварга тотынды.

Хәерлегә булсын!..

## *Сабакташлар*

Менә ничә ел инде Ирдан, магнитка эләккән тимер кисәгедәй, Саниягә тартыла. Кыз да егетне якын итә бугай. Карашларының ягымлы, мөлаем булуыннан шул сизелә. Ләкин гел күз карашлары белән генә аңлашып булмый бит. Вакыты җиткәч, хүңелдәген тел белән дә әйтеп бирергә кирәктер, мөгаен! Ә аның өчен, билгеле инде, зур тәвәккәллек сорала. Тик, гафу итегез, бусы Ирданнан булмый: Сания белән ачыктан-ачык сөйләшеп аңлашырга кыюлык җитенкерәми ич аңа.

Алайса, нишләргә соң Ирданга?

Менә шундый сораулар белән башы каткан бервакытта, аның янына Илдар белән Зөфәр килеп басты.

— Сәлам, гадук! — дип елмаештылар алар.— Без синең Саниягә гашыйк булуыңны беләбез... Хәзер үк, бу турыда әйтеп, записка яз үзенә! Тапшырырбыз...

Бу аларның Ирданга ярдәм итәргә теләүләре идеме, әллә аннан чираттагы көләргә җыенуларымы? Шулай да кызыксыну һәм Саниянең йөрәген яулап алырга теләү хисе һәммә нәрсәдән дә өстенрәк булып чыкты, Ирдан сабакташларының тәкъдимен кабул итте. Шулай итеп, ике. яшь йөрәкнең араларын

күренмәс җепләр белән тоташтырырга тиешле записка язылып, Илдар белән Зөфәргә тапшырылды. Ә алар исә, үз чиратларында, записканы Саниягә илтеп бирергә тиешләр.

Уйлары шушы төшкә җиткәч кенә, кинәт барысын да сискәндереп һәм дәресләр тәмамланганны белдереп, коридорда кыңгырау чыңларга тотынды. Класста ыгы-зыгы купты. «Сания хәзер үк кайтмас әле ул, стена газетасы чыгарырга калыр»,— дип уйлады Ирдан һәм, шул мизгелдә, Зөфәр белән Илдарның Сания тирәсендә чуалырга керешүләренә кәефе күтәрелеп, киенергә тотынды.

Озакламый аның янына Илдар белән Зөфәр ялт итеп килеп тә бастылар.

— Записканы Сания укыган, җавабы бүген үк булыр, өеңә кайта тор,— диештеләр алар, бердәм рәвештә.

енә Ирдан, сөенеченнән зураеп киткәндәй булып, өенә кайтып бара. Язгы матур, җылы, рәхәт көннәрнең берсе. Өйлә авышып барган чак. Ирдан үзе дә, диңгезләрне айкап, Урал тауларын чалкан әйләндереп ташларлык көч сизеп, капкаларын ачты, һәм, чынлап та, менә хәзер нидер майтарып ташламыйча торып, күңеленә тынычлык таба алмаячак иде ул. Шундый ният белән малай, өйгә кермичә генә, өйалдында дөп-дөп басып йөренә башлады. Бу вакытта Ирданның әнисе сепарат аерту белән мәшгуль иде. Кинәт өйалдында нидер дөбердәп куйгач: «Әллә сарык фәлән кердеме икән?» — дип, ишекне ачса, бер почмакта малаеның сызгыра-сызгыра нәрсәдер эзләвен шәйләп алды. Вакытлы-вакытсыз бимазалап эшеннән бүлдергәне өчен ул малаен тиргәргә дә җыенган иде, мәгәр ана авыз ачканчы, малай шат кыяфәт белән:

— Балта кирәк иде миңа, әни, утын ярырга! — диде.

Фирданиянең йөзенә татлы елмаю җәелде. «Кара син аны, нинди уңган минем улым!» — һәм ана балтаны алып, көлемсери төшеп, малаена сузды.

Ирдан лапаска кергәч, дөньясын онытты: класссташы, күрше партада утыручы — мәктәп күләмендә иң чибәр кыз Санияне күз алдына китерде һәм байтактан бирле җыелып килгән ботаклы түмәрләрне ярырга керешә.

Бераздан капкада аның дуслары — Зөфәр белән Илдар күренде. Икесе дә шат, икесе дә елмаялар.

Илдар килә-килешкә үк, уң кулын алга сузып, учына ымлады. Аның уч төбендә хат кисәге иде!

Ирдан кызарып китте. Аннары, яра башлаган түмәрен таш-

лап, Илдарның кулына барып ябышты.

— Ә-ә, таламакчы буласыңмы? Бушка бирмим, бирмим! — дип чәрелдәп кычкырды Илдар.

— Әйтегез, ни бирим?..— дип өзгәләнде Ирдан.

— Бер стакан дары!

Сабакташ дуслар, үзләре теләгәнне алгач, күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә, бер читкә китеп бастылар. Ирданның инде дулкынланудан куллары гына түгел, аяклары да калтырый иде. Аның тизрәк хат кисәген укыйсы, анданиләр язылганны беләсе килә. Ләкин... умырып ертылган гап-гади дәфтәр битенә, кәкре-бөкре хәрефләр белән бары берничә сүз генә язылган иде анда.

«Ирдан! Мин дә сине сөям. Сания!»

Бу сүзләр шундый тәэсир итте ки Ирданга, кинәт, бәхет ишегенең ачыла башлавын сизеп, каушавыннан һәм сөенеченнән чак-чак кына елап җибәрмәде ул. Әгәр шунда малай кайнар хисләргә бирелмичә генә җентекләп укып чыккан булса, күрер иде аның Сания тарафыннан язылмавын һәм шунлыктан тылсымлы да булмавын. Әмма мәхәббәт сөреме күзен томалаган иде шул егетнең.

— Йә, укып бетердеңме? Саниягә җавап язасыңмы? — дип, Ирданның башындагы уйларын чуалтып ташлады Зөфәр.

— Ә-ә... язам, язам!

Илдар аңа кәгазь белән карандаш бирде.

«Сания! Мин синең белән очрашып сөйләшергә телим. Җавап көтәм. Ирдан!» дип, тиз-тиз сырлады егет.

— Җавабы бүген үк булыр. Көт,— диде Зөфәр, кәефле генә елмаеп.

Сабакташлар көлешә-көлешә чыгып киттеләр. Ирдан исә, матур-матур хыялларга бирелеп, янә түмәргә барып ябышты.

Илдар белән Зөфәр кабат килгәндә, кояш инде сүрелеп, ул баткан турыда күк йөзе алсу шәфәкъ булып янарга керешкән иде. Тамчы тавышы аермачык булып, тыкрыкта гөрләвек челтерәгәне ишетелә. Кайдадыр оясыннан чыккан ана каз кыйгаклый.

Илдар, кулындагы кәгазьне эре генә итеп, Ирданның борынына якын ук китереп җилпи башлагач, Ирдан:

— Күпмегә бирәсез монысын? — дип сорады.

— Ике стакан дары!

Өйгә кереп, атасының аучыларга бирелә торган дарыны киметеп чыккач кына, Ирданга кәгазьне сузды Илдар, һәм алар чыгып киттеләр.

Егет кәгазьне ачты. Ур-ра! кычкырып җибәргәнен тоймый да калды ул.

«Ирдан! Мин дә синең белән очрашып сөйләшергә телим. Күккә ай калыккач ук, иске тимерче алачыгы янына кил. Көтәрмен. Сания!»

Менә егет ояла-ояла гына урамга чыкты. Мәчет урамында ике тапкыр мылтыктан аттылар. Бераз торгач тагын, тагын...

Ирдан курка-курка гына тимерче алачыгы янына килеп җиткәндә, ату тавышлары да тынды.

— Сания килми әле,— дип сөйләнеп куйды җиденче класс укучысы һәм, йөрәге дөп-дөп каккан хәлдә, текәлә-текәлә көнбатыш тарафка карап торды.— Юк әле, күренми.— Аннары ул пальто кесәсендәге җимешне капшап карады.— Ничек итеп бирергә икән? Тотам да, мә, Сания, бу сиңа күчтәнәч, дим. Алыр микән? Алыр, бүтән кызлар әле симәнке ярганны күрсәләр дә сорап теңкәне корыталар ич. Ә бу симәнке түгел...

Шулчак караңгы күк йөзенә, Чиполлино китабындагы шаян әфлисун төсле, түп-түгәрәк кызгылт ай калыкты. Ул шундый якты, шундый мөлаем, мондый кичтә сөйгәнең белән янәшә булудан да олырак бәхет юктыр.

Кинәт кенә буа өстенә карап куйган иде егет, бирегә таба Зөфәр белән Илдарның килүен күреп алды. Әнә алар якыная төштеләр. Тагын бераздан аларның дорфа һәм карлыккан тавыш белән кыска-кыска гына итеп сөйләшүләре дә аермачык ишетелә башлады.

— Син ничә күгәрчен аттың?

— Бишне.

— Мин дә шул чама...

— Күбрәк тә атып алырга була иде, дары бетеп китте.

Икесе дә Ирдан поскан койма белән тигезләнделәр.

— Теге тиленең дары капчыгы шактый ук мул булырга тиеш.

Соңгы сүзләренең кем турында баруына төшенгәч, Ирданның башы чыңлап, күз аллары караңгыланып китте. «Димәк, хатны Сания язды диюләре хак булмаган. Аны сабакташлары үз хаҗәтләре өчен генә алдалап китергәннәр икән монда».

Ирдан, чагарга килүче корттан сакланырга теләгәндәй, артка чикте, алачыктан чыкты һәм Илдар белән Зөфәр кайтып барган юлдан кирегә таба җан-фәрман йөгерә башлады. «Димәк, мин тиле»,— диде ул үз-үзенә.

Ләкин ай җавап бирмәде аңа; ферма каралтылары да, өянкеләр дә эндәшмәделәр, тып-тын калып тора бирделәр.

Йөгерә-чаба торгач, Ирдан тау каршында тукталып калды. Гаҗәеп биек иде бу тау! Мәгәр Ирдан тотты да тауның иң биек төшеннән үрмәләп менеп китте.

Бик озак менде ул. Арып бетте, тәмам хәлдән тайды. Әмма шулай да менеп җитте. Ә бераздан ул үзен Саниялләр өе каршында, пәрдәсе корылмаган тәрәзәгә карап кызның үзен дә күрде әле. Ә бу вакытта Сания, булып узган хәлләр турында берни дә белмичә, онытылып, дәресләрен әзерләп утыра иде.

## Ришат ничек итеп кунак кызны көлдерде

Мәктәптән кайтты да, сумкасын идәнгә томырып, урамга атылды Ришат. Артыннан әнисенең: «И-и, тагын әллә кая чыгып олага инде»,— дигән рәнҗүле авазы гына яңгырап калды.

Капка төбенә чыгып баскач та, уйлары гел кунак кыз турында гына булды егетнең. Ничекләр генә көлдерергә үзен, бигрәкләр җитди инде...

Баш вата торгач, анысы да хәл ителде. Әнә мәчет тавында шау-гөр киләләр! Бу ямьле көндә кунак кыз гына өйдә утырып кала алмагандыр әле, аның да тынгысыз йөрәген уен үзенә тарткандыр!

Тауга җитеп түбәнгә карагач, берникадәр вакыт авызын яба алмый торды Ришат. Тау итәгендә кызлар бер якта, малайлар бер якта тәгәрәшә. Ниһаять, төшенде Ришат. Гарәфетдин дигән шук малай кырдан салам урлап ташый торган чаналарын сөйрәп килгән икән. Кунак кызның күңелен ачарга, көлдерергә теләп булса кирәк. Ә кыз-кыркын, малай-шалай төялгән чана, тауның иң шома төшенә җиткәч, янтаеп киткән дә, әй сибелгәннәр тегеләр кайсы-кая: зур чана өстенә кечкенә чаналылар, кечкенә чаналылар өстенә чаңгылылар өелешеп-буталышып беткәннәр...

Ертык арасыннан портык эзләп дигәндәй карана торгач, кызлар төркеме уртасында кыйммәтле тунын каккалап маташучы тузәлкәйне шәйләп алды Ришат. Мәгәр кунак кыз тамчы да көлми иде, бик җитди иде.

Инде шуып туйганнар, өйләренә таралышырга торалар. Гарәфетдин дә, чанасын сөйрәп, кайту юлына борылды.

Ә Ришат нишләргә тиеш хәзер? Чү! Туктале... Тегесе... ат чанасы бугай! Әһә, менә, ичмасам, бу — шәп! Бу инде синең ишәк җигәргә генә яраклы чанаң түгел, Гарәфи дус!

Ришат, үзе дә сизмәстән, йөрәксенеп, астагыларга кычкырып җибәрде:

— Монда менегез әле!

Барысы да, гаҗәпләнеп, тау өстенә карады.

— Менегез әле, мен!

Берничә ачык авыз югарыга ашыкты, алар артыннан йомык азызлар иярде.

Менеп тә җиттеләр тау башына. Малай ике җөмлә белән генә нишләргә җыенганын төшендереп бирде. И сөенделәр болар, и шатландылар һәм, ат чанасында шуып карау өчен, тауның әле берәү дә төшеп уйнамаган иң хәтәр җирен сайлап алдылар.

Төшеп киттеләр, ниһаять. Бермәлне шундый итеп карап куйды кунак кыз Ришатка,— аның әле кибетче Дәүләтша малаена да болай мәхәббәтле итеп караганы юктыр! Әй чибәр дә соң... Егетләр юкка гына хан кызына тиңләп йөрмиләр икән аны! Ә ул менә Ришатның янәшәсендә генә утыра...

Тауның яртысын уздылар. Кыз нигәдер борсаланырга тотынды; коңгырт кара күзләренә сорау билгеләре чыгарып, Ришатка еш-еш карап куйгалый башлады.'

Егетнең дә йөрәге урыныннан купты: әнә ич ат чанасы калын бозын кар каплаган буа өстеннән алагаем шуып китте. Инде елганың теге ягындагы Габделбәр бабай мунчасына барып җитәргә дә санаулы метрлар гына калып бара. һәм берзаман чана әнә шул иске мунчага — шалт!

Кунак кыз, түземлеген җуеп, Ришатның беләгеннән эләктереп алырга гына өлгерде, гаҗәеп көч тәэсирендә барчасы да як-якка чәчелеп китте.

Туфрак сөреме арасыннан берни күрер хәл юк. Үзем исәнен исән, ә башкалар ни хәлдә соң, дип уйлады Ришат. Ул, күзләрен угалый торгач, кыз-кыркын, малай-шалайның мунча җимерекләре арасында кыймылдашып ятканнарын шәйләде. Кунак кыз да шулар арасында...

Тагын да текәлебрәк карагач, Ришат Чибәркәйнең көлүен ишетте. Чөнки ат чанасы таралып беткән иде. Ә ул каравыл йортыныкы. Ә каравыл йортында Ришатның әтисе янгын сүндерүче булып эшли иде.

## *Хушлашмый калдым*

Операциядән соң носилкада палатага кертеп яткыргач та, су, су, дип ыңгыраштым мин. Төн иде. Бүлмәдә утны сүндергәннәр. Барчасы да йоклый булыр. Су-у... Ярдәм итәргә теләүче табылырмы, анысын белмим.

Бераздан тагын күзләремне ачам, тагын ыңгырашып куям. Каршымда ниндидер кара шәүлә торган кебек.

— Син... әҗәлме әллә?! Әҗәл, телгә килеп:

— Тынычлан, балакай,— диде.— Сиңа әле су эчәргә ярамый, шулай да бер йотым бирәм!

— Ник ярамый? Ник бер йотым гына?

— Тиз савыксын өчен, балакаем! — Кара шәүлә бер йотым суны кашык белән авызга салды да юкка чыкты. Мин янә, утлы күмерләр өстендә яткандай, әрнеп, газапланып йокыга талдым.

Иртәгесен уянгач, мин иң элек операция булган җиремнең сулык-сулык авыртуын һәм палата эченә ике зур-зур тәрәзәдән көн яктысы кереп торуын шәйләдем.

Обход вакыты икән инде. Палата эче ак халат кигән ирләр, хатын-кызлар белән тулган. Түгәрәк җитди йөзле, зур коңгырт күзле, сабыр, уйчан карашлы яшь хирургны күргәч, минем хәтеремнән төнге операция: янымдагы табакка бер-бер артлы очып торган кызыл төстәге мамык, марля кисәкләре чагылып үтте...

Менә озын буйлы хирург минем янга туктады. «Молодец!»— диде ул, җиңелчә генә минем иңнәремә кагылып, аннары хирург, врачларны ияртеп, янә бер авыру янына китте. Анысы минем күршем — төнлә миңа бер йотым су эчерткән Кара шәүлә булып чыкты. Ул, ике кулы белән ятагына таянып; аякларын салындырып утырган. Ул аякларга карасаң... Алар тубыкка шае юанаеп шешкәннәр, хәтта ялтырап торалар. Миңа иң тәэсир иткәне күршемнең чиктән тыш ябыклыгы иде. Аның гел сеңердән генә диярлек торган беләкләрендә һәммә кан тамырлары да беленә иде сыман. Минем уемча, бу кешенең бердәнбер тере нәрсәсе — утлы күмердәй өтеп ала торган чем-кара күзләредер. Әйе, алар әле яшәүдән өмет өзмәгән, тормышка тотырып, могҗиза көтеп карыйлар.

Хирург чак кына иелде дә, күршемнең аякларындагы шешкә бармакларын батырып баскалый-баскалый, врачларга нидер аңлатырга кереште:

— Сәгыйть Гафурович! — диде ул аннары күршемә.— Сезгә барыбер аякларыгызны кистерергә туры киләчәк, үҗәтләнмәгез, хатыныгызны чакыртып сөйләшегез, киңәшегез...

Бу хәлне күзәтеп торган авырулар,Сәгыйть Гафуровичтан

уңайсызланып, башларын мендәргә куйдылар. Миңа да кызганыч иде күршем. Бу кеше бит төнлә миңа алып килеп су эчертте, ә мин аңа берничек тә ярдәм итә алмыйм!

Икенче көнне обход вакытында хирург күршем янында янә озак тоткарланды. Тагын кичәге сүзләр: ялынулар, үгетләүләр... Болар ни гомер кабатлана торгандыр инде, белмим. Мина шунысы гына билгеле: күршем — сугыш ветераны! Ул ни сәбәпле хирургны тыңламый, аякларын кисәргә рөхсәт бирми: савыгырга теләмиме?.. Уйлыйм-уйлыйм да, катлаулы, ай-һай катлаулы бу тормыш дигән нәтиҗә ясап куям.

Төштән соң Сәгыйть Гафурович янына бер ханым килде. Юантык гәүдәле, уйчан йөзле, моңсу карашлы бу ханымның да чәчләренә «вакыт бабай» көмеш тузанын мул итеп сипкән иде. Ул ашыкмый гына сөйли, күбрәк сораштыра һәм киңәшләрен бирә иде.

— Юк, юк, Рабига... Аякларымны кистермим! — диде күршем, ниһаять.

Аларның күңелсез генә сөйләшүе, көзге җилнең эчпошыргыч дуылдап сызгыруына аваздаш иде кебек.

— Бәлки, тотарсың, Сәгыйть, сүземне?..

Тәрәзә каршында яфраклары саргайган яшь каенны җил һаман айкый да чайкый. Каен чәчләрен йолкый-йолкый елаган кешене хәтерләтә. Ул да булмый, вак кына сибәләгән яңгыр, эре-эре тамчылар белән кушылып, көчәеп, шыбыр-шыбыр пыялага килеп бәрелә һәм вакыты-вакыты белән тәрәзәләрне чыкылдатып-чыкылдатып куя.

— Рабига... кителемә яңа орденымны да так, җай чыгып... Ханым, җавап урынына:

— Уйныйсыңмы, Сәгыйть? — дип сорады.

Күршем кулын, көтелмәгән кискенлек белән, ханымга таба сузды.

— Чынмы, Рабига? Алып килдеңмени?..

Рабига ханым алып күрсәткәч, Сәгыйть Гафурович аңа, ниндидер бер изге нәрсәгә баккандай, таң калып карап торды. Аның эчендәге шатлык-куанычы тышка бәреп чыкты, йөзе алсуланып китте, күзләре дымланды.

— Әлбәттә, уйныйм! — диде ул, дулкынланудан тамагына бөялгән төерне йотарга азапланып. Мандолинаны иплəп кенә күкрәгенә кысты да җиңел, нәзек кылларга сак кына кагылып алды. Аннары, башын бер якка кыегайта төшеп, мандолинасына төбәлгән көе, дәртләнеп уйнап җибәрде.

Авыруларга гүя хәл кереп китте. Көйне һәркемнең җаны тансыклаганга күрә, авырулар аның уйнау рәвешенә аеруча

игътибар иттеләр. Ә уйнаучы, чынлап та, оста иде. Бик белеп, җиренә җиткереп башкарылган көй, гәрчә борынгы булса да, тыңлаучыны битараф калдырмаслык иде! Ә Сәгыйть Гафурович, тагын да дәртләнеп, җилкенеп чиртә дә чиртә, күз алдында могҗиза тудыра. Авырулар гүя хастаханәдә ятуларын да оныттылар; алар әйтерсең лә зур бер урман аланына килеп чыктылар. Монда кошлар сайравы да, чәчәк-гөлләрдән хуш исләрнең аңкып торуы да — монда һәммәсе дә бар! Шундый өермәле хисләр эчендә бөтерелеп, кайнап, мин уйнаучының үзен исемнән үк чыгарганмын икән. Көйнең соңгы аккордлары уйналып беткәндә, ялт кына Сәгыйть Гафурович тарафына карадым. Гаҗәеп тамаша, күршем, мандолинасы белән бергә, хатынын күкрәгенә кыскан да:

— Юк, мин кистермим аякларымны, Рабига! Минем аякларымны фашист бомбасы да өзә алмады бит...— ди.

Рабига ханымның иңбашлары калтыранып куйды. Ул, башын күтәреп, иренә төбәлде, нидер әйтте бугай, әллә без аңламадык, әллә ишетмәдек!

Ә тышта тынгысыз җил бертуктаусыз үкерә, кая барып бәрелергә белмичә елый, өзгәләнә иде.

Бер уйласаң, кеше җаны да шулай бит: өзгәләнә-өзгәләнә дә аннары вакыты җиткәч тынып кала, тып-тын булып.

Икенче көнне иртән Сәгыйть Гафуровичның төнлә кинәт кенә үлүен ишетеп шаккаттык. Җил дә тынган иде. Күршемнең җансыз гәүдәсен соңгы юлга озатып җибәргәндә, мин ярамны бәйләтергә киткән идем: мәрхүм белән хушлашмыйча калдым.

## *Хәсрәт*

Чатнама суык иртәләрнең берсе иде. Өстәмә юлларда күп кенә йөкле вагоннар торган, аргы башта биек булып утын өелгән станциягә, һавага ак бу бөркеп, пошкыра-пошкыра, тепловоз килеп туктады. Вагон ишекләре ачылып китте һәм тимер баскычлардан сакланып кына биштәрдер, чемодандыр, капчыктыр күтәргән кешеләр төшә башлады. Уртадагы вагоннан иң соңгы кеше булып бер егет чыкты да, як-ягына күз дә салмыйча, таныш юл буйлап якын тыкрыкка юнәлде. Бераздан инде ул Вафа карт ишеге янында басып тора иде. Аз гына дулкынланып, өстен-башын тәртипкә китергәч, кыяр-кыймас кына, ишек яңагындагы түгәрәк төймәгә үрелде. Бер-ике минут үттемеюкмы, өйалдында нидер шалтырап куйды һәм егет каршына ишектән таныш әби чыкты да елап җибәрде:

— Илгиз улым, Фаругыбыз үлде бит...

Әби, такмаклый-такмаклый, көннең суык булуын да онытып җибәрде. Өстендә фланель халат кына, ә тышта? Әбигә салкын тиюе мөмкин! Егет әбигә шул турыда әйтте.

Әби:

— Иң-иң яратканым иде, арада иң тәртиплесе, инсафлысы иде,— дип такмаклауга күчте.

Илгиз әбине җитәкләп өйгә кергәч, мич буенда хәрәкәтсез калып утыручы бер кызны күрде. Гәрчә мич эссе булса да, кыз киемнәрен салмаган, мамык якалы пальтосының төймәләрен генә чишкән дә башындагы кәҗә шәлен аркасына шудырган. Кыз яны белән утырып һәм озын кара керфекләрен кыймылдатып та карамаганга күрә, егеткә ул йокымсырый төсле тоелды.

«Солдатның кәләше булса кирәк»,— дип уйлады Илгиз, кызның нәфис борын очында елтырашкан тир тамчыларына төбәлгән көе. Шуннан соң, исәнмесез, диде. Кыз, гаҗәпләнеп, егеткә жарады. Аның ике бите буйлап агып төшкән күз яшьләре солдат үлеменең никадәрле кайгыга салганлыгын, хәсрәткә дучар гткәнлеген әйтеп тора иде. Яшь кызның шулай газаплануы Илгизнең дә күңелен нечкәртеп җибәрде. Гәрчә ул солдатның тутан тиешле кешеләр баласы икәнлеген белсә дә, аның үзен гургәне булмаганга, Фарукның холкын, йөз чалымнарын, әбинең сөйләвенә таянып төсмерли иде. Чөнки ул бу калага быел гына килеп урнашты. Маһруй әбиләрен табып, аларга килгәләп йөри башлаганына да икенче ай гына иде. Ул менә бүген дә ялны Маһруй әбиләрендә күңелле итеп үткәрергә килде, әмма, бу күңелсез хәлне күргәч:

— Ник үлгән ул әбинең олы малаеның яхшьт улы? Ник үтергәннәр аны? — дип өзгәләнде.

Өй эчендә ике тереклек иясе, ике җан газап чигә: берсе — солдатның яраткан әбисе, икенчесе — мәхәббәте, сөйгән яры.

Әби, кулларын өстәлгә куеп, яңакларына таянып утырган җиреннән кинәт борылып, Илгизгә карады. Аның күзләре яшьле һәм сагышлы иде.

— Улым, чишен! — диде әби.

Егет, шунда гына аяк өсте торуына төшенеп, пальто төймәләренә кагылды һәм бүреге белән шарфын да юынгыч, янәшәсендәге элгечкә асып, кыз каршындагы урындыкка урнашты. Ә кыз һаман боегып утыра да утыра. Ул гүя җансыз, таш сын!

Әби, янә хәрәкәткә килеп, башындагы яулыгын төзәтте һәм кызга таба борылды:

— Латифә, син дә чишен инде, балам! Нихәл итик соң? Безгә шулай язган, күрәсең...

Кыз чак кына кыймылдап алды, борынын тартты, ләкин дәшмәде.

Аны кызганудан егетнең дә йөрәге чәнчеп куйды. Мондый вакытта кешене ничек кызганмыйсың да, ничек аның хәленә керергә тырышмыйсың ди.

Әби чәй кайнатып чыгарды да, Вафа бабайның Нәҗип абыйларга менеп китүен, ә Нәҗип абыйның хатыны белән Фарукны алып кайтырга очуын әйтеп, касәләргә лимон турап салды.Өчәүләшеп чәй эчәргә утырдылар. Әбинең кәефе яхшыра төште, ахры. Ул, оныгы Фарукның яшьрәк чагын сөйләп, күңелен дә бушатып алды.

Икенче көнне Илгиз техникумга бармады. Старостага аңлатма язып бирермен әле, дип, Нәҗип абыйларда калды.

Әнә койма буена да күп кеше җыелып өлгергән. Күршекүлән, туган-тумача — барысы да мәрхүмне алып кайтканны көтеп тора. Көн гадәттәгечә салкын һәм коры. Кешеләр куллары-кулга шап-шоп суккалыйлар, вакыт-вакыт, башларын борып, тыкрыкка карап алгалыйлар. Туңганраклары исә, җылы өйгә кереп, кайнар мичкә аркаларын терәп, буыннарын йомшартып чыгалар. Егет тә киенеп урамга чыкты һәм, төркем янына килеп, сөйләшүләргә колак салды.

— Энесенә телеграмма суктылармы икән? — дип куйды бер апа.

— Суктылар! — диде кызыл чырайлы абый, мыегындагы бәсләрне сыпыргалап.

— Нимес җирендә бит ул, кайтуы да озакка сузылыр инде.

— Билгеле...

Көннең икенче яртысында җирдән себерә торган буран күтәрелде. Бер сәгать эчендә тыкрык чатларын, капка тирәләрен киртләч-киртләч көртләр басып китте. Ниһаять, караңгыланды. Өйләрдә утлар кабынгач, тәрәзәләрнең кыш бабай тырышып төшергән бизәкләре дә күренә башлады.

Инде менә хафаланып, өзгәләнеп көткән авыр минутлардан соң, киләләр, киләләр, дигән авазлар ишетелү барча кешене бердәм каушатып җибәрде. Киң урамны иңләп таралган ваквак төркемнәр, зур бер төркемгә оешып, инде ни булыр икән, дигән сыман тын калдылар, һәммәсенең дә күңелендә курку катыш кызыксыну, мәрхүмне күреп калырга теләү хисе уянды.

Карга бата-чума килгән машина төркемгә якынаерга кыймыйча туктады. Ишекләр бер үк вакытта диярлек ачылды һәм кабинадан иң элек Нәҗип белән Кәүсәрия төште, аннан озын буйлы капитан һәм дә ике солдат чыгып, иңбашларына кызыл тукыма белән тышланган табутны күтәреп, капкага таба атладылар.

Солдатлар табутны алдагы өйгә, ике урындык өстенә куйдылар да, Фарукны халыкка күрсәтер өчен, капкачын ачтылар. Ята Фарук! Өстендә чик сакчысы киемнәре, күзләре йомык, иреннәре кысылган, иягендәге бала төкләре дә сакланып кал-

ган, ул гүя үлмәгән дә, йоклый гына, менә-менә күзләрен ачып җибәрер... Илгизгә Фарук чынлап та иреннәрен кыймылдата сыман тоелды. Ә кешеләр керә тора, чыга тора, барысы да солдатка текәлә-текәлә карыйлар. Өй эче тулы газап, киеренкелек...

Кинәт өйгә баштанаяк карага киенгән кызның пәйда булуы һәм ачыргаланып елап җибәрүе барча кешене дә өнсез итте.

— Фар-рук, җаныкаем! Нишләдең син? Нигә ташлап киттең? Бик яшь идең бит әле, Фарук! Фарук, дим!..

Егетнең күз аллары караңгыланып китте. Маһруй әбиләр өендә очраган кыз иде бу. Илгиз, кызның иңрәүләренә түзә алмыйча, абьша-сөртенә ишеккә юнәлде. Чыгып барганда, астагы өйдән: «Йөрәк даруы... валидол бирегез!» — дигән сыкранулы авазлар ишетү егетне тәмам шаштыра язды. һәм ул, саташып, овчарка яши торган бүлмәгә барып керде. Бәхетенә — эт чылбырда икән.

Мәрхүмне ике көн күмми тоттылар. Беришләре күмик дисәләр дә, Нәҗип абый:

— Германия Марста түгел әле, кайтып җитәр,— диде.

Чынлап та, Илдус кичкырын кайтып төште. Юлда тоткарлык килеп чыкмаса, алданрак та кайтасы булган, имеш.

Каберне алар икенче көнне иртүк барып казыдылар. Ә сәгать ун тулганда инде табутны зиратка алып та киттеләр. Кеше галәмәт күп, әйтерсең бормалы-сырмалы елга! Илгиз исә шул елганың башында, табут күтәреп баручылар арасында иде.

Мәетне сак кына кабергә төшерделәр.

Ничәдер минуттан соң зиратта — кар катыш кызыл-сары балчык өеме — өр-яңа кабер калкып тора иде инде.

Мәрхүмнең баш очында йолдыз беркетелгән тимер казык тора... Урта бер җирендә Фарукның сурәте, ә сурәт астына

*«Вафин Фарук Нәҗип улы*
*1952-1971 3.02 8.11»*

дип язылган иде.

## *Кыек авыз*

Мин балачактан ук мактаганны үлеп ярата идем. Күрәсең, шулай өйрәтеп аздырганнар һәм бозганнар да! Кирәккәндә дә, кирәкмәгәндә дә мактау аркасында үз гомеремдә күп мәртәбә «яндым». Барысы да яшьлектә, әле яңа гына тормышка аяк басып килгән чагымда!.. Юк, бу берәр мокыт кибетченең база-

да товар-фәлән барлаганда яки сатып алучының гастрономда кибетче ханым яисә кассир туташ тарафыннан алдануы кебек түгел иде. Болар бит матди алдану, ә минем җанымны алдадылар ул вакытта!

Мин, авылыбыздагы тугызъеллык мәктәпне тәмамлагач, укуымны унынчыда дәвам итәр өчен, авылыбыздан утыз чакрым ераклыкта урнашкан атаклы Хәмзә авылына киттем. Үзем генә түгел, күрше дустым Әхсән белән. Икебездә дә яңа сәпид, икебез дә рәхәтләнеп кызлар турында сөйләшәбез. Зур булдык бит инде! Аннары авыл кызлары нигәдер безнең икебезне сөймиләр, ә тегендә, әлбәттә, кызлар безнең өчен үлеп торырга тиешләр.

Уйларымны сизгәндәй, Әхсән хәйләкәр генә елмайды да:

— Сине Хәмзәдә, Идеал, бөтен кызлар ошатачаклар әле, үз итәчәкләр, менә күрерсең! — дип куйды.

Әхсән дустымның бу сүзләре күңелемә сары май булып ятты, валлаһи менә!

Озакламый еракта, тау өстендә урнашкан зур гына Хәмзә авылы күренде. Ә Хәмзәдән өстә тагын тау башлана иде. Таулы авыл икән бу!

Әхсән миңа:

— Кышын чаңгы шуып уйнарга әйбәт икән бу авылның тавы,— диде.

Әйе, чибәр-чибәр кызлар белән...— дидем мин, мутланып һәм хыялланып.

Әхсән исә:

— Әнә... матур күлмәк кигән бер кыз суга бара, мин аңа гашыйк та булып өлгердем инде, малай,— диде.

Чынлап та, кызның күлмәге матур иде: зәңгәр җирлеккә ак борчак төшерелгән, мәгәр йөзе күренми үзенең; ул бездән кире якка таба китеп бара әле. Бу — Хәмзәдә иң беренче очраткан кызыбыз, шуңа күрә күбрәк кызыксындыргандыр, мөгаен. Без аның артыннан күздән югалганчы карап калырга булдык. Ләкин кыз көтмәгәндә генә тыкрыкка борылды. Борылды һәм... без аның бөкре икәнлеген чамалап алдык.

Мин шундук кычкырып көлеп җибәрдем. Әхсән исә кыпкызыл булып кызарды, эндәшмәде. Хәер, беренче пешергән коймак төерле була, диләр. Икенче юлы, һәр очраган Хәмзә кызын матурга санап, алданмабыз инде!

Без, авылга кергәч, утын яручы агайдан мәктәпләренең кайдалыгын сорадык.

— Кайсы мәктәп кирәк икән соң сезгә? — диде агай һәм озынча кызыл йөзеннән аккан тирне учы белән сыпырып алды.

— Без... унынчыга укырга килдек,— диде Әхсән.

— Ә алайса...дальше барыгыз,—диде агай, кулы белән авылның теге ягына таба ишарәләп.

Без, агайга рәхмәт әйтеп, ары киттек...

Ниһаять, без, Хәмзә авылының безгә кирәкле мәктәбе белән танышып, тулай торагына урнашып, клубының да эчен-тышын җентекләп тикшереп (бераз искерәк искесен дә, ничава, ярап тора әлегә), инде хәзер кич, бильярд суккан егетләреннән очлы карашыбызны алып, кызларына игътибар биреп күзәтеп утырабыз. Дустым Әхсән әнә тагын бер чибәргә гашыйк булып өлгерде. Мәгәр ул кыз минем шундук гайрәтемне чигерде, тамчы да ошамады. Ошау гынамы әле: мин хәтта идәнгә төкереп җибәрә яздым, һай, нинди егеттер бу Әхсән, һич аңламассың. Ул гашыйк булган кыз, көндез күргәне кебек, янә гарип: кылый күзле, кыек авызлы булып чыкты!

Ә Әхсән (тиле түгел диген син аны!) көлә һәм сер бирмәгән атлы булып кылана әле:

— Калган әгъзалары камил аның, Идеал күрше, авызы гына чепуха, үбә-үбә турайтам мин аны, — ди.

— Ярар, авызын үбеп турайттың да, ди, ә күзен ничек итеп турайтырсың икән, Әхсән дус?!

Авылдашым чак кына уйланып торды да:

— Калган әгъзалары «сәгать» икән аның, Идеал күрше, авызы гына бераз кыек булу комымны коймас әле, ә күзлек кигәч, күзенең кылыйлыгы беленмәячәк, хәтта әле ул укытучыга охшап китәчәк, менә күрерсең! — диде.

Шул чакны клубта көндез без күргән бөкре кыз пәйда булды. Әхсән миңа төртте:

— Монысын син турайтырсың инде, Идеал дус. Бөтен нәрсә кулыңнан килә ләбаса, оста ич син!

Авылдашымның һәрвакыттагыча үтереп мактавы йөрәгемә сары май булып ятты. Мин үземнең «оста» булуым белән эчемнән генә горурлана ук башладым.

Утырабыз шулай, утырабыз: без чибәр-чибәр кызлар ягына, ә алар безнең якка карап. Хәмзә авылының нечкә билле кызлары безнең өчен әле — кроссворд, ә без алар өчен, билгеле инде — чайнворд, шуннан да ким түгелдер?!

Ниһаять, берсеннән-берсе гүзәлкәйләр арасында иң шәбе, иң кәттәсе торып, гармун күтәреп, минем каршыга килеп басты. Ул елмая — мин оялам, ул көлә — мин бетәм, ул күз кыса — мин гүя бу дөньяда юк.

Кыз әйтә:

— Кунак булсаң, тыйнак бул дигәндәй, син бит, Идеал, кунакка килмәгәнсең: мә, бер сыздырып җиф-фәр инде.

Мин ялт кына Хәмзә егетләре тарафына төбәлдем. Алар ни әйтер бит әле. Хуп күрерләрме, яратырлармы бу эшемне? Әллә...

Ләкин Хәмзәнең кызу канлы егетләре өчен мин әллә бар, әллә юк: алар әле һаман да булса ниндидер бер чит егеткә бәйләнепме-бәйләнәләр. Миңа аларның: «Өйрәтергә-нитәргә кирәк бу кала дурагын»,— дип бәхәсләшүләре дә ишетелә. Шулар янәшәсендә үк авыл рәссамы калын пыялага майлы буяулар белән Ленин портретын ясап маташа... Мин сыздырып уйнап җибәрдем. Теге кәттә кыз, шуны гына көткәндәй, минем каршымда бөтерелә-бөтерелә бии башлады. Вакыты-вакыты белән ул миңа төбәлеп, күз уйнатып, каш сикертеп ала. Мин дә, кыюланып китеп, аңа күз кысып җавап бирергә керештем. Инде бармакларым да гармун төймәләренең тигән җире-нә тия,тимәгән җиренә юк. Аякларым да тыпырдый башлагач, Әхсән түзмәде, терсәге белән кабыргама төртеп куйды: «У-у-у, Чүлмәк (чүлмәк минем кушамат була инде), Хәмзәнең беренче кызын үзеңә җәлеп иттердең бит, янәсе».

«Дөрес, дөрес, Жираф»,— дидем мин сөенеп. Түзмәдем, гармунны Әхсәнгә тоттырдым, мә, син дә сыздырып ал әле бераз дим... Әхсән — молодец ул, ялындырып тормады. Шуны гына көткәндәй, Әхсән кызының гүя авызы турайды, күзләре дә берсе көньяк, икенчесе төньяк полюска карамый башлады сыман. Зөбәрҗәт (кызның исеме) мине биергә чакыра, ахры. Ук шикелле каршына атылдым моның. Үзебез биибез шикелле, ә үзебез бер-беребездән күзләребезне ала алмыйбыз. Ай-һай, мин әйтәм эчемнән генә, иң зәһәр чегән кызының да күзләре моныкы кебек үк ут түгелдер әле, дим. Болай дәвам итсә, мин моның ялкынында куырылачакмын, күмергә әвереләчәкмен. Уф, ярый әле Әхсән арып уйнавыннан туктады, юкса теге Кыек авыз минем белән вальс әйләнмәкче иде: бөтерелми торсын әле! Мин, элеккеге урынымнан күчеп, рәссам янәшәсендәге эскәмиягә барып утырдым. Аста нидер шытырдап куйды. Ул да булмады, баягы кала егете гармунда «Барыня»ны әйттерергә тотынды. Әнә инде Зөбәрҗәт мине биергә чакырырга да килә. И-и, ардырыйм әле үзен биетеп. Чү! Ни булды? Нинди тавышлар бу? Карасам, Хәмзәнең үгездәй егетләре Әхсәнне, җилтерәтеп, ишеккә таба алып баралар иде. Тышка алып чыгып, коймак итәргә телиләр, ахры, дустымны. Ләкин һич аңламыйм: ни өчен, нинди этлек эшләгән соң ул аларга?! Шулчак Зөбәрҗәт колагыма пышылдады: «Өстенә утырып, Ленин сурәтен көл иткән өчен... мәгәр ул сурәтне син ваттың, Идеал, бар, чык, йолып ал дустыңны нахак бәладән, әгәр намусың чиста булса».

Зөбәрҗәт сүзе миңа закон. Шундук урамга атылып чыктым. «Тимәгез аңа,— мин әйтәм,— Ленин сурәтен мин ваттым...»

Берничә секундтан инде егетләр керүгә таба баралар, ә минем борынымнан гөрелдәп кан ага иде.

Озакламый клубтагылар тарала башлады. Менә Зөбәрҗәтнең бик затлы күлмәге дә 'күренде. Кыз минем яннан сыдырылып кына диярлек үтеп китте. «Әйдә, җаным, минем арттан калма!» — дип тә әйтте бугай әле. Шуннан соң мин, кыюланып, Зөбәрҗәтне өенә озата ук киттем. Капка төбендә суырып үптем дә әле үзен. Ай, аның ул иреннәре-е... балың-шикәрең бер якта торсын, валлаһи!

— Иртәгә тагын кил, яме, Идеал! — ди бу, пышылдап кына.

— Килермен инде,— мин әйтәм,— һәр кичне килермен, хәзер син минеке!

Шуннан соң ул йөгереп кереп китте, ә мин акрын гына, йолдызлар белән серләшә-серләшә, кайтып киттем. Авыл уртасында Хәмзәдә туган атаклы бер каһарманның һәйкәленә дигән гранит таш өстендә моңаеп утыручы. Әхсәнне очраттым. Янәшәсендә теге Кыек авыз да утыра иде.

— Чао, Жираф! — мин әйтәм авылдашыма.

— Хэлло, Чүлмәк! — дигән була бу.

Мин, кеткелдәп келә-көлә, ары киттем. Кайтып яттым тулай торакка. Бераздан, миңа таныш түгел җырны авыз эченнән генә көйли-көйли, Әхсән дә кайтты.

— Ну ничек соң,— мин әйтәм,— кызыңның авызын турайттыңмы?

— Юк-ук шу-ул,— ди Әхсән, хәйләкәр генә елмаеп.— Киресенчә, Кыек авызны син озаттың ич! Син кайтып барганда, мин Зөбәрҗәт белән утыра идем ләбаса! Танымадыңмыни?..

Кемнең-кем икәнлеген танырлык идеммени мин ул чакта, башым Чүмеч йолдызга тигән иде бит! Мәгәр Әхсәннең, авызын ерып, Кыек авызны син озаттың ич, дип көлеп торуы, минминлегемә кагылды. Мин шундук, эт кебек ырылдап, Әхсәннең бугазына ябыштым.

— Мин сине Хәмзә егетләреннән аралап калдым, дус итеп,— мин әйтәм.— Ә син, Кыек авыз минеке, дип, мине алдагансың, киресенчә, Кыек авыз артыннан мине җибәреп, үзең исә Зөбәрҗәт янында басып калгансың, хаин!

Әхсән мине читкә тибәрергә теләде, тормакчы булды. Мәгәр мин бирешмәдем. Озын буй әле ул көчле булу дигән сүз түгел шул!

— Туктап тор әле, Идеал, кызма шулхәтле! — диде Әхсән,

ниһаять, минем ихтыярыма бирелеп.— Син үзең ич, кызлар тарала башлагач, әйтми-нитми генә минем яннан каядыр китеп бардың. Аннары яныма Зөбәрҗәт килеп басты, синңе сорады, ә мин ни әйтергә дә белмәдем. Аптыраганнан гына, хәзер килә ул, дидем. Шуннан соң без сине көтеп, теге гранит таш өстендә сөйләшеп утырдык. Ә син... чалыш авызны озатып йөргәнсең икән ул чакта! Син үзең... дуслыгыбызга төкергәнсең икән, хаин!

Әхсән мине гүя телсез калдырды. Мин, чарасызлыктан йомшарып, урыныма барып аудым. Әйтәм аны үбешкәндә авызымны кыегайтып, суырып алды. Шул булган икән, Кыек авыз булган икән минем белән үбешүче, ә мин аны... Зөбәрҗәт дип...

Мин, кимсенеп, хурланып, үз-үземне ботарлап ташлардай булып, яттым да яттым. Әй котыртырлар инде мине, әй мыскыл итәрләр, күземне дә ачтырмаслар Хәмзә авылының яшь-җилкенчәкләре...

Дөрестән дә шулай булып чыкты, һәм мин бу тарафтан китеп югалырга дигән карарга килдем...

## Фәрхия апа

Мин ул елны Пановка дигән чиркәүле авылда, унберенче сыйныфта укый идем. Билгеле инде, исәбем отличнога уку. Мәгәр, бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, биология һәм химия укытучысы Тәгъзимә апаны беренче дәресләреннән үк ошатмады минем сыйныфташларым: бигрәк тә кызлар! Чынлап та, Тәгъзимә апа дәресләрен күңел биреп үткәрми, сүлпән һәм ялкау иде. Мондый укытучының булуыннан булмавы артыграк ич. Ә безгә белекле, чая, үткен, ягъни, чын мәгънәсендә, югары класслы укытучының булуы шарт. Шунсыз һич мөмкин түгел. Ансыз, безнең карашыбызча, киләсе елга институт яки университетка кергәндә, биологиядән һәм химиядән сынауларны уңышлы тапшыра алмаячакбыз. Димәк, мондый күңелсезлекләргә тарымас өчен, безгә үз язмышыбызны алдан билгеләп куярга, ягъни директордан бүтән укытучы китертүен сорарга, һәм без шулай эшләдек тә. Мәгәр директор (өйләнмәгән егет кеше) безнең ялкынлы сүзебезне ошатмады; сары кашларын җыерып, кызыл йөзен чытып тыңлап торды-торды да:

— Тәгъзимә апагыз югары белемле. Ул үз фәннәрен яхшы белә. һәм сезне укытырга нинди укытучы кирәклеген роно хәл итә. Әйе, әлегә ул сезгә ят, ләкин бу вакытлыча гына. Тора-

бара сез бер-берегезгәияләнерсез, күнегерсез: барысы да ал да гөл булыр,— диде, безне юатып. Без әле ул чакта Тәгъзимә апаның директорга туган тиешле кеше икәнлеген белми идек.

Юк, теләсә ни әйтсеннәр, Тәгъзимә^ апа ошамый иде безгә һәм киләчәктә ошарга мөмкин булуы да икеле. Шуннан соң яшьлек кайнарлыгы белән үзара киңәш-табыш итештек тә, Тәгъзимә апа дәрескә керер алдыннан гына, классыбыз белән урамга чыгып киттек. Бу идеяне классташларыма мин тәкъдим иткән идем. Кем белгән бит аны ул чакта яхшы ният1дн чыгып әйтелгән сүзнең тора-бара үз башыма тукмак булып төшәсен...

Әйе, без барыбыз да, тавыш-тынсыз гына (директор бүлмәсе классыбыз янәшәсендә генә, ишетүе бар), дәрес ташлап чыгып киттек. Сүзебез үтмәгән иде, инде кылган гамәлебезгә карап хәл итсеннәр, ягъни яңа укытучы китертсеннәр: теләгебез.шул! Шул теләгебездән һичкайчан кире кайтмаячакбыз һәм алга куйган максатыбыздан бер адым да артка чигенмәячәкбез: хет атсыннар, хет ассыннар, хет тереләй тунасыннар... Ахыр чиктә без иректе илдә туган кешеләрнең балаларымы, әллә...

Ниһаять, аңладылар булса кирәк. Тәгъзимә апа тиз генә җыенган да сигез чакрымдагы авылына кайтып киткән. Озаклламый класс җитәкчебез безгә керергә кушты. Ул мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта иде. Нинди усал һәм гаярь ханым булып, ул да бу юлы безгә тузынмыйча, җикеренмичә генә, җайлап кына аңлатты:

— Тәгъзимә апагыз... китте инде. Хәзер үк артыннан барып ялынып, ялварып сорасагыз да, бүтән ул сезне укытырга сүтмәячәк. Димәк, алга таба сезнең класста химия һәм биология дәресләре булмаячак, чөнки сезгә ярардай укытучы әлегә юк, шулай булгач, бүгеннән башлап биология урынына — мин, ә химия урынына Заһир (директор) абыегыз керәчәк.

Чынлап та, икенче дәрес химия булырга тиеш иде, ә химия — юк*!* Аның урынына Заһир абый керде. Заһир абый безгә тарих белән җәмгыять белеме укыта иде. Заһир абый, кереп утыруга ук, мине такта янына чыгарып бастырды. Үземә калса, мин тарихны су урынына эчә идем. Ә менә җәмгыять белеме... авыр иде аны үзләштерүе. Әгәр монда язылганнарга ышансаң, дөнья халыкларының үткәне гел караңгылыктан гына тора һәм бүгенге капиталистик системаның да якты киләчәге юк, ул бетүгә бара һәм тәмам үлемгә дучар булачак, янәсе. Заһир абый моның шулай булырга тиеш икәнлеген шулхәтле ялкынланып сөйли, шундый тырышып, төкерекләрен чәчә-чәчә аңлата иде ки, без, хыялыбыз белән шундук коммунизмга күчеп, рәхәткә

талып йоклап китә яза идек!

Заһир абый миңа борылды.

— Йә, йә, сөйлә! — диде ул.

Ә мин һич аңлый алмыйм: күрше илләр белән-гомер буе дошманлашып яшәп буламыни? Нигә дус һәм тату гына, кунакларга йөрешеп кенә яшәмәскә ди? Капиталистик илләрне күздә тотып уйлавым бу минем. Чөнки әбиләремнең икесе дә, элек байлар китапларда язылган шикелле, әшәке, явыз, ерткыч түгел иде, әйбәт иде, безгә һәрвакыт ярдәмнәре тия иде, диләр. Менә шуннан соң бел инде: кемгә ышанырга? Надан әбиләргәме, әллә югары белемле коммунист укытучы-директоргамы?! Әлбәттә, без, комсомоллар, бер карасаң совет заманында басылган китапларга һәм коммунист абзыйлар-апаларга гына, ышанырга тиешле, мәгәр күңел түрендә әбиемнәрнең әйткән сүзләре дә урын алган шул инде.

— Белмисең, димәк, укымагансың: утыр, икеле!

Директор бу сүзләрне шундый зур тантана белән әйтте ки, хәтта йөзенә елмаю кунды. Ул бәхетле иде бу минутта. Ә мин, җир ярылса төшеп китәрдәй булып, хурланып, урыныма барып утырдым. Шуннан башланды инде Заһир абыйның мине талкулары, шуннан китте инде, китте... Бу — декабрь башына чаклы, ягъни химия белән биология укытучысы килгәнче дәвам итте. Ә яңа укытучы — гөлдерәвек тавышлы, зифа буйлы, чибәр генә, яшь кенә кыз иде. Беренче күрүдә үк уңай тәэсир калдырды ул бездә, ә инде химия белән биологиядән өч ай буена үтелмәгән программаны куа башлагач, без, ниһаять, нәкъ үзебез теләгән укытучыга тап булуыбызга инандык. Фәрхия апа (яңа укытучыбызның исеме шулай) үзенең бер үк вакытта гади дә, ачык та, нечкә күңелле дә, шулай ук таләпчән, нык ихтыярлы һәм үз сүзендә катгый рәвештә тора ала торган принципиаль педагог икәнлеген ике атна үтәр-үтмәс исбатлады, һәм без Фәрхия апаны шул кыска гына вакыт эчендә яратырга өлгердек. Бәлки, безгә Фәрхия ападагы кешелеклелек күбрәк тәэсир иткәндер. Ул бит дәресләрен кат-кат аңлата, төшендерә, алай да үтмәсә, мәктәпкә кичке укуларга да килергә чакыра. Ә бу өстәмә дәресләр өчен — без бик яхшы беләбез — Фәрхия апага бер тиен дә түләмиләр. Шулай да ул безнең тирән белемле булуыбыз өчен җан-фәрманга тырыша, көченкуәтен, вакытын кызганмый, һәм менә шул әйтелгәннәрдән тыш, Фәрхия апаның, янә килеп, әдәбиятны үлеп яратуы миңа аеруча ошый иде. Чөнки мин үзем дә әдәбиятны шашып яратам ич, алай гына да түгел әле, үзем дә шигырьләр язгалыйм. Ә язган шигырьләрем бервакытта да стена газетасында урын ал

мыйча калмыйлар иде. Күрәсең, Фәрхия апа аларны укырга вакыт таба. Ул һәркөнне диярлек мине мактый. Әлбәттә, үземне түгел, ә шигырьләремне һәм шигырьләремнең дә барысын түгел, ә күңеленә тәэсир иткәннәрен, хисләрен кузгатып җибәргәннәрен генә... Кайбер кичләрне Фәрхия апа үзен миннән озатып куюны үтенә иде. «Синең белән күңелле, өйгә кайтып җиткәнне тоймый да калам»,— ди торган иде ул. Шумы сабакташларым, күпертеп, аңа әллә нинди ят мәгънәләр салып, кинаяләп, уңлы-суллы чәчәргә тотынды. Бу сүзләрне ишеткәч, директор Заһир абый көнчелегеннән күкле-зәңгәрле булган, ди, имеш. Дөрестер, мөгаен. Ул хәзер үз дәресләрендә миңа элеккедән дә ныграк, зәһәрләнебрәк каныгырга кереште. Ләкин инде мин үзгә Варис идем. Чөнки Фәрхия апа миңа җәмгыять белеменең кабыгын ватып биргән иде, аның төшен үземә чәйнәп йотасы гына калган иде. Һәм мин аны бик әйбәтләп чәйнәп, йотып та күрсәттем Заһир абыйга көннәрдән бер көнне. Директор, мескен, өстәмә сорауларына да минем тапкыр гына җавап биреп баруымны сизгәч, аптырап калды: кызарындыбүртенде, шулай да бишле куярга мәҗбүр булды. Бу — минем җиңүем иде. Мәгәр Заһир абый инде хәзер Фәрхия апага ачыктан-ачык бәйләнә, аңа гел үзенең ялгыз булуын аңлата һәм өйләнешергә тәкъдим ясый, имеш. Ә Фәрхия апа директорыбызның мондый кискен һөҗүмнәрен кире какканмы яки кире кагарга үзендә көч таба алганмы — бусы безгә караңгы иде. Мин дә бит Фәрхия апа өчен гади бер укучы гына. Ә Заһир абый, күрәсез, аның начальнигы, өстәвенә өйләнмәгән егет һәм ул Фәрхия апаны сөя дә, әгәр теләсә, аңа рәхәтләнеп өйләнә дә ала. Бу максатына ирешүдә аның юлында бернинди киртәләр дә тормый һәм аңа беркем дә комачаулык итә алмаячак иде, әлбәттә. Шулаен шулай да, тик мин Фәрхия апаны үлеп ярата башладым бит әле, аннан башка киләчәк тормышымны һичничек күз алдына китерә алмыйм. Инде нишләргә? Чү! Тукта, бу четерекле мәсьәләне чишүнең тагын бер юлы бар лабаса, ягъни боларның барысы турында да Фәрхия апаның үзеннән сорап карау лазем түгелме? Шулай ич. Һәм мин тәвәккәлләдем, уңайлы вакыт очрап, сорадым болар турында Фәрхия апаның үзеннән. Ул болай дип җавап бирде: «Мин әле тиз генә кияүгә чыгарга җыенмыйм, Варис... Ә сиңа тырышып укырга кирәк, кырга!» Ул шунда Заһир абыйга карата мөнәсәбәтен белгертеп ник бер сүз әйтсен. Ярый, мин укырмын анысы, унберне тәмамлагач, тагын укырмын, ә Заһир абый бу вакытта нишләр,

янәшәсендәге чибәр туташны кулыннан ычкындырырмы? Шикләнәм. Киләчәктә миңа Фәрхия Фәттаховна белән кавышып гомер сөрү насыйп итмәс, ахры, болар бары сагынып сөйләргә якты бер истәлек кенә булып калырлар сыман.

Мине уйларымнан Фәрхия апа бүлдерде. Яңа ел кичендә утыра идек без чыршы куелган һәм тырышып бизәлгән үзебезнең класста. Өстәлләрдә җаның ни тели, шул бар...

Бермәлне Фәрхия апа миңа: «Минем янга килеп утыр әле, Варис»,— дип дәшмәсенме! Ә Фәрхия апага каршы якта Заһир абый утыра иде. Ул, сөйләшүеннән кинәт туктап, гүя бу эшкә сәерсенеп, усал итеп миңа карап куйды. Шуннан соң минем шигырь сөйләвем сөйләү, ашавым ашау, эчүем эчү булмады. Мине һәрвакыт һәм һәр төштә диярлек Заһир абыйның зәһәр карашы эзәрлекләде. Менә бервакыт мин мәктәп ихатасында үземнең Фәрхия апа белән икәүдән-икәү генә калып басып торуыма төшендем. Минем җиңелчә генә башым әйләнә һәм нигәдер үтереп йокым килә иде. Фәрхия апа миңа: «Көт инде, Варис, хәзер кайтам, мине озатырсың»,— ди. Шул чакны ишек ачылып китте дә яныбызда Заһир абый пәйда булды. Ул: «Әйдә, Фәрхия, анда сине чакыралар»,— дип, укытучы кызны култыклап ук алды. Фәрхия апа исә, гаеп өстендә тотылган шикелле, юашланып, башын түбән иде. Бераздан ул гүя аңына килде, нидер әйтергә теләгән кебек, минем тарафка төбәлде, әмма берни дә әйтә алмады, Заһир абый ихтыярына буйсынды: алар кереп киттеләр, ә мин кайтып киттем.

Тулай торакта беркем дә юк иде. Тиз генә урын җәйдем дә йон юрган эченә кереп чумдым. Берни хакында да уйлыйсым килми, чөнки мәгънәсен күрмим, кызык та тапмыйм мин хәзер: бетте, бар да җимерелде, юкка чыкты... Аһ, нигә болай бәхетсез икән мин?! Шулай җаным кыйналып йоклап киткәнмен. Берзаман: «Тор, хайван!» — дигән тавышка уянып күзләремне ачып җибәрсәм, йа Хода, каршымда директор басып тора, янәшәсендә Фәрхия апа, аннан чак кына арырак минем сабакташларым...

Мин, нәрсә булганына төшенмичә, сораулы карашымны Заһир абыйга төбәдем. Директорның күзләре тонган, тешләре

юылган, ә йодрыклары, сугышырга җыенган калай әтәчнеке кебек, йомарланган иде. Җитмәсә, Фәрхия апа, миңа үпкәләгән ман, читкә карап тора. Ә сыйныфташларым тагын... Чү! Бу уен эш түгел ләбаса, бу — трагедия...

Ниһаять, Заһир абый, минем уянуымны күреп булса кирәк, һшәтле итеп кычкырып җибәрде:

— Кабахәт, аһ, кабахәт! Шакшы җан! — Ул, ясканып, минем тәге юрганны сыдырып алды.— Тор, җавап бир иптәшләрең
ршында: ишекне ник ачмадың? Алар әнә, өч сәгатькә якын суыкта басып торып, тәмам өшеп, туңып беттеләр инде... Ә син арны кертмичә, Алланың кашка тәкәсе кебек, җылыда, юрган тында мышнап йоклап яткансың! Өстәвенә Фәрхия апаң, ул малай үз-үзенә кул салмадымы икән, дип, елый-елый шешенеп бетте... Әйе, салыр ул үз-үзенә кул, салган ди берәүләр анда, тот капчыгыңны!

Мин куркып киттем. Чынлап та өч сәгать вакыт үтте микәнни? Мин бит күзләремне генә йомган кебек идем! Аннары гомеремдә дә болай каты итеп йоклаганым юк иде бит минем, шылт иткән тавышка да уянып китә торган идем ләбаса! Ә монда, иптәшләрем һәм яраткан укытучы апам каршында, директор, сүгенәсүгенә, Себергә олактырырлык сүзләр сөйләп то- ра ич! Димәк, директорның: «Аптырагач, тәрәзәнең зур пыяла-сын алып, Хәйдәрне эчкә керттек: ул безгә ишекне ачты»,— дигән сүзләре дә хак. Димәк, минем гаеп сүгеп кенә бетерерлек түгел! Инде хәзер миңа нишләргә? Бу бәладән ничек котылыр-га?.. Күңелем белән шулай дип уйласам да, йөрәгем белән әле һаман бу хәлнең чынлыгына ышанып җитмим. «И-и, Варис, нишәдең соң син? Синең белән мондый хәлнең булганы юк иде **бит** әле!» — дип ачынам, һәм уйлый торгач: «Юк, монда минем гаебем юк! Монда ниндидер бер аңлашылмаган сәер нәрсә булырга тиеш»,— дигән катгый карарга киләм.

Директор, ниһаять:

— Кара, кара, ул әле һаман тормыйча ята,— дип, кызары-нып-бүртенеп акырып җибәрүгә, мин торып утыруымны сизми калдым, әмма аякка ук басмадым, оялдым: мин трусиктан гына ич... Минем торып утыруымны гына көткән диярсең, җиңнәрен сызганып куйган директор минем йөземә сукты. Борынымнан гөрләп кан ага башлады. Әмма бу директорны өркетмәде (хәер, өркерлек булса, ул миңа кул күтәрергә батырчылык имәс тә иде), киресенчә, ярсытып кына җибәрде.

— Кара, кара... оялмыйча, күзләрен челәйтеп, туп-туры ми-карап тора бит әле, кабахәт! — диде ул кабатлап.

Шунда мин иптәшләремнең һәм Фәрхия апаның миңа, бер мескен, мәхлук җанга караган сыман, кызганып карап торула- рын сиздем. Бу хәл мине сискәндерде, йокымсыраулы халәт- тән чыгарды, мин-минлегемне кузгатты. Юк, ялгышасыз! Мин мескен түгел... түгел... һәм мин директорга, чак-чак кына: «Син үзең кабахәт!» — дип кычкырмыйча калдым.

— Кара син аның каравын-н!..— диде директор чыелдап.— Шагыйрь булган, имеш... Күргән инде синең-кебекләрне генә...

Ул янә миңа сугарга дип кулын күтәрде. Шунда мин аның ярыйсы гына исерек икәнлеген чамалап алдым. Әйтерсең хә- зер минем каршыда директор түгел, ә гап-гади бер исерек ба- сып тора. Минем уйларымны ул үзе дә сизде сыман. Ләкин тәҗрибә һәм власть дигәнең тагын бер мәртәбә үзенең көчен күрсәтергә ашыкты:

— Сөрт, идәнне пычратып утырма... әллә кем булып! — дия-дия кычкырынырга тотынды.— Чүпрәк булмаса, чалбарың белән сөрт... шагыйрь булдым дигәч тә!

—Ә сез директор булдым дигәч тә, укучыларга теләсә нәрсә әйтергә, хәтта кул күтәреп сугарга да ярый дип уйладыгызмы?!

— Сине бит туган авылыңнан да кыйнап җибәргәннәр! Ни өчен кыйнаганнарын бик беләм мин, милициядә документ ки-рәк тапсалар, юнәтербез! — дип, минем авызны томалап куй-макчы булды Заһир абый.

Ләкин андый чакта мин дә төшеп калганнардан түгел.

— Әгәр милиция кирәк дип тапса, мин дә берничәне язып бирермен! — дидем.

Заһир абый, инде эшне беткәнгә санап, чыгарга юнәлгән җиреннән шып туктады, кире борылып килде:

— Ә-ә, шулаймы-ы, милициягә язасыңмы?! — диде дә тез ас- тына китереп типте. Тагын типмәкче иде, мин аның аягын тотып алып үземә таба тарттым. Директор бу хәлне көтмәгән иде бул- са кирәк, шундук тигезлеген җуеп, гөрселдәп идәнгә ауды.

Менә хәзер булачак иде тамаша! Шуны аңлаптыр инде, та- тар теле укытучысы белән тәрбияче Мария Васильевна, директорны тынычландырып, тулай торактан алып чыгып,киттеләр. Ә минем беләгемә Фәрхия апа асылынган иде, шуңарга мин дә тиз тынычландым.

Бераздан инде иптәшләрем йокларга ятты, ә мин, Фәрхия апаны фатирына озатып куярга дип, урамга чыктым.

Баягы күңелсез хәлдән соң ничек итеп сүз башларга бел-мичә аптырадым... Пановка йоклый инде. Мәгәр аяк астында кар шыгырдавы кайбер этләрнең кытыгына тия бугай, алар ялкау гына өргәләп куялар.

Ә күктә йолдызлар... Их, Фәрхия апа белән икәү генә шул йолдызларның берәрсенә ашып яшисе иде, сөеп-сөелеп!..

— Син, Варис, миңа үпкәләмә инде, яме! — диде Фәрхия апа, кинәт телгә килеп.

— Нишләп үпкәләргә тиеш әле мин сезгә? — дидем мин.

— Чөнки... синең үлгәндәй йоклап ятуыңа мин гаепле идем бит...

— Кит аннан... сөйләмәгез булмаганны, Фәрхия апа... йә ышандырып куярсыз!

— Әйе, әйе... мин синең чәеңә йокы даруы салган идем, Варис...

Мин шып туктадым. «Ни өчен? Ни сәбәпле?» Күңелем шулай уйлый, ә телем көрмәкләнгән: бер сүз дә әйтә алмыйм һәм алга таба да бара алмыйм, аякларымны гүя богаулап куйдылар!

Фәрхия апа да туктады:

— Юк, мин сиңа әле сөйләп бетермәдем,— диде ул, тиз-тиз генә.— Син, Варис, Заһир абый янәшәсендә утырган таза гына бер егетне күргән идеңме?! Заһир абыйның энесе ул. Боксчы! Заһир абый сиңа күрсәтеп: «Әнә шул егетне акылга утыртырга кирәк, Заһит, — диде.— Тик... бу эшне аулак җирдә, шаһитларсыз гына башкар»,— дип тә өстәде. Шул хәлдән соң мин нишли ала идем, Варис? Үзең уйлап кара! — Фәрхия апа көрсенеп куйды.

Мин дә көрсендем, ләкин эндәшмәдем.

Фәрхия апа сүзен дәвам итте:

— Мин бит сиңа яхшылык, бары тик яхшылык кына теләгән идем, Варис! Әмма... азагы яман булып бетте...

Аңладым мин Фәрхия апаны, һәм минем инде бүтән бу турыда сөйләшәсем килми иде. Шуңа күрә:

— Заһир абыйга кайчан кияүгә чыгасыз? — дидем.

Фәрхия апа, минем мондый сорау бирәсемне көтеп торган сыман, кырт кисеп:

— Баягы тамашадан соң һичкайчан да! — диде.

Аннары, миңа таба авышып, йомшак кына итеп:

— Каникулдан соң сине директор Пановкада тотмас инде, куар, сиңа, укуыңны дәвам итәр өчен, башка мәктәп эзләргә туры килер, бәлки...— диде.

— Ул кумаса да, китәм мин... калмыйм,— дидем мин һаваланып.— Тик... сездән аерылуы гына читен булыр инде миңа, Фәрхия апа!

— Хат язарсың миңа, Варис! — диде Фәрхия апа.

Мин аны аңладым. Без капка төбенә килеп җиткән идек инде. Яраткан укытучым келәгә үрелде...

Мәгәр дөнья, син уйлаганга караганда, бик күпкә катлаулырак шул. Мин кышкы каникулдан соң, Ивановка мәктәбендә укуымны дәвам итәргә керешкәч тә, Фәрхия апага хат язып салган идем, әмма җавап килмәде.

Берничә ел үткәч, мин Фәрхия апаның Заһир абыйның энесе Заһитка кияүгә чыкканын ишеттем.

## *Идеал*

Техникумның өченче курсында укый идем. Мең ярым студентның биш йөзе көндез, биш йөзе төштән, соң, биш йөзе читтән торып белем ала. Без төштән соң укыйбыз. Күренеп тора бит, тулай торакка соң гына кайтыла. Өстәвенә җидешәр, күп очракта сигезәр сәгать тоташтан укытучылар сөйләгән лекцияләрне яза-яза арып-талып, йончып беткән булабыз. Шунлыктан без, кайтуга урын җәеп, койкаларыбызга авабыз. Иртән тагын бер мәшәкать: торып киенергә, юынырга, аш җылытырга, чәй әзерләргә, аннары бүлмәне җыештырырга һәм тәрәзәне ачып, һавасын алыштырырга, аннары, өстәлгә китапларны куеп, конспектларны ачып, алдагы кичтә алган гыйлемнәребезне ныгытырга утырабыз. Ныгытмас идең, дәрестә укытучы сорауларына җавап бирә алмавың мөмкин, җавап бирмәдеңме — икеле, икеле эләктердеңме — стипендияне кисәләр. Ә стипендияне кистерәсе килми. Башкалар әнә тырышкач өстәмә түләү дә алалар әле: син алардан киммени?! Шулай көчәнә-көчәнә, азаплана-азаплана көннәр үтә, айлар үтә; кыш бетә, яз җитә... Сез тагын, һаман укып кына яши икән болар, дип уйламагыз. Юк. Гыйшык тотарга да, мәхәббәт утларында янарга да вакыт кала әле.

Мин — булачак товар белгече — Гөлшат исемле кызны ярата идем. Ә Гөлшат технолог булырга укый иде. Ул да өченче курста, ул да төштән соң укый һәм ул да мине сөя иде. Мәгәр Гөлшатның буй-сыны, чибәрлеге турында шуны гына әйтәм: чәчәк тә чәчәк, ул да чәчәк иде инде менә! Аннары Гөлшатның иптәш кызы — табак битле, кыска буйлы, почык борынлы Ләмига — күңелне үзенә җәлеп итсә дә, сул аягының гариплеге гайрәтне тиз чигерә иде. Күз алдыгызга китерегез: сул аягын тез турысыннан бөгә алмыйча, чалыш-чолыш атлый-

атлый бер кыз бара. Ашыга да алмый әле ул. Чабу турында инде әйткән дә юк! Шул кыз, мин сиңа әйтим (гаҗәп бит!), Гөлшатның аерылмас дустына, сердәшенә әверелгән дә куйган. Кая гына бармасыннар, алар бергә, кайда гына очратмасыннар аларның икесен күрергә була иде. Бер уйлаганда, аларның шагыйранә хәйран матур дуслыгына сокланасы гына да бит, юк, йөрәк дигәнең килешми, Гөлшат янәшәсендә — аның үзе шикелле — камил дәрәҗәдә чибәр кызның булуына өметләнә. Чөнки минем группадашым Идеал төз озын буйлы, капкара кашлы, киң маңгайлы, галәмәт тере егет. Ул чем-кара чәчләрен, майлап, артка тарап йөри. Бу мәгърур кыяфәт аңа бигрәк тә килешә, аны сабыр, җитди, уйчан һәм киң холыклы итеп күрсәтә иде. Әлбәттә, табигый инде, Идеал өчен җанын урталай бүлеп бирергә әзер торган кызлар да бар иде техникумда. Әмма, ни хикмәттер, Идеал үзе кызлар дип аптырамый һәм аның гыйшык-мыйшык тотарга, мәхәббәт утларында дөрләп, ялкынланып янарга вакыты да чамалы гына бугай.

Әйе, Идеал муеннан диярлек җәмәгать эшләренә күмелгән, дөресрәге, аны шулай күмеп ташлаганнар. Ул комсомол секретаре да, студсовет рәисе, профбюро члены, культмасса җитәкчесе дә! Бер карыйсың, Идеал студентларны велосипед ярышына әзерли, икенче текәләсең, ул фото-кино түгәрәге оештырган да яшь фото-кино сөюче студентлар белән мәш килә.

Менә шул данлыклы, булган егетебезгә гашыйк булып куйган бит әле көннәрдән бер көнне безнең гарип Ләмигабыз. Бу турыда миңа берәүдә әйтмәде, билгеле, аны мин үзем сиздем...

Бер якшәмбе кичендә мин Гөлшатлар бүлмәсендә озак утырдым. Сөйгән кызым туган төбәгенә кайтып килгән иде. Тәэсирләре күп. Ул сөйли тәмләп, тасвирлап Арча хәлләрен, мин тыңлыйм! Ләмига исә — матур итеп киенгән — үз эше белән мәшгуль, китап укый: безне тыңлый да, тыңламый да кебек!

Берзаман бүлмәгә, мине эзләп, ахры, Идеал килеп керде. Ләмига инде өстәл янында нидер язып утыра иде, шундук атаклы егеткә урындык тәкъдим итте, вәкарь белән генә, утырырга кушты. Ни хикмәттер, Идеал утырды. Алар да сөйләшеп киттеләр. Дөрес, Идеал кычкырып сөйләмәде бу юлы, аларның сүзләре безгә ишетелмәде, әмма мавыгып, дөньяларын онытып сүзгә керешүләре хак иде. Без бермәл аларга кызыгып та куйдык хәтта. Ә инде үз бүлмәбезгә кайткач, Идеал, Ләмиганың тәрбияле, әйбәт кыз булуы турында шәрехли-шәрехли аңлатып, мине шаккатырды. «Менә сиңа гарип кыз!» — дип, тел шартлатып куйдым мин эчемнән генә. Шулай да әле күз өстендәге кашыбыз Идеалның «Ләмига! Ләмига!» дип, авыз ту

тырып шоколад ашагандай тәмләп сөйләнүенә,— чираттагы бер кызык хәлнең кереш өлеше генәдер бу, дип, көлемсерәп әйттем:

— Ә син аның аякларын күрдеңме соң, иптәш начальник?!

Идеал дустым сүзләрен дә, ике потлы герне күтәреп кенә чөйгәндәй, җиңеллек белән, елмаеп кына әйтте:

— Аның аяклары да шәптер инде түлке!

— Башта күр син аларны, аннары әйтерсең,— дидем мин, җитди генә итеп һәм бүтән бу темага тирән керергә теләмичә.

Икенче көнне безнең бүлмәгә Гөлшат төште. Ә Идеал Ләмига янына менеп китте. Озак торды. Әйләнеп кайткач, ни өчендер минем белән сөйләшмәде, биргән сорауларыма да җавап кайтармады. Ул, сизенүемчә, борчулы һәм сагышлы иде.

Иртәгесен минем янга янә Гөлшат төште. Ә Идеал, кемнедер эзләгәндәй, текәлеп ишеккә карап куйды. Гөлшат, аның ниятен хатын-кыз сизгерлеге белән аңлап булса кирәк, ишеккә таба борылып эндәште:

— Ләмига, кер әйдә, кер!

Озакламый бүлмәбездә Ләмиганың әллә оялудан, әллә шатлыктан кызарган нурлы йөзе пәйда булды.

— Менә монда утыр,— диде Идеал, Ламигага үз янына урын тәкъдим итеп.

Ләмига, утырыр алдыннан, өздереп кенә Идеалга карап куйды: чынлап әйтәсеңме, шаярып кынамы дигән шикелле.

Мәгәр Идеал шаяртмый иде төсле, шаяртырга аның исәбендә дә юк иде сыман. Шуннан соң гына Ләмига, үз дәрәҗәсен белеп кенә һәм, гыйффәтле булуына ишарә иткән кебек, әдәп белән генә, күрсәтелгән урындыкка утырды.

Сүз дә юк, зыялы кыз. Мондый кызлар, гадәттә, төрле юкбар гайбәтләрдән күп өстен торалар; югары зәвыклы һәм үтә нечкә күңелле булалар. Минем Гөлшатыма исә, кайсыбер очракларда, менә шулар җитешми бугай! Ул, әлбәттә, бераз бүтәнчәрәк — җиңелрәк холыклы димме — тиз ярсып, тиз кызып китүчән, шул ук вакытта бик тиз суына да: үпкәчел түгел, ул кешеләргә ачу тотмый, нәфрәт сакламый һәм аның йомшак ягы да шундадыр, бәлки, ул кешеләргә ышана! Әле күптән түгел генә сөйгән кызымның, Идеални мактый-мактый һәм аның тора-бара зур-зур дәрәҗәләргә ирешәчәге хакында төрлечә гөман кыла-кыла тәфсилләп сөйләнеп маташуы кытыгыма тигән иде инде бер. Тик Идеал дустымның гына Гөлшат хакында ни мактап, ни яманлап сөйләнмәве тынычландырган иде үземне.

Әйе шул, Идеал минем дөньядагы иң гуманлы сердәшчем, фикердәшем, ә Гөлшат — сөйгән кызым! Шулай булгач, мин алар-

дан шикләнергә тиешме?

Мин шуларны уйлап, кичереп бетергәч, күпкә җиңеләеп һәм чак кына шаянлана төшеп Идеалга эндәштем:

— Ләмига, ди-ди төнозын борсаланып чыккан идең, менә инде... үзе дә килде яныңа.

Гөлшат та түзмәде, ачылып китеп:

— Ләмиганың «Идеал!» ди-ди уфылдауларын күрсәгез әле сез...— дип, әллә иптәш кызына, әллә минем иптәш егетемә төрттереп куйды.

Тегеләр шундук бер-берсенә караштылар да, янә бер-берсеннән читкә, әллә кая төбәлеп, кып-кызыл булып кызарыштылар.

Мәгъшукларны бүтән кызартмыйсы иде бит, дип уйладык без һәм башка темага керешеп киттек.

Менә шулай башланды безнең бүлмәләрдә сөйләшә-сөйләшә, парлашып урамга аяк басулар, аннары инде, кино-театрларга сукмак салып, җилкенә-җилкенә күңел ачып йөрүләр!

Мәгәр дөньяда һәр яманның яхшысы, һәр яхшының яманы була дигәндәй, безнең дә бу матур дуслыгыбызның азагы ямьсез булып бетәр дип башыбызга да китереп карамаган идек ул вакытта, киресенчә, без дүртебез дә киләчәктә бәхетле булачагыбызга ышандык, тормыш күгебездә, елмаеп-көлеп, кояш балкып торачагына инандык. Ә бу безгә шактый гына кыйммәткә төште...

Әйе, бүгенгедәй хәтеремдә, февраль урталары иде. Якшәмбе киче. Без чираттагы кинога барырга чыктык, дүртәү! Күңелләр көр, кәефләр күтәренке иде. Идеал кинәт безгә шундый уен тәкъдим итте. Әйтик, мин Идеалның, ә Идеал минем, аннары мин Гөлшатның, ә Идеал Ләмиганың уй-фикерләрен алдан ук чамалап әйтеп бирә ала ди; ә менә мин Ләмиганың, Идеал исә Гөлшатның уй-фикерләрен алдан ук чамалап әйтеп бирә аламы? Кызык идея иде бу безнең өчен. һәм без тәвәккәлләдек!

Мин Ләмига белән артта калдым, ә Идеал Гөлшат белән алдан китте. Озакламый алар нәрсә турындадыр кызып-кызып, бәхәсләшә-бәхәсләшә бара торгач, мавыгып китеп, безне онымтып җибәрделәр бугай, һәм минем бу хәлгә эчем поша, ачуым килә башлады. Чөнки минем Ләмига белән борчагым пешми генә бит: мин дәшмим, ул эндәшми, мин эндәшмим... Ә үземнең күзләр тегеләрдә генә! Ләмиганың күзләре дә...

Ниһаять, Ләмига түзмәде, чалыш-чолыш атлаган җиреннән үзәкләрне өзәрлек дәрәҗәдә моңсу гына итеп:

— И-и,ниләр сөйләшә икән тегеләр, белсәң иде шуны! — дип куйды.

Мин исә, эчемә корт төшкәнне сиздермәскә тырышып:

— Идеал сиңа ниләр сөйли иде соң, Гөлшатка да шуларны сөйлидер инде,— дидем, уенын-чынын бергә кушып.

— Бигрәк инде син...— диде Ләмига, мине битәрләп.— Миңа сөйләгән сүзләрнеме? Гөлшаткамы? Юк, алай була алмый ул! Алай булса ул аннары нәрсә була, беләсеңме?

— Беләм, мәхәббәт була! — дидем мин.

— Кит, авызыңнан җил алгыры... Тфү-тфү, диген!

Мин үзем дә бу эшнең, кем әйткәндәй, хәвеф-хәтәрсез генә төгәлләнүен тели идем, әлбәттә, һәм Ламигадан битәр үзем өчен:

— Тфү-тфү, әйттем исә кайттым! — дип куйдым.

Озакламый без клубта, залда, дүртебез бергә кабат очраштык. Ә кайтканда инде Идеал Ләмигасы белән артта калды.

Гөлшат миңа көтмәгәндә генә:

— Гаҗәп тә кызык кеше икән ул Идеал, ничек моңарчы белмәгәнмен,— дип ташламасынмы.

— Миннән дә кызыкмыни? — дидем мин, коры гына итеп.

— Икегез дә кызык инде, тамаша...— диде Гөлшат һәм нигәдер тыенкы гына көлеп куйды.

— Нигә көлгән буласың инде? — дидем мин, сөйгән кызымны чынлап торып ачулана-ачулана.

Мәгәр Гөлшатның минем белән ачуланышып кәефен бик кырасы килми иде бугай. Ул, йомшак кына итеп, миңа сорау бирде:

— Ләмига белән ниләр сөйләштең соң, Гафур?

— Ә син... Идеал белән ниләр сөйләштең соң?!

— Сез ниләр сөйләшсәгез, без дә шуларны ук сөйләштек!

— Без, ай-һай, ерак китте болар, дидек.

— Ә без, ай-һай, артта калды болар, дидек.

— Сез бит көлештегез!

— Ә сез еладыгызмыни?

Мин дәшмәдем.

Шул чакны безнең арттан килгән Ләмиганың кычкырып көлгәне ишетелде. Гөлшат, ялт итеп, шул тарафка карап куйды.

Әйе, Идеал көлдерә белә кызларны, хәерсез, әфсене бардыр аның, валлаһи менә! Ә миннән булмый, юк!

Әһә, менә кайтып та җиттек. Кызларны бүлмәләренә тикле озаттык та, әйләнгечтән, аралыкның, теге ягындагы баскычтан икенче катка төшеп, үз бүлмәбезгә кердек. Әйбәтләп ашадык-эчтек тә, Идеал койкасына сузылды, ә мин дәресләр әзерләргә утырдым...

Мин китаптан башымны күтәреп караганда, инде Идеал борынын сызгырта-сызгырта йоклый иде. Аңа рәхәт. Ул иртәгесен күрше җөмһүрияткә чаңгы ярышларында катнашырга китәчәк!

һәм Идеал китте. Хәер, Идеал китте дип кенә, техникум урыныннан күчмәде, әлбәттә. Тормыш үз җае белән дәвам итә бирде. Гөлшатта да үзгәреш сизелми иде. Тик Ләмига гына... Ай, авыр кичерде ул сөйгәненең янәшәсендә булмавын! Җитмәсә, хат та килми үзеннән! Әллә вакыты кысанмы, әллә, сагынсын әле мине Ләмига, көтә-көтә зарыгып бетсен, дип уйлыймы? Ни генә булмасын, Ләмига өчен бер атна вакыт нәкъ бер ел шикелле озакка сузылса да, ул үтте!

Менә Идеал кайтып күренде берзаман... Ябыккан, җиңелчәләнгән; йөзе кара туткылланган, ә күзләре... ут та ут, алар да ут! Мәгәр Идеал чаңгы Ярышларыннан зур уңышларга ирешеп, көмеш һәм бронза медальләргә ия булып кайтса да, бик әллә ни сөенергә ашыкмады. «Дәресләрем күп калды, дәресләрем...» — дип офтанды. Чынлап та, бер атна эчендә без дүрт йөз бит чамасы конспект язып ташлаган идек. Хәзер Идеалга ашыгычлык белән шул дүрт йөз битне безнең конспектлардан күчереп алырга кирәк инде. Дүрт йөз бит! Хәер, дүшәмбе көнне кич техникумнан кайткач, Идеал, конспектлар өстенә иелеп, аптырап, борынын салындырып озак утырмады, гадәттәгечә, шыпырт кына торып, сабыр гына итеп әйтте:

— Иртәгә тулай торагыбызның икенче катында мин дежурный икән, Идеал, ә өченче катта синең Гөлшатың дежурный... Берара кухнядагы чүп-чарларны түгеп, коридорларны юып, җыештырып, тәртип урнаштырып бетергәч, миңа конспектлар күчерергә булышсын әле Гөлшатың, тыңлат әле син аны, Идеал, малай, үтенеп сорыйм, бик үтенеп!

— Ярар, кайгырма, нәчәлник, иртәгә әйтермен Гөлшатка,— дидем мин. һәм үзем дә, чишенеп, йокларга яттым.

Иртәгесен дустымның гозерен, минуты-сәгате белән, Гөлшатка җиткердем. Гаҗәп, сөйгән кызым рәхәтләнеп риза булды...

Кичен техникумнан кайткач, мин аларның йөзәр бит конспект күчерергә өлгерүләрен белдем. Әйбәт! Тагын бер ыргым һәм Идеал безне куып җитәчәк... Ләкин, баксаң, Гөлшатка бу юлы нидер булган сыман: минем белән теләр-теләмәс кенә сөйләшә; сорауларыма әйле-шәйле генә җавап кайтара һәм таләпчән карашым белән дә очрашмаска тырыша, күзләрен гел читкә ала, түбән яшерә иде, үзе оялган сыман. Ахырда ул түзмәде, авыр сулап, офтанып:

— Ай, арыдым бүген, эт булдым, башым да авырта,— дип

куйды, һәм аннары, башына яулык бәйләп, юрганы эченә кереп ятты.

Минем көтмәгәндә генә йөрәгем жу итеп китте. Ләмига да, нидер сизенеп, югалып калган кебек иде. Әмма мондый тиктомалдан гына хәвефкә тару һәм эч поша башлауның сәбәпләрен миңа да, аңа да анык кына белергә мөмкин түгел иде әле.

Иртәгесен, мин йокыдан торгач, Идеал башын да калкытып карамады хәтта. Бу хәл мине ярсытып җибәрә язды. Ләкин мин, үземне кулга алып, тынычланырга теләп, озаклап юындым, аннары ашадым-эчтем, ә Идеал (хөрәсән!) һаман йоклавын белде. Ул тик сәгать унбер тулганда гына уянды: торды, юынды, ашарга утырды, ә мин, авылдан хат-фәлән килмәдеме икән дип, түбәнгә, почта әрҗәсен тикшереп карарга төшеп киттем. Анда Ләмиганы очраттым. Харап! Гөлшат та.яңарак кына торган, әйтерсең шулай эшләргә сүз берләшеп куйганнар?

— И-и, аларның тагын йөзәр бит конспект күчерәселәре бар ич,— дип көлеп маташкан була әле Ләмига.

— Ярый инде шул йөзәр бит конспектны күчереп бетергәндә генә җан тәслим кылмасалар?! — дип, мин дә елмайгандай иттем.

Аннары Ләмига туганнарына юл тотты, шуннан техникумга барам, ди, ә мин бүлмәбезгә!

Идеал конспект күчереп утыра иде, миңа ялт кына күтәрелеп карады да янә язуын дәвам итте.

Мин ашыга-кабалана Гөлшат янына күтәрелдем. Ул да конспект күчереп утыра иде. Ул да миңа ялт кына карап алды һәм... Ләкин ул язуын дәвам итә алмады, каушады булса кирәк; йөзе алсу, ә күзләре моңсу һәм сагышлы иде аның. Башына кичә кич бәйләгән яулыгын да алып ташламаган.

— Миндә температура,— диде сөйгән кызым, ниһаять, әкренрәк тавыш белән, уч төбенә көчәнеп кенә йөткеренгәләп,— бүген дә укырга бара алмам, ахры. Грипп!

— Справка бирделәрме соң?

— Ләмига фельдшерны чакырган иде, хәзер менәргә тиеш...

Мин Гөлшат янәшәсендәге урындыкка утырдым һәм, күңелем нечкәреп китеп, шундук аны, нечкә биленнән кочаклап, үзеүземә таба тарттым. Мәгәр сөйгән кызым минем кочагымнан җитез генә ычкынып торып басты:

— Шаярма инде, Идеал! Микробларым иярер, җә авырырсың! — диде.

Нәкъ шул минутта шактый кыю гына итеп ишек шакыдылар.

— Әйе, керегез! — дип эндәште сөйгән кызым.

Менә бүлмәдә кап-кара бөдрә чәчле фельдшер ханым пәйда булды. Ә мин, куганнарын да көтмәстән, чыгып тайдым.

Идеал бүлмәдә юк иде. Техникумга китте микәнни? Һәм мин дә, җыенып, техникумга юл тоттым. Ләкин Идеал биредә күренмәде, килмәде... Озын тәнәфестә, буфетта Ләмигага тап булдым. Ул бигрәк тә борчыла Идеалның укырга килмәвенә.

— Ни булды икән аңа, Гафур? — дип, миңа текәлгән.

— Конспект күчереп ята торгандыр инде,— мин әйтәм.

— Әйе, Гөлшат белән! — ди Ләмига.

Кызның кинаяле бу сүзләреннән соң, минем тәмам җан тынычлыгым югалды. Көч-хәл белән финкредитны үткәреп җибәрдем дә, сәүдә эстетикасы белән фәнни атеизмнан, эчем авырта, дип, тулай торакка сыпырттым. Ачкычны вахтер түтәйгә калдырып киткән идем, хәзер алырмын инде аны. Аннары? Уйларымны никтер алга таба дәвам итәргә куркам. Менә соңгы адым да үтелде. Менә ишек. Эчкә үтәм.

— Миңа ачкычымны гына бирегез, зинһар!

— Кайсы бүлмәдән сез?

— Егерме ике.

— Ул бүлмәнең ачкычы миндә юк, алганнар аны.

— Кем алган?

— Иптәшегез бугай, кем әле ул?

— Идеал!

— Әйе-әйе, Идеа-ал...

Мин баскычтан йөгерә-чаба икенче катка менеп китәм. Менә ул мин яши торган егерме икенче бүлмә! Төртәм — ачылмый, шакыйм — ачмыйлар... Аннары мин үзебезнең каттагы дежур кызга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булам.

— Сезгә ачкыч бирмәделәрме?

— Бирделәр! Ә сезгә кайсы бүлмәнеке кирәк? .

— Егерме икенче... китерегез тизрәк!

— Да, вспомнила, от той комнаты ключ, оказывается, как раз нам не давали,— ди татар кызы, кинәт урысчага күчеп.

Мин «тфү!» дип төкерәм дә ук кебек коридорга атылам. Чү! Болай таба, әвеш-тәвеш атлап, Ләмига килә түгелме соң?! Әйе ич... Менә ул якынлаша, килеп каршыга ук баса һәм, зур коңгырт күзләре белән ялварган кебек итеп, миңа төбәлә.

— Ачмыйлармы әллә?

— Ачарлар иде дә, эчтә кеше юк! — дидем миң, үз-үземә нык ышанып.

— Эчтә кеше бар бугай,— диде Ләмига һәм, колагын ишеккә куеп, тыңланып тора башлады.— Әйе, бар! — дип өстәде ул ераздан. Аннары ишекне үзенә таба тартып һәм эчкә этеп арады да, иелеп йозакны тикшерергә кереште. — Әйтәм бит... —

дип пышылдады ул, катгый бер карарга килеп.— Әнә йозак бикле түгел...

— Чынлап та! — дидем мин, нәфрәтләнеп һәм кинәт артка чиктем дә уң аяк белән бар куәтемә ишеккә типтем, һәм... тотка белән бик элмәгенә тоташтырып куелган табаның чуен ыстыргычы шартлап уртага сынып, ишек ачылып китмәсенме!..

Элек мин кердем бүлмәгә, аннары — Ләмига! Иа Ходаа... төшме соң бу?! Өнме?! Тегеләр койкага берничә матрас салганнар да, дөньяларын онытып, тирләп-пешеп «конспект күчереп» яталар!!!

Ниһаять, безнең кемнәр икәнлегебезне шәйләделәр булса кирәк, торып утырдылар, тын гына киенә башладылар. Йөзләендә, күзләрендә каушап калу сыман бернәрсә бар, мәгәр эшләгән эшләреннән үкенү дигәне юк!

Гөлшат, өстәлдә таралышып яткан китап-дәфтәрләрен җыйнап, хәзер барыбер инде миңа, сер чишелде дигәндәй, башын эрур гына тотып, әллә кая карап, чыгуга таба кузгалды. Хәер, горурлык дигәнең миндә дә бар ул. Шуңарга күрә мин Гөлшатка акырмадым, җикермәдем; үземне түбәнсетмәдем, кечерәйтмәдем: буласы булган ич, кем әйткәндәй, буасы буылган бит инде кызның! Ә ул буаны буучы егет, билгеле шәхес, мәкерле адәм, иң якын дустына астыртын гына кабер казып яткан бәндә, минем курсташым һәм бүлмәдәшем Идеал!

Идеал эт шикелле сизгер дә әле; минем күңелемдә барган көрәшнең иң кискен җирендә генә, каты итеп, Гөлшатка эндәште:

— Тукта! Ашыкма...

Гөлшат туктады. Идеал аны тупас рәвештә кочаклап алды һәм дорфа тавыш белән:

— Менә шулай... без кавыштык инде... иртәгә... язылышырга барабыз! — диде.

Аһ Ходаемм! Әллә Идеалны тотып тәрәзәдән ыргытыргамы? Әллә Гөлшатны, мине алдап йөргән өчен, эт итеп кыйнап ташларгамы? Әллә?! Юк, кирәкми, ярамый, биредә... яшьлегемнең төрмә белән очлануы мөмкин! Иң әйбәте — урамга, кешеләр янына чыгып китү, минемчә.

Минем уйга талып, икеләнеп калуым Идеалны тагын да ныграк батырайтып җибәрде, ахры, ул, ниһаять, оятсызларча:

— Ник котламыйсьң Бульдог (минем яңа кушаматым),— дип, күрешергә кулын сузды миңа.

— Хаин, Тузик (аның кушаматы),— дидем мин, нәфрәтемнән дерелдәп-калтыранып.

Сатлык җанның кулы бушлыкта асылынып калды.

Шул чакны Ләмига горур тавыш белән:

— Һинд киносына ике билет алган идем, әйдә киттек, Гафур — акыллым,— дип эндәште миңа.

Мин Гөлшатка карадым. Ул миңа таба җилкәсе белән борылып басып тора иде инде.

— Әйдә суң, киттек! — дип, мин Ләмига артыннан кузгалдым.

Кино искиткеч кызык иде. Кызганыч иде. Ләмига елады. Мин дә еладым. Әйе, бәхете баштан тулып ашканда да еларга мөмкин кеше, һәм, киресенчә, таудай кайгы-хәсрәт кичереп тә еламаска була! Мәгәр без еладык һәм безнең тирә-юнебездә утыручы кешеләрнең дә күбесе елады. Их, Идеал белән Гөлшатны да шушында китереп елатасы иде бер! Ләкин шикләнәм. Як-якта елашып утыручы кешеләрдән алар көләрләр сыман тоелды миңа...

Ниһаять, без урамга аяк бастык. Җил! Кала өстендә берәмсәрәм генә йолдызлар җемелдәшә. Ләмига, күзендәге яшьләрен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә:

— Мин бүтән чибәр ир-егетләргә ышанмыйм, Гафур! — диде.

— Мин дә! — дидем мин, Гөлшатны һәм аның кебек чибәр, алдакчы унлаган, йөзләгән хатын-кызны күз уңында тотып.

Ләмига кинәт туктады. Мин дә туктап калдым.

— Әйдә, Гафур, икәү чын дус булып яшик әле,— диде гарип кыз.— Техникумны тәмамлагач та хатлар язышып торыйк берберебезгә, яме!

— Син әйткәнчә булыр, Ләмига! — дидем мин һәм бик теләп кызның бәләкәй, йомшак кулын учыма алып кыстым...

***

Миңа бу хикәятне күп еллар элек, Мәскәүдән поездда кайтканда, купедашым сөйләгән иде. Сөйләделәр, сөйләп күңелләрен бушаттылар, ә мин... уйга калдым! Һәм менә көннәрдән бер көнне минем дә бу хәлләр турында кемнәргәдер сөйлисем һәм бушанасым килеп куйды. Менә мин аны, хөрмәтле укучым, сезгә сөйләп бирергә дип, кулга каләм алып яздым да!

## *Тормыш чәчәкләре*

Ул көнне Җәүдәт Закирович болында чәчәкләр җыйды. Балачактан таныш булган урыннарда йөрде. Хәмидулла чишмәсеннән салкын су эчте, аннары куаклыкта нindiдер кошның өздереп-өздереп сайравын тыңларга кереште.

«Сандугач!» — дип уйлады. Янә узган гомер юлын кичереп утырды, хатыны Асия белән яңа туган улы Зөфәрне күз алдына бастырып, урыныннан калыкты.

— Ярый, кошчык, сау бул, миңа кайтырга вакыт. Озакламый янына өчәүләшеп килербез әле.

Мәгәр кошчык алай тиз генә аерылышырга теләмәде кебек, якындагы куакка күчеп, өр-яңадан сайрап җибәрде.

— Җә, сайра инде, алайса, сайра!

Җәүдәт хисләнеп болын юлыннан атлаганда, каршыга буровой машинасының килгәне күренде. Кабинага икенче вахта буровигы Гариф утырган иде.

— Ни булды?

— Авария!..— дип кычкырды Гариф.

Җәүдәт кабинага керде. Өйләре яныннан үткәндә, ул шоферга туктарга кушты. Үзе сайлап, яратып җыйган чәчәкләрне хатынына калдырып чыкты.

Ә кичен, көтмәгәндә шланга ярылып, Җәүдәт Закировичның күзләренә нефть бәрде.

***

— Асия, Асия!

— Әү, җаным, мин монда...

Хатынының иркә тавышы Җәүдәтне сискәндереп җибәрде. Ул аны күрергә теләп, күзендәге бәйләвечне ярсып-ярсып сүтәргә кереште.

— Нишлисең? Ярамый, акылыңа кил! — дип, Асия Җәүдәтнең кулына ябышты.

— Кит-кит... кит-кит...— дип илерде ир.— Соң мәртәбә булса да, кояшның якты нурын күреп калыймчы.

— Җәүдәт, бәгырем, тыңла-а!

Мәгәр Җәүдәт тыңламады. Бәйләвечен сүтеп атты да, башын як-якка йөртеп маташканнан соң, ниһаять, төшенке, хәлсез тавыш белән:

— Мин кайда соң? — дип сорады, җавап биргәнне дә көтмәстән, торырга азаплана башлады.

— Җәүдәт, акыллым, нишләвең инде бу?!

— Авария! А-а, яна дөнья...

Җәүдәт Закирович, шабыр тиргә батып, мендәренә ауды, бераздан гырылдап йокыга китте. Ләкин йокысы тынычсыз иде:

ыңгырашты, тешләрен шыкырдатты; аның төшенә тагын авария керде, ул янә упкынга очты.

Җәүдәт Закирович, шулай бер саташып, бер аңына килеп, ничәдер көн ятканнан соң, күзләренең бүтән һичкайчан да яктылыкны күрмәс булуына төшенде, һәм ул, узган утыз ел гомерен уйлап, сагышларга батты. Киләчәге юк бит инде аның хәзер! Ике күзе дә дөм сукыр кеше нәрсәгә ярасын ди? Кемгә хаҗәт ул?..

Ике айга якын Бөгелмә хастаханәсендә ятканнан соң, очкыч белән Казанга китергәндә, Җәүдәт әле үзенә Герой исеме бирелүен дә белми иде.

***

«Юк, тормышны яратудан туеп буламыни соң?! Сукыр булып калу әле ул тормыштан бөтенләй ваз кичү дигән сүз түгел ләбаса! Ул хәзер элекке эшендә эшли алмый икән, нигә соң үзен башка бер хезмәттә сынап карамаска? Әйтик...»

Җәүдәт Закирович, хыялы белән мавыгып, янына килеп басучы кешене сизми дә калды.

— Моңаябызмы?

Доктор Сабир Исхакович тавышы иде бу.

— Әйе, менә тыңлаган булабыз шунда,— дидеҖәүдәт, кошлар тавышы килгән якка, бакчага таба йөзен борып.

— Шәп сайрыйлар! — диде Сабир Исхакович.— Аларны тыңлагач, мин концлагерьларда һәлак булган ватандашларымны искә төшерәм.

— Сез... анда булдыгызмы әллә?

— Өч елга якын газап чиктем. Әле дә йөрәгемнән чыкмый. Бер әсир, сукырайгач: «Их, Сабир энем! Әгәр дә исән калсам, ничек яшәргә кирәген белер идем!» — дип, үксеп-үксеп елаган иде.

— Исән калдымы соң, доктор?

— Кая инде, сукыр икәнен белгәч тә, немецлар бөтенебез каршына бастырып аттылар.

Җәүдәт канатканчы иренен тешләде.

— Ярый, дустым...— дип, Сабир Исхакович дәвам итте: — Тик шуны онытма: күзләреңне алдырмый торып, сау-сәламәт булмаячаксың!

— Бәлки... болай гына үтәр, Сабир Исхакович?

— Юк, кадерлем, күзләрендә гангрена. Ә гангренадан без бары тик скальпель белән генә дәвалый алабыз,— диде док-

тор һәм өстәп куйды: — Ә син батыр бул, курыкма! Островский әйткәнчә: «Тормыш ул кешегә бер генә бирелә...»

— Аңлыйм, Сабир Исхакович, тик... күзләрем күрмәсәләр дә, урыннарында калуларын теләгән идем бит мин!

— Ә безнең теләк, Герой... сине исән-сау терелтеп чыгару. Шулай булгач, тагын-тагын уйла, телефоннан хатының белән дә киңәшеп ал! — дип, доктор китеп барды.

***

Операциягә керәсе көнне иртән Җәүдәтне телефонга дәштеләр.

Трубкада хатынының йомшак, иркә тавышын ишетеп, ул чак-чак кына уңайсызланып китте.

— Хәлең ничек, Җәүдәт? Үзеңне сагынып та беттем инде. Бала булмаса, яныңа килеп тә чыккан булыр идем.

— Үзегезнең хәлләр ничек соң?

— Ярыйсы гына...

— Нык бул, Асия! — диде Җәүдәт, ниһаять.— Бирешмә, бәгырем! Бүген минем күзләремне алалар, шунсыз яшәү юк.

Асия көттеребрәк җавап бирде.

— Нишлисең инде: язмыштан узмыш юк, диләр бит.— Аннары ул моңлы итеп җырлап җибәрде:

**Тәрәзә төбем исле гөл,**
**Иснә, дустым, исле ул.**
**Уртасында бер чәчәк бар,**
**Өзмим, синең төсле ул.**

Җыр көчле булып, телефон трубкасына гына сыя алмыйча, тирә-юньгә ишетелә иде.

Янәшәдә генә бер апа сулкылдап куйды:

— Әй, бәгырькәем, менә бит ул тормыш дигәнең ничек: яшь-яшь көйгә тома сукыр кал әле.

Җәүдәтнең шунда кычкырып җибәрәсе килде: «Борчылмагыз, кешеләр... Бу әле бөтенләй юкка чыгу түгел, җиңү безнең урамда булачак, тормыш дәвам итәчәк».

Әмма ул нык дулкынланудан тирә-юньдәге кешеләргә бер сүз дә әйтә алмыйча, шәфкать туташы ярдәмендә операция өстәленә кереп ятты. Аннары: «Шприц, новокаин...» — дигән өзек-өзек сүзләр ишетте, һәм менә инде энәнең, авырттырып, күзнең кайсы төшенәдер кереп кадалуын тойды.

***

Бакчада кошлар чут-чут итеп сайрап торган бер вакытта, радиодан концерт бирделәр.

Флера Сөләйманова нефть чыгару остасы Җәүдәт Закировичка багышлап бер җыр да сузды:

**Без бергә идек,**
**Калфаклар үрдек**
**Шул ак чәчкәдән.**
**..................................**
**Безнең гомерләр,**
**Өзелгән гөлләр**
**Кебек булмасын.**

Палатага доктор керде. Үзе белән дару исеннән тыш әллә никадәр хуш ис тә алып кергән иде. Менә табиб Җәүдәткә иелеп карады да, йоклый дип уйлап, баш очына чәчәкләр куйды. Юк, Җәүдәт йокламый иде. Ул докторны кулыннан тотып үз янына утыртты.

— Рәхмәт сезгә! Чәчәкләрегез бик матурлар булса кирәк!

— Үз бакчамда үскән чәчәкләр,— диде Сабир Исхакович.

— Тагын бер кат рәхмәт.

Доктор Җәүдәтнең иңенә кулын салды:

— Инде хәзер терелдегез, эшегезне дәвам итәрсез дип ышанам!

— Ышанычыгызны аклармын, рәхмәт.

## *Килешү*

Көннәрдән бер көнне Хәлил агай: «Печән бетеп килә, хайваннарга ни ашатырбыз инде»,— дип зарлангач, «Галләмгә кереп кара соң»,— диде хатыны.

Галләм аш ашап утыра иде, сәламне теләр-теләмәс кенә алды.

— Зур йомыш белән мин,— дип башлады Хәлил агай сүзен.— Печән кирәк иде миңа, хотя бы өч пот кына булса да.

— Мин кыш көне печән үстереп куйдым сиңа, иеме?

— Ну... салам булса да ярар иде.

— Тирес тә бирмим!

— Нигә ул чаклы каның катты әле?

— Соң, үзең сазаган кызыңны малаема бирмәдең ич.

— Монда кызның ни катнашы бар?

— Синең кыз артыннан ияреп, малай авылны ташлап китте.

— Китсә, әллә малаең авылдан китеп кенә минем кызга ия була алыр дисеңме?

— Күз күрер әле.

— Менә сезгә кыз!

— Менә сиңа печән!

Агай чыгып китте. Чү! Ишегалдында өченче көн каладан кайткан Нияз баҗасы басып тора. Исерек.

«Шул гына җитмәгән ие»,— дип уйлады Хәлил. Шулай да ул Ниязга кулын сузды.

— Аракың бармы? — диде баҗасы.

— Нинди бетмәгән аракы ди ул. һаман-һаман кибеткә чабарга мин капиталистмыни?!

— Елына бер генә кайтам мин,— диде баҗасы.

— Кайтканда берәгәйле итеп кайтасың.

— Аh! — дип куйды Нияз.— Кызың җиде яшьтән бирле миндә тора. Унсигез ел асрадым мин аны...

— Ә мин сиңа күпме бәрәңге, ит-май ташыдым... Әйдә, капканы тышкы яктан яп, айныгач килерсең. Җенем сөйми исерекләрне!

Нияз чыгып киткәч, Хәлил ага аның артыннан койма тишегеннән карап калды. Әнә Галләмнәргә әче бал эчәргә кереп бара. Эчкәч мактаначак ул. Ялгышкан син, Галләм, малаеңа Сафирәне Хәлилдән түгел, миннән сораргае, диячәк. Бирәм, әбәзтелне бирәм Сафирәне малаеңа, дип такмаклаячак.

«һай, үләрсең хурланып,— дип уйлады Хәлил ага.— Чынлап торып хуҗа булып маташа бит бу минем кызга! Бүген үк барам калага, кызга йорт алам. Шунсыз котылып булмас болардан. Аннан соң кыз укыган кияү табар үзенә...»

Хәлил ага, өйгә кергәч, хатынына эндәште:

— Теге акча төенчеген бир әле, карчык!

— Әллә машина кайтканмы?

— Кайткан пычагым, кызга йорт алырга барам."

— Ә печән?..— диде хатыны.

— Базда бәрәңге море, ашата тор!

***

Зур уйларга бөялеп шәһәргә килгәч, Хәлил ага туп-туры дусты Мәсхут янына китте.

Ул хатыны белән Әмәт тавы итәгендәге дача кебек йортта тора иде. Шул йортка килеп кергәч, бер хатын, фикус яфрагы сыман тар-озынча йөзен почмак яктан күрсәтеп, агайның сәламен алды. Хәлил калага килүенең серен әйткәч, хатын:

— Мәсхут базарда! Озак торыр, бәлки... Озак көтмәссез инде сез. Булмаса, каршы як таудагы чегәнгә барып килегез, ул бер өен сата бугай,— диде.

— Аңа ике өй каян килгән соң?

— Баргач күрерсез әле.

— Бәһане күпме сорый икән?

— Беренчесен биш ярымнан төрткән иде, бусыннан күпме каерадыр, белмим.

Хәлил ага, рәхмәт әйтеп, каршы як тауга китте. Чегән салган йортларны бик тиз тапты. «Бусы беренчеседер,— дип уйлады ул, тәбәнәк кенә өйгә карап.— Уртадагысы ярыйсы шикелле. Быел эшләп ятканы — кәртинкә!»

— Сигезгә бирмәсә, тугызга килешмәсә, уны әлегә юк югын. Әмма бер меңнән генә эш терәлмәс,— дип фикер йөртте агай, әкрен генә чегән яшәгән йортка якынлашканда.

Капкада тимер чылбыр иде. Капка астыннан йомры әнчек ырылдап килеп чыкты.

— Көтим әле...— диде агай, үз-үзенә һәм якындагы ак таш өстенә хәл алырга утырды.

— Иптәш... иптәш...— дигән тавышка сискәнеп күзләрен ачса — Мәсхут!

— Карчык әйтте: чынлап өй алырга йөрүеңме?

— Кәмит өчен түгел. Ни, чегән кайда?

— Ул, парин, Мари урманында бит...

— Их-ма! — диде агай.— Ичмасам, өе бер дигән иде.

— Бер дигәнен бер дигән дә шул: чегән бу өennән егерме мең каера,— диде Мәсхут.

— Әстәгъфирулла! — диде агай, өне алынып.

— Борчылма,— диде дусты.— Качалов урамында бер танышым өен сигезгә генә сата. Әйдә шунда!

Һәм менә тар гына, бәләкәй генә Качалов урамы! Өен сатучы кеше — авызын тутырып алтын теш куйдырган ит чабучы булып чыкты. Аңа фатир биргәннәр икән!

Хәлил ага менә шул адәмнең кечкенә агач өен~еигез меңгә килеште. Кыйммәт кыйммәтен дә, нишлисең, кызның киләчәге өчен тырышам, дип күңелен юатты ул.

***

Үз йортына күчеп килүгә үк, Сафирә туташ идән-түшәмнең буявын яңартты. Белгән маляр хатынны чакырып, накат белән диварларны акшарлатты. Күршеләре, сарай түбәсеннән су үтә, дигәч, ике кат толь белән аны да яптырды. Аннары, яздан анык-лап куйсаң, көз борчылмыйсың, дигән киңәшкә колак салып, бер машина ташкүмер дә кайтартты.

Өй җиһазы — мебель ише әйберләрне йә туганнары биреп җибәргәләде, йә комиссион кибеттән тапты. Инде барысы да булды дигәндә, бер җитешмәгән нәрсә калган икән: кияү кирәк!

Анысын инде аның комиссион кибеттән табып булмый шул. Мәгәр Сафирә монысына да аптырап калмады. Теге чакта күмер китереп киткән Галләм малае Таҗига күңелен беркетте. Егеткә шул гына кирәк тә! Күрсәтте ул Сафирәсез тора алмавын. Иртә дими, кич дими, өй янына килә дә баса... Сафирә кем икәнен белер өчен тәрәзәдән карый да елмая, карый да елмая.

— Тазик икән ич... Үт әйдә, төкле аягың белән!..

Ә егетнең өй эчендә дә тик торган сәгате юк. Ул чиләкләр күтәреп суга да китә, утын да ярырга вакыт таба.

Сафирә аптырый:

— Ичмасам, туйганчы бер утырып сөйләшеп тә булмый,— ди.

Ләкин егет ошый иде аңа. Туктаусыз бөтерелеп, хәрәкәт итеп торуы күңеленә сары май булып ята иде.

Берара эти-әниләргә сиздермичә генә өйләнешү турында да сүз булып алды.

— Язылышып кызык итик әле үзләрен! — Чынлап та!

***

Хәлил ага күзләрен ачып җибәрде — таң аткан икән!

Чү! Бәләкәй капка шыгырдап ачылды түгелме? Аһ! Монда таба кемдер якынлашып килә, чөнки аяк тавышлары... Менә, ниһаять, өй ишеге төбенә чаклы каерылып ачылды да... кечкенә буйлы, шадра Галләм пәйда булды.

Галләм бераз төшереп алган, җилле күренә иде. Керә-керешкә үк: «Күршеләрем!» — дип үкереп җибәргәч, хуҗаларга аның бу каргалган йортка ни өчен аяк басуы аңлашылды.

— Газизләрем! — дип, тагын да катырак кычкырды Галләм.

— Әкрен, юньсез,— дип ачуланасы килде Хәлил аганың. Әмма элекке үпкәләре юкка чыккан иде. Ул әйтер сүз таба алмады.

Галләм, шул форсаттан файдаланып:

— Малаем кызыгызга өйләнгән! — диде.

Ул моны шундый тантаналы итеп, тәэсирләнеп әйтте ки, Хәлил ага шундук кулын карават астына таба сузды.

— Сәлимә, закускалар әзерлә! — дип кычкырды ул хатынына, һәм үзе әрҗәдән бер шешә алып, өстәлгә утыртты.

## *Беренче хикәя*

Төнге өч иде, кинәт ак якта идән сайгаклары шыгырдап куйды, ярым пыяла ишек ачылды да ул күренде.

— Җитәр, улым, ташла бу шөгылеңне! Булмагач булмый инде ул бездән...

— Һе, әйтүе җиңел: тәмәкене ташлап булмаган кебек, бу «афәт»тән дә арынып булмый инде хәзер — соң! Аннары, әти, син үзең дә эшсезлектән интегеп яткан бер кышны, уйнап кына башлап, калын гына роман сырлап ташлаган идең ич! Соңыннан ул «әсәр»не орфографик хаталардан арындыра-арындыра, өчме-дүртме тапкыр акка күчереп, мин ничек аптырап беткән идем бит! Ахырда син, әти, чиләктәге эремчек-май өстенә шул кульязма китабыңны да төреп салып, җилкенеп, Казан тарафына чыгып киткән идең һәм караңгы төшеп килгәндә, аннан ялт итеп әйләнеп тә кайттың. Эремчек-майны базарда алып бетергәннәр, ә яшьлегеңдәге хаталарга багышлап язган романыңны язучы агайлар бушлай гына алып калганнар икән. Укып чыккач ук хәбәр итәрбез, дигәннәр.

Әйе, бик ачык хәтерли Илсур, ярсып аккан ташуны читтән генә күзәтеп йөри иде, янына йөгереп диярлек әнисе килде, куенына нидер кыстырган иде бугай.

— Улым! — Ана, кеше ишетмәсен дигәндәй, як-ягына каранып алды һәм куеныннан төргәк чыгарды да, серле генә елмаеп, Илсурга тоттырды.— Моны әле генә пучты тапшырды. Әтиеңә! Китабын чыгарып, акча җибәргәннәр, ахры... Кара хисабым буенча, ун меңгә якын булыр дип уйлыйм. И-и, зур итеп өй салыр идек, Алла боерса!

Малайның битләре кызышты, аяклары да сучинкәсенең юеш булуын тоймый башлады — әнисе әйткән ун мең тәңкәдә аның да өлеше бар лабаса! Болайга киткәч, әтисе улына гармун белән мопедны алып бирә инде!..

— Укы инде, улым! Ни яздылар икән?

— Язучылар союзыннан бу, әни!

— Шулаймыни, балам? Алайса, монда ун мең генә түгел инде!

— Мең тәңкәсе миңа!

— Кит, оятсыз! Нишлисең ул тамаша акча белән?! Бер тәңкә дә җиткән сиңа кинога керергә!

— Ә мопед? — диде Илсур үпкәләп.— Гармун?

— Алырбыз әле, өй салгач!.. Җә, ач-инде төргәкне, акчаларын ертмыйча гына...

Илсур төргәкнең читен сак кына ертты. Эченнән шәмәхә карандаш белән чуарланып беткән «роман» чыкты. Кош теледәй кәгазь дә бар иде. Анда, газета-журналларга мәкаләләр язып, каләмне шомартырга кирәк, диелгән иде.

— Нәрсә дип язганнар, улым? Акча җибәрәләрме?

Илсур җавап хатын әнисенә укып бирде. Ана кеше исә:

«Артык күп сүзле, көпшәк: образларда һәм сюжет-композициядә һичнинди яңалык юк»,— дигән сүзләрне аңлап җиткермәде, малаена төбәлде:

— Акча бирмәскә булганнармы әллә?

— Басмыйлар, әни, әтинең китабын. Басмагач, акча да бирмәячәкләр...

— Шулай булыр дип уйлаган идем аны...— Әни кеше елап җибәрде.

Ә кич, эштән кайтып, әлеге хәбәрне ишеткән Илһам абзый кара көйде, «роман»ны идәнгә тондырды, аннары аны аралыкка ук тибеп очырды. Хатыны да, уклау тотып, «роман»ны кыйнап чыкты. Әнә шулай үч алдылар алар басылмаган әсәрдән. Тик Илсур гына аны кыйнашуда катнашмады, киресенчә, җитлекмәгән «роман»ны кызганып һәм, әлбәттә, мопед белән гармунга ия булу хыялының башка юл белән дә тормышка ашасына инанып: «Юк, мин әти шикелле ярты юлда-тукталып калмаячакмын! Көрәшәчәкмен! Язучы булачакмын!» — дип уйлады.

Инде тугызынчы класста укыганда, Илсурның бер көлтә шигыре район газетасында басылып чыкты, унда укыганда — ике көлтә! Ләкин өлкә газета-журналларына гына үтмәде алар. Аңа карап Илсур күңелен төшермәде, язуын дәвам итте. Кемдер аңа университетның филология факультетында укырга тәкъдим итте. Әмма, бәхетсезлегенә каршы, монда да үтмәде: беренче сынауда ук татар теленнән инша буенча икеле алды, гәрчә мәктәптә укыганда гел бишлегә генә язып барса да!

Шуннан соң да күңелен төшермәде Илсур, сәүдә техникумына укырга керде, язуын да дәвам итте. Техникумны исә уңышлы гына тәмамлады. Хәзер ул райүзәктә товар белгече... Авылга кайткач, төнозын шигырьләр яза һәм аннары рус классикларының әсәрләре буенча инша язарга да өлгерә, чөнки ул читтән торып университетның әзерлек бүлегенә кергән иде. Юрфакка!

Илһам абзый тамак кырып куйды, мич ырмавыннан папирос алып кабызды, тышка чыгып китте, озак тормады — керде, урындык алып малае янәшәсенә утырды, янә папирбе кабызды, көлемсерәп:

— Чего пишешь, поэт? — диде урысчалатып.

— Рассказ пишу! — диде Илсур, шулай ук урысчалатып. Илһам абыйның йөзе яктырып китте.

— Укып күрсәтимме, әти?!

Илһам абзый утыннар каршындагы чүп-чар өстенә төкерде:

— Яле!

«Мин малай чакта, әти белән әнинең һәм күршеләребез Сабир абзый белән Сафура апаның, һич тә юк нәрсәдән тавыш-гауга куптарып, пыр тузып әрләшеп йөрүләрен һәм торабара...»

—Тукта, улым, әнкәң дә ишетсен инде. Хәтирә-ә!

Түр яктан:

— Нәрсә инде? — дигән чәрелдек аваз ишетелде.

— Илсур безнең турыда язган әнә... Чык әле!..

— И-и, аның шул булыр инде...— дип, Хәтирә түти мич янәшәсендәге урындыкка урнашты.— Җә соң...

«Тыкрык буена урнашкан...»

— Нәрсә тыкрык буена урнашкан? — дип сорады атасы.

— Безнең өй! — диде Илсур.

Ата кеше җөпләп баш какты.

— Гыйфрит Сафураларның тыкрык чатыннан икенче...— Илсур өтек Сабир белән Гыйфрит Сафурага, әтисе белән әнисенә һәм үзенә хикәядә бераз гына урын биргәннән соң, беренче гауга бакчадан күтәрелде, дип, куе вакыйгалар эченә өермәдәй бөтереп алып китте. Менә аларның яраткан этләрен үтерәләр. Озакламый мәчеләренең дә юкка чыкканлыгы беленә. Кылган кабахәтлекләр шул дәрәҗәгә җитә ки, яңгырлы көзге төннәрнең берсендә, тәрәзә пыяласын чыңгылдатып, өй эченә бала башыдай ак таш килеп керә. Илсурның атасы караваттан тора да, ташны кулына алып, әйләндереп карый-карый:

— Чыгыйм әле, тотмаммы икән. Башын өзәм! — дип чыгып китә. Шактый вакыт үткәч керә.

— Бәхете, качып котылды. Юкса үтерә идем...

Илсур әтисенең күршеләрен үтерәчәгенә ышанмый, билгеле. Шулай да: «Тотса нишләтер иде икән ул аларны?» — дип уйлый-уйлый йокыга китә.

Хикәя шулай тәмамлана иде.

— Җә, ничек? — Илсур, җавап көтеп, әтисенә төбәлде, әтисе — әнисенә! Әни кеше исә, яшьле күзләрен яулык чите белән сөртә-сөртә:

— Дөрес инде болар барысы да,— диде.— Күрмәгәнне күрсәттеләр инде алар безгә...— һәм борынын тартты, тураеп утырды.— Минем өчен әйбәт инде бу!

— Минем өчен дә начар түгел бу! — дип, дәртләнеп әйтеп куйды Илһам абзый.— Ләкин... моны әле басмаячаклар! — Илсур егылып китә язды.

Ни өчен басмыйлар? Сәбәбен аңлатсын иде, ичмасам!.. Юк бит, юк... Менә ничәмә-ничә ел инде Илсур бу сорауга җавап эзли, таба алмый, хәтта әсәрләргә карата язылган рецензияләрдә, мәкаләләрдә дә бу турыда шәрехләп аңлатылмый, әйтелми. «Булмаган», «начар» һәм бетте-китте! Ни өчен булмаган, ни өчен начар? Җавап юк...

Илсур, ниһаять, эчендәге үпкәсен әтисенә түкте. Илһам абзый башта кулын селтәп кереп китмәкче иде, аннары нидер, исенә төшеп, туктап калды.

— Ярый алайса, менә тыңла,— диде ул.— Салих Зиннәтов дигән бер механизатор егет районда гына түгел, өлкә күләмендәге ярышларда да гел беренчелекне ала килә. Күкрәгендә — Ленин ордены! Кызы Сания дә унтугыз яшеннән Кызыл Байрак орденына ия булды. Синең сабакташыңның өченчесе — Шакир Мәүлетов — комбайнчы, партия съездында утырган каһарман!

— И-и, әти... алар турында яздылар ич!

— Яздылар, ләкин мәкалә!

— Очерк та! — диде Илсур.— Журналда укыдым.

— Ә менә син повесть яки роман яз алар турында, әсәреңне, һичшиксез, басарлар!

— Әйтүе генә җиңел ул...

— Куркасыңмы?

Илсурның йөзе кып-кызыл булды.

— Син, әти, куркакка санама мине! Роман да язармын әле, күрерсең менә!

— Романны бергә язарбыз,— диде Илһам абзый дәртләнеп,— чөнки Шакир Мәүлетовның историясен әйбәт беләм мин. Салих Зиннәтовны аның олы малае итәрбез, ә Санияне — төпчек кызы! Ә хәзер хикәяңә килик... Хикәяңнең кимчелеге шунда: күп геройларыңның тарихын белмисең. Син уйлыйсың, шту, Сафура белән Сабир берничә сутый бәрәңге җире өчен тавыш күтәрәләр дип. Юк, сәбәбе тирәндә моның, бәрәңге җире ул так себе...— Илһам абзый сәгатькә карады.— Алар турында икенче бер вакыт сөйләрмен әле, ә хәзер ят, ял ит: әсәр бер утыруда гына язылмый ич,— дип, ул түр якка кереп китте.

Илсур исә әтисе әйткән теге тарихны белә иде. Хикәясен төзәткәләп, дөньясын онытып, өр-яңадан акка күчерә башлады.

Тәрәзәләрдә үткен хәнҗәр йөзедәй көн яктысы беленә башлаганда, түр яктан авазлар ишетелде:

— Кара әле, кара, кече якта әле һаман ут яна!

— Яза ич, яза.

— Каны бозылып бетә инде малайның.

— Юлның иң озынын, иң авырын сайлады шул...

— Өйләндергәч, бәлки...

Егет елмаеп куйды.

## *Людмила*

Алар көн дә дүртәү, өйлә вакытында яки кичкырын кибеткә кереп, бик озак итеп Русланның прилавка артында сатып торуын күзәтәләр иде. Кибет эчендә кеше-мазар калмагач, якын килеп, Русланга йомышларын әйтәләр һәм, тегесен-монысын алып, акрын гына чыгып китәләр иде.

Баштарак Руслан алардан шүрләп калды, чөнки бу адәмнәрнең кигән киемнәре, тышкы кыяфәтләре — күп вакыт кырынмаган булулары — юлдан язучыларны хәтерләтә иде. Ә дүртенчесе — хатын-кыз булу, Русланның шиген көчәйтә генә төшә... Әйе, егетнең ишеткәне бар: явыз ниятле адәмнәр күп очракта хатын-кыз да ияртеп йөриләр... Ул хатын таза да, матур да, яхшы киенгән дә булыр. Шуннан белеп кара инде кемнең-кем икәнлеген!

Дөрес, болардан сак булырга, берсе белән дә аралашмаска, бигрәк тә теге Чибәркәйдән ерак торырга кирәк: сизми дә калырсың, күзне-башны әйләндереп ташлар да...

Әмма авыл кешеләре әлеге дүртәүнең каладан килгән малярлар икәнен әйткәч, Русланның куллары җиңелчә генә дерелдәүдән туктады. Ул хәтта алар белән башлап үзе танышты. Баксаң, аларның исемнәре дә сәер икән. Коңгырт сакаллысы — Атлет, кара сакаллысы — Каһарман, нәзек озын буйлысы — Кипарис, ә дүртенчесе — шат кыяфәтле, гел елмаеп кына торганы — Людмила! Бу мөлаем туташ гел бәйрәмчә генә киенеп йөри иде, ә кибетче егет белән танышкач, тагын да бизәнебрәк йөри башлады. Ул хәзер иртәнге якта да, маляр егетләргә ияреп, кибеткә килә һәм, нәзек кара кашлары астыннан гына сөзеп, илаһи елмаеп, Русланның соскычлар белән оста эш итүен күзәтә: вакыт-вакыт, утлы күмердәй карашын төбәп, яшь сатучының бәгырен парә-парә телеп ташлагандай итә иде.

Руслан да, хисләрен яшерә алмыйча, өздереп-өздереп Людмилага карый һәм, әлегә шуннан да артыгын булдырырга базмыйча, көрсенеп куя...

Әйе, мәхәббәт утында яшертен генә дөрләп янарга кереште кибетче, ябыкты, уйчанланды. Ә Людмила? Ябыкмады да, тазармады да һәм нурлы йөзендәге елмаюы да кимемәде, егетне газаплавын дәвам итте.

Беркөнне кибеткә Атлет белән Каһарман килеп керде. Йөзләре сытык, кашлары җыерылган, күзләрендә яшь. Әллә кайдан күренеп тора — махмырдан интегәләр, мескеннәр!

Сатучы егет форсаттан файдаланып калырга, Людмила турында сораштырырга тотынды.

— Калада без яши торган фатир хуҗасының кызы,— дип аңлата башлады Атлет.— Безгә ияреп, акча эшләргә килде!

— Шәп кош бит, ә...— дип тел шартлатты Каһарман.

— Ошатсаң, үзеңә булыр,— диде Атлет, дилбегәне кулга ала башлавын тоеп, көр тавыш белән.— Рәхәтен күр, әйдә...

Руслан бер агарды, бер кызарды, ә горурлыгы аңа сер бирмәскә кушып, котыртып торды. Шулай да Людмилага мәхәббәте көчлерәк булып чыкты: ул җиңелде! Ә Каһарман белән Атлетка нәкъ шул гына кирәк тә инде, алар сатучы егеттән әҗәткә шәраб, даулый башладылар.

Атлет белән Каһарман күздән гаип булып, ярты сәгать вакыт үткәч, кибеткә, айның ундүртенче кичәседәй балкып, Людмила килеп керде.

— Исәнме, җаныкаем?! — диде Людмила, егет каршына ук басып.

— Исәнмесез...— дип, каушап җавап кайтарды егет.

— У-у-у... тәмле прәннекләр бар икән! — диде туташ һәм кулын әрҗәгә таба сузды.— Берәрсен кабып карарга рөхсәт итәсеңме?

— Алыгыз...— диде Руслан, сүрән тавыш белән.

— О-о... искиткеч тәмле бу! Тагын берне алыймммы?

— Ник сорап торасыз инде: үз иркегездә бит! — Егетнең тавышы юаш һәм сәер иде. Ул моны үзе дә сизде һәм аның кыюсызлыгына ачуы килә башлады.

— О-о... үз иркәмдәме? — дип сорады Людмила, кара күзләрен челәйтеп.— Алайса, кассадагы акчаны алам!

Егет эндәшмәде, читкә борылды.

— Шул шул минә...— диде туташ.

Руслан кашларын җыерды:

— Акчадамыни хикмәт! — диде ул.

— Нәрсәдә соң... синеңчә? Бәлки... мәхәббәттә, димәкче буласыңдыр, җаныкаем!

Егет, «әйе» дигәнне белгертеп, ым какты.

— һи-и, бармы соң ул мәхәббәт?!

— Нишләп булмасын, Людмила, бар...

— Әһә... син мине, яратам, димәкче инде... Алайса, әйт: син мине хәзер үк, менә шушы минутта ук, дөньяның читенә алып китә аласыңмы? Яисә син минем өчен кибетеңне кемгә дә булса бушлай бирә аласыңмы? Ә?..

Егет мондый кискен сорауларга җавап бирергә әзер түгел иде: тирләп чыкты.

— Шул шул менә...— диде туташ, тантаналы рәвештә.— Мәхәббәт юк ул хәзер, юк!

Людмила, башын горур тотып, ишеккә таба атлады.

Шуннан соң Людмила чибәркәй, кара күзкәй, бүтән кибеттә күренмәде.

Ул калага ук китеп барган иде.

## *Эт*

Ике ирнең күрше йорт ишегалдындагы чылбырда торган овчарканы, тынычландырып, кара «Нива»га утыртып алып китәргә җыенуларына төшенгәч, Рәсим, хәле китеп, чирәмгә чүкте. Эт тә, аерылышуның дүрт-биш көнгә генә булмаячагын аңлагандай, малай ягына карап, өреп-өреп куя иде.

«Һичничек ярдәм итә алмыйм шул!» — дип, ачынып уйлады үсмер егет. Ул авыру әнисе белән яши, зур эт асрарга хәленнән килми, бөтен өмете күрше бабайда иде, ул да бик иртә, бик вакытсыз ташлап китте бу нурлы дөньяны.

— Уф-ф! Карышма, Чегән, мин — яңа хуҗаң бит инде! — диде тәбәнәк ир, ал роза чәчәкләре төшерелгән күлмәк җиңе белән тирләгән кызыл йөзен сөртә-сөртә.

— Һау-һау.

— Артыннан этеп кара инде!

— Тешләшә ич, иблис! — дип, мыгырданып җавап кайтарды очсыз зәңгәр костюм кигән какча йөзле ир.

Эткә Чегән дигән исемне Рәсим кушкан иде, көчек чагында ук, көрәнгә караганда, кара төс күбрәк иде анда; хәзер дә шулай. Менә хәзер Рәсим: «Чегән, минем янга!» — дип эндәшсә, овчарка, чит ирләрне як-якка чәчеп ташлап, килеп тә җитәчәк. Ләкин ярамый!

— Чегән! Һоп... Әнә ит, аша! — дип чыелдады кыска буйлы ир.

— Һау-һау.

— Ай, үҗәт, карышма инде! — дип ялварды озыны.

— Ыр-рр!..

Бер мәртәбә, бары бер мәртәбә генә Рәсим көчекне усал казлар чукып тилмерткәндә килеп коткарган иде; дуслашып киттеләр... Өй каршыларында гына түгел, тыкрык чатларында, күперләр тирәсендә һәм су буйларында очрашкан чакларда, Рәсим, шаяртып һәм Чегәнне ирештерергә омтылып, бүрәнәләр, утын әрдәнәләре өстенә, йә бакча киртәсенә, яисә телеграф баганасына үрмәләп менеп китәргә күнекте.

Шап та шоп ишекләр ябылганы ишетелде.

—һау-һау!

Эт китте.

Дүрт ел үтте. Рәсим укуын дәвам итәргә калага күчте. Фатиры биш катлы гомумторак бинасында иде. Шунда ул Әмин белән дуслашты.

Кыш урталары иде. Алар нарат урманы эченә салынган поселокка кайттылар. Монда Әминнең апасы белән җизнәсе яши икән. Төн таңга таба авышып барганда, Рәсим күлмәкчән генә тышка, ишегалдына чыкты.

Кинәт егет каршында бозау хәтле овчарка пәйда булмасынмы! Рәсим, бар кыюлыгын җыеп, этне әйләнеп узып, кереп китәргә уйлаган иде, әмма теге зәһәр ырылдап, зур, көчле күк-рәге белән аны лапаска таба кысрыклады.

— Чегән! — диде кунак егет, этне танып.

— һау-һау!

— Чегән?

— Ыр-р, ыр-р!

Рәсим утын әрдәнәсе өстенә менеп кунаклагач кына тынды эт. Бары тик күктә йолдызлар сүнеп беткәч һәм абзар эченә сизелер-сизелмәслек кенә кереп торган ак кар яктысы таң яктысы белән алышынгач кына, кыска буйлы хуҗа чыкты.

Салкын тиюдән үпкәсе ялкынсынып, Рәсимгә айга якын хастаханә койкасында аунап ятарга туры килде.

## *Гафу итегез, иптәш подполковник!*

Көз урталарында урамда өзлексез вак яңгыр сибәләп торганда килде ул безнең колониягә эшкә. Ул өстенә.костюм, аякларына җәйге ботинкалар кигән иде. Яланбаш. Буйга озын булса да, гәүдәгә үтә юка, яңаклары эчкә баткан, күзләре сагышлы... Галәмәт дәү борыны өстенә атландырып куйган коңгырт кысалы кечкенә күзлеге белән ул миңа бигрәк тә мескен кыяфәтле булып күренде. Әйе, беренче карашка малай гына сыман күренгән бу егерме яшьлек «дәүбәк» минем күңелдә чын-чынлап кызгану хисе тудырды, һәм... без аны эшкә алдык. Дөрес, аңарчы миңа начальник янына ике мәртәбә ялынып керергә туры килде. Начальник, билгеле инде, минем гозерне аяк астына салып таптамады, үтәде. Шуннан, малай, ул минем кул астында кече цензор булып эшли башлады.

Берәр ай чамасы тыныч кына, бик тырышып эшләп йөргәннән соң, көннәрдән бер көнне малаебыз иркәләп бозылган эт

кебек аза башламасынмы?! Иң элек аның күңелендә йоклап яткан «мин»е уянды. Нәрсәгә генә тотынмасын, моны мин эшләдем, яисә, моны мин генә булдыра алам, дип әйтергә остарып китте. Бу хәл, әлбәттә, бездән юллама алып, юрфакка читтән торып укырга кергәч булды. Аңа бездә эшләгән атлы булып кылану — әнә ни өчен кирәккән икән!

Шулай максатына ирешүдә хәлиткеч адымны ясагач, малай көрәеп, тазарып китте. Битләре тулыланды, йөзе аллана башлады, күзләре дә, салкыннан кергән кешенеке сыман, ялтырый иде.

Ашханәгә баргач ашавын күрсәгез оле сез аның. Бер тәлинкә щи, пилмән, гарнирсыз өч шницель, ике касә каймак, бер тустаган кофе, җиде кисәк ипи, соңыннан салат яки эченә ит салып төрелгән белен дә алып килә...

Беркөнне бүлмәбезгә керсәм, малаем тирләп-пешеп комендант белән шахмат уйнап утырмасынмы! Әә эшлисе эш, укып чыгасы хатларның күплеге?! Юк, моны болай калдырырга ярамый... Өлкән опер Нотфуллинга җиткерсәм?!

Шул ниятемне тормышка ашырырга дип, урынымнан кузгалган гына идем, комендант, шәрә хатын-кыз сурәтләреннән ясалган уен кәртен пычракка төшереп җибәргәндәй, аһ! дип куйды.

— Мат! Мат! — дип кычкырды малай, куанычыннан сикергәләп. Һәм, минем якка да борылып, өстәүне кирәк тапты:— Камил Шәрипыч! Мин сезгә дә мат бирә алам! Гомумән, мине әле шахматта берәүнең дә...

Мин әйткәнне дә көтмичә, фигураларны тактага тезәргә кереште.

— Ярый, әйдә...— дидем мин, малайның кикриген шиңдерергә теләп һәм король каршындагы пешканы ике шакмак алга эттем.

Уйный торгач, мавыгып кителгән. Бүлмәбезгә опер Нотфуллинның керүен тоймый да калганбыз. Вәт каптырды ул безне-е!..

Шуннан соң мин ике ай чамасы айный алмыйча йөрдем. Хәзер шахмат уйнау түгел, якын да килмим... Ә малай исә, күрәсең, үзенә бүтән кызык тапты: бүлмәдән чыгып, яртышар сәгать югалып тора башлады. Берсендә түзмәдем, артыннан чыктым. Йа Хода! Безнең контор баскычыннан каршыдагы склад диварында эленеп торган янгынчылар чиләгенә кар атып маташа бу. Берничәне тидергән дә инде. Бикле склад ишегендә дә кар йомарламының эзләре аермачык беленеп тора!

— Гер-ра,— мин әйтәм,— нишлисең син?!

Ул минем тавышны әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә аңа әһәмият бирмәде, янә чираттагы «бомба»сын әвәләде.

Шул мәлне ишегалдында колония начальнигы подполковник Зиннуров пәйда булды. Ул янәшәдәге дуңгыз абзарыннан чыгып

килә иде булса кирәк. Юл уңаеннан цензорларның да ничек эшләүләрен барлап үтәргә уйладымы икән?.. Ни генә булмасын, подполковник олы яшьтә һәм гаять тәҗрибәле кеше. Ул инде ишегалдында максатсыз-нисез генә бушка селкенеп йөрмәс!

Малай подполковникны әллә танымады, әллә шәйләмәде, әллә танып та аңа игътибар итмәде: аның максаты янгынчылар чиләгенә тидерү иде бит! һәм ул кулындагы карны бар көченә шул якка таба ыргытты. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, кар юнәлешен үзгәртте һәм... колония начальнигына таба очты. Очты да, картлачның башындагы хәрби бүреген бәреп тә төшерде.

Мин, каккан казыктай, каттым да калдым. Ниһаять, малаең да башындагы бүреген бәреп төшергән кешене күрде һәм подполковникны танып алды шикелле. Ул шундук кар өеме артына яшеренде...

Подполковник, иелеп, җирдән бүреген алды, аны тезенә суккалап какты да, башына киде һәм як-ягына каранып куйды. Кызганычка каршы, бу хәлне миннән башка беркем дә күрмәде.

Подполковник мине күреп алды.

— Нишләп торасың анда? — дип кычкырды ул миңа, ниһаять.

— Гафу итегез, иптәш подполковник,— мин әйтәм,— мин әле генә саф һава суларга чыктым...

— һава су-лар-га?..— дип сорады подполковник, аннары, ялт кына борылып, кулы белән складка таба ишарәләп күрсәтте.— Болар кем эше?!

— Гафу итегез, иптәш подполковник! — мин әйтәм.— Мин...

— Ай-яй шәп сулыйсыз икән һаваны!..— диде подполковник, һәм, җил-җил атлап, минем яннан үтеп китте. Әгәр дә борылып караса, көрт артына качкан Гераның дер-дер калтырап торуын күрер иде. Булачак юристның бәхетенә дер, подполковник борылып карамады.

— Мин инде, подполковник мине гафу иткәндер, дип уйлаган идем. Мәгәр подполковник мине гафу итмәгән булып чыкты. Икенче көнне миңа эштән китәргә туры килде.

## *Көрәш*

Сөембикәне хатынлыкка Булат сорап аптырата иде. Төскәбиткә ярыйсы гына егет үзе, тик чамадан тыш кызу канлы булуы, менә мин дигәндәй, борын чөяргә яратуы кызның гайрәтен чигерә. Шулай да әле Булатның Сөембикәдән күңеле суынганы юк. Бүген дә килде ул кыз артыннан, максатына ирешергә теләп. Бу юлы егет тотты да Сөембикәне тау тиклем өелгән утыннар өстенә күтәреп утыртты:

— Чыгасыңмы миңа кияүгә, юкмы, канса да канис! — диде Булат, ниһаять, ачыктан-ачык янауга күчеп.

— Сиңа кияүгә бирер өчен үстермәгәннәр мине, понял! — диде кыз, энәләрен тырпайтып.

Тарткалашучыларның тавышларын ишетеп, Сара апа чыкты.

— Аһ, денсезләр,— диде ул,— тавык кебек кая менеп кунакладыгыз анда. Төшегез, көш! Утыннарымны ишәсез...

Юк, кыз төшә алмый шул инде. Сикерергә җайлы урын эзләп үрмәшә дә алмый, чөнки билендә егетнең кулы!

Уңайлы форсаттан файдаланып калырга ашыкты Булат.

— Килештекме, Сара апа? Сиңа — утын, миңа — кызың!

— Ә-ә, синмени әле бу? Бирермен мин кыз. Кара син аны, оятсызны... Сөембикә, ни карап торасың? Очырт...

— Канатым юк минем очарга,— диде егет көлеп.— Ә менә кызыңның очуы мөмкин безнең өй ягына таба!

Карчыкның тәмам каны кызды.

— И-и, авызыңа шайтан төкергере,— диде дә, — картны апчыгып күсәк белән сыйлатмасам, исемем...

— Серафима булмасын! — диде егет кеткелдәп.

Көтмәгәндә тавыш-гауга ишетеп йокысыннан уянган Фазыл карт та капка төбенә чыгып карчыгына төбәлде.

— Чү! Ни бу? Ни өчен кычкырыш?

— Әнә утыралар... Утыннар өстендә...

Фазыл карт шул тарафка озак кына карап торды да карчыгының җиңеннән тартты.

— Бар, бар! Яшьләр эшенә кысылып йөрмә... юкса...

Сара апа чәбәләнеп карады, мәгәр булдыра алмады, картының ихтыярына буйсынды.

— Уф-ф! — дигән булды егет, карт белән карчык кереп киткәч, сөенеченнән балкып.— Миңа әлегәсе күсәк өчен агачы да утыртылмаган әле...

— Кит, аю...— дип сулкылдарга тотынды кыз,— мин сиңа барыбер чыкмыйм, урласаң да, тәрәзәгезне ватып качачакмын.

Булат Сөембикәне утын өстеннән төшерде.

— Бизнә буйларыннан урап кайтыйк әле башта, аннары күз күрер! — диде егет.

Сөембикә бу үҗәт егет белән артык телләшеп торырга теләмәде. Аның тизрәк, өйгә кереп, йокларга ятасы килә иде. Әле бит таң белән торып җәйләүгә сыер сава барасы да бар. Ниһаять, кыз, йомшак кына итеп, егеткә эндәште:

— Соң инде, Булат абый, керим мин. Иртәгә кич точно безнеке булыр!

— Алдамыйсыңмы, Сөембикә?

— Берәр кыздан алдандыңмы әллә, миңа ышанмыйсың?!

— Ну, ярый, Сөембикә... ышанам! Элеккеге киреләнүләреңөчен суырып үбәр идем дә инде...

— Үбәрсең әле, үбәрсең! Үптерсәләр, хи-хи-хи...

***

Әнисе тавышына Сөембикә уянды.

— Кызым! Гөлүсә капкаларыннан чыкты инде...

Сөембикә, ә, диде дә, тиз генә торды, юынды һәм тамагына капкалап алды да тышка атылды. Өйалды ишеген ачып җибәргәч, ул чак-чак кына әтисен бәреп екмады. Комган тотып, тәһарәт яңартып кереше икән, ачуын кызына тамагын кырып кына сиздерде карт.

Сөембикә исә, каушавыннан гафу үтенергә дә онытып, урамга аяк басты һәм машина туктый торган җиргә юнәлде.

Гөлүсә күренми әле. Әни кеше кызына йокыдан тиз торсын өчен юри әйткән икән. Ул гел шундый инде...

Сөембикә сәгатенә карады. Әнә Миңниса килә! Аның артыннан башкалар... Гөлүсә әле һаман юк!

Шофер егет озак итеп кычкырткач кына ашкынып чаба башлады ул.

— И-и, малайлар... ашарга да өлгермәдем ич! — диде Гөлүсә.

— Иртәрәк кереп ятсаң, капкагызны күтәреп китмәсләр иде әле,— диештеләр кызлар.

Җәйләүгә тиз килеп җиттеләр. Шофер егет кыз-кыркынны чырылдатып җиргә коя башлады һәм Сөембикәгә дә кагылып йөрәк ярсуын басмакчы иде, әйләнеп тә төште. Көтүче Гыймран агайга тикле кеткелдәп көлде.

Кызлар дәррәү җәйләүгә таралдылар.

Сөембикә дә ак халатын киеп сыерлары янына ашыкты, һәм кинәт җир астыннан үсеп чыккандай, каршына пәйда бул-

ган хәрби егетне күреп туктады. Егет тә... Тын гына бер-берсен сынап карашып тордылар. Ниһаять, егет:

— Исәнме, Сөембикә! — диде.

— Доктор булдыңмы әллә?!

— Юк, доктор ук була алмам инде мин, Сөембикә! — һәм егет кызның кулындагы чиләккә ымлады.— Кая, мин дә һава күтәрешеп барыйм әле.

— Күтәр, күтәр! Авыл һавасы тансыктыр сиңа.— һәм кыз чиләкләрен Тәфкилгә тоттырды. Алар янәшә атлап киттеләр.

— Турыдан ярсам, ачуланмыйсыңмы, Сөембикә? — диде егет, аз гына юл үткәч.

— Кыектан яр алайса!

— Дөресен әйтим, мин сиңа өйләнергә кайттым, Сөембикә.

— Өйлән соң, авылда Сөембикәләр ничәү әле?

— Юк... миңа син кирәк...

— Ә миңа син кирәк түгел!

— Газаплама, Сөембикә. Болай да өч ел газапландым инде.

— Кем өчен газаплангансыңдыр... Миңа караңгы...

— Шулай инде, язган хатларыма җавап бирмәгәч...

— Син язмагач, мин ничек языйм ди...

— Әллә миннән хат килмәдеме сиңа?

— Килмәде шул.

Тәфкил бик каты итеп иренен тешләде.

— Болай булгач аңлашылды,— диде ул.— Почтада Булатның сеңлесе эшли бит. Димәк ки, минем хатларны ул ташлап барган булса кирәк.

— Чынлап әйтәсеңме, Тәфкил?

— Муенымны түмәргә куеп ант итәргә могу, Сөембикә, язган хатларымның чиге юк иде. Барысына да: «Сагынам! Бик күрәсем килә»,— дип яза идем.

— Алай булгач, отпускыга кайтып нигә яныма килмәдең?

— Сиңа ачуым килгән иде инде, Сөембикә. Бер хатыма да җавап алмаганга күрә. Соңыннан белдем: гаеп башкаларда булган бит!

— Уйлыйм әле, Тәфкил, бераздан әйтермен, яме! — диде кыз, ниһаять.

— Вакытягы кысан. Ун көн хәзер үтә ул. Туй итәсе дә бар,— диде егет.

— Биш көннән Сабантуй...— диде кыз, ишетелер-ишетелмәс кенә. Аннары, тавышын күтәрә төшеп, Тәфкилнең күзләренә туры карап: — Булаттан рөхсәт алдыңмы соң? — дип сорады.

— Юк инде, Сөембикә,— диде егет кайнарланып.— Мин рөхсәтне Булаттан түгел, ә Сара апа белән Фазыл абыйдан сорармын!

— Алай булса, мин риза! — дип әйткәнен сизми дә калды Сөембикә.

Тәфкилнең шатлыктан кызны күтәреп аласы һәм зыр-р-р

итеп әйләндерәсе килде. Мәгәр тыелып калды. Менә алар күңелле генә гәпләшә-гәпләшә карда эченә керделәр.

...Тәфкил белән Сөембикә бер-берсеннән аерылып күпмедер вакыт үткәч, тракторы белән Булат килеп чыкты. Ул, кабина тәрәзеннән башын сузып:

— Кайда теге прапорщик?! — дип кычкырды.

Гыйльман агай тәмәке тартып утырган җиреннән дәррәү сикереп торды.

— Ул олан шушы елга буйлап китте инде...

...Әмма Сөембикә, Тәфкил белән кич очрашырга сүз бирсә дә, бу хәлдән соң клубка чыгарга җөрьәт итмәде. Иртәгесен инде авылда менә нинди хәбәрләр йөри иде. Имеш, Тәфкил Сөембикәне алып китәргә кайткан икән дә, кызны Булат бирми икән. Сөембикәгә үзем өйләнәм, дип әйтә, ди. Эш якалашуга җиткән, сугыша язганнар, ди.

Алай булгач, Сабан туенда мәйданга чыгып көрәшик без, кем җиңә — Сөембикә шуңа була,— дип, кызып ташлаган ди, Тәфкил. Булат ике дә уйламыйча: «Мин риза!» — дип, шалтшолт кул сугып килешкән, ди. Ә аннары: «Сабан туена чаклы беребезгә дә Сөембикә белән очрашмаска!» — дигән шарт та куйган икән...

***

Менә көрәшче егетләр, мәйдан уртасына чыгып, шобага салдылар. Хәлиткеч тартыш башланып китте. Ул дүрт сәгатькә сузылды. Ниһаять, егыласылар егылып бетте, мәйданның кендеге булып ике пәһлеван — Булат белән Тәфкил басып калды.

Булатның чуендай каралган тәне урыны-урыны белән суелып чыккан, ә Тәфкилнең шикәрдәй ак тәне инде хәзер кыпкызыл булган.

— Әйдә, башлагыз! — диде көрәшкә судьялык итүче Габделбәр Наилевич.

Егетләр, тәвәккәлләп, сөлгене бер-берсенең биленә салды.

Халык арасыннан Булатка куәт өстәп кычкырдылар. Ләкин Булатның бүтәннәргә карата кулланган алымы бу юлы уңыш китермәде.

— Җә, ектыр инде,— диде ул, еш-еш сулап.

— Егалсаң, ек! — диде Тәфкил, Булатның билен кысуына шундый ук кысу белән җавап кайтарып.

— Тәкә сиңа булыр, тыңла!

— Ә сиңа нәрсә?

— Миңа...— Булат башын борып каядыр карады. Тәфкил дә шул тарафка текәлде һәм, күзләренә Сөембикә чалынып, сөлгене бер мизгелгә генә бушатып җибәрде.

...Кинәт янгын чыктымыни. Кешеләр шау-гөр итә, кычкырыша, чабыша башлады. Фазыл карт Булатның әтисе белән сөйләшеп утырган җиреннән: «Ни булды икән?!» — дип калыкса, халык чолганышы эчендә, иңнәренә тәкә күтәреп, Булат басып тора иде.

«Димәк, Тәфкилне Булат җиңгән! Булат минем кияү!» — дип уйлады карт.

Ә Сөембикә бу вакытта йөгерә-йөгерә су башнясы янына җиткән иде инде...

## *Зәңгәр томаннар артында*

Нык имән ишек өстенә көрән буяу белән «Сельмаг» дип язылган җыйнак кына калай кадакланган кибеткә шактый ук дулкынланып килеп керде Мисхәт. Эчтә баганадай озын һәм бик акрын кыймылдаучан сатучы абзыйдан гайре кеше-кара юк иде.

Кәнсәләр әсбаплары шыплап тутырылган бүлек каршына малай никтер курка-курка гына килеп басты. Әнә алар иң аста, иң күрексез шүрлектә бер почмакта, мескен рәвештә кысылышып, тузан җыеп яталар. Бик күптән яталар булса кирәк. Мисхәт әнисенә ияреп кибеткә килә башлаганнан бирле күреп белә инде аларны! Соңыннан, санарга өйрәнгәч, аларның төптөгәл унбиш данә икәнен һәм шуннан кимемәүләрен дә, артмауларын да искәрә торды. Тагын шунысы сәер, алар белән кызыксынучы да, хәтта алар тарафына ялгышып кына күз салучы да күренми бит! Сатучы абзый үзе дә аларның тәмам искереп, хисаптан чыгарылып ташланачакларын гына көтеп маташа шикелле.

— Нәрсә кирәк, малай?

Мисхәт, каушый-каушый гына, теге затсыз шүрлеккә ым какты: .-.^

— Әнә андагы ниләрне, китапларны сатып алырга телим дә...

— Акчаң?!

Мисхәт, гаепле малай сыман кызарып, башын түбән иде.

— Ярар, кем... Син минем улымның сабакташы ич әле. Әгъзам иртәгә акча эшләргә бара. Аңа әйтермен: юл уңаеннан сине дә эләктерер! Менә шуннан соң инде, беренче хезмәт хакына алырсың боларны — үсәргә ярдәм итә торган хикмәтле китапларны. Ярыймы?!

— Рәхмәт, абый!

Мисхәт кайтып кергәндә, әтисе белән әнисе йокларга әзерләнеп йөриләр иде инде.

Мисхәт уянганда, өй эче кояш нурлары белән тулган, өйалды ишеге тышкы яктан бикле — әтисе дә, әнисе дә эшкә киткән иде.

Малай аннан-моннан капкалап алды да тәрәзә аша бакчага төште, аннары, капкадагы аркылы таякны баганага сөяп куеп, ишегалдына аяк басты.

Менә урам якта машина тавышы ишетелде; кече капканы тибеп кенә ачып, Әгъзам килеп керде:

— Әйдә, тизрәк бул, китмәнеңне күтәр дә киттек!

Мисхәт, көрәк, сәнәк, тырма арасыннан китмәнне танып алып,

шундук Әгъзам артыннан (әрҗәсенә егермеләп малай-шалай төялгән) машинага таба йөгерде.

Кама тавы кашлагындагы яшь нарат төпләрен бер көндә үк йомшартып бетереп кайткannan соң, ай ярым вакыт үткәч, акча килде.

Кулларына акча эләккән малайлар, үзләрен бик булдыклыга санап, елмаешып, кибеткә юнәлделәр. Әнә... кемдер әнисенә оек ала, кайсыдыр — әтисенә, беришe әбисенә яки бабасына! Ә Әгъзам,— гаҗәп хәл,— кыйммәтле автокаләм сатып алды. Берне һәм... барлык акчасына!

— Мин моны, бик бүләк итәм! — диде ул. Аның көр тавышында, нәселенә хас булганча, бераз гына һавалану да, үзенең бинИһая озын буена соклану төсмерләре дә чагыла иде кебек.

Шуннан соң кәрлә Мисхәт, кибеттәге кешеләрнең күпмесендер шаккатырып, бөек сере тик үзенә генә мәгълүм булган теге ымсындыргыч китапларның һәммәсен дә сатып алып вә киндер букчасына тутырып, өенә кайтып китте.

Кайтып керде дә, ике яки өч елдан ук Әгъзамнан да озынрак булачагы турында уйлап, эченә әллә нинди тылсымнар яшерелгән кебек тоелучы китапларның берсен суырып чыгарып, юка, бик юка тышлыгын ачты. Ләкин бу — «Үсү юлы» атлы китапчык — яшь язучыларның альманахы булып чыкты!

## *Язмыш*

Шәргыя әби, аз гына ятып торыйм, дип, мендәргә баш төрт--кән иде, йоклап ук киткән. Күпме йоклагандыр — тәгаен белми — ятканда сәгатькә карамаган иде. Тик шунысын гына хәтерли: бер солдат аларның койма буенда басып торганда кояш әле төшлек турысында гына иде. Ә хәзер ул әнә, җиргә бик якын ук килеп, ерактагы тау артына батарга җыена. Әби, нидер исенә төшереп, ян тәрәзә алдына килеп басуга, койма буендагы эскәмиядә утыручы солдатны күреп алды.

— Тфү,— дип төкереп куйды ул, эчке зәһәрлек белән.— Кемне көтәдер? Ни калгандыр аңа бу тирәдә!

Әби солдат киемендәге кешеләрне сөйми иде. Бу сөймәүнең үзенә күрә бер тарихы да бар. Ул тарих менә болай иде.

Инде күптән, бик күптән бер кичне Шәргыя түтинең тәрәзәсен чиртteләр. Кем булыр бу? Ана куркынып унынчы класста укучы кызына карап куйды. Ә кыз — анасына. Куркырлык та шул. Алар өй эчендә икәү генә бит. Шәргыя түтинең ире күптән үлгән, олы малае читтә өйләнеп калган, ә уртанчысы шулай ук еракта — шахтада эшли.

Тышта давыл. Җил, шашкан сыман, котыра-котыра дулый, монда килеп кемгәдер ялварган төсле елап ала да тегендә китеп ыңгыраша, зарын сөйли. Ләкин урамдагы кешенең җилне тыңлап торырга теләге юк, аның тизрәк бу каһәр суккан әче бураннан котыласы, берәр җылы почмак табып ышыкланасы килә. Бигрәк тә ул кеше, юлчы булып, өенә кайтып җитә алмыйча, караңгыга да калган булса... Нишләмәк кирәк, юлда катып үлеп булмый, очраган беренче өйнең тәрәзәсен кагасың. Әзмени миһербанлы кешеләр дөньяда, ярдәм итәр әле берәрсе, дисең, һәм ялгышмый бәндә — теләгәненә ирешеп тә куя, ә кайвакыт күбрәккә дә ирешә әле. Шәргыя түтинең үзенә дә шушындый каһәр суккан көннәрдә, өенә кайтып җитә алмыйча, кеше почмакларында күп кунарга туры килгәнгә, мондый тәрәз шакучыларның хәлен яхшы аңлый. Мөмкин булса, ярдәм итәргә дә әзер. Ә нишләп мөмкин булмасын ди? Ул кемнән ким? Юк, кызгана ул андый юлчыларны... Шәргыя түтй,"Тагъш бер кат кызына карап, шуларны уйлап алгач һәм кызының да күзләрендә ярдәмчеллек чаткылары күргәч, тәвәккәлләде. Өстенә генә элеп алды да чыгып китте. Капка буена җиткәч, иң элек:

— Кем бар? — дип сорады.

Җил тавышын җиңәрлек итеп берәү тыштан:

— Мин, мин! — диде.

— Кем соң ул «мин, мин»?

— Солдат мин, апа, Фәрхетдин, түбәтәем бәрхетдин.

Шәргыя түтинең көләсе килеп китте. «Яле, нинди бәрхетдин түбәтәйле солдат икән ул?» — дип, капканың эшермәсен тартып алды да керүчегә текәлде. Зур гәүдәле, озын шинельле берәү, аркасындагы капчыгы белән баганага сыдырылып, ишегалдына үтте. һәм «ай-һай» дип бөгелә төште дә, күн итеген шап-шоп китереп, бәргәләп алды...

— Нәрсә, аяк туңдымыни, Бәрхетдин? — диде Шәргыя түти.

— Туңды дип... Туңмады инде ул туңуын да, өшеде генә.

Шәргыя түти, аның салкыннан шакыраеп каткан итекләренә карап, башын чайкады.

— Шулай ярыймыни, Бәрхетдин? Киез итек киярге кирәк иде, агач аякка калуың бар бит югыйсә.

— Анысы кирәк тә бит...

Фәрхетдин унлы лампа яктысы төшеп торган тәрәзәгә таба борылды...

Шәргыя түти кабалана башлады, болдыр баскычына менеп, солдатка ымлады. Керделәр. Өстәл янында оекбаш бәйләп утырган кыз керүче солдатка текәлде һәм, кинәт кенә кызарып, күзләрен яшерде.

— Фәһимә, чәй кайнатырга куй! — диде әнисе, мич башыннан идәнгә җылы киез каталар ташлап. Үзе дә шул каталар артыннан идәнгә дөпелдәп сикереп төште. Солдат, шинелен, бүреген агач чөйгә элеп, аягыннан итеген сала алмый җәфа чигеп ята иде, Шәргыя түти, ярдәмгә килеп, солдатның аягыннан каткан итекләрне суырып алды. Фәһимә, аларны мич башына бастырып, казаннан ләгәнгә салып, җылы су алып килде. Солдат, кызарып бүртенгән аякларын кайнар су эченә тыккач, ютәлли-ютәлли әйтеп куйды:

— Сабанчыга кайтасы идем мин, юлда килә-килә адашканмын.

— Ә нигә Ташбүләккә кермәдең?

— Ташбүләк сулда кала ул, апа. Миңа Тук-Шөкердән соң уңякка кирәк.

— Әйе шул, анысы хәтеремнән чыккан икән! — Шәргыя түти, үзенең хәтерсезлеген сугыш вакытында күргән нужага сылтап, егет алдына комган белән бер кисәк сабын да китереп куйды.

— Иртәгә буран туктаса, безнең атлылар Сабанчыга барачаклар.

— Анысы яхшы менә.— Фәрхетдин, аяк бармакларын югалап, каш астыннан гына Фәһимә ягына карап куйды. Фәһимә дә солдатны күзәтә иде. Күзләре очрашты... «Чибәр, каһәр» дип уйлады солдат. Фәһимә дә солдат турында шундыйрак фикердә иде, ахры... Ә Шәргыя түти исә, тышта үкергән җилгә

колак салып тыңлана-тыңлана, бөтенләй башка нәрсә турында — солдат авылларына кайтып кергәч, ата-анасының малайларын күреп ничек сөенәчәкләрен уйлый иде. Ә аннан соң егетнең язмышы нинди булыр? Авылда әти-әниләре янында калырмы ул, юкмы? Әллә Шәргыя түтинең уллары кебек читкә бәхет эзләп чыгып китәрме?

Солдат, аякларын җылытып үзен рәткә керткәч, коры аякларына киез ката киеп, урыныннан торды һәм, эскәмия йөзлегенә куелган сабынны алып, янә ләгәнгә иелде. Фәһимә комган белән аның кулларына су коеп торды. Егет, суны шапырдата-шапырдата, муеннарын ышкып юынганнан соң, чип-чиста сөлге белән тәннәре кызарганчы сөртенеп, стенага эленгән көзге алдында байтак кына басып торды. Чөнки ул көзгедән Фәһимәне күрә һәм аның йөзендәге һәрбер сызыгын, һәрбер хәрәкәтен искәрә — кыскасы, ул кызның чәч бөртегенә тикле мавыгып күзәтә иде. Әгәр ул шунда Шәргыя түтинең үзенә эндәшүен ишетмәгән булса, кызның гүзәллегенә мөкиббән китеп, тагын да берәр сәгать көзге каршында басып торудан баш тартмас иде. Һәм кинәт:

— Сезне әллә, Бәрхетдин, солдатта көзге алдында шушылай озак басып торырга өйрәтәләрме?

— Һич юк,— диде егет,— солдат законы бик каты ул. Иртән үрә кат та, кич үрә кат. Берәр нәчәлник алдында үрә катмый калсаң, биш суткы кухнядан чыкмый бәрәңге әрчергә, круго-ом арш! — Егет, солдат адымнары белән ишек буен урап, өстәл янына килде;

— Ихи-хи-хи,—-дип кеткелдәп көлде Шәргыя түти.— Кругум арыш, алайса, бодай түгел, диң.

— Кругом борчагы да бик күп аның, апа, армиядә.

— Шулаймыни? Уңамы соң анда борчаклар?

— Ничек кенә әле! Армия борчагы автомат пулясыннан бер дә ким түгел.

— Алай. Автомат пуләләре ашап армиядән кайткач, бик күркәм егеттер инде син.

— Кызларга күркәммен, түтәйләргә бүтәнмен, кояшка дип менгәнмен дә айдан егылып төшкәнмен.

— Һай, телләрең синең, Бәрхетдин!

— Җиз минем телләр, тальяннныкы кебек. Кирәк икән көлдерә, кирәк икән елата.

— Ә мин елауны бер дә теләмим.

Шәргыя түти зур гына бер ипине, агач саплы чалгы пәке белән юка-юка гына телемнәргә кискәләп, чәчәкле матур тәлинкәгә түбәләмә өеп куйды һәм, почмакка кереп, мич авызын-

нан бер чуен итле аш күтәреп чыкты да тирән эчле калай мискиләргә салырга тотынды...

— Әйдәгез, балалар, табын тирәли утырышыйк. Ә син, Бәрхетдин, бүре кебек ачыккансыңдыр инде.

— Әйе, апа, эчтә бүреләр улый башлады инде.— Фәрхетдин, елмая төшеп, кызга каршы якка, кулдан ясалган шкаф, тирәсендәге урындыкка килеп урнашты.

— Әйдә, Фәрхетдин, җитеш әле.

Фәһимә ашыкмый гына ашап утырган җиреннән уңайсызланып кызарып куйды. «Әнисе кебек түгел икән бу, сөйләшми икән»,— дип уйлап алды егет, кызга астыртын гына күз сирпел.

Фәрхетдин Шәргыя түти бүлеп биргән ит калҗасын тәмләп кабып йотты да, кулын тастымалга сөртеп, урыныннан купты.

— Бик зур рәхмәт сезгә, апа. Һаман шулай тигез, матур булып яшәргә Ходай насыйп итсен.

— Үзеңә, әйткән сүзеңә рәхмәт,— диде Шәргыя түти.

Фәрхетдин шунда, нидер исенә төшкәндәй, ашыга-ашыга ишек буена килеп, агач карават астыннан юл капчыгын сөйрәп алды. «Кызның телен ачам әле мин хәзер, ачам, теге ефәк күл мәкне генә күрсәтим дә»,— дип, эченнән генә матур хыялларга бирелә-бирелә, капчыктан әллә ниләр тартып чыгарды һәм берикесен янында калдырып, калганнарын кире салып куйды. Шәргыя түти белән Фәһимә егетне кызыксынып күзәттеләр, ә ул ике кечкенә төргәк тотып яннарына килгәч, гаҗәпләнеп калдылар.

— Менә бусы, апа, сиңа,— диде егет.— Бусы — Фәһимәгә.

Түти, каушап, төргәкне алыргамы, алмаскамы дип, бераз икеләнеп торгач, алырга да ачып карарга булып, төргәккә кулын сузды. Тик элек егеттән төргәк эчендә нәрсә барлыгын сорашты.

— Курыкма инде, апа, буар елан юк,— диде егет шаяртып.

Төргәкне сүтүгә, Шәргыя түти кычкырып җибәрде һәм, үзе дә сизмәстән, зур бизәкле ялтыравыклы атлас яулыкны башына бәйләп тә куйды.

— Хан хатыны булдым, хан хатыны...— Шәргыя түти үзен әле тегеләй, әле болай итеп көзгедән карап туйгач, кызына күзе төшеп, чалкан авып китә язды.

— Үләм, матурлыгы! — дип, дөньядагы барлык төсләрне үзенә җыйгандай елык-елык килеп торучы ефәк күлмәкне тотып карады. Аннан, артка чигеп, сокланудан авызын җыя алмыйча әйтеп куйды:

— Менә, ичмасам, син, кызым, хан кызы булдың!

Бу сүз егетнең дә күңеленә хуш килде. «Ә, шулаймы!» — дип уйлады ул, бүләге белән горурланып.

Шәргыя түти егетнең мондый уйлары барлыгын башына да китермәде, әлбәттә. Ул бертуктаусыз сайрый-сайрый кызы тирәсендә бөтерелгәндә, егет тә, яңа чыккан кояш кебек балкып, Фәһимәгә якынлашты, күлмәк кысан түгелме, тартып тормыймы, дигән булып, кызга орынып та алды.

— Бу күлмәкне кигәч, син чын сылу,— диде егет. Аның күзләре ут яна иде.

Ана кеше сизмиме соң?! Эчендә егеткә карата ачу туа башласа да, башта күрмәмешкә салынды Шәргыя түти. Ачуын тышка чыгармаска, сиздермәскә теләп йөри бирде. Инде егет кызына артык сылана башлагач, ниһаять, түзмәде:

— Сал, кызым, каралтканчы. Күлмәге шәп тә, сатып алырга акчабыз җитмәс,— диде.

Бу сүздән егет тә, кыз да бердәм каушап киттеләр. Кыз, матур иреннәрен бөрештерә төшеп, чыраен сытты.

— Нигә аны акчага сатып алырга? — диде егет, тиз-тиз генә, килешмәгәнен белгертеп.— Бушлай биргәндәме... һе...

— Бушлай бернәрсә дә кирәкми. Хәрәм ул безнең өчен.

— Бүләк итеп бирәм соң, алай булгач.

— Анысын әнкәңә бир и сөйгән кызыңа. Бүләк алырга без сиңа кем ул хәтле. Юк, юк, булмый.

Шәргыя түти күлмәк белән яулыкны бергә төрде дә егеткә сузды. Бу эшне шулай пичәтләгәч, яшь йотып торган кызына да күтәрелеп карамыйча, урын җәяргә кереште.

— Ярар соң, алай булгач,— диде Фәрхетдин. Кызга күз кысып алды да, кулындагы төргәкне үзе ятасы агач караватның мендәре астына кыстырып, чишенә башлады. Бераздан утны сүндереп йокларга яткач, Фәһимә әнисенең колагына пышылдады:

— Бик ошады миңа бу солдат, әни. Үзе матур, үзе сүзгә оста, үзе юмарт.

Шәргыя түти кызын кочаклап алды һәм, чәчләреннән сыйпап, күкрәгенә кысты:

— Эх, юләр дә соң син, балам... Бер күргән егеткә йөрәк ышанып тапшыралармыни?.. Менә мин әтиең белән дүрт ел йөрдем, дүрт ел. Барыбер аның нинди икәнлеген аңлап бетерә алмадым. Кеше дигәнең бик катлаулы бит ул...

Фәһимә икенче ягына әйләнеп ятты. «Әни дөрес әйтми,— дип уйлады ул.— Кешене бер күрүдә дә таныргга була. Бер күрүдә ошаган кеше, ул инде иң әйбәт кеше...»

Шулай дип йоклап китте кыз.

Шәргыя түти иртүк уянып торганда, кыз да, егет тә йоклый иде әле... Түти янә кичәге хәлләрне исенә төшереп һәм, бүгенге көнгә план кора-кора, тышка чыкты. Тышта инде буран басылган, җил тынган, күк йөзе болытсыз, һава саф. Әле яктырып җитмәгән иде, шулай булса да, карның җете аклыгыннан Шәргыя түтинең күз нурлары киселде. «Ай-һай, бер төн эчендә никадәр өйгән бит!» — дип, капка төбен тау иткән буранны каһәрли-каһәрли, көрәк алып урамга юл ачты. Әллә ни күп тә эшләмәгән иде әле, берзаманны артта тавыш ишетелде:

— Мәшәкатьләнмәгез, апа, кая, үзем көрим!

Борылып карады. Кичәге солдат, кичәге кирза итекләрдән, гәүдәсен аз гына алга авыштырган да бер кулын, түтидән көрәк алыр өчен, сузып тора. Түти, ни дип җавап бирергә дә белмичә, аптырап, солдатның аз гына көлемсери төшкән күзләренә сынап карап куйгач, үзе дә сизмәстән көрәген солдатка бирде. Фәрхетдиннең җене кузгалгандай каударланып эшли башлаганын карап торды да өйгә кереп китте. Кызы да уянган икән, каядыр барыр өчен пәлтәсен киеп маташа иде. Түти кар көрәүче солдатның Фәһимәгә, Фәһимәнең солдатка күзе төшкәнен белә иде инде, шуңа кызының кая җыенуын сорады.

Фәһимә, кырт кистереп:

— Тышка гына чыгам, әни,— диде.

— Яңа пәлтә киепме?

— Кисә ни, ашаламыни?

Шәргыя түтинең «Солдат янынамы?» дип әйтергә теле дә кычытып киткән иде, ләкин бу сүз тупас булыр, кызның күңелен генә рәнҗетер дип, эченнән генә тынды да өй мәшәкате эченә чумды.

Уйга бирелеп, тегесен тегеләй, монысын болай итеп эшләп йөргән арада, бәрәңге пешкән икән, чәй дә әзер. Тик табын гына хәстәрлисе калган. Шәргыя түти шулчак, кызының «тышка гына чыгып керәм» дигән сүзен исенә төшереп, сискәнеп куйды һәм, «шул гомердән бирле нишли икән ул анда?» дип, тәрәзәдән караса — шаккатты. Кар көрәлеп беткән. Фәһимә Фәрхетдин белән куышып уйнап йөри. Менә син ә, тамаша! Заман ахыры җитәме әллә, Ходаем! Кич күргән солдат белән бүген мәш килеп йөри. Шәргыя түти тиз генә пимасына ташланды. «Кыз яшь нәрсә, тәки солдатның баллы теленә алданып башын харап итәр. Аны вакытында бу эштән туктатырга да солдатын пыранлатып куып җибәрергә кирәк!» — дия-дия, тышка атылып чыкты.

Үзен белештермичә, бар көченә:

— Фәһимә! — дип кычкырып җибәрде. Хәтта тавышыннан үзе дә куркып, калтырап куйды. Егет белән кызны әйткән дә юк. Алар, аңнарына килеп, Шәргыя түтигә карарга да оялып, башларын түбән иделәр.

— Кит кереп,— диде түти кызына. Ә егеткә исә:

— Бар, күз алдымнан югал! — дип, капканы япты.

Шуннан кермәде егет, күренмәде. Шәргыя түти, кызулык белән Фәһимәсен эт итеп әрләп елатканнан соң, карават астында ятып калган капчыкны һәм мендәр астыннан теге төргәкне дә табып алгач, беразга гына йомшый төште. Шулай да ул, бүген солдатның өйләнеп килүеннән шикләнеп, калага бармады. Юкса барырга ниятләгән иде бит. Икенче көне дә шундый шик эчендә үтте. Һаман болай килмәгән солдат өчен кайгырып яшәп булмый иде. Һәм ул беркөнне: «Килмәгән солдат өчен борчылып торып булмас»,— дип, калага тәвәккәлләде. Анда көн буе булды. Тегендә барып, монда килеп йөри торгач, кызына муенса, үзенә Оренбург шәлен дә тапты. Тагын капчыгы тулганчы ашау әйберләре дә алып, стансага төште. Поезды да озак көттермәде. Сәгать ярымнардан соң түти, үзләренең тукталышында вагоннан чыгып аз гына баргач, бер атлыга юлыкты. Бу хәтле дә мач килсә килер икән. Түтәебез әле караңгы да төшеп җитмәгән бер вакытта капка төпләрендә атлы юлаучының чанасыннан төшеп калды.

— Аллага шөкер,— дип куйды ул, үзенең исән-сау кайтып җитүенә сөенеп, һәм, шатлыгын кызы белән дә уртаклашырга теләп, капкага юнәлде. Өй ишеген ачып җибәрсә, түрдә бәйрәмчә киенгән Фәрхетдин утыра, ә аның каршысында күбәләк кебек җилпенә-җилпенә, теге ефәк күлмәктән кызы Фәһимә йөри. Икесенең дә күңеле шат, икесе дә бик әсәрләнгәннәр. Шәргыя түтине күрү белән, сикереп торып янына килделәр.

— Күземнән югал,— дип аваз салды түти Фәрхетдин солгка.

— Ә мин югалырга теләмәсәм,— диде Фәрхетдин җитди генә, түтидән курыкмавын белгертеп.

Шәргыя түти кызына төбәлде:

— Ә син соң нишләргә телисең? — диде.

Фәһимә тиз генә җавап бирмәде. Башта егеткә карады, аннан соң, өй эченә күз йөртеп чыккач кына, билгеле бер карарга леп әйтеп куйды:

— Китәм мин, әни.

— Кай-й-йа? Кияүгәме?

— Фәрхетдин белән, эшчеләр каласына. Ул анда урнашып кайткан инде.

— Ә укуың?

Кыз өчен Фәрхетдин җавап бирде:

— Укымый калмас, апа. Хәтта мин аңа институт тәмамлатам!

— Беркая да җибәрмим,— диде түти, эчке борчылудан картаеп киткәндәй булып.

— Җибәрерсең,— диде Фәрхетдин һәм куен кесәсеннән өйләнешү турындагы таныкламасын алып, түти алдына ачып **салды.**

— Ай-һай, тиз тотканнар сезне?!

— Атлас яулык эшне шулай тиз хәл итте,— диде Фәрхетдин көлеп.

...Шуннан бирле күпме еллар үтеп, чәчләре агарып бетсә дә, солдат дигән адәмне һаман җене сөйми Шәргыя түтинең...

Уйларыннан бүленеп, янә тәрәзәгә күз ташлады. Теге солдат һаман утыра иде.

— Менә кызык, кемне көтә икән бу?

Шунда солдат, аның уйларын сизгән кебек, тәрәзәгә карап куйды. Шәргыя түти артка чикте. Бу аның кияве Фәрхетдин иде...

## *Югалган кыз*

Фагыйлә авылда туса да, әнисенең озак авырып хастаханәдә ятуы сәбәпле, уку яше җиткәч, апасы белән җизнәсенә ияреп салага китте, һәм шулай итеп, шәһәрдә үсәргә туры килде аңа.

Баштарак ул әти-әнисе янына җәйге каникулларда гына сайткалый иде. Менә укулар тәмам. Апасы Фагыйләне җитәкләп вокзалга алып төшә, билет алып автобуска кертеп утырткач, йөгереп кенә кибеткә дә барып килә. Үзенең киңәшләрен дә әйтергә өлгерә:

— Фагыйлә кызым (әйе, үз кызы кебек итеп күрә иде ул аны), авылга кайткач, юньле генә йөри күр, яме!

— Ярый, апа.

— Атаң-анаң сүзеннән чыкма!

— Чыкмыйм, апа.

— Берүк минем йөземә кызыллык китермә, балам!

— Юк, апа.

Шул вакыт, төтен чыгарып, автобус кузгала башлый. Фагыйлә тәрәзәгә сарыла.

— Сау бул, апа!

— Хуш, хуш...

Тәбәнәк буйлы, юан гәүдәле апа кеше инде түзми, кесәсеннән кулъяулыгын тартып чыгара. Курчак кебек киенгән Фагыйләнең ачык соры күзләренә дә яшь тыгыла бу мизгелдә. Ул, автобусны туктатып, янә апасының кочагына атылырга тели. «Апа, без бүтән беркайчан да аерылышмыйк, син мине яратасың, мин дә сине яратам, әйдә кире өйгә кайтыйк»,— диясе килә. Ләкин төтенле каланы чыгып, урманнар, кырлар аша ба-

ра-бара авылга якынлаша башлау белән, бу уйлар үзгәрәләр. Фагыйләнең күз алдына апасы кебек үк мөлаем, изге күңелле әнисе килеп баса. «Ничек каршы алыр?» — дип уйлый ул.

Әлбәттә, кояш астында йөреп каралган ана кеше зарыгып көткән кызына кочагын җәеп ташлана. Исәнләшеп күрешкәч, хәл-әхвәлләр сорашу китә.

— Сине, кызым, танырлык та түгел...

— Ник, әни?

— Үскәнсең, чибәрләнгәнсең...

Ә Фагыйлә рәхәтләнеп елмая гына. Әнисеннән мондый назлы сүзләр ишетү аңа тансык. Шуннан соң, Фагыйлә өчен тоташ бәйрәмгә әверелеп, көннәр арты көннәр үтә башлый. Иртән пәрәмәч, өйләдә йомырка тәбәсе, ә кич тагын әллә нәрсәләр... Хәтта шактый ук кырыс күренгән Вәли абзый да «кызым, кызым» дип үлеп тора. Бер генә көн дә өйгә күчтәнәчсез кайтканы юк. Ата-анасының күрсәткән сый-хөрмәтләр өстенә, авылның гаҗәеп табигате, урманы-болыны, елгасы-күле, саф һавасы — барысы бергә кызны үстереп кенә калмый, аны тазартып та җибәрә. Фагыйлә һәр җәйне менә шулай үткәреп, үзгәреп китә иде авылдан. Ә киткәндә әнисенең күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы була иде. Фагыйлә нигәдер әнисенең елап калуын теләми. Бер тапкыр ул аңа:

— Әнием, син мине озатканда елама! — диде.— Син елагач, минем дә елыйсым килә, миңа син гел елап кына яшисеңдер кебек тоела.

— Ярар, балам, бүтән еламам,— дигән иде аңа әнисе. Ләкин сүзендә тора алмады — еларга туры килде шул, әле ничекләр генә итеп еларга туры килде. Аның тарихы менә болай булды.

Кыз мәктәпне тәмамлаган ел иде ул. Җәйнең матур гына булып, яңгыры явасы килгәндә явып, кояшы кыздырасы килгәндә кыздырып, тыныч кына, шау-шусыз гына үтеп барган чагы иде. Бер дә бер көнне Фагыйлә ашыгып өйгә кайтып керде дә яшь кызларда гына була торган эчкерсез бер сөенү белән яңа хәбәр әйтеп ташлады:

— Апаем, матур апаем, безнең класс кызлары Себергә эшкә китәләр, алар белән мин дә китәм.

— Нәрсә?! — диде кер үтүкләп торган апасы, үз колагына үзе ышанмыйча. Аңлап алгач, артсыз урындыкка хәлсез кешедәй чүгеп, көрсенеп куйды. Үтүген кулыннан ычкындырмаган килеш.— Булмаганны, син дә...— дип өстәде.

— Ник, эшлиләр ич әле, ә мин кемнән ким...

— Сөйләмә юкны, атаңның холкы болай да начар, ишетсә, давыл куптарыр.

Фагыйлә, апасына үпкәләп, иреннәрен турсайтты:

— Һаман бер балык башын чәйнисең син дә. Унике яшемдә дә авылга озатканда шул сүзне әйткән идең, инде хәзер унсигез тулганда да шул.

— Юк, атаң белән киңәшләшми булмый, кызым...

— Әллә тагын кырыкка якынлашканда да ата сүзеннән чыкмас идемме?

Шул вакыт аш бүлмәсеннән тәмле ис килә башлады. Газга җылытырга куйган итле аш кайный иде, ахры. Апа кеше газны сүндереп чыкты:

— Анысын белмим, кызым, хәзер киңәшләшергә кирәк, ул ни әйтер бит. Уртак фикергә килергә тырышырбыз.

— Ярый,— дип, апасы белән килешкәнен белгертте һәм Фагыйлә аш бүлмәсенә кереп китте.

Кичен инде ул авылда табын янында утыра һәм, астыртын гына, куркынып, атасына карап-карап ала иде. Бу куркыну юкка түгел: берәр артык сүз ычкындырсаң, Вәли ага коры дары кебек хәзер кабынырга тора лабаса. Күптән түгел әле Фагыйлә институтка имтихан тапшырып та, конкурстан уза. алмагач, өйдә тузынып йөргән-йөргән дә, тышка чыгып, матаен ит тарткыч аша үткәргәндәй иткәч кенә тынычланып калган ул. «Әгәр ул кызының Себергә эшкә китәргә йөргәнен белсә, акылыннан язуы бар»,— дип уйлады Фагыйлә. Ләкин Вәли абзый акылыннан язмыйча, тыныч кына әйтеп салмасынмы шулчак:

— Сине Себергә китәргә йөри, диләр, дөресме бу?

— Дөрес.

— Әй, җитешмәгән! Әй, уңмаган! — дип, урындыгын аударып, өстәл яныннан торып ук китте әтисе. Соңыннан, ачуы беразсүрелә төшкәч кенә, кызы каршына килеп:

— И Фагыйлә, мин сине бит укысын, кеше булсын, дип үстердем! Туган җиреннән аерылган кош шикелле, читтә каңгырып йөрер өчен үстермәдем! — диде.

Бу сүзләр Фагыйләнең күңелен коточкыч өермә эченә алып кереп киткәндәй булды... Фагыйлә, еламаска тырышып, беркадәр вакыт өнсез торгач кына, башын читкә борып, күзләрен агач рам эчендәге зур карточкага юнәлтте. Их, бәхетле чаклары бар иде шул аның. Әнә шул карточкадагы иптәш кызы белән ничек ашкынып тәмамлаганнар иде алар унынчы классны. Инженер булабыз дип, эчтән янып, тыштан ваемсыз, шат булырга тырышып, җиләкләргә дә бергә йөргәннәр иде. Барып чыкмады бит. Бер бәхетсез билет аркасында барча планнар җимерелде. Их, чибәр комсорг, чибәр комсорг, сиңа гына институтның мәрмәр баскычларын санарга язган икән шул. Фагый-

лә хисләреннән арынып карточкадан күзләрен алганда, Вәли абзый инде, маңгаен җыерып, мич каршында папирос көйрәтеп утыра иде. Нәфисә апа самовардан чокырга чәй агызып куйды да, зәңгәр күзләрен Фагыйләгә төбәп, әйтеп салды:

— Хәсрәтләнмә, кызым! Атаң әйтә инде ул, холкы шундый, ә мин, заводка кереп эшләсәң әйбәтрәк булыр, дим.

— Заводка?! — диде Фагыйлә гаҗәпләнеп.— Ә кайсы заводка?

— Курчаклар ясый торганына. Хәтерең дәме? Син бәләкәй чакта курчакларны бик ярата идең.

— Ярата идем,— диде Фагыйлә, күңеле тулып,— ләкин минем курчак фабрикасына урнашасым килми.

— Ә кая урнашырга телисең соң, кызым?

— Белмим әле, бу турыда уйлап карармын, әни.

— Уйлап карармын дисеңме? Хэ-хэ-хэ... Күп уйладың инде син, Себердә дә эшләп кайттың...— Бу баядан бирле сүзгә кысылмыйча утырган Вәли абзый тавышы иде. Фагыйлә, яңа бәла киләсен сизеп, тиз-тиз җыенып, клубка чыгып китте.

Бүген аны Әнәс исемле озын буйлы егет озата килде. Бакча янәшәсендәге имән бүрәнәләр өстенә утырып, байтак кына сөйләштеләр. Әнәс, авыл мәктәбен тәмамлаганлыктан, гел авыл, ә кыз исә гел шәһәр тормышы турында гына сөйләде. Сүз арасында егет:

— Мин дә шәһәргә китәм,— дип куйды.

— Кил шул,— дип җөпләде кыз.— Кала, ни әйтсәң дә, кала инде.

Ул моны шундый кызык итеп әйтте, төнге һава салкыныннан аның тешләре тешкә тими иде кебек. Егет лавсан костюмын салып кызның иңенә япты:

— Юк, Фагыйлә, шәһәргә бөтенләйгә күчмим әле мин, укып чыккач та авылга кайтырга исәп.

— Дөрес, Әнәс, бар кеше дә шәһәргә күчсә, авылда кем калыр!

— Шәһәргә ашкынучылар күчә бирсен.

Әнәснең авыл табигатенә күңеле береккәнлеге кызга да тәэсир итте.

— Мин дә авыл хуҗалыгы институтына керәчәкмен әле,— диде ул.

— Бик әйбәт. Ә кайсы факультетка?

— Белмим әле...

— Минемчә, сиңа агрономия факультеты кулайрак булыр.

— Ә син кайсына керәсең? — дип пышылдады кыз. Егет җавап биргәч, икесе дә тынып калдылар. Әнәс күзләрен көнчыгыш яктан күк йөзенә җәелә барган шәфәкъ кызыллыгына төбәп уйга калды. Ул — үзенең менә җиде җәй колхоз малларын көтүен, эшен яратуын, малкайларның берәрсе яралансанитсә авыруга сабыша язуын — барысын, барысын да кызга сөйләп бирмәкче булды. Хәер, сөйләсә дә аңламаган булыр иде әле аны ике арада йөреп иркә үскән ак кала кызы! Шул вакыт күршеләрнең шпоры коелган карт әтәче бик ямьсез тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Ой! — диде кыз сискәнеп, һәм, тиз генә бүрәнә өстеннән төшеп, капкага ташланды.

— Фагыйлә, бер генә минутка тукта инде,— диде егет, чибәр кызның шәһәрдәге адресын сорамый калуына эче пошып.

Фагыйлә җавап бирмәде.

***

Иртәнге чәй янында Вәли абзый кызыннан ачулы гына сорап куйды:

— Көтүче Әкрәм малае белән күптән йөрисеңме?

Фагыйлә эчә башлаган чынаягын чак кына төшереп җибәрмәде, елардай булып, кызарып, каш астыннан гына җавап бирде:

— Нинди Әкрәм? Нинди көтүче? Һич аңламыйм, әти.

— Аңламыйсыңмы? Бәлки, син, таң атканчы егет белән бүрәнә өстендә утырмадым, дип тә әйтерсең, ә? — Фагыйлә, атасының бу соравыннан хурланып, йөзен аска иде.

— Менә бит,— дип дәвам итте Вәли абзый сүзен.— Институтка керүне булдыра алмады, ә егет белән йөрүне белә, башсыз. Әле егете нинди диген...— Ата кеше кулын түшәмгә таба сузды.— Озын! Ике метрлы!

— Мин иртәтеп кайттыммыни аны. Ул үзе ич...— Фагыйлә инде керфек очларында мөлдерәгән яшьләрен тыеп тора алмады, сулкылдап-сулкылдап үксергә кереште.— Си-и-ин, си-ин, әти... мин кайткан саен тавыш күтәрәсең... Шулкадәрле күрә алмагач, нигә дип...

— Их-ма! — дип, мич каршыннан сикереп торды Вәли абзый һәм кул астына эләккән фарфор касәне идәнгә орып ныклыгын сынады.— Бердәнбер өметне дә аклый алмагач, нигә үстергәнмен, белмим. Үз башыма хәсрәт булсын өчен, мөгаен,— дип сөйләнә иде әле ул.

Фагыйлә инде атасына карап торырлык хәлдә түгел иде. Ул, күзләрен йомган килеш, битеннән бертуктамый аккан яшьләрен дә сөртергә онытып, өстәлгә капланды да: «Башка ка-йтмыйм»,— дип үкседе.

Баядан бирле ут йотып табын янында утырган Нәфисә апа да түзмәде:

— Җитәр, атасы, бердәнбер кызыбызны туган өеннән биздерәсең ич инде,— диде.

Вәли абзый аңа күтәрелеп тә карамады, борын эченнән генә мыгырданып:

— Юньле бала — озын гомер, юньсез бала — кара күмер,— дип куйды. Нәфисә апа кызының аркасыннан кагып, юата-юата ак өйгә җитәкләп кертә киткәч кенә, Вәли абзый ишегалдына чыгып папирос кабызды, ике-өч минут үзенә урын таба алмый әрле-бирле йөренде. Аннан бер утын бүкәне өстенә килеп утырды да, арттырыбрак җибәрдем, ахры, кыз кешегә алай ук әйтү кирәк түгел иде дә, ярый инде, шәһәргә озатканда юлына утыз сум акча бирермен, дип, күңелен тынычландырды. Шул тынычлыгын саклаган көе, төпчеген сулы чиләккә ыргытып, эшкә китте. Ә кичен эштән кайтканда инде өйдә Фагыйлә күренми иде. Өстәлдә бары тик: «Сагынсагыз, рәсемемне алып карарсыз»,— дигән язу гына калган иде. Шуннан соң кыз авылга кайтмый башлады. Ата белән ана бу хәлгә бик борчылдылар һәм: «Фагыйлә менә кайта, менә кайта»,— дип, берөзлексез вак яңгырлар сибәләп торган көзләрдә дә, күз ачкысыз әче буранлы кышларда да, беренче сыерчыклары белән йөрәкләрне яшәртеп җибәргән язларда да, хуш исле үләннәре, чәчәкләре белән дөньяны матурлыкка төргән назлы җәйләрдә дә көттеләр. Әмма кыз кайтмады. Кыз кайтмагач, бәлки, хат ташучы газета белән бергә хат калдырыр дип тә өмет иттеләр. Ләкин барысы да бушка булды. Теге чакны, авылдан күз яшьләрен агызып киткәч, Фагыйләне шәһәрдәге җизнәсе дә өнәми генә каршы алган булган икән. Салып кайткан вакытларында, Вәли абзый кебек, ник укымыйсың, дип, теңкәсенә тиеп беткән. Кыз бик хурланчык булганлыктан, бу мәсхәрәләүләрне күтәрә алмаган, нәтиҗәсе шул, көннәрдән бер көнне каядыр китеп югалган. Кая киткән, моны беркем дә белмәде. Милициягә дә хәбәр итеп карадылар. Ләкин кыз, чынлап та, суга төшкәндәй юкка чыккан иде. Вәли абзый әле һаман кызының табылуына өметен өзмәсә дә, Нәфисә апа инде кысыр сөенечләргә кулын селтәгән, Фагыйләнең һәлак булуына ышанган иде.

***

Шушы вакыйгалардан соң җиде ел үтте. Бу вакыт эчендә күпләрнең чәчләре сирәгәйде, йөзләре җыерчыкланды, кашлары

бәсәрде. Вәли абзый менә, саусызланган йөрәген дәвалатыр өчен, санаторийга китәргә җыена... Нәфисә апа ирен пристаньнан озатып калырга тиеш. Автобус белән райүзәккә килеп төшкәч үк, туры шунда юнәлделәр. Дебаркадер баскычын менгәндә, моңсу чырайлы Вәли абзый сул яктагы коңгырт утыргычка ишарәләде:

— Ял итә тор, Нәфисә! Мин хәзер, билет кына алам да...

— Бар, бар, Вәли!

Нәфисә апа ипләп кенә урнашкач, күзләрен як-якка йөртеп, тирә-юньне күзәтә башлады.

Кама елгасының мәһабәт ярлары, ташлы кыялары, яшеллеккә күмелгән вак-вак утраулары тагын да матуррак, тагын да нәфисрәк булып күренде аңа бу иртәдә. Әнә еракта, кояш нурлары белән җемелдәшкән дулкыннар арасыннан юл ярып, бирегә таба бер ак нәрсә йөзеп килә. Пароход бу. Озакламас, ул килеп җитәр дә сөекле Вәлиен ерак җирләргә алып китәр. Аһ! Нәфисә тагын ялгыз калыр...

Шул мизгелдә су өстендә акчарлаклар пәйда булды. Алар, үзләренчә нидер кычкыра-кычкыра, якыннан гына очып үтеп, каядыр юкка чыктылар. Тик төркемнән аерылып калган бер акчарлак кына, Фагыйләнең теге чактагы елавын хәтерләткән яшь һәм нечкә тавыш белән, үзәкләрне өзеп, дулкыннарга ташлана-ташлана оча бирде.

«И балакаем,— дип уйлады ана.— Син дә шушы кош сыман рәхимсез дулкыннарга ташланып очасың микән?! Әллә инде канатларың талып егылдыңмы? Шуңа эндәшмисеңме?..»

Вәли абзый әйләнеп килгәндә, Нәфисәнең кап-кайнар яшьләре юл-юл булып ага иде.

— Чү! Ни булды сиңа? Әллә...— Абзый сүзен әйтеп бетерә алмады, кинәт кенә тирә-юньне тутырган көчле су шавы һәм нәрсәнеңдер дөп-дөп килеп гүелдәп эшли башлавы аны шул якка борылып карарга мәҗбүр итте. Дебаркадерга галәмәт зур бер теплоход якынлашып килә икән. Менә инде ул яны белән дебаркадер бортына килеп орынды. Дебаркадер палубасы, мондый зур көчкә каршы тора алмыйча, чайкалып куйды. Кешеләр дә, йокыдан кисәк кенә уянгандай, сискәнеп киттеләр һәм ашыга-кабалана дебаркадер капкасы янына килеп тезелделәр.

Өстенә елга хезмәткәре формасы кигән олы яшьтәге бер ир капканы ачып җибәрүгә, теплоход палубасында торган кешеләр дә чыга башлады. Әнә ике арада сөенечле кавышу, бәхетле очрашу авазлары... Вәли абзый, күңеле тулып, бер почмакка китеп басты да кесәсеннән папирос алып кабызды, ләкин төтен аның йөрәген тагын да ныграк хәлсезләндерде. Вәли абзый чүгеп куйды һәм урындыкка утырды...

— Их! Язмыш, язмыш... Уналты яшемнән читкә китеп азмы нужа күрдем. Унсигез яшемне Ленинград фронтында ут эчендә каршыладым. Илле биш яшемне дә менә читтә, санаторийда каршыларга туры килә. Борынгылар: «Саулык — байлык»,— дигән. Дөрес икән шул...

Вәли абзый түбән иелгән башын күтәреп алга караса, бермәлне үзенә якынлашып килгән ике хатын-кызның берсе Нәфисә, икенчесе Фагыйләгә охшаш булуын күреп, урыныннан торып басты, һәм шул мизгелдә кыз тирә-юньне яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Әти! Исәнме, әти!

Бу сүз Вәли абзыйны баш түбәсенә күсәк белән орган кебек итте. Ул шаккаткан җиреннән йөрәген тотып хәрәкәтсез калды да сүнеп барган күз карашын әле зәңгәр чиксезлеккә, әле кояш нурлары белән каймаланган матур үзәнлекләргә төбәгән көе акрынлап-акрынлап кына палуба идәненә чүгә барды. Фагыйлә:

— Әти, әти, нишләдең? — дип, атасына барып ябышты. Әмма Вәли абзый җавап бирмәде. Аның иреннәре кара көйгән, күзләре йомык, йөзендә нур әсәре калмаган иде. Фагыйлә тиз генә кулын капшап карады: пульсы да бик зәгыйфь икән. Кызның башыннан яшен тизлегендә «приступ» дигән уй йөгереп узды. Мондый чакта кеше гомерен секундлар хәл итә: «Менә минем чемодан! Мин аны хәзер ачам! Шприцны алам да...»

Фагыйләнең уйлары йөгерек, куллары җитез иде. Җыелган халык аңа сокланып карап торды.

Биш минут чамасы вакыт үтте...

Ниһаять, укол үз эшен эшләдеме, әллә башка бер сәбәптәнме, Вәли абзыйның керфекләре кыймылдашып куйды һәм ул, күзләрен ачып, бермәл җыелган халыкка текәлеп торгач, эшнең нидәлегенә төшенеп, кызының ярдәме белән урыныннан, күтәрелде.

— Беткән идең ич инде Фагыйлә булмаса,— диде хатыны, яшь аралаш.

Вәли абзый шунда гына кызын күкрәгенә кысты һәм, чыланган яңагын аның бөдрәләткән чәченә орындырып:

— Бөтенләйгә кайтуыңмы, кызым? — диде.

— Бөтенләйгә, әти.

— Алайса, мин санаторийга китмәм инде. Хәзер врач үзебез белән. Әйдәгез, өйгә кайтыйк!

Әлегә хәтле сүзгә кысылмыйча түзеп торган Нәфисә апа, теплоход китәргә гудок биргәч, ире кире уйлар да санаторийга китеп барыр дип, ахры:

— Безнең монда эш бетте. Тайыйк тизрәк! — диде.

Нәкъ авылча итеп әйтелгән әлеге сүзгә Фагыйләдән дә ныграк сөенүче булмагандыр. Менә, юл күрсәтүче маяк кебек, ул ярга алдан атлады. Бераз гына туктап, әтисе белән әнисен көтеп торды. Аннан, өчәүләшеп, сөенешә-сөенешә үргә менеп киттеләр. Озак та үтмәде, аларның күзләренә үзләре яши торган Елга авылының яшелле-кызыллы өй түбәләре дә күренде.

## *Мин болгар?*

Брежнев вакытында паспортымда башка милләт исеме йөреп яшәгән дә яшәгән икән мин әрәм булып. Горбачев властька килгәч кенә чын дөреслекне белдем: мин болгар икән бит!

Бу турыда Әхми күршемә сөйләгән идем. Ул хәйләкәр генә ;лмайды да:

— Алайса, Дәүли дус, мин дә болгар! — дип куйды.

— Ю-ук, мин әйтәм, Әхмәт, син болгар түгел, синең аяклар бик тә кәкре...

— Алайга китсә, син дә болгар түгел,— ди Әхмәт.— Синең күзләрең кысык, явыз татарга охшагансың.

И хурландырды мине Әхминең бу сүзләре, и хурландырды... Ачуыма чыдый алмыйча, тоттым да Әхми күршемне судка бирдем.

*«...Шулай-шулай,— мин әйтәм,— күршем мине көндә кыргый татар дип мыскыллый. Явыз татар түгел, зирәк болгар мин! Минем укымышлы болгар бабайларым дөньяда беренче булып чуен койганнар, калаларының капкаларын гел алтыннан гына ясаганнар. Бу турыда күп сөйләделәр инде, калганнарын әйтеп тормыйм. Дорфа күршемне җавапка тартуыгызны үтенәм!»* дип яздым.

Анда бит тегенди-мондый гына кешеләр утырмый," башлы кешеләр утыра. «Ярар, абзый, карарбыз, өйрәнербез, җавап бирербез»,— дип, гаризамны алып калдылар.

Ике атна үттеме, юкмы, судка чакырдылар. Бардым. Әхми дә килгән икән.

— Нихәл, болгар! — дип көлгән була.

— Авызыңны җыр әле, җыр,— мин әйтәм,— кыпчак калдыгы!

Менә суд башланды. Иң элек пыркарур торып сөйләде, аннары Каф тау борынлы бер галим. Шул галим әйтә:

— Бүгенге болгавыр заманда болгар булу юньлелеккә илтми, татарлыкны саклап калырга кирәк...

Аһ, имансыз хәзәр калдыгы... теленә тилчә чыккыры...

— Син... үзең кем соң? — мин әйтәм.

— Мөселман! — дип ычкындыруын тоймый да калды бичара галим. Судья, мескен, кып-кызыл булды һәм:

— Болай булгач, сезнең эшне өйрәнүне ярман кәмпүтеренә тапшырырга туры киләчәк,— диде.

Мин рәхәтләнеп риза булдым. Мин риза булгач, Әхминең ризалыгын сорап та тормадылар. Кайтып киттек икебез ике урамнан...

Ярман кәмпүтере эшне ай-һай кызу тота икән: өч көннән безне чакыртып та китертте. Килдек, Әхмәт миңа карамый, мин — Әхмәткә. Күзләребез ярман кәмпүтерендә генә...

Әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, ярман кәмпүтере мине болгар итсә, шушы кәмпүтерне ясаган нимес иптәшкә ике дә уйламыйча бер пот урман чикләвеге җибәрәм — үзем җыйганны!

Пыркарур, минем уйларны сизгәндәй, ялт кына ниндидер төймәгә басты, экранда ут кабынды.

— Менә җавабы — укыгыз! — диде ике иякле судья.

Укыдык. Шундук ярсып киттек. Ярман кәмпүтере безгә «урыс» дигән мөһер суккан иде.

— Нишләп урыс булыйм мин?! — дип кычкырына башлады Әхмәт.— Мөселман мин, мөселман!

— Мин дә мөселман,— дип акырдым мин.— Ярман кәмпүтере безгә яла яга. Ярман кәмпүтерен — судка!

Шуннан соң безнең эшне япун кәмпүтеренә йөкләделәр. Япун кәмпүтере безне бер атнадан соң гына чакырды. Килдек. Әхми бөгелә-сыгыла сәлам бирде япун кәмпүтеренә. Мин дә бирдем сәламне. Их, мин әйтәм, эчемнән генә, әгәр дә син, кәмпүтер иптәш, минем болгар булуымны танысаң, ярты байлыгымны бирер идем сине уйлап тапкан даһи япунга.

Ниһаять, яшел күзле пыркарур бәллүр төймәгә басты, көмеш пыяла эчендә аксыл ут кабынды. Ләкин... атаклы япун кәмпүтере «сез төркиләр» дигәннән узмады.

Шулай да мин җиңел сулап куйдым. Чыкмаган җанда өмет бар, диләр бит. Кем белә, бәлки...

— Йә... җаваптан икегез дә канәгатьме? — дип сорады судья, сөенеченнән кояштай балкып.

Әхмәт канәгать иде шикелле. Тик мин генә тулысынча килешмәдем.

Шуннан соң безнең эшне болгар кәмпүтеренә тапшырдылар.

Болгар кәмпүтере безне өч ай интектереп йөртте. Дүртенче айга чыкканда, Әхмәт түзмәде, үлеп китте. Күршемне соңгы юлга озатыша бармадым. Йөрәгем нидер сизенде, чөнки күршемнең килене марҗа иде. Менә шул марҗа килен каенатасын урыс зиратына илтеп күмдергән бит, әй!

Минем дә бер киленем марҗа, ике киявем урыс. Үлгәч, мине кая илтеп күмәрләр икән?

Чү! Болгар кәмпүтереннән чакыру кәгазе җибәргәннәр түгелме соң? Әйе ич...

Бу юлы судка ашкына-ашкына килдем. И, мин әйтәм, болгар кәмпүтере минем болгар икәнемне исбатлап күрсәтсә, шул кәмпүтерне уйлап тапкан болгар егетенә бөтен байлыгымны бирер идем, төпчек кызымны да өстәп бирер идем хәтта!

Ниһаять, пыркарур дулкынлана-дулкынлана чынаяк төймәгә басты. Бакыр пыяла эчендә яшел ут кабынды. Җавап әзер.

Экранда:

— Иң борынгы әби-бабаларыгыз — маймыллар! — дип язылган иде.

## *Зимагур, кибетче һәм шофер*

—Зимагур Фәтхул кайткан, ди. Баеп кайткан. Кибет янында ир-атларны аракы белән сыйлаган. И кинәнгәннәр икән ирләр аракы эчеп...

Әнисенең бу сүзләрен шыпырт кына, куркып кына тыңлап ятты Шүре Салих, чөнки кичә кибет янында аракы белән сыйланучылар арасында ул да бар иде. Башта өч кешегә бер яртыны, аннары ике кешегә берне, соңыннан кеше саен берәрне эчтеләр. Шуннан соң кайберәүләр өйләренә кайтып китте, кемнәрдер чирәм өстенә авып гырлый башлады, ә мәлҗеп төшмәгәннәр — яшьрәкләр Фәтхулның үнәрләрен карарга кереште.

— Мин — Жабатинский! — диде Фәтхул. И$_4$»ләр ышанмады. Фәтхул ашыкмый гына күлмәген салды. Җирдә яткан зур ак ташны күкрәгенә куйды, аннары баш очына күтәрде. Мужиклар ләм-мим сүз әйтмәде.

— Мин — Брумель! — диде Фәтхул. Тагын берәү дә ышанмады. Карт егет чалбарын салды һәм урманчы ирнең җигүле аты аша сикерде. Мужиклар ул-бу сиздермәде.

— Мин — Кашпировский! — диде Фәтхул. Бусында тик Салих кына ышанмады. Ничек инде татар Фәтхулы урыс Кашпировские була алсын, янәсе.

— Китер балта, ышанмасаң...— дип боерды ата зимагур.

Салих шундук йоклап яткан бер ирнең кулыннан плотник балтасын алды, Фәтхулга китереп бирде. Ә бай кунак балтаны баш очына күтәрде дә беләгенә чапты...

***

Фәтхулның беләге төнозын үтереп сызлады. Аптырагач-йөдәгәч, Фәтхул Гыйматдин абыйсына килеп егылды. Гыйматдин абыйсының әле таң атар-атмаста ук өендәге товар-фәләннәргә

ревизия ясап йөргән чагы иде. Ник дигәндә, кибете кечкенә, склады да юк, ә планны бирә белә түрәләр: планны ничек тә үтәргә кирәк ич, шуңа күрә Гыйматдин абыйга товар-фәләннәрнең күбрәк өлешен өендә сакларга туры килә дә инде. Кем белә, бәлки, кибетнең склады булмау Гыйматдин абый файдасына гынадыр әле, балыкчы чанасында яткан төлке сыман, уңлы-суллы үз кесәсен генә караштырып йөридер ул, мескенгә сабышып. Кибеттә эшли башлагач бөлеп беттек инде, дип сөйли икән авылдашларына, хәйләкәр. Гомер булмаганны ямаулы кием кияргә керeште, бала-чагаларының да кием-салымнарында ямалган урыннар күбәйде, ләкин аның каравы барысы да көрәеп китteләр...

Фәтхул үкереп диярлек килеп кергәч, Гыйматдин абый, язу-сызуларын куеп торып, энесен ияртеп, шофер Салихның капкасын барып какты.

— Әйдә, энекәш, парктан апкайт машинаңны, менә күрәсең ич Фәтхулның хәле мөшкел, аны бүльнискә илтәбез дә кайтышлый сәүдә берләшмәсенә кагылып товар төйибез...

«Сәүдә берләшмәсе» сүзен ишеткәч, шофер Салихның махмыры бетеп киткәндәй булды, чөнки сәүдә берләшмәсенә баруларның тәмен татымаган кеше түгел ич ул. Тик шунысы бар: Гыйматдин кибетче белән сәүдә берләшмәсенә барып кайткан көннәрдә, Салихның күңеле хуш була, ә өйдәгеләрнең киресенчә котлары алынып тора иде. Бит сәүдә берләшмәсенә барып кайтканның төнендә Салих белән Салих түгел, ә шайтан идарә итә...

— Салих! — диде Шайтан.— Хатыныңның авызына кәнфит каптыр әле, күп сөйләнә башлады.

— Хәзер! Мин аны...

— Әниеңне, дә тый!

— Баш өсте...

— Өеңә, өеңә ут төрт!

— Тыңлыйм...— дип өтәләнеп, шырпы эзләргә керешә Салих.

Ә бу вакытта Гыйматдин абый, гадәттәгечә, ялт-йолт карана-карана, кыек юлда йөреп тапкан малны урнаштырып яткан була инде.

Менә шулай...

Ярты сәгатьтән инде зәңгәр йөк машинасы, кырлар юлы буйлап тузан туздыра-туздыра, районга таба җилдерә иде.

Фәтхулның күзләренә ак-кара күренми, офтана да офтана, ай да вай килә.

Гыйматдин абый, битләрен алландырып, тавык күзләрен хәйләкәр генә кыскалап:

— Ну, энекәш, кулыңа бер шешә аракы тоттырсам, сыкранудан туктар идең инде түлке! — диде.

— Кирәкми, абый, үзеңә булсын...— диде Фәтхул, маңгаен җыерып.— Хәтта шәрә кыз мутланып ятса да исем китми, кулым сызлый... Икенче кулга да күчте инде әллә?..

— Ташласана,— диде Гыйматдин абый, соры эшләпәсенә күмелеп бетә язып,— авызыңнан җил алсын, шәрә кыздан ваз кичәргә ашыкма әле син.

— Кызы нинди бит...— дип сүзгә катышты Шүре Салих.— Акылдан ниткән кыз булса гына инде, юньле кыз алай шәрә ятмый ла ул.

— Юньле кыз шәрә ятмагач, каян килгән соң алай булгач без, гел юньсез кызлардан гына туганмы? — дип, чынлап торып ачуланып кычкыра башлады Гыйматдин абый.

Шофер Салих бераз гына дәшми-нитми барды да машинасы тигезлеккә чыккач әйтте:

— Никахлы ир янәшәсендә яту белән, һәммә кеше күз алдында аунап ятуның аермасы — җир белән күк шикелле аның, Гыйматдин абый...

— Беләм, беләм,— дип кырт кисте кибетче, син үз хатыныңнан көнлисең, шуңа күрә бу турыда сөйләшәсең килми...

— Минем ул турыда уйлап баш катырганым да юк,— диде Салих ачуланып,— минем хатын тапланмаган, намуслы һәм мин үзем дә шулай ук кер кунмаган, намуслы ир: хет егет чакта булсын, хет хәзер кеше ярларына ялгышып кына да орынганым юк һәм минем Азиләм дә шулай ук...

— Шулай ук микән? Ялгышмыйсыңмы икән, энем? — диде Гыйматдин абый, мәгънәле генә итеп, Фәтхул ягына таба ишарәләп.— Менә бу тәти егет кулыннан үтмәдеме икән әле ул синең хатының — кияүгә чыкканчы, ягъни мәсьәлән...

Азиләнең кыз чагында Фәтхул белән бераз гына йөреп алуы хак иде анысы. Әмма эшләр алай ук тирәнгә киткәндер дип башына да китереп караганы юк иде әле Шүре Салихның. Менә хәзер Гыйматдин абый шул турыда сүз кузгаткач, яшь ирнең тыныч йөрәгенә әллә ни булды: куллары дерелди-калтырый башлады, күзләрен кан басты һәм ул кинәт тормозга басты да машинаны шып туктатты, сикереп төште, Фәтхул утырган якның ишеген ачып:

— Дөресме, булдымы шундый хәл, булдымы?! — дип, ярсып-ярсып кычкырырга тотынды.

— Саруымны кайнатып бетердегез инде шул хатын-кызларыгыз белән, тәмам косасыларым килеп бетте инде,— дип мыгырданды Фәтхул, яралы беләген күкрәгенә кысып.

— Юк, син боргаламыйча гына минем сорауга җавап бир: Азилә белән булдымы шундый хәл, булдымы-ы?..

Шүре Салихның арыслан булып маташуы ошамады әзмәвер Фәтхулга һәм ул:

— Булды ди, йә, булса, шуннан ни була,— дип, мыскыллы елмаеп әйтеп ташлады.

— Ә-ә, булдымыни-и-и? Шуннан ни бу-ла-мы-ы?! — дип эләктереп алды Шүре Салих.— Шуннан шул була...— һәм ул Фәтхулны машинадан сөйрәп төшерде, Гыйматдин абыйны да бер читкә тибәреп, яшен ташыдай атылып кереп, руль артына утырды. Шуннан, син күр дә мин күр, зәңгәр йөк машинасы кыр юлы буйлап китеп күздән гаип тә булды.

И куып та карады соң Шүре Салих машинасын. Машинаның көпчәкләре тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә юк!

Һәм менә машина авыл урамнары буйлап чаба инде: күпергә керде, түбән очны артта калдырды, җәйләүгә таба борылды.

Әле иртәнчәк кенә сөеклесе булган, хәзер инде җене сөймәс әшәке, сөйрәлчек хатынга әверелгән Азиләне Салих бидоннар янына сөт тулы ак чиләкләр күтәреп килгән чагында очратты.

Азилә тукталып:

— Ник иртә кайттыгыз, районга бармадыгызмы әллә, Салих? — дип сорады.

Ә ир исә җавап урынына, ажгырып килә-килешкә, дәшмитынмый гына, Азиләнең сокланып карап туймаслык сөйкемле, чибәр йөзенә сугып җибәрде. Яшь хатын егылды. Ә яшь ир аны типкәләргә, изәргә тотынды.

***

Хастаханәдә озак, бик озак ятты Азилә. Салих та, кулга алынып, изоляторда утырды. Гыйматдин абый белән Фәтхулны да милиция читтә калдырмады. Берничә айдан инде «Азилә эше» буенча, төрле-төрле документлар белән дүрт папка шыплап тулган иде.

Шулай да бу «четерекле эш»тә төп гаепле кеше кем соң? Шаһитнамәләр исә Шүре Салихның гаепле булуын әйтә. Ә Салихның әнисе «Фәтхул!» ди.

Чынлап та... Фәтхул кайтмаган булса, Салих әле һаман Азиләкәе белән матур гына яшәп яткан булыр иде, дип куялар кайберәүләр.

Шулай итеп, суд ясап, Салихны берничә елга төрмәгә яшереп куйдылар.

Кибетче Гыйматдин исә бүтән шофер белән дуслашты.

Ә Азилә Фәтхулга, яшьлек мәхәббәтенә ияреп, читкә китеп барды.

## *Рәхмәт, сандугач!*

Чигәләре вакытсыз чаларган Кәрам Гәрәевич кызгылт таза куллары белән олы тәрәзәләрне як-якка каерып ачып җибәрүгә, заманча бай җиһазлы тынчу кабинет эченә дымлы, җиләс язгы һава ургылып керә башлады. Җил үзе белән Идел тарафларыннан төче су исен, шәраб заводы ягыннан — әчкелт исләр һәм Яңа бистә бакчаларыннан чия, шомырт, алмагач чәчәкләре исләрен дә ияртеп килгән иде. Бу исләр — кайчандыр булып үткән күңелле чакларны искә төшерәләр, йөрәкне каядыр барырга, китәргә ашкындыралар, җилкендерәләр, һәм шулай ук нәрсәләрнедер эшләмәскә дә кушалар, кисәтәләрдер кебек.

Ул да түгел... өздереп-өздереп сайраган сандугач тавышы ишетелә башлады, һәм шул чакны... Алия пәйда булды!

Гел югарыга карап кына хөкем вә шөкер итә-итә яшәргә күнеккән бухгалтер-йөкләмәче ханымны күрүгә, нәчәлникнең кырыс, арыган, талчыккан йөзе юып алгандай яктырып китте.

Менә ни өчен бу.

Контор каршында гына бихисап тимерләр, торбалар арасында ялгыз тирәк үсеп утыра. Шул тирәдә үк сүтеп, ватып, кисеп, ябыштырып әвәрә килгән эшчеләр кырда, бодай диңгезе уртасында калкып торган ялгыз агач төбенә оя ясап урнашкан тынгысыз кырмыскаларны хәтерләтәләр. Кырмыскалар табигать бизәге булган ул агачтан күп файда күрсәләр, монда эшчеләр, киресенчә. Чөнки монда үсеп утыручы тирәк гүя эшче халкының дошманына әверелә. Чөнки ул игътибарны гел үзенә юнәлттерә, әллә кайда, күңел төпкелендә яшеренеп яткан самими хисләрне, тойгыларны кузгаттыра: шуннан тимер-томырга булган күңел җылысы сүрелә төшә дә, баш инженерның ике алтын теше елтырап торган авызыннан «Аһ, йөкләмә?!» дигән чиркандыргыч сүзләр чыгып, хуҗаның болытлы йөзен тагын да төмсәләндереп, йодрыгын йомарлатып, өстәлгә суктыра, һәм куба давыл, чыга өермә, күтәрелә тузан: «газраил» кабинетының ишекләре ачыла да ябыла. Анда йә бригадир калтырап кереп югала, йә мастер, йә...

Чираттагы бер өмәдә нәчәлник хәсис тирәкне төбе-тамыры белән йолкытып ташлатмакчы иде инде, өстәмә акча түләп. Аны бу дуамал ниятеннән ваз кичеп торырга Алия генә мәҗбүр итте. һәм иллә дә дөрес эшләгән икән. Әнә ич ялгыз «шпион» тирәкнең хисапсыз яшел чуклары арасыннан «фить-фить, тьютью» итеп сандугач сайраганы ишетелә!

Кәрам Гәрәевич, моңарчы булмаганча, җылы карашын плановик ханымга төбәде һәм бәрхеттәй йомшак тавыш белән:

— Алия! — диде.

Көмешләнә башлаган коңгырт-кара чәчләрен ясалма бөдрәләткән Алия, кыюланып, уң кулына тотып кергән эштән китү турындагы гаризасын, нилектәндер колакларына чаклы кызарып, өстәлгә куйды. Аның курку дәрәҗәсенә җитеп дулкынлана башлаганын матур күзендә һәм түгәрәк йөзендәге сәер үзгәреш кенә түгел, дер-дер итеп калтыранырга тотынган килешле генә аяклары, озын бармаклы ак куллары да сиздереп, белгертеп тора иде сыман.

Мәгәр нәчәлник икеләнергә урын калдырмады, теге кәгазьне алып укып, аннары вак-вак кисәкләргә ертып кәрзингә ыргытты.

— И син минем кадерлем! — диде. һәм өздереп Алиягә карады.— Мин... бу турыда сиңа... күптән инде... тик... аны әйтергә уйлап та, ни өчендер кыймыйча, һаман иртәгесе көнгә калдыра килдем... Инде менә хәзер... бу чуалчык мәсьәләне, һичшиксез, чишәргә кирәк дип саныйм!

Алия еларга да, көләргә дә белмәде. Аның сөрмә тарткан озын, әмма сирәгәйгән кара керфекләренә төбәлеп тә, җир җиләге төсле иннек яккан уймак иреннәренә багып та, максатына туры килгән яшәү рәвеше өчен, кичә кабул иткән ниятеннән кире кайтырга әзер икәнен аңларга була иде.

Хуҗа дәвам итте:

— Чын-чынлап, Алия... Үтенеп сорыйм синнән! — һәм ул, укытучы каршында басып торучы гаепле укучы сыман, ярдәм өмет иткән шикелле, очкынлы карашын кинәт ишеккә юнәлтте.— Болай... газапланып, тәмуг утларында янып, аерым-аерым гомер кичергәнче, кушылыйк та яшик бергә-бергә матурларга тиңдәш булып...

Алар, урта мәктәпне тәмамлаганчы, бер сыйныфта укыдылар. Төрле институтларда белем алганнан соң, байтак еллар үткәч, юллары янә шушы төзелеш идарәсендә кисеште. Дистә еллап бергә эшлиләр инде алар монда. Алия — кыз, Кәрам Гәрәевич ул үстереп җиткерде. Хәзер кызның да, малайның да аерым-аерым үз тормышлары. Тик менә Алия белән Кәрам Гәрәевичнең генә, кем әйткәндәй, тормыш иптәшләре вафат.

Ниһаять, плановик-йөкләмәче ханым:

— Мин — риза! — диде.

Алия, сөенеченнән бер карышка үскәндәй, канатланып чыгып китүгә, хуҗа, кош сайраган якка карап:

—Рәхмәт, сандугач! — дип пышылдады.

Шимбә көнне алар язылыштылар.

Ә чәршәмбе өмәсендә Кәрам Гәрәевич тылсымлы ялгыз тирәк янәшәсенә тагын бер яшь тирәк утыртты.

## *Тирес*

Кечкенәдән тирес арасында үсеп, механизатор булгач та, фермада кайнашып йөри торгач, тәмам тирес исе сеңеп беткән иде үземә. Кичләрен клубка менгәч тә, бергә эшли торган Вәсимәгә хәтле: «Читкәрәк кнт әле, Ислам, туйган инде ул тирес исеннән»,— дип, мине яныннан куып маташкан була. Әйтерсең лә аңардан гына хушбуй исе килә, аңардан бер дә тирес исе килми. Шулай эчемнән генә җенләнеп, тузынып маташканда, күзем Кәримәгә төште. Кәримә калада аромат фабригында эшли иде. Тоттым да янына барып утырдым мин моның. Менә, ичмаса, әйбәт кыз, ялгышып кына да тирес сүзен искә алмый, һәм мин, кыюланып китеп, Кәримәне биергә чакырдым. Ә инде клубтагылар тарала башлагач, өенә үк озатып куярга булдым үзен.

Күпергә килеп җитәрәк:

— Ну ничек соң, Ислам, эшләр барамы? — дип сорап куйды бу.

— Барганда бара, бармаганда торып тора инде,— мин. әйтәм...

— И-и, Ислам, йөрмә монда авылда тирес арасында хур булып. Кит калага, урнаш аромат фабрикасына: кеше булырсың!..

— Анда кайда торырмын соң мин?

— Башта фатирда яки тулай торакта. Аннары...

— Бүлмә бирәләрме?

Һәм мин тәвәккәлләдем.,.

Кәримә белән унбиш ел матур гына, тату гына яшәдек. Малай белән кыз үстерәбез. Фатирны да иң югарыдан — ундүртенче каттан алдык. Мин бәхетлеме? Белмим! Рәхәт яшимме? Анысын да әйтә алмыйм. Әгәр дә илдә үзгәртеп кору җилләре исә башламаган булса, мин әле үземнең кол икәнлегемне дә **БЕЛМИ** яшәгән булыр идем. Белдем һәм көннәрнең берендә бу ***эштән*** китәргә булдым. Бөтенләйгә! Югыйсә аромат фабри**касында** төп-төгәл егерме ел эшләгән идем... йөк төяүче булып.

Киттем. Артымнан озатып калучы булмады,

Кайттым. Нindидер бер рәхәт хис күңелемне кытыклапмыкытыклый, гел күләсем генә килеп тора. Әйе, мин азат хәзер, менә шушы сәгатьтән башлап, берәүгә дә буйсынмаячакмын. Миңа берәү дә: «Әй, грузчик, монда кил, әй, грузчик, тегендә бар,

әй, грузчик»,— дип, уртага ярылырдай булып кычкырмаячак. Мин ирекле, шайтан алгыры!

Ишектә егерме ел бер түшәкне бүлешкән хатыным Кәримәнең көл төсенә керә башлаган чырае күренде, күзләре шак*мактай* иде. Сөекле балаларым да миңа аркалары белән борылып бастылар. И-и, мин бит ат кына булдым алар өчен, гади эш аты гына! Хәер, юньле адәмнәр атны да иркәләп сөяләр, *ә миңа* гел камчы гына эләгә бу фәрвайсызлардан. Әнә башладылар да инде. Хатыным «ахмак», дип, балаларым «юләр», дип тетепме тетә. Янәсе, дөньяның асты-өскә килеп яткан бу заманда, башында җил сызгырмаган адәм үз теләге белән эштән китәме инде?!

Мин башта хурланып, аннары боларны кызганып, тавышсыз гына елап җибәрдем. Димәк, болар да тәмам кол бу-лып беткәннәр икән. И мескеннәр, и мескеннәр...

Һәм мин, югары уку йортлары студентлары өчен чыккан философия китабын алып, диванга кырын яттым. Исәбем Ленин төзегән социализмның тереклеген фаш итү иде. Мәгәр китабымның марксизм-ленинизм институтында әмәлләнгәнен күргәч, ачуымнан чәчләрем үрә торды. Гафу итегез, минем чәчләрем юк, пеләшем елтырый, ягъни тирли башлады, диюем инде. Шуннан соң мин яшел тышлы китапны карават астына тотып томырдым. Хәзер аның беркемгә дә хаҗәте юк, ятсын әле шунда тузан җыеп!

Шул вакыт күрше бүлмәдә сөекле хатынымның яшеллекүкле тавышы ишетелде: «Ашатмыйм!» Ә мин күп уйлап тор**мадым,** тоттым да ачлык игълан иттем: коллар илендә кол булып яшәгәнче, үз фатирыңда ирекле һәм азат булып, ачлыктан үлүең мең мәртәбә әйбәтрәк ич!

Кичке ашны да ашарга чыкмадым. «Кил инде, кил»,— дип ялына-ялына тамаклары карлыгып бетте тегеләрнең. «Икейөзләнмәгез,— мин әйтәм,— бая әйткән сүзләрегез тамагыма сөяк булып тыгылды, соң инде хәзер, бернишләп булмый, бигайбә!» Һәм мин иртәнге чәйгә дә тормадым: яттым да яттым уйланып, фәлсәфә корып: «Бу эт тормышын үзгәртеп буламы? Булса, ничек итеп?»

Шулай ике көнем үтеп китте. Мин ачыктым,ябыктым. Ачыккач, ябыккач баш әйбәт эшли икән ул! Күңелем дә нечкәргәннән-нечкәрә, әллә ниләр искә төшә, гел елыйсым гына килеп тора. Пышын-пышын гына түгел, үксеп-үксеп, кычкырып-кычкырып елыйсым килә минем хәзер.

Өченче көнне хатыным белән балаларым авылга — Яңа елны каршыларга кайтып киттеләр. Мин кайтмадым: кеше кол

дереп авылда үләсем килми әле. Минем шикелле пеләш философлар авылда туа, калада үлә бит алар...

Шулай да үләсе килми, каһәр! Әнә бит, каршыдагы йортның түбәсендә америка өрәңгесе үсеп тора. Яшисе килгәч аптырап калмаган, түбәгә үк менеп үскән! Америкадан килеп бит әле... һәм минем күңелдә кызык кына бер фикер борынлый башлады: әллә чит илгә чыгып таяргамы икән? Мәсәлән, Гарәбстанга! Анда һәммә кеше миллионер, гади эшчеләр дә юк, дй/Мәскәүдән өч студент барган икән, урам себерүче генә булып эшләп тә, бер ел үтәр-үтмәстә череп баеп кайтканнар, ди.

Чү! Кыңгырау чылтырый түгелме? Әйе ич.„ Ишекне ачып җибәрсәм — хатыным, артында — балалар! Йөзләре көләч, күзләре елтырый, ә авызлары колакларына таба ерылып киткән... Баксаң, авыл клубында латари уйнатканнар да, минекеләр өчесе дә хәйран гына отышка ия булганнар. Хатынга — бозау, кызга — печән, малайга... бер трактор йөге тирес!

Тирес сүзен ишеттем дә, күңелем тулып, кычкырып елап җибәрә яздым. Бер минут тормыйча, авылыма кайтып китәсем килә башлады. Сагындым, шундый сагындым мин сине, туган авылым. И хатыным, и балаларым, белмисез генә, хәлемә керегезсәнә...

— Әти, кайгырма,— диде улым, шулчак телгә килеп.— Мин тиреснең немножкасын спичечный коробкага салып алып куйдым: вот ул!

Чынлап та... Аромат фабригындагы агулы исләрне егерме ел иснәп тузып бетә язган үпкәләремә рәхәт булып китте. Менә, ичмасам, бу ис шифалы, менә, ичмасам, бу ис организмдагы шыплап тулган тозларны эретеп бетерә, мин әйтәм, валлаһи!

Мин бу кичне бәләкәй генә шырпы тартмасындагы чын тирес исен иснәп туя алмадым. Иснәп туя алмагач, качып-посып кына ялап та карадым. Хатын аш пешергәч, тиреснең беразын ашка да салып карарга иде исәбем, ләкин институтта укучы улым белән университетта укучы кызым рөхсәт итмәде. «Сдохнешь еще»,— диде малаем, мине битәрләп. Тик аромат фабригында әрҗәләргә «тройной» тутырып егерме биш ел гомерен үткәргән хатыным гына бу сөйләшүләргә катышмады. Ул, шырпы тартмасына таба авышып, күзләрен йомып, рәхәтләнеп тирес исни иде. Бераздан балаларым да, борыннарын шырпы тартмасына таба сузып, тын гына, моң гына тирес иснәргә керештеләр. Гәрчә калада туып, ак туфлиләр киеп кенә, ак калачлар ашап кына үссәләр дә, исниләр тиресне, рәхмәт төшкерләре! Геннары уяна бугай, геннары... Уянсын! Аннан безгә файда

гына... Тирестән качып, тирес исен җиңел генә онытырга теләгәнгә күрә шушы хәлгә төштек тә инде без. Мин, әгәр кодрәтемнән килсә, илебездәге бөтен түрәләрнең дә, академиклар, профессорларның да затлы кабинетларына тирес китертеп куяр идем. Һәрдаим иснәсеннәр иде алар аны һәм үзләренең кем икәнлекләрен белеп торсыннар иде. Тормышның яме, кызыгы һәм яшәүнең мәгънәсе, кыска гына итеп әйткәндә, философиясе — тирестә! Мин моны, һич курыкмыйча, үземнең ачы тормыш тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам. Яшәсен тирес!

## *Фатир*

Чал болытларга ашкан мәһабәт корыч вышка янындагы ярым җимерек агач өй каршында чирләшкә йөзле хатын белән әзмәвер бәдәнле ир ике көн буе кыш ягар өчен утын кисеп маташтылар. Утынны бераз кистеләр кисүен, әмма пүләннәрне ярып, сарай буена ташып өеп куярга хәлләреннән килмәде. Анысын киләсе атнаның шимбә-якшәмбесенә калдырып торырга булып (чөнки карт калага барып эшләп йөри иде әле), өйгә керделәр.

Хатын шунда әйтте:

— Авылыбыз бетү хәлендә... Инде синең дә карчыгың күптән вафат, минем дә картым байтактан ук гүр иясе... Синең дә балаларың бөтен ил буенча таралышып беткәннәр, минем дә балаларым үз янымда тормыйлар — кайтканнары да юк, хатхәбәрләре дә... Мин...— Ул буыла-буыла ютәлләп куйды.— Озак тормам кебек, хәлем яман, кышны да җиткерә алмам шикелле... шулай булгач, син, кем, үзеңә бүтән хатын тап... фатир эзлә, дию инде, кыш чыгар өчен...

Иртәгесен карт, башын түбән иеп, вышкалар яныннан узып, калага юл тотты. Бер сәгатьтән инде ул шәһәрдә иде.

Менә каравылчы будкасының ишеге, чинаган, сыкранган һәм сызланган авазлар чыгарып, акрын-акрын гына ачылды да, ишегалдында маймыл кыяфәтле (чөнки кырынмаган) безгә таныш кеше пәйда булды. Аның иләмсез дәү башында әллә коңгырт, әллә зәңгәр, әллә инде кара төстә — һич белерлек түгел — ямьшек кепка, өстендә шактый ук таушалган һәм шулай ук нинди төстә икәнлеген бары тик порошоклы суда өч көн тотып югач кына белеп була торган сырган бушлат, аякларында

гүя биш былтыр крем күрмәгән кирза итекләр... Аңа баккач, күңелдә ирексездән-ирексез (кәефнең нindiлегенә карап, әлбәттә) йә кызгану, яисә чиркану хисе туарга мөмкин: икенең берсе... Күзәтүебезне дәвам итәбез... Бу адәми затның борыны шешенке һәм кызыл иде. Ләкин күзләре тере иде. Әйе, әйе, сабый бала күзләре кебек гөнаһсыз һәм самими иде алар, дөньядагы барлык нәрсәгә, барлык җан иясенә, гомумән, тормышның үзенә томырылып-томырылып карый иде әле ул зур кара күзләр. Димәк, бу кешенең әле яшәүдән бөтенләй үк гайрәте чикмәгән, ул әле күкрәген тутырып һава сулый һәм киләчәк көннәрдән нидер көтә иде.

Шулай итеп, хикәябезнең бу каһарманы ишегалдында пәйда булгач, аның эшкә соңарып килүенә (чөнки ул пенсиядә, шуңа күрә аңа сүз әйтә алмыйлар) күнегеп беткән кешеләр, әнә Сөләйман хәзрәт тә килде инде, диештеләр дә янә үз эшләренә керештеләр. Сөләйман хәзрәт исә туп-туры автотөягеч янына барып (рәхәт, өс-башны да алыштырып торасы юк), кай төшендәдер казына башлады. Ул механик иде. Механик кына да түгел, ә алтын куллы оста! Әйе, аның кулларыннан гөл тамганын остаханәдә генә түгел, хәтта бөтен кала кешеләре дә беләдер сыман. Ләкин шул ук вакытта аңа Сөләйман исемен кем кушканын, Хәзрәт кушаматын кем такканын, алай гына да түгел, аның кайда, нинди фатирда яшәп ятканын белүче бер генә кеше дә юк иде... Кызыксынып сораучыларның авызларын Сөләйман хәзрәт, минем фатир — Советлар Союзы! дип кенә томалап куя торган иде шул.

Ниһаять, эретеп ябыштыручылар: «Әсхәт Лотфиеч... әнә... әнә...» — диешеп, Сөләйман хәзрәт тарафына ымладылар.

Ярты сәгать буе эшчеләр янында тегесен-монысын сораштырып, төпченеп, бәхәсләшеп мәш килеп кайнашкан тәбәнәк буйлы, какча яңаклы, озын борыны астына бер чеметем мыек калдырган Бөтерчек кушаматлы кеше шул вакыт, махмырдан кызарган күзләрен кыса төшеп, беләгендәге алтын сәгатенә карап куйды. Сәгать телләре тугызынчы яртыны күрсәтә иде. Озак еллар буе остаханәдә урнашып килгән эчке тәртип буенча нәкъ обход төгәлләнгән чак... Корычтай бу тәртипне булдырган әлеге дә баягы тәбәнәк буйлы тиктормас һәм эштән чыккан усал кеше бары тик шул чакта гына тимердән «чәчәк ясаучылар» әйткән тарафка карады да, дүрт кешелек Гаффар төркеме уртасында Сәгыйрә Бикбулатованың елап торуын күреп, гаҗәпкә калды. Чү! Ни хәл бу?! Тәэминатчы кулында нинди фатир булсын, әкәмәт?! Сәгыйрә (әгәр дә акылдан шашма-

ган булса) фатир таләп итеп, директор кабинетына керергә тиеш иде ләбаса! һәм шунда, кем әйткәндәй, энҗе-мәрҗәннәргә тиң күз яшьләрен дә... Ә ул әнә анда яклаучы тапкан, имеш, җылы һәм көчле канат астына барып сыенган! Тфү... Әсхәт Лотфиеч ике ай элек кабинетына Гаффарның килеп керүен хәтеренә төшерде. Ә Гаффар бирегә, Сөләйман хәзрәт киңәшен тотып, сугылып алырга уйлаган иде булса кирәк, һәрхәлдә, Сөләйман хәзрәт, автобустамы булсын, сыраханәдәме булсын, «Минем фатир — Советлар Союзы!» дип күкрәк сугуы белән байтак кына кешеләрнең игътибарын җәлеп итеп өлгерә иде. Менә шулай танышып киткән ир-егетләрнең байтагы, остаханәгә килеп, кыл иләктән узды инде. Бу юлы Әсхәт Лотфиеч каршында Гаффар.

— Мин, белемем буенча, сәүдәгәр... Сезгә тәэминатчы кирәк дип ишеткән идем...— дип, Җаббаров кыяр-кыймас кына, сүзләрен уйлап кына әйтеп маташа иде: сул тезе өстенә куйган соры эшләпәсен кинәт идәнгә төшереп җибәрде дә, эшләпәне иелеп алганда, йөзенә кан йөгереп, чөгендердәй кызарып чыкты. Таза да соң үзе... Ә аның яшькелт күзләре кызларныкыдай нәзек кара кашлары астыннан, мәрхәмәт өмет итеп, юаш кына карыйлар иде. Әсхәт Лотфиечка барыннан да бигрәк Гаффарның әнә шул нәзек кара кашлары ошаган дц&»ул чакта: аннары аның хезмәт кенәгәсендә бер генә дә буш урын калмавы исен китәргән иде... Соңгы елларда Җаббаров йә кибет мөдире, йә йөк төяүче, йә инженер, йә кабер казучы булып эшләгән икән...

Шулай итеп, элекке кабер казучы остаханәдә тәэминатчы булып эшли башлады. Баштарак, башын түбән иеп, юаш кына күренсә дә, тапшырылган эшне җиренә җиткереп үти иде үзе. Тик соңга таба гына чыгымчылый башлады. Имеш, аңа остаханәдәге кайбер тәртипләр ошап бетми, гаделсезлекләргә юл куела... Җомга көнне берләшмә җитәкчесе, остаханәгә озакламый өч бүлмәле ике фатир биреләчәк, дип хәбәр иткән иде... Шул хәбәрне Гаффар ничектер ишетеп алган бит! Ишетеп алган да, өч бүлмәле ике фатир бары тик сезгә генә булырга тиеш, дип, Сәгыйрә Бикбулатова белән Таҗетдин Ишбулдинны агитлап өлгергән. Җитмәсә, ул остаханәгә коточкыч озын бәндә иявртеп килгән. Туктале, анысы кем соң аның?!

— Флүс Мөсәгыйтович!

Мөслимов эретеп ябыштыручылар бригадиры белән сөйләшеп торган җиреннән капылт кына башын борды да, зәңгәр күзләрен тутырып, директорга карады.

— Әнә теге... кем икән... бел әле. Әгәр дә ул ялгышып килеп кергән булса, хәзер үк ишегалдыннан сөреп чыгар син аны...

Табак битнең бармак шартлатуы булды, «очкын сибәләүчеләр» брезент бияләйләрен салып куеп, «багана»ны сырып ал-

дылар да, шул мизгел бильярд шарлары кебек як-якка чәчелеп тә киттеләр.— Яңа экономист икән ул, Әсхәт Лотфиеч!..— «Аңлашылды... Димәк, әлеге фәртабай да «бывший могильчик» (элекке кабер казучы), күрәсең. Юк, кирәк түгел ул миңа... Тагын килер әле берәрсе, бәлки, менә монысы...» — Әсхәт Лотфиеч, күз алдымда җан көеге булып тормасын әле бу дип, «багана»га арты белән борылып басты да түбәдә ни өчендер талашучы ике чыпчыкны күзәтә башлады. Бераздан янына Гыйззәтне чакырып:

— Бар әле, астыртын гына шуларның сөйләшүләрен тыңлап йөр,— диде.

Мөслимов эченнән генә тантаналы төстә уйлап куйды: «Болай булгач, бу сузанга1 роза чәчкәсен хыялындагы ханымның нәфис түшенә кадарга мөмкинлек бетте инде...»

Ләкин «багана» тиз генә бирешергә уйламый иде, ахры. Аның юка иреннәре кысылган, ә күзләрендә таләпчән горурлык чаткылары күктә балкыган йолдыз җемелдәвен хәтерләтә шикелле. Ул күзләрдә явызлыкның мыскалы да юк сыман. Ләкин алар гел изгелек белән генә мөлдерәп тулып тора дип тә ышанырга ярамый... Була бит кешеләр, алларына куйган максатка ирешү өчен, хәтта гомерләрен корбан итүгә чаклы барып җитәләр. Бу ир дә шундый фидакарьләр төркем.ена карый булса кирәк, һәрхәлдә, ул үзен каһарманнарча тыныч тота иде бу минутта, һәм менә шул кеше, тәвәккәлләп, директордан ике башка озын буе белән каршына ук килеп басты да дәү ябык кулын күрешергә сузды:

— Исәнмесез...

Остаханә җитәкчесе, эшем кешеседәй, нәзек трубаларны урыннарыннан кузгатып, санап маташкан булды, аннары, кесәсеннән кульъяулыгын алып, борынын сеңгерергә тотынды.

— Мин... негр түгел?! — диде ул, ниһаять, «багана»ның ак чалбарындагы кечкенә генә кара тапка караган көйгә кәпрәеп.— Минем... кабинетым бар!

Әмма «багана», давыл алдыннан була торган сәер бер тынлык хасил итеп, чак кына дәшми торганнан соң, көлемсери төшеп әйтеп куйды:

— «Идән юуучыгыз» чибәр нәрсә икән!.. Минем беләсем килә: аны еларга нәрсә мәҗбүр итте икән?!

Шул мизгел болытлар астыннан килеп чыккан кояшның якты нурлары контор тәрәзәсеннән үтеп керде дә, почмакта

---

*** С у з а н — озын буйлы кеше.**

торган көзгедә кайтарылып, ишегалдында бер тирәгә җыелып баскан кешеләрнең күзләрен чагылдырды: койма янындагы чирәмнәрдә чык бөртекләре җемелдәшә башлады.

Гүя директорның янтавына без белән чәнечтеләр: йөзе агарды, какча яңагы чалшаеп китте һәм ул, читтән ярдәм эзләгәндәй, бер Меслимовка, бер эшчеләргә карап:

— Аңа миннән нәрсә кирәктер инде, белмим,— дип куйды.

— Мин экономист, эшкә урнашырга килдем сезнең остаханәгә,— дип аңлатты «багана», дустанә йомшак тавыш белән.— Сездә бер-ике ел эшләгәч үк фатир алырга була дип ишеткән идем!

Каядыр очып баручы төклетура, җирдә аунап яткан журналның тышында матур-матур чәчәкләр күреп, төшеп кунды.

— Фатир?!

— Әйе, фатир.

— Юк, кем, сез ялгышкансыз бирегә килеп... Безнең остаханә йортлар төзү белән шөгыльләнми... Сезгә иң яхшысы шул: идарәгә барып эшкә урнашу. Йортлар төзи торган идарәгә. Менә анда фатирны бик тиз алырга була!..

— Ай-һай җиңел генә фатирлы буласы килә бу кешенең, чурты-матыр,— диде Гыйззәт.— Әнә Сөләйман хәзрәт безнең остаханәдә ни гомер эшләп тә...— Аннары ул, читкә китеп, тозлап-борычлап сүгенә башлады.

Сөләйман хәзрәт, автотөягечнең көпчәкләре арасыннан иләмсез зур башын сузып:

— Минем фатир — Советлар Союзы! — дип мыгырданып алды.

Әсхәт Лотфиеч, иртән француз коньягы йоткалап, тәмле итеп итле карабодай шулпасы ашаган иде: кинәт сузып кикереп куйды һәм, кәефе килеп, хәйләкәр генә елмаеп, ак болытларга сәлам юллады, әле генә яшь кыз кулы кебек, биттән сыйпап үткән җил гүя күгәрми торган трубалар эченә кереп, бию көе суза башлады...

«Багана» күзлеген төзәтте, тамак кырды:

— Сез җитәкләгән остаханәдә эшлисем килә минем...— Бу сүзләрне әйткәндә, аның тавышында көмеш чылтыравына охшаш аһәң ишетелгәндәй булды. Гаффар, шулай кирәк дип, дәртләндерергә теләп, ахры, сузанга күз кысты, Сәгыйрә Бикбулатова елмайды, ә Таҗетдин карт исә бер тәэминатчыга, бер «идән юуучы»га төбәлеп, кызып-кызып нидер аңлатырга кереште... Әсхәт Лотфиеч маңгаен җыерды... Узган көз Ишбулдин машинасы белән «Май» совхозында эшләгән иде. Кырдан яшелчәләр ташылып беткәч, директор фәрманы белән, бик шәп ак

кәбестәләр алып кайткан иде остаханәгә... Җитәкче кәбестәләрнең һәммәсен дә үзенә алды, әмма акча бирмәде. Соңыннан кәбестәләр өчен акчаны шоферның хезмәт хакыннан тотып калдылар. Шул турыда сөйләвеме әллә картның? Бәлки, фатир турындадыр! Чөнки ун ел элек үк фатирлы булачак иде инде Ишбулдин. Шул чакта отчет-сайлау җыелышында Әсхәт Лотфиечны яңадан директор итеп калдыруга каршы кул күтәреп кенә бу бәхеттән колак какты ул.

Әһә... бәхәскә Сәгыйрә Бикбулатова да кушылды бугай. Кызык! Биш ел элек секретарь-машинистка да «сәмруг кошы»-на тиенәчәк иде бит. Инде юллама әзер, кул куясы да, берләшмәгә илтеп бирәсе генә иде. Ләкин... иңбашка кунып өлгергән шайтан кылыдай каты чәчтән сыйпый-сыйпый сөйләнә башламасынмы шулчак:

— Әсхәт Лотфиеч, бәгырем, юлламага кул куярга беркайчан да соң түгел, сабыр ит әле, күрәсеңме, синдәй олы түрәләр чибәр секретарьлары белән сәхрәләргә чыгып ял итәләр: исеп куйган җил белән агачларның шаулавын, яфракларның лепердәшүләрен тыңлыйлар. Юк, яфраклар лепердәшмиләр, ә серләшәләр... Урман эче гүя җәннәт. И Әсхәт Лотфиеч, җаным, юан имән төбендә, яшел палас өстендә, илаһи секретарең каршында утырган көе югарыга күз салсаң, агачлар очыннан зәңгәр күк нинди матур күренә. Тирә-юньдә чут-чут итеп кошлар сайравыннан колаклар иркәләнә, җаннар сихәтләнә...

— Җитте! — диде директор, һәм шайтанны кабинетыннан сөреп үк чыгарды. Мәгәр шайтан аның күңеленә вәсвәсәсен салып өлгергән булган инде: тәрәзәгә караса да, күз алдына урман килде, радио тыңласа да, колакларына яфракларның күңелле кыштырдашулары ишетелде... Беркөнне" җитәкче түзмәде, руль артына (ялга киткән Гыйззәт урынына) Таҗетдин Ишбулдинны утыртып, ә арт урындыкка, Сәгыйрә янәшәсенә, үзе урнашып сәфәр чыкты.

Бикбулатовага Әсхәт Лотфиеч:

— Хатыным больниста... дачабызда тәртипсезлек... барып, җыештырып-юыштырып кайтыйк әле,— диде.

Карусыз секретарь риза булды. Йә, ничек баш тарта алсын инде: әтисе яшендәге кеше гозерләп сорый ич, өстәвенә, юлламага кул куеп, фатир алып бирәм дип тә ышандыра!

...Килеп җиттеләр. Ишбулдин машина карый калды, ә секретарь белән директор дачага кереп китте. Шуннан соң чыгып эндәшүче булмады картка. Бер сәгать үттеме икән, эчтән чырыйлап кычкырган аваз ишетелде. Таҗетдин сагаеп, тыңлана башлады. Тавыш тагын кабатланды, һәм карт: «Минем урында Сөләйман хәзрәт булсамы?!» — дип ишеккә килде. Тартып

карады, ул эчтән бикле иде. Аннары шофер тәрәзә шакырга кереште. Үзе шакый, үзе кайбер урыннарда бер сүзне ике мәртәбә әйтеп кабатлый иде.

— Әсхәт энем, шаярма, ярамый, шаярма, дим. Син бит түрә кеше. Мондый эш өчен ике тапкыр җаваплы. Әсхәт энем...

Максатка якынлашып килгәндә, көтмәгәндә генә таяк белән башыңа суксыннар әле... Эссе көнне үләр дәрәҗәдә сусап, чишмәдән су алып, савытны иреннәргә тидерәм дигәндә генә, кемдер кулга бәреп суны түгеп җибәрсен әле...

Тәрәзә шакыган һәм, Әсхәт энем... дип, акылга килергә кушып әйткән сүзләрне ишетеп алгач, директор шундый ике төрле халәт кичерде. Ә секретарь (яхшылыкның кадерен белмәнәрсә) ялт итеп сикереп торды һәм ишеккә ташланды.

Кайткач, бу хәлне остаханә халкына чәчә инде болар. Юл**да** үзләрен кисәтеп: «Ул-бу ишетелсә, карагыз аны!» — дигән иде дә, тыңламаганнар бит. Эше зурга китте. Берләшмәгә чалрдылар. Бюро җыеп, җиңелчә генә мунча керттеләр һәм азак***та*** исе чыгарлык булгач, нигә тотындың инде син бу эшкә, керешмәскә кирәк иде, дип, йомшак кына аркадан кагып куйдыар. Шуның белән вәссәлам! Директор исә остаханәгә кайткач, миңа нахак гаеп тагып, батырырга теләделәр, дип, Сәгыйрә Бикбулатова белән Таҗетдин Ишбулдинга фатир бирдертмәде. Хәзер дә бирдертми. һәрхәлдә, остаханәне ул җитәкләгәндә, фатир ала алмаячаклар алар! Әнә Сөләйман Хәзрәтов та, зәһәр теле аркасында, остаханәдә ике эт гомере эшләп тә...

Әсхәт Лотфиеч шуларны хәтере аша кичергәч, «багана»га җавап бирде:

— Бездә фатир юк... Әнә Таҗетдин Ишбулдин унөч ел, ә Сәгыйрә Бикбулатова ун ел эшләп тә фатир ала алганнары юк әле!

Тимер өеме астыннан килеп чыккан йөнтәс кенә бер эт, олакларын сәлперәйтеп, ялкау гына атлап, төркем янына киеп утырды һәм, телен чыгарып, кояштан күзләрен кыса төшеп, шул ук вакытта башы очыннан үтеп киткәләгән чебен-фәләннәрне дә игътибардан читтә калдырмыйча, кешеләрнең сөйләтүләрен кызыксынып тыңлап тора башлады.

«Багана» шат күңелле кыяфәттә елмаеп куйды, ләкин кара үзләре моңсу иде аның, гүя ул күзләрдән гүр салкынлыгы бөркелә...

— Ун ел элек сез җитәкләгән остаханәдә баш бухгалтер ел ярым эчендә, баш инженер исә ике ел эшләгәч үк фатирга тиенә! Сез үзегез соңгы биш елда гына да ике тапкыр фатир алгансыз! Хәзер менә фатирның алты бүлмәлесендә яшәп ятасыз. Шул ук вакытта Таҗетдин Ишбулдин белән Сәгыйрә Бик-

булатова һәм аларның гаиләләре ярым җимерек элекке йортта, юештә яшәп, бер бүлмәле фатирны да тик төшләрендә генә күреп юаналар. Бу факт?! — дип кызу-кызу сөйләнде ул.

Йөнтәс эт кинәт дерт итеп китте һәм, койрыгын бот арасына кысып, тиз-тиз генә тимер өеменә таба юнәлде.

«Аһ! Димәк, бу үҗәт адәмгә остаханәдәге хәлләрне җиткереп тә өлгергәннәр инде. Ярый!» — Әсхәт Лотфиеч астан өскә габа «багана»ның оятсыз күзләренә төбәлде.

— Әйе, безгә экономист кирәк! Тик белеп торыгыз — фатир мәсьәләсе соңыннан хәл ителер. Мин эшкә кабул иткәндә сынап, сират күпере аша үткәреп алачакмын!..

— Мин... әзер! — диде элекке экономист.— Исемем...

— Яхшы! — Директор көлемсерәде: күз төбеннән яңак сөягенә таба сызылып киткән тирән бразна — чигә турысында күп тармаклана, бу инде аңа да тормышның җиңел генә бирелмәвен күрсәтеп тора.— Ә хәзер мин сезгә сораулар бирә башлыйм...— Әсхәт Лотфиеч йөнтәс эт кереп киткән тимер өеме янәшәсендә җирдә яткан озынча һәм киң тимергә төртеп күрсәтте.— Нәрсә дип атала? Аннан нинди детальләр ясыйлар?

— Производство кирәк-яраклары эшлиләрдер инде,— диде Хикмәтуллин, тимерләргә юньләп карап та тормыйча.

«Әһә... Менә аның йомшак ягы кайда?!» — дип уйлады директор.

— Төгәлрәк?! Сез бит төгәл саннар, атамалар белән эшитәчәксез... Мин тыңлыйм!..

— Калач... Көлчә... Бублик...— дип пышылдаштылар эшчеләр. Оятсыз сүз кыстырып әйтүче кеше директорның шәхси шоферы Гыйззәт иде.

— Белмисезмени? — Остаханә җитәкчесе мәсхәрәле көлемсерәде.— Шундый гади нәрсәне дә белмәгәч, катлаулыларын белмисез дә белмисез инде сез... Ә үзегез югары белемле! — Соңгы сүзләрен директор, барлык кеше дә ишетсен өчен, ашыкмыйча, юри кычкырып әйтте. .

Гыйззәт, тантаналы кыяфәт белән, Сөләйман хәзрәткә күз кысып алгач, көтмәгәндә генә кеткелдәп көлеп җибәрде.

«Багана» күзлеген салып сөртергә тотынды: җирдә яткан кара сәдәпкә карап чак кына уйланып торды.

— Ашханәләр трестында хезмәт иттем бит мин, тимер-томырны белмим, әлбәттә... өйрәнермен әле! — һәм ул, кара күзләрен челт-челт йомып, ни өчендер Гаффар ягына төбәлде: тегесе исә, үз чиратында, Сөләйман хәзрәткә таба борылды.

Директорны корт чактымыни... Аның тынгысыз коңгырт күзләре зур булып ачылды.

— Ә, юк инде... әнә тәэминатчы да, эшкә урнашканда, өйрәнермен, дигән иде, ике ай булды инде, әле һаман «пастеризатор»ны «культиватор» белән бутый, «кукуруз»ны «купоростан аера алмый йөри...

Эшчеләр көлгән булып кыландылар. Ә кайберәүләр, директорга ярарга тырышып, арттырып та җибәрде... Гыйззәт ике эшчене култыклап бер читкә алып китте һәм аларга сүгенә-сүгенә ниләрдер әйтте, Мөслимов берәүгә дә кушылмады. Ничек инде шеф янында авыл чәүкәсе шикелле чәүкелдәп тормак кирәк, янәсе! Теге эшчеләр дә Гыйззәткә сүгенеп җавап кайтардылар, ахры. Шуннан соң Гыйззәт, эчен тотып, сыгылып ук төште. Әйе шул, аңа ни кыланса да килешә, ул шофер кеше!

Бу кызыксыз, мәгънәсез тамаша Сөләйман хәзрәт күңелендә нинди хисләр кузгаткандыр, билгесез. Ул бу мизгелдә авто төягечкә җан өреп җибәргән иде. Аның карашы кырыс, йөзе җитди иде.

Шулай итеп, Гаффар төркеме җиңелү ачысын татыды. Таралыша башладылар. Хәмит Хикмәтуллин остаханәдән чыгып ук китте. Сәгыйрә Бикбулатова конторга юнәлде. Тәэминатчы кызарынып-бүртенеп зур төркемгә аркасын борып калды әле калуын. Ә Таҗетдин карт гаражга юл тотты. Баярак кына әтәч кебек кукраеп маташкан дип уйламассың да, бөкрәеп, калтыранып атлый шоферың, нәкъ суга чыланган чебеш инде менә!

Әсхәт Лотфиеч, эшләпәсен күтәреп, пеләш башын кашып куйды. «Гыйззәтне өстерәм әле мин аңа хәзер! — дип уйлады ул.— Адәм балаларын таркау яшәтим дисәң, араларына ут ташла инде син! Таркау халык буйсынучан була ич!» Директор шәхси шоферына машинаны гаражга кертеп, карыйсы җирен карап, майлыйсы төшен майлап җибәрергә кушты да, боерыгының үтәлүен тикшергән булып, читтән генә тамаша кылып тора башлады.

Менә Гыйззәт өч көн элек кенә ремонттан чыккан төзек машинаны гараж буена китереп куйгач, яшьли агарган бөдрә чәчләрен тузгытып, ишекне ачып җибәрде. Бер-бер артлы биш хатынга өйләнеп яшәүләре җиңел булмагандыр ул бахырга!

Эчтә Таҗетдин карт, яктырткыч тотып, үзе кебек картаюы тәмам җиткән машина астында казынып ята иде инде. Зәңгәргә ак сызылган фуфайка, кара чалбар кигән Гыйззәт, машинаңны тышка чыгарып көйлә, абзый, синең урынга мин куям машинаны, дип, әллә кем булып сөйләнгәч, Ишбулдин дерт итеп китте, хәтта кулыннан ачкычын төшереп җибәрде. Әмма ул Гыйззәт

янында Сөләйман хәзрәтнең басып торганын күреп, батыраеп китте. Ачуы эчтә өреп тутырылган куыктай кабара башлады.

Әсхәт Лотфиеч, Сөләйман хәзрәткә карап торды-торды да, Мөслимовка якын ук килеп, Таҗетдин Ишбулдин ягына таба ымлап:

— Син дә бераз чеметкәләп ал әле шул дорфа картны! — диде.

Производство башлыгы, зәңгәр күзләрен майландырып, аңладым, дигән сыман баш кагып куйды һәм тагын бер мәртәбә хуҗасына турылыклыгын белгертергә теләгән эттәй, Ишбулдинның машина тирәсендә чуалуын күреп:

— Син, абзый, тишек-тошык кызыл күлмәк киеп, чолганыштан чыккан полк байрагы шикелле, сәләмәләреңне җилфердәтеп йөрмә монда, безне мыскыл итеп, бүген комиссия килә! — дип, эт кебек өрде.

Ишбулдин, ул-бу була калса, Сөләйман хәзрәтнең якларга әзер торуын чамалап, көйләп җавап бирде:

— Ай, сүзләрегез... спиртка салынган тузганак чәчкәсенең шифалы төнәтмәсе! Сызлавык баскан җаныма җиңел булып китте хәтта! Әйтерсең пәрдә артыннан бер гүзәлнең шәрә кулы сузылып, карт тәнемә кагылды!..

Сөләйман хәзрәт, җаваптан канәгать калып булса кирәк, чабата кашларын дугаландырып елмайды. Ә «аучылар» чайкалышып куйдылар. Менә сиңа әрвах! Юк, бу карт башын түбән иеп дәшми-тынмый йөргән шикелле генә күренә... Аның хикмәтле ягы да бар, бик бар!

Директор, даһи фикерләргә сусаган җанына җим эзләгәндәй, җиргә текәлеп, борын төбендәге бер чеметем мыегын сыпырып куйды.

— Ә хәзер чираттагы бәрән — Гаффар! Бәрән итеннән кыздырылган шашлык эчкә тимиме икән ул?! Мөслимов, син ничек уйлыйсың, бәрән итеннән әзерләнгән шашлык — деликатесмы икән?!

Тонык зәңгәр күзләрдә шаян очкыннар җемелдәп киткән кебек булды:

— Үземнең ашап караганым юк әле, Әсхәт Лотфиеч! Әмма, минем уемча, тәмле булырга тиеш ул!

Мыегына чал керергә тиешле кеше белән урта яшьләрдәге ирнең ачыктан-ачык үзен мыскыллап сөйләшеп торулары Гаффарның җен ачуларын чыгарды:

— Их, сезне! — диде ул. Аннары эченнән генә:— Шакаллар! — дип өстәде.

Мөслимов тыенкы гына төстә авызын колакларына таба ерып җибәрде, ә директор мыек астыннан гына елмаеп, күзләрен кысып, кояшка карап куйды. Кояш та безнең яклы, янәсе, әнә көлә бит ул!

Яшь секретарына, сәгать күкеседәй, баскычка чыгып:

— Әсхәт Лотфиеч, Сезне телефонга дәшәләр! — дип кычкырмаган булса, Гаффар бу ике кеше каршында үзенең зур эшләргә дә сәләте бар икәнлеген исбатлаячак иде! Ләкин монысы булмый калды! Шулай да идән юуучы Сәгыйрәнең күзләрендә елтыраган яшь «мәрҗәннәре»нең — директорга бетмәс-төкәнмәс нәфрәте барлыгын искәреп өлгерде Гаффар. Димәк, элекке секретарь шефына беркайчан да баш имәячәк, хаклык өчен соң чиккәчә көрәшәчәк! Баягы алышта Хәмит Хикмәтуллинның җиңелүе дә бары тик вакытлыча гына, чын җиңү киләчәк — килми калмаячак! Әмма аларга чаклы әле Әсхәт Лотфиеч үзенең явызлыгы белән изге ниятле бу кешеләрне тинтерәтеп, әллә нишләтеп бетерәчәк. Беренче хөкем, әлбәттә, Гаффарга карата булачак. Нишләргә?! Мондый хәтәр сорауга җавап табар өчен, һәрхәлдә, иң элек дуслар белән киңәшләшергә кирәк...

Тәэминатчы, Сөләйман хәзрәт фикерен дә истә тотып, олы портфелен күтәреп, остаханәдән ераклашып барганда, Мөслимов куып җитте.

— Әле генә сөт заводыннан үтенеч кәгазе килеп төште... Монда безгә, кичекмәстән ике йөз метр рельс табып җибәрергә, диелгән. Ул эш сиңа йөкләнә... Директор бик нык кисәтеп әйтте: әгәр дә тәэминатчы шул эшне очлап чыга алмаса, иртәгә үк эштән китү турында кәгазьгә сырласын... без аңа ике кулын кесәсенә тыгып, урамда сызгырып йөргәне өчен генә йөз җитмеш тәңкә түләп тора алмыйбыз лабаса,— диде.

— Ярый...— Гаффар еш-еш сулаган Мөслимовның кулыннан кәгазьне алды.— Мин үз өстемә төшкән ул бурычны намус белән үтәп чыгармын! Хәзер бар инде, минем янга машинасы белән Таҗетдин абзыйны җибәр!

Мөслимовның күзләре серле елтырап китте:

— Ишбулдинны дисеңме? Хәзер үкме? Җибәрәм, әлбәттә! Җибәрәм!

***

Урманның теге ягында берничә вышканың манаралары күренә. Тагын бер вышканы, корыч арканнар белән тарттырып, дүрт трактор урман эченә кереп килә.

Кояш зенитта тора диярсең. Кабинада түзеп булмаслык эссе. Сумала исе һәм, каяндыр чыгып, урман эченә тарала башлаган газ исе сулышка каба, башларны әйләндерә.

— Гыйззәтнең килгәне күренәме әле? — дип сорады Гаффар, тирләгән йөзен-муенын кулъяулыгы белән сөртә-сөртә.

— Урманга керер алдыннан туктап калды бугай, ул һаман шулай эшли,— дип җавап кайтарды Таҗетдин, хәлсез тавыш белән.

— Хәзер без дә кире борылыйк... Каеннар үсеп торган урында туктап ял итәбез дә әзрәк...

— Әһә!!! Кояшны әйтәм, атна буе пыскаклап яуган яңгырлардан соң, чын җәйдәгечә кыздыра, каһәр.

— Их, элек иде ул, Таҗетдин абзый, үлән-чәчәк исләре...— дип офтанды тәэминатчы.— Ул урманнардан аңкыган баш әйләндергеч хуш исләр, мин сиңа әйтим, ул чишмәләр...

— Беләсең килсә, Гаффар энем,— диде Ишбулдин, соры күзләрен ак һәм яшь, зифа каеннарның әле берсенә, әле икенчесенә төбәп,— элек мине туган авылымда Чөгендер Таҗи дип йөртәләр иде дә... Ә хәзер, күрәсең ич, тәмам суырылганмын, йөзем җыерчыкланып беткән: хатын шулай ди... Картаюдан түгел бу, юк, авырудан да түгел: мин авырмыйм; кайгыдан бу! Әйтсәм әйтим...

— Аһ! Нинди сылу каеннарны аударып бетергәннәр?! — дип, шоферны сүзеннән бүлдерде тәэминатчы.— Нефть-газ разведчикларының эше бу, кеше дигән роботларның эше, ягъни...

— Син минем сүләгәнне тыңлап бетер әле, энем,— диде шофер, һәм куе үлән өстенә чүкте. — Машинамның ике көпчәге дә тимерчыбык белән генә тарттырып куелган бит, мәсхәрә. Әнә кара. Чөнки яңалар юк. Маминт алыштырып куяр идем дә... Сорагач, үзең юнәт, диләр. Хәләл акчадан... күпме сатып алырга мөмкин, җә...— Таҗетдин як-ягына каранып куйды һәм тәэминатчының колагына якыная төште.— Бер тапкыр... коробка переданный вилкасындагы, теге ни... Нәрсә әле ул? Кара, онытгым инде, тел очымда гына тора иде... Менә шул сынгач, и тыкырдата мине директор, эшләмичә кесә калынайтып ятасың, ди. Запчасть булмагач нишләргә тиеш инде мин, дим. Эзлә, тап, ди теге. Ә таба алмасаң, ул сине булдыксызга чыгара, санламый. Ярар, бер көн түздем, ике, өченче көнне тоттым да Сөләйман хәзрәт өйрәткәнчә (хурлыгы директорга, миңа түгел), тимерчыбык белән беркетеп куйдым...— Картның йөзе чак кына алланып китте.— Сөләйман хәзрәткә рәхмәт. Руль тәҗесендә дә бил каешы бит минем...

Гаффар, тузганак чәчәгенең таҗларын өзә-өзә, үз уйларына күмелеп, тыңлап утыруында булды. Ишбулдин тәэминатчының чалбарына сырышкан кырмыскаларны сыпырып төшерде.

— Биек үләннәр арасында аунап ятучы тимерчыбык-фәлән күп лә ул. Тик менә анавы ябь-яшь каеннарны таптап-сытып киткән кебек, иманны гына аяк астына салып измәсеннәр, Гаффар энем, шунысы куркыныч аның...

— И изәчәкләр дә! — дип кистереп әйтте тәэминатчы.— Әгәр дә тотып изгәннәрен көтеп ятсаң... Юк, издермәскә кирәк, абзый! Сөләйман хәзрәт әйтә, алар өер генә, ә без — халык! Халыкның иманын беркайчан да таптап сыта алмаган ул өер, ди...

— Вот именно! — дип кычкырып җибәрде шофер, төкерекләрен чәчеп, тәэминатчының күзләренә керердәй булып.— Вы и Сулейман хазрат совершенно верно говорили, Гаффар Мунавирханович.— Таҗетдин юлдашының чишелгән күлмәген төймәләп куйды да татарчага күчте.— Менә мин биш ел Төньяк флотта хезмәт иттем, унөч ел рус каласында яшәдем. Мария исемле сөйгән кызым да бар иде. Начальнигым Николай Иваныч, өйләнеп, монда калсаң, дип, алтын таулар вәгъдә итә иде... Их, туган җирләр сагындыра иде шул, Гаффар энем, төшләремә кара кашлы, әйе, әйе... көлмә, татар кызы кереп йөдәтә иде. Түзмәдем, бирегә кайтып урнаштым утыз җиде яшемдә. Шуннан бирле үз халкым арасында яшим. Хыялымдагы алсу йөзле татар кызы минем тормыш иптәшем булды, ике бәбәй алып кайтып бирде... Әйе, мин үземне бәхетсезгә санамыйм, Гаффар Мөнәвирханович, әмма балаларым... Чөнки подвалдагы күгәрек исне иснәп үтте аларның балачагы!.. Эшкә кабул иткәндә Әсхәт Лотфиеч, фатир иң элек сиңа булачак, дип ышандырды. Ул чакта инандым. Хәзер өметләнмим дә инде. Бирмәячәк ул миңа фатир!.. Әгәр дә мин тегендә торып калган булсаммы?! Николай Иваныч миңа фатир күптән биргән булыр иде инде. Минем хатыным Мария Герасимовна булыр иде. Мәгәр куларымны күкрәгемә куеп әйтәм, Гаффар Мөнәвирханович, минем балаларым минем телне, ата телен, белмәсләр иде!

— Әйе... дәрес...— диде тәэминатчы, һәм ясканып урыыннан торды.— Әйдә, утыр, Таҗетдин абзый, машинаңа, китик изрәк... МиНе анда, Ризван янында Хәмит Хикмәтуллин көтә булыр.

***

Әсхәт Лотфиеч кабинетында, маңгаен учлап, очлы күзләрен б'ер ноктага төбәп, әле генә чибәр секретарь кайнатып керткән кофены ашыкмыйча гына эчеп утыра иде. Ул остаханәдә беркемнән дә, хәтта үз-үзеннән дә канәгать түгел иде. Баярак кына баш бухгалтер икенче квартал планының үтәлүе турында хәбәр итте. Моңа сөенергә кирәк иде. Ә бит квартал тәмамланырга тагын бер ай вакыт бар әле. Юк, нишләптер шатландыр-

мый иде бу хәбәр директорны. Мастерлар, күрәсең, эшләнмәгән эшләрне кәгазьдә инде төгәлләнгән итеп язалар. Хәзерге чакта бу бик хәтәр нәрсә. Кичекмәстән баш инженерны участокларга чыгарып җибәрергә кирәк, тикшерсен... Микъдарның сыйфатка әверелүе өчен көрәш барамы — беррәттән анысын да хәбәр итсен... Әгәр дә мастерлар алга таба да хәбәрләренә юкә хушбуе исен сеңдереп җибәрә торган булсалар — үзләренә үпкәләсеннәр?! Әсхәт Лотфиеч әле бу якты дөньядан туй маган, аның яшисе килә һәм пенсиягә чыкканчы гына булса да, директор креслосында утырып торасы килә. Ләкин шуңарчы утыртырлармы аны?! Бу әлегә билгесез иде. Һәм шул билгесез, әмма кайчан да бер билгеле булырга тиешле нәрсәдәндер калтырап курка иде остаханә җитәкчесе, һәм шул курку аның хәзерге минутта кәефе китеп торуга да сәбәпче иде.

Чынлап та, тәэминатчы булып Гаффар эшкә керешкәннән бирле, Әсхәт Лотфиеч өчен дөньяның яме югалды кебек... күңел күге өстендә авыр, салмак кара болытлар йөзеп йөри. Җил исә, яңгыр ява, ләкин болытлар таралмый, кояш һаман чыкмый һәм тән дә җылынмый: гел туңдыра, калтырата...

Гаффар остаханәдә булган әүвәлге кыек эшләрнең һәммәсен дә беләдер шикелле: Сәгыйрә Бикбулатова аңа үзе белгәннәрен түкми-чәчми җиткергәндер инде, аннары Таҗетдин Ишбулдин һәм, әлбәттә, Сөләйман Хәзрәтов!

Директор, нервыланып, ишекле-түрле йөренеп алды. Аннары креслога килеп утырды: күзләрен зур ачып, яшерен сейф тарафына текәлеп карады, хыялы белән алтын-көмешләрен барлады да батыраеп китте. «Сөйләсәләр!.. Нидән куркырга?.. Унбиш ел элек хәбәрсез юкка чыккан кассир өченме? Урманга барып пошилар аулап йөргәнгәме? Тыелган урында динамит шартлатып, балык «кырган» өченме? Әллә, биш ел буе яшь, чибәр хатын экономист Алсуны сөяркә итеп файдаланган өченме?! Сөйләсеннәр!.. Курыкмыйм!.. Беренчедән, мине гаепләргә аларның шаһитлары юк инде хәзер! Икенчедән, гаепсез килеш нахак бәлаләр таккан өчен, аларның үзләрен хөкемгә тарттырачакмын мин! Моны эшләячәкмен, әлбәттә, эшләячәкмен!..»

Әсхәт Лотфиеч вак-вак итеп кофе йотты. «Әгәр дә шаһитлар табылса?! Шул юл белән йөз ел элек булган хикмәтләрнең дә серләренә төшенәләр ич!.. Юк! Юк!..» Ул янә хыялы белән алтын-көмешләрен барлап куйды. «Бу хәлне булдырмаска кирәк! Булдырмас өчен нәрсә дә булса уйлап чыгарасы иде бит!.. Каһәр суккан, йомгакның очы һаман шул Гаффарга барып тоташа...»

Остаханә җитәкчесе тәрәзәгә карап алды. Ике тәрәзә арасында, каяндыр очып кергән, ләкин кире чыга алмыйча аллыгөлле күбәләк бәргәләнә иде.

Кабинет ишеге ачылып китте, таныш түгел берәүнең караңгы йөзе шәйләнде. Ул кеше, гүя Әсхәт Лотфиечка ташланыр өчен, йодрыкларын төйнәгән, менә-менә хәзер нидер булачак...

— Әй, кая керәсең? Мин эш белән мәшгуль! Алло... секретарь? Минем янга... кертмә әле!.. Фу, нинди көн булды бу?!

«Ух, нәрсә турында уйлый идем соң әле?! Әйе, Гаффар берәр оешма белән бәйләнеш тота, ахры. Ләкин нинди оешма белән — аңлашылмый... Гыйззәт бүген дә урманга чаклы озаткан үзләрен. Туры депога киттеләр, ди. Ярый, барсыннар! Анда аларны күтәп торучы кеше юк! Рельс дефицит! Димәк, хәйләм барып чыга. Гаффар иртәгә үк остаханәнең теге ягында булачак!.. Ә хәзер ул, мескенләнеп, деподан шалтыратырга тиеш...»

Әсхәт Лотфиеч авыз эченнән: «Хикмәт элек җимдә, аннары кармакта»,— дип көйли-көйли, яшел телефонга текәлде, һәм шул мизгел кинәт, җанны сискәндереп, кара телефон чылтырады. Гади телефоннар арасында үзенең купшылыгы һәм мәһабәтлеге белән әллә каян аерылып торган телефон-рация чылтыравы иде бу. Ай-һай хәтәр итеп кабаланып чылтырый, каһәр! Кем... үземе әллә югыйсә?! Алай дисәң, нинди йомышы төшәр икән аның төзәтү-көйләү остаханәсенең директорына?! Әле дүрт көн элек кенә сөйләшеп аңлашканнар иде ич. Хәер, белмәссең аларныкын. Кичә алай, бүген болай дигәндәй...

Директор тәвәккәл горурлык белән, сул кулының өч бармагын сузып кына трубканы алды һәм колагына якын китерде:

— Әйе, тыңлыйм Сезне! — диде ул.

Трубкада җан өшеткеч коры һәм сәер аваз ишетелде:

— Безобразие бу! Аһ, безобразие!.. Кем куша сиңа шулай эшләргә, ә?!

Остаханә җитәкчесенең маңгаена салкын тир бәреп чыкты, коелып бетми калган чәчләре үрә torгандай булды. «Аның тавышы түгел бу! — дип уйлады ул.— Алайса, кем тавышы соң бу?!» Юк, белми иде Әсхәт Лотфиеч болай елан ысылдаган тавыш чыгарып сөйләшүче кешене. Ләкин шулай да корыч кебек салкын һәм шомлы бу тавыш теге «бөек йорт»тан сузылган чыбык аша килә ләбаса!.. Шулай да Кем булыр бу?! Ник әле ул тиктомалдан гына төзәтү-көйләү остаханәсенең министрын... тфү, директорын сүгәргә кереште?! Ни хакы бар аның алай эшләргә?!

Әсхәт Лотфиеч үзен кинәт бозлы суга төшкәндәй хис итте, урындыгына сеңеп, тагын да кечерәеп калгандай булды. «Әллә берәр адәм актыгы аның өстеннән... Юк, юк, булмас!.. Дирек-

тор үзенә зыян салырдай мәгънәсез кешеләрдән күптән арынып бетте инде, төзәтү-көйләү остаханәсен ялт иттерде. Әмма шулай да кайбер урыннарда берәм-сәрәм генә чүп үләне посып калгандай, син тәхеттә киерелеп утырганда, итәк астыннан гына эш йөртеп, сине батырырга теләүче табылмас дисеңме?! Әйтик, Сөләйман Хәзрәтов?! Аннары?!»

Остаханә җитәкчесе, маңгаен учлап, бармаклары белән пеләшен ышкып алды. Үзенә таныш йөзләрне берәм-берәм күз алдыннан үткәрә башлады. Тукта, тукта!.. Аның зиһене яктырып китте. Хәмит Хикмәтуллин?! Әйе, әйе, ул?!

Һәм шул вакыт, директорның уйларын җөпләгәндәй, трубкада ысылдаган тавыш ишетелде:

— Хәмит Хикмәтуллинны, экономист итеп, эшкә ник кабул итмәдең?!

Әсхәт Лотфиеч, хатасын танып, үкенеп куйды. Их, иртән кире борасы калмаган бит Хикмәтуллинны, өр-яңадан сөйләшәсе, аңлашасы калган. Ләкин соң шуЛ' инде. Хәзерге шартларда кеше намусына кагылу — уен эш түгел икән. Юк, түгел... Димәк, «багана» остаханәне ташлап чыгуга ук, директор өстеннән (үч алырга уңай вакыт табылган ич!) тегендә шикаять илтеп биргән. Ә бәлки үзе дә кереп сөйләшкәндер «аның» белән. «Багана»дан бусын ук көтмәгән иде остаханә җитәкчесе. Баксаң, ул әнә нинди кабахәтлек эшләргә дә маһир икән...

Ярый... Әсхәт Лотфиеч тешләрен кысты, һәм аннары чыбыкның теге очында (телефон-рациядән җавап көтеп) кем басып торуын хәтеренә төшерде. Болай булгач, эшкә кабул итәргә кирәк Хикмәтуллинны... Гәрчә директорына тәлинкә тотып яшәрлеге күренмәсә дә... Ә Әсхәт Лотфиеч үзенә берсүзсез буйсынучыларны ярата инде. һай, ярата... Кабул итәргә дә... тора-бара чарасын табып остаханәдән...
Әсхәт Лотфиеч трубкага сак кына өрде һәм:

— Зинһар, Сез мине гафу итегез... Мин бик ялгышканмын... Хатамны таныйм... бүтән алай эшләмәм... Хәмит Хикмәтуллинны, иртәгәдән дә калмыйча, экономист итеп, эшкә кабул итәчәкмен,— дип, теге «бөек йорт»та, зур, якты тәрәзә кар шында күкрәк киереп басып торган мәһабәт кыяфәтле кешене ышандырырга тырышты.

...Теге зур абый трубканы куйды, ахры. Әсхәт Лотфиечның трубкасында «пип-пип» иткән өзек-өзек авазлар гына ишетелә иде инде.

«Димәк, Сәгыйрә Бикбулатовага да өч бүлмәле фатир бирергә...» дип уйлады директор, аклы-кызыллы булып, һәм аның күз алдына дачада булган хәл килеп басты... Таҗетдиннең (кабахәт җан) тәрәзә шакуы, Сәгыйрәнең алтын брошканы кире кайтарып, җан-фәрманга карышып маташуы, Әсхәт Лотфиеч

күңелендәге нәфрәт утын дәррәү дөрләтеп җибәрде. «Шундый уңайлы урында да бирелмәгән булды бит әле, секретутка?!» — дип кимсенеп уйлады остаханә җитәкчесе. Аннары ул бар көченә өстәлгә китереп сукты. «Бит быел мин малайны, башлыкүзле итеп, өч бүлмәле фатирга чыгарачак идем ләбаса! Ә Демон (малай) берләшмә җитәкчесе (гади слесарьдан генераль директор дәрәҗәсенә ирешкән кеше) кызына өйләнәчәк иде... Болай булгач, Әбдел Рәхимычның күзләренә ничек карармын да, Бикә Спартаковнаның йөзенә ничек багармын?!»

Әсхәт Лотфиеч, дерелди-дерелди, тумба тартмасын ачты, валидол алып тел астына салды, бераздан чак кына тынычланып киткәндәй хис итте ул үзен... Әлбәттә, Әсхәт Лотфиечның кечкенә генә планына караганда, теге «бөек йорт»тан килгән фәрман бик күпкә җитдирәк иде. һәм аны үтәми һич мөмкин түгел иде.

Директор: «Күрәсен күрми, гүргә кереп булмыйдыр инде»,— дип уйлап, селектор төймәсенә басты. Кабинетта нурлы йөзле элеккеге секретарь пәйда булды. Әсхәт Лотфиеч, ачуын эчкә яшереп, мөмкин чаклы ягымлы күренергә тырышып:

— Юллама язып керт әле, Сәгыйрә...— диде. һәм аннары, чак кына көлемсерәгәндәй итеп, үзалдына текәлеп, уйланып торгач, күтәрелеп чибәр хатынга карады. Сәгыйрәнең болай да алсу йөзе тагын да кызара төште. Озын, кара керфекләре дерелдәп куйды...— Фатирлы итәм мин сине?!

Ул, колакларым ялгыш ишетәме әллә дигәндәй, сәер итеп, директорга карады. Ләкин директорның йөзе ачык, карашы мөлаем иде. Димәк, хәбәр дөрес!..

Сәгыйрә:

— Рәхмәт Сезгә, зур рәхмәт, Әсхәт Лотфиеч...— диде дә, авызы белән кош тоткандай, сөенеп, ишектән атылып чыгып китте.

Остаханә җитәкчесе элеккеге секретарь-машинисткага әйткән сүзләрне кич белән Таҗетдин Ишбулдинга да җиткерде. Ә Сәгыйрә, үз чиратында, шундый ук сүзләрне, шаяртып, Сөләйман хәзрәткә әйткән иде. Ах, әйтмәгән булса... Сөләйман хәзрәт элек, багана шикелле булып, катып калды. Аннары исен җыеп баскычка ташланды, дөбердәп конторга килеп керде һәм, профком җитәкчеләрен йөдәтә торгач, яздырып, бер-береңә ярдәм итү кассасыннан шактый гына акча алды.

«Нигә кирәк сиңа бу тамаша акча?» дип сораган кешеләргә:

— Кирәк инде...— дип кенә җавап кайтарды сугыш ветераны.

Бу минутта остаханә җитәкчесе, барып, ике катлы тәрәзә арасына күзләрен талдырганчы карады, ләкин көндез кергән аллы-гөлле күбәләк анда юк иде инде... Чак кына ачык калдырылган форточка аша кичке кала һавасы кереп тора, ә ул һава табада кыздырылган май исен хәтерләтә иде.

Икенче көнне остаханәдә, Сөләйман хәзрәтне күреп, кешеләр шаккаттылар. Кырынган, чистарынган карт. Өстенә өр-яңа күлмәк, костюм-чалбар кигән. Башына асылташлар белән бизәлгән, кояш яктыртканда җем-җем итеп торган кара кәләпүшне кыңгыр салган. Менә, ичмасам, тамаша дисәң дә тамаша бу! Остаханәдә мондый күңелле хәлнең күптән булганы юк иде инде. Ниһаять, конторда эшләүче яшь хатыннар, әлеге дә баягы хикмәтнең серенә төшенеп алгач, көлешеп рәхәтләнделәр генә. Хәтта Әсхәт Лотфиечның да көлә-көлә эче катып бетте.

— Нәрсәгә сиңа фатир? Синең фатир — Советлар Союзы ич инде?! — дип чыркылдаштылар конторда эшләүче яшь хатыннар. Сөләйман хәзрәт эндәшмәде, сораулы карашы белән Сәгыйрә Бикбулатовага төбәлде. Тегесе исә, үз чиратында, кызарып, башын түбән иде.

Шул мизгел ишегалдына тирләп-пешеп Мөслимов килеп керде. Ул:

— Әсхәт Лотфиеч! Май-сыр комбинатында зур авария... Аварияне бетерергә аларның үзләренең генә көчләре җитми, бездән ярдәм сорадылар,— диде.

— Кемнәр барырга тели?! — дип, эшчеләргә үткен карашын юнәлтте остаханә җитәкчесе.

Сөләйман хәзрәт директор каршына барып басты:

— Мин!

Аңа тагын берничә эшче кушылды.

...Бу көнне директор күңелсез генә берләшмәгә китте. Юлламаларны өстәлгә китереп салгач, «бөек йорт»та утыручы түрәнең телефон-рациядән әйткән сүзләрен, күпертә төшеп, булачак кодасына җиткерде.

Әбдел Рәхимын, кызарып пешкән кабартмадай, мимылдап торган битләрен алсу учлары белән сыпыргалап куйгач, кинәт җанланып:

— «Бөек йорт»та утыручы ул «кем» телефон-рациядән әйткән сүзләрне җитди дип уйларга кирәк, минемчә,— диде.— Ләкин... Берләшмә...— Әбдел Рәхимыч, кырыйга борылды да, каты итеп төчкереп җибәрде.— Берләшмә...— Ул янә төчкереп җибәрде, һәм, кесәсеннән яшел ефәк кульяулык чыгарып,

борыны төбендә уйнатып алды. Аннары, елмая төшеп, булачак кодасына карады. Шул чакта аның күзләрендә хәйләкәр чаткылар елтырап китте.— Берләшмә остаханәгә бер генә фатир бирә бит?!

— Ничек бер генә фатир?!

Әбдел Рәхимыч булачак кодасын, иңбашына кагылып, урынына утыртты. «Сюзанна белән Демонның бәхетле киләчәге өчен инде, кода-а-а?!» ,

— Аңла-шыл-ды,— диде остаханә җитәкчесе, гәрчә бик үк аңлап бетермәсә дә, елмайган атлы кыланып.— Аңла-шыл-ды, ко-да-а!..

Шулай итеп, төштән соң... остаханәгә өч бүлмәле бер генә фатир тиеш икәнлеге ачыкланды. Ә тагын бер фатир?! Анысы киләсе ел азагында төзелеп бетәргә тиешле йорттан бүлеп биреләчәк, имеш. Бу хәбәрне элеккеге секретарь белән шоферга Әсхәт Лотфиеч креслосында киерелеп утырган килеш кенә ирештерде. Кабинеттан чыгып икәүдән-икәү генә калгач, Таҗетдин Сәгыйрәгә туры карап, борчылып:

— Булмаса, яңа фатирга син күчеп тор инде, сеңелем... Синең балаларың да, ни бит әле, бәләкәйләр... ирең дә... кызганам мин аны,— диде. Фатир мәсьәләсе шулай хәл ителде. Ә кич бу хәбәр, борма юллар белән зураеп, күпереп, май-сыр комбинатына — Сөләйман хәзрәт колагына да килеп «иреште. Оста элек эретеп ябыштырганда файдалана торган масканы кулыннан ычкындырып җибәрде. Аннары кинәт күз аллары караңгыланып китте дә, бөтен гәүдәсе белән калтырана-калтырана, уңга-сулга чайкала башлады... Түбәндә нindидер хатын-кыз куркып чәрелдәп кычкырырга кереште.

***

Өч бүлмәле яңа фатирга күченгәч, яңа фатирны котлап мәҗлескә җыелган туган-тумача, дус-иш арасында Сәгыйрәнең элекке шәриктәше һәм аның белән ун ел буе бер партада утырган шаян егет тә бар иде. Ризван әле һаман өйләнмәгән... әнисен җирләгәннән соң, калага килеп урнашкан һәм «бөек йорт»та зур урында эшләүче түрәне «Волга»да җилдереп кенә йөртә икән.

Кайчандыр озын буйлы, алсу йөзле, шат күңелле булган Сәгыйрәнең ире, коляскада утырган көе генә, директор дигән кешенең үзе укмаштырган шигъри такмаклар белән «бизәлгән» гаять озын, русча тостын тыңлагач, кинәт сулкылдап елап җи

бәрде, куллары белән йөзен каплады. Әмма аның яшьләре бармаклары арасыннан да юл-юл булып агып чыга һәм идәнгә — туганнары тарафыннан бүләк итеп китерелгән кызыл палас өстенә дә тамып-тамып киткәли башлаган иде. Кемдер Кәрим-гә яулык ташлады, кайсыдыр, дәртләнеп, браво! дип кычкырыр-
га тотынды, ул сүзне бүтәннәр дә күтәреп алды,— кунаклар Кәрим шатлыктан елый дип уйладылар, ахры, борынгы ярым җимерек агач өйдә яшәп, көтмәгәндә генә заманча йорттагы өч бүлмәле фатирга күченеп кара әле син!

Әтиләренең ни өчен елавын аңлаганга күрә, Кәримнең ике ягында басып торган малае белән кызы гына бу вакытта моңсу иде.

Яран гөленең чәчәгенә төклетура кунган тәрәзә турысында утыручы Ризван шундый нәтиҗәгә килде: Кәрим кимсенеп елый... Әйе, әйе, сау-сәламәт кешеләр арасында ярты кеше генә булган көе сөенеп кара әле син?! Кәримнең ике аягы да төптән кисеп алынган иде шул...

Чү, тәрәзә алдына ике ак күгәрчен килеп кунды түгелме?! Әйе ич, әнә канатларында бөрчек-бөрчек кара таплары да бар...

— Безнең остаханә күгәрченнәре бу,— диде Гыйззәт, яшь хатыны ягына таба бөдрә чәчле башын борып.— Тәки Сәгыйрәне эзләп килгәннәр бит, әй!

— Бәхет китергән бу ак күгәрченнәр, бәхет! — диде Таҗетдин Ишбулдин һәм, бизәкләп эшләнгән пластмасс савыттан олы гына бер әфлисун алып, кара кашлы чибәр хатынга суздı. Аның хатыны иде ул.

Мәҗлес кызганнан-кыза барды. Әсхәт Лотфиеч монда да, остаханәдәге кебек, дилбегәне азаккача үз кулында тотарга исәп итә иде бугай. Кемдер аңа:

— Иптәш, сез татарча гына сөйләгез әле, биредә безнең милләттәшләр генә утыра бит! — дип кисәтү ясагач, ул:

— Гафу итегез... Менә минем тормыш иптәшем Андреомана Марсовна...— Директор янәшәсендә утырган һәм кайберәүләргә таныш булмаган кыска аяклы юан ханымга ымлады... — Татарча белми, и мин дә...

Шулай итеп, үз телен белмәгән ике маңкорт өчен мәҗлестәгеләр урысча гына сөйләшергә һәм урысча гына җырларга тиеш булып чыкты.

Әсхәт Лотфиеч һаман кәперәенде, һаман аягүрә басып нотык арты нотык тотты, һаман үзен мактады. Имеш, ул Сәгыйрәне һәм аның гаиләсен фатирлы итте, алар аңа гомерләре буена рәхмәт укып яшәргә тиешләр...

Таҗетдин Ишбулдин, галстугын төзәткәләп, усал итеп тамак кырып куйды, ләкин эндәшмәде. Алсу йөзле Сәгыйрә аны күз карашы белән кисәтеп өлгергән иде инде. Гаффар мәгънәле итеп елмайды. Мөслимов, дөньясын онытып, директорның күзләренә генә карап утыра иде. Гыйззәт «Алмагач»ны русча җырларга азапланды: кызарынды-бүртенде, әмма булдыра алмады.

— Эссе... — дип, озынча йөзле ир кеше кече тәрәзәне ачып җибәрде, бүлмә эченә аллы-гөлле күбәләк очып керде. Хәмит Хикмәтуллинның «дүрт күзенә» кичке Кабанның яшькелт суы шәйләнде. Арырак, җылыту станциясенең күккә ашкандай озын торбасыннан, бүрек-бүрек кара төтеннәр өргылә иде. Менә җил химия заводы тарафыннан «Алсу» дигән шампунь исе алып килде: әрекмән колаклы абзый төчкереп җибәрде һәм, борынын сөртергә дип, кесәсеннән чигүле кульяулык чыгарды.— Кызлар исе борынга кергәч, кулда яулык пәйда була,— дип шаяртты ул. Ләкин аның урысчасы татарча сыман килеп чыкты. Сәвиянең иптәш марҗа кызы пырхылдап көлеп җибәрде.

— Ой, как смешно тут у вас?! — диде зәп-зәңгәр күзле Марина гаҗәпләнеп.

— Көлке булган җирдә сәламәт тормыш, сеңелем! — диде дә остаханә җитәкчесе, авызына кабып чәйни башлаган каз итен йотып җибәрде һәм чәчен ясалма бөдрәләткән, шул сәбәпле ир-ат кыяфәтенә кергән хатынына карап елмайды. Ә Мөслимов белән Гыйззәт, әче-әче, дип, тәлинкә тотып, аларны үбешергә кыстапмы-кыстый иде әле.

Инде бүтән түзеп торыр чама калмаган иде. Ризван аягүрә басты да кычкырып:

— Син әле һаман элеккечә яшь күренәсең... Картаерга уйламыйсың, ахры, сабакташ! — дип, шундук мәҗлес халкының игътибарын үзенә җәлеп итте.

— Күпертмәсәнә, Ризван-шәриктәш... картаелды, бик картаелды бу елларда... Күрдең ич, ирем ярты кеше генә хәзер... Тормышның бар авырлыгы минем җилкәдә... — дип зарлана башлаган булды Сәгыйрә.

— Аның каравы менә дигән фатирга тиендең, рәхәтен күреп яшә инде...

— И рәхмәтләр яусын мин эшли торган остаханә директоры Әсхәт Лотфиечка! Ул тырышты безне фатирлы итү өчен! Кул-аяклары мәңге сызлаусыз булсын иде аның!

— Юк шул! — диде Ризван шактый ук дулкынланып.— Гаффар белән Таҗетдин тырышты сине фатирлы итү өчен...

Әсхәт Лотфиеч «тормыш иптәше»н үбәргә үрелгән җиреннән катып калды, лып итеп урынына утырды, куллары белән башын тотты...

Бераздан исенә килде ул: мәҗлес халкының кызгангандай итеп үзенә карап торуын, Таҗетдин Ишбулдинның тантаналы төстә елмаюын, ә Хәмит Хикмәтуллин белән тәэминатчы Гаффарның хихылдап көлүен искәреп, чәчрәп сикереп торды һәм:

— Сөенәсезме?! — дип кычкырып җибәрде.— Юкка шатланасыз... Өч бүлмәле бер фатирны сез минем кулдан тартып алдыгыз, дөрес... Тагын бер өч бүлмәле фатирны мин дә сезнең кулдан тартып алдым бит!

Мәҗлес халкы аһ! итте. Мөслимов белән Гыйззәт.каударланып директорга кул чаба башлады. Ә шофер Таҗетдин... Әсхәт Лотфиечның гомерендә дә онытасы юк бу минутны... Шофер Таҗетдин, куен кесәсенә тыгылды да, нинди дер кәгазь чыгарып, Мөслимовның башы аша остаханә җитәкчесенә сузды:

— Мә... укы!..

Таҗетдин Ишбулдинның әлеге ике сүзе Әсхәт Лотфиечка, фәлән итим, дигән сүгенү сүзләре кебек булып ишетелде. Ул шундук кәгазьне йолкып диярлек шоферның кулыннан алды да шыпырт кына укырга тотынды... Боерык язуы иде бу. Боерык язуына «бөек йорт»та утыручы дәү түрәнең кулы куелган һәм мөһере төшерелгән иде.

«Таҗетдин Ишбулдинга кичекмәстән өч бүлмәле бер фатир бирергә... үтәлеше турында миңа хәбәр итәргә...»

Директорның язу тоткан куллары калтыранып куйды. Нәрсә бу? Моны ничек аңларга?! Кайчан гына әле «Таҗетдин Ишбулдинга өч бүлмәле бер фатир бирергә...» дип, телефон-рациядән боерганнар иде, инде әнә аңа язуын да биреп җибәргәннәр. Ләкин гади язу гына түгел. Юк! Зур көчкә ия язу бу!

Остаханә җитәкчесе маңгаен җыерды һәм, язуны эчке кесәсенә шудырып җибәрде дә, өстәлгә таянып, ә күзләре белән каядыр бер ноктага төбәлеп, чак кына хыялга бирелеп торгач, уң кулы белән борын төбендәге бер тотам мыегын сыпыра башлады. Мәҗлес халкы, тын да алмыйча диярлек, аңа карап нидер көтә иде. Ул моны яхшы аңлый иде. һәм, ниһаять, ул хәтереннән алтын-көмешләренең һәммәсен дә барлап чыкты да, тынычланып, хәтта елмаеп, көлемсерәп шоферга эндәште:

— Синең язуың, кем, Таҗетдин Тәлгатович... миндә калып торсын әле... бередә мәҗлес... берсекөнгә, иртә белән минем кабинетыма керерсең, кем, Таҗетдин Тәлгатович... синең проблеманы шунда уртага салып хәл итәрбез, ярыймы?!

Карт ни әйтергә белмичә катты да калды. Ах, шайтан алгыры, тагын төп башына утыртты, ахры, аны директор?! Бит Таҗетдин,

Әсхәт Лотфиеч язуны укыгач, нервыланыр, ярсып китәр, үзен-үзе белештермичә кычкыра башлар дип көткән иде. Һәм шул вакыт, директорны тәмам аяктан егарлык итеп, берничә зәһәр сүз әйтергә исәпләп куйган иде. Шулай була калганда, директор җиңеләчәк, халык алдында адәм мәсхәрәсенә калачак иде. Ләкин барып чыкмады бит. Тагын барып чыкмады. Болай булгач, тагын фатир тәтемәячәк инде Таҗетдин Ишбулдинга...

Мәҗлес халкының күпчелеге, картның Әсхәт Лотфиечтан язу таләп итеп һавада асылынып калган кулына карап, дәррәү көлеп җибәрде. Кайбер чая хатыннар:

— Ну булган да инде, тапкыр да соң бу Әсхәт Лотфиеч, бер дә җавапка аптырап калмый, чукынган! — диештеләр.

Шулай итеп, Таҗетдин Ишбулдин бөтен эшне харап итеп ташлады. Шулай шул, әйбәтләп йөзә белмәгән килеш, тирән суга кереп маташма инде син?!

Тәэминатчы Гаффар төркеме янә берләшеп, директордан үч алу юлларын эзләп, баш ватарга тотынды. Ә остаханә җитәкчесе яклылар шау-гөр килеп сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә керештеләр табындагы ризык-фәләннәрне сосарга, керештеләр урырга...

Берзаман, һәммәсен дә сискәндереп, ишектә каты итеп кыңгырау чыңлады. Кем икән бу, нинди йомыш белән килә икән?! Ишекне ачып җибәрсәләр: Демон! Янында — Сюзанна!

— Әти?! — диде дә Демон, Әсхәт Лотфиеч каршына барып басты.— Баярак кына безнең фатирга ике милиционер килеп керде... Бүген иртән тимер юл вокзалында, Дөм исерек килеш буталып йөргәндә, Сөләйман Хәзрәтов кулга алынган икән. Аның кесәсендә безнең фатирның адресы язылган кәгазь булган. Шул адрес буенча килгәннәр икән милиционерлар безгә: ул сезнең туганыгыз бугай, диделәр дә, картны бездә калдырып киттеләр... Хәзер Сөләйман Хәзрәтов, бу — минем фатир, мин моннан бер кая да китмим, дип дау куптара... Нишлибез инде, әти?!

Шунда гына кешеләр «Минем фатир — Советлар Союзы!» дип күкрәк сугучы, кырынмаса да ачык йөзле, шат күңелле булып йөрүче Сөләйман хәзрәтнең чын хәлен аңлап алдылар.

Сәгыйрә Бикбулатованың битләре кып-кызыл иде. Таҗетдин Ишбулдин да кушучлап уң як күкрәген тотты. Ә Әсхәт Лотфиеч исә, кара көеп, башын түбән иде.

Барысы да, ул фатир Сөләйман хәзрәткә булырга тиеш дигәндәй, тынып калдылар. Әйтерсең лә бүлмә эчендә төнге тынлык урнашты. Тик бу тынлыкны экрандагы сугыш гарасаты гына бозып куйгалый иде әле. Ниһаять, безнекеләр Рейхстаг

түбәсенә байрак кададылар... Күңелгә-берсеннән-берсе борчулы уйлар килә. Рейхстаг түбәсенә байрак кадәрле байрак кадаучы каһарманнар арасында Сөләйман Сафи улы да бардыр сыман. Күңел ялгышмый ул, әлбәттә, бардыр!

Ә без ул ветеранга нинди кадер-хөрмәт күрсәттек соң?! Ничә фатир бирдек соң без аңа үз теләгебез белән?! Ә бит ул бу фатирны алырга чын мәгънәсендә хаклы булган, иптәшләр! Әйе, хаклы булган...

## *Интуиция*

Татарның Гоголе тирләп-пешеп «Тере җаннар» исемле поэма иҗат итеп утыра иде, кинәт ишектә кыңгырау шалтырый башлады. Бала-чага, ахры. Йә Гөлмир, йә Илшат янына килгәннәрдер?! Фу, бигрәк каты шалтыраталар. Юк, бала-чага түгел бу! Алайса, кем? Күрше-фәләнме?..

Киләчәкнең булачак бөек сатиригы трикосын киде дә ишеккә юнәлде. Ачып җибәрсә, апасы басып тора! Ярты елмы, бер елмы күрешкәннәре юк иде, чөнки Гөлфирнең вакыты юк. Их, шул вакыт булмау!

Каршында билдән ялангач, юеш тәнле энесе басып торуын күргәч, апа кешенең яшькелт-соры күзе елтырап китте.

— Һаман язасыңмы әле?

— Туктарга уйламыйм да!

Ванна ишегеннән, төтен кебек булып, пар чыгып торуын искәреп алгач, апа кешенең алтын тулы авызы җем-җем итә башлады.

— Ай-һай, энем, йөз чакрым юл үткән ат шикелле тирләп-пешеп яза башлагансың икән, маладис!

Апасының сөенеченә теләктәшлек итеп, татарның яшь Гоголе әйтеп салды:

— Җизни үлдеме әллә?

— Каян беләсең?

— Интуиция.

— Үлде шул! Киен әйдә, киттек дәү апаларга, җизнәбезне, йола кушканча, соңгы юлга озатып җибәрик инде!

Күптән көтә иде Гөлфир бу хәбәрне. Чөнки җизнәләренең авырып урын өстенә ауганына кичә нәкъ өч ел тулган иде. Өч ел!

Бер аягын сугышта калдырган җизнә кешенең баш түбәсендә ике бармак сыярлык тишек тә булган икән. Бусын Гөлфир җәһәннәмдә яшәүче дәү апаларының уналтынчы каттагы фатирларына кергәч һәм мәрхүмнең өстенә каплаган ак җәймәнең бер читен күтәреп карагач күрде. Мәрхүмнең йөзе, кулы балавыз сыман сап-сары иде. Алтын тешләрен алганнар бугай: ирене эчкә батып тора, яңаклары сулган, ә муены шак-

тый ук нечкәргән. Ай-яй, кайчандыр әзмәвер бәдәнле иде бу кеше, хәзер әнә бәләкәй генә булып калган. Ышанасы килми хәтта!

— Юа башларга кирәк инде,— диде бер абзый, һәммәсен дә сискәндереп.

— Шулай шул,— диде җизнә кешенең бер туганы,— сугыш инвалиды үлгәч, берәү дә юарга теләми. Ә бай кеше үлгән булсамы? һи, бай кеше үлгән булса-а-а?!

— Чурты-майтыр, үзем юам! — дип дәртләнеп җиңнәрен сызгана башлады кояшта янып каралган эчкече кыяфәтле бер абзый.

— Юк, сиңа юарга рөхсәтебез юк! — диде, бая, юучы булса, үзем укыр идем, дигән бабай телефон аша кем беләндер сөйләшеп утырган җиреннән бүленеп.— Син похоронный командада хезмәт иткән кеше...

Аннары ул татарның яшь Гоголенә таба борылып әйтте:

— Әкрәмнең элекке эшләгән җиреннән яртылаш каплаулы машина җибәргәннәр, әнә шоферы! Бар, энем, шуңа утыр да мәчеттән юуучы алып кайт!

Эченнән генә, ниһаять, дип җиңел сулап куйды яшь сатирик, «Мәчетне кереп күрәм, болай булгач!..»

Мәгәр аңа мәчет эченә керергә туры килмәде. Ишек янында басып торган кизү карт, Гөлфирнең ни йомыш белән килүенә төшенгәч, сул кулы белән кәҗә сакалын сыпырып, теле белән мыегын ялап куйды.

— Шамил мөәзин әле генә китте... Йөз егерме бишенче йорт, утыз беренче фатир. Шунда бар!

Яшь сатирик утыз беренче фатирга килеп керсә, караватта вафат булган берәү ята. Өстенә ак җәймә каплаганнар... Фатирда түзеп булмаслык эссе. Урамдагы бөркүлек мондагыдан чүп кенә икән әле. Гөлфирнең битләреннән, аркасыннан гөрләп тир ага башлады. Мәгәр апалар, әбиләр, чит-ят ирне күреп:

— Хәзрәт килде... Әссәламегаләйкем, хәзрәт,— диештеләр.

— Мин хәзрәт түгел шул. Мин үзем хәзрәтне эзләп йөрим әле,— диде Гөлфир аларга.

Шул вакыт ишектән озын буйлы, сап-сары чәчле, сап-сары сакал-мыеклы, зәп-зәңгәр күзле, яшь кенә кыяфәтле ир-ат килеп керде. Ул башына ак чалма, өстенә кара ряса киеп куйган, һәм калын, гөлдерәвек тавыш белән:

— Мин — хәзрәт! — диде.

— Әссәламегаләйкем, хәзрәт! — дип, яшь сатирик Шамил мөәзин белән күреште һәм аңа гозерен җиткерде.

— Ярый, урамда көтеп тор! — диде хәзрәт.

Егерме минуттан әйләнеп тә чыкты. Башыннан чалмасын, өстеннән рясасын салып, «Жигули»еның уң як урындыгына ташлады да, арт ишекне ачып, Гөлфирне утыртты. Ә киләчәкнең бөек Гоголе тәрәзәдән кулын изәп, үзе утырып килгән машинаның шоферына кайта торырга кушты.

Шамил мөәзин, кардай ак чүпрәк белән машинаның тәрәзәсен сөртеп куйгач:

— Кем ул вафат булган кеше? — дип сорады.

— Сугыш инвалиды! — Гөлфир җизнәсе турында белгәннәрне кыскача гына сөйләп бирде.

— Фатирлары ерак икән шул,— дип сузып әйтте хәзрәт.— Сәгать унике инде... Ярый, мәчеткә сугылыйк әле, анда бер карт бар. Синең белән, бәлки, шуны...

Шамил мөәзин мәчеткә үзе генә кереп китте һәм береаздан әйләнеп тә чыкты.

— Картыбыз кайтып җитмәгән әле,— диде ул.

Булачак мәшһүр сатирик яшь хәзрәтне күндерергә тырышып:

— Җизнәбез бик игелекле кеше иде... Безнең бәхетле яшәвебез өчен, унҗиде яшьтән фронтта аягын калдырган. Алла күрә ул, белә...

Шамил мөәзин, шәһәр өстендә очып баручы вертолеттан күзен алып, Гөлфирдән сорады:

—Кайда эшлисең?

— Университетта... ни, инженер...

Хәзрәт яшел «Жигули»ена кереп утырды һәм ишекне шатылдатып япты да моторны кабызды. Кузгалдылар. Береаздан, күзге аша гына Гөлфиргә карап, сөйләнеп куйды мөәзин:

— Язам, дисең, алайса!

— Каян беләсез?!

— Интуиция! — Шамил мөәзин сигарет кабызды һәм киләчәкнең булачак даһи сатиригына тәкъдим итте.

— Юк, мин тартмыйм,— дип Гөлфир баш тартты.

— Хуш исле тәмәке суыру ләззәтеннән мәхрүм икәнсең, егетем!

— Мин элек тарттым тартуын. Күп тарттым. Аннары инде...

— Менә монысы ярый...

— Миндә бронхитмы, нәрсәме...

— Ә, алайса, тартма инде,— диде яшь хәзрәт һәм кунакханә каршында чытлыкланып сөйләшеп торган өч чәчбигә кычкыртып сигнал бирде. Тегеләр көлешә-көлешә кул изи башладылар.

— Их, шуларны урманга алып китәргә! — диде Гөлфир, күзен уйнатып, хәзрәткә ярарга тырышып.

— Ник алып китәсең аларны урманга?

— Чәчәк җыярга!

— Чәчәкне күбәләкләр генә ярата аны... Өч кызның берсе — /ртадагысы — минеке иде!

Киләчәкнең булачак атаклы сатиригы ык-мык итте, нишләргә белмәде.

— Сул колагыңа операцияне күптән ясадылармы?

— Сезгә кем әйтте, хәзрәт?

— Интуиция! Интуиция көчле минем...

— Интуиция дигәннән... Сез менә, хәзрәт, безнең милләт кешеләренә охшамагансыз...

— Ни өчен?

— Сап-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле сез! Йә, шундыймы инде безнең милләт кешеләре?

— Безнең борынгы бабаларыбыз, нәкъ миндәй, сап-сары чәч-ле, зәп-зәңгәр күзле булганнар, егетем, аннары гына синең шикелле кара чәчлегә әверелгәннәр алар! Әнә килеп тә җитте... Университетта укытучы Хәбриев атлы галимне beләсеңме син?

— Бе-лә-м! — дип шыттырды татарның яшь Гоголе.— Аның белән мәҗлесләрдә дә утырган бар.

— Мин Хәбриев белән күптән түгел генә Истанбулда булдым. Бик тырыш, бик уңган егет, милләтебез өчен җан атып тора. Миннән сәлам тапшыр син аңа!

— Тапшырырмын, әлбәттә, тапшырырмын, хәзрәт!

Лифт белән уналтынчы катка менеп, кирәкле фатирга керделәр. Шамил мөәзин белән ни өчендер исәнләшүче булмады. Хәер, хәзрәт тә исәнләшеп тормады, туп-туры мәрхүм яткан бүлмәгә кереп китте.

Мөәзин ал ягына клеенка алъяпкыч бәйләде, башына кәләпүшен кыңгыр салды, җиңнәрен сызганып, кулына перчатка-лар киде дә, бисмиллаһи-рахман-ир-раһим, дип, комган белән сабынга барып ябышты. Мәрхүмне әйләндереп-тулгандырып, җиренә җиткереп юды ул. Инде кәфенләр өчен носилкада яткан мәрхүмне чак кына алга тартканда, уң күзе ачылып китте. Ачылып китте дә киләчәкнең бөек сатиригына карап тора башлады.

—Үләр алдыннан сине күрәсе килгән аның! — дип пышылдады Шамил мөәзин, Гөлфирнең колагына таба иелеп.— Күрәсеңме, берәүгә дә түгел, тик сиңа гына карап тора!

— Йомдырыгыз әле шуның күзен! Ул бит бораулаган сыман итеп карый!

— Файдасыз... Ул хәзер сиңа күмгәнче карап торачак инде.

Гөлфирнең йөрәге урыныннан купты, чәнчеп-чәнчеп... Аякларының егәре китте. «Минем аннан аласым да, аңа бирәсем дә юк лабаса! Нигә миңа гына карап тора соң ул?»

Ә авылга, зиратка алып кайтып, кабергә төшерер алдыннан мәрхүмнең йөзен ачып, соңгы мәртәбә карап каласы килгән кешеләргә күрсәттеләр. Шул мәлне кемдер яшь Гогольнең җилкәсенә төртеп алды: борылып караса, элекке көтүче малае, яшь галим Әнәс әфәнде Хәбриев!

— Чү! Син ничек монда килеп чыгасы иттең әле? — диде Шамил мөәзин Әнәс әфәндегә.

— Интуиция! — диде Хәбриев. Аннары ул Гөлфиргә карады.— Син... җизнәң турында әйбәт итеп язарга тиеш...

—Язармын... — диде яшь Гоголь. Әкрәм абзый уң күзен йомды.

— Ул хәзер... тыныч йоклар инде,— диде яшь хәзрәт.

— Баҗасы Вәли абзый янәшәсендә...— дип өстәде Әнәс әфәнде.

— И-и-и... Гөлфир улым да кайткан икән әле! — Нәфисә түти, дүрт ай күрешмәгән улын танып, шыпырт кына елап җибәрде.

«Газиз әнкәйләрнең күз яше...» — дигән җыр сүзләре яңгырап киткәндәй булды яшь Гогольнең колагында, һәм ул каршында моңаешып басып торган малайларын шәйләп алды, аннары утлы карашын авылдашларына төбәде. Кешеләр ни өчен-дер күзләрен аннан яшерәләр, гел читкә борылалар, йә агачларга төбиләр, йә күккә карыйлар сыман иде.:

Шул мизгел мәрхүмне кабергә төшерделәр.

...Җизнәсен күмеп, ике ай чамасы вакыт үткәч, Фагыйлә туташ Әнәс әфәндегә кияүгә чыкты, һәм ул, әтисе үлгәннән

соң, аннары җизнәсе вафат булгач, мирас булып калган малны берләштереп кесәгә салды да, галим кияве белән чит илгә, сәяхәткә китеп барды.

Ә Гөлфиргә:Җизнәсеннән мирас булып бары тик бер генә нәрсә — лотерея гына торып калды, һәм Гөлфир, түземсезләнеп, тираж чыкканны көтә башлады. Ниһаять, ул көн дә килеп җитте! Гөлфир лотореясын тикшереп караса, лотереягә «Волга» чыккан иде.

## *« Блат » кирәк*

Ниһаять, газапланып һәм тетрәнеп язган унберенче трагедиямне, мәшһүр артистлар башкаруында сәхнәдә күрәсем килеп, театрга илтә киттем. Барып керсәм, анда афишалар да афишалар... Чү! Аларның берсендә минем дә исем Шәрифлә-

рем бар. Әнә бит акка зур зәңгәр хәрефләр белән Гали Гази дип язганнар! һе, бу... шул инде, мин! Мин булмыйча, кем булсын тагын... Ә пьесаның исеме... У-у-у... «Кыска койрык» икән. Ә минеке «Озын койрык» иде. Димәк, болай булгач, кыскартканнар, ысбулычлар! Күпмегә кыскарттылар икән? Ярар, анысын белербез әле! Жанрын карыйм да... Чү! Музыкаль кәмит, дигәннәр. Мин «трагедия» дип билгеләгән идем бит аны! Хәер, анда көлкеле диалоглар да юк түгел иде ич. Димәк, шулардан чыгып, музыкаль кәмит иткәннәр. Ну, осталар да соң, хайван-нар!.. Ә музыкасын кем язды икән? Гонорары күпме чыгар икән? Әгәр дә мин исәпләгәнчә чыкса, иң элек үземә шәп тун алам, аннары хатынга алтын тешләр куйдырам! Аның үз тешләрен мин, шушы трагедияне, юк, музыкаль кәмитне язганда, сүзгә килеп, коеп төшергән идем ич! Рәхәтен күрсен, әйдә!..

Ниһаять, дөбердәп-шаулап әдәби бүлек мөдире янына барып кердем.

Әдәби бүлек мөдире кечкенә бүлмәсендә, бик күңелсез кыяфәт белән, бәләкәй тәрәзәдән «Клячкин» хастаханәсенә таба карап тора иде. Сәламемә каршы аның бәләкәй колагы селкенеп куйды.

— Утырырга мөмкинме? — дидем мин.

Җавап урынына мөдирнең бәләкәй колагы гына кыймылдады.

Димәк, мөмкин, дип, мин бәләкәй яшел кәнәфигә килеп утырган идем, ул, хәсис, җимерек булган икән, мин шундук шалт идәнгә! Бәхеткә, бала чакта тәкә өстеннән егылып төшеп сындырган аягыма да әллә ни зыян тимәде шикелле. Хәер, бу мизгелдә авызда кан булса да, төкерергә ярамаганны беләм ич инде мин. Бая мөдир янына күтәрелгәндә, баскычта таныш артист туташ очрап, колагыма «Орбит» сагызы исе килеп торган сулышын өрә-өрә:

«Постарайтесь сынатмаска! Ля Шеф-ан промашканы вообще ненавидит»,— диде.

Шуңа күрә, идәндәге мул тузанның шактыен үзенә җыеп өлгергән пальтом белән бергә «ә» дигәнче торып бастым да, мөдирнең гөгелдәп көлүен искәреп, үзем дә. һеһелдәп көлеп җибәрдем.

— Бүген инде син — җиденчесе,— диде мөдир, көлүеннән туктап.

— Шәп-шәп,— дидем мин, кулларымны уып.

— Классик урындык бу! Маминт айныта...

— Хөрмәтлем! Сезнең янга исереп тә кергәлиләрмени әле? — дидем мин, хәйләкәр елмаеп.

Мөдир бәләкәй бармагын тырпайтып, кыска көпшәле пистолет шикелле итеп селкә-селкә:

— Спирт эчеп түгел, ә... гениальный пьеса яздым, дигән ялган хистән исереп.

Аһ, шәп әйтте бу! Ләкин, алайга китсә, мин дә бик төшеп калганнардан түгел, мөдирнең бәләкәй, өтер күзләренә текәлеп:

— Мин... пре-зи-дент кия-ве! — дидем.

— Нәр-сә-ә?

— Мин президент кияве-е!

Мөдир гүя телдән язды. Ниһаять, көчкә-көчкә генә исенә килеп:

— А-а, чежмени әле ул? Мин чежне күптән көтәм бит инде, ә чеж һаман юк та юк! — диде.

Һәм ул күрешергә кулын сузды. Ә мин исә, букчамнан алып, аңа унберенче трагедиямне тоттырдым. Мөдир, урынына утырып, тирләп чыккан бәләкәй маңгаен кульяулыгы белән сөртә-сөртә, трагедиямне укырга кереште. Аның күз алдында хәрефләр биешә иде булса кирәк, һәм ул озак укый алмады, куркулы карашын миңа төбәде:

— Ә, Гали Гаҗи чежмени әле ул?! — диде.

— Мин булмыйча, кем булсын инде! — дип кычкырып җибәрдем мин.

Бүлек мөдире ак кәгазьгә тиз-тиз генәниләрдер язды да, дистәләгән әсәрләр арасыннан трагедиямне алып, кәгазь белән бергә миңа сузды:

— Уңышлар чежгә, Гаҗи Хатипыч! — диде.

— Хаталанмагыз, мин — Гали Фатыйхович! — мин әйтәм.

Мөдир лып итеп кәнәфиенә авып төште. Мин чыгып киттем.

Трагедиям салынган букча нигәдер авырайган сыман тоелды. Мәгәр мин аңа игътибар итеп тормадым, ясканып кәгазьдәге язуларны укырга керештем. Анда менә ниләр язылган иде.

*«һәйбәт рижисурга!*

*Әйбәтләп укып чыктым. Моның писсасы бик әйбәт. Шушы мәсьәләне үтә тиз хәл итсәгез, бик әйбәт булыр иде...»*

Әһә... Миңа хәзер әйбәт режиссерны эзләп табарга кирәк икән! Мин аны грим бүлмәсендә ике актер белән өч актриса арасында кәрт сукканда очраттым!

Күкрәтеп сәлам биргәч, актрисаларның берсе, ярым шәрә ботлысы:

— Чаһо тебе тут нужно? — диде.

Мин исә режиссерга төбәлеп елмайдым, каш сикерттем. Режиссер аңлады, торып яныма килде, һәм тегеләргә карый-карый, миңа:

— Слушаю вас-с,— диде.

Мин аңа әдәби бүлек мөдире язган кәгазьне, трагедиямне тоттырдым. Бу режиссер, чынлап та, әйбәт икән. Башта кара күзлеген салып кәгазьне укыды, аннары, трагедиямне селкә-селкә:

— Моны кая куярга инде хәзер? — диде.

— Ник... Сәхнәдә куегыз! — мин әйтәм.

— һе-һе... Сәхнә буш түгел шул, җанкисәгем!

— Ничек инде ул алай?

— Ш-шулай-й... Сәхнәдә... Радмир Вилдановичның... «Тойото»сы саклана ич!

— Ә-ә, кече сәхнәдә куеп булмыймыни? — дип үҗәтләндем мин.

— Кече сәхнә дә заняты шул. Анда «девяткы»!

һәм мин, режиссерның төссез колагына үрелеп: _

— Төкерәм! — дидем.— Мин... президе-ент кия-ве-е, белдеңме?!

— А-а-а... аңлашылды! — диде әйбәт режиссер һәм лып итеп палас өстенә утырды, трагедиям салынган папканы ачып карый башлады. Аннары миңа күтәрелеп карады, елмаерга тырышып: «Бу — писса түгел икән ич! Бу — шәп роман икән ич!» — дип куйды. Мин эндәшмәгәч, автокаләмемне кулымнан тартып диярлек алды да теге кәгазьнең икенче ягынаниләрдер язып, үземә тоттырды:

— Журналга илт син моны йә нәшриятка — анда гонорарны да галәмәт түлиләр, баерсың! — диде.

«Баерсың» дигән хикмәтле сүз генә кирәк булган инде миңа, күрәсең. Мин, биредә бөтен нәрсәгә кул селтәп, урамга чыгып киттем...

Мәшһүр журналның баш мөхәррире мин алып килгән романны өстәле өстенә куйды да, теге кәгазьнең ике ягын да укыгач, бармагы, белән чирткәләп уйланып торды, аннары кинәт көлеп җибәрде:

— Кызык бит әле бу!.. Язучы халкы театрга пьеса ташый, ә драматург халкы безгә роман китерә!.. Ярый, кем, әсәрең калсын бездә.

— Журналда; кайчан бастырып чыгарырсыз икән инде моны? — мин әйтәм.

— Портфель бушагач! — ди бу.

— Ә пәртфилегез кайчан бушый инде? — мин әйтәм.

— Биш-алты елдан,— ди бу, күзен дә йоммыйча.

— Слушай,— мин әйтәм.— Ул пәртфил дигән нәрсәне быел ук бушатып булмыймы аны?

— Син нәрсә?! — ди бу миңа җикереп.— Бездә атаклы әдипләрнең романнары да җидешәр ел ята әле.

Мин шундук, күркәдәй кабарып:

— Ә мин-н... пре-зи-дент ки-я-ве-е! — дим.

Баш мөхәррирне алыштырып куйдылармыни:

— А-а-а... ш-шулай-мы-ни? — ди.— Ярый, алайса, мин сезнең романны бүген төнлә укырмын... таң алдыннан хәбәр итәрмен! Телефоныгыз бармы?

— Бар...— мин әйтәм. Баш мөхәррирргә кулдан язылган «визитка»мны тоттырдым.

— Мөмкин булса, әйтегез әле, сез кайда эшлисез соң? — ди бу, йомшак кына итеп.

— Мәктәптә (слесарь, димәдем инде) директор булып! — мин әйтәм.

Баш мөхәррирнең сипкелле йөзе кояштай балкып китте.

— Сез әйткән мәктәптә минем җәмәгатем дә директор булып эшли бит! — диде ул.

— Әйе шул! — мин әйтәм.— Ләкин сезнең хатыныгыз «непроф»ларны укыта, ә мин слисәрләр мәктәбенә җитәкчелек итәм!..

Шулай дидем дә, эшләр артык тирәнгә кереп киткәнче, «сипкел»гә кулымны суздым.

Баш мөхәррир минем кулга шундук ике куллап ябышты. Аның учларына салкын тир бәреп чыккан, ә куллары дер-дер калтырый иде.

— Ярар, кем... Миндә телефон номерыгыз бар... таң алдыннан әбәзәтелне шалтыратып хәбәр итәрмен! — диде.

Өемә кош тоткандай сөенеп кайтып кердем.

— Нәрсә, писсаңны куялармы инде, юкмы-ы? — дип, уклауны артына яшереп кенә каршы алды хатыным.

— һәй, пьеса гынамы сиңа, роман язганмын икән мин бу юлы, романымны бер ай эчендә журналда бастырып чыгарачаклар! — мин әйтәм.

Бу кичне без, өч ел аерым ятканнан соң, ниһаять, бергә кочаклашып йокладык! Мәгәр таң алдыннан мине телефон шылтыравы уятты. Хатыным җылы юрган эченнән юан ак беләкле кулын сузып кына трубканы алып бирде, анда исә баш мөхәррирнең карлыгып беткән тавышы ишетелә иде.

— Әлү-әлү,— ди дә,— әлү-әлү,— ди.

— Кто это так рано беспокоит? — мин әйтәм.

— Ә-ә, кем... Гази Галиев әфәнде, җиңүегез белән котлыйм! — ди бу.

— Туктагыз әле,— мин әйтәм.— Мин бит Гали Газиев!

Әмма баш мөхәррир трубканы куеп өлгергән иде инде. Мин хатыныма ни дип җавап бирим икән дип уйланып торган арада, ишектә дәртле генә итеп кыңгырау шылтырады.

Бераздан хатыным минем янга телеграмма күтәреп килде. Театрдан җибәргәннәр икән, рәхмәт төшкере. Анда менә ниләр язылган иде:

«Гали Гыйззәтуллин әфәнде!

Сезнең унбиш ел элек китереп биргән әкият-пьесагыз тиздән сәхнәгә менәчәк».

## *Мин ничек итеп карьера ясадым*

Бу дөньяда һәркем рәхәт яшәргә омтыла. Ә муллыкта яшәү өчен күп нәрсәгә ирешергә кирәк, бигрәк тә матди байлыкка! Матди бөтенлеккә ия булу өчен бик күп рәхәтлекләрдән баш тарта белергә дә кирәк. Менә мин эчмим, тартмыйм. Аннары чит хатыннар янында чуалмыйм. Боларны эшләсәң, матди байлыкка ия булып булмый ич. Байлык булмаса, рәхәт яшәп булмый. Ә рәхәт яшәп булмагач, билгеле инде, озын гомерле булып булмый. Ә минем үлепләр дә озын гомерле буласым килә! Миңа хәзер утыз биш яшь. Белемем — югары!

Мин эшли торган конторда ике генә кеше гуляйть итми иде: мин дә, профком рәисе Зөлфия Мәҗитовна!

Көннәрдән бер көнне Зөлфия Мәҗитовнаның ире үлеп китте һәм ул миңа килеп сарылды: «Әйдә, бәгырем, очраша башлыйк»,— ди.

— Хатыным усал шул,— мин әйтәм.— Юкса контордагы барлык ялгызак хатыннар белән йөреп чыккан булыр идем инде...

Зөлфия Мәҗитовна серле итеп елмая:

— Миндә Кара диңгез буена бер путевка бар,— ди.— Хатыныңны шунда җибәрик, ял итеп кайтсын. Ә син, хатының кайтканчы, көч туплый торырсың!

Килештем, килешми ни, чөнки Зөлфия Мәҗитовна минем хатынга караганда яшьрәк тә, чибәррәк тә!

Хатын китте. Ә мин Зөлфия Мәҗитовна белән рестораннарда типтерергә, таксиларда җилдерергә керештем.

Берничә атнадан мине конторда директор урынбасары итеп күтәрделәр, һәм тагын алты айдан инде мине Мәскәүгә эшкә чакыра башладылар. Баксаң, минем хатын, Кара диңгез буенда

кояшта кызынып ятканда, Мәскәүдән килгән зур гына бер түрә кисәге белән танышкан булган икән...

## Чокыр

Совхоз бухгалтеры Җаббаровның эчә-эчә күзләренә шайтаннар күренә башлады. Беркөнне ул хәтта сөекле карчыгының күрше Наил кочагында ятканын күрде. Шулар тарафына төбәп балта ыргыткан иде, тәрәзә пыялалары чылтырап коелды. Шуннан соң аны хастаханәгә дәваларга алып киттеләр.

Җаббаров монда да җен-пәриләрдән качып котыла алмады. И-и чыелдыйлар тегеләр, и-и азалар, ул гына да түгел, Фәһимне яман эшкә котырталар. Ничекме? «Син монда энә ашап ятасың, ә хатының авылда рәхәтләнеп Наил белән гүләйт итә»,— диләр.

Җаббаров ашаудан калды һәм хастаханәдән качу юлын эзли башлады. Ләкин бер ирнең хастаханәдән качып, суга батып үлү хәбәрен ишеткәч, бу уеннан кире кайтты, һәм Наилнең Салисәгә нәфесен киметә торган бүтән чара эзләп тапты. Ул өстәлгә ак кәгазь куйды һәм каләмен карага манды... Аның күз алдына яшь чагы, Наилнең Салисәне озатып йөргән җәй килде. Хәтерендә әле, Наил аңа: «Ну, малай, Салисәне суырып үптем дә соң!» — дигән иде... Җаббаров каләмен янә карага манды...

***

Лейтенант керүчеләргә төбәлде: җыйнак кына гәүдәле, тулы түгәрәк йөзле мөлаем генә хатын белән озын буйлы, кара мыеклы чибәр ир иде бу.

— Утырыгыз... Фамилияләрегез ничек?

Тегеләр, һични аңламыйбыз дигәндәй, сәер итеп бер-берсенә карашып куйдылар һәм кыяр-кыймас кына фамилияләрен әйттеләр.

— Тәк...— Лейтенант алдындагы кәгазьгә ниләрдер сырлап куйды.— Ә хәзер, Җаббарова, минем сорауларыма җавап бир: Галиев сиңа кем була?

Хатын мыеклы иргә карады, ир дә хатынга карады.

— Күршем бу минем! — диде хатын.

— Күршең белән ничек яшисең, Салисә?

— Аңламыйм! — диде хатын, үзе кызарып китте.

— Татумы? Әллә...

Хатын елмайды, аннары көлеп җибәрде.

— Әлбәттә, тату! — диде.— Тату булмыйча соң...

Ир дә елмайды һәм, хатынның сүзен җөпләп, баш какты.

— Хәзер әйт инде, Җаббарова: ошбу айның унөчендә, кич сәгать унда синең белән Галиев арасынданиләр булды?

Җаббарова янә Галиевкә карады, Галиев Җаббаровага!

— Берни булмады... Ни булсын безнең арада? — диде хатын. Аның йөзе шәфәкъ төсенә кергән иде. Галиевнең дә йөзе шуннан ким түгел иде.

— Хәзер әйт инде, Җаббарова: ошбу айның ундүртендә больницага баргач, ирендә Галиев турында ниләр сөйләдең?

Галиев тә, Җаббарова да дерт итеп куйдылар.

— Ни сөйлим инде мин аңа? — диде хатын һәм, чак кына уйланып торгач: — Шуфир булгач, берәр сүз әйткәнмен инде... хәзерге вакытта кемгә кирәк түгел ул шуфир,— дип өстәп куйды.

— Тик шуның өчен генә ирең Галиев өстеңнән прокурорга шикаять яздымы? — диде лейтенант, хатынны үчекләгәндәй итеп.

— Шикаять? Прокурорга-а? — диде хатын исе китеп.

— Әйе... менә ул!.. Монда шундый урыннар бар ки, әгәр... дөрес булса... күршеңне бүген үк Себергә олактырачаклар!..

Хатын иренен тешләде һәм башын түбән иде. Галиев исә күзләрен челт-челт йомгалап куйды, ни уйларга да белмәде: тәмам аптырап, югалып калган иде.

— Тыңлагыз! — диде лейтенант.— Ошбу айның унөче көнне, кичке унда Галиев, рәшәткә артына посып, сыер эчертеп кайтып килүче Салисәгә һөҗүм итә. Көчләү нияте белән! Салисә югалып калмый, чиләге белән...

— Аһ! Ялган...— дип куйды шабыр тиргә баткан ир.

— Бүлдерми тор әле, иптәш Галиев! Әйе, чиләге белән... башына тондыра... Наил югалып кала... Салисә өйгә чаба... Ләкин Наил озакламый безнең капканы килеп кага: Салисәне әле һаман яратуын, оныта алмавын әйтә һәм өйгә кертүен үтенә... Салисә, билгеле инде, Наилнең исерек булуына төшенә һәм аңа моннан китәргә, өенә кереп ятарга куша... Галиев тыңламый, сүгенә башлый, Салисәгә янарга тотына, ут төртү белән куркыта...

«Көчләү» һәм «ут төртү» дигән сүзләрдән Галиевнең күз аллары караңгыланып китте; башы чыңлый, йөрәге дөп-дөп итеп тибәргә кереште. Хатын исә:

— И-и Ходаем... бар икән күрәселәрем...— дип илерде.

Лейтенант, Галиевкә туп-туры карап:

— Йә, гаепләреңне таныйсыңмы инде? — дип сорады.

— Беразын т-тан-ныйм,— диде Галиев, көч-хәл белән генә.

— Ә кайсыларын танырга теләмисең?

— Салисәнең чиләк белән нитүен... Минем аны көчләргә теләвем... Өйләренә ут салырга маташуым...

—

— Ярый. Инде әйт: ни өчен син Җаббарованы рәшәткә артында сагалап тордың?
— Мин үз хатынымны шаяртып куркытмакчы идем, ә ул...
— Ә төнлә ни өчен Җаббарованың капкасын килеп кактың?
— Мин өйләрне бутаганмын, иптәш лейтенант, гафу итегез!
— Син эчкән идеңмени?
— Кем эчми инде хәзерге заманда, иптәш лейтенант...
— Бөтен бәлаләр дә исереклектән чыга бит, иптәш Галиев... Ярый, аңлатма яз! Җаббарова, син дә яз!
— Ярар, ярар...
Лейтенант аларның аңлатмаларын зур дикъкать белән укып чыкты.
— Булган! — диде лейтенант.— Ләкин болар гына Галиевне коткара алмый әле, иң мөһиме: Җаббаровны шикаятеннән ваз кичәргә үгетләү! — Аннары егет хатынга эндәште: — Иртәнге сигезгә больницага кил!

***

Билгеләнгән сәгатьтә лейтенант килгәндә, Җаббарова тәрәзә каршындагы эскәмиядә ире белән сөйләшеп утыра иде инде.
Җаббаровның өстендә зәңгәр пижама, йөзе шат, күзләре көләч.
— Сәлам! — диде аңа лейтенант.
Фәһим күтәрелеп бакты:
— Сез минем гариза буенчамы?
— Түгел шул, шикаятегез буенча, менә ул! Ә болар Галиев белән хатынының аңлатмасы! Гомумән, фантазия җимешләрегез черек сезнең...
Җаббаровның төсе үзгәрде һәм ул күзләрен алартып хатынына төбәлде:
— Син... тагын Наил белән миңа каршы сүз берләштеңме?
— Син... син... ни сөйлисең, Фәһим?! — Хатын пышынпышын гына балавыз сыгарга тотынды.
— Ярар, карчык, елама! — диде Фәһим. Аннары лейтенантка таба борылды: — Бир гаризаны, ертам!..
Лейтенант, Җаббаровлар белән хушлашкач, авылга барып, кәнсәләргә Галиевне чакыртты.
— Ну, бәхетең... Себер китүдән чак-чак кына котылып калдың бит! — дип каршылады ул аны.— Менә түләрсең... икенче, салып, кеше хатыннарына бәйләнеп йөрмәссең?!
Галиев җавап урынына тешләрен генә шыкырдатып куйды.

***

Җәй уртасы... Җаббаров, бишекле матайда тирбәлә-тирбәлә, күрше авыл кибетеннән кайтып килә иде. Чөгендер җире башланган төштә аны Галиевнең хәләл җефете туктатты:

— Фәһим абый, эчем авыртып тора... авылга утыртып кайтсана! — диде.

Бухгалтер Җаббаров гади генә бер хатын белән тел чайкашып торырга ваксынды, бишек ягына ым гына какты. Утырды теге сары пошлак!

Юл бер урман аша үтә иде. Урманны чыккач, машинасына печән төятүче Галиев күренде. Бухгалтер Җаббаров, шофер Галиевне танымаганга сабышып, үтеп китте. Тере ир исә, явыз елмаеп, тузан өермәсенә карап алды.

Берничә көннән Җаббаров, баш төзәтергә дип, кичтән калганны эзләп маташа иде, йомышчы хатын килеп керде:

— Сине авыл советына милиция чакыра,— диде.

«Эчкән өченме икән әллә?» дип уйлады Фәһим.

Авыл советында ирле-хатынлы Галиевләр дә утыралар иде. Баш кагып кына исәнләштеләр.

— Синең өстән, Җаббаров иптәш, милиция начальнигы исеменә яман куркыныч шикаять керде,— диде өлкән лейтенант һәм шикаятьнең эчтәлеге белән таныштырырга тотынды.

«...матайга икәү утырып урманнан чыктылар... хатынымның күлмәге ертылган иде» кебек дөрес булмаган сүзләр Җаббаровны караңгы һәм тирән чокырга этеп төшергәндәй иттеләр.

Аңына килгәндә, Галиева аңа су бөрки, ә Галиев исә ясалма сулыш алдырып азаплана иде.

## *Без әле шулай яшибез*

Минем хатын, ягъни көтүче кызы, ашханәдә җыештыручы булып эшли. Ә мин исә шабашник малае, бәдрәф тазартам. Көтүче белән шабашник балаларының урыны кайда инде бу заманда? Әлбәттә, без эшли торган төбәктә. Ярар... Быел, Аллага шөкер, икебезнең дә ял җәйгә туры килде, һәм мин бу җәйге ялны рәхәтләнеп авылда үткәрергә ниятләп, хатыным белән төпчек малайны машинага, үз янымда утырттым да каладан чыгып киттем. Машинага утырттым, дигәч тә... машинам чүплектән табып ремонтланган. Кулым алтын минем ул якка: сәга-

тен дә төзәтәм, тузан суырткычын да, барысын да булдырам. Шулай... авылга соң гына кайтып төштек. Арылган. Йокы дигәнең үтә тиз баскан мине. Бераз черем итеп алдым. Уянып күземне ачып җибәрсәм — баҗай төрткәләп маташа икән! «Тор әле, тор»,— ди коры гына итеп. Авызыннан аксыган әче бал исе бөркелә. Кулында тәмәке. Йөзен яктыртып суыра да төтенен миңа өреп җибәрә, бәдрәф исеннән дә зәһәррәк сасысы, борынга кереп, күзне әчеттерә. «Юк, моны бирегә берәү дә кертмәгән, капка өстеннән төшкән бу жулик,— дип уйлап куям мин эчемнән генә, балдызны эт итеп әрли-әрли.— һәй, шушы камунис алкашка кияүгә чыкмаган булса канә, калада укыган вакытта биспартини дворник малаена чыккан булсамы-ы?! Алкаш та түгел иде-е».

— Әкрен, кияү, баланы уятасың! — дип телгә килде уң ягымда яткан биспартини хатыным.

— Ә-ә-ә-ә... син дә мондамыни әле... Торыгыз, тор... киттек чиягә... Балаңны әбигә тапшырып торырсың.

Минем үтереп йокым килә иде, шуңа күрә: «Без ялда,— дидем мин киреләнеп.— Зинһар, безне тынычта калдыр, баҗай...»

— Син беләсеңме? Син (ул тотлыга иде)... беләсеңме, җәйнең бер төне елны туйдыра?! — һәм ул безнең өстән юрганны тартып алды.— Торыгыз!

Шәпләп кенә баҗайның муен шәрифенә кундырасым килеп китте. Узынмасын өчен. Камунис булдым дигәч тә... Мәгәр минем төйнәлгән йодрыгымны хатын тотып калды. «Ярамый, Гайфул,— ди,— син аның кабыргасын санасаң, ул аннары, кайтып, минем сеңелнең гаепләрен саный, кыйный, синнән аласы үчне минем сеңелемнән ала»,— ди.

И балдызкайны, җанашны әйтәм, бигрәк юаш шул инде, баҗай партбилет тота торган кулы белән сул яңагына чәпелдәтсә, ул аңа ләм-мим сүз дәшми икән. Ә үзе, камунис баҗайны әйтәм, гел болай дип бызгый икән: «Менә бусы дворник малаеннан алданганың өчен, менә бусы мине, атасыз үскән малайны алдаганың өчен»,— ди икән, кыяр карагы.

Ә хатын, хәйләкәр төлке, бу турыда сүз чыккан вакытларда сеңелесен яклап, миңа: «Ярата ул Әсфирне, ярата...» — дип әйтә.

Шулайдыр, ярата торгандыр, яратмаса, каладан кайтып, фермада дуңгызлар астын тазартып йөрмәс иде.

Уйларымны баҗай бүлдерде. «Киттек әйдә, неперт!» — ди. Хәер, баҗай үзе дә әллә кем түгел әле, камунис булса да, кырлар каравылчысы гына! Шуның өчен бугай минем аңа җен ачуларым чыкты. «Ә, шулаймы, непертме?!» Йодрыкларым ирексездән йомарланды. Ләкин ярамый, балдыз жәлке! Их, балдызны әйтәм, калада чакта...

— Нинди дворник малае? Син ни сөйлисең? — ди хатын, лакан тулы майлы суны идәнгә түгеп җибәргәндәй итеп.

Йә Ходам, ул сүзләрне чыннан да кычкырып әйттем микәнни?! Мин камунис баҗама карадым. Әсфир инде... җыру суза иде.

Ишегалдына аяк бастык. Мин корама машинамны кабызып җибәрдем. Мәгәр камунис баҗайның мыскыллап әйткән сүзе йөрәгемнән чыкмый да азаплый бит. Неперт, диме? Тфү! Күз алдыма мескен малай чагым килеп басты. Әйе, мин ул вакытта, көтүдән кайтмаган бәрәнне эзләп, ындыр буена ук барып җиттем. Әсфир иптәшләре белән өянке ботагында шалкан кимереп, тәмәке тартып утыра иде. Мәгәр тәмәкеләренә исем китмәде. Ә минә шалканнары кызыктырды . Уйларымны сизгәндәй, Әсфир дигән камсамун жулик шундук каршымда пәйда булды. «Неперт **КАБЫП** караганың бармы синең?» — ди. Белмим, тәмле нәрсәме ул, тәмсезме? Шулай да: «Юк, андый нәрсәне кабып караганым юк!» — дидем. Әсфир ках итеп бармагына төкерде дә авызыма сылады. «Мә, кабып кара инде, алайса!» — ди.

Еллар үтте. Мин бу хәерсез вакыйганы уртанчы малайга сөйләдем. Чөнки улым, авылдан килгәч, елаган иде. «Әти, анда мине гел Неперт малае дип котырталар»,— дигән иде, «Кемнәр котырта? — дидем, тешләремне шыкырдатып,— камсамуннармы? Самунислармы? Или же беспартйниларммы-ы?..»

— Бөтенесе дә...— диде малай.

— Шуларның, — дидем,— һәммәсенең исем-фамилияләрен язып ал да миңа хәбәр ит... Закунда камунис министр да, биспартини бәдрәф тазартучы да бердәй тигез хокуклы дип язылган лабаса!

Беспартини малай аңлады. Тегеләр дә, партиялеләр дә аңлаган булырга тиеш. Тик баҗай гына минә алкаш булуы белән һаман аңламаганга сабышып йөри, алма буры! Хәер, ул дивана апасына да...

Әйе, аның юан артлы камунис апасына тагылган кушаматны белмисездер әле сез? Гаҗәп түгел! Сөйлим, алайса... Шулай көннәрдән бер көнне пионер Әсфир камсамун апасы белән сугышта җиңелә. һәм ул, озын-озакка сузмыйча, камсамун апасыннан үч алырга карар кыла. Җае да табыла. Камсамун апасы мунчага кереп киткәч, пионер Әсфир шыпырт кына ихатага үтә, нәрсәнедер эләктереп, тышка алып чыга да казык башына элеп куя һәм үзе күлгә төшеп су коена башлый. һәм «чибәр» Тәгъзимә чабынып-юынып ихатага аяк басса, ни күрсен, ыштаны урынында юк! вәссәлам... Кем эше? Әлбәттә, пионер  Әсфирнеке... Шуннан

камсамун Тәгъзимә, ихатаның муртайган ишегеннән башын чыгарып, яшелле-күкле тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Әсфир... Үтерәм... ыштанны бир-р-р!

Үткән-сүткән бу әкәмәт хәлнең серенә тиз төшенә: пионер Әсфир бит күлдә су коенып йөри, ә камсамун Тәгъзимәнең зәңгәр борчак төшерелгән ыштаны казык очында җилферди. Менә шушы тамашадан соң камсамун Тәгъзимәгә Ыштан Тәгъзи дигән кушамат тагылып кала инде.

***

— hоп... hоп...— Камунис баҗай рульгә үк ябышты.— Сул якка борылыйк, сул якка...

— Андагы бакчаны саклыйлар шул,— дип, кыйммәтле савыт-саба күтәреп баргандай, курка-курка гына сүзгә катышты биспартини хатыным.— Беркөн әнә фәләннәрне, каптырып, райүзәккә апкиткәннәр дә, төгән чаклы...

— Ха-ха-ха... мин булмаган анда... Мине уятып алып барган булсалармы?! — дип, унбишләп печән карагын кинәт тоткандай, мактанып ташлады камунис баҗай.

— И хәсрәт... син кем соң ул хәтле?! — дип әйтеп салуымны сизми дә калдым.

— Мин-ме-е? Мин — коммунист! Мин барысын да көйлим, барысын да булдырам...— дип сузды баҗай.

Кем белә, бәлки, чыннан да булдыра торгандыр камунис булгач! Әйе, ниһаять, ышандыра мине баҗайның соңгы бу сүзләре, чөнки авылда соңгы елымны яшәгәндә булды шундый хәл. Кыш уртасы иде. hич көтмәгәндә арт ягыма чуан чыкты. Сызлапмы сызлый, тишелми дә: унбиш укол кадаткач та тишелмәде бу — хетегыл да үл! Инде мәктәптә, дәрес вакытында, арт шәрифемнең сул ягына өч китап кыстырып утыра башладым. Хәлем чыннан да бик мөшкел. Өйдә гарәпчә язулы китаплардан гайре нәрсә укый белмәүче әни: «И Ходаем, чуаныңның үлеге каныңа таралса, кәкрәеп катасың инде син, балам!» — ди. Шулай итеп әни мине кочаклап елый, мин әнине... Ә мәктәптә ваемсыз камсамун сабакташларым өчен әллә бар минем чуан, әллә юк — төкереп тә бирмиләр. Шулай берчакны озын тәнәфестә камсамун Әсфир, яныма килде дә: «Әйдә, колагыңа важный хәбәр әйтәм»,— дип, мине читкә алып китте һәм, сул кулы белән иңемнән кочаклаган көе,уң аягы белән шап чуанга! Күземнән көлтә-көлтә утлар очты, йөрәгем типмәс, колакларым ишетмәс булды; җаным,гүя чыгарга теләп, тамагыма килеп бөялде... Күпме вакыт үткәндер, карасам: мин гашыйк булган биспартини кыз да, түгәрәк әйләнүче камсамун кызлар да, камсамун Әсфир дә, бүтән камсамун малайлар да юк. Зал тып-тын. Ә үземнең чуан турысы рәхәт сулкылдый, аннан нииндидер сыеклык чыгып, бот буйлап түбән таба ага... Инде

эчтәге трико тәмам юешләнгән, салкынайган һәм ул мине чир-кандыра,туңдыра. Дерелдим, калтырыйм, тешләрем тешкә тими,ә үзем эчемнән генә камсамун Әсфиргә рәхмәт укыйм: «Рәхмәт сиңа, Әсфирҗан, зур рәхмәт! Зур бәладән коткардың мине...» һәм мин, трикомны салып ташларга дип, ихатага чыктым. Чишенеп кенә торганда, ишегалдыннан камунис директор апа килеп керде. Ул мине шундук күреп һәм биспартини малай икәнлегемне та-нып: «Чү! Әхмәтвафин (әйе, нәкъ шулай диде), кар белән юынып, чыныкмакчы буласыңмы әллә?» Мин дәшмәдем. «Кара аны, Әх-мәтвафин, салкын тимәсен»,— дип, камунис директор апа эчкә кереп китте...

— Менә шушында туктат! — дип, миңа боерык биреп, ка-мунис Әсфир уйларымны бүлдерде.— Машинаның безгә якын-рак торуы хәерле.

— Шулай шул, Әсфирҗан...— дип, мин машинаны туктат-тым, утларын сүндердем, һәм без, ике биспартини белән бер камунис, чиләкләребезне күтәреп, сөйләшмичә генә чиялеккә юл тоттык. Быел чия ай-һай уңган икән, кем әйткәндәй, сыпты рабыз гына! Ә арырак, түбәндә, Майлар авылы, ай һәм йолдыз-лар яктысына иркәләнеп, зур булып җәйрәп ята. Хәзергә ул-бу шетелми әле. Ну, всү же йөрәк, биспартини гына булса да, нидер сизенә, кай тарафтандыр бәдрәф исе дә аңкый сыман. Юньлегә түгел бу! Хатын кая соң әле...

— Их, Гайфулкаем, кинәнәбез быел кыш варенье ашап! — дип каршылады мине биспартини хатыным, латарига кытай фар-юры откандай сөенеп.

— Компот-фәлән дә әзерләп куярбыз беррәттән,— дигән улдым мин, хатынныкыннан битәр үземнең биспартини кү-ңелне төшермәскә теләп.

Шул мәлне якында гына, бик якында гына шартлап нидер ынды; чия куаклары арасыннан бәләкәй генә кошчык пыр-хылдап чыкты да каядыр очып китеп юк булды. Шул тарафка текәлебрәк карасам, каршымда, кул сузымы гына җирдә, бозау хәтле эт басып тора! «Тегеләрнең, ягъни сакчыларның, эте ич бу!» — дип шыр җибәрә язып, уйлап куйдым мин. һәм чия тулы чиләгемне күтәреп, бу тирәдән шыпанлап кына таймакчы идем, мәгәр чиләккә үрелүгә, эт ырылдап, өскә килмәсенме...

— Каптык?! — дип, эчемлек тулы бәллүр тустаганнарны дәр-рәү идәнгә койгандай итеп пышылдады биспартини хатыным.

— Б-б-баҗай кай-да-а?!

Биспартини хатыным як-ягына карана башлады. Камунис баҗай озак көттермәде.

— Чиләкләрегез тулган да икән! — диде ул килеп җиткәч, күңелле генә итеп.— Киттек, алайса...

Камунис бажай бер адым да атларга өлгермәде, эт, бик яман итеп ырылдый-ырылдый, аның каршына ук чыгып утырды.

— Аһ! Эләктек...— дип, тагын нәрсәләрдер мыгырданды камунис бажай, һәм ул җиргә тезләнде дә, ике кулын алга таба сузып, эткә ялварырга кереште.— Эт, бәгырем, җибәр безне кайтарып... Шарик, Бобик, Дүрткүз...— Аннары ул, ярдәм өмет итеп, айга, аннары йолдызларга, аннары бөек Аллага ялварырга тотынды.

Ул арада яныбызда ике ир-ат (чия бакчасын саклаучылар, мөгаен) пәйда булды. Безнең белән алар әллә ни сатулашып тормадылар, иске машинама утырттылар да райүзәккә, милиция бүлегенә алып киттеләр.

Камунис Әсфир (аннан инде, чыннан да, бәдрәф исе аңкый иде) бу ике биспартини кешегә юл буе ялынып-ялварып барды.

— Абзыйлар, җибәрегез мине өйгә кайтарып,— диде,— мин кырлар сакчысы! Ни кирәк: печәнме, икмәкме? Бирәм!

— Ә-ә-ә... син әле шулай колхоз милкен дә уңлы-суллы таратып ятасыңмыни?! Ярар, тегендә... бу сүзләрең өчен дә...— диештеләр биспартини абзыйлар. Алар әле Әсфирҗанның камунис икәнлеген төгәл генә белмиләр иде.

Әйе, җавап тотты камунис Әсфир, камунис булгач, җавапның зуррагын тотты. Безне (хатыным белән мине) биспартини булгач, иллешәр тәңкә генә штраф түләттеләр дә кайтарып-җибәрделәр. Ә Әсфиргә, җан кисәгем, камунис булгач, штрафның ун тәүлек дигәнен чәпегәннәр! Шулай да икенче көнне биспартини балдызкай барып, камунис Әсфирен தоткынлыктан йолып алып кайткан кайтуын да, мәгәр кайтуга ук камунис бажай, явыз, биспартини балдызны эт итеп кыйнап ташлаган. Кыйный, һаман кыйный ул аны. Биспартини балдызны биспартини миннән көнли, теге вакыйганы оныта алмый булса кирәк. Чөнки ул чакта биспартини балдызны ял йортына ияртеп барган биспартини егет, ягъни дворник малае, мин идем ул.

## *Елмаю*

Яңа директорның өйләнмәгән утыз өч яшьлек гаҗәеп бай һәм кызыклы биографиягә ия егет икәнен белеп алган сәгатьтә үк сыр-май заводы конторасында тырышып эшләүче ялгыз ханымнар, туташларның күңелләрендә менә сүнәм, менә сүнәм дигәндәй мелт-пелт итеп кенә янучы өмет уты дәррәү кабынды да, кем әйткәндәй, ыжгырып янарга кереште. Инде Дилүс Варисовичның олы сәнгать океанында горуранә йөзеп баруы — сүз сәнгатен дә үгисетмәве беленгәч, арада каләм кыштырда

тучылар: шигырь, поэма иҗат итүчеләр, хәтта роман сырларга маташучыларның да барлыгы ачыкланды.

Һәрхәлдә, директор үзе төрле опералардан дәртле арияләр башкарырга һәвәс икән. Кыскасы, чын мәгънәсендә затлы хисләр формалаштыра торган музыка дөньясына башы-аягы белән гашыйк кеше булып чыкты ул.

Ә менә мәгълүм заводта инженер-конструктор булып эшләүче Гадилә туташ спорт белән, аның да нәфис гимнастика төре белән шашып мавыга, имеш. Дөрестер. Чөнки ул бередәге сылулардан-сылурак, чибәррәк. Ләкин ни хикмәттер, һәр тарафка яңалык чәчеп, күкрәп, үз кул астындагыларны сөендереп яшәргә омтылучы директорны җитди, басынкы холыклы туташыбыз беренче күрүдә дә, икенчесендә дә, аннан соң да ошатмады: җәй уртасындагы кар базы шикелле салкын, битараф кала бирде ул аңа.

Әмма...

***

Ниһаять, чөгендердәй кызыл йөзле, ат күзле Дилүс Варисович нык сеңерле йонлач беләгендәге «Дан» дигән көмеш сәгатенә карады, көлемсерәп, вакыт! дип уйлады, итләч борын очын кашый-кашый. Туташ-ханымнарның ушын ала торган назлы борынкай, дип сөйләнергә ярата ул үзенең тукмактай борыны турында. Шуңадырмы хуҗаның кәефе гаҗәеп күтәренке. «Их-х, мих-х» дип авыз эченнән генә көйләп алды да ул селектор төймәсенә басты:

— Гадилә? Көтәм!

Шыпырт кына ишек ачылды.

— Әзерсеңдер инде! — дип каршылады «кунак»ны хуҗа һәм, күзләреннән шаян очкыннар чәчеп, аңа күз кысты.

— Нәрсә? — диде Гадилә сәерсенеп. Аннары, дикъкатен тиз генә завод эшенә юнәлтеп, култык астына кыстырып кергән кызыл папканы каушый-каушый гына өстәлгә куйды.

«Әйе шул, җиләкнең вакытында өзелүе хәерлерәк»,— дип уйлады Дилүс Варисович һәм кинәт карашын усалландырып, Гадиләнең зур, туры караучан күзләренә төбәлде.

Туташның карап кына торырдай нәфис аяк буыннары хәлсезләнгән кебек булды. Ул кыргый җәнлектәй ялт кына ишеккә карап алды.

Директор исә кәефле генә көлемсерәп, юан бармагын иренә тидереп:

— Тс-с-с-с! — диде һәм көрәшчеләрнекедәй таза кулы белән сары күн диванга ишарәләде.

Инженер туташ гүя тылсымлы бер көч тәэсирендә шунда барып утыруын тоймый да калды.

Хуҗа затлы, ак костюмын салып йомшак урындыгының артына элеп куйды. Ак нейлон күлмәгенә зәңгәр галстук килешми иде бугай! Аның караве Дилүс Варисовичның күзе аяз күк шикелле зәп-зәңгәр иде! Менә ул Гадиләнең каршына ук килеп басты:

— Әйдә...

Инженер-конструктор, үзе дә сизмәстән:

— Юк! Кирәкми! — диде.

— Кирәк, бик кирәк! — дип, хуҗа «кунак» янәшәсенә үк утырды.

— Аңладым! — диде Гадилә, ниһаять, директор егетнең тәненнән күчкән кайнарлыктан дөрләп кабынып.— Сез, Дилүс Варисович...

— Конечно, шулай!

— Ләкин Сез мине дә аңларга тиеш бит!

— Аңлат!

— Җыр аша... ярыймы?!

— Ярар соң...

Инженер-конструктор туташ бәрхеттәй йомшак һәм ярыйсы ук моңлы тавыш белән җырлый башлады:

**Искән җил күк гомер үтә.—**
**Кем ала соң исәбен?..**
**Уйнарсың да ташларсың, аһ,**
**Куркам бит, җанкисәгем!**

Калын бас тавыш белән директор егет дәвам итте:

**Уйнамам да, ташламам да,**
**Шүрләмә, җанкисәгем.**
**Искән җил күк гомерең үтмәс,**
**Мин алырмын исәбен!**

Җыр бетүгә, ул Гадиләнең бит уртасын үбеп алды. Гадилә ачуланмады, урыныннан торды, өстәлдән папкасын алды, ишеккә юнәлде. Ишектән чыгуга ук аны аппаратның берничә «бройлер тавыгы» каршылады:

— Йә... ничек?

— ...ошадымы соң?

Гадилә туташ, «әйе!» дигән мәгънә белдереп, ым гына какты да үз бүлмәсенә таба үтте.

Кереп утырды. Өстәлнең бер читенә папкасын куйды. Ан-

нары утыз биш тәңкәлек лак сылаган озын тырнаклы бармагын Дилүс Варисович үбеп алган урынга тигезеп, һәм шул мизгел күзләренә бүген генә чәчәк аткан роза гөле чалынып, гомерендә беренче мәртәбә рәхәтләнеп елмайды.

## *Икәү*

Кыр юлы буйлап кызып-кызып, бәхәсләшә^бәхәсләшә икәү бара. Икесе дә кызмача. Алар чыккан авыл тарафыннан «Родина, Родина!» дип радиодан берәүнең җыр сузганы ишетелә.

— Ә нәрсә ул Родина?! — дип сорады тәбәнәге кинәт.

— Родинамы? — диде озыны, яулык бәйләнгән (теше сызлый булса кирәк) яңагын сыйпап.— «Родная мать родила, вот моя Родина» дип җырлый идек без армиядә чакта... Ә син, абый, шуны да белмисең, Родинаның нәрсә икәнлеген дә...

— Беләм, энекәш, синнән биш мәртәбә (дөньяны күбрәк күргән, янәсе) артыграк беләмдер әле. Менә ул, Родина нәрсә.— Тәбәнәге — башына ямьшек кәпәч, өстенә уңа башлаган зәңгәр халат, аякларына кунычы кайтарылган резин итекләр кигәне — җиргә тибеп күрсәтте.— Без шушының өчен революция ясадык. Тик ул хәзер синеке дә түгел, минеке дә...

— Кемнеке соң ул, алай булгач? — дип сораган булды озыны, күзләренә үк батырып фирменный эшләпә кигәне. Өстендә аның кызыл эчле, чем-кара француз курткасы, аякларында «Адидас» кроссовкалары иде.

— Белмим, һәм белергә дә теләмим,— диде тәбәнәге, халат кесәсенә тыккан кулын чыгарып селти-селти.— Мин хәзер җир кешесе түгел: икмәк икмим, мин гади бер сатып алучы гына.

— Ну, даешь, абый! Кибеткә китерелгән икмәкне ашаганчы, аны сатып алырга кирәк бит әле,— диде озыны, теше яман злаганга, ахры, йөзен чытып.

Ул күптән түгел генә читтән «баеп» кунакка кайткан иде. «Хәерче» абыйсы аны әй сыгып карады да соң! Тәмам бөлдереп 'ерәсе иде, тик тегесе Яшелчә урамындагы фахишә хатынга тәшеп өлгерде. Әнә яңагы да шунда шеште инде аның; кесәсе дә шунда такыраеп беткәндер инде, кабахәтнең?! Шулай да рхәмәтле абыйсы үзенә ияртеп алып барачак әле аны район хастаханәсенә, сызлаган тешен суырттырырга. Чөнки кунак узган җәйдә һәйбәт өс-башын райүзәктә юк кына бәягә сатып киткән иде. Ә быел? Юк инде, бүтән мондый хурлыкка калырга Ходай язмасын!.. Ләкин тегеләре өчен үчен кайтарачак әле

абый кеше бу юлы, һичшиксез, бише белән кайтарачак, менә күрерсез... һәм турыдан-туры һөҗүмгә күчте:

— Акчаң булса-а, алырсың! — дип, эчке кесәсеннән бер кап акча чыгарды. Ул шулай көяз киенгән, мәгәр кесәсендә бер *тиен* дә акчасы калмаган энесен ирештерергә тели иде, билгеле. Тегесе исә, күзләрен челт-челт йомгалап, авырткан яңагын Кама тарафына борып, бик мескен хәлгә төшүенә аптырап басыпп тора башлады.

— Хак сүзләрдән ояласыңмы әллә, братан? Оялма! Шундый-шундый эшләрдән соң оялып торалармыни инде...

— Абый, әнә машина килә, туктат әле...

«Димәк, чынлап та акчасы калмаган моның» дип уйлады тәбәнәге. һәм:

— Нефтьчеләрнеке бу, Карнау ягына китә,— диде. Аннары:— Акчаны күп каера болар, братан, акчаны күп «төшереп» азынып беткәннәр, синең тиеннәрең белән хисаплашып та торилар,— дип өстәде.

Озыны уфылдап куйды, ике кулы белән дә яңагын тотты, күзләренә яшь бәреп чыкты.

— Күтәр инде, абый, күтәр!

«Әһә, юл хакын миннән түләтмәкче була бу? Тот менә! Фахишә Гөлсем түләсение юлына! — һәм ул энесенә өттереп карап куйды.— Ә үзе, хастаханәдә тешен суырткач, сыра эчмәкче була әле, субакы».

— Абый?

— Бусы да нефтьнеке моның... Карнау янәшәсендәге сазмыкта нефть чыгарып карамакчылар ич... Чыкса, ә, нифтене әйтәм, баеп бетәр идек аннары, чит илләргә валютага сатып...

— Шулай булыр иде дә бит, дуслар күп, дуслар, башта алар**ны** туйдырырга кирәк! — дип кирегә сөрә башлады озыны.

«Бу тиле, «дуслар!» дип, фахишә Гөлсемне күз уңында тотып әйтәме, әллә кибеттә эчертә-эчертә аяктан еккан авыл гыйбадларынмы? Ләкин тегеләре дә, бусы да рәхмәт әйттеме икән аңа тик торганда гына акчасын суга салган өчен? Тот капчыгыңны!» һәм ул, кесәсеннән башланган аракы чыгарып, шешә авызыннан бер-ике йотым эчте дә, бөкеләп, янә чалбар каешына кыстырды. Бу хәлне күреп энесе, телен чыгарып, иренен ялап куйды: бик тә эчәсе килә иде, ахры, әмма сорарга базмады. Ә абый кешенең инде башына да китеп өлгерде булса кирәк, кызып-кызып сөйләнә башлады:

— Бозылды хәзер кешеләр, яшьләр дә азынып бетте, белмим, нәрсә булды, элеккеге иркенлек юк инде... яшәүдән тамчы да ямь табып булмый хәзер бу чукынган заманда...— Абый кеше эчке

кесәсеннән гел йөзлекләрдән генә торган берничә кап акча чыгарып җиргә ташлады. Мәгәр «кунак»ның кылы да селкенмәде.

— Ут төртеп яндырыйммы?— диде абый кеше, кыргый алма капкан сыман йөзен чытып.

— Яндыр-р-р!

— һә, хикмәте дә шунда инде анын, энем, яндыра алмыйм мин боларны, хәтта хатыныма да, балаларыма да бирә алмыйм, ә үзем шулардай башка тора алмыйм — нишләдем мин? Дөнья үзгәрдеме, әллә тормышмы, әллә үземме — белмим... Элегрәк, мин яшь чагымда, кесәмдә бакыр тиеннәр булмаганда да исем китми иде дөньясына, һай, шат күңелле, уен-көлкегә әвәс егет идем мин. Ә хәзер...— Абый кеше акчаларга тибеп җибәрде.— Кесәмдә шушылар булмаса, сөйләшәсем дә, урамга да чыгасым килми, ник алай ул? Ә инде бу зобанилар куенымда кабы-кабы белән яткан чакта, гүя мин канатлы ат: батырлыгым да, кыюлыгым да поты белән. Теләсә кемне сәгатьләр буе авызыма каратып тора алам. Дөрес, бу элегрәк шулай иде, ә хәзер...— Абый кеше җиңе белән күзендәге яшьләрне сөртеп алды.— Мин шашарга могу! Әйе, әйе... Юкса үз акылыңдагы кеше ут төртеп яндырырга теләр идеме боларны?..— Озыны иреннәрен кыймылдатып куйды, әмма авызыннан сүз чыкмады.

— Шул шул менә,— диде тәбәнәге.— Яндыра алмыйм...— һәм иелеп җирдән акчаларын алды.— Килегез әле, җаныйларым, кереп оялагыз әле җылы куеныма... Акчаның кадерен аны тир түгеп тапкан кеше генә белә... Менә син, энем, шахтер булгач, акчаны көрәп кенә алгач, әлбәттә, кадерен белмисең... Ә мин менә, тишек бүрек, алама җилән, юкә чабата киеп үскән малай, бик беләм акчаның кадерен... Ә син абыеңның җилкәсендә үскәнгә күрә сикерәсең: хатыныңны да иркәләп боздың, малайларыңны да азындырып бетердең... Ә мин... малайларымны кеше итеп үстердем, берәүгә дә махы бирмиләр әнә... Безнең бабай мәрхүм: «Иртә өлгергән алманы корт баса»,— ди торган иде. Шәп әйткән бит. Ә мин бабакайның сүзләрен болай шәрехләр идем: «Иртә өлгергән баланы бозык баса!..»

Озыны уфылдап куйды, чирәмгә сузылып ятты һәм учы белән яулык бәйләнгән яңагына орынды. Тәбәнәге исә... голтголт итеп аракы йотты да, шешәсен янә чалбар каешына кыстырып, сүзен дәвам итте.

... — Тегермәнче урыс әйтә иде, балаларыңа карата гаять жестокий син, друг, дип. Мин әйтә идем аңа, мы сами-то в ж-жестокости воспитывались, и детей-то нужно ж-жестоко воспитывать, иначе нам крышка! дип. Көлә иде теге, ну все ровно злой ты мужик, дип... Ха-а, ди идем мин, был бы мягко, жевали бы

как жевачка... Во! Это верно, дип печәт чәпәп куя торган иде ул һәм ни өчендер үзе күңелсезләнеп китә иде... Тегермәнче урыс гаҗәп сәер кеше иде. Әгәр аннан исерек чагында берәү өстендәге күлмәген сораса, ул аңа анысын да салып бирер иде... Дөрес, үзе исән вакытта андый юмарт эчкече бәндәне хөрмәт итәргә мөмкиннәр, кабатлап әйтәм, үзе исән чакта гына... ә үлгәч инде?! Шуңа күрә мин мондый алама гадәтле кешеләргә кызганып карыйм... Менә мин үзем саран, усал кеше, ләкин мин хәйләкәр бит... Малны мин, берәүгә дә калмасын әле, дип, күмеп, яшереп, бу дөньяны ташлап китәргә ашыкмыйм... Мин болай итәм, энекәш, акчаларымны Швейцария банкысына күчертәм дә, үлгәч, минем исемемдәге халыкара премия булдырсыннар өчен, васыятьнамә язып калдырам...

Озыны, абыйсына караган килеш, селкенеп куйды һәм аның чалбар кесәсеннән каргаборын чыкты да чирәмгә төште. Ул үзе моны сизмәде.

— Нәрсә эндәшмисең... димәк, син дә минем яклы?..— диде тәбәнәге.— Шулай шул, мин бу турыда күп уйладым инде, энекәш... Үзем исән чакта зур мәртәбәләргә ирешеп яши алмадым, инде сөякләремне гүр туфрагы күмгәч, исемемне бөтен дөнья халыклары олы хөрмәт белән искә алсыннар иде, дим... бу шулай булачак әле, мин моңа ышанам...

Озыны, ниһаять, озак еллар амбарда эшләп пенсиягә чыккан абыйсының кайчандыр «колхоз амбары — дәрья, ә мин шул дәрьядагы балык» дип көлдергәнен хәтерләде һәм:

— И-и абый! Синең ул акчаларың иске бит, узган ел ук әйләнештән төшеп калдылар ич инде алар,— дип кычкырып җибәрде.

Тәбәнәге сискәнеп китте, җиргә тезләнде һәм тырмаша-тырмаша энесенә таба бара башлады:

— Әйе... иске шул,— дип мыгырданды ул,— яндым мин, утсыз-төтенсез генә, кычкырып... Бөлдем! Хәзер авылда миннән дә хәерче кеше юк! Ә бит мин, әти белән әни каберенә куярга, чардуганнарга, ташларга заказ биргән идем... ясаткан өчен аларга нәрсә сатып түлим инде мин хәзер?! — Ул энесе янына килеп җитте, каргаборынны кулына эләктереп алды: — Ач авызыңны! — дип боерды.

Тегесе карышып маташкан иде, бусы аның өстенә үк менеп утырды...

Берничә минуттан инде көяз кунакның авыру теше абыйсының учында ята иде.

Тагын берничә мизгелдән абый кешенең башында фирменный эшләпә, өстендә кызыл эчле чем-кара француз курткасы, аякларында «Адидас» кроссовкалары иде.

— Син боларны барыбер дармы-шармыга сатып, эчеп бетерәчәксең юлда, ә мин, боларны сатып, әти-әнинең каберенә чардуган белән таш куячакмын! — дип сөйләнә иде абый кеше.

## *Бер картлыкта, бер яшьлектә*

Нурания җиңги яңа өйгә керде дә мич казнасына утырып уйга калды. Әле генә Фәсихы мичче Сәфәрне алып килер өчен күрше авылга китте бит.

Сәфәр Нураниянең яратып кияүгә чыккан беренче ире иде. Дүрт ай гына бергә яшәп калдылар, сугыш гарасаты купты, Сәфәр фронтка китте. Харьков тирәсендә эзсез югалды!

Әле дә хәтерендә җиңгинең... Бер як күкрәгенә сабыен, икенчесенә үлем хәбәре китергән хатны кысып күз яше түккәннәре... Хәтерендә соңгы өмете булган малаен күмгәндә шашып-шашып үксүләре.

Җиңү көнен чәчүдә каршылады Нурания. Ул бу вакытта агач аяклы Фәсихта тормышта иде инде. Фәсих яманат чыгарган егет түгел, мәгәр Сәфәр дә начар кеше түгел иде.

Бигрәк тә гөрләвекләр челтерәшкән төннәрдә Сәфәр Нураниянең исенә еш төшә, җан тынычлыгын ала иде. Ә көзге караңгы төннәрдә, Фәсихы каравылда чакта, җиңги: «Стенадагы сәгатьнең асып куям тирләрен. Үлгәч тә сине эзләрмен, тар булмасын гүрләрем»,— дип моңайды.

Ниһаять, сугышта үлем хәбәре килгән кайберәүләрнең исән икәнлекләре беленә башлагач, Нураниянең дә күңеленә шик төште. «Сәфәр дә исәндер әле, менә кайтыр да минем кияүгә чыгуымны гафу итмәс...» — дип эчтән генә сызды.

Сәфәр чынлап та исән иде. Кайтуының икенче көнендә үк, зиратка барып, баласының каберен эзләгән, ә төштән соң... Ләкин өйгә кермәгән нишләптер. Аннары кое буена киткән, хатынын көткән, билгеле. Кызганыч, бу көнне Нурания авырып урын өстендә яткан иде.

Ә Сәфәр икенче көнне дә көткән, өченче көнне дә, көтеп-көтеп тә морадына ирешә алмагач, өметен өзеп, читкә үк китеп барган, ди.

Кайларда гына эшләмәгән Сәфәр, нинди генә чая хатыннар иптәш итәргә теләмәгәннәр аны. Шулай да... Туган авылына кайтып төпләнде Сәфәр. Ялгыз кайткан иде.

***

Ишек ачылып китте. Өйгә икәү керде.

Сәфәр үзенә генә хас ягымлы тавыш белән:

— Хәерле иртә! — диде.

— Хәерле иртә! — дип җавап кайтарды җиңги.

Ирләр мич казнасы янына килеп бастылар, ә Нурания: «Мин малайны уятыйм әле»,— дип чыгып китте.

Марсель торган иде инде. Бил тиңентен су белән юынып маташа иде. Җиңги, малаеның таза беләкләренә, кояшта каралган киң җилкәсенә сокланып карап куйгач, мунча ихатасыннан сөлге алып чыгып кадакка элде дә җиләк җыярга кереште.

Нурания өйгә кергәндә, Фәсих инде маллары янына киткән, ә Сәфәр мич чыгара башлаган иде.

Җиңги, почмак якка үтеп, табын яңартырга кереште. Ләкин ир-егетләр чәйне ике чынаяктан артык эчмәделәр. Алар купкач, Нурания дә торды. Аның күңеле сөенеч белән тулы иде. Нигәдер елыйсы да килә кебек. Әллә Сәфәрнең мактавыннанмы? Җиләген ошатты бит. Чат шикәр генә, ди.

Нурания, табынны җыештырып алгач, каз бәбкәләрен карарга Типке елгасы буена төшеп китте. Аннан кайткач, Марселенә измә ясарга булышты. Кичкә мичнең яртысы тәмам булды.

Икенче көнне җиңги иртүк торып көтү куды. Башта Фәсихны эшкә, аннары Марсельне, сынау тапшырыр өчен, мәктәпкә озатты. Сәфәр килгәндә, өйдә ялгызы гына иде. Ә мич остасы, гадәттәгечә күн алъяпкыч ябып, инструментларын тоткач, менәсе урынга менмичә, тышка чыгып, измә ясарга кереште. Нурания, яңакларына ут каба башлавын тоеп: «Кирәкми, Сәфәргали, измә ясау синең эшмени ул!» — дип әйтергә теләсә дә, Сәфәрнең барыбер үз ниятеннән кире тайпылмаячагын сизеп, тыелып калды.

Менә Сәфәр тагаракка су салды, аңа кызыл балчык белән ком кушты, аларны озаклап бутый торгач, измә дигәнең әзер дә булды. Шуннан соң мичче хуҗа хатынга:

— Ярый инде, Нурания, син үз эшләреңне кара, монысын мин үзем дә көйләрмен! — диде.

Хуҗа хатын теләр-теләмәс кенә ишеккә юнәлде.

Менә инде ул Типке елгасы буенда, яшел чирәм өстендә каз бәбкәләрен ашатып утыра... Түти инде казларга карамый, аның хыялый карашы елга аръягындагы әрәмәлекләргә текәлгән. Кичке уенда Сәфәр белән куыша-куыша сөрлегеп егылгач, тәүге кат үбешкән бәхетле кыз чаклары хәтеренә төшә аның. Моңсу, бик моңсу булып китә җиңгигә. Ул тора да бәрәңге бакчалары буйлап авылга таба юнәлә.

Урамга кергәч, адымнары ешайды җиңгинең. «Бәрәч!» — дип куйды ул. Арт як өйнең түбәсеннән морҗа, ә морҗадан төтен чыгып тора лабаса! Туктады да таң калып карап тора башлады. Могҗиза бит, валлаһи! Шуннан соң җиңги калган юлны ничек үтүен дә, өйгә ничек кайтып керүен дә тоймый калды. Тик тәрәз буендагы эскәмиядә, такыр башына чигүле түбәтәен кыңгыр салып, әле эш киемен дә алыштырмаган көе, Сәфәрнең гармунда өздереп-өздереп уйнап утыруын һәм, колгадай буен уртага бөгеп, мич эченә Марсельнең утын атып торуын күргәч кенә исенә килде.

Суыткычта пилмәнлек ите бар иде, шуны алып камыр җәяргә кереште. Улы Марсель исә идәнне минуты-секунды белән измә калдыкларыннан арындыргач, мунчадан су алып керде һәм уңган хатын-кызларга хас җитезлек белән ышкый-ышкый юарга кереште. Сәфәр генә гармуныннан аерылмады. Нурания пилмән ясап бетергәндә, Марсель дә үз эшен төгәлләгән, юынтык суны түгәргә дип, тышка чыгып киткән иде. Берзаман: «Яңгыр-р-р...» — дип атылып керде ул. Өстенә кожан киде дә бәбкәләрне алып кайтыр өчен Типке елгасы буена йөгерде. Нурания белән Сәфәр тәрәзәгә капландылар. Урамда инде шаулап-шаулап яңгыр котырына, ялт-йолт итеп яшен яшьни, җирне дер селкетеп күк күкри иде.

Ниһаять, баш өстендә, югарыда, нәрсәдер чартлап ярылды кебек һәм шуның артыннан ук морҗа эченнән йодрык шае утлы божра, чыжылдап чыгып, әллә җил, әллә башка сәбәптән ачылып куйган тәрәзә аша юк та булды.

— Үз гомеремдә икенче мәртәбә күрүем! — диде түти.

— Минем дә! — диде Сәфәр. Ул яны белән торган көе маңгаендагы тирләрне сөртеп алды һәм, кулъяулыгын салырга дип, кулын кесәсенә китерде. Ләкин кулъяулык кесәгә керергә теләмичә, Нураниянең алдына килеп төште дә ачылып-таралып китте. Чын мәгънәсендә пакь йөрәк, саф күңел белән чигелгән истәлек яулыгы иде бу. Нурания аны теге чакта Сәфәргә әрәмәлектә тапшырган иде. Әле бергә тора башлагач та, Сәфәр аны үзеннән калдырмыйча йөртте. Фронтка киткәндә дә үзе белән алды... Баксаң, шул яулык хәзер дә исән икән!

Сәфәр, аңа карап, тын гына елый иде.

Нуранияның дә күңеле мөлдерәмә булып тулды һәм ул кайчандыр өзелеп-өзелеп сөйгән бу кешене әле һаман яратуын, аны мәңге-мәңге оныта алмасын аңлады.

## *Өч чакрым юл*

Тәслимә түти хәбәр көтә иде. Шылт иткән тавышка да сагаеп, тыңлана башлый ул. Менә-менә кемдер капканы ачып җибәрер кебек. Аннары түти хыялын эшкә җигә. Ишегалдында итекләрен каккач, ул кеше,"баскыч сайгакларын шыгырдатып, болдырга күтәрелер, кармаланып ишекне ачар, әллә ничаклы салкын ияртеп, өйгә килеп керер, исәнләшер һәм: «Ай-һай, көне дә көне!» — дип, бияләйләрен салып, кызарган ун төпләренә өрер, бармакларын угалар. Шуннан соң гына ул кеше кулы белән мыегындагы бәсләрне сыпырып төшерер, шатлык-куаныч тулы күзләрен түтигә төбәп:

— Тәки морадыңа ирештең бит, Тәслимә апа! — дияр.

Әйе, шулай дияр. Аның шулай диячәгенә ышана түти. Карчык хәбәр китерәчәк кешенең исемен дә белә, шул исемне еш кабатлый: «Гарәпша!..»

Тәслимә түти бүген дә көнозын тәрәзәдән күзен алмый Гарәпшаны көтте. Шулай күңеле белән яшь бала сыман очынып өметләнгән бер мизгелдә, түтинең күзләре стенадагы бер сурәткә төште. Ничәнче мәртәбә инде аның йөрәге тетрәнеп куйды, елганың теге ягындагы авылдан килен булып төшкән чагы хәтеренә килде.

Җәй уртасы иде бугай. Атна буе яуган яңгырдан соң дәррәү кыздыра башлаган кояш җир өстен инде тәмам катырып куйган иде. Юлларда, көзгедәй булып, эреле-ваклы күлләвекләр җәйрәп ята. Гүя катлы-катлы ак болытлар һәм зәңгәр күк җиргә төшеп яткан да шул күлләвеккә танавын төртеп эчәргә кыймый тора.

Һидият белән Тәслимәнең солы басуы буйлап җигүле атта җәйләүгә таба китеп барышлары иде.

— Булды, җитте,— дип сөйләнде Һидият.— Йолдызларны күп санаттың, Тәслимә, инде бергә кушылып, дөньяның матурлыгын балалар белән күреп яши башларга вакыт!

Тәслимә башын артка ташлап тын гына көлде, аннары:

— Киләсе елга... шомыртлар чәчәк атканда, яме, Һидият,— диде шаяртып.

Тәслимә, чынлап та, биргән вәгъдәсендә торды. Туйны зурдан кубып үткәрделәр, һәм, ниһаять, ике яшьнең йолдызлы кичләр, айлы төннәр, шаяру-бәхәсләшүләр, кызып китү һәм чак кына үпкәләшүләр белән тулы гомере, ике чишмәдәй бергә кушылып, тирән елгадай тын гына, назлы гына ага башлады.

Һидияткә эш төткәреп булмады. Тәслимә дә иреннән ким куймый иде. Һади каенатай бәхетле иде: Бибисара әнкәй дә иреннән ким сөенмәде. Көтү куа Чыккач, хатыннарга киленен мактый. Яшелчә бакчасында кыярларга су сипкәндә, ызандашларына: «Шөкер, әйбәт киленгә тиендек»,— дип сөйләнә.

Әмма бу тату тормыш озакка сузылмады. Көннәрнең берендә ил өстенә сугыш афәте ябырылды. Бик күп асыл иргетләргә ияреп, Һидият тә сугышка чыгып киткән иде. Шул китүдән кире әйләнеп кайтмады. Һади каенатай да кайтмады. Бибисара кыска гомерле булып чыкты. Шулай итеп, Тәслимә елга аръягындагы йортта берьялгызы торып калды.

Ә гомер дигәнең саллар шикелле агып үтә дә китә икән.

Бүгенге көн дә үтте инде. Әнә кояш байый. Гарәпша килмәде, ахры...

Тәслимә түти тәрәзә яныннан кубып китте. Күңеле борчулы, бимазалы иде аның. Бер-бер хәл булдымы икән әллә? Әмма бу сорауга ул җавап таба алмады.

Карчык ут кабызды. Чәй эчеп алды. Аннары, ак җирлеккә кыңгырау чәчәкләре төшерелгән чаршауны аралап, мич артыннан кабасын тартып чыгарды. Йон эрләргә кереште. Гарәпшаның хатыны, син оста эрлисең, дип, күп итеп йон биргән иде. Кышкы озын төннәрдә артык ямансулап киткәндә бик ярап куя бу кул эше.

Тәслимә түти, моңаеп, мавыгып, озак һәм күп итеп эрләде. Ниһаять, күзләрен йокы баса башлады. Ул караватка менеп ятты.

Карчык тирән итеп сулыш алды, күкрәк читлегендә гүя зур куыш барлыкка килде, кан тамырларында талгын гына дулкыннар тибрәнде. «Их, килде рәхәт заманнар! Әмма...— дип уйлады түти, соңгы елларда күргәннәрен, кичергәннәрен бер җепкә тезеп.— Кеше дигәнең рәхәткә чыдый алмый башлады хәзер. Бер-беренә этлек арты этлек кыла, куенында үч, йөрәгендә явызлык йөртә. Ни өчен? Мае артыкка күрә. Элек без, станцадан чана тартып кырыгар чакрым кайтканда, бер-беребезгә игелек кылу турында гына хыяллана идек. Димәк, кешене кайгы-хәсрәт берләштерә. Тук тормыштан гарык кеше бәхетнең ни икәнен аңламый. Элгәре хәсрәт чикми, акыл керми адәм балаларына, дип җырлар җырлый идек. Ә хәзергеләрнең җырлары... Шуңа күрә дә олыны — олы, кечене кече итү бетте. Кем көчле — шул алга чыга, кемнең кулында — шуның авызында...»

Карчык көрсенеп куйды. Өй эчендә сәгатьнең ашыкмый гына текелдәве ишетелә иде. «Чикерткәләр дә сайрамый хәзер,— дип янәдән уйга бирелде түти,— тараканнар да йөгерешми, чебеннәр дә кырылып бетте. Кыр казларына, кыр үрдәкләренә төшеп, йөзәр күл калмады, булганнары да, төпләренә ләм утырып, саегып киптеләр, корыдылар... Элек күлләр тирән, балыклы, таллы, камышлы иде, сулары чиста иде. Элек халык бердәм иде. Хәзер халык таркалды да, вакланды да...»

Тәслимә түти чак кына терсәгенә күтәрелә төште. Тәрәзәдән тулы ай, аксыл күкнең бер чите, бәсәргән агачлар һәм елганың теге ягында берән-сәрән генә утлары белән туган авыл караеп шәйләнә иде. «Әнә безнең урам,— дип уйлады карчык.—

Мин туган нигездә хәзер авыл советы... Елганың теге ягындагы авылга барып кайтыр өчен өч чакрым юл үтәргә кирәк, чөнки турыдан күпер юк!»

Ул тәрәзәдән күзләрен алды, башын иләп кенә мендәргә куйды. Шул күпер хакында булырга тиеш инде ул зарыгып көткән хәбәр. Бу хәбәрне аңа район советыннан Гарәпша китерергә тиеш иде. Килмәде бит...

Карчык йоклап китте. Уянгач та, өй эченең салкынаюын тоеп, җылы юрган эченнән чыгарга иренеп ятты. Кояшның бакыр төсендәге нурлары тәрәзә бозларында сүрән генә булып җемелдәшә башлаганда, исенә килде. Бүгенге көннең күңелсезлекләр алып килмәвен теләп, урыныннан торды. Нафталин исе аңкып торган чиста киемнәрен киде. Караеп ыржайган мич авызына сак кына иелеп, ут кабызды. Йөзенә ал шәүлә төште. Ачык һавада күп итеп утын яргач, элегрәк әнис алмасыдай кызара торган иде аның бит урталары. Хәзер ничек икән? Яшь чагында аңа алма битле Тәслимә, диләр иде...

Түти күлмәк җиңнәрен терсәгенә тикле сызганып юынды. Чиккән сөлге белән йомшак кына итеп сөртенде, һидият көрәшеп алган тагы бер чиккән сөлге бар әле зур агач сандыкта. Анысын, күпер төзелеп беткәч, Сабан туена сөлге җыеп йөрүче «никрут» егетләргә бирергә дип адарынып куйды инде,

Карчык караватка болан сурәтле бәрхет покрывал җәйде. Кызыл атлас тышлы дүрт мендәрен икешәрләп ике почмакка куйды. Мендәрләр өстенә ак челтәр корды. Аннары күәс янына килде. Камыр да матур булып кабарган икән!

Менә, соскыч белән кисәү тотып, мич авызына иелде ул. Кояшлы көнне талгын җилдә тирбәлгән кызыл чәчкәләрдәй җем-җем итүче күмерләрне чуенга тутырды, бөккәннәрне пешәргә тезеп куйды, корымлы юшкәне башка ис тимәслек һәм шул ук вакытта мичнең җылысы да чыгып бетмәслек итеп кенә япты. Аннары көзгедәй итеп агартылган самавыр тирәсендә мәш килде. «Гарәпша уннардан да калмас инде, бәлки, иртәрәк тә килеп җитәр әле, йөрәге түзмәс»,— дип үз-үзен юата башлаган иде, шул мизгел ян тәрәзәне кемдер шакыды.

Гөлләрне аралап, Тәслимә түти тәрәзәгә капланды. Көмеш болытларны, ак тауларны, тагын әллә нәрсәләрне хәтерләткән кар бизәкләрен сулышы белән эретеп, тышка күз салды. Авыл советында җыештыручы Нәсимә икән, чаңгы белән килгән! «Сәвиттә эшләүчеләр, гадәттә, йомышка-фәләнгә Нәсимәне чаптыралар»,— дип борчулы уйлап алды түти. Гүя шунда күк күкрәде, тау-ташлар ишелде, җир тетрәде, шул мәхшәр эчендә кинәттән Гарәпшаның чал мыегы, чак кына кәкрерәк борыны, ач яңа-

гы һәм чулак кулына тоткан кызыл унлык күренеп китте. «Ышан миңа, Тәслимә апа! Мин дә башкарып чыкмасам, ул күпер эшен тагын кем генә булдыра алыр!» — дип ант итә кызмача Гарәпша...

Карчык исенә килде: «Хәзер! Хәзер!.,» — дип, өстенә киенә башлады.

Капканың теге ягында, айның ундүртенче кичәседәй балкып, Нәсимә басып тора иде. Нәсимә гади генә итеп киенгән. Ләкин ул кирәк чакта кала ханымнарының да күзләрен кыздырырлык итеп киенә һәм табигать биргән чибәрлегенә тел-теш тидермәслек итеп кенә бизәнә дә белә иде. Нәсимәне авылда гадел булуы өчен хөрмәт итәләр, чөнки ул тормышның җелеген суырып алырга җыенмый, кем әйткәндәй, күккә сикерми, барына риза булып яши белә. Аның кебекләр инде унны бетергүгә, калага китеп, әллә кем булдылар, Нәсимә әле һаман авылда — авыру әнкәсен карый.

Нәсимәнең көләч йөзенә карап: «Юк, бу пошаман хәбәр китермәгән,— дип уйлады карчык,— авыр хәбәр китерсә, кызның йөзе болай якты булмас иде», һәм ул Нәсимәнең сәламен алды. «Шөкер, бер Көйгә кыймылдап ятам әле»,— диде. Аннары ул кызны өенә чакырды.

Түти артыннан Нәсимә өйгә керде. Өй эченә, тәмле булып, майда пешкән ризык исе чыккан иде. Нәсимә, үзе дә сизмәстән, төкерекләрен йотып куйды. Колагында салмыш Гарәпшаның: «Беренче сорт пешекче ул Нәсимә»,— дигән сүзләре яңгырап киткәндәй булды.

Мех эчле курткасы белән йон башлыгын чөйгә элде кыз һәм, өй эченең пакьлегенә соклана-соклана, өстәл янына килеп утырды.

Тәслимә түти исә кызның яшьлегенә, тазалыгына сокланды: шундый шәп кызның бүгенгәчә кияүсез яшәп ятуына ачынды. Аннары: «Әнисенә бердәнбер бала шул»,— дип нәтиҗә ясап куйды.

Түти белән кыз, кара-каршы утырып чәйләр эчә-эчә, тормыш-көнкүреш хәлләре турында җай гына сүзгә керешеп киттеләр.

Карчык тыштан сабыр күренә. Әмма аның күзләре һаман Нәсимәдә. Ул, эчтән тынычсызланып, хәбәрнең тизрәк әйтелүен көтә иде булса кирәк. Ләкин Нәсимә нишләптер ул хакта сүзне үзе башларга җөрьәт итми тора иде. Бераздан инде карчык түзмәде, серне чишәргә вакыт икәнлегенә ишарәләгәндәй, Нәсимәгә сорау бирде:

— Монда килгәндә Гарәпшаны очратмадыңмы?..

— Кичә кибет янында күрдем. «Сул кулымны фриц өзеп алмаган булса, ул күперне күптән саласы кеше идем инде мин»,— дип, ике бабай каршында күкрәк сугып тора иде.

— Ә-ә-ә,— диде түти. Аннары: «Миннән әҗәткә алган унлыкны суга салып йөргән чагы булган инде алайса»,— дип уйлый-уйлый, касәсенә чәй агыза башлады.

— Гарәпша абыйга әйтеп яздырган гаризаңны... — диде Нәсимә, түтинең текәлеп каравына уңайсызланып, күзләрен алсу тырнакларына төбәп, һәм аннары, сүзләрем ничегрәк тәэсир итәр дигәндәй, карашын янә карчыкка төбәде.— Район советында тикшергәннәр дә гаризаның азагында «Хәзер инде ерак юлга чыга алмыйм, аякларым үтереп сызлый, ике авыл арасына күпер салдырыгыз» дигән сүзләрнең астына кызыл белән сызганнар да, кичекмәстән чара күрергә дип, авыл советына җибәргәннәр...

Тәслимә түтинең күзләре очкынланды, яңакларына алсу төс инде кебек. Ул хәтта эчә торган чынаягын куеп, берәр сүзне ишетмичә калмыйм тагын дигәндәй, тын алырга да куркып, Нәсимәнең авызына гына карап утыра башлады.

— Авыл советында... — дип дәвам итте Нәсимә.— Астына кызыл сызган җөмләләрне хәтәр нәрсәләргә юрап бетерделәр, һәммәсенең дә күңелендә тик бер генә уй: нишләргә? Бәйләнчек карчыкның бимазалавыннан ничек котылырга? — Нәсимә, сүзләреннән бүленеп, касәдә калган чәен эчеп куйды да дәвам итте: — Совет әгъзалары бу мәсьәләне чишә алмыйча үзара пышын-пышын гына бәхәсләшкән арада председатель аягүрә басты да: «Иптәшләр, Тәслимә апаны картлар йортына озатырга кирәк, минемчә»,— дип ташлады. Тегеләрнең тынып калуларын өнәмичә: «Өен сатып китәр, билгеле»,— дип өстәде. Шуннан соң калганнары да: «Шулай шул, шулай итәргә кирәк»,— дип, председатель сүзен хупладылар...

— И-и-и,— карчык, Нәсимәнең сөйләп бетергәнен дә көтмичә, куллары белән битен каплады.

Карчыкның иңбашлары дерелдди, арык тәне ток тоткандай калтырап-калтырап китә иде.

— Ни өчен?..— дип үкседе түти.— Кемгә зыяным тиде икән соң минем?..

Түтине юатырдай йомшак-иркә сүзләр әйтмәкче иде Нәсимә, әйтә алмады. Чөнки мондый чакта хәлгә кереп, кызганып әйткән сүзләрдән генә елаучының йөрәгенә җиңеллек килмәячәген ул аңлый иде.

— Картлар йорты кирәкми миңа,— дип дәвам итте карчык яшь аралаш.— Минем үз йортым бар ич. Күрәсең бит, яңа әле ул. Артистлар авылга килсә дә, гел миңа кертәсез бит. Яныма

торырга һәр елны укытучы кызлар кертәм. Узган көз дә кертәсе идем. Күпер булмагач, эшкә йөрергә ерак, дип килмәделәр. Салсыннар күпер!..

Нәсимә урыныннан купты:

— Сыең-хөрмәтең өчен зур рәхмәт, Тәслимә апа... — дип киенә башлады.

Карчык эндәшмәде. Ул әле һаман, очкылык тоткандай, үкси иде. Бары тик Нәсимә чыгарга кузгалгач кына, урыныннан торып, кызның кулларын тотты, тутырып күзләренә карады. Ни әйтергә теләде икән ул?!

Елга буйлап китеп барганда, инде Нәсимәнең дә күзләреннән яшь ага иде.

...Шулай итеп, Тәслимә түти алдына зур сорау килеп басты: нишләргә? Гомер иткән нигезне бөлдереп, һәр аткан таңда кояшның чыгуын сагынып каршы алган шушы әрәмәле су буйларын калдырып китсенме ул?! «Китмим,— дип үз-үзен дәртләндерде ул, ниһаять.— Гомер кичергән нигеземнән бер карыш та... Әйе... менә... хәзер...» Шкаф тартмасын ачты, Чүпрәк-чапраклар арасыннан бәләкәй генә төенчек тартып чыгарды. Сөйләнә-сөйләнә киенде, өй ишегенә йозак салды, капка тимеренә аркылы таяк куйды да сукмак буйлап яр читенә килеп җитте.

Елганың теге ягында шау-шу иде. Анда мәктәп. Балалар. «И-и күпер булса!..— дип уйлады түти.— Мин ул балаларны өемә чакырып сыйлар идем. Балалар да, бу ялгыз әби дип, йомышымны тыңларлар иде...» Карчыкның күзенә яшьләр килде. Ничәмә-ничә еллар инде Тәслимә түти шундый уй-хыяллар белән яши! Әгәр авыл советы рәисе Ханиев, бик искергән, бик тузган инде бу, бәладән башаяк, яңаны салырга кирәк, дип, элекке күперне җимертеп ташламаган булса, аның бу өметләре тормышка ашкан да булыр иде.

Дөрес, баштарак, Ханиев яңа күпер салдырам дип, «җиңнәрен сызганып» маташты маташуын, аннары бәләкәй авылны зур авылга күчерү шаукымы купкач — суынды, һәм тора-бара бу эшкә тәмам кул селтәде. Ул арада күпер юлларын да бәбкә үләне күмеп китте... Җитәкчеләрнең йөрәкләре мүкләнү, аларның халыктан аерылулары, халык күңеленә күпер сала белмәүләре — менә шулай башланды инде безнең илдә.

Карчык елмайгандай итте. Әйе, Ханиев күперне җимерткәч, кайберәүләр, Тәслимә көн саен өч чакрым үтеп эшкә йөри алмас, арыр, талчыгыр, түзмәс, өен сатып, колхоз үзәгенә күчеп килер, дип сөйләнгәннәр иде ич. Әмма ялгыштылар. Тәслимә һаман күчмәде, эшен дә ташламады, пенсиягә чыккач та, байтак еллар ферма юлын таптады. Ул чакларда әйбәт иде әле, биш

ай буена юлны кыш кыскарта — елга өстенә боз ката. Ә менә берничә ел элек, нефтьчеләр бораулап киткән җирләрдән кайнар чишмәләр бәреп чыккач, елга өстенә кыш көне дә боз катмый башлады. Бик зур бәла иде бу Тәслимә өчен. Бу газаптан котылуның бердәнбер юлы — күпер иде. Әмма ул күперне, кирәксенсәләр дә, салдырабыз, дип зурдан кубып йөрүчеләр юк иде шул инде. Кешеләр торгынлык дип аталган зәхмәт белән егылып бетеп чирли башлаган еллар иде бит ул. Хәтта бер кулын фриц өзеп алган Гарәпша да баш төзәтергә акчасы булмаганда гына (матур апасының хәлен белер өчен, янәсе) килеп чыга һәм үзенең сукыр киңәшләрен биреп китә иде. Тәслимә түти, Гарәпшаның киңәшен тотып, беркөнне куак таягына таянып, өч чакрым ераклыктагы авылга — советка юл тотты. Ханиев райүзәктән кайтып җитмәгән иде әле. Бер хатын исә, шәлме, нәрсәме бәйләп утырган җиреннән башын күтәрми генә:

— Син яшәгән җир совхозга керә бит, апа, күперне шулар төзетергә тиеш! — дип сүзен бетерде.

— Әйтүләре җиңел дә, килеп-китеп йөрүләре авыр шул,— дип, түти аксаклый-аксаклый кайтырга кузгалды. Шулай да ул, ун чакрымдагы совхозга барып, җитәкчеләрне эшләреннән бүлеп, күпер турында сүз кузгатып карады. Анда да аңа: «Ул төбәктә безгә күпер кирәкми әле, һәм синең өчен генә күпер чаклы күпер салдыра алмыйбыз, син инде, иң яхшысы, давай безгә үзең күчеп кил!» — диделәр.

«Ә мин анда күчеп нишлим?.. Мине анда кем белә?..— дип уйланып кайтты түти.— Мине хәзер туган авылымда да оныттылар диярлек, елга бер генә исләренә төшерәләр, анда да каладан артистлар килгәндә генә...»

Колакка кыңгырау чыңнары ишетелде, балаларны дәрескә чакыра булса кирәк, «һай, былбыл балаларыдай сайрашалар, бәгырьләрем! — дип уйлады карчык.— Кайберләре, ямансулагандай итеп, бирге тарафка — миңа карап торалар, ахры. Их, бу күпернең юклыгы... Шуның аркасында бит инде бер-берләребез белән аралаша да, аңлаша да алмыйбыз, һаман болай дәвам итсә, киләчәктәниләр булып бетәр, Ходаем?! И... Ханиев?! Ханиев?! И... район советы эшмәкәрләре?!» Түти елмайгандай итте. Исенә совхоз җитәкчеләре әйткән сүзләр килеп төшкән иде. «Апа, яшәргә кыен булса, монда күчеп кил, имеш». Җүләрләр! Җәннәтне ташлап, кем тәмугка керсен, әкәмәт! Гарәпша да шулай ди. Туган нигеземне онытмадым мин, кайтып, өй салып яшәячәкмен әле, ди. Гөрләтеп эшләргә яшьлеге, балта-пычкы тотарга ике кулы булмаса да дәртләнә бит картлач. Күпер генә салсыннар,

имеш. Күперне салсыннар өчен яздык ич инде без ул язуны... Тәслимә түти учы белән күз яшьләрен сөртте. «Бөтен өметем төенчектә! — дип уйлады.— Төенчекнең серен чишеп биргәч, Ханиев, бәлки, гозеремне аяк астына салып таптамас! Үтәр! Әлбәттә, үтәр!» — һәм түти туры сукмактан тау төшә башлады.

Авыл советына килеп җиткәндә, төш авышкан иде инде. Ханиев, өенә кайтырга дип, ахры, кабинеты ишегеннән чыгып килә иде. Аның күзләре бүген үтә уйчан, ә йөзе бик борчулы сыман иде. Елап күзләре кызарып беткән түтине күргәч, Ханиевнең уйчан күзләре кинәт елтырап китте, ә борчулы ак йөзен шул арада кара болыт баскан сыман булды/ «һә, килгән икән. Теге хәбәрне ишеткәч, итәгеңә ут каптымыни, кортка?! Соңардың шул. Гел әйтә: килдем мин сиңа, коега төкермә, суын үзеңә эчәсе булыр! дип. Тыңламадың. Инде менә «максатыңа ирештең» — үзең утырган ботакны үзең кисеп төшердең. Көзгегә үпкәләмә!» Рәис карчыкка арты белән борылды, ишек йозагын бикләп, ачкычларын кесәсенә шудырып җибәрде. Аңа баярак кына өйгә тиз кайтып җит! дип хәбәр китергәннәр иде. Чөнки аны өендә, әгәр дөрес булса, хатынының абыйсы (Мәскәүдән кайткан) көтеп торырга тиеш иде. Табында, әлбәттә, башкала күчтәнәче — әрмән коньягы да — менә мин инде ул дөньяның кендеге! дигәндәй тора булыр әле. Аннары Җаһитның үзенең дә суыткычта «борыч чәе» белән «үгез каны» бар бит. Шулар янында, үзенең урынын, дәрәҗәсен белеп кенә, Җаһитның авылда (хәер, авылда гынамы икән әле!) иң чибәр хатыны да утырсамы — бетте! Дөньяда иң бәхетле кеше — Җаһит! Җәннәт— Җаһитныкы!

Шулай да, дәшми-тынмый гына чыгып китәргә яхшысынмыйча, Ханиев сәгатенә карады, тиз-тиз генә:

— Бүген кабул итмим, эш сәгатем чыкты,— диде.— Иртәгә килерсең, апа, иртәгә, ишетәсеңме?!

Түтинең хәле китте, күз аллары караңгыланды: егылмасам гына ярар ие, дип торганда, түр бүлмәдән, шулай ярыймыни инде, Җаһит, дигән сыман нәзек кашларын җыерып, Нәсимә чыкты. Ул, әлбәттә, рәиснең сүзләрен ишеткән булырга тиеш.

Ханиев Нәсимәгә яшертен генә кызыгып йөри иде бит. Сүз дә юк, кыз шәп булырга охшый. Мондый чакта әйтәләр бит әле, ачылып укылмаган матур тышлы китап кебек, дип... Әйе, җыештыручы кызның үткен дә, шул ук вакытта сөйкемле дә карашы Ханиевне каушатып җибәрде, йөзе аклы-кызыллы булды.

— Үзе гаепле! — дип мыгырданды ул һәм кесәсенә салып куйган ачкычларын кире чыгарды.— Үзе кибеп корышкандай үҗәт булгач соң!..

Ханиевнең фирәзә кашлы алтын йөзек кигән бармаклары сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде.

Эчкә уздылар.

Идәндә зәңгәр сызыклы кызыл келәм. Кыйммәтле мебель. Җитәкчелек итә торган бүлмәсенә аяк баскач, Ханиевне алыштырып куйдылармыни. Ул тагын да усаллана төште һәм, үзенең кем икәнен кабат барчасына да танытырга теләгәндәй, урындыкны каударланып, дөбер-шатыр китереп артка этте дә чит илдә эшләнгән өстәл артына кукраеп кереп утырды. Иреннәрен бөрештереп, мыекларын күпертеп, тартмадан ниндидер кәгазьләрне ялт кына суырып чыгаргач, аларны җилпи-җилпи түтинең борын төбенә китереп терәде:

— Картлар йортына җибәрәбез сине... Менә документлар тутырылган инде. Картлар йортына, аңладыңмы?

Тәслимә түти тик шунда гына Җаһитның күзләре дүрт төрле төстән торганлыгын искәреп алды. һәм ул төсләр Җаһитның рухи халәтенә карап үзгәрәләр дә икән әле. Гаҗәп! Табигатьтә бик сирәк очрый торган кавем бит бу. Гаять куркыныч кавем.

Карчыкның көтмәгәндә генә сыны катып китте һәм ул шунда аяклары астындагы идәннең чайкала башлавын тойды. Егылып китүдән аны Нәсимә генә тотып калды.

— Юк, юк, дөрес әйтмисең, ялганлыйсың, Җаһит! —диде Нәсимә.— Апаның ризалыгы юк, син аны берничек тә картлар йортына җибәрә алмыйсың!..

Каян килеп чыккан яклаучы булды соң әле бу дигәндәй, Ханиев җыештыручы кызга тутырып карап куйды.

Нәсимәнең соңгы сүзләре түтигә шифалы тәэсир итте. Ул тураеп басты. Куеныннан төенчек тартып чыгарды да председательнең алдына куйды. «Өендәге бетен кадими кәгазь-фәтәннәрне җыеп килгән инде бу!» — дип эченнән көлеп уйлады рәис. Шуңа төенчеккә орынмады.

— Нәрсә бу? — дип кенә сорады.

— Акча! — диде түти. һәм тамагын кырып куйды. Аннары, батырая төшеп, Ханиевнең дүрт төрле күзләренә туры карап өстәде: — Күпер салдырырга сезнең акчагыз юк икән дип ишеттем. Монда минем гомерем буе эшләп җыйган якчам, салдырыгыз күпер!

Ханиев карашын читкә алды. Кашларын җыерды. Ләкин тиз генә җавап бирмәде. Баш бармагын чигәсенә терәп, уң кулына тоткан ручкасы белән өстәлне шакый-шакый, тәрәзәгә карап уйланды: «Карчык белеп әйтә... безнең акчабыз бик аз. Әнә икенче ел инде авыл советы бакчасының рәшәткәләрен сырлап-бизәкләп эшләтә алмый изаланам. Инде тирә-юньдә бер дигән останы да таптым. Әмма бәяне кыйммәт сорый». Ул

түтигә карап куйды, аннары карашын түенчеккә күчерде. «Әгәр дә бу акчаларны шул изге эшкә сарыф итсәк, ә?» Рәис хәтта шатлыгыннан кулын кулга сугып куйды. Аннары, бик тәкәллеф белән йомшак кына итеп, карчыкка сүз катты. Түти исә якын да килмәде:

— Юк, күпер салдырыгыз, бары тик күпер генә салдырыгыз,— дип, үз сүзләрен өскә чыгара торды.

Ниһаять, Ханиев, киребеткән бу карчык белән эш майтара алмасына төшенеп:

— Ярый алайса, балта осталарын ялла да ул күперне үзең салдыр! — дип, җәһәт кенә урыныннан купты.

Тәслимә түти председательнең каршына ук килеп басты.

— Риза булмыйлар шул, авыл советының рөхсәте кирәк, диләр. Алайса, Җаһит энем, күпер салу өчен рөхсәт кәгазе бир миңа!

Ханиев кайчандыр балта осталарына, минем рөхсәттән башка күпер төзи күрмәгез, дип әйткән иде. Шул хәтеренә төште, һәм:

— Андый кәгазьне мин бирә алмыйм,— диде. Аннары уйлап куйды: «Ни өчен әле мин җитәкче башым белән кемнәргәдер изгелек эшләргә тиеш. Киресенчә, кемнәрдер миңа изгелек эшләргә тиешләр ләбаса! Чөнки миңа кешеләр түгел, ә мин кешеләргә кирәк!..»

Шулай итеп, рәис, кабул итү сәгате чыкканлыгын аңлатып, ачкычларын кулына алды.

Менә бит бөтен хикмәт Ханиевнең рөхсәт бирү-бирмәвеннән генә тора. Ул рөхсәт бирсә — күперне салалар, бирмәсә — юк!..

Тәслимә түти бары тик зират буена җиткәч кенә исенә килде. «Кара инде бу Җаһитны, бигрәк тә юньсез икән... Күзләре дә юкка гына дүрт төрле түгел икән аның!» — дип, шәл чите белән күзендәге яшен сөртте.

Өенә кайтып җитте дигәндә, караңгы төште. Ул тәмам эштән чыгып арган иде. Чәй дә кайнатып тормады, кочкә урын җәйде дә салкын юрган эченә кереп ятты.

Тәрәзәдә томан, томан... Елга да, теге яктагы авыл да күренми: буран купкан иде.

***

Буран төнозын котырды. Нәсимә, керфек тә какмыйча, җилдавыл тавышына колак салып, уйланып чыкты. Тәслимә түтине кызгана иде ул. Торып әнисен карады. Әни кеше тигез сулыш алып йоклый. «Юк, Тәслимә апаны картлар йортына җибәрттермим,— дип куйды кыз.— Күпер белән эш барып чыкмады инде... Иң дөресе — Тәслимә апаны үзебезгә яшәргә алып кайтам. Әни каршы төшмәс әле».

Бу төнне Гарәпша да йоклый алмады. Махмырдан тубал булган башын юеш сөлге белән урап, ах-ух килеп йөрде. Намусы газаплый иде аны. Әйе, белде бит ул шулай булачагын, барысын да алдан сизде, әмма, Тәслимәдән бу дөреслекне яшереп, эчәргә акча алу өчен алдашып йөрергә мәҗбүр булды. Ниһаять, абзый: «Тәслимәне үзебезгә чакырам,— дип уйлады.— Кыз кияүгә киткәннән соң бушап калган бүлмә бар, шунда яшәр! Ә хатын? Хатын нәрсә ул, монда әлегә мин баш!..»

Җаһит исә чибәр хатынының җылы куенында тыныч үткәрде бу төнне. Таң атты. Буран басылган иде. Җаһит хатыны белән эшкә китте. Мәктәп янында хатыны аннан аерылып калды.

Тыкрыктан килеп чыккач, авыл советы каршында Нәсимәне күрде.

— Җаһит, районнан шалтыраттылар, артистлар килә икән. Нишлибез, аларны шул Тәслимә түтигә урнаштырабызмы? — диде кыз ашыга-ашыга.

— Тагын кая булсын? Нәрсә, бу юлы киреләнер, дисеңме?

— Белмим, Җаһит. Тик мин Тәслимә түтигә ул сүз белән бара алмыйм, үзең сөйләш.

— Бар, алайса, чакыр Гарәпшаны, ат җиксен, үзем сөйләшәм карчык белән,— диде Җаһит.

Ат яшь, таза һәм йөгерек. Тиз килеп җиттеләр.

Капка аша атлап, өйалды ишеген күмгән карны көрәп бетергәнче, Җаһит белән Нәсимә кара тиргә баттылар. Бу вакытта сыңар куллы Гарәпша абзый арлы-бирле йөренеп торудан, атка печән каптырудан башка нәрсәгә ярамады.

Ниһаять, эчкә үттеләр.

Тәслимә карчык, ахрысы, ишеген кар басканга гаҗизләнеп йөргән-йөргән дә кире караватына яткан иде. Ханиевкә эшне ничек тә җайларга, карчыкның күңелен күрергә кирәк, шуңа күрә ул өй эчен яңгыратып сәлам бирде. Карчыкның үпкәсе бик зур, күрәсең, боларга таба әйләнеп тә карамады. Нәсимә, каударланып, аптыраулы кыяфәт белән түтигә таба иелде, аның кулына сак кына кагылды. Гарәпша абзый гына бу минутта, нидер сизенеп, бусагага утырды.

Тәслимә түтинең тәне урамдагы кар кебек салкын иде.

## *Бер шатлык та бер кайгы*

— Тр-р-р, дим, тр-р-р, мәхлук...

Көтмәгәндә ишетелгән бу тавышка сискәнеп, Галимә тәрәзәгә капланды. Фатыйх карт икән. Капка төбенә килеп җит-

кәч кенә кулыннан дилбегәсен төшергән дә арба көпчәгенә чорнаткан, шуны алам дип азаплана. Галимә, дөрләп кабынган ут кебек, кинәт борылды да өй эше белән әвәрә килеп йөрүче Гафифә түтигә:

— Әни, башыңа юеш сөлге ура да тиз генә урынга ау,— дип кычкырды.

Гафифә, эшнең асылына төшенеп җитмәгән сыман, йөзенә каушаган бер кыяфәт чыгарып:

— Чү! Дөнья бозылган мәллә, нигә өтәләнәсең шулхәтле? — дигән булды. Ә үзе исә эченнән генә сөенә иде, тәки килгән бит: сүзен сүз иткән бит Фатыйх! Ләкин кызы үз исәбендә нык торырга чамалый иде булса кирәк, көчләп диярлек урынга яткыргач, Гафифә түти бүтән карышмады һәм, үзен авыру булырга тиешле санап, әйтте:

— Чәйгә сөт салып китер әле, кызым, тамагым кибебрәк тора.

— Китерәм, әни, хәзер,— диде Галимә, серле генә пышылдап. Аннары, күзләрен хәтәр елтыратып: — Фатыйх абзый өйләнергә йөри икән... Пыранлатып куам әле мин аны бу юлы,— дип Гафифә түтине утка салып, кече якка китте.

— Әйтәм аны,— дип мыгырданды карчык, башындагы сөлгене капшап.— Әйтәм аны, шуңа икән, шул хикмәттән өркүе икән бахырымның.— Гафифә түти яткан уңайга гына кул сырты белән күз кабагын кашып алды да, тфү, зәхмәт, дип, үзалдына төкеренеп куйды. «Яшь чыкмагае тагын, күз кабагы кычыту юньлегә түгел инде ул, башка да әллә нинди уйлар килә...»

Галимә бүлмәгә әйләнеп кергәндә, арткы өйдә калын, көр тавыш яңгырады. Гафифә түти сискәнеп китте һәм эченнән генә Фатыйх картның сәламенә каршы: «Исән әле, Аллага шөкер, менә шушылай бер чама яшәп торабыз кана»,— диде дә, тормакчы булып,.урыныннан күтәрелде. Моны күргән кызы, утлы табага баскандай, янына очынып килде.

— Энекәем, торма инде, ят шым гына, монда үтә-нитә калса, ыңгырашып җибәрерсең.

«Һай, бу Галимә... Фатыйх мине алып китәргә килгән дип дуамаллана бит тәки. Сүзен дә тыңламыйча булмый, газиз балам бит ул минем!» Гафифә түти, теләсә-теләмәсә дә, кире урынына ятып, телен аркылы тешләргә мәҗбүр булды. Галимә моның белән генә ризалашмады әле, өстенә юрган да япты, аның чит-читләрен матрас астына кыстырып, эшен тәгәлләгәч, Фатыйх карт янына чыкты.

— Чү! Галимә сеңлем, әниең өйдә юкмы әллә? — диде Фатыйх карт.

— Өйдә әйдәсен дә, саулыгы китеп тора әле.
— Ни булды инде тагын?
— Кар базына төшкәндә егылып башын бәргән.
— Бик яман сызлыймы?
— Төн буе үкереп таң аттырды.

Шул мәлне идәннәрнең шыгырдап китүеннән картның үз янына кереп килүен чамалады Гафифә түти. Кызы да тыеп кала алмады, күрәсең. Аюдай лап-лоп атлап, мондый көрешүгә әзерләнмәгән карчык янына тәки үтәсе иткән. Кем әйткәндәй, татар тотып карамыйча ышанмый, дигән кебегрәк килеп чыга инде бу... Әнә Фатыйх, иң элек рөхсәт сораган булып, бүлмә эченә көләпүшле башын тыгып карады, җавап бирүче булмагач, түргә үк үтте. Карт артыннан кабаланып кызы да ияреп кергәч, Гафифә түти бердәм каушап китте. Ыңгырашасы урынга, тыелып кына көлеп җибәрде ул.

— Бәрәкалла... Менә син, әй! — диде шома итеп алдырылган башына гатырша мае сөрткән Фатыйх карт, төсе агарган хаста Гафифәне күрәсе урынга, ике бит уртасы кызыл алма кебек янып торган чибәр карчыкны күргәч. Аннары акыллы көрән күзләрен Галимәгә төбәде: — Әниең сау-сәламәт икән ич синең, кызый! Алай булгач, авырый, дип, ник мине күрәләтә алдап маташасың? Син минем белән тиятыр уйнама! Мин тиятыр уйнап йөрерлек яшьтән узып киттем инде! Сезгә, яшьләргә кирәк тиятыр... Сез уйнагыз...

Галимә, алдавы барып чыкмаганга оялып, күзләрен, кая яшерергә белмичә, анда-монда йөрткәләде дә, бер зур гына бүрәнә ярыгын күреп, шунда текәлде. Бигрәк тә ачы бу Фатыйх картның теле, шуңа эләкмәс өчен әллә ни бирерсең, валлаһи. Әллә кайдан гына колакка чалынмаган сүзләрне табып алыр да, секунды белән такмагын да чыгарып өлгерер. Аннан килеп картның тагын бер ягы бар, олыгаеп баруына карамастан, ир уртасы сыман бик таза, тере, хәрәкәтчән. Гомер буе балта остасы булып эшләп, бөтен тирә-як кешеләрен яңа өйләр салып кинәндергән олпат кеше ул. Үзенең өе генә дә ни тора? Кыландырмаган җире калмаган. Әллә нинди бизәкләр, сырлар дисеңме — бер дә галәмәт. Ләкин картның гаилә тормышында гына бәхете булмады. Заманында Гафифәне сөеп тә кавыша алмый калган. Күп еллар үткәч, артык чибәр булмаган бер кызга өйләнеп, кешечә тормыш корып яши башлыйм дигәндә, анысы да дөнья куйган. Шуннан бирле Фатыйх башкаларга күз атмый, һаман да әле кара күзле Гафифәгә өметләнеп яши иде. Башта-

рак яшерен хисләрен ул яшьлек мәхәббәтенең иясенә турыдан әйтеп сиздермәде. Ә менә узган ел инде, ире вафат булгач, йөрәген ачарга тиеш тапты. «Гафифә, әйдә өйләнешик!» — диде. Ике авыл арасы иде. Янәшәдә генә матур булып күтәрелеп киткән чыршы посадкасы, арырак ямь-яшел кыр, көн дә кояшлы иде, күктә берөзлексез кошлар сайрый. Шушы гүзәллек эчендә әйтелгән «татлы» сүзләрдән Гафифә түтинең йөрәге кыз чактагы кебек сикереп-сикереп типте. Фатыйх зарыгып җавап көтә иде. Ни дип әйтергә соң? Картның бала-чагасы булмады. Гафифәнең исә берәү генә булса да кызы бар. Кызыннан узып ризалык бирсә, яхшы булырмы? Уйлады-уйлады да, төпле карарга килмичә:

— Фатыйх, бераз сабыр итик инде, яме,— диде.

Шулай өзелмичә генә аерылыштылар. Өметләре мулдан иде югыйсә. Ләкин Галимә бу эшне бер дә хупламады. Дөрес, аны да аңларга мөмкин: бала бит, йөрәк парәсе! Тик Фатыйх та җиде ят түгел бит Гафифә өчен! Карчык менә шулай ике ут арасында торып калды: «Нишләргә?» Әлбәттә, бу очракта, алга-артка карамыйча, тәвәккәлләргә кирәк иде. Ләкин... Менә шул ләкин дигән билгесезлек шомландыра иде инде Гафифә түтинең йөрәген, һай, шомландыра иде, каһәр!

Ә Галимәне, киресенчә, «бәлки» дигән өмет иңнәренә канат куйгандай итә иде. Яшь шул әле ул. Аның якты киләчәге, табылачак бәхете алда!

Ә Фатыйх карт һәрьяктан ялгыз...

Гафифә түти, менә шуларны уйлап, эчтән ялкынга әверелеп бара иде. Фатыйх карт көтмәгәндә генә кулын маңгаена тидергәч, түзмәде:

— Юк, авырмыйм ла мин, Фатыйх! — дип торып ук утырды.

Карт «Менә күрдеңме?» дигәндәй, чәнечкеле күз карашын Галимәгә төбәп көлемсерәде.

Галимә, бөерләренә таянып, ачулы тавыш белән:

— Фатыйх абзый, синең белән булышып торырга минем вакытым юк, ни йомыш белән йөрүеңне әйт тә, давай сызу җаен кара,— диде.

Көтелмәгән бу һөҗүмнән аптыраган Гафифә түти дә башындагы чалмасын каерып читкә атты.

— Әкрен, кызым, олыларга мондый сүз әйтмә, язык булыр.

— Хи,— дип ясалма көлеп куйды Галимә.— Олылар, имеш. Язык, имеш. Алайга китсә, языгы да казык башында аның, менә шул.

Фатыйх карт Галимә алдына печән кибәнедәй торып басты.

— Син... авызыңны чамалап ач, сеңлем?!

Фатыйх карт, бермәл исен җыя алмый торгач, кулындагы эшләпәсен әвәләүдән туктап башына киде. Юк, тиз генә борылып китәргә түгел, озаклап сөйләшеп утырырга, Гафифә түтине алып китәргә дип килгән иде ул бүген. Нишлисең инде, эш шулайга киткәч, булмады бу. Фатыйх карт тәртәсен кайту ягына борырга җыенды. Гафифә түти, бу олпат ирне озатырга чыгып, озак кына тышта торып кергәч:

— Урман тарафында болытлар кабара, бик каты яңгыр явар, ахры,— диде.

***

Бу вакыйгадан соң берничә көн үтте.

Галимәнең бүген ял көне иде. Ул өй тирәсендә генә кайнашты. Бакчага чыгып, керләр юды. Бүләккә бирелгән «Океан» приемнигын шомырт ботагына элеп, концерт тыңлады. Аннары бакча артлап кына элекке тегермән буасына кер чайкарга төшеп китте.

Гафифә түти дә, вак-төяк эшләрен төгәлләгәч, мунча ягып җибәрде. Суга хәзер еракка барасы түгел, колонка капка төбендә генә, теләгән чаклы китер. Галимәсе буадан менгәнче, кыз чагындагы кебек җилләнеп-җилләнеп су ташып йөрде. Бар булган савытларны су белән тутыргач, чормага менеп, бер бәйләм бик шәп каен себеркесе дә алып төште. Аннары, җиң сызганып, бакча чүбе утарга чыкты.

Чип-чиста күк йөзендә, дөньяны нурга төреп, кояш елмая иде. Гафифә түти кояшта янып каралган беләкләренә, кызыксынып, карашын төбәде. Яшь чагында аның беләкләре иң элек кызара торганнар иде бит. Әле дә хәтерендә: шулай көнозын колхоз эшендә булып, кояшта янып кып-кызыл төскә кергән беләкләреннән Фатыйх аны үзенә таба тартып китерде дә серле пышылдап:

— Гафу ит,— диде.

— Нигә гафу итәргә?

— Мин сине яратам, үбеп алсам, ачуланма.

Дөрес, бу вакытта кояш урынында күктә ай балкый иде. Шушындый ук бакча эчендә сандугач сайрый иде.

Гафифә «ә» диярге дә өлгермәде, Фатыйх шундый итеп кысып кочаклады, кыз югалып калды. Аннары Фатыйх, өйләнешик, диде бугай. Ләкин өлгерә алмый калдылар шул, вәгъдәләр буш өмет булып җиргә коелдылар. Егет армиягә китте. Сугыш. Җәһәннәм эченнән үлем хәбәре килү, фронттан яраланып кайткан Хәбибнең арага керүе... Фатыйх кырык җиденең

язында, орден-медальләр тагып, авылны шаккатырып кайтып төште. Партизанлыкта йөреп чыныккан, кырысланган. Ә үзе һаман да шулай җор телле, көр күңелле, булып калган. Авыз читендәге яра эзе күренмәслек итеп, сыздырып кына мыек та үстергән иде. Гафифәнең ул вакытны инде бишектә елап яту-
чы Галимәсе бар иде. Кичләрен, иңенә тальян гармунын асып, өй янынннан гына үзәк өзгеч моң белән Фатыйхның җырлап узуларын онытырлыкмы соң?!

**Туктале, җил, исмәле, җил,**
**Өзмә гөлнең чәчәген лә.**
**Алга килми белеп булмый**
**Башның ни күрәчәген!..**

Гармун тавышы авыл очына китеп югалгач та, Гафифә мендәренә капланып балавыз сыга иде. Ләкин ни кыласың. Елап кына яшьлекне кире кайтарып булса икән ул. Яшьлек үтсә дә, мәхәббәтнең чәчәкләре коелып бетмәгән икән әле. Дүрт елдан соң тагын очраштылар алар — болында. Ярасыннан авырып, Хәбибнең урынга егылган чагы. Ә монда өмә, халык мәш килә... аркалардан тозлы тир ага. Гафифә, халыктан калмыйм дип, үз өлешен очлап килгәндә генә, чалгысының сабы сынды, утыр да ела! Шулчак халык диңгезе эченнән Фатыйх килеп чыкмасынмы?! Изүләрен ачып җибәргән, йонлач күкрәкләре кояшта янып, кызарып чыккан, сумаладай җете кара чәчләре, тирдән юешләнгәнгә, тагын да караеп күренә. Ә күзләре! Чын мәгънәсендә сөю уты белән тулы иде ул күзләр. Менә егет сабы сынган чалгыны кулына алып карады да шундук урман ягына таба китеп барды. Бераздан өр-яңа саплык тотып әйләнеп килде һәм чалгыны, күз ачып йомганчы дигәндәй, көйләп тә куйды. Ай-һай, алтын иде дә соң куллары.

«Кузгалдык»,— диде Фатыйх һәм чалгысы белән билдән узган печән дәрьясына юл салып кереп китте. Ни дияргә дә белмәде, караса, Фатыйх инде әллә кая җиткән, Күздән югалып бара...

Еллар үтә торды, ил дә сугыштан алган җәрәхәтеннән арынды. Ул да картайды, әмма күңеленнән Фатыйх атлы егетне барыбер чыгарып булмады.

Гафифә түти, уйларыннан бүленеп, артына әйләнеп карады. Гаҗәп хәл, чүп белән бергә суганнарны да йолкып барган бит. Галимә күрсә, ни дип акланырсың, тиз генә урыннарына утыртырга кирәк булыр. Ләкин Галимә күрде, тик бу хәлгә исе дә китмәде. Ул анасы алдына килеп тезләнде дә, күзләреннән шаян очкыннар чәчеп, битеннән үбеп алды;

Чү, ни булган моңа? Кызының бу кыланышыннан башы әйләнеп киткән түти тагын бер суганны йолкып чыгарды.

— Әни, әни,— диде Галимә көмештәй тавыш белән.— Бер сүз әйтер идем, тыңлыйсыңмы мине?

— Йә, әйт соң,— диде түти, аптыраудан гаҗиз калып.

— Гыйшкым кайткан, менә шул,— диде Галимә сөенеп.

— Әстәгъфирулла, ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы?

— Бүлдермә, әни,— диде Галимә, чәч толымнарын аркасына ташлап.— Аңламасам әйтеп тораммы соң, кайткан инде менә, су буенда очраштык.

— Очрашсаң ни?

— Кем икәнен беләсеңме аның?

— Белмәскә. Илгизәрдер инде, бала чактан ук дус идегез ич.

— Шул инде, шул.— Тагын ни әйтим икән дип уйланып торгач, йолкынган суганнарны күреп, көлеп җибәрде Галимә.

— Боларга әйбәт. Йолкынсалар да, янә күмгәч тиз тернәкләнәләр, һич тә җир үзләрен әбиҗәйт итми.

— Ә сине?

— Кимсетте, бәхетсез хатын итте.

— Үкенәсеңмени? Терсәгең еракмыни хәзер? Үкенмә, җир гаепле түгел. Ике елыңны җәлләп, Илгизәрне көтми Фәрзетдингә кияүгә ашкынып, үзең харап булдың.

— Әйе,— диде Галимә.— Көтмәдем шул, яшьлек-юләрлек, дип белми әйтмиләр икән, үз башыңа төшкәч кенә беләсең дә, соңлап кына аңлыйсың икән аны, әни.

— Бу сүзне элек тә әйттем түгелме? Үкенерсең, кызым, уйлап эш йөрт, димәдемме?

— Дидең, әни. Ну, андый ялгышуларны гына тормышның гафу итә торган гадәте дә бар бит!

Гафифә түти кызы янына якынрак килеп утырды.

— Хикмәте дә шунда аның, балам. Тормыш ялгышуны гафу да итсен, ди. Ә мәхәббәт соң, мәхәббәт гафу итәрме?

— Илгизәрем гафу итәр шикелле, әни... аның өмете һаман булса әле миндәдер,— диде Галимә.— Су буена килеп, кер чайкавымны күзләп торып, кайтканда каршыма чыкты.

Гафифә түти кызының уң ягына күчте, күзләренә төбәлеп карады. Ләкин Галимә әнисен күрми иде, аның хыял белән тулы күзләре әллә кая, еракка төбәлгән иде.

— Ялгышмыйсың микән, балам? Су буена төшеп, синең каршыңа килүе юл уңаеннан гынадыр, бәлки.

— Алай була алмый ул, әни, чөнки бакчага тикле әле керләремне дә күтәреп килде Илгизәр,— дип, әнисен иңнәреннән

—

кочып алды Галимә.— Илгизәр бит ерактан мине сагынып кайткан, менә хикмәт кайда ул, әни.

Гафифә түти, шатлыгын кызына бик үк сиздермәскә теләп, мунчаны карап киләсе бар әле, дип, урыныннан купты. Галимә дә, җилләнеп, керләрен эләргә китеп барды.

***

Фатыйх карт бу көнне бик күңелсез иде. Ямьсез уйлардан кая качарга белми ишекле-түрле йөренә торгач, янә конюхка килеп егылды.

— Аңла хәлемне, бер атыңны төнгә болынга җибәрми тор, бик кирәк,— диде.

Ат караучы да хәйләкәр:

— Теге атнада да бир ат, бу атнада да бир ат, бушка гына булмый,— дип мыек астыннан көлде.

Нишлисең, теләсә-теләмәсә дә, «Бер бәхилләтермен әле» дип җавап бирде карт.

Инде менә ул кичне көтүдән зар-интизар булып, үзе белән яшьтәш диярлек балтасын кайрап утыра.

Сәгать өч. Фатыйх карт моны кояштан чамалап шулай ди. Ул әнә Кашан урманы өстенә төшкәч, сәгать сигез була, шул вакыт кузгалсаң да ярый. Фатыйх карт, балта кайрап аргач, җилкәсен кашып уйланып торды да бакчага чыкты. Читәннең икенче ягында күршесе хатыны белән ниндидер эш майтарып йөри иде. Ун бала үстереп, бер-берсенә «Их син» дип тә әйтешмәгән бу ике адәмне күрсәң, күзеңә яшьләр килер, шундый да гомер кичерәләр, берсе сандугач, берсе карлыгач, дисәң дә аз булыр. Фатыйх карт, үз бәхете булмауга пошынып, күршеләренекенә кызыгып яшәүдән туйган иде. Бүген дә күршеләрен бергә күреп, йөрәге януына чыдый алмады, өенә дә кереп тормыйча, конюх янына китте. Күңелендә һаман Гафифә иде. Гафифәнең дә кызарып пешкән җиләктәй өлгергән чагы, башында алсу җирлеккә зәңгәр чәчәк төшерелгән атлас яулык, яшел крепдешин күлмәк аңа бигрәк тә килешә, гәүдәсенә ятып тора иде. Беренче мәртәбә ул аны менә шушы килеш аулак өйдә күрде. Ниләр булды монда, нинди уеннар уйналды — барысын да хәтерләми, шулай да бу кунак кыз ул кичне Фатыйх бәхетенә эләкте. Фатыйх кулында җиз телле тальянка булып, кызның да тәңкә чыңына тартым тавышы гармун моңына кушылгач, искиткеч тамаша туды.

Ул көнне таңны алар чишмә буенда утырып аттырдылар...

***

Кичкырын Гафифә түти, мунчага кереп, хәлдән тайганчы чабынып чыккач, үзен бик яхшы хис итте. Галимәнең дә башы күкнең җиденче катында иде. Ана белән кыз, бер-берсенең хәлен аңламыйча, яңа күлмәкләр киеп көзге алдына бастылар да, берсен-берсе этә-төртә: «Әни, дим, мишәйт итмә», «Кызым, менә бу җирен генә төзәтәм»,— дип чак талашмадылар.

Гафифә түтинең кершән, иннек дигән нәрсәне яшь чагында да җене сөйми иде. Галимә исә, шулар белән мавыкканлыктан, әнисен бер читкә кысрыклап, көзгенең тулы хуҗасына әверелде.

— Әй, кадалсана,— диде түти, кызына ачуы килеп,— егетләр куенына керергә җыенсам икән.

Ләкин бер караганда ул әнә шушы нәрсәдән һич кенә дә баш тартмас иде бу минутта... Туктале, битнең бу төшенә аз гына сөртсәң, җыерчыклары күренмәс иде. Шуны искәргән Гафифә түти кремны кызыннан яшереп сөртергә карар итте. Кызында аларның ниндие генә юк иде. «Әнә теге тартмада бугай»,— дип, Гафифә түти кечерәк бер савытны кулга төшергәч, арт өйгә чыкты, савытны ачты да, бармагын кремга манып, сөртенәм дип торганда гына, ал өйдән елак аваз ишетелде:

— Минем арабский кремымны кем алган инде тагын?

Гафифә түти, оятыннан кызарып, сер бирмәскә тырышып, әйтте:

— И-и-и кызым, син аны бу якта калдыргансың, менә ул.

— Бәй, каян чыккан ул анда?

— Белмим,белмим.

Бераз юангач, Гафифә түти арткы өйдән генә Галимәгә кычкырды:

— Ярый, кызым, мин Мәчтүрә түтәңнәргә киттем,— диде.

— Озаккамы?

— Бәлки, кунып та калырмын әле. Борчылып торма.

Шул китүдән икенче көнне кич белән дә кайтмады ул, суга баткандай юкка чыкты. Галимә пошаманга төшеп, Мәчтүрә түтәйләренә барса, әнисе бөтенләй үк монда килмәгән икән.

Инде кайдан эзләргә?!

Күктә инде йолдызлар да калыккан. Галимәгә бигрәк ямансу иде, ул менә чокырлы-чакырлы юлдан абына-сөртенә өенә кайтып бара. Кинәт караңгы тыкрыктан бер шәүлә калкып, кыз каршысына килеп басты да: «Чү, Галимә каян килә?» — диде. Башка вакыт булса, Галимә әллә ниләр эшләр иде. Бу юлы нәрсә әйтергә дә белмичә каушап калды. Алай да хәлне Илгизәргә аңлатып бирде. Илгизәр, бер ым белән генә «киттек» дигәнне сиздереп, Галимәне үзләренә алып китте. Капка төп

ләренә җиткәч, Галимәне тышта калдырып, мотоциклын сөйрәп чыкты да аны кабызды. Кузгалдылар. Бераз китүгә, мотоцикл күрше авыл юлына борылды. Күз ачып йомганчы килеп тә җиттеләр. Артларыннан тузаң да басылырга өлгермәде, Фатыйх картның бакчасына үтеп, тәрәзәдән эчкә күз салдылар. Гафифә түти тәрәзә алдындагы гөл чәчәкләренә сырынып кына, боларга таба аркасы белән борылган көе, Фатыйх карт исә аңа каршы утырып чәй эчә иделәр. Илгизәр бик озак итеп карап торгач, күзләрен, тәрәзәдән алып, Галимәгә төбәде. Кызның керфек очларыннан җем-җем килеп яшь бөртекләре тәгәрәшә иде. Илгизәр сакланып кына аның чәченә орынды.

— Кайгырма, кирәкми! Без дә...— дип, әллә ниләр сөйләде...

Әле генә бик шыксыз булып тоелган дөнья Галимә өчен бик күңелле, вак-вак йолдызлар белән чуарланган галәм күге яктырып, биегәеп киткәндәй тоелды.

## *Китап хикмәтләре*

Минем туганнан туган бер апам бар. Мөршидә исемле ул. Кечерәк чакта аның китаплар укырга һәвәс булуын беләидем инде. Соңрак, кияүгә чыгып, башка урамга күчеп киткәч, ул, бүтән киленнәр шикелле үк, клубка күңел ачарга йөрүләрен ташлады, һәм шуннан соң мин аны китапханәдә очратмый башладым. Мөршидә апам тормыш коргач, муеннан эшкә чумган, аның китаплар укырга вакыты да калмаган, дип әйтергә җыенмыйм. Чөнки, үземнән беләм, китап укуның тәмен бер татып баккан кешенең хәле — ипи ашамыйча тора алмаган кешенеке сыман инде ул! Хәер, ипине аны сарык та, кәҗә дә ашый, ә менә китап уку теләсә кем кулыннан килерлек эш түгел ул. Бу урында мин «яхшы һәм мәгънәле эш» дип әйтер идем. Чөнки әнә аракы эчү дә кемнәрдер өчен эш булып санала ич: әшәке һәм кабахәт эш! Әйе, әйе... аракы эчеп кем рәхәт күргән әле бу җирдә? Ә менә... күп-күп китап укыганнарның аракы эчеп йөрергә бер дә вакытлары юк, чөнки аларның тагын да күбрәк китап укыйсылары бар бит. Һәм шуннан соң аларга карап башкалар да китап укырга керешмәс дип кем әйтә алыр? Әнә миңа җизни тиешле кеше элек китапханәнең янына да килеп карамый иде, ә минем туганнан туган апама өйләнгәч исә, кызыклы китапның тәмен татыгач, үзен китапханәдән куып та чыгарып булмый башлады. Киштәдән «Ат җигүнең серләре» дигән китапны алып, китапханәче туташ каршына урнаша да утыра кыты-кыты көлеп. Чөнки фермада ат җи-

геп төрле-төрле эшләр башкарып йөргәч, аңа бу китапны уку кызык һәм рәхәт, күрәсең. Мәгәр укучыга шул да мәгълүм булсын, бу китапта да сүз дүрт аяклы атны түгел, ә ике аяклы ир дигән атны ничек итеп җигәргә өйрәтү турында бара иде. Шуннан соң җизни кеше, киштәдә кабат-кабат актарына торгач,

«Каенана вазифалары» белән «Килен-киленчәк» китапларын тотып, туташ каршына килә:

— Боларны да язып куй инде, өйгә алып кайтам,— ди.

Китапханәче кыз, билгеле инде, серле генә елмаеп:

— Менә бу «ЧТЗ тракторлары» нәрсәгә инде сиңа, ат җигеп эшләгән кешегә? — ди.

Мәгәр бу юлы җизнинең җавабы үзе сыман озын булып чыкты:

— Башын эшләткән кемсәгә тимер-томыр турындагы китап та укырга кызык икән ул, туташ,— ди.— Мәсәлән, менә бу китапта бер тракторның егәре җитмеш ат көченә тиң, имеш. Ә мин болай уйлыйм: әгәр дә җитмеш ат белән кырда җир сөрергә туры килсә, ул җитмеш атка йөз кырык кеше хезмәт күрсәтер иде. Ә аннары шул җитмеш атны һәм йөз кырык кешене бер көн туйдыру өчен өч йөз илле чиләк су һәм җитмеш капчык солы кирәк булыр иде һәм, билгеле ки, эшләгән эшләре бер тракторга тормас иде. Һәм шул ук вакытта, шул ук эшләрне башкарып чыгар өчен, тракторга бары тик егерме чиләк ягулык белән ике чиләк автул гына кирәк булачак икән,— ди.

Китапханәче туташ, сабыр гына тыңлап торгач, көлемсерәп:

— Ә менә «Ясалма хатын» нәрсәгә инде сиңа? — диде.

Җизни тиешле кеше исә, ялт-йолт итеп кенә як-ягына каранып куйгач:

— Ясалма хатын үтә тыйнак бит ул, ашамый да, эчми дә, затлы кием дә сорамый, бай буласым килә, дип тә йөдәтми,— диде.

Һәм шуннан соң, җизни кеше китапларын култык астына кыстырып чыгып киткәч, китапханәдәге кешеләр, чыш-пыш килеп:

— Ай-һай, бу Мөршидә инде Миңлекәлимулланы да үз кубызына биетә башлаган лабаса! — диештеләр.

Әйе, минем туганнан туган апамның яманатын элек безнең урам хатыннары гына сата иде, ә хәзер әнә югары очтагы хатын-кызлар да яманлый икән аны. «Ай-яй, бу Мөршидә усалның да усалы, эзбирнең дә эзбире икән!» — диләр алар.

Белмим инде, ул хатын-кызларга апамның кай төше ошамыйдыр. Буй дисәң буй, чибәрлек дисәң чибәрлек, татлы тел дисәң, татлы тел — барысы да бар бит анда!..

Мин бәләкәй чакта, юлына очраган мәлләрдә, Мөршидә апам:

— И-и ма-тур-р да инде син, Хөршид, нәкъ күрше авылдагы Бикмуллага охшагансың! — дип, аркамнан сөя торган иде. Аннары исә, үсә төшкәч: — Ай Хөршид, наным, бигрәкләр дә шә бәйгәнсең инде син шигырьләр яза башлагач! — дип, башымнан сыйпап куя иде.

Аннары мин укуымны күрше райондагы авыл мәктәпләренең берсендә дәвам иттем, һәм, әлбәттә, шигырьләр язуымны да ташламадым. һәм аларның кайберләре район гәзитендә басылып та чыккалады. Шуннан мин үсеп җитеп, унберне тәамлагач, университетка барып кердем. Әмма миннән барыбер шагыйрь чыкмады. Бүгенге көндә гади бер укытучы гына мин. Ә укытучы халкын беләсездер инде, китапсыз — ике кул**сыз** алар. Чөнки яшь буынга белем, тәрбия күбрәк китаплар аша бирелә бит. Әйе, тәрбия дигәннән, шул үтә авыр, әмма төшемле темага мин дә юка гына бер китап язып бастырдым әле. Китабым кибетләргә чыккач, таныш-белешләр генә түгел, гомердә күрмәгән-белмәгән кешеләр дә үземә сәлам биреп үтә башлады, һәм бераз вакыт үткәч, Мөршидә ападан да саллы гына хат алдым. «Хөршид, акыллым, китабыңны, район кибетеннән алып кайтып, авылыбыздагы бөтен кешеләргә күрсәтеп йөрдем. Шуннан соң нәчәлстуа безгә бик җылы карый башлады. Эш проблемасы бетте. Икмәк, печән, утын — бүле. Болай булса, Алла кушып, быел кышка һич курыкмыйча бер сыер, бер тана, бер ат, бер тай, биш сарык, дүрт каз белән кермәкче булабыз»,— дигән. Ә инде икенче елны тагын, юка гына бер китабым басылып чыккач, Мөршидә апамнан күптин-күп, чуктин-чук кайнар сәламнәр, җып-җылы хисләр белән тулы рәхмәт хаты алдым. «Ну, энем, шигырьләрне әйбәт язасың да инде, маладис. Икенче китабың белән тирә-юнь авылларны да шаккатырдың лабаса. Хәзер инде район нәчәлстуалары да безгә җылы карый башлады. Менә әле шушы араларда гына яңа йортка кердек. Быел, Алла боерса, кышны өч сыер, ике тана, ике ат, унбиш сарык, егерме каз белән үткәрмәкче булабыз»,— дигән. һәм тагын бер ел үтеп, өченче китабым дөнья күргәч, иһаять, Мөршидә апам мине кунакка чакырды. Баксаң, Миңлекәлимулла җизнигә илле яшь тулу уңаеннан, каенесенең атаклы шагыйрь булуыннан киләчәктә файда арты файда алыр- га тырышып, машина бүләк иткәннәр икән!

Ярый, бөтен ярым кара ипи белән ике ак калач күтәреп кайтып төштем мин боларга. Күрәм: җизни симерткән күркә-

не дә уздырып җибәргән, ишеккә чак-чак сыя. Ә Мөршидә апа исә — богыл, һәм болар мине шундук бай җиһазлы кунак бүлмәсенә алып керделәр дә бер бик затлы шкафка таба этеп җибәрделәр. Әнә синең исем-шәрифләрең алтын су йөгертеп язылган өч китабың да, тузан да кунмаган килеш саклана, янәсе.

Мин сагаеп кына шкафка якынлаштым. Күрәм, уртадагы шүрлектә олы бәллүр савытка сөяп куелган, теге...

Минем кинәт башым әйләнеп китте. Чөнки бу китаплар гасыр башында Уфада вафат булган шагыйрь Хөршид Хәлим нең өч томлы сайланма әсәрләре иде.

## Яшәү мәгънәсе

Иртә. Хөснетдин абзый тегермәнгә төшеп бара. Исәбе он тарттырып алу һәм бер тәкәне сугымга симертү... Малайлары, «Озакламый ялга чыгам, хатын һәм балалар белән кайтам», дип язган бит.

Асфальт юлдан күпергә керүгә, абзый яшелчә бакчасы ягына карап куйды. Йөрәге түзмәде, сугылып узарга булды. Гаҗәп. Бакчада адәм заты юк, ә менә яшелчә түтәлләре арасында дүрт сарык белән бер бозау бар иде. Шуларны ут уйнатып куа-куа алма бакчасына да килеп чыкты абзый. И-и, бусы моның тәмам ташландыкка әйләнгән ич! Киртә-мазары кая киткән дә, чүп үләннәре каян килеп үскән диген син?.. Хөснетдин карт тирләп пешкән иде, җиргә чүкте, хыялга бирелде.

Әй бар иде соң заманнар! Хөснетдин, булсын дип, көнне төнгә ялгап эшләгәндә, кайларга гына китеп таралмады бу җимеш бакчасының даны. Ул май урталарында шау чәчәккә күмелгән агачлардан нинди генә хуш исләр аңкып тормый иде дә, җәй азакларында өлгергән берсенНән-берсе татлы җимешләрне күреп, кемнәрнең генә авыз сулары корымагандыр...

Кызыгып сораучыларга берни дә җәлләми иде уңган бакчачы, ә менә урлап ашау нияте белән йөрүчеләрне...

Нәби дигән нәни каракның этлекләре әле дә хәтерендә. Ике мәртәбә тоз белән атып үрле-кырлы сикерткәч тә тынәмәде шул. Аптырагач, Хөснетдин малайны үз янына эшкә дәшеп төзәтмәкче итте һәм ялгышмады. Хәзер Нәбиулла бер совхозда галим-бакчачы: эредән-эре, татлыдан-татлы җиләк-җимеш бирә торган агачлар үстерү белән мәшгуль. Ялларга кайтканда, әлбәттә, Хөснетдин остазын күрмичә, күчтәнәч-фәләннәрен бирмичә китми.

Ә менә Сәйфинең малай чакта ук ни ите, ни йоны иде. «Мә, наный, ашап кара!» — дип чакыргач та, алманы яки грушаны килеп алмый иде. Хурлана, янәсе. Җаны теләгән җиләк-җимешне ул төнлә урлап, агачларны да сындырып ашый иде, кем әйткәндәй, яхшыдан яман булып туган нәрсә! Үсеп, бакчачылыкка укып, Хөснетдин урынына калгач та, әнә... ул ниләр майтарган?..

Тегермәнче Вафа яшелчә бакчасында хайваннар куып йөрүче Хөснетдин картны шәйләп калган иде. Шулай да елмаерга тырышып каршылады ул аны:

— Картаеп буламы соң?

— Картаерсың да...— диде Хөснетдин бабай тегермәнченең соравына каршы җитди генә итеп. һәм бакча тарафына күрсәтте.

Вафа, он кунган кашларын хәтәр җыерып:

— Син үзеңә кабер эзләп килдеңме әллә монда? — диде. Вафа әйләнеп караса, карттан җилләр искән иде.

***

Председатель китәргә җыенган иде. Хөснетдин бабайның гозер-ниятенә тиз төшенде һәм шундук бакчачы Сәйфигә йомышчы йөгертте. Усал хатын озак тормады. Баксаң, Сәйфи Бурсык җәйләвендә көн-төн кунып, үзенә печән-фәлән хәстәрләп ятмыш икән...

— Менә нәрсә, абзый,— диде председатель.— Минем әле бу колхозда беренче елым гына. Шулай да синең турыда матур-матур сүзләр ишетеп өлгердем инде. Әллә, дим, бакчаны янә үз кулыңа алып җибәрәсеңме?!

— Мин риза! — дип әйткәнен тоймый да калды карт.

***

Кайтып җиткәндә, антенна баганасына бәйләп куйган атны «Кемнеке икән бу?» дип уйлап бетермәде, капкадан яхшы гына кызган Вафа килеп чыкты. Сәйфинең «бабасы».

— Онга төшкәнсең икән... әнә алып мендем...— диде ул.

— Кәнсәләрдән язуың-фәләнең бармы соң?

— Язу-у?! Мин үзем колхоз лабаса... һе-һе-һе...

## *Гөлсәрия*

Әбәт вакыты... Газзә алты яшьлек малае белән табын янында утыра. Кайсына гына карама, өйнең кайсы төшенә генә күз салма — ярлылык! Нихәл итәсең — сугыш гаепле!

Кинәт ишек ачылып китте. Бер кулын фронтта калдырып кайтуына карамастан, зәңгәр френч һәм галифе чалбар кигән

Агапов, аңа ияреп бер кыз керде. Газзә каушый калды, аяклары калтырау алды. Гаепсездән гаепле итүләр заманы бит, Алла сакласын! Һәм шул мизгелдә яшь хатынның уен укыгандай авыл советы рәисе, кызга ишарәләп:

— Менә сиңа алып килдем әле бу кызны, Газзә килен! — диде.

— Гөлсәрия атлы булам мин,— диде кыз, ак тешләрен балкытып.— Фельдшер-акушер...

Агаповның эшләрен тавык та чүпләп бетермәле түгел! Ул чыгып китүгә, яшь хатын белән врач кыз, кала күчтәнәчләреннән авыз итеп алырга дип, чәй эчәргә утырдылар...

Кич җил капка төбендә Гөлсәрия, елмаеп, Газзәнең эштән кайтканын көтеп тора иде инде.

— Бик шат күренәсең, бәгырем, сөенечле хәбәр бармы әллә? — диде Газзә, килеп җиткәч.

Гөлсәриянең янып торган шомырт кара күзләрендәге шаян очкыннар гүя җемелди-җемелди серләшүче бихисап йолдызларга әверелделәр.

— Сезнең авылда үсмер егетләр бик тә кызык икән... Медпунктны ачып керүгә, өерләре белән кереп тулдылар да, кайсы эч авырта, кайсы башым сызлый, дип зарланыша башладылар. Ә бер жирафы, укол яса, дип, койкага ук сузылып ятты хәтта!

Шуннан мин моңа: «Авырмаган кешегә энә кадарга ярамый!» — дим. Юк... аның һаман үз җитмеше җитмеш... Кадарга туры килде.

Гел дә ябышкак инде... Башкалары киткәч тә куып булмады үзен. Сезнең белән чын-чынлап танышырга телим, ди...

***

Ниһаять, көз урталарында Әмирханга да повестка китерделәр. Шул кичне егет, тәвәккәл, төгәл бер карарга килеп, Газзәләргә юл тотты.

Бу кичне Гөлсәрия дә йокыга китә алмыйча ятты. Чү! Әнә тәрәзәдә кемдер бар кебек?!

— Хәзер...

Озакламый өй эченә яңгыр шавы һәм салкын ияртеп кергән «Таһир» «Зөһрә»сенең җиңел, җылы гәүдәсен киң күкрәгенә кысты...

Газзә уянды, мәгәр түзә алмады, килеп, кызның җилкәсенә орынды:

— Нишләдең?

Кыз мышык-мышык елый иде.

— Ни сөйлисең, Гөлсәрия, тилердеңме әллә?!

— Ул бит китә иртәгә, мәңгелеккә...

... Әйе, Гөлсәриянең «Китә бит иртәгә, мәңгелеккә...» дип иңрәве тикмәгә булмаган икән. Алты ай үтүгә, Әмирханның авылга үлү хәбәре килде. Ә тагын бер айдан Гөлсәрия фронтка үзе теләп китте. Ләкин... исән-аман әйләнеп кайтырга насыйп булмады аңа.

Кызның хәрби киемнән төшкән фотосурәте әле һаман саклана Газзә әбиләрнең гаилә альбомында. Ә Газзә әби исә, һәр кич диярлек, ястү намазын укыгач, Гөлсәриянең якты рухына багышлап дога кыла. һәм карчык, елга бер мәртәбә калага барып, Гөлсәрия туып үскән өй нигезен христиан зираты эченнән күреп кайта!

## *Марфа әби*

Карчык бер бүлмәле фатирда ялгызы гына яшәп ята. Карты үлгәч, күзләре дә начар күрә башлады, аяклары да юньләп йөрми, кыскасы, биреште карчык! Шулай да элекке гадәте буенча, авырсынып кына булса да, подъезд төбенә чыгып баса үзе; үтеп-сүтеп йөрүчеләрне мавыгып күзәтә, таныш-белешләренең сәламнәрен ала, балаларның да хәл-әхвәлләрен җентекләп сораша, кирәк дип тапса, киңәшләрен дә бирә, чөнки карчык күрше-тирә кешеләрнең ярдәменә бик мохтаҗ иде шул инде! Бит әнә Марфа түти янына, минем белүемчә, кунак-фәләннәрнең дә килгәне юк, һәм ул үзе дә кая да булса кунакка бармый иде бугай! Ник? Ни өчен?

Бу сорауларга мин, һичшиксез, җавап табарга тиеш идем. һәм... таптым да!..

— Ай, рәхмәт инде! — диде Марфа түти чиләктәге сапсары бәрәңгеләрне күргәч, сөенеченнән кояштай балкып...

Кергәләгәнем булса да, дивардагы фотосурәтләрнең күбесен беренче генә шәйләвем әле! Белсәң иде, кемнәр икән алар?

— Минем Васям, күгәрченкәем, сугышта элемтәче булган инде! Шулай бермәлне иртән атышуларның тынып торган чагы икән. һәм Василий, кайнар баш, тәвәккәлләгән дә, радистка чибәр Люсяны култыклап алган. Алар чәчәк букетлары тотып урманнан чыкканда, янә «кигәвеннәр» безелди һәм «күк күкри» башлаган, ди.

— Шул көнне Вася-Василий, бер «сукыр чебен»гә юлыгып, каты гына яраланган, госпитальгә озатылган! Ә аннары — өченче группа гарип булып — Казанга!

— Таныштык. Өйләнештек. Ә ике ел үткәч, Вася мине талый

башлады: «Бала кирәк!» — ди.

Шулай беркөнне хәсрәтләнеп утырганда, өйгә почтальон килеп керде. Кулында... телеграмм! Курка-курка гына күз төшергән идем, бәгырькәем, чалкан авып китә яздым: Люся Шевченко суккан лабаса!

Менә шулай... Вася көтмәгәндә генә малайлы булып куйды, һәм Боря, бераз үсә төшкәч, безгә хат арты хат яудыра башлады. Аннары хатларны Боряның улы Коля язды. Аннары Коляның улы Саша! Хәзер менә, җаныкаем, Вася кара гүргә барып кергәч, миңа беркемнән дә хат килми...

Мин кыенсынып кына, туганнарыгыз бармы соң, дип сорамакчы идем, Марфа әби, ниятемне сизгәндәй, үзе сүз башлады:

— Мин — Ленинградныкы! Бирегә сугыш вакытында эвакуацияләнеп килдем. Юлда әнием бомбежкага эләгеп һәлак булды. Шулай менә туганнарым да кайсы кайда югалып бетте! — Карчык күпне күргән күзендәге сагышлы яшьләрне сөртеп алды.— Ярый әле сез бар! Балаларыгыз да тәрбияле, ярдәм итәргә әзер без! дип кенә торалар...

һәм карчык, бәрәңгеле чиләкнең авырлыгыннан бөкрәя төшеп, хәзер чәй эчәрбез, дип, кухняга кереп китте.

## Өч баҗай

Әүвәле без өч малай идек. Өчебез дә бик дус идек һәм өчебез дә бер исемле булып, өчебез дә бер урамда яши идек. Хәтта әтиләребезнең исемнәре, кушаматлары да бер үк булганга, безне авылда, шаяртып, игезәкләр дип йөртәләр иде, ягъни Өч Күпер Ибраеның өч Сәләхе без! Шәп яңгырыймы?..

Чү! Туктале, каян килгән күпер булды әле бу? Безнең тирәдә күпер түгел, басмасы да юк ич аның. Басма гынамы әле, чебеш батып үләрлек суы да юк. Шулай булгач, кушаматыбызның асыл мәгънәсен бүтән урыннан эзләргә кирәк.

Мин бабай бакчасыннан сугып чыккан шалканны бик тиз генә балчыгы-ние белән сыпырттым да, текә яр башыннан сусыз елгага төкереп яткан җиремнән торып, өйгә йөгердем. Бәхеткәдер, әби бүлмәсендә иде. Мине күрүгә:

— Вәлибулым бетте...— дип ярып салды. Ә мин:

— Җарар, күпер турында сөйләсәң, алып кайтып бирермен,— дидем.

Әби Коръән укыгандай көйли-көйли сөйләп китте:

— Минем әти солдаттан җәфритер дәрәҗәсенә ирешеп армиядән кайткач, авылдашлары чак-чак кына таныган, ди, үзен. Тора, ди, әти, как генерал, елмаеп. Авызы тулы көмеш теш, ди, күкрәге сплушь медаль, ди. Җитмәсә, үзе татарчасын да оныткан, ди, бахыр. Ул хәтта үз атасы Дөгри картка да «Здрастуй, старик!» дип кенә сәлам биргән, ди.

Ә Дөгри бабай, шуның өчен малаен каргап:

— Ярабби, мәңгелек дөньяда сират күперенә кергәч, егылып телең ачылсыние, имансыз,— дигән.

Чынлап та, озакламыйча әтинең теле күпердән тракторы белән мәтәлеп төшеп барганда ачылган, ди.

Бусы булды. Ә шадра Ибрай, чөеп уйный торган бер тупны тагын да зуррак итәргә теләп, өрә дә өрә, ди, ә үзе «ишу күпер, ишу күпер» дип тупны дәртләндерә, ди. Шулай күперә торгач, туп шартлаган да киткән, ди.

Әһә... икенчесе дә булды. Ә юан Ибрай? Анысы менә молодец булган аның. Бер җимерек күперне астан җилкәсе белән тотып торып, өстеннән өч олау үткәреп җибәргән ул.

Әби хикәятен тәмам итте. Болай булгач, минем әти белән шадра Ибрайның күпере ялган, тик юан Ибрайның күпере генә чын булып чыга бит инде. Һәм шул көннән алып минем белән юан Ибрай малае арасында буй җитмәстәй киртә корылды да куйды. Мин юан Ибрай малаен сөйми башладым, юан Ибрай малае — мине. Һәм без, елның кайсы гына фасылында, кайда гына булмыйк, юк-барга да әрепләшеп китә идек.

Мин аңа һаман Юан бүкән дим. Ә ул миңа Чатан антилопа ди. Антилопасын кайдан алып әйтә торгандыр инде, әрем тел. хәер, антилопасына ачу да килми бугай, тик менә әллә кайчангы бер өмәдә аягына имән бүрәнә төшеп аксап калган әтине чатан!» дип мәсхәрәләттерәмме соң. Юан Ибрайның юан малаена ташланудан чак-чак кына тыелып:

— Әй, син... ит тумраны-ы, — дип акырып җибәрәм. Якалашудан шикләнеп булса кирәк, шундук арага шадра Ибрай Сәләхе килеп керә.

Мин, телләшеп юан Сәләхне җиңә алмау ачысыннан, корбан тапкан карчыгадай, шадра Сәләхкә кунам да:

— Мин бүгеннән башлап Дәүбәк Хәсән малае белән генә Юнаячакмын,— дим.

— Ә без менә Шакал Барый малаен үз компаниябезгә кертәбез,— ди Сәләх, исе китмичә генә.

Мин, Сәләхнең чатан сүзен кыстырмыйча иплəп кенә әйтүенә күңелем тулып, тагын үзләре белән дуслашып китәм.

Менә шулай әкренләп үсеп җиттек без. Борын төбенә дә берән-сәрән генә мыек төкләре шытып чыга башлады. Кызлар янына да бергә йөри башладык.

Кызлар дигәннән... Шамил Зәйтүнәсе булса, берни дә кирәкми миңа. Хәтта ки: «Галәветдиннең сихерле лампасын бирәм, Зәйтүнә сиңа булмасын»,— дисәләр дә. Әйе, бик-бик гашыйк булган идем мин ул чем-кара озын чәчле кызга...

Ә бит Зәйтүнәнең тагын Зәйнәп белән Заһидә исемле чем-кара озын чәчле игезәк сеңелләре бар...

Озакламый Зәйнәпкә — Күпер Ибрай Сәләхе, ә Заһидәгә икенче бер Күпер Ибрай Сәләхенең гашыйк булуы беленде.

Менә шулай...

Бу эшнең азагы ни булып беткәнен чамалыйсыздыр инде, хөрмәтле укучым? Чамаласагыз шул: сау булыгыз!

## *Тәңре хөкеме*

Хөббениса түти «Нива»га кереп утырыр алдыннан күрше Сараттәй:

— Син булганда, бергә-бергә яшәве күңелле иде, син киткәч бик ямансу булып калыр инде миңа,— диде.

— Өем болын чаклы. Ирем әзерләп калдырган утын бетте. Балаларым калада яши. Язлар җиткәч кайтырмын әле,— диде Хөббениса түти һәм ишекне ябып куйды.

Машина, шуны гына көткән сыман, кузгалып китеп барды.

Кыш уртасында карчыкның килене эштән коточкыч хәбәр ишетеп кайтты. Авылдагы йортны талаганнар.

Янә теге ак «Нива»га утырып кайтып төште Хөббениса түти.

Карчыкның кайтуын ишетеп булса кирәк, ишегалдына күрше-күлән кереп тулды һәм шул арада төбәк милиционерын иярткән авыл советы рәисе дә пәйда булды.

Ул:

— Нәрсәләргә тигәннәр, апа, берсен дә калдырма, яр да сал! — диде.

— Нәрсәләргә тигәннәр...— дип кыенсынып кына җавап кайтарды әби.— Шөкер, бар нәрсә дә үз урынында...— һәм карчык түбән оч Габделфәртнең җиде яшьлек малаена, кесәсеннән чыгарып, ике кәнфит тоттырды.

— Актка нәрсә дип языйк соң, апа?!

— Җил селкетеп ишекне ачкан, дип языгыз инде шунда...

Авыл советы рәисе белән төбәк милиционеры чыгып киткәч, күрше-күлән Хөббениса түтине үзләренә чәй эчәргә әйди башлады. Ул Талак Касыймының кыставы тагын, ул түбән оч Габделфәртнең өзми-куймый сайравы дисеңме, бер дә галәмәт инде!

Ләкин карчык, Сара ахирәтенә ияреп, каршыдагы йортка таба китеп барды. Аш ашап, чәйләр эчеп чыккач, түтинең тонык зәңгәр күзләре утын түмәренә чабып куелган балтага төште. Таныш сыман тоелды аңа бу балта. Чынлап та! Бу мәрхүм иренең авыл кешеләренә өйләр салган чакта үзеннән калдырмыйча йөрткән иң шәп, иң үткен балтасы иде. Тагын ике көннән әби Йомран Шәрәфләрендә сәнәк-көрәкләрен, Тигәнәк Хәтимәләрдә чиләк-көянтәләрен, Чебеш Хәйдәрләрнең ишегалдында малае уйнап үскән «Газ» мопедын таныды. Ә инде җәйгә чыккач, ул ире үләренә ике ел калганда сатып алган матайның өч көпчәген дә түбән оч Габделфәртнең матаенда күрде. Күрде, мәгәр Габделфәрткә берни дә сиздермәде. Ә ике атнадан һич көтмәгәндә Габделфәртнең уртанчы малае асылынып үлде. Бик эчә иде. Башын элмәккә тыкканда да дөм исерек булган. Шунысы кызык, Габделфәртнең малае үлеп биш көн үткәч, Хөббениса түти иртән баскыч төбендә матайның өч көпчәге ятуын күрде. Шуннан соң балта да, «Газ» мопеды да, сәнәк-көрәкләр дә, көянтә-чиләкләр дә янә үз урыннарына әйләнеп кайттылар. Йә, шушы хәлләрдән соң Тәңре юк дип әйтеп карагыз инде...

## *Чыпы*

Кәлимулла абый өенә күкерттәй кабынып кайтып керде. Коймак пешереп мәш килгән Мәрфуга апа, иренең куйдырган тешләре генә агарып торуын күреп, егылып китә язды. Баксаң, «җен эшергән» Хәсән тыкрыгы чатында Кәлимулласының каршына Габдрахманның сары тракторы арт ягына нашатырь кыстырган Хуҗа Насретдин ишәге шикелле килеп чыккан да өстенә саз сулары чәчрәтеп узган.

Әйе, Габдрахман булган төштә ЧП булмый калмый инде. Шуңадыр аның кушаматы да Чыпы.

Ирен бу кыяфәттә күргәч, Мәрфуга йөрәге турысына учын куеп торырга мәҗбүр булды. Ярый әле әтисе үлгәндә аңа васыять итеп әйткән «Җырлап яшә син, кызым! Җыр ракны да җиңә ул!» дигән сүзләре исенә төште. Ниһаять, ул, башын го-

рур тотып, көчле тавыш белән җыр сузып җибәрде:

**Мин яшь чакта күкрәгемә**
**Чәчәкләр кадамадым.**
**Чөнки яшьлек үзе чәчәк**
**Кирәк дип санамадым...**

— Чәчәк, имеш. Син, миңа кияүгә чыкканда, әрем себеркесе идең инде, утыз икедә идең,— дип мышный-мышный мыгырданды Кәлимулла.

Ул олы бүксәле имән мичкәнең бөкесен алырга маташа, ләкин бүрткән каен бөке нык урнашкан, һич кенә дә бирешергә теләми иде. Моңа тагын хатыны белән Чыпы гаепле булмыйча, кемнәр гаепле булсын соң! Берсе әнә тегермән идәненнән себереп тутырган нәрсәне «выши сорт, әмма мал-туарга гына ашатырга яраклы» дип китерә, икенчесе аны кызының туена өлгертергә куйган ачы бал белән былкынганчы сыйлый. Шуннан соң мескен хайваннарның ашкайнату системасына һәм Кәлимулла абзагызның эчке дөньясына нинди һәлакәт янаганын шайтан белсен!

Мәрфуга иренең шулай авырткан төшне кычыттырып сөйләшүенә күнегеп беткән инде. Шуңадыр сүзләренең агулы уклары кызлары Фирая тарафына ешрак очарга керешкәч тә картына каршы дәшмәде. Ә бит уйлап баксаң, Кәлимулла вчүтеки маладис. Бүген дә ул калада яшәүче Фирая янына, кызымны шәп кияүгә тиендерәм әле, дип, армиядә бергә хезмәт иткән иптәшенең хатынына чыбык очы туган тиешле кемсәнең бик тә «дәрәҗәле» улын ияртеп барган иде. Егет күркәм кыяфәтле генә түгел, оялчан һәм тыйнак холыклы да булып тоелды аңа. Ул юл буе бер кәлимә сүз әйтмәгән, тәмәке дә тартмаган, хәтта сыра рекламалары ягына да борылып карамаган. Бары тик чишенеп бетә язып йөрүче салам сыйраклар очрый башлагач кына, «А-а, вут иты ничау-а! А вут та ичу лутчы-ы!» дип борсаланырга керешкән. Сынауны уза алмыйча, август башында сакланып калган кура җиләк шикелле сусыл кәләшнең куенына керүдән колак каккан.

...Шул мизгелдә капка ачылганы, аннары кургаш беркетелгән нәзек туфли үкчәләренең өйалды идәнен шакылдатканы ишетелде. Ишектә, диңгез өстендәге куе томанны тараткан кояштай балкып, соңгы берничә атна арасында күзгә күренеп тазарып киткән кызлары Фирая пәйда булды.

— Исәнмесез, батя и мамуля,— диде туташ, юри генә кыланчыкланып.— Суккан телеграммагызны алуга кайттым менә!

— Нинди тилигырам? — Түти, каушавыннан ялгышып, кайнап чыккан чәйнеккә кайнамаган су кушып куйды.

Әти кешенең төпченүле карашы исә кызының юанайган бил турысында, ә уйлары иртәгәләргә йә берсекөннәргә бүселеп чыгарга тиешле үтә дә четерекле мәсьәлә хакында иде.

Мәгәр кызый актыгы, әтисенең кирәгеннән артык нечкә сизенүләренә тиз һәм төгәл җавап биреп:

— Шаярып кына әйттем лә, әти-әни, гафу итегез,— диде. Урынсыз шаяртуыннан уңайсызлык кичергәндәй, түм-түгәрәк бит алмаларына чаклы иннек яккан кебек булып китте, һәм аннары, барча гаебен боларга сылар өчен:

— Сез үзегез ич «Шаярып яшәү ярты бәхет» дип бәләкәйдән үк өйрәттегез мине, — диде дә чыркылдап көлеп җибәрде.

Ниһаять, Кәлимулла түзмәде, гәрчә «калхуз кәнсәләренә» гомере буе урау юллар аша йөрүдән бизә алмаса да, бу мәлдә ул турыдан гына суктырырга булды:

— Йә, кызым! Кем була инде ул, ягъни мәсәлән, үзең тапкан киявең? — дип, тамагын кыргалап сорады.

— Ф-фырансуз! — дип ярып салды Фирая.

— Кем, кем? — Мәрфуга колагын кызына якынрак китерде.

— Оноре Бальзак.

— Аннары... балдак, дисеңме?!

Чыннан да, уен-муеннан башланган эшнең азагы хәерле булып бетмәвен искәртеп, төн уртасында карт белән карчыкны кызларының иңрәп-иңрәп ыңгырашкан авазы уятты.

— Ай-й, Ал-ла-ам! — дип, Мәрфуга эчен тотып ыңгырашып яткан «туташ»ның билендәге тәти каешын чишеп алды да сандык өстендә укынып утырган иренә:

— Бар инде, берәр җаен эзлә,— диде.

Абзый, чебен кугандай, кулын гына селтәде дә ишектән чыгып- юк булды. Әнә инде аның Габдрахманнарга таба китеп баруы шәйләнә.

«Дошман» егетнең көпчәкле тракторы Кәлимулланың татар бизәкле урыс капкасы төбенә егерме минуттан, ә тагын бер сәгатьтән район хастаханәсе ишеге янына җитеп тукталды.

Бульдог чырайлы дежур табиб, «туташ»ның эчендәге җимеше өзелеп төшәргә озак вакыт калмаганын, гомумән, кешеләр тормышында сирәк эләгә торган мондый олуг сөенечкә

тиенер өчен чак кына көтеп утырырга кирәклеген арган-талчыккан миләргә сеңдереп, алсу марля-мамыклы бүлмәгә чумды.

Ун минуттан шәфкать туташы чыгып:

— Кизигыйз киз бабиляды! — дип хәбәр итте. Һәм соңгы сүзләрен урысчалаштырып: — Черненькая, как цыганка! — дип бетерде.

Авылга кайтып барганда, Мәрфуга апай:

— Пырансуз чегән шикелле кара халык микәнни ул, безнең сыман ак түгел, ахры,— дип сөйләнә башлагач, Кәлимулла агай, кичә чыгып бетмәгән ачуын менә хәзер чыгарып бетерергә җай табылуга куанып, тозлап-борычлап сүгенергә керешге.

— Ярар сана, атасы, буласы булган инде. Хәзер оныгыбызны...

Фаразан, көпчәкләр чокыргамы-нәрсәгәме туры килеп, карчыкны сүзеннән бүлдерде. Әлхасыйль, Мәрфуга, башлаган сүзен бетермичә, ярты юлда тукталып калучы токымнан түгел иде: аягын янга таба сузып җибәрде дә өзелгән сүзен дәвам итмәкче иде, нәкъ шул мәлне арба башта уң якка, аннары сул тарафка авышты. Шунда күзләренә якында гына балкып янучы таң йолдызы чалынды. Карт бар дөньясын онытып кычкырып җибәрде:

— Булды бу. Онытма, Зөһрә куштырам, боерса!

Бу тавыш кабинадагы Габдрахманга да ишетелде. Егет каушавыннан кинәт педальләргә баскалады һәм ялгышып тирес түккәндә куллана торган рычагны да урыныннан кузгатып куйды. Боерганны карышмыйча үтәргә ясалган арба, шундук кырынаеп, карт белән карчыкны җиргә мәтәлдерде.

...Кәлимулла белән Мәрфуга, бәрелгән-сугылган төшләрен бүльнистә дәвалатып кайткач, туп-туры кызлары янына китте-ләр. Фирая вә Зөһрә кошчыкның Чыпы Габдрахманында яшәп ятуларын ишеткәннәр иде инде алар.

Керделәр. Исәнләштеләр, һәм... түрдә эленеп торучы бишек янына барып, пәрдәне ачып текәлсәләр, шаккаттылар: оныклары суйган да каплаган Чыпы иде инде менә!

## *Юлда*

Кечкенә авылдан «Жигули» чыкты. Үр күтәрелде. Тау төште. Зур авыл янында күпергә кермичә туктады. Күпер җимерек. Өстенә алабута ише әрсез чүп үләннәре шаулап үскән, баганалары муртаеп гөмбәләнгән.

Кабинада көтүче Гата утыра. Янәшәдә авырлы хатын — сыер савучы Гөлназ. Ул башын иренең иңенә куйган. Күзләре йомык, ирене кара көйгән, ыңгыраша.

Шәһәрдән кунакка кайткан Галимнең машинасын кабызып юлга чыгуына да апасы Гөлназ сәбәпче. Ул көтмәгәндә генә авырый башлады, урын өстенә ятты.

Мондый чакта хатын-кызны тиз генә хастаханәгә илтеп куялар.

Ләкин... каһәр генә суксын инде... күперне!

— Бүгенге колхоз җитәкчеләре бөтен нәрсәне булдырырга тиеш. Ә бу?..— Гата җимерек күпергә ымлады.— Үз борыныннан башка нәрсә күрә алмый, хөрәсән...

— Әүвәл Мисыр кешеләре кәйләләр белән дә нинди биек корылмалар калдырганнар, ә бу... ни галәмәт куәтле техникага ия була торып та... Иеме, җизни?!

— Хөрәсән...

Ирләр «Нишләргә?» дип уйланып тордылар да сай сулы елганы кичеп чыгарга карар кылдылар. Әмма машина батты. Гөлназның йөзеннән тәмам кан качты. Аны инде тулгак тота башлаган иде.

Галим, врач алып киләм дип, авылга йөгерде.

— Чак кына түз инде, җанашым,— дип, хатынын башыннан сыйпап тынычландырмакчы булды Гата. Ә үзенең йөрәге минутына йөз илле мәртәбә типкән кебек иде.

Ниһаять, күренделәр.

Су буена җиткәч, фельдшер кыз, Галимнең җилкәсенә асылынып, машинага таба килә башлады. Кызның ак туфлиләре чулт-чулт итеп суга тиеп-тиеп алды. Мәгәр туктап торырга вакыт юк иде.

Гөлназ инде: «А-а-а-а...» — дип кычкыра, ә Гата машина янында колакларын томалап басып тора иде.

Фельдшер кыз кабинага керде. Озак та үтмәде, чырылдап бала елаган аваз ишетелде.

— Ата кеше... Кызың туды...

— Кызым? Ул сәламәтме? Хатыным?

— Исәннәр! Исәннәр!

Су буена зур сары трактор килеп туктады. Чылбыр сузып,

машинага тоташтырдылар. Берничә минуттан инде кызыл «Жигули» елганың теге ягында тора, ә Гата үз-үзенә ишетелерлек итеп кенә: «Шөкер, кызым да, хатыным да исәннәр!» — дип пышылдый иде.

## *Кемгә нәрсә*

Сул яңагында яра эзе беленеп торган трест башлыгы бүген хезмәткәрләре белән исәнләшмичә генә кабинетына таба үтеп китте. Керде һәм чишенмичә-нитмичә, җәһәт кенә үрелеп, селектор төймәсенә басты.

— Валерий Степаныч! Хәзер үк минем янга...

Тавышсыз гына ишек ачылды һәм ярым пеләш ир күренде.

— Чү! Сезгә ни булды? — дип куйды керүче, аптырап. — Тәмам төсегез качкан! Авырыйсызмы әллә?

— Төш күрдем мин!

— Нинди төш? Сөйләгез әле! Бәлки, берәр киңәш бирә алырмын,— дип кызыксынгандай итте урынбасар.

— Имеш, мин туган өемә кайткан булам да, капканы ачып җибәрүгә, эчтән берсе кара, икенчесе кызыл сыер атылып чы-гып...

Шул чакны озын сары чәчле, нәзек билле секретарь туташ көмеш сыман поднос тотып кайнар куе чәй һәм гөбәдия кертте.

Урынбасар хуҗадан көнләшеп куйды. Чөнки Валерий Степанычның мондый гүзәл секретаре да, шоферы да, машинасы да юк. Ә романтика дигәнең... Урынбасар нәзек биек үкчәле туфли кигән, кара капрон оеклы төз аякларга тагын бер мәртәбә ымсынып карап алды.

Секретарь туташ мөлаем елмаеп кабинеттан чыгып киткәч, Гали Кәлиеч юаш урынбасарны сискәндереп:

— Шәп кош бит, ә?! — дип куймасынмы.

Пенсия яшендәге адәм күзләрен тозландырып утырган җиреннән кинәт кызарып:

— Хоть асыгыз, хоть кисегез, Али Калич, мин төш юрый белмим! Бу мәсьәләдә Матвей Харитоныч, бәлки... Ул бит хәрби хезмәттә Сездән дә озаграк булган! Прапорщик!..

Озакламый урынбасарның икенчесе мышкылдап килеп җитте. Чәчен тап-такыр итеп кырдырган. Йөзе кырыс. Битләре кабартма.

Упыр төшен моңа да сөйләп бирде.

— Сыер игелекле мал инде ул, — диде Матвей Харитоныч көрсенеп. — Карасы киткән инде! Кызылы керсә дә... Шулай да Валентина Максимовнаны чакыртып багыгыз әле, минем

хатынны! Ул ни әйтсәң дә...

Әмма чибәр һәм шаян склад мөдиренә хуҗаның төше әһәмиятсез булып тоелды, ахры. Ул:

— Сезнең халыкта ничектер, Али Калич, бездә, төштә дуңгыз күрсәң, бәйрәмең бәйрәм булмый инде! — дип ташлады.

Упыр, ачуын эчкә яшерергә тырышып, әйтте:

— Ике-өч көнгә ял алып, үзегезне тәртипкә кертегез әле, ярыймы?!

Очлы иягенә чирткәләп уйланып утыра торгач, хуҗаның күз алдына Газизов килеп басты: зур борынлы, тар, озынча йөзле, кызыл күзле өлкән инженер! Ул нәкъ менә Яңа бистәдә үз йортында яши, сыер да асрый!..

һәм менә Газизов начальнигының төшен дикъкать белән тыңлый, итләч учын кашыган була, тирән итеп, күкрәген туты-рып сулыш ала! Әһә, ике чебен куышып йөри торгач, упырның чәенә барып төште.

— Кара сыер хәсрәтне белдерә инде, Гали Кәлиеч, аның китеп баруы яраган! Кызыл сыер исә... янгын! — диде Газизов иснәнеп.

Упыр көч-хәл белән генә:

— Зинһар, ишекне тышкы яктан ябыгыз! — дип боерды. Унунбиш минуттан инде упыр соры "Опель"ен Яңа бистәгә таба җилдертеп алып бара иде.

Уһ-һу-у! Нишләп әле мин туган йортның олы капкасы каерылып ачып куелган? Ни-нәрсә хөрмәтенә?!

Ниһаять, өйдән, шортыдан гына килеш, Вася йөгереп чыкты: упыр хатынының энесе!

Нәзек озын Васяның уң кулында стакан, сулында... шешә иде.

— Бәйрәмең белән сине, җизни!

— Нинди бәйрәм?!

— Ветераннар көне бит бүген! — Шулай диде дә Вася шешәдән стаканга сөт салып, аны Гали Кәлиечкә сузды:

— Төбенә чаклы, яме!

— Кызыл сыернкымы?!

## *Очрашу*

Бер күзле Наилә, телеграмм баганасыдай буен урталай сындырып һәм аксыл-саргылт йөзен иренә якын ук китереп:

— Мөбинә кайткан! — диде.

Хәйләкәр хатынның бөлеш шае авызындагы барлык җиз тешләре дә елтыраша башлаганчы ук, үзен эшкәртергә керешәчәгенә төшенгән иде сыңар аяклы Илнур. Мондый очракта

ирләрен — җанкисәкләрен өзелеп яраткан барлык усал хатыннар да шулай эшли. Чөнки бер-ике сүзе генә әйтелеп, иң кирәкле урыннары әйтелеп бетмәгән җөмлә-читлекне ачкач чыгачак котырган бүренең шәүләсе генә әле ул. Мәгәр Илнур барыбер җебек кемсәләрдән түгел. Бастыproductой хатыны күпме генә дуласа да, куйган максатына ирешми калганы юк әле. Менә хәзер дә, мәшһүр итек-читек каючы ачулы җыерган маңгаеннан тыгыз мускуллы кара-туткыл муенына таба гөрләп ага башлаган тирләрне тастымал белән ялт кына сөртеп атты да, тирән эчле фаянс тәлинкәгә, аның да төбе яшел мөһерлесенә, ягъни өченче сортлысына, карт әтәч шулпасын янә дүрт бакрач салдырып, ашыкмыйча гына шопырырга кереште.

Шулай да бераздан пәке-шөшле остасының кечкенә түгәрәк күзләре каршы яктагы шифер түбәле йортның тәрәзәләрен капшап алды. Бу инде Илнур әфәнденең туйганлыгын, аруларының таралып юкка чыгуын аңлата иде.

Ниһаять, хуҗабикә түзмәде:

— Мөбинәне әйтәм әле. Бу юлы бер әрмәнне ияртеп кайткан,— диде дә өйдән чыгып китте.

— Нишләтәсең инде. Зур елгага дәү пароход кирәк булгач...— дип көлде хуҗа. Аннары, диван-караватка кырын ятып, хыял дөньясына чумды.

Мөбинә әнисе ягыннан шанлы Мәче нәселенә барып тоташа. Гәрчә әтиләре Илнурларга туган тиешле булса да, аларны һәрчак Мәченекеләр дип йөртәләр иде. һәм Мөбинә тач Мәче нәселенеке иде дә инде. Әйтик, Әнәк күлендә анадан тума коенучы кыз-кыркын күзгә чалынмас. Әгәр дә андый «йөрәкле» күзгә чалынса, ул, һичшиксез, Мөбинә булыр иде. Әнә шундый кыюлыгы өчен ярата иде инде аны Илнур. Аннары Мөбинә үзе дә, энәгә тагылган җеп кебек, гел шамакай Илнур тирәсендә уралыр иде. Электрик кушаматлы кызга үзеннән ике яшькә олы Артист кушаматлы үсмер тирәсендә буталып йөрү бик ошый иде бугай. Кызга кушаматны да, койма башларында утырып, капкаларга үрмәләп, агачларга менеп йөрергә ратканы өчен Илнур кушкан иде. Ә кызның болай эшләве егетнең дикъкатен һаман үзенә җәлеп итеп торырга теләүдән килеп чыга иде шул. Кыскасы, авылдагы урта мәктәпне тәмамлап, Илнур укуын дәвам итәргә Казанга китеп барды да... Мөбинәнең ташып торган дәртен басардай кызык та калмады авылда. Андый чакта иң дөресе — яраткан кешеңнең әйләнеп кайтуын сабыр гына көтеп тору!

Ләкин Илнур, азгын җан, мескен Мөбинәнең өметен акла-мады. Калага китүенә бер ел да булмады, авыл Сабан туена Свердлау кызын алып кайтты.

«Ярар!» диде Мөбинә, иреннәрен канатканчы тешләп, һәм калага укырга китте дә, икенче елны авыл Сабан туена берьюлы әзмәвердәй ике урыс егетен ияртеп кайтты.

Шуннан китте ярыш, башланды тартыш болар арасында. Ме-нә көннәрнең берендә Ташкенттан Казанга куылган төрек кызы Наиләгә өйләнеп җибәрде Илнур. Ә Мөбинә, Ташкентка китеп, Наиләне бирегә куып кайтарган үзбәк егетенә кияүгә чыккан.

— Бигрәкләр дә уңды инде кызыбыз кияүеннән,— дип сөйләнде әнисе соңыннан.

Кызганыч, Илнур белән Наиләнең балалары булмады. Ә Мөбинә тегендә берсеннән-берсе матур өч егет үстереп ята, ди. Шулай да итек-читек каю остасы түзмәде, узган ел Мөбинә яшәгән җиргә барып, комын коеп кайтты. Быел инде әнә Мөбинә үзе кайткан, ди!

Илнур, аякларына читекләрен киеп, култык астына бер пар хатын-кыз читеге кыстырып, сул аягына аксый-аксый, чишмә буена юл тотты. Хатынына исә, култыгындагы читекләргә ым-лап:

— Ванька хатынына тектерткән иде, шуңа илтәм,— диде. Аның Ванька дигәне сары башлы, сипкелле Вәлиулла иде.

Инде кояш та баеды, күктә ай да калыкты — Илнур юк та юк! Вәлиуллаларга бөтенләй бармаган булып чыкты ул...

Наилә ирен эзли торгач, әллә ничек кенә чишмә буена килеп чыкты. Ә чишмә янында, иңнәрен-иңгә терәп, сөйләшеп, Илнур белән Мөбинә утыра иде.

— ...Хәтерендәме? Агачлыкка кергәч, күземә ботак тиеп... Хәтерендәме? Кукуруз арасында... Хәтерендәме? Урман сукмавында үбешеп торганда елан килеп чыгып...

— Ну...

Наилә күккә күтәрелеп бакты, таң беленеп килә иде. Хатын гомерендә беренче мәртәбә таңның тиз генә атмавын теләде. Чөнки тегеләр бигрәкләр дә матур, бигрәкләр дә тәмле итеп сөйләшәләр иде шул, шайтан алгыры!..

## *Сызгырып бию*

«Сызгырып бию» дигән кулъязма китабым нәшрият киштәләрендә озак тузан җыеп ятты. Ә бит ул, басылып чыккан тәкъдирдә, китап кибетләрендә генә түгел, хәтта китапханә шүрлекләрендә дә аунап ятарга вакыт тапмыйча, гел укучылар кулында булып, «сызгыра-сызгыра биергә» тиеш иде. Ярар, болай ук тирәнгә кермик әле, чөнки бу китап басылмаган! Ни өчен басылмаганмы? Әлеге сорауны ачыкларга теләп, мин нәшрият мөхәрриренә мөрәҗәгать иттем, һәм ул миңа мондый җавап кайтарды:

— Син, кем, иптәш, китабыңның исемен буташтыргансың. Чөнки җыентыкта «Сызгырып бию» исемле әсәр юк һәм, тулаем, калганнары да «Сызгырып бию» дигән мәгънәгә җавап бирмиләр. Йомшак әле, кһм, йомшак...

— Кһм, гафу...А-а, исәнмесез, мадам!..У-у, Хәбир Фәй... ы-ы-ы Хәйретдинович, сколько лет, сколько зим!.. Ә-ә, Салават Мәҗитович... кайтып җиттегез-з-з... Да, вряд ли синең ул «Кәлҗемә» дигән китабыңдагы кәлҗемәнең укучы күңеленә хуш килүе! Хәзер бит базар икътисады, конкуренция, рэкет... ы-ы-ы...

— Мин кайда калдым әле бая?

— Бөгештермичә, турысын гына әйтегез әле, минем «Сызгырып бию» исемле мәшһүр кулъязма китабымны кайчан дөнь-яга чыгарасыз канса да канис?! — дигәч, мөхәррир бәләкәй генә түгәрәк, кызгылт күзләрен чабата кашлары астына яшереп, җитди итеп миңа карап торды да, кинәт кояштай балкып:

— Синең бу җыентыгында кәлҗемә бармы? — дип сорады. Мин, ике дә уйламыйча:

— Бар, бар... «Урыс аракылары» да бар әле анда, ни тук-мышту! — дип, турыдан-туры чәпәп җавап кайтаргач, пеләш мөхәррирнең уймак авызы бәлеш кебек җәелде.
Ул, миңа таба авыша төшеп:

— Шулай да... китабында «Коньяк» дигән әсәрнең булмавы кызганыч, чөнки шунсыз аны тулаем аңламаулары мөмкин һәм мәңге басылып чыкмавы бар! — диде дә, нидер өмет иткәндәй, бер миңа, бер букчама карап тора башлады.

— «Коньяк» дигән әсәрне аерым төреп алып килдем,— мин әйтәм,— менә букчада ул! Аның янәшәсендә тагын «Закуска» дигән шигырь кисәге һәм «Тушенка» исемле баллада да бар!..

Мөхәррир һич көтмәгәндә төкереген йотып куйды һәм:

— Теге «Сыер» атлы поэмадан чыккан нәрсәме соң ул? — диде.

— Юк, «Дуңгыз» исемле олы романның кечкенә бер кисәге генә ул.

Шулчак өздереп-өздереп телефон чылтырый башлады. Мөхәррир трубканы алды:

— Әйе, дөрес, дөрес... сез нәкъ точкага туры килгәнсез... Әйе, чынлап та юләрләр йорты бу. Соң инде бу катмарлы за-манда акыллы кеше, китап язып, ач ятамы?.. Бизнес белән шөгыльләнә, беләсең килсә!..

— Җаваплы персон көлә-көлә трубканы урынына куйды һәм, миңа таба борылып, батыраеп эндәште:

— Букчаңдагы әсәрләрне әнә тегендә куеп калдыр, ә кулъязма

китабың пока ятсын әле киштәдә, «Сызгырып бию» дигән мәгълүм әсәрне иҗат итеп китергәнче... Тик аның янәшәсендә «Чәшке тун» дигән мәшһүр романнан саллы гына бер өзек тә булсын! — һәм ул, миннән ерак түгел генә сигара пыскытып утыручы бер яшь шагыйрәгә елмаеп эндәште: — «Жигули» атлы дилогиягезнең беренче кисәге безгә бик ошады! Икенчесен дә китереп куйсагыз...

Әмма яшь әдибә каушап калмады, җаваплы персонның муеныннан кочып битеннән үпте дә колагына нидер пышылдады. Ә җаваплы персон, бик канәгать чырай белән алты бармаклы кулының ике тырнаклы бармагын селкә-селкә:

— Ладны, дарагая, сезнең исем **Шәрифләрегезне** списокка иң беренче итеп керттерербез! — диде.

Шуннан купты тавыш, китте кычкырыш. Бер юан гына тәрҗемәче ханым: «Боларга «Танк» дигән шигъри романымны китереп күрсәтмичә булмас инде!..» — ди. Ә озын буйлы ветеран агай исә барысын да уздырып җибәрде: «Менә мин «Атом» дигән эпопеямнең кечкенә генә бер кисәген китереп ташласам...»

Җаваплы персонның җаны бугазына менеп җиткәндәй булды, ул безнең алга тезләнде дә, теге бармагы белән түшәмгә күрсәтеп:

— Пачадите, тауаричи... бездә тамчы да гаеп юк. Без бит үзебез дә әнә тегенең кубызына биибез. Гади итеп кенә дә түгел әле, сызгырып-сызгырып биибез! — диде.

## *Мунча*

Хәбибулла, эченә ике әрем, дүрт бөтнек, сигез мәтрүшкә сабагы кыстырып бәйләгән хикмәтле каен Себеркесе белән тәне уттай кызганчы чабынгач, күңелле генә итеп ухылдый-ухылдый ләүкәдән төште дә, таза йөрәгенең бугазга менәргә талпынып дөпелдәвен тыңлый-тыңлый, башыннан бүреген, кулларыннан бияләйләрен салып, рәхәтләнеп-ләззәтләнеп салкын әйрән эчте дә, сау үпкәләренә саф һава килешәсен белеп, өйалдына чыкты һәм усак эскәмиягә килеп ятты. Әллә кайдан белепсизеп торам: моның тәннәре сихәтләнеп, күңеле иркенәеп китте инде! Буеның озынлыгы да ярдәм итәдер инде моңа шундый кызуда ярты сәгать буе эһелдәп тә карамыйча, бүректән-бияләйдән чабынып утыра алуына, дип уйладым мин. Уемны үзенә дә әйттем.
һич тә алай түгел икән, дустым! — диде Хәбибулла.

— Мин бит авырган чакларымда иптәш, картайган вакы-

тымда булышырга балаларым булыр, дип өйләнгән идем. Хәзер аңа ничек итеп өйләнүемне сөйләп маташмыйм, шунысын гына әйтәм: хатынымның буе 148! Гаҗәпме? Әле ул, җитмәсә, армиядә хезмәт иткән, аннары шахтада ике ел күмер чапкан!..

«Армиягә ничек алдылар соң сине?» — дип сорагач, хатыным, кулын гына селтәп куя да: «һи, ние бар инде аның! Буемны үлчәгәндә, аякларымны күтәреп тордым, менә шул!» — ди. «Ә шахтага курыкмыйча ничек төштең соң, бәгырем?» — дип сорагач, ул, алтын тешләрен җемелдәтеп: «И-и Хәйбулчик! Бер стаканны гөпелдәтеп төшкәч, анда юлбарыс түгел фил килеп чыкса да курыкмыйсың инде!» — ди.

Менә шулай, иптәш, хатыннан бетеп уңдым мин. Әйтәм ич, буе кечкенә кечкенәсен, ну кыюлык үзендә, гайрәт! Ул йөрәк, һи, бездәге йөрәк йөрәкмени!.. Мәгәр шулай да, иптәш, һәр катының йомшак ягы да була дигәндәй, минем җефетнең дә андый ягы бар булып чыкты — мунча яратмый икән бу! Әгәр дә ул мунча яратса, минем белән мунчага керүгә үк, аннан-моннан юынып, тиз генә чыгып китү ягын каермас иде! Ярар, хатынымның мунча сөймә- ве — минем файдагадыр әле. Алай-болай дилбегә кулдан китә башлаган чакларда, моны капылт кына мунчага алып кереп «җебетергә» мөмкин ләбаса! Мин бит студент елларында каланың мәшһүр мунчасында җилкә чабучы булып эшләп, теләсә нинди кызуга чыдарга өйрәндем! Авылга кайтып мунчага кергәч тә, яшьтәшләремә: «Студентлар менә шулай чабыналар!» — дип кенә куя идем.

Әһә, чираттагы получкадан соң хатыным янә чәпчергә тотынды! Җитте, бүтән түзәрлегем калмады. Кичкә таба әйбәтләп мунча яктым да, мунча өлгергәч, хәләлемне алдан кертеп җибәрдем. Андагы шартларга күнегә торсын, мин кереп ләүкәне тәмугка әверелдерә башлагач, тышка чыгып сызарга җайлырак булыр, янәсе. Аннары бераздан хатыным- янына елмаяелмая үзем дә киттем.

Барып җитеп, чишенеп эчкә үтүем булды, шундук пелт итеп, шампан бөкесе сыман атылып чыгуымны да тоймый калдым! Артымнан җефетем: «Җаныкаем! Менә шулай чабына инде ул шахтерлар!» — дип калды.

— Шулай, иптәш, шул хәлдән соң дилбегә тулысынча хатын кулына күчте! Их... мунча гына харап итте мине! — дип, Хәбибулла урыныннан торды.

Мин агачтагы сырга карадым. «Хәйбулчик»ның буе төптөгәл ике метр иде.

## *Мин кем?*

Соңгы вакытларда башыма кайгы төште әле: һич көтмәгәндә үземнең кем булуым турында уйлана башладым. Юк, бу очракта сарык яки сыер ише йорт хайваннарын әйтмим мин һәм усал җанварларны да күздә тотмыйм. Мин, шөкер, үземне Кеше дип атыйм әле. Хәер, бүтәннәр дә үзләрен Кеше дип атыйлардыр. Дөньяга яшәргә килгән һәммә кеше дә үзен Кеше дип атарга телидер. Әмма чынлыкта тормыш кануннары күпкә катлаулырак һәм кырысрак шул. Ә кешенең табигатендә җиңел һәм рәхәт яшәү омтылышы көчле. Бу бармакларның ияләренә таба кәкрелегеннән һәм нәфеснең йөгәнсезлегеннән килә, минемчә. Югыйсә кешеләр, әллә нинди төркемнәргә берләшеп, әллә нинди халык вә милләтләр оештырып, бер-берсенә этлек кылып яшәмәсләр иде. И-и малай, аларның ул яшәүләрен яшәү дип атап та булмый инде. Юк. Менә мин, ичмасам, яшим! Чөнки мин бер генә төркемгә дә кермим, бер генә халыкка да, милләткә дә хезмәт итмим. Мин — ирекле кеше!..

Шулай беркөнне урамга чыктым. Төньяктан, ыж-жид, дип җил исә башламасынмы! Әй ачуым килде дә инде. Нишләп мин жид булыйм әле, мин әйтәм, һәм, күкрәк кесәмнән чыгарып, кульяулыгымны җилгә бүләк итәргә туры килде. Аннары җилнең җилбәзәклегеннән рәхәтләнеп көлеп җибәрдем.

— Очырта бир,— мин әйтәм.— Анысы иске кульяулык иде. Яңасы менә «Техас» дигән чалбар кесәсендә!

Атлый торгач, әкәмәт телдә сөйләшкән авазлар ишетелде. Карасам, «Ресторан» дип язылган унсигез катлы йорт янында костюмнан, күлмәктән генә егетләр-кызлар басып тора икән. Тәвәккәлләп яннарына киттем.

— Сез кемнәр? — мин әйтәм.

— Чуашлар! — ди егетләрнең чалыш күзлесе.

— Ә син үзең кем соң? — ди кызларның кыек авызлысы.

— Чу-а-ш! — мин әйтәм. Шуннан болар:

— А-а, чу-аш космонауат! — дип, мине эчкә алып кереп киттеләр. Ә анда чуашлар туй итеп, типтереп яталар икән. һәм минем чуаш икәнемне белеп алдылар да, и тотындылар закускасыз гына сыйларга!.. Сыйлана торгач, тәмам йөрәксенеп киткәнмен, малай, кәләш-кәмәшнең уймак ирененә үк үрелә башлаганмын икән. Ярый әле кияве күрми калган, мин әйтәм, колак төбенә зур гына бер миң ясап куяр иде дә аннары йөрер идем Миңлеленар булып!

Әйе, мин ул кичне рестораннан иң соңгы кеше булып чыкканмын. Чыкканда, әйтүләренә караганда, татарча җырлаганмын икән. һәм тегеләр дә миңа кушылып татарча җырлаганнар, имеш. Баксаң, алар үзләре дә мари булган икән!

Ярар. Анау мәчеткә бер негр кереп китте, мөселман булса кирәк. Хәер, мин дә мөселман бит, керим әле. һәм, малай, барып керсәм, андагы кешеләрнең күплегенә исем китте. Араларында урыс кыяфәттәгеләр дә аз түгел!

Тыгыз сафларны тиз генә ырып-ерып үтмәкче идем, әй, тәһарәт ал, дип, артымнан бер шәкерт кычкырды. Аны тыңлап тормадым инде, мәчет әллә кемнәрнеке түгел әле, үзебезнеке!

Хәзрәт янына барып чүмәштем, малай. Ә корсагым түп-түгәрәк. Мине мөфти дип уйладылар, ахры. һәммәсе дә сирәк тешле авызыма карап катты. Ә мин аларга ымлап кына хәзрәтне күрсәттем. Янәсе, бу мәчеткә ул баш, аңа карап сәҗдәгә китегез. Аңладылар, мәхлуклар! Соңыннан байлар өләшкән сәдакадан миңа да симез калҗа эләкте. И сөендем дә инде. Как раз баш чатнап тора иде, мәчеттән чыккач, туп-туры сыраханәгә юнәлдем...

Чү! Акчагыз коела, дип кемдер кычкыра түгелме?

Түбәнгә карасам, чынлап та, җиргә пәлтә итәгеннән сәдака акчалары шыбыр-шыбыр коелып бара. Кесәләргә кулларны тыккан идем, кулларым әллә кая төштеләр дә киттеләр. Аһ! Харап, кесәләрне кисеп алганнар, мин әйтәм. Мәгәр тикшерә торгач, шул беленде: мин мәчеттә, ашыгычлык белән, үземнеке дип уйлап, бер кяфернең эче тузган пәлтәсен киеп киткәнмен икән!

Аннары, өйгә кайткач, хатын иләде, малай: «Ярый әле, пәлтә урынында мин булмаганмын, мине калдырып, Мәрүскәне алып киткән булыр идең»,— ди. Дөрес сүзгә җавап та юк инде ул, эндәшмәдем.

Ә кичә, малай, базар чатында тагын бер кызык хәлгә тап булдым әле. Шул тирәдә генә урыслар туй итеп ята икән. Үземне урыс дип әйтеп, араларына барып кергән идем, кабул иттеләр, малай. Ну, сыйлаганнарын сөйләп тормыйм, мәгәр табыннары янында татарча җырлап, гармуннарында марҗаларны хәлдән тайдырганчы «Әпипә»гә биеткәнемне һич онытасым юк. Соңыннан бөтен туй гөрләтеп кул чапты үземә.

— Молодец! Сам русский, а все знает! — диделәр.

Шуннан иллә дә үсенеп киттем, малай. Казан урамнарында янә ике көн яһүд, өч көн вьетнамлы булып йөрергә туры килде әле миңа. Тик озакламый милиция кулына эләккәч кенә үземнең кем булуыма төшендем, малай. Баксаң, мин — интернационалист икән!

## *Солтан буласың килсә*

Үзебезнең транспорт хуҗалыгында мине белмәгән кеше юк! Гади шуфир гына булсам да, дәрәҗәм буенча нәчәлник шикелле мин монда! Бүтәннәрнең кушаматлары да Храмой да Кривой, минеке — Прафисыр! Хәтта мине ялгыш ишегалдына очып төшкән чыпчыклар да белә, күгәрченнәр дә таный; күргәч, «чирик та чирик», «гү дә гү» итә башлыйлар!.. Беркөнне әле турыбыздан очып баручы виртәлүт лүтчиге дә танып кул болгады. Мөселман булды, ахры:

— Әссәламегаләйкем! — ди.

— Вәгаләйкемәссәлам! — мин әйтәм.— Кая юл тотасың?

— Бохарага! — ди бу.

— Үзбәк дусларга күп итеп сәлам тапшыр, карбыз-кавын төяп җибәрсеннәр Казанга! — дим.

— Ярар, тапшырырмын! — ди.

Гомеремдә күрмәгән урам этләренә тикле таный мине. Юлда очраткач, койрыкларын болгарга, колакларын селкетергә тотыналар, чөнки исемем дә башкаларныкы кебек этләр ачуын китерә торган түгел! Аннары мин бит эчмим дә, тартмыйм да. Үзебездә эшләүче хатын-кыз кавемнәре үләләр миңа кызыгып! Берсеннән-берсе чибәр марҗалар:

— Ох, Абдулчик, милый, кайда булдың икән син элек?! — диләр.

Яшем кырыкка җитсә дә, үземне һаман унсигездә сыман хис итәм! Моның серен бары тик үземнең Әстерханда карбызлар өлгергән вакытта туган булуым белән генә аңлата алам. Шуңа күрә мине быел район советына депутат итеп сайладылар да инде! Аңарчы бер сөйкемле генә марҗа әбие, зәңгәр төймәдәй күзләрен елтыратып, миңа:

— Әгәр дә депутат булсаң, ни эшләр майтарыр идең? — дигән сорау бирде.

— Иң элек сайлаучыларымны тамакларына ангина чыкканчы карбыз белән сыйлар идем! — дидем.

И рәхәтләнделәр дә соң көлеп! Кул чаба-чаба уч төпләре авыртып беткәндер. Шунда тагын бер сайлаучым:

— Ә син апельсин яратасыңмы? — дип сорап куйды.

— һәй, голубушка, яратмаган кая! — мин әйтәм.— Шуның исе чыкса, мин, әйләнчек сарык шикелле, борылам да киләм, борылам да киләм апельсин исе чыккан төшкә.

Күреп торам: татарлар елмая, кайберләре көлеп тә куйгалый, мәгәр урыслар бик җитди. Баягы марҗа түти түзмәде:

— Капчур по-русски нәрсәне аңлата ул, энем? — дип төпченүендә булды.

— Капчур чуаш сүзе инде ул,— дидем.— Ә бүрәнә — татарныкы! Коммунизм — Марксныкы! Тун — тунгусныкы, ә дуңгыз — дуңгызныкы...

Бутала башлавымны сизеп, диспетчерыбыз Дуня:

— Ә безнең өчен нинди файдалы эшләр майтарыр идең? — дип сүзгә кереште.

— Иң элек урыс теленең дәрәҗәсен күтәрер идем,— дидем.— Аннары үзебезнең автохуҗалык статусын үзгәртер идем! һәм шул акционерлар җәмгыятенең президенты булып алгач, иң беренче эш итеп урыс телле иптәшләрнең хезмәт хакларын...

Шунда мине, аяк-кулларымнан эләктереп, ура кычкыра-кычкыра, югары чөйделәр, һәм шунда мин киләчәктә туп-туры президент креслосына барып төшәчәгемне аңладым!

## *Галим хәсрәте*

Ул ничек була, дисеңме?! Киномеханик, көтүче яисә сыер савучы хәсрәте кебек була инде галим-голәмәнең хәсрәте. Әйе-әйе, кем... Про... Ничек? Фес-с-ор? Ә-ә, мине этәсеңмени әле, профессор, дип? Әй, шәп егет тә соң син, кем... Ака... Ничек? Димик?! Ә-ә, мине этәсеңмени, канәтем, ака-демик, дип? Бик хуп, бик хуп! Ә үзең ниме соң? Юк, үләнгәнлегең кирәкми миңа, канәтем, син үзең, мәсәлән, ниме, укыганмы? Шулай-мы-ни-и?! Туктале, нәрсә аттең әле син?! Ничек? Пановка университетын? Андый университет та бармыни әле бу нидә. Әһә, бар ызначит. Латны, язып куям хәзер. Тәк, ничә ел укыдың инде анда син? Ун-ө-ч-ч?! Фью-у-у... Аспирантураны да тәмамладыңмыни беррәттән?! Көчләгән өчен, дисеңме? Ни дигән сүз була инде бу, канәтем, аңлатып бирсәңче! Пахан идем, дисеңме?! Гыйльми дәрәҗәңмени бу, коллега? Ә-ә, минем гыйльми дәрәҗәмме? Анау кем ул? Юк, качмыйм, канәтем... Дәфтәрдән кем булуымны гына карамакчы идем. Телефонга ник орындың соң дип инде... Склероз бит миндә, әйе. Ә син кем буласың әле, энем? Ә-ә, рэкетермыни?! Әйдә суң, алайса, таныш булыйк, мин дә рэкетер бит! Нәрсә, шөлләдеңме, коллега? Ха-ха-ха... Юк-юк, пәке күрсәтмә, кирәкми, ату мин дә күрсәтергә могу. Нәрсә? Дүрт иптәшем бар бирәдә, дисеңме? Булса соң. Минем меңнән артык ыстудинтым бар, алайга китсә! Куркытма! Пахан, имеш!..

Мин дә пахан анысы... Меңнән артык ыстудинтка пахан мин! Так шту минем белән не шути, кем... Атәм бит, миндә мина бар, тол бар, и тагын бар миндә... Ничек? Сөяркәләреңнең кушаматларын атама бүтән, җитте, гарык, дисеңме? Шул шул менә, кем, син туйдың, ә мин ач әле, ач эт шикелле! Давай бир миңа акча, сталавайга кереп чыгыйм, корсакны тутырып чыккач, Сораганнарыңны атәрмен, белмәгәннәреңне үрәтермен. Ә-ә, атам куштырган исемемме? Галим, Галим булам мин! Теге чакта ни өчен ниткәннәрне суң, дип... Шул инде, бер чибәр туташның кәләпүшенә төкергән өчен... Ә хәзер монда эшлисеңмени, дип... Әйе, монда эшфитсар булып эшлим бит мин хәзер...

## *Инженер*

Инженер булам мин үскәч, дип бәләкәй чакта очраган бер кешегә  әйтә торган идем. Ниһаять, утыз җиде яшь тулып килгәндә, инженер булдым да куйдым менә. Дөрес, аңарчы байтак кына лаеш шулпасы чөмерергә туры килде. Башта үзебезнең авылда сигезне бетердем. Аннары, күрше авылга йөреп, тугызны тәмамладым. Аннары, малай, СПТУга кыякладым. Анда ике ел чамасы чиләнеп йөрдем дә колхозга кайттым. Тракторга утырттылар. Ләкин мин, үзегез беләсез, инженер буласы кеше ич. Шуннан, малай, тут прәме юл пашул, дидем дә сыпырттым калага. Янә дә килеп ГПТУга урнаштым. Болай ничауа үзе, яшәргә урын, кияргә кием бирделәр, ашау-эчү дә алар кесәсеннән, малай. Шуннан ГПТУны ничек кирәк шулай җырып чыктым да, озак уйлап тормадым, бер яшь ханым аша элемтә техш никумына барып кердем. Андагы хәлләр, малай, андагы хәлләр!.. Бер язучыга сөйләсәм, валлаһи, ипи калынлык китап язып ташлар иде. Ләкин мин, үзегез беләсез, скрумный җегет, күргән-белгәннәрне теләсә кайда, теләсә кемгә сөйләп йөри алмыйм, бигайбә!.. Шуннан, малай, сәүдә техникумына барып кердем. Элемтә техникумын ничек кирәк алай маташтырып чыккач инде. Шуннан, малай, өченче курста укып маташканда, көннәрдән бер көнне безне бер базарга җибәрделәр, зур базарга! Нитәргә инде, әйе, практика үтәргә. Шунда, малай, түбәнгә төшкәндә лифт нитте, әйе, тукталып калды. Ә лифтта директор да бар иде. И кыбырсый бу, и үрсәләнә, шакып караган була, кыч-

кырып баккан була, юк, ишетмиләр генә бит өстәгеләр. Шуннан, ярар, торабыз инде төшеп коткарганнарын көтеп. Юк, килмиләр, малай, төкереп тә бирмиләр, ысбулычлар. Шуннан эчкә сурку керде бит, кычкырып сүгенеп җиффәрәсе килә. Ярамый, чөнки тигезлек юк шул бирeдә. Шаккатмалы хәл бит, малай:

өч урыс та биш татар икәнбез монда!.. И шөллиләр тегеләр, и калтыраналар! Ул бахырларны кызганып мин дерелдим, гәрчә чыкылдаган татар булсам да. Ул-бу була калганда, тегеләрне яклар өчен, әлбәттә, үземне урыс итеп күрсәтмәкче булам! Ни өчен, дип инде... Теге өч урыс арасында Мәскәү кунагы — урыс министры бар бит! Ә минем, үзегез беләсез, әле яшисем бар, өйләнеп җиффәргәч, канишны. Кемгә, дип... Теге Мәскәү министрының каршында елмаеп торучы бәләкәй борынлы кызына, канишны! Шуннан, малай, бар булган кыюлыгымны җыеп: «Әй, не грустите, тауаричи! Мы же люди русские! Давайте повеселимся, давайте поплясать!» — дидем дә, лифт идәненә сикердем. Шунда лифт гөжелдәп кузгалды да китте бит, малай, түбәнгә төшеп! Шуннан, озак та үтмәде, «За проявленное мужество!» — дип, укыган җиремә китереп күкрәгемә урдин тактылар! Хәзер мин — белмәсәң бел! — өйләнгән кеше. Кемгә, дип... Шул инде, министр кызы Мариночкага. Әйе, инженер мин бүгенге көндә! Кайда, дип... Мәскәүдә, министирыстыбада инде...

# Яшь шагыйрь маҗаралары

## Повесть

Ибраһим абый белән Фәүзия апа аның дөньяга тууын һич тә теләмәгәннәр иде. Дөресрәге, әлегә бала кирәк түгел иде аларга. Чөнки бер кыз белән ике малайлары бар иде инде. Шуңа күрә, кем әйтмешли, "планда каралмаган" малай тугач та, кадерсез бер җан иясе шикелле, бишегендә ис чыгарып ята башлады. Мәгәр малай үзе дә, эшнең кая таба тәгәрәгәнен сизгәндәй, бишегендә имезлеген суыра-суыра тын гына ята бирде. Була иде шундый вакытлар: тыны-көне беленмәгәч, әллә үлгәнме теге, дип, килеп аны карыйлар иде дә — таң калалар иде. Чөнки шикәр сыман ак йөзле малай, акыллы коңгырт-кара күзләрен зур ачып, каршындагы нәрсәләрне җентекләп өйрәнеп ята иде бу мизгелдә! Ул гына да түгел әле, апасының яки абыйларының кырыс йөзләрен күреп елмаеп ук җибәрә, көлә үк башлый, мин сиңа әйтим! Шуннан соң, Фәүзия апа әйткәндәй, теге "күз көекләре"нең дә йөзләренә кояш чыга инде. Ләкин төпчек малай төшеп калганнардан түгел шул, үтә горур! Тегеләр күтәрергә итеп тирәсендә бөтерелә башлагач, ул аларның беләкләрен тота да, тешләп ала! Болай гына, шаярып кына түгел, чын-чынлап. "Ә шулаймы... ярый алайса...", — диләр тегеләр,— китеп тә баралар. Әмма бәләкәчне ялгыз калу өркетми һәм ул кулына эләккән берәр нәрсә белән мавыгып уйнарга да тотына. Әлбәттә, һәрвакыттагыча, уенның азагы бик күңелсез тәмамлана инде: резин курчак тешләп-тешләп алынган, тәлинкә-фәләннәр ярылган, агач кашыклар кителгән була, — и әзмени өйдә ватарга яраклы нәрсәләр?!

Менә шул хәлләрдән соң, Ибраһим абый белән Фәүзия апа: "Илвирны өйдә ялгыз гына калдырырга ярамый!" — дигән фикергә килде. Мөмкинлек булганда, инде бераз үсә төшкән малаен йә Фәүзия апа, йә Ибраһим абый үзе белән ияртеп алып барырга тырыша иде. Ләкин малай барган җирендә дә үтә кызыксынучанлыгы һәм тиктормаслыгы аркасында нинди дә булса бер маҗарага тармый калмый иде. Соңыннан исә, Илвир

турында сүз чыкканда: "Ә-ә, теге... агач башыннан мәтәлеп төшкән... читән аударган... каз талаган... эт тешләгән малайны әйтәсең икән!" — дип, байтак вакытлар сөйләп көлешәләр иде. Ә бит, чынлап торып тикшерсәң, бу тамашалар менә нидән килеп чыккан була — агач башындагы бердәнбер алмадан! һәм: "Шул алманы өзеп алырга кемнең кыюлыгы җитә?" — дип, дүрт-биш малайга карап, серле генә елмаеп торучы Резеда исемле искиткеч мөлаем, чибәр кызны да искә төшермичә ары китеп бару килешмәс, мөгаен!

Әйе, шул чакта Резеда инде сүзен әйткән, ә теге "тишек борын"нар исә: "Бу менсен дә, ул менсен", — дип бәхәс куертып торган арада, Илвир ясканып агачка менеп тә китте! Алманы үрелеп алды ул алуын, мәгәр ботак кинәт сынып, Илвир читән өстенә шап итеп барып төште. Читән ауды! Каяндыр бакчага кергән усал казларның берсе шундук Илвир өстенә ташланды! Аннары, каздан качып барганда, тагын каяндыр пәйдә булган кара эт, зәһәр ырылдап, малайның алма тоткан кулын каптырып алды! Әгәр дә шул мизгел йорт хуҗасы "Пират!", — дип этен чакырмаган булса, бу тамаша нәрсә белән төгәлләнер иде икән? Әйтүе кыен...

Һәрхәлдә шунысы аяныч: урамда инде ят малайларның да, Резеда дигән чибәр кунак кызның да эзе суынган иде... Шуннан соң тәндәге эт ярасы төзәлде, ә күңелгә салынган яра, юк, төзәлмәде. Бит Резеда Илвирны батырлыкка әйдәде, кыю булырга өндәде, ә үзе, хәвеф якынлашкач, җавап тотудан куркып, качып китте. Юк, Резеда, болай булгач, кирәгең юк синең Илвирга, бер тиенгә дә кирәгең юк!

Әнә, күршедә яшәүче Хәбирә әбинең оныгы Гөлмирә яшелчә бакчасыннан бергәләп кыяр урлаганда, каравылчы искәрмәстән генә Илвирны эләктереп алгач та куркып качмады бит! Менә, ичмасам, ул әйбәт кыз! Әмма Гөлмирә Илвирга ошамый. Аннары бергәләп кыяр урларга да Илвирны шул кыз котыртты ич! "Ә урлау — әзме ул, күпме — ни генә әйтсәң дә, гөнаһлы эш!" — ди Илвирның әбисе. Ә Илвир- ның гөнаһлы эшләр кылып, теге дөньяда тәмугта янасы килми. Ул җа- ны- тәне белән оҗмахка эләгергә тели! Моның өчен, кунак кына бу- лып яшәгән бу дөньяда бик күп саваплы эшләр кылып калдырырга ки- рәклеген дә белә! Ә изге, саваплы эш җиңел генә эшләнми бит! Хәер, оҗмахка эләгәсе килгән кешегә, изге, саваплы эшләр кылырга — җае да чыгып кына тора ич. Әйтик, барганда-кайтканда олыларга яки эш кешеләренә исәнлек-саулык теләп үтеп китү! Аннары, бер генә минутка да Алланың барлыгын истән чыгармаска кирәк! Чөнки Аллаһы Тәгалә кемнең ни кылганын, ни эшләгәнен һәрчак күреп, белеп тора лабаса! Әгәр дә инде Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәтенә ия булыйм дисәң, һич кичекмәстән изге Коръән сүрәләрен өйрәнә башларга кирәк! Менә хәзер үк...

Әбисе Илвирга бу сүзләрне әйтеп кенә калмады, үзе дә Коръән сүрәләренең белгән чаклысын өйрәтергә кереште... Ә менә күкрәкләренә комсомол значогы таккан игезәк абыйлары белән муенына кызыл галстук бәйләп йөргән апасының исә әби кешене "диндар", "надан" дип атаулары һәм Алланың юклыгын тырыша-тырыша исбат итеп маташулары Илвирга һич аңлашылмый иде. Җитмәсә, Ибраһим абый — коммунист та! Ул да Алланың барлыгына ышанмый! Шулай да, үзе, "капкан" чакларында, идәнгә аяк бөкләп утыра да:"И Аллам, гафу ит мине", дип,кулларын түшәмгә таба су- зып, ялвара торган иде. Ә Фәүзия апа исә, Алла бар дип тә, юк дип тә әйтми... Шулай итеп, ул ике якка да ярарга тырышкан, ахры. Мәгәр мондый күз буяуларны Илвир берничек тә кабул итә алмый иде әле ул чакта. Чөнки аның өчен Алла йә бар, йә юк кына була ала иде шул!

Ә укырга кергәч, совет мәктәбендә, дөньяда фәннәрне бик шәп укытучы һәм иң якты идеалларны пропагандалаучы укытучыларның тик СССР дигән шанлы илдә генә булырга мөмкин икәнлегенә инандырдылар аны! Ә сул кулын чак кына артка ташлап, уңын исә күкрәге турысына китереп, Ленинга охшарга тырышып йөрүче бөер авырулы директорның чын мәгънәсендә диктатор булуын һәм, галәфи чалбар киеп, кәпрәеп йөрүче чахоткалы завучның да директорга охшарга тырышып пеләшләнүен, яшь кенә ир укытучыларның да берничә елдан соң баш түбәләре "шомара" башлавын күреп: "Алла, чынлап та бар бугай син!", — дип, шигырь арты шигырьләр язды егет. Мәгәр яшертен генә иҗат газапларында янып, дөньяга "тудырган" ул шигырьләрне бер генә газет-журнал да бастырып чыгарырга теләмәде. Чөнки шул "сөрсегән" редакцияләрдә утыручы пеләш башлы мөхәррирләр үзләре дә "пеләш" шигырьләр язарга гына остарып беткәнлектән, ничек итеп инде алар Илвирның "бөдрә" шигырьләрен бастырып чыгарсыннар, ди! Бит яшь шагыйрьнең ул самими шигырьләрендә ачыктан-ачык Алланы олылау, аңа табыну бар иде!

Илвирны инде абыйлары да, апасы да "Октябрь"гә, "КПСС"ка һәм "Комсомол"га мактау шигырьләре язып карарга өндиләр, "шунсыз син шигъриятә сазаган кыз сыман булып калачаксың", дип тә өстәп җибәргәлиләр иде әле.

Менә шулай итеп, тәки сындырды бу каһәр суккан кыргый җәмгыять Илвирны! һәм егет, җиңнәрен сызганып, мәрмәр потларга табынып яшәгән денсезләр илендә денсез шигырьләр язып бастырырга тотынды! Бу эштә ана бигрәк тә сабакташы Сөләй Акт дигән ярым сукбай-эчкече шагыйрь үтә ярдәм итте. Менә шул Сөләй Акт бер тапкыр Илвир Чулманскийга әйтте:

— Син, дустым, ак интеллигент булырга омтыласың! Ләкин шуны бел: даһи юлбашчыбыз төзегән җәмгыятьтә ак интеллигентлыкка урын һичкайчан булмаячак! Чөнки безнең

гербыбызда интеллигентлык билгесе —- каләм сурәте юк! Шулай булгач, мин университетта укымыйча да, ягъни "урак белән чүкеч"не "эшкә җигеп" тә синнән шәбрәк шигырьләр язып бастырачакмын әле! И, шулай итеп, мин бай, җитеш тормышта яшәячәкмен! Ә син?..

"Мин дә юкка чыкмаячакмын! Әнә, Йосыф Гали дигән татар язучысы, "кып-кызыл" романнар иҗат итеп маташмаса да, начар яшәми кебек! Татар халкы арасында үзен белмәгән кеше юк!"

Гәрчә шулайрак уйласа да, университетка кереп укый башлагач һәм кайбер "пеләш" укытучыларның, галимнәрнең "пеләш" лекцияләрен тынлап утырырга керешкәч, Илвир үзе дә тәмам "пеләшләнеп" китә язды. Чөнки ул, йөзләгән-меңләгән студентлар шикелле үк, бәлышәвикләр остазы җитәкчелегендә "төзелгән" канэчкеч дәүләт машинасының корыч көпчәкләрендәге гап-гади бер шөреп кенә иде бит! Ә аннары инде, илдә "үзгәртеп кору" дигән хәтәр-хәтәр дулкыннар купты да, Илвирны да йомычка сыман бөтерә-бөтерә, әллә кая алып кереп китте...

## I

Көннәрнең берендә Илвир Чулманскийга әтисеннән хат килеп төште.

*"...Соңгы хатыңда, бу арада кәефем юк, авырыбрак торам, әллә салкын тиюдәнме, бәлки, иҗат кризисы башланудандыр — белмим, икесе дә бардыр, ахры, дип язган идең. Без әнкәң белән бик кайгырыштык, төнозын күзгә йокы кермәде, таң атканчы сөйләшеп чыктык. Чөнки иҗатта күңел төшенкелеге башландымы, беттем, юкка чыктым, дигән сүз ич ул. Әмма син, улым, заманабыз гаҗәп авыр булса да..."*

Шушы урында Илвир әтисен күз алдына китерде... Ибраһим абый, сугышта яраланган аягының сызлавын басарга теләгәндәй, таза тешләрен кысып әйтә торган иде бит чабата каш Генсек турында: "Эчә-эчә шешенеп беткән инде бу! И-и, илебезне дә тоташлый алкоголик итәргә маташа, кабахәт!"

Илвир әле ул чакта политбюро әгъзаларына, кемдер Аллага табынгандай, мөкиббән иде. Ә Генсекның исә, авызын чапылдатып һәм ияген чак кына чалшайтып, ниндидер юбилейлар уңаеннан, кемнәрдер язган сүзләрне көчкә-көчкә генә укып чыгуы — даһилык билгесе шикелле булып тоела иде. Әйе, Алтын йолдыз, егермеләп Ленин һәм башка орденнарны тикмәгә генә бирмәсләр шул! Тагын әле ул оста язучы да, Ленин премияләре лауреаты да, маршал да һәм Югары Совет президиумы рәисе дә!

Илвирны тыңлагач, Ибраһим абый ул чакны сүрән генә итеп әйтеп куйды: "Пләмәнни үгез ул, Генсек! Вәт, кем ул..."

Шулчакта Илвир, берәрсе тыңлап тормыймы икән, дигән шикелле, кыюсыз гына як-ягына каранып алган иде... Аннары, ниһаять, Горбачев властька килгәч, егетебез әтисенең хаклы булуына иман китерде...

Яшь шагыйрь хатны укуын дәвам итте... *"бу афәткә бирешмәгәнсең икән, тагын да тырышыбрак иҗатка тотынгансың икән! Без моңа бик сөендек. Аннары, безгә шунысы да мәгълүм булды: син гәзиттә эшләргә калгансың икән, сиңа әлеге иске йортта булса да бер бүлмәле фатир да биреп куйганнар икән... Өйләнә калсаң, фатирның зурысын, биек йорттагысын да бирәчәкләр, ди, имеш.*

*Чынлап та, улым, сиңа өйләнергә вакыт. Ләкин, өйләнәм дип, әллә нинди кызларга күз атып йөрмә... — Илвир университетта укыганда күргән һәм чәчләр үрә торырлык "хикмәтләре"булуын ишеткән "интер" һәм "блат"лы кызларның кайберләрең күз алдына китереп, чак кына уйланып торды да, янә укуын дәвам итте... — үзебезнең янга гына кайт! Без сиңа, хак Тәгалә язса, Кече Көмеш Елга авылында яшәүче Гөлбикә апа кызы Гөлсылуны димләмәкче булабыз.*

*Ә Кече Көмеш Елга безгә ерак түгел! Мондагы да, андагы да — барысы да күз алдында, кемнең кемлеген шәп беләбез, сиңа начар кыз димләмәбез."*

Илвир әтисенең элегрәк киңәш итеп әйткән сүзләрен хәтеренә төшерде: "Улым, бәхетле яшисең килсә, хатының үзең шикелле университетта укыган булмасын! Менә мин, азмы-күпме, техникум тәмамлаган кеше, ә әниең, үзең дә беләсен инде, җиде генә класс бетергән, и шулай да начар яшәмибез һәм киләчәктә дә әйбәт кенә гомер итәчәкбез, бергә-бергә, Алла боерса!"

Илвир көлемсерәп куйды, тагын хат укуын дәвам итте.

*"Хатны алуга ук, җавап язып сал. Вакытың булса, бәлки, үзең дә кайтып китәрсең әле, кызны да күреп китәр идең берочтан!"*

Яшь шагыйрь "Гөлсылу" дигән сүз астына кызыл белән кат-кат сызды да, хат даими күзгә чалынып торсын өчен өстәлгә куйды һәм кайбер мәсьәләдә атасына каршы килеп, ишекле-түрле йөренә башлады.

Әйе, Гөлсылу ун гына класс белемле! Әйе, Гөлсылу авылда сыер савучы гына булып эшли! Әйе, ул — теге чакта Илвирны кыяр урларга әйдәгән Гөлмирәнең сеңлесе! Ә Гөлмирә белән Илвир унынчы сыйныфны бергә тәмамлады. Болай ипле кыз иде бугай ул... Аның сеңлесе дә юньсез булмаска тиеш!

Шулай, тәмәке арты тәмәке тартып уйлана торгач, егет әтисе белән килешергә мәҗбүр булды, һәм көннәрнең берендә тотты да авылга кайтып китте! Ә Илвирның кайтуын ата белән ана дүрт күз белән, зарыгып көтәләр иде инде. Әле иртәнчәк кенә Фәүзия түти:

— И-и, кычыта да соң борыным! Җөмәләндерә генә инде менә, җөмәләндерә генә! — дип, сөенә-сөенә улы кайтырга юрап куйган иде. Ана каршы Ибраһим абзый да:

— Әй, сул күзем тарта, карчык, әй, сиңа әйтәм... Сул күз тартса, чынлап та сөенечкә була ул! — дип, елмаеп, теле белән борчак атып алды.

Менә көткән өметләре акланды да инде: каршыларында кибәндәй гәүдәсен төз тотып, сөекле уллары, югары белемле яшь шагыйрь комсомолец Илвир Чулманский басып тора!

Коммунист Ибраһим абзыйның тап-такыр итеп кырылган зур башында кызыл төстәге татар түбәтәе. Йөзе, нигәдер, җитди. Тирән утырган коңгырт күзләре борчулы һәм сагышлы.

Бер генә фиркадә дә әгъза булып тормаучы Фәүзия түти озын итәкле күлмәк кигән, алъяпкыч япкан, керәч тәлинкәләргә кайнар аш бүлә. Ул әле сүзгә катышмый, тыңлый гына һәм шул ук вакытта аның да алсуланып киткән тулы, түгәрәк йөзендә борчылу төсмерләр шәйләнә...

Ибраһим абзый, гадәттәгечә, ашын ялт кына ашап бетерде дә, зур гына ит кисәген авызына кабып, таза тешләре белән чәйнәгән арада:

— Ничек уйлыйсың, улым? Башта кызны күреп китәргә, аннары өйләнергәме?.. — дип сорады.

Яшь шагыйрь үзенең ит кисәген бәләкәй пыяла савыттагы тозга тидереп алгач:

— Шулайрак, әти! Ошаса... — дип җавап кайтарды.

Һәммәсе дә ашыкмыйча, кабаланмыйча гына чәй эчәргә керештеләр.

— Ошар! Ошар! Тугыз бала табып үстергән мулла Гөлбикәсенең кызы, диләр аны.

Илвир эченнән генә елмаеп куйды һәм кичке сый-нигъмәт өчен рәхмәт әйтеп, урыныннан купты.

— Мин дә әтиең әйткәнчә уйлыйм, улым, — диде, ниһаять, биспартини әни кеше җиңел сулыш алып.

Илвир Чулманский, бусында инде ачыктан-ачык елмаеп, урамга чыгып китте. Ул университетта укыганда чал чәчле бер профессорның: "Әдәбият өч киттан тора: фикер, метафора, деталь!" — дигән хикмәтле сүзләре турында уйлый-уйлый Кече Көмеш Елгага килде. Кичке якта кара кыялар арасында торучы ак пароходны хәтерләткән клубка таба юнәлде шагыйрь. Яңа клуб янын хәйран зур бакча иткәннәр икән. Тимер челтәр белән әйләндереп алганнар да, аны зәңгәргә буяганнар. Ә тирә-юньдә төрле-төрле агачлар, күпчелеге юкә бугай. Шунысы кызык: бу агачларны хәзер яңа өйләнешүчеләр утырта икән!

Илвир Чулманский асфальт җәйгән юлга керүгә таба борылгач, биек таш болдырда яшь әтәчләр сыман "кызу канлы" бер өер егет күренде. Егетләрнең күпчелеге Илвирны шундук танып алды. Шатланып сәлам алышу һәм канатланып күрешүләр китте.

Илвир дулкынлануыннан җиңелче генә кызарып, ишекне ачканда ук йөзгә эссесе бөркелеп торган клубка керде. Аннары уртада дәртле вальска аккошлар сыман җиңелчә генә бөтерелүче нәзек билле кызларны ымсынып күзәтергә кереште. Кызлар да, үз чиратларында, романтик табигатьләрендәге үтә дә нечкә хискә бирелеп, Илвир ягына озын кара керфекләрен сирпештергәләп, сөйләшергә, пышылдашырга тотындылар.

Айдай йөзле чибәр-чибәр кызларның күпчелеге, әлбәттә, Илвирга таныш түгел иде. Илвир белгән "Җанкай-җанаш"ларның инде байтагы кияүдә булмыйча кайда булсын соң?! Ә болар — әллә кайдан күренеп тора — әле яңа гына буй җиткергән сылукайлар!

Илвир Гөлсылуны да үз янәшәсендә басып, сызгыра-сызгыра кызларга "көч" өстәргә маташучы, ике алтын коронка куйдырган таза гына егеттән сорап белде.

Баксаң, урта буйлы, алсу йөзле, ак тәнле, йомры гына кыз булып чыкты ул — нәкъ менә Гөлмирә шикелле! Башында аның зәңгәр косынка, өстендә кыска җиңле, чәчәкләп-чуклап чигелгән яшел джемпер. Тездән түбән кара итәге үзенә килешле булып, туфлиләре дә кара, лаклы иде. "Ай-һай, киенә белә икән үзе, чукынчык!" — дип уйлады Илвир Гөлмирә сабакташының сеңлесе турында.

Егет янә игътибар итте: Гөлсылуның күкрәкләре мул, аяклары — ак булмасалар да — төз. Мәгәр шулай да кызның бер ягы ошамады: ул егет ягына ялгышып кына да карап бакмады! Әйтерсең, Илвир Чулманский дигән шагыйрь егет аның өчен дөньяда да юк...

"Яра-а-ар...", — дип уйлады күрше авылның горур егете.

Шул мәлне баянчы егет бию көенә күчте. Кызлар, бильярд шарлары сыман як-якка чәчелеп, урыннарына таралыштылар. Ә Гөлсылу — кыю да икән үзе! — гармунчы каршына басып биергә кереште.

Кечкенә-кечкенә түгәрәкләр ясап, бөтерелә-бөтерелә шактый гына биегәч һәм клубтагы барча кешене дә үзенә караткач, ул кинәт гармунчыга арка белән борылып, йөзәрләгән күз алдында — ышансаң ышан, ышанмасаң юк! — Илвирга таба йөзеп китте. Әйе, әйе, йөзеп! Йөгереп түгел!

Ә егет мондый хәл булыр дип һич тә көтмәгән иде! Менә сиңа тәкәббер кыз! Шулай да егет каушап төшмәде, үзен тиз кулга алды һәм канатланып Гөлсылу каршына атылды. Идәннәрне тыпыр-тыпыр китереп, дәртләнеп, мавыгып, озак биеде ул. Аның тирәсендә күбәләк шикелле очынып Гөлсылу биеде, Гөлсылу тирәсендә — Илвир!

Бу кичне Илвир, соң булуга да карамастан, Гөлсылуны өйләренә тикле озата барды. Капка төбендә бер-берсеннән аерыла алмыйча шактый гына сөйләшеп тордылар әле.

Аннары Илвир, атна саен диярлек, авылга — Гөлсылуы янына кайткалап йөри башлады...

Туйны алар зурдан кубып үткәрделәр.

Туйга хатынын һәм балдызын ияртеп Ризван Мөштәриеч тә килде. Ризван Мөштәриечнең хатыны Гөлсылуларга чыбык очы гына булса да туган тиешле икән. Илвирның Ризван Мөштәриечне күргәләгәне генә бар, якыннан танып белми иде. Егет Ризван Мөштәриеч җитәкләгән газетта эшләми иде ул чакта. Әйе, Ризван Мөштәриеч — зәңгәр күзле, зур пеләш башлы, кып-кызыл юан муенлы, киң күкрәкле, уртачадан шактый калку буйлы. Шулар янына югары педагог белемен һәм мөхәррир дәрәҗәсе белән җор телен дә өстәп куйсаң — кем генә битараф булыр икән аңа! Мәгәр Ризван Мөштәриеч кимчелекле дә: аның сул күзе сиңа текәлсә, уңы түшәмгә карый! Хәер, бу кимчелек Ризван Мөштәриечнең аттай гәүдәсе, хәрәкәтчәнлеге һәм үткен теллеге сәбәпле, үзен бик артык сиздерми. Хәтта бу аңа килешә дә бугай.

Ә Илвир мөхәррирне бигрәк тә балдызын алып килгәне өчен яратты. Дөрес, аның үз кызы да чибәр. Ә балдызы-ы!.. Илвирны (Илвирны гынамы икән әле) бер күрүдә үк таң калдырды. Ул аңа йөрәгендә йөрткән һәм гомер буе йөртәчәк беренче мәхәббәтен хәтерләтте. Кем белә, бәлки Илвирның ул "беренче мәхәббәт" дигәне менә шушы кыз ук түгелме икән әле?

Тәнәфескә чыкканда, Ризван Мөштәриеч балдызын Илвир белән Гөлсылу янына алып килде.

— Менә, Резеда (ах, матур исем!), таныш бул, бу — яшь шагыйрь Илвир Чулманский абыең булыр!

Кыз сабый бала сыман садә һәм эчкерсез елмаеп, Илвирга ак нәфис кулын сузды һәм энҗедәй ак тешләрен елтыратып:

— Исәнмесез... — диде.

— Сезнең белән танышуыма мин бик шатмын... — диде яшь шагыйрь кызның кайнар кул җылысыннан алсу күлмәк эчендәге сылу тәннең дә уттай кайнар булуын сизгән сыман чак кына кызара төшеп. Кызның чия төсендәге кызыл ирене читенә дә елмаю кунды һәм ул җете, кара чәч толымнарының озынлыгын, яшькелт якут таштан эшләнгән колак алкаларының гаҗәеп шәп булуын күрсәтергә теләгәндәй, Гөлсылуга карап, Илвирга яны белән борылды.

— Исәнме, туганым, матурым! Котлы булсын туйларыгыз! — дип гөлдерәде.

Гөлсылу, олы кабартма сыман күпереп торган битләрен кызартып, әллә каушаудан, әллә белеме-мәдәнияты җитмәүдән, Резеданың нәфис кулын бик тупас рәвештә үзенә таба тартып алып кысты.

— И-и... минем нинди... туганым да бар икән ич! Менә әйбә-әт... — дип сөйләнде ул.

Резеда исә елмайган килеш кенә янә бер мәртәбә күзен

тутырып Илвирга карап алды да җизнәсенә ияреп, апасы янына китеп барды.

Аһ, ошамады, бигрәк тә ошамады Гөлсылуга Резеданың әнә шулай күзен тутырып Илвирга каравы... Бу карашның төбендә берәр этлек яшеренеп ятмыймы икән?! Резеда Гөлсылудан әнә бит ничаклы чибәр! И-и, кая инде Гөлсылуга бизәнү-төзәнү ягыннан Резеда белән ярышу, Резеда шикелле "мәдәниятлы" булу... Юк, юк, Резеда тикмәгә генә өздереп карамагандыр Илвирга, монда ни дә булса бар!

Шуннан башланды Гөлсылуның Илвир өчен хафаланып өзгәләнүләре, кайгырып пошынулары, хәсрәткә батулары... Шуннан башланды Гөлсылуның Илвир яныннан бер адым да читкә китмичә, Илвирының авызына гына төбәлеп, Илвирының күзенә генә карап торулары. Ә Резеда, бәйсез кыз, Гөлсылуның йөрәгендә нинди утлар кабынганын, күңелендә нинди зилзиләләр котырына башлаганын бөтенләй үк сизмәде дә диярлек. Ул гүя Илвирны Гөлсылу кулыннан тартып алыр өчен бөтен тырышлыгын эшкә җикте, бар булган мөмкинлектән файдаланып калырга омтылды шикелле. Әйтик, Гөлсылу каршында, туйдагы бар халык күз алдында алар икәү кара-каршы басып, туйганчы, күңелләре булганчы җырладылармы?! Парлашып бии-бии "ах" итә яздылармы?! Түр башында урыннары янәшә туры килеп, әллә ниләр, әллә ниләр сөйләшеп утырдылармы?! һәм бөтен туй барышында Резеда Илвирга карап егерме ике тапкыр көлде, утыз сигез мәртәбә елмайды!

"Яра-ар, — дип, шартларга җитешеп уйлады Гөлсылу, — туй гына үтсен әле, мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтермен! Менә шулчакта мине ничек итеп яратырга кирәклегенә төшенерсең! һәм шуннан соң бүтән бер генә кызга да карамассың! Әйе, кызык итәм әле мин сине!"

Илвир, әлбәттә, Гөлсылуның күңелендә үзенә карата мәкерле план пешеп өлгергәнен башына да китереп карамады. Хәер, аның бу турыда уйларга вакыты да булмады. Ул бөркет булып кыядан күтәрелде, тургай булып бик биектән атылды, сандугач булып сайрады... Ул шарлавыктагы сулар шикелле кайнады, орчык кебек бөтерелде, коньяк җиледәй исте... Ул өйдә генә торып кала алмады, урамга чыгып китте, урамнан карлы кырларга, бәсле урманнарга... Мәгәр ул кырларга, урманнарга сыя алмады, галәмгә үк менеп китте, үзе артыннан Резеданы да ияртте...

Илвир Чулманский, туйдан яшьләр таралгач, әти-әнисе кунарга күршеләргә киткәч һәм идәнгә Гөлсылуы калын итеп җәйгән урынга килеп, йомшак юрган астына кергәч кенә, галәмнән әйләнеп кайтты... Үзе кайтты, ә Резеда — юк! Берәр егет белән шунда торып калды, ахры.

— Сиңа әйтәм.

— Нәрсә? Миңа орынма!

— Орындырмаслык булгач, нигә кияүгә чыктың син?

— Көндез дөньяңны оныткан идең, күзеңә ак-кара күренми иде, хәзер мин кирәк булдыммыни?!

— Йә, йә, кәҗәләнмә... борыл миңа таба.

— Юк, борылмыйм!

— Көч кулланганны көтәсеңме?

Гөлсылу кинәт сикереп торды да, киенергә итә башлады.

— Нишлисең? Кая бармакчы буласың?

— Китәм... Әниләргә!

Илвир хатынына ташланды һәм аны күтәреп урынга алып килеп салды. Шундук каты итеп күкрәгенә кысты. Үпте.

— Тиле! Аһ, тиле! Шулай ярыймыни? — дип кайнарланып пышылдады яшь ир.

Гөлсылу карышты... Илвирны күкрәге өстеннән этеп төшерергә теләде, мәгәр булдыра алмады. Хәер, ул моңа чынлап торып керешмәде дә шикелле. Ул бит юри генә, Илвирны төнәтү өчен, икенче кызларга карамасын өчен генә карышып маташкан була. Чынлыкта исә, ул бөтен барлыгы белән, җаны-тәне белән Илвирны тели... Аның озак-озак иркәләнәсе, төн буе, таң атканчы күкрәккә күкрәк куеп ятасы килә. Бит ул моңа хокуклы! Һәм бу хокукны аның кулыннан берәү дә алмаячак, алырга батырчылык итмәячәк әле. Хәтта Резеда да!

Резеда исенә төшкәч, Гөлсылу тагын нәфрәтләнде һәм... икенче ягына борылып ятмакчы булды. Мәгәр Илвир хатынын шундый итеп суырып үпте ки, Гөлсылу бүтән инде карыша алмыйча, иренең иркенә бирелеп, тынып калды...

Шулай үтте аларның туйдан соң беренче төннәре. Ләкин барыбер Гөлсылу Резеда туганының Илвирга карап кына көлүләрен, мәгънәле итеп кенә елмаюларын оныта алмаячак инде! Болар һәммәсе дә, мөмкинлек туу белән, ирдән үч алырга сәбәп булачак әле! Аннары туйдагы яшь-җилкенчәк арасында чибәр генә, шаян гына бер егет тә бар иде. Шул егет исә, ни өчендер гел, туйның йөзек кашы булган Гөлсылуга гына төбәлеп, Гөлсылуга гына елмаеп утырды шикелле.

Бу хәлләргә инде берничә ел вакыт үтте...

## II

...Яшь хатын бишенче катта ике пассажирын калдырды, аннары алтынчыда, җиденчедә, сигезенчедә дә тукталыш ясады, әмма чем кара күзле берәү һаман лифттан төшәргә ашыкмады. Кем соң бу, кая барырга итә: врачмы, авырумы, әллә авыру-фәлән янына килүчеме? Үзе болай таныш та шикелле... Әллә...

Ниһаять, яшь хатынның хәвефләнүен, шомлануын сизгәндәй, әлеге кеше әйтеп куйды:

Мин сезне кайдадыр күргәнем бар кебек, чынлап та... Тик

менә исемә генә төшерә алмыйм.

— Ә мин сезне белмим шул! Сез үзегез кем буласыз соң?

— Хәтеремә төште, шайтан алгыры! Сез бит — Гөлмирәнең сеңлесе, ә Илвир Чулманскийның иптәше, Гөлсылу буласыз, иеме?! Яшь хатын җиңелче генә кызарып куйды. И, бу кешенең аны белүеннән белмәве әйбәтрәк буласы иде дә, хәзер бернишләп булмый инде. Мондый чакта: кеше үз күләгәсеннән качып котыла алмый, диләрме әле?!

— Әйе, мин Гөлмирә апаның сеңлесе, ә Илвир Чулманский дигән яшь шагыйрьнең хатыны — Гөлсылу булам! Ә сез мине каян беләсез? Сез соң үзегез кем буласыз?

— Мин Көмеш Елганыкы. Илвир белән бергә укыдым, — сабакташлар, ягъни... Кара, монда телефон да, радио да бар икән! Монда магнитофон да алып килеп җырлатырга була, ахры?

— И, шулаймыни и, Илвирның сабакташымыни — и әле сиин! Исемең ничек соң?

— Сөләй Акт, — кыскартып әйткәндә: Сөләйман Актуганов, ягъни.

— Кы-зы-ык... Монда ничек килеп чыгарга иттең соң әле?

— Аның тарихы озын инде, Гөлсылу... Мин тугызынчы катта, беренче блокта ятам... Кич белән яныңа килеп чыгармын әле, сөйләрмен... Бүген биредә була торгансыңдыр ич әле?

— Әйе. Мин бер тәүлек эшлим, өч тәүлек ял итәм. Аннары монда магнитофон уйнатырга да була!

— Аh, әйбәт икән алайса!

Сүзендә торды Сөләй Акт. Сәгать тугыз тулып унынчыга киткән иде, Гөлсылу лифт янәшәсендәге кысынкы гына бүлмәдә чәй эчеп утыра иде: ишек шакыдылар.

— Керегез! — диде Гөлсылу, гадәттәгечә коры гына итеп. Ишектә чит илдә эшләнгән магнитофон күтәргән, уртачадан чак кына озынрак, томырылып карый торган коңгырт күзле, кыска коңгырт чәчле ир-егет күренде.

—Тәмле булсын чәйләрегез, — диде Сөләй Акт, пижамасының кесәсенә сул кулын тыккан көе, башын әле тегендә, әле монда боргалап, бүлмә белән танышып.

— Рәхмәт! — диде Гөлсылу, елмаеп. Аннары Сөләйманның өйләнгәнме, әллә буйдакмы икәнлеген белергә теләп: — Син өйләнгәнме соң әле, юкмы? — дип, җитезләнә төшеп сорады.

— Өлгермәдем шул әле, вакыт җитми, — дигән булды Сөләй Акт, көлемсерәп. Аннары "Очкын" дигән газетны кулына алып ачып карады да сүзне икенче якка борып җибәрде:

— Менә бу газетның баш мөхәррирен беләм бит мин, Ризван Мөштәриеч дигән кешене... ул яшь чакта минем әни белән йөргән... минем әнидә аның фотосурәте дә саклана әле!

Минем ирем Илвир Чулманский шул газетта, шушы кеше кулы астында эшли инде, — диде Гөлсылу, шулай ук, тавышына горурлану төсмерләре чыгарып. — Аннары шунысы да бар:

— Рәхмәт! — диде Гөлсылу, елмаеп. Аннары Сөләйманның өйләнгәнме, әллә буйдакмы икәнлеген белергә теләп: — Син өйләнгәнме соң әле, юкмы? — дип, җитезләнә төшеп сорады.

— Өлгермәдем шул әле, вакыт җитми, — дигән булды Сөләй Акт, көлемсерәп. Аннары "Очкын" дигән газетны кулына алып ачып карады да сүзне икенче якка борып җибәрде:

— Менә бу газетның баш мөхәррирен беләм бит мин, Ризван Мөштәриеч дигән кешене... ул яшь чакта минем әни белән йөргән... минем әнидә аның фотосурәте дә саклана әле!

— Минем ирем Илвир Чулманский шул газетта, шушы кеше кулы астында эшли инде, — диде Гөлсылу, шулай ук, тавышына горурлану төсмерләре чыгарып. — Аннары шунысы да бар: Ризван Мөштәриевич безгә әни ягыннан туган тиешле...

— Алай булгач, ник үзең шунда, газетта эшләмисең! — дип гаҗәпләнеп сорап куйды Сөләй Акт. — Монда дару исләренә карлыгып ятканчы, анда әйбәтрәк булыр иде, минемчә.

— Әйбәтрәк булыр иде дә бит... Мин... биредә эшләвем белән беррәттән дәваланам да лабаса! — Аннары Гөлсылу, Сөләй Актның алтын чылбырлы "Мерседес" дигән сәгатенә күзе төшеп, әйтеп куйды:

— Әйе, авылыгызда элек тә байлар саналдыгыз сез... Әтиең әле хәзер дә хисапчы булып эшлидер, иеме?!

Сөләй Акт тәрәзә аша урман тарафына караган көе уң аягы белән сул аягын кашый-кашый:

— Эш-ли-и! — диде.

— Элек эчә иде синең атаң, хәзер эчмидер инде... Горбачев абзый кайбер ирләрне эчүдән биздереп бетерде бугай, ә?! — дип, Гөлсылу сынап, иренең элеккеге шәриктәшенә карап куйды.

— Молодец ул минем әти! — диде Сөләй Акт, көлемсерәп. — Элек кеше кесәсен сыгып эчә иде, хәзер исә, кеше җелеген суырып эчә!

Гөлсылу дерт итеп куйды. Әйе, дөрес сүзгә җавап юк шул Эндәшмәде хатын.

Сөләй Акт сәгатенә карады да, кинәт кенә ишекне тартып ачты; чыгып китәр алдыннан әйтте:

— Синең нидән дәваланганыңны беләм мин, Гөлсылу! Синең балаң юк! Ә үземнең авыруга килгәндә, өч көннән әйтермен сөй- ләрмен... Хәзер менә магнитофонны калдырып торам, вата күрмә, яме! Сау бул!

— И-и, магнитофоның өчен рәхмәт инде, Сөләйман! Юк, юк, ватмам мин аны... и-и, ватаммы соң инде... — дип, кояштай балкып калды яшь хатын.

Дүрт көн үтүгә, нәкъ кичке тугызда Сөләй Акт "Монтана" дигән фирменный киемнәрдән, тәмле хушбуй исе чыгарып, Гөлсылу каршына килеп тә басты. Яшь хатын нигәдер ямансулап тәрәзә аша каядыр карап тора иде. Сөләй Акт аңа "Сникерс" дигән шоколадлы батон бирде дә, кызу-кызу гына сөйли

башлады. Ә Гөлсылу исә, шоколадлы ят батонның тәмен ләззәтләнеп татый-татый, кулына затлы кәнфит эләгүенә канәгать калып, Сөләй Актның хикәятен теләр-теләмәс кенә тыңларга кереште...

Теләр-теләмәс кенә дигәннән... Бер "тәти апа" ирләр турында: "Акчаларын гына яратам мин адарның!" — дигән иде.

... И-и, кара инде син Сөләй Актның тыкылдавын:теленә шайтан төкергәнмени...

— ...Шуннан,Гөлмирә мине ташлагач, — диде егет коңгырт күзләрен хәйләкәр генә елтыратып һәм пыяла ярчыклары өстенә шап итеп баскандай, бер урында тик тора алмыйча әрле-бирле йөренеп, — армиядән кайттым да туп-туры КАМАЗга юнәлдем...

— Язмышың шундый булгандыр инде...— диде Гөлсылу, авыр сулап.

— Шуннан, шуфир булып эшкә керештем мин, — дип хикәятен дәвам итте Сөләй Акт. — Ай ярым эчендә мин булмаган урын калмады, дисәм дә, һич арттыру булмас, Гөлсылу янашым! — Егет кабалана-каба- лана кесәсеннән затлы сигарет кабы чыгарды. Капны ачты, бер си- гарет алды да, зажигалкасыннан ут элдерде. Хатынга да, әллә шаярып, әллә чынлап, бер сигарет тәкъдим итте.

"Мине кемгә саный икән соң бу? "— дип уйлады Гөлсылу сүрән генә итеп, кирәксенмичә баш селекте. Шунысы гаҗәп иде: бирedә авырулар, врач-фәләннәр күреп, кисәтү ясамаса, ир-аты да, хатын-кызы да төтәтепме төтәтәләр...

Сөләй Акт та төтенне тирән-тирән генә эчкә суырды да, авызыннан, борыныннан бөркелдереп төтен чыгаргач, сүнмәгән-нитмәгән шырпыны чүп савытына таба чирттереп җибәрде. Аннары янә сүз йомгагын сүтәргә тотынды.

— Шулай итеп, Гөлсылу янашым, командировкаларга туктаусыз йөреп, ике ел эчендә бөтен Рәсәйне гизеп чыктым... Мин күрмәгән авыл, мин булмаган кала һәм мин кочмаган милләтләрнең шәп-шәп кызларын санарга өч урынлы сан кирәк булыр иде! Икмәк менә...

Гөлсылу күңеленнән генә иренең сабакташы сөйләгән кайбер хәл-тамашалар белән килешмәскә, бәхәскә керергә теләсә дә, аны бүлдермәде. Беренчедән, Гөлсылу бит Сөләй Актның магнитофонын уйнатып күңел ача. Икенчедән, ул аннан шоколад-батон кабул итеп алды. Өченчедән, хатынга вакытның үтүе кадерлерәк иде... Егет сөйли бирде.

— Шулай, эшләр майлагандай, шома гына барганда, Гөлсылу күз нурым, Мәскәү юлында авариягә юлыктым... Поезд юлын кичеп чыкканда булды ул хәл. Дөрес, миндә чыбык очы хәтле дә гөнаһ юк! Ие, барысына да, теге... "Татра" гаепле. Миннән алда иде шул.

Берзаман тукталды да калды! Ә поезд килә җан-фәрманга чаптырып! Поезд ул — машина түгел, рельсыннан читкә китә

алмый... Шуннан, җаныкаем, Гөлсылу бәгырем, ниндидер серле көч мине кабинадан йолкып алып, әллә кая ыргытып бәрде! Күзләремне ачып җибәрсәм, мине бик күп кеше чолгап алган...

— Аһ, менә бит, ә! — диде Гөлсылу, Сөләй Актка ярарга тырышып.

— Шуннан шул, янашым: "КамАЗ" кәлҗемә булды, ә үземнең күз үткенлеген җуйды... Начальнигым янә "КАМАЗ"га утыртмакчы иде, гаишниклар рөхсәт итмәде. Аннары правамны ук алып калдылар. Шуннан инде мине бирегә дәваланырга җибәрделәр. Ә биредә... җәннәт, иеме, Гөлсылу, бәгырькәем?!

— Белмим шу-у-ул, — диде сипкелле лифтчы хатын. Аннары, бераз уйланып торгач, өстәде, — биредә нинди җәннәт булсын икән, Сөләйман-бөркет?!

— Кемгә ничек бит! Мәсәлән, үрдәккә — көрпә сибелгән ат тизәге дә шоколад! — диде үз-үзенә гаҗәп нык ышанган кыяфәт белән. һәм ясканып урыныннан купты да, лифтка таба килүче яшь сестрага каршы атылды: кара тутлы чибәр шәфкать иясе гүя Сөләй Актны бөтенләй күрми, йомшак иркә тавыш белән лифтчы хатынга эндәште:

— Гөлсылу апа! Мине беренче катка төшереп куй әле, пожалысты...

— Ул... ул... ял итә. Үзем төшерәм, үзем... — дип өтәләнде Сөләй Акт.

— Ә син кем соң? Лифтчымы, авырумы, дигәндәй...

— Ул... Минем якташ! — диде Гөлсылу.

— Ох-ша-ган! — диде дә дәртле кыз ялт кына лифтка таба үтте. Сөләй Акт та өтәләнә-өтәләнә аңа ияреп лифтка керде. Шундук чәкердәшә-чөкердәшә түбән төшеп киттеләр.

Озакламый Гөлсылуның йомры колагына яшьләрнең чикылдашкан тавышлары килеп иреште. Әллә нигә йөрәге дөпелдәп тибеп куйды. Күзен кара урман өстеннән шудырып, ерактагы якты утларга төбәде.

Сөләй Акт тугызынчы катка бер сәгатьтән соң гына әйләнеп менде. Аның түгәрәк йөзе шат, ә авызы колакларына таба ерылып киткән иде.

Ниһаять, көннәрнең берендә, Сөләй Акт Илвир Чулманскийның хатынына әйтте:

— Мине иртәгә больницадан чыгаралар, Гөлсылу янашым... Ә минем биредән беркая да китәсем килми, карлыгачым! Соң инде, ярым-йорты күрә торган күзләр белән кая барып урнашыйм ди мин! Йә әйтеп бир әле, кыңгырау чәчәгем! һә, әйтә алмыйсыңмы? Әйтә алмассың шул! Алайса үзем әйтәм, Гөлсылу аппагым: минем синең янда каласым килә, лифтчы булып!

— Лифтчы булып эшләү өчен... таныклык кирәк бит! — диде Гөлсылу нидер сизенеп, һәм кызарып та китте. — Аның өчен укыйлар, Сөләйман!

— Ә-ә-ә, укыйлар-мы-ни-и!.. — Сөләй Акт елмаеп, бер ханым белән сөйләшеп торган яшь, чибәр шәфкать туташка күз кысты. Аннары Гөлсылуга төбәлеп:

— Ю-у-к, мин алай укып мәшәкатьләнмәячәкмен! Мин... шагыйрь булып кына калачакмын... Илвир сабакташ кебек! — диде.

## III

...Илвир Чулманский күңелсез кыяфәт белән редактор ишеге янындагы эскәмиядә чакырганны көтеп утыра иде.

Каты коңгырт чәчләрен керпе энәседәй итеп артка яткырып тараган, коңгырт күзендә моңсу ут шәүләсе бии.

"Башта — муссон җиле, йөрәктә төнге бушлык..."

Әллә каян гына шушы сүзләр чыга да тора, чыга да тора. Тиктән генә түгелдер инде бу. Чөнки башка бер генә дә образлы фикер килми, күзгә дә шәп детальләр ташланырга ашыкмый... Гүя, "миндә — Маяковский карашы, миндә — Байрон йөрәге", дип кайнарланып шигырьләр дә язмаган ул!

Бүлмәгә көләч йөзле бер ханым керде.

— Ә мин сине дөнья бетереп эзләп йөрим, — диде ул көтмәгәндә генә күптәнге танышын очраткандай сөенеп. — Мөстәкыйльлек яулап алган Республикабызга багышлап язылган җыр көенә таман шигырь кирәк иде бит!

"Беренчедән, сине түгел, сезне, — дип куйды Илвир эченнән генә бөек бер әдип портретына күзе авырткканчы текәлеп. — Икенчедән, кем биргән әле безгә мөстәкыйльлек! СССРмы, әллә РСФСРмы? һи, йөрисең шунда кычытмаган башны кашып!"

— Нәрсә, җаным, заказымны кабул итмисеңмени? Ярый... бүтән шагыйрь табармын мин, хуш!

"Мин дә бүтән музыкант табармын!" — дигәндәй, Илвир композитор ханымны күрмәс өчен йөзен читкә борды. Бу илтифатсызлыкның сәбәбе дә юк түгел иде, әлбәттә... Иртәнчәк кенә Илвир хатыны белән бик яман гына тузынышып алган иде! Яшь ир хатынына әйткән иде:

— РКБдан, лифттан чык, бүтән эш табарсың әле.

— Ни өчен?

— Ошамый миңа синең ул... эшең!

— Беләм, Сөләй Акттан көнлисең син, шуңа шулай дисең?

— Мин үз сүземне әйттем, калганы... синең намусыңда, Гөлсылу!

— Юк, мин РКБдан китә алмыйм әле, Илвир... бит мин анда дәваланам, аңла инде!..

— Бүтән эшкә кергәч дәвалана алмыйсыңмы, бүтән җирдә врачлар юкмы-ы-ы?..

— РКБдагы кебек аппаратлар бүтән бер төштә дә юк, диләр, шуңа китмим мин аннан!

— Хикмәт аппарат-фәләндә генә булса икән, Гөлсылу-у-у!..

— И-и, канымны кыздырдың, чистый... — дип, утка май сипкәндәй, дөрләп кабынды яшь хатын. — Син үзең кем соң? Син... арыш боламыгы, син... бәрәңге кәлҗемәсе! Әнә — булган кешеләр — әниең белән апаң... Атаңнан калган малны үзара бүлешеп бетерделәр дә, йөриләр хәзер кыш көннәрендә Казан урамнары буйлап күкрәкләрен киереп, киенеп-ясанып, театрларга барып, таксиларда гына җилдереп, югары класслы рестораннарда гына тукланып...

— Иөрсеннәр-р-р! — дип, гәрчә эчтән ут төшсә дә, тыштан исә дулкынлануын сиздермәскә теләп, әйтеп куйды Илвир. — Атадан калган мал тиз бетә ул... күрербез — аннары нишләрләр икән?

— Ул мал беткәнче әле безнең яшьлек үтә, ә апаң рәхәтләнеп типтереп кала...

— Аның каравы, минем киләчәк буын өчен иң зур байлыгым — китапларым калачак, белдеңме?! — дип шактый ук көр тавыш белән әйтте яшь шагыйрь.

— Харап инде, эт теле калынлык ике китап чыгарган да, масая... Син менә чын ир булсаң, әниеңнән үзеңә тиешле хәләл акчаңны кайтып сорар идең! Ә бәлки син әниеңнән үзенә тиешле акчаны сорарга ояласындыр?

— Түбән җанлы кешеләрдән акча сорап түбәнлеккә төшмим әле, Гөлсылу...

— Әниең... түбән җанлы кешемени соң синең?

— Әни түгел... апа! Әнием әйбәт минем, ләкин ул апа сүзеннән чыкмый, никтер чыга алмый... Хәер, әнине дә бик мактамыйм, аның да хаталары күп... Әтиемнең гозере буенча мин Казаннан кайтып төшкәндә, әти инде ярым үлек хәлдә иде. Шулчакта әни миңа: сарайларны тирес басты, улым, чистартып чыгар әле, диде. Уйлап кара, Гөлсылу! Әйе, мин моңарчы да кол кебек идем, бөтен авыр эшне каладан кайтып мин эшләп бара идем, ә апа кыл да кыймылдатмый иде, шулай да ул ит-майны, бәрәңгене-фәләнне авылдан минем белән тигез дәрәҗәдә ташый иде.

Ләкин ул чакта әле минем киләчәккә ниндидер ышанычым, өметем бар иде, ә хәзер, әти үлгәч, ни буласы билгеле: мина өй дә, сарай да, бүтән нәрсәләр дә тәтемәячәк, — барысы да әни аша апага күчеп бетәчәк! һәм мин гомеремдә беренче мәртәбә әни сүзен тыңламадым: сарайны тирестән арындырырга чыкмадым, ә инде... әтине күмеп кайткан сәгатьтә, җанымны кая куярга белмичә, ишегалдында киләп сарыл йөргәндә, мин кинәт апаның верандада кемнәргәдер әйткән сүзләрен ишеттем. Болай диде ул: өйне дә сатарбыз инде, мотоциклны да, бензопычкыны да, электр насосын да, агач эшкәртү станогын да, ат сбруйларын, чана белән арбаны да... Тагын бик күп нәрсәләр әйтте әле ул... Мин

шаккаттым, чак кына егылып китмәдем, баганага тотынып калдым. Әйе, моны эшләделәр алар. Дөрес, өйне сатмадылар...

— Әле дә соң түгел, Илвир! Үзеңә тиешле өлешне каерып ал син, ал!..

— Ничек итеп? Суд ашамы?

— Суд ашамы анда, черт ашамы, әллә бугазлапмы...

— Син мине күрәләтә җинаятькә этәрәсең, Гөлсылу...

— Юк, мин сине җинаятькә этәрмим... Үз өлешеңә тигән малны каерып алу ул берничек тә җинаять була алмый...

— Мин юрист белән бу турыда сөйләштем, Гөлсылу... юрист әйтә: атаң васыятьнамә калдырмаган булса — крышка! Чөнки атаң үлгәннән соң бөтен мал әниең кулына күчкән, ә әниең бәгъзе малдан сиңа өлеш чыгарырга таләмәсә, суд пычагым да кыра алмый, бушка вакыт үткәреп маташма, энем, ди.

— Йөр, йөр, Илвир! Кирәкле шаһитнамәне аны юнәтергә була, бик була-а!..

— Ю-ук! Авылга кайтып, шаһитлар эзләп түбәнлеккә төшмим әле, Гөлсылу!..

— Бәрәч, Илвир, нишли башладың син, әллә... ычкынырга итәсеңме? — Яшь хатын озын тырнаклы бармагын чигәсе тирәсендә уйнатып алды. Аннары көлемсерәп өстәде. — Алайга китсә, авылда бит әле интеллигентлар да яши. Алар якларлар сине, шагыйрь кешене!

— Интеллигентлар! дисең инде... һә, интеллигентларның да малайлары бар ич, хатын... кем белә, шуларның берәрсенең малае минем апаның кызына гашыйк булып куйгандыр, бәлки...

— Алайга киткәч, сиңа бу дөньяда яшәп ятарга ничу икән!

— Үзем өчен генә булса — шулай! Ләкин мин халкым өчен яшим, язам, иҗат итәм! Дөрес, шагыйрь — матди яктан ярлы яшәсә дә, рухи яктан гаҗәп бай кеше бит ул! Һәм менә шул байлыкны инде шагыйрь кеше халкына вакытында җиткереп барырга тиеш. Бу — аның төп бурычы, вазифасы!

— Саф-са-та-а! — дип, кычкырып куйды Гөлсылу. — Җитәр, күп алдадыгыз инде, бүтән алдый алмассыз... — Аннары ул, Илвир каршына ук килеп, ике кулы белән нәзек биленә таянып әйтте. — Мокыт син... Әти үлгәндә, янында булып та... сорамагансың?!

— Әйе, шагыйрь булмаган булсам, бәлки сорап карарга батырчылык итәр идем шикелле, әмма шагыйрь булгач — юк! Намусым кушмады...

— Кит... намус... имеш... бу заманда кемдә бар соң ул намус? Әкият сатып торасың шунда... Әмма шуны бел: миңа рәхәт яшәү бүген кирәк, киләчәктә түгел! Булмаган киләчәктә!

— Әйтерсең лә, без икебез, — ике котып кешесе!.. Шулай да соңгы тапкыр әйтәм: мине аңла инде, бәгырем, Гөлсылу! Шигырьләремнән, еллар үткәч, миңа гына түгел, сиңа да җылы киләчәк бит! Сиңа да...

— И-и-ди-от! — дип кычкырып җибәрде Гөлсылу кинәт. — Кит, күз алдымнан югал...

— Кем идиот? Минме! Минме!

— Син! Син!

Менә шулай күңелсез башланган иде бу иртә. Менә хәзер Чулманский иптәш (бәлки, әфәндедер) редактор янына керергә тора.

"Ни өчен чакырды икән? Теге мәкалә өчен түгелме?" — дип уйлады яшь шагыйрь, берничә көн элек кенә мәкаләсенең редактор тарафыннан кире кагылуын хәтеренә төшереп, һәм кызарып китте.

Бит мәкалә яшь һәм башлап язучылар белән эшләүче консультация бюросының җитешсез якларын камчылап, киң аудиториягә исәпләп иҗат ителгән иде. Ул басылып чыккан тәкъдирдә Илвирның яшь һәм башлап язучылар арасында шөһрәте артачагы шиксез иде. Чөнки яшь шагыйрьгә карт язучылар каршында абруй яулап маташу пычагымамы? Картлар бит картая да үлә, ә дөнья яшьләргә кала!

Әмма мондый "камыр батыр" авторларны үз гомерендә күп күргән редактор Илвирның өметен акламады. Аклау гынамы әле сиңа! Ул аның адресына карата зәһәр сүз дә әйтте хәтта. Ишеттегезме? Әллә кайчан түгел, ә Җөмһүриятебез азатлык яулап алган чорда, булачак бөек шагыйрь Илвир Чулманскийны тәнкыйтьләп бит!

Редактор, карт төлке кебек, хәйләкәр дә иде:

— Син, Чулманский дус, мәкаләңне дөрес язгансың, — дип башлады сүзен тыныч һәм җитди тон белән. — Ләкин җөмләләрдә кайбер сүзләрнең урыннарын саксызрак рәвештә буташтырып кына җибәргәнсең. Әйе, әйе, дустым. Син яшь һәм башлап язучыларның үзләрен инициативасызлыкта гаепләп язарга тиеш идең...

Менә бит ул ничек... Болай булгач, кайда монда хаклык? Юк монда хаклык! Моны берничек тә аклап булмый. Ул чаклы башлык булдым дигәч тә, һаман үз карашларын гына алга сөрергә, ә хезмәткәреңнең карашын санга сукмаска аңа кем кушкан? Юк, юк, беркем дә кушмаган һәм кушмас та... Менә Илвир Чулманскийның китабы гына басылып чыксын. Аннары ул, шигъри роман иҗат иткән Вәгыйз Кәли кебек...

Илвир Чулманский, коктейль эчкәндәй ләззәтләнеп, төкереген йотып куйды.

"Аһ! Ул көннәргә дә ерак калмагандыр инде, күп калмагандыр!" һәм шул мәлне яшь шагыйрьнең үткен карашы өстәл өстендәге көзгегә иелеп, бизәнеп утырган кызга төште. Төште дә, аның күз алдына апасы һәм апасының кызы килеп басты. Кыз әнисенә бердәнбер бала булганлыктан, кечкенәдән бик җитешле һәм бик иркә булып үсте. Берничә ел элек кенә, әнисе белән каты гына әрләшкәндә авызы кыегаеп, хастаханәдә ятып чыккач ул тәмам узынды... Илвирның апасына врач ха-

ным әйткән: кызың бик нервылы, аның белән әчеләнешмәскә тырыш, әгәр дә тагын бер мәртәбә авызы кыегайса — тураймаска мөмкин, дигән. Шулай итеп... ана кеше тә- мам кызының колына әверелгән дә куйган! Хәзер ул, бабасы үлгәннән соң, әбисен дә, әнисен дә үз кубызына биетә... Күптән түгел генә аның янына бер урыс егете ияләшкән. Урыс егете килгән чакта кыз әйтә икән әнисенә:

"Слушай, мамочка, бирeдә син булганда безгә неудобно, бар әле, киенеп, ике сәгатькә генә урамга чыгып тор!"

Өстәл янындагы чит-ят кыз, зәңгәр кабаклары астыннан гына сөрмә тарткан керфекләрен сирпеп һәм аннары шундук маңгаен җыерып, шагыйрьгә карады.

— Нәрсә ошыймы? Ошамыймы? — ди сыман иде чит-ят кызның күз карашы.

— Белмим, — диде Илвирныкы.

— Ничек инде белмисең? Шулай белмәскә ярыймыни!

— Җаныңны аңлатканың юк бит әле...

— һи, абый җаным, бәбәкләреңне ачыбрак кара, күзкәйләрең матурлык тойгысыннан мәхрүм түгелдер әле!

— Бу тышкы матурлыгын синең, ул минем өчен диварга ябыштырган обой кебек кенә бит.

— Аңламадым.

— Табигыйлегең юк.

— Әллә анадан тугандай шәрә калып, дүрт аяклап йөрергә кушасыңмы? Алайга китсә, анысын да булдыра алам!

— Бизәнү-төзәнүгә бушка вакыт исраф иткәнче, файдалы эш белән шөгыльләнсәң, мең мәртәбә яхшырак булыр иде, минемчә.

— Мин эш аты түгел, абый! Аннары эш ул — бүре түгел, урманга качмый. Яшь чакта буш вакытны күбрәк уен-көлке, күңел ачугабагышларга кирәк. Ә уен-көлке, күңелача торган урыннарда билгеле инде безсез эш барып чыкмый.

— Алайса, гафу ит.

— Гафу итмим, матур абый, сиңа ясалмалык килешми, табигый булып кал. — һәм кыз зәһәр елан шикелле боргаланып-сыргаланып бүлмәдән чыгып китте.

Илвир янәшәсендә утыручы абыйның йөзендә көлемсерәү билгеләре чагылды... Ул гүя:

— Безнең замандагы тыйнак, акыллы, сабыр кызлар юк иңде алар хәзер, юк! — ди иде.

"Шулай шул, — дип уйлады Илвир баягы кыз белән апасының кызын күз алдында тотып. — Ләкин шулай да киң, якты музейларның мәрмәр залларында, әллә кай дәвердәге алиһәләрнең гүзәллекләренә сокланып, тел чартлатып йөргәндә, бүгенге "алиһәләрне" күрер күзләребез кайда була икән безнең? Әллә кай замандагы роман героиняларының чибәрлекләренә, тапкырлыкларына, кешелелекләренә мөкиббән китеп укып утырганда, бүгенге гүзәл, тәвәккәл һәм кешелекле героиня-

ларыбызны язар каләмнәребез кайда була икән безнең?

— Кешеләр, — дип уйлады яшь шагыйрь, — киләчәккә төбәлеп хыяллансалар, үткәнгә карап офтаналар һәм сокланалар. Ә бүгенге көн кайда?!

— Сезне... редактор чакыра-а!

Илвир күтәрелеп карады. Аның каршында ябык йөзле, гади генә киемле секретарьша басып тора иде. Ул, елмаеп, шагыйрьгә редактор янына керергә кирәклекне кабатлап әйтте.

Чулманский дерт итеп сискәнеп куйды. "Бүгенге менә кайда, редактор ишеге төбендә икән", — дип уйлады ул.

***

Илвир кергәндә, Ризван Мөштәриеч сәркатип алып кергән ниндидер кәгазьләргә тыныч кына кул куеп утыра иде.

Ул чак кына алга иелә төшкән. Пеләш башын бер якка кыңгыр салган. Киң маңгаендагы сырлары элеккечә урыннарында торалар, димәк, борчылырга кирәкми әле, барысы да тәртиптә!

Яшь шагыйрь кычкырып исәнләште һәм редакторның йөз ишарәсен аңлап, өстәл каршындагы урындыкларның берсенә барып утырды.

Бүлмә зур һәм иркен иде. Ишектән редактор өстәленә таба зәңгәр каймалы палас сузылып китә. Сул якта, дивар буенда, китап шкафы тора. Шкафның өске киштәсе Маркс һәм Ленинннан башлап бүгенге дәүләт эшлеклеләренекенә хәтле китап белән шыплап тулган. Урта киштәдә — газет-журналлар. Аскы киштәдә очерк һәм монография китаплары, төрле белешмәләр, брошюралар урын алган... Ә яңа басылып чыккан "Коръән мохтасар" китабы юк. Менә сиңа, мә! Менә сиңа замана редакторы! Болай булса, киләсе елга газетабызның тиражы бик күпкә кимиячәк!

Уң тарафта тәрәзә, тәрәзәдән кышкы елга һәм борынгы шәһәрнең ныгытма диварлары ап-ачык күренеп тора.

Ниһаять, кәгазьләрен кочып, сәркатип хатын чыгып китте... Илвир Чулманский җиңел сулыш алып, монда мин дә бар әле дигәндәй, кыймылдап куйды. Әмма Ризван Мөштәриеч, Чулманскийның баядан

бирле биредә интегеп утыруын күрмәмешкә сабышкан сыман, телефоннан каядыр шалтыратырга тотынды. Аннары, селектор төймәсенә басып, чираттагы санга керәсе материал турында кем беләндер әрепләшеп алды.

— Син миңа нәрсә бирдең? Ә! Каян килгән милли мәсьәлә ул? Юк бездә андый мәсьәлә! Ничек? Рус газеталары язалар да, язалар безне — татарларны сүгеп дисеңме-е? Язсынна-ар... ник шунда, кем әйткәндәй, дөньялары аслы-өсле килеп бетми: төкермибез дә!

— Ни-и бит... Ризван Мөштәриеч...

— Ни-ни... Ниелдәмә: турыдан ярып сөйләш, — ни булды?

— Милләтебезнең язмышы аяныч хәлдә... Сезнең кулдагы мәкаләмдә мин шуны яктыртып, җитәкчеләр алдына олы бер мәсьәлә куймакчы идем!

— Кабатлап әйтәм, иптәш Гарифуллин, безнең җирлектә милли проблема килеп туу куркынычы юк һәм була да алмый! Ә инде бакчалардагы һәм мәктәпләрдәге тел мәсьәләсенә килгәндә... без инде гомер-гомердән интернациональ гаиләләр корып яшәргә җайлашкан халык, шулай булгач, кемнең кайсы телне күңеленә якын тел итеп сайлавы үз иркендә булырга тиеш! Мә, мәкаләңне ал, Гарифуллин! Әгәр аны бастырып чыгарырга исәпләсәң, мин әйткәнчә эшлә... аңладыңмы мине, иптәш Гарифуллин!

Селектор көрсенеп куйды.

— Аңладым, Ризван Мөштәриеч.

Редактор шуннан соң гына Илвирга күтәрелеп карады.

— Ну, Чулманский, ашыйсыз сез минем башны, тәки ашыйсыз, ашарга телисез, — диде ул юри үзен кызгандырып.

Ризван Мөштәриечнең бу сыналган алымы иде. Гадәттә ул үзен кызгандырып башлый да, бераздан, рингтагы боксер шикелле, сүз перчаткалары белән уңлы-суллы тукмарга тотына.

Илвир Чулманский сагайды. Ризван Мөштәриечнең һөҗүмен каршы, алырга хәзерләнде. Редактор озак көттермәде:

— Син... хатынына кул яга башлагансың ич! — диде.

Илвир болай ук булыр дип уйламаган иде, кинәт күз аллары караңгыланды, аяк буыннарының хәле китте, битләренә, колакларына шаулап кан йөгерде.

"Димәк, чаккан икән, — дип уйлады ул кайгылы күз карашын нығытма манарасына төбәп. — Әйткән иде шул. Эшеңә барып җиткәнче үк шалтыратам, белеп торсыннар әле кемлегеңне... Тәки сүзен сүз иткән ләбаса!"

— Иә-ә-ә... — диде редактор ачы көлемсерәп.

Илвир Чулманский берара кайдан һәм нидән башларга белмичә уйланып торды. Мондый чакта, үч иткәндәй, башка да юньле фикерләре килми бит аның...

— Димәк, гаебеңне таныйсың? — дип, яшь шагыйрьнең ачуын тагын да кабарта төште редактор.

"Нинди гаеп? Ни сөйли бу картлач? Күрмәгән, белмәгән "юньсез" хатын сүзенә таянып кына мине пычратырга, кем дип белә икән ул мине?.."

Илвир Чулманский иртәнге бәрелештә үзенең хаклы, хатынының хаксыз булуы турында кыскача гына сөйләп биргәч, Ризван Мөштәриеч ютәлләгән сыман көлеп куйды.

— Менә-менә, аңладым кебек мин сине, Илвир дус! Үзең үк әйтеп бирдең кемлегеңне!

— Көлмәгез, Ризван Мөштәриеч! Мин үземнән көлгән кешене яратмыйм. Хәтта ул редактор булса да...

Ризван Мөштәриеч маңгаена чирткәндәй сискәнеп китте, чырае җитдиләнде, күзенә моңсу төс инде. Пеләш башы да, көмеш бөртекләре сипкәндәй, елтырап куйды... Тирли башлаган иде ахры.

"Ә кем ярата соң үзеннән көлгәнне, — дип уйлады ул. — Берәү дә сөйми үзеннән көлгәнне. Ләкин көлгән өчен түгел, ә көлгәнгә йодрык күтәргән өчен җавапка тартыла кеше!"

Ризван Мөштәриеч күзлеген киеп, календарь битенә нәрсәдер сызгалап алды да, ачулы кыяфәт белән Илвирга эндәште.

— Димәк, үзеннән көлгәнне яратмыйсың инде син, дус, әйеме?

Хәтта ул редактор булса да...

— ???

— Ләкин юкка, — дип дәвам итте редактор. — Үзеннән көлгән шәхесне дә хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк, Илвир дус! Дошманны хөрмәт итсәң, аны буйсындыруы ансатрак. Аннары редактор өстәл тартмасыннан ниндидер кәгазь алып Илвирга сузды.

— Мә, укы!

Яшь шагыйрь кәгазьгә төбәлде. Дәфтәр бите! Анда... язулар! Әйе, бу — редакциягә җибәрелгән хат булган. Хатның почеркы... Сөләй Актныкына охшаш. Чү! Чынлап та бу хатны Сөләй Акт язган ләбаса! Әйе, ул... Тукта! Ниләр язды икән?

Укыган саен Илвирның йөзе караңгыланганнан-караңгылана барды. Ул хатны ертып ташларлык булып ярсыды һәм авыз эченнән генә: "Кабахәт!" — дип куйды.

"...Әллә кем булды. Бик борын чөя. Үз ишләрен санга сукмый. Алай гына да түгел: урын өстендә авырып яткан газиз әнисенең хәлен дә кайтып белгәне юк. Авылга юлны тәмам онытты. Хөрмәтле редакция, сездән үтенеп сорыйбыз, кайтарыгыз әле Илвирны авылга, Фәүзия апаның хәлен белергә..."

— Йә укып чыктыңмы?! Бир хатны монда...

— Бу нине бит Сөләй Акт — минем... сабакташ җибәргән!

— Ә-ә-ә-ә... шулаймыни! Мин аны әле тагын, исем-фамилиясен куймагач, аноним хаттыр, дип йөри идем. Алайса, монда язылганнар дөрес! Иеме? (Илвир Чулманский укучы баладай башын түбән иде.)

— Иеме? Дөресме?

Яшь шагыйрь үзен тиз кулга алды, редакторга туры һәм яндырып карады.

— Сөләй Акт көнче күбәләк... Ул гомер буе миңа каршы булды: уңышларыма — көенде, уңышсызлыкларыма — сөенде... Мина ышанмау — Сезнең үз намусыгызда, Ризван Мөштәриеч!

— Тәк, тәк, тәк... Ие, ие, ие... Әйтеп бетер, әйтеп!

— "Сатира" апакаем әйтеп бирер әле аларны Сезгә: тозлап, борычлап, суганлап һәм сарымсаклап!

— Нәр-сә-ә? — Ризван Мөштәриен кызарып китте һәм аннары, эшнең нидәнлеген аңлап алгач, бераз гына тынычлана төште дә, карашын Илвирның баш түбәсеннән өскә, ишеккә таба юнәлтте. Ә ишек өстендә Тукай портреты эленеп тора иде. Танылган бер рәссам тарафыннан май белән ясалган!

"Шулай да Илвир Чулманский — Тукай түгел инде", — дип уйлады редактор һәм үзе әйтмешли, "гениальный" күзләрен ак беләгендәге "Командир" сәгатенә текәде дә, боеручан тавыш белән:

— Бар әле, Илвир... син миңа хатының Гөлсылуга ни сәбәпле кул ягарга мәҗбүр булуың вә авылга әниеңнең хәлен белергә ни өчен кайтып йөрмәвең турында аңлатма язып керт! — диде.

***

Илвир Чулманский үз бүлмәсенә чыгып, өстәле янына килеп утыргач, "эшне нидән башларга икән?" дип уйга калды. Икенче яктан аны Ризван Мөштәриечнең чиновникларга хас һич аклап булмый торган тәкәбберлеге изә иде. Юкса, инде илне үзгәртеп кору башланганга да ничә ел үтте, ә ул әле һаман үзгәрергә теләми: туң йөрәк! Имеш, мин хатыныма кул күтәрәм! Әйе, күтәргәлим шул кайчакларда... Чөнки хатынның теле озын! Ә ник озайта ул телен? Шуның өчен, чөнки миңа сәмәнне бик аз түлиләр! Димәк, шулай булгач, мин үземне тулы канлы шәхес итеп саный аламмы? Юк, әлбәттә! Юк, юк... Аннары мин әни янына да кайтып йөрмим икән әле! Әйе, бусы да дөрес. Чөнки, әти вафат булган елны бөтен мал, бөтен байлыкны әни тотты да апага бирде. Ә читтә яшәүче абыйлар белән миңа — кукиш! Дөрес, мин үтә мал җанлы түгел, матди җитешлеккә әлләни кызыкмыйм, әмма юклык бугаздан китереп кыскан бүгенге көннәрдә әтидән калган мал бик ярап куяр иде әле. Ә әтидән мал аз калмаган булырга тиеш. Бит безнең әти кырык ел буе тире җыючы булып эшләгән кеше! һәм ул базар икътисадына күчүнең нәрсә икәнен дә белмәгән. Шуңа күрә аның туплаган малы да булгандыр. Бик мөмкин...

Илвир Чулманский, хыялыннан арынып, алдында яткан ак кәгазьгә карады. Аңлатманың бер генә юлын да язмаган иде әле ул һәм аны алдаусыз-йолдаусыз гына язарга мөмкин дә түгел иде, Ә ялган язып, билгеле инде ерак барып булмый, иртәме-соңмы барыбер тотылачаксың! Бәс шулай икән инде, иң шәбе — аңлатманы язмау! Әйе, әйе...

Яшь шагыйрь урыныннан купты, бүлмәсен бикләп, баскычтан төшә башлады. Таныш-белешләренең кайберләре белән исәнләшеп үтте, кайберләре белән күрешеп үк узды.

Менә ул вестибюльдә киенеп урамга чыкты. Шундук аның тын юлларын салкын куырып алды. Радиодан "төнлә кырык градус булачак" дигәннәр иде, дөрескә чыгар, ахры... Илвир,

Ризван Мөштәриечнең соңгы сүзләрен хәтерендә тотып, өйгә кайткач хатыны белән ничегрәк сөйләшергә кирәклеген уйлый-уйлый урам буйлап китте.

Кышның кыска төне сүрелеп, кала өстенә кич кара пәрдәсен корган иде инде... Ләкин урамнар яп-якты. Машиналар, троллейбуслар һәм автобуслар фараларын да яндырмыйча йөриләр. Кая бакма, аллы-гөлле реклама утлары бер янып, бер сүнеп, күңелләрне әллә каян алгысытып, үзләренә чакырып тора. Әйтерсең лә кибетләрнең заллары, киштәләре кирәк-яраклар белән тулып ташкан! һай, кайчан килер икән, кайчан күрербез икән без ул бәхетле заманны?..

Илвир Чулманский элекке елларда кичке шәһәр күренешеннән сокланып, хозурланып кайта иде. Кайту белән үк дәртләнеп, илһамланып иҗатка чума... Ләкин аның бүген бер нәрсәгә дә исе китми. Ул, тормышка кул селтәгән битараф кеше хәлендә атлый торгач, кемгәдер бәрелеп, култыгындагы китабын шапылдатып тротуарга төшерде.

— Әй, өтек, күзең чыктымыни-и!

Илвир дәшүчегә күтәрелеп карады. Ике адымда гына нәзек буен бөкрәйтә төшеп, исерек кыяфәтле бер егет аңа күзен акайтып, ачуланып карап тора иде. Сөләй Актка ошаган иде ул...

Илвир, сабакташ танып алганчы... дип, тиз-тиз китеп барды.

Аның күңелсез халәтен авылдашы очрап тагын да көчәйткән иде. Ул шунда "К" урамындагы ике катлы таш йортның икенче каттагы бүлмәсендә арлы-бирле йөренгән хатынының сипкелле зур йөзен, бүренекедәй мәкерле соры күзен, бер әйткәнгә ун җавап таба торган сугандай әче телен хәтерләп, саран гына елмайды.

"Нәрсә ди әле, Ризван Мөштәриеч! Буйсындырасың килсә, дошманыңны хөрмәт ит, диме? Ярый, мин бу алымны хатынга карата кулланып карыйм әле: җиңеп, кулга алып булмасмы шул кыргыйны!"

Илвир тузып, таушалып беткән баскыч сайгакларын артык шыгырдатмаска тырышып, икенче катка күтәрелде. Гадәттәгечә сак кына кыңгырау төймәсенә кагылды. Шул мизгел аның күңеленә бер-бер артлы тезелеп мондый сүзләр килде:

"Юк, без — җиде ятның явыз баласын бәхетле итү өчен кырык ел тире җыеп эшләмәдек һәм апаны гына бәхетле итү өчен дә...

Без җыйдык аны... бөек максат белән!"

Кинәт ишек ачылып китте. Илвир каршында хатыны — Гөлсылу пәйда булды. Лифтчы!

— Исәнме, карчык! Сагындыңмы мине? Көттеңме? — дип теленә салына башлады яшь шагыйрь.

Гөлсылу, РКБда эшләүче карт марҗа киңәше буенча, күптән түгел генә, шомырттай кара чәчен кистерү сәбәпле, малай сыман булып калган кыяфәт белән бүре күзен тасрайтып Илвирына

текәлеп катты. "Аек кайттыңмы соң син, әллә ике талонга аракы сатып алып эчеп кайттыңмы?" — дигән шикелле...

Илвир хатынының йөзендә тамчы да кимемәгән, киресенчә арта гына барган сипкелләренә текәлеп һәм хатынының: "Сипкелле ул сөйкемле", — дигән сүзләрен аңында яшендәй кабындырып, серле генә итеп елмайды.

— Нәрсә, сагынмадыңмыни? Көтмәдеңмени, карчык?

— Ки-и-ит, — диде Гөлсылу кашларын җыерып. — Кит, килешми... Сүзләрең дә ясалма, үзен дә... Гүпчим...

Унынчыда укыганда, бервакыт Илвирның шигырьләрен кире җибәрделәр. Аңа шигырь техникасын оста үзләштерүе, ләкин әлегә табигыйлек җитешмәү, аларның ясалмарак хискә корылган булулары турында нечкәләп язып җибәргәннәр иде. Гөлсылу моны каяндыр табып укыган да, үзенчәрәк әйтергә остарып китте. Кайвакытта ул кыска гына итеп "фальш" дип тә ычкындыргалый иде.

Тора-бара бу сүз Илвир Чулманскийның дөньяда иң күрә алмаган, иң бәгыренә тигән сүзләрнең берсенә әверелде. Менә шушы сүзне генә әйткән өчен дә, Гөлсылуны "өйрәтергә" мәҗбүр була иде бит ул!

Бүген иртән генә булып алган һәм редакторга барып ирешкән талашның җимеше дә шул каһәр суккан сүздән пешеп өлгергән иде бит инде!

Менә тагын шул ук хәл...

Ишекне ач та: исәнме юк, саумы юк, газиз иренә тот та "фальш" дип әйт!

Илвир Чулманский агарынып килде. Уң кулын кысып күкрәк турысына китерде. Йодрыгын йомарлады.

— Нәрсә дидең? — дип кычкырып җибәрде ул. — Нәрсә дидең, кабатлап әйт әле?

— Фальш, фальш, дидем! Фальш, син менә шул, белдеңме?
Илвир Чулманский акылдан шашар дәрәҗәгә җитте. Аны хәзер

берәү дә, берничек тә тыеп кала алмый иде. Ул җәясеннән ычкынган ук шикелле атылып, йокы бүлмәсенә таба китеп баручы хатынына:

— Кирәгең юк синең миңа, бер тиенгә дә... Талак, талак, талак! — дип илереп-илереп кычкырды.

Гөлсылуның яңагына суктылармыни...

— Каравыл! Каравыл! — дип бүредәй улап җибәрде ул. — Коткарыгыз! Суя... Суя-а-а... — Аннары, аягыннан тапочкасын салып, ире ягына ыргытты да, шул кызулык белән акны-караны ни дип тә белмичә, бүлмәдән чыгып та китте.

— Кая барасың? Кер өйгә! — дип яланөс чыгып акырды Илвир хатыны артыннан.

— Аена өч йөз грамм макарон ашап җан асрый ала торган хатын тап үзеңә?! — һәм Гөлсылу борылып та карамады. Шыгырт-шыгырт басып ишегалдыннан юк булды.

...Менә сиңа кирәксә...

Илвир Чулманский күз ачып күз йомган арада булып узган бу вакыйгадан миңгерәүләнгән хәлдә әйле-шәйле килеп өйгә керде. Нишләргә дә белмичә чигәләрен кысып байтак кына басып торды. Йөрәге сулык-сулык тибә иде. Күңеле сыкрый. Бәгыренең әллә кайсы, әллә кайсы кылларында матәм музыкасы сыман искиткеч бер кайгылы көй чыңлый да чыңлый, чыңлый да чыңлый иде.

Илвирның гүя үкереп-үкереп, үксеп-үксеп елыйсы, тәрәзәләрне урамга ачып шашасы, өзгәләнеп-өзгәләнеп түбәнгә атыласы килде.

Кандагы тиле ярсу, күңелдә пәри туе ясап котырышкан утлы давыллы хисләр, җаннан суырылып чыккан икеләнүле, газаплы авыр тойгылар Илвирны тупас чынбарлыкка кайтарып, аның магний утыдай очкыннар чәчеп, җемелдәп торган нәфис хыялларын көл иттеләр дә ташладылар.

— Менә сиңа кирәксә! — дип ул, янә исе китеп, көрсенеп куйды. Аннары көзгегә текәлеп үз-үзенә аптырап карап торды. — Шулай итеп, Илвир дус, хатынга синең кирәгең беттемени? Шулай итеп, син аның өчен фальшка әйләндеңмени?.. — Шул мизгел Илвирның эче яна, әллә нишли башлады, һәм ул иртәдән бирле тәгам ризык капмаганын исенә төшерде. Әйе, чынлап та, ашказаны буш, ул үтереп-үтереп ашарга сорый иде.

Илвир аш бүлмәсенә керде. Плитә өстендә торган кәстрүлләрне ачып-ачып карады. Мәгәр аларның эчендә судан гайре нәрсә юк иде. Чәйнектә дә су гына! Шкафта да буш пакетлар һәм банкалар гына! Шулай итеп, Илвир Чулманский, аптыраудан гаҗиз калып, нишләргә, кая барып бәрелергә һәм нәрсәгә тотынырга белмичә интегеп торганда, кинәт аның күзенә шифоньер өстендә диварга сөяп куелган тел галиме һәм мәгърифәтче язучы портреты чалынды. Гүя галим мыек астыннан гына көлеп: "Нихәл, социализм баласы?! Коммунизмга таба барып буламы?" — ди төсле иде.

— һм... һм... — диде Илвир һәм чишенмичә-нитмичә карават янына килде дә ларс итеп ауды.

## IV

...Гөлсылу таң атканчы керфек тә какмады диярлек: уйланып, борсаланып чыкты. Ул бөтен гомерен күз алдыннан үткәрде. Аның күп һәм киеренке уйлардан мие катты. Ул сискәнеп, сагаеп башын күтәрде һәм шашмагаем тагын, дип, торып, ян тәрәзәгә килде, кызыл чәчәкле гөлләрне аралап тышка карады. Якты иде. Бу яктылык йокыга чумган төнге шәһәр өстендә тын гына, мыштым гына гүя үз уйларына чумып йөзеп йөргән тулы түгәрәк айдан төшә иде.

Каршыдагы бер катлы кирпеч йортның тәрәзәләре караңгы иде инде.Әмма шулай да, җентекләбрәк карагач, аш бүлмәсенең

сыңар тәрәзәсендә беленер-беленмәс кенә яшькелт ут шәйләнә иде. Ә биредәрәк, ишек янында ике хатын-кыз белән бер ир-ат сөйләшеп тора. Гөлсылу нидер сизенеп өстенә пальтосын алды да, өйалдына чыгып, такта дивар аша тыштагы сөйләшүләргә колак салды.

— Минемчә, чынлап та өйдә түгел бу! Авылларына, әнисе янына кайтып китмәдеме икән?..

— Киттек алайса, Илвирларга барып кунабыз! Марсель: "Хатын өйдә булмаса, Илвир кайнеш фатирына барып куныгыз!" — дигән иде ич.

— Юк, юк, мин анда бармыйм, сезгә дә барырга киңәш итмим, — диде ир-ат тавышы. — Илвирның хатыны усал, әшәке телле икән, әллә ниләр әйтеп, хур итеп бетерер, Алла сакласын!

Шулчакны бер-бер артлы борын сеңгергән һәм бик күп кар шыгырдаган тавышлар ишетелде. Гөлсылуның кинәт шунда ишекне ачып тышка атыласы, "юк, апалар, абый кеше, ялгышасыз, мин явыз хатын түгел, китмәгез, менә минем фатирым, менә монда керегез дә куныгыз", дип әйтәсе килде. Мәгәр ул моны шундук эшли алмады. Аның күңелен ниндидер шик биләде, кулын кемдер тотып торгандай булды. Ә аннары инде тәвәккәлләп урыныннан кузгалганда, Марсель җизни яныннан — санаторийдан кайткан төнге юлчылар ишегалдында гына түгел, урамда да күзгә чалынмыйлар иде. Гөлсылу кинәт юкка чыккан әлеге сәфәрчеләрне кызганып куйды. Юк, ул аларны Илвир исемен телгә алганнары өчен генә җәлләде, ахры. Ләкин аңа ул исемне әйткән апа кешенең кем икәнлеге дә, буй-сыны да, төс-кыяфәте дә кирәк түгел бугай. Аңа тик Илвир дигән исемне ишетү генә тансык булган ич! Әйе, бу — чынлап та дөрес иде. Шул колакка ягымлы сихри исемне бер дә белмәгән, күрмәгән кешеләр авызыннан ишеткәч, "К" урамында ялгыз торып калган ире Гөлсылуга тагын да якынрак, тагын да кадерлерәк булып тоелды.

Яшь хатын өйгә кергәч тә утны кабызып, шкафтан кәгазь-каләм алып, Илвир Чулманскийның исем-шәрифләрен берничә мәртәбә язып карады. Аннары, бу — гаҗәеп тирән мәгънәгә ия исем Шәрифләрнең асылына тулысынча төшенергә теләгәндәй, авыз эченнән генә пышылдап әйтте:

— Ил-ви-р Чу-л-ман-с-ки-й...

Ниһаять, шул исем-шәрифләрне мәңге онытмаячак икәнлегенә, шул исем-шәрифләр аның олы йөрәгенә тормышта бары тик бер генә тапкыр бирелә торган бик кыйммәтле мизгел белән уелып кереп калган икәнлегенә төшенеп, йокларга ятты. Ул елый-елый йокыга китте.

Иртәгесен Гөлсылу йокыдан соңарып һәм кәефсез уянды. Баштарак ул үзенең кайда кунуын да, караватта ялгызы гына ятуын да, бүлмәдә аннан башка берәү дә юк икәнлегенә дә төшенеп бетмичә торды. Ә инде бераздан, аңлап алгач, ул бу хәленә тешләрен кысып-нитеп тә түзәргә, кичәге яман нәрсәләр

турында бүтән уйламаска, булдыра алмаган тәкъдирдә исә, күңелсез итеп искә алмаска тырышты. Әмма табигать кануннары кырыс шул: кирәк икән — кояшлы көндә елата, буранлы төндә көлдерә. Кирәк икән...

Гөлсылу җиңелче генә киенгәнлектән, тәннәренә буран җиле кагылудан бик тиз суык сеңеп, тыштан кергәндә инде радиодан концерт тапшыра башлаганнар иде. Колакларга гына түгел, җанга да ягымлы бәрхет тавыш белән Илһам абый җырлый иде:

Иртә буран, кич тә буран,
Мамык шәлеңне уран шул,
Мамык шәлеңне уран.
Кигән киемең күрсәм дә,
Җаныем, бәгырем,
Үзең күргәндәй булам...

— һәй, Илвир! Ишетәсеңме мине-е?..

***

Иртүк торып, Илвир, ач килеш, урамга, эшкә барырга чыкты. Күңелендә хисләр ташкыны. И ул хисләр, ярсый, өзгәләнә һәм кая барып бәрелер урын тапмыйча, әллә ниткән җил-давылга әверелеп, әллә ниткән җәнлек-җанвар сурәтенә кереп, сызгырышып, котырышып, тилерешеп, бер мизгелдә дөньяның бер читендә, икенче мизгелдә — икенче читендә әллә ниткән гарасатлар куптарган сыман булалар да, янә яшь шагыйрьне чынбарлыкка кайтарып, аның җанын һаман бер үк сорауны биреп, талкый, изә башлыйлар.

— Киттеме Гөлсылуың?

Кайтырына өмет тә юк шикелле, һәм гүя дөбердәтеп күк күкри, чартлатып яшен яшьни. "Даһи"ның яңаклары яңгыр явып чыланган сыман була. Яшь ир каударланып кесәсенә тыгыла, әмма кулъяулыгы да юк икән! Булмаса, чәнчелеп китсен, бу каһәрле яшьләрне кулъяулыкка чылатып кесәгә салганчы, тротуарга коеп боз эретүең яхшы!

Илвир "Т" урамы чатында үзе дә сизмичә тукталып калды. Мәгәр соң иде инде. Тар җилкәле, уртачадан калкурак егет аны күреп алган иде.

Илвирның әлеге адәм актыгы белән һич кенә дә очрашасы килми. Чөнки бу бәндә Сөләй Акт иде!

Яшь шагыйрь "болай да бәладән баш-аяк" дип, күрмәмешкә сабышып үтеп китмәкче иде, кинәт Сөләй Акт аңа дәште. Илвир Чулманский адымнарын кызулата төште. Сөләй Акт кулындагы асфальт чокыта торган чүкечен ташлап, йөгереп килә үк башлады, һәм куып җитеп, сабакташын иңнәреннән тотып туктатты да.

"Әһә! Унбиш тәүлектә утыра икән бу", — дип уйлады Илвир Сөләй Актның сакал-мыек басып бетергән җилсенгән йөзенә, өстендәге ертык-портык бушлатына карап алгач.

— Дустым, сабакташым, даһием минем, — дип шатланган булып кычкырып җибәрде Сөләй Акт. Аннары, бөтен урамны яңгыратып көлеп куйды. — Гәзит фирмәсенә эшкә барасыңмы?!

Илвир Чулманский Сөләй Актның ярыйсы гына салмыш икәнлеген дә абайлады һәм тагын ниләр ишетермен икән инде дип, шомланып, авылдашына төбәлде.

— О-о-о! Карама миңа лайтеп... Ак каеннар арасында селкенеп тора кара төп... Шәп әйтте Сөләй Акт, ә?!

Илвир Чулманский дәшмәде.

— Шулай шул, син минем кебек гайрәтле түгел, юаш син, гәзит корты... Әнә: көмеш очлы боз-сөңгеләр — кызлар керфеге төсле, учыма алсам, эри шундук, миндә мәхәббәт — көчле! Да, да-а..

Сөләй Актның кызыл күзендә шәпләп мунча кергәннән соң кичерелә торган рәхәтлек чагылып узды.

— Да-а... Хатын-кыз халкы теләсә кайсы ир-ат өчен җан фида кылырга тормый бит хәзер, Илвир янашым. Ә минем өчен... Менә бу курба Сөләй Акт өчен сугышалар хәтта, җан кисәкләрем...

Илвир Чулманский эченнән генә, нәрсә сөйли бу ахмак, дип уйлады, ә тыштан исә Сөләй Актның хатын-кыз турындагы ләззәтле һәм вакыты-вакыты белән татлы пышылдавы кайнар суга салган шикәрдәй эреп киткән сыман тәэсир калдырды. Имеш, мондый тылсымлы әңгәмәдән кем генә битараф булып, читтә ялгызы гына торып калыр икән? Чөнки хатын-кыз шундый асыл зат инде ул, син аңар мәңгелек гашыйк: үлгәнче, кабергә кергәнче гел үзенә тарта, гел үзенә чакыра ул сине...

Әйе, Илвир Чулманский, сүзләр нәкышенең остасы буларак, хатын-кыз халкы турында тик матур итеп кенә уйлый ала инде. Ә Сөләй

Акт, күп очракта, хатын-кыз нәфислеген — тик ир-ат халкының дәртен басарга яраклы түбән бер нәрсә итеп кенә саный иде. һәм менә шул сәләмә философ, илаһи хисләрне пыран-заран туздырып, аклыкны каралтып, пакьлекне биниһая таушалтып, сөйләргә керешмәсенме!

— Шуннан, бал корты кебек, теге хуш исле чәчәкнең нектарын суырып бетергәч, тагын да шәбрәк мәткегә юлыктым мин. И-и, дәртле дә, мул күкрәкле дә соң үзе, парин! М-м-м... "Ирем санаторийдан кайтып җиткәнче, әйттереп калыйк әле, арсланым!" — ди. Әйе, әйе, "арсланым!" — ди, янашым. Шуннан...

Сөләй Акт аякларын аерып басып папирос кабызмакчы иде, шырпысы бетте.

— Мин хәзер... — диде ул Илвир Чулманскийга, — анау фараоннан гына ут элдерәм дә...

Яшь шагыйрь, бәйләнчек һәм исерек Акттан шулай җиңел генә котылуына сөенеп, китеп барды.

"Хатын-кыз... ди бит, ә... Кеше хатынын, ягъни минем апамны үз сөеклесе кебек итеп, аның турында, яратам, фәлән-төгән дип, селәгәйләрен агызып... Их, Сәләмә! Сәләмә! Шигърият өлкәсендә генә түгел, гаилә тормышында да графоман икәнсең әле! Менә синдәй адәмнәр инде ул бай кеше хатыннары янында йөреп, таушалып бетә дә, аннары, аларның үз хатыннары сөяркә эзләп уңлы-суллы каранырга мәҗбүр була.

Соң, табигатьтән килә торган наз дигән нәрсәгә сусаган була ул синең хатының! Ә син аңа бирергә тиешле назны инде әллә кайчан уңлы-суллы өләшеп бетергәнсең... Кызганыч, бик кызганыч! Шулай итеп, ач белән тук икесе бергә тыныч кына ятып йоклый алмый! Тук рәхәтләнеп, изрәп йокласа да, ач — юк, йоклый алмый, һәм ул торып эзләнергә тотына, яки..."

— Фу, — дип куйды Илвир Чулманский йөзен чытып, — ахмакны очратсаң, башыңа да тик ахмак уйлар гына килер, ди китап. Йә, юньле адәм очраса, мәсәлән — Ризван Мөштәриеч! — дип, үзе дә сизмәстән әйтеп җибәрде Илвир һәм шундук кылт итеп, аның исенә Резеда төште.

Чү! Бу ни бу?.. Яшь ир тигез урында сөрлегеп китте.

Янәшәдәге зур кибеттән, шагыйрь абыйсын шаккатырып, кара күзләреннән утлар очырта-очырта, Резеда чыгып килә иде.

Резеда да Илвирны күреп алган кебек булды, ләкин танымады ахры, шагыйрь яныннан гына сыдырылып диярлек үтеп китте. Ә Чулманский үз хатынының чибәр кыз туганын күздән яздырмаска, югалтмаска тырышып, аңа иярде.

Ә бу чибәр кыз Резеданың көндәлеген укый алсак, без аңда менә мондый сүзләр күрер идек:

"Ул мине күреп, артымнан калмыйча килде дә, авиация институты каршында куып җитеп туктатты.

— Исәнмесез, Резедәкәй! Танымыйсызмы әллә? Мин бу — Илвир Чулманский, — ди.

Тулы түгәрәк алсу йөзендә шатлык билгеләре, ә коңгырт-кара күзендә яшьләр иде аның.

Илвир җизни, әлбәттә, минем уңайсызлануымны сизмәде һәм ул кинәт көчле бер омтылыш белән, хисләнә-хисләнә, минем кулымны үбәргә, сыйпарга һәм салкында кызарып янып торган яңакларына кысып-кысып алырга кереште.

Мин түзмәдем:

— Йә, җитәр сезгә, җизни, — дидем элекке танышымның атаклы институт бинасы каршында, сәхнәдәге шикелле кыланып маташуыннан көләсем килеп һәм кулымны тартып алдым. Сөйгән егетем Ирданның тәрәзәдән карап торуы да бар бит! Бу сәер хәлне күреп ул ниләр генә уйламас та, көнче башка нинди

генә шикләр килмәс. Бу турыда Илвир җизнәмнең үзенә дә әйттем, — кисәтеп!

— һм-м, ярый, сеңелем, гафу итегез! — ди бу. — Мин белмәдем. Алайса, мин сезнең чыкканны әнә тегендә, — ул урам якка ишарәләп күрсәтте, — көтеп торырмын.

Мин битләремә, колакларыма ут капкан хәлдә институт бинасына кердем. Аспирант егетләр — булачак галимнәр арасында басып торган Ирдән мине танып, елмаеп миңа таба килә башлады. Килеп җитте дә, уң кулы белән иңемә орынып, күземә туры карап әйтте:

— Иртәгә язучыларның зур әдәби сөйләшүе була. Шунда минем яраткан әдибем Йосыф Гали дә була — киләсеңме?

— Алай Йосыф Гали дә катнашкач, бармыйча ярамас инде, — дидем мин елмаерга тырышып.

— Әлбәттә, әлбәттә, Резеда сандугачым, килә күр! — диде Ирдан һәм "иртәгә очрашуга кадәр!" — дип, иптәш аспирантлары янына китеп барды.

Мин Илвир җизни кайтып киткәндер инде, дип уйлаган идем. Ә ул көтеп торган икән, чыгуга ук култыклап алды. Мин исә ни уйларга да белмәдем.

— Мин сине өеңә чаклы озатам әле, Резеда! — дип сайрарга керешмәсенме шунда Илвир җизни.

Әйе, әллә кайдан сизелеп тора чая шагыйрь икәнлеге! Мәгәр Гөлсылу туганым хакына мин аның белән урам буйлап озаклап янәшә барудан баш тарттым. Моның өчен, әлбәттә, сылтавы да табылып куя инде аның. Мин бераздан:

— И-и, Чулманский җизни, безнең юллар шушында аерыла да инде, — дидем һәм шагыйрь җизнигә саубуллашыр өчен, кулымны суздым. Чөнки якында гына бер троллейбусның килгәне күренә иде.

Ләкин мин Илвир җизнидән тизрәк котылырга тырышуым белән ялгышканмын икән. Баксаң, ул мине түгел, ә мин аны култыклап өенә озатып куярга тиеш булганмын бит! Ник дигәндә, Җөмһүриятебез мөстәкыйльлеккә тулысынча ирешсен өчен татар зыялыларының кайберләре утка кергәндә, Илвир Чулманский дигән каһарман шагыйрь (көтмәгәндә генә хатыны ташлап китүе сәбәпле!) сугышчанлыгын киметә төшкән, имеш. һәм ул шундый киеренке көннәрдә сөекле халкына арка терәге була алмам, дип курка!

И Аллам! Ярый әле мин очрадым бүген батыр шагыйрь җизнинең туры юлына! Әйе, мин аңа бик теләп ярдәм итәчәкмен — янына Гөлсылу апаны кайтарырга, бик теләп! Ләкин шунысы да бар: ни өчен ташлап киткән соң әле Гөлсылу апа Илвир җизнине? Менә шушы сорауга дөрес җавап тапмый торып, бүгенге заман тормышы куйган бүтән катлаулы мәсьәләләрне чишеп булмый да булмый инде. Мин Гөлсылу туганымның тәртибе турында төпченеп сораштыра башлагач, Илвир җизни,

өлгергән помидор сыман булып, кызарып китте, сулъяк бите сизелер-сизелмәс кенә тартышып куйды, коңгырт-кара күзендә сәер чаткылар барлыкка килде. Ниһаять, ул портфелен җиргә куеп, кесәсеннән газетмы-нәрсәме чыгарды да:

— Иманым камил, Резеда: гаиләләр эчендә низаг-талаш чыкса, ил эчендә дә яхшы тәртип калмаячак... Син миңа Гөлсылуны кайтарырга ә булыш инде, яме! Тагын бер мәртәбә үтенеп сорыйм! — диде.

Аннары ул миңа Гөлсылу апаның адресы язылган кәгазь кисәге сузды һәм соңыннан кулындагы газетны бирде:

— Әгәр дә мәгәр, Резеда Чибәркәем, Гөлсылу туганыңны минем янга кайтып яшәргә күндерә алсаң, иртәгә менә бу газетта язылган әдәби сөйләшүгә килерсез! — диде".

***

Көндәлекнең дәвамы мондый:

"...18.30. Мин үземә кирәкле йортның яшелгә буялган капкасы буенда басып торам. Серле капка булып чыкты әле бу минем өчен. Ни келәсе, ни тоткасы юк. Торам шулай карана-карана һәм уйлап та куям: Бу урамга әле һаман газ үткәрмәгәннәр икән, гәрчә Җөмһүриятебездә илле елдан артык нефть-газ чыгарылса да! Аннары Илвир җизнинең ике абыйсы да нефть-газ эшендә чиләнә бугай әле! Ә биредә, Казанның борынгы тар урамнарында, морҗалар ҖЭС торбалары шикелле — төтенләпме төтенлиләр! Һавалар агулана, агулана...

Әйе, чынлап та биредә утын, ташкүмер, брикет ягалар. Кичке шау-шулы урамга кыздырылган суган исе, базар ите исе, кәбестә ашы исе һәм пешкән камыр исе аңкый иде. Кайсыдыр уңганы бәлеш-фәлән дә пешереп маташадыр әле.

Биредә күбрәге шәхси йортлар булу сәбәпле, урам җыештыручысы тотмыйлар икән. Кар бөтерелә-бөтерелә ява да, трамвайдан өерелеп төшкән кешеләр аны шундук таптый да бара. Әнә, күрше урам колонкасыннан ташыганда чайпалып түгелгән сулар пыяладай ялтыр боз хасил иткән. Яшь-җилкенчәк, егете-кызы, парлысы-парсызы аның өстеннән чажылдап кына шуып үтеп китә. Бер караганда мондагы кешеләр үз йортлары, үз мәшәкатьләре белән тыныч кына, җай гына яшәп яталар кебек. Ләкин ул тышкы яктан гына шулай тоела. Чынлыкта исә бу кешеләр дә ил-көн язмышына битараф түгелләр. Җөмһүриятебездә, сөекле Казаныбызда килеп туган катлаулы сәяси һәм икътисадый киеренке хәлләр аларның йөрәкләрен дә борчуга сала, милләтләр арасында сугыш уты кабызырга маташучы кайбер җинаятьчел фирка әгъзаларына карата алар да иксез-чиксез нәфрәт һәм ачу белдереп яшиләр. Шуның белән бергә алар үзләренең тормыш шартларын яхшырту турында да кайгыртмый түгелләр иде.

Мәсәлән, үзәк газеталар "Бу урамдагы йортлар соңгы гомерләрен кичерәләр", — дип язып чыкты. Менә мин шундый сүтелергә тиешле йортлардан берсенең яшел буяулы капкасын ачып ишегалдына аяк бастым. Каршымда ике катлы агач өйнең беренче катына менә торган кечкенә генә болдыр иде. Аскы катның тагын икенче бүлеменә керер өчен бу бинаның артъягына үтәргә тиешмен икән әле. Шул бүлмә нәкъ мина кирәкле фатир булып чыкты да.

Мин сакланып кына "төймә"гә бастым. Озак та үтмәде, ишектә йомшак һәм кызыксынулы хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Кем ул?

— Бу — мин әле, апа... Резеда!

Менә ишек артык тавышланмыйча гына ачылып китте. Дөм караңгы өйалдында мин хатынның киңчә битле зур йөзен һәм ярым ялангач беләкләрен генә шәйләдем. Бу — билгеле инде — Гөлсылу апа иде.

Туганым да мине таныды, ахры, йөткеренгәләп куйды, аннары:

— Мин мичкә тәм-том тыккан идем. Пешмәделәрме икән, карыйм әле... Ә син, сеңелем, чишен, чишен! — диде. Аның йөзендә гаҗәпләнү чалымнары һәм шул ук вакытта сөенүгә охшаш билгеләр дә бар иде кебек.

Бераздан инде без әлеге фатирда күптәннән очрашып сөйләшә башлаган кешеләрдәй, ярым авылча, ярым шәһәрчә җиһазлы түрьякта төрле сый-нигъмәттән авыз итеп, чәйләр эчеп, гәпләшеп утыра идек. Шулай да сүз Илвир тирәсеннән еракка китмәде. Мин моны үзем шулай теләдем. Миңа бигрәк тә Гөлсылу апаның Илвир җизни турында үз авызыннан ишетү кирәк иде. Мин шул турыда күбрәк белергә теләп, Гөлсылу апага кабат сорау бирмәкче идем, ә ул кинәт "аһ" дия-дия тәрәзәгә барып капланды. Мин дә: — Ни бар, ни булды? — дип, тәрәзә аша тышка карадым.

Безгә каршыдагы кирпеч йортның өйалды ишеге янында уңлы-суллы чайкалып, сәрхүш ирме, егетме басып тора иде. Буе уртачадан чак кына калкурак, өстенә мех эчле кыска тун кигән, аякларында шулай ук мех эчле ботинкалар.

— И әкәмәт, и адәм мәсхәрәсе! — диде Гөлсылу апа. Аның тавышында теге бәндә өчен хафалану сиземләнә иде.

— Кем соң ул, берәр танышың мәллә?

— Минем авылдаш ул, Сөләйман Актуганов... Ә Илвирның сабакташы! Аннары минем белән РКБда да эшләде, лифтта! Болай әйбәт иде үзе, юмарт, — бай кеше малае булганга күрәдер инде!

— Нишләп йөри соң ул монда?

Гөлсылу апа кинәт елмаеп:

— Эт нишләсә, бу да шуны эшли инде, — дип җавап кайтарды.

— Апа! Синең монда яши башлаганыңны белгәндер ул, бәлки...

— Белә, каничны. Ләкин ул Илвирның апасы янына килгән. Теге йортта Илвира апа яши. Шуңа күрә Сөләйман миңа күренергә курка! Әрлим ич, сүгәм ич мин аны бу хайванлыгы өчен...

Шул мизгел кирпеч йортның өйалды ишеге ачылып китте һәм аннан Илвир җизнинең апасы — таза гына гәүдәле хатын ялт кына чыгып басты. Менә ул симез кулын селки-селки сәрхуш егеткә нидер боерды. Ә бу Мәҗнүн исә шундук кулындагы чәчәк бәйләмен Илвира апага сузды. Мәгәр Илвир җизнинең апасы чәчәкләрне атып бәрде дә, сәгать күкеседәй, артыннан өйалды ишеген дә ябып куйды.

— Бәлки ул Илвира апаның кызы Люция янына килгәндер, — дидем мин. Бит кайчандыр, Марсель абый белән Илвира апа гаилә тормышында үзләренчә кечкенә генә революция ясарга теләп, уллары тугач — Рево, ә кызлары дөньяга килгәч, аңа Люция исеме куштырганнар. Әмма бу гаиләнең революциясе шулай да барып чыкмаган, чөнки көннәрнең берендә уллары Рево үлеп киткән! Моны бәхетсезлек димичә ни дисең инде?

Гөлсылу апа чак кына уйланып торганнан соң:

— Белмим инде, ни әйтергә дә белгән юк! — диде.

Сөләйман Актуганов, иелеп, чәчәкләрен җыеп алгач, без карап торган тәрәзә каршына килеп, шешенке һәм кара мыеклы йөзен пыялага терәде.

Мин, шүрләп, артка чигеп куйдым. Сәрхуш егет күзен шарландырып нәкъ мина текәлеп каткан иде. Ул мине күрә, мәгәр кем икәнлегемне әле танып җиткерә алмый шикелле. Шулай да:

— Гөлсылу! — дип эндәште үзе. Мин түзмәдем:

— Юк, абый, мин Гөлсылу апа түгел! — дип җавап кайтардым.

Исерек егет инде тәрәзәгә чиртергә үк тотынды.

— Син?! Илвир? Сабакташ! Ач... Чынлап та, эт тә эт, бу да эт икән!

— Бу бәйләнә башласа, тиз генә котылдым юк моннан, — диде Гөлсылу апа. — РКБда да бәйләнеп, бер сестра кызның теңкәсен корытып бетергән иде бу! — Аның тавышында, кайчандыр бергә эшләгән Сөләйманны, хәзерге исерек егетне, авылдашын, Илвир җизнинең сабакташын кызгану да чалымлана иде кебек.

Ниһаять, без тәвәккәлләдек.

Менә инде мин һәм Гөлсылу апа — түр бүлмәдә, йомшак тахтада ятабыз. Янәшәбездәге өстәл өстендә, сулы вазада — чәчәкләр! Ә чәчәкләрне безгә бүләк иткән егет — үзе әйтмешли — Сөләй Акт ян бүлмәдә, идәндә гырылдап ята. Аның баярак кына минем каршыма тезләнеп, "Мамзель, мин сезгә үлеп

гашыйк!" — дип әртисләнгәненә ышанасы да килми хәтта, һәм ул вакыты-вакыты белән йокы аралаш шундый итеп гырылдап җибәрә ки — ерткычларның ерткычы арсланның да болай ук гырылдаганы юктыр!

Каршыдагы кирпеч йортның аш бүлмәсендәге тәрәзәдә дә яктылык бетте. Без яткан бүлмә эче тәмам караңгыланып китте.

— Карале, Гөлсылу апа! — дидем мин. — Илвир җизни турында нәрсә дә булса сөйләп ташламассыңмы икән, юкса, бик күңелсез...

Гөлсылу апа кинәт, ачулангандай итеп:

— Кеше бәхетсезлегеннән кызык табарга ярыймыни инде шулай... — дип куйды.

— Кеше бәхетсезлегеннән, әлбәттә, кызык нәрсә табып булмый, әмма бит сезнең гаилә тарихыгызда да бәхетсезлек очраклары күренми бугай! — дип, шартлатып җавап кайтардым мин. Гөлсылу апа минем фикерләр белән килеште ахры, җилкә чокырын кашый-кашый.

— Нәрсә калды икән инде? Нәрсә сөйлим икән соң? — дип, бер мәл аптырап торганнан соң. — Ә, ие... Баштарак, булды мондый хәлләр! — дип башлап китте. — Иң беренче мәртәбә мин Илвирга ияреп калага килгәч, ул мине тамак ялгап алырга кафега чакырды. Минем кафе дигән җиргә гомеремдә беренче генә керүем иде. Андагы тәртип-фәләннәрне бик белеп тә, өнәп тә бетермим. Шулай, туганым, утырып ашарга урын эзләп йөрүемне күреп, Илвир миңа и-и-и акаеп карады, әйтерсең лә ялгышлык белән мин аның поэмасын мичкә ыргыткanмын! Ә инде ашап-туеп, авылдагы гадәт буенча, "Аллаһеәкбәр"не әйтеп, ике куллап битемне сыпырып куйгач, ул мине битәрләп туя алмады. Имеш, монда карчыклар җыелып утыра торган урын түгел, имеш, монда "общественный столовой", имеш, бирегә урысы да, керәшен татары да, яһүде дә, фәләне дә керә...

Аннан соң янә бер ел узгач, икенче хурлыкка калуым ресторанда булды. И мин, ашау приборлары дигән нәрсәне гомеремдә дә ишетмәгән авыл мулласының кызы, әнә шул нәрсәләрне, чәнечке, пычак ише әйберләрне куллана белмәвем аркасында яндым да инде. Бусында җизнең миңа рестораннан чыккач күтәрелеп тә карамады.

Тагын бер хәл кинозалда элеккеге муллалар тормышыннан фильм карап утырганда булды. Мин онытылып китеп: "Карале, теге адәм тәганәсенә генә, карале!" — дип экранга кулымны сузып күрсәткән идем, Илвир әйтер сүз дә таба алмыйча зәһәренә буылып, залдан ук чыгып китте. Ул көнне, адашкан бәрәндәй, ялгызым гына елый-елый өйгә кайттым.

Инде ярый, бусы да үтте ди, мин монысын да гафу иттем, ди. Әмма Илвир мине юк-бар белән тинтерәтүеннән туктамады әле. Һәй, туктау гынамы сиңа, туганкаем! Ул хәзер миңа әдәбият теориясен өйрәнергә кушып бәйләнә иде. Ә минем, мулла кызы

буларак, билгеле инде, Коръән сүрәләрен яттан өйрәнәсем килә бит! И дәген өйрәнәсем килә, туганкаем... Шуннан, шулай, түздем-түздем дә, түзем савытым мөлдерәп тулгач, китеп бардым менә... калганын үзең дә беләсең булыр инде, туганкаем?!

Гөлсылу апа сүзеннән туктады һәм, минем сөйләгәннәрем турында бу ни уйлый икән, дигәндәй, минем якка таба төбәлеп карап тора башлады. Шулай да ул әле һаман миңа иң кирәклесен әйтми калдыргандыр кебек тоела иде.

Мин шул турыда Гөлсылу апага сорау бирдем. Хатын тыелып кына көлеп куйды:

— Ул чаклы ук интим хисләргә кагылма инде, Резеда сеңелем! Ярар алайса, әйтсәм әйтим: төп бәла Илвирның үзендә — төнозын шигырьләр белән җенләнеп, минем ялгызым гына мендәр почмагын тешләп елап ятуым турында онытып утыруында инде... Әйе, әйе, кемнәрдер өчен яхшы шагыйрь була белсә дә, минем өчен төннәрен әйбәт ир була белен иде ул... Без хатын-кызлар төн өчен дә яратылган ләбаса, Резеда туганкаем!

Һай, бу Гөлсылу апа, гел үз ягына гына каера, гәптәшенең күңелен аңларга теләп тә карамый, әй! Аның белән Илвир җизни арасында да шундый ук хәл булгандыр, мөгаен. Әйтик, Гөлсылу апа гел үзен генә кайгырта, үз мәшәкатен генә алга сөрә... Аның тик үз кайгысы гына кайгы да, үз хәсрәте генә — хәсрәт. Ә Илвир җизнинең рухи тормышы аны тамчы да дулкынландырмый, һәм ул Илвир җизнинең борчу-куанычлары турында чак кына да уйлап бакмый, ди. Болай булгач, әлбәттә, Илвир җизни төннәрен "салкын" Гөлсылу апа янына "кайнарланып" килеп ята алмаячак. Чөнки алар бер-берсен аңламыйлар һәм аңларга теләп тә карамыйлардыр шикелле. Чөнки алар бу дуамал холыклары белән икесе ике котып кешесен хәтерләтәләр инде. Ләкин аюны да биергә өйрәтәләр, ә болар бит — кеше! Кеше! һәм боларны ничек кенә булса да яңадан кавыштырырга кирәк! Илвир җизни миннән шуны көтә ич...

— Әйе, Гөлсылу апа... — дидем мин, әлеге уйларымны үз күңелемдә генә калдырып, хәйләгә керешеп. — Синдә хаклык бар! Илвир җизнидә дә хаклык бөтенләй үк юк түгел, бар! Тормыштагы бу четерекле мәсьәләләрне чишкәндә сезнең һәркайсыгыз үзен генә хаклы санаячак... Тик шуны онытма, апа: кимчелексез нәрсә юк бу җиһанда, хәтта нинди якты, нурлы "изге" кояшта да кара тап бар!

Гөлсылу туганым эченнән генә минем белән килеште булса кирәк, кинәт башын түбән иде дә:

— Инде безгә нишләргә? — дип сорады.

— Кавышырга! Только тәвәккәлләп кавышырга! — дидем мин үз- үземә нык ышанып. — Иртәгә сәгать өчтә әдәби сөйләшү була, шунда кил! Менә шунда Илвир Чулманский да киләчәк инде... Мин дә шунда барачакмын! — дип өстәдем аннары, Ирданымны күздә тотып. Ул да шунда барачак бит!

— Чынлап та, кызык бу... — Гөлсылу апа башка сүз әйтмәде. Тынды. Тойгыларга бирелдеме әллә?

Мин дә уйга чумдым. Әйе, хәлебез яхшы түгел бит безнең, таркау бит без, кем-кемгә дус һәм туган икәнлекне дә белмибез... Иң яманы — белергә теләмибез... Уңга-сулга карамыйча дан артыннан куабыз, шанлы булырга омтылабыз, мөмкинлек табылу белән үк, тизрәк-тизрәк череп баерга тырышабыз һәм терсәкләребез белән этеп-төртеп, егып дигәндәй, тагын мал-мөлкәтле булыр өчен һәм янә әллә нинди, әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән дәрәҗәләргә ирешер өчен дә бер-беребезгә карата яман кабахәтлекләр кылабыз, шулай итеп, кешелеклегебезнең генә түгел, хәтта бөтен бер милләтебезнең дә бәясен бик түбән төшерәбез! Һәрхәлдә, мондый очракта "кешелек" һәм "милләт" дигән изге төшенчә үтә тупасланып, аяк астындагы тузаннан бик әллә ни югары күтәрелмәскә мөмкин! Гади генә итеп әйткәндә, болай аның исеме дә бар, яңгыравыклы җисеме дә бар, ә асылда исә гуманлы принципларга нигезләнгән чын кешелек юк!

Мин тәрәзәдән карадым. Күктә йөзгән ялгыз ай, минем тынгысыз уйларымны куәтләп шәрехләгән шикелле, күз кысып куйгандай итте. Мин янә җирдәге тормыш, яшәү һәм үлем турында үземчә фәлсәфә куертып, йоклап китүемне сизми дә калганмын... Берзаман чәрелдәп кычкырган тавышка уянып китсәм, янәшәмдә генә яткан Гөлсылу акыра икән:

— А-а-а... сө-зә-ә, сө-зә-ә...

Нәрсә сөзә? Кемне сөзә? Гөлсылу апа әллә куркыныч төш күреп саташып, уяна алмыйча интегеп ятамы?!

Мин шундук, Гөлсылу апаның юрган читен күтәреп, башы белән эчкә, җылыга керергә маташкан Сөләй Актны этеп җибәрдем. Ул идәнгә барып төште. Әмма торып, яңадан Гөлсылу апаемның юрган читен күтәреп, башы белән эчкә, җылыга кереп ояламакчы булды. Мин аны кабат этеп төшердем. Ул, киребеткән дисәң дә киребеткән инде, янә сикереп торды. Мәгәр бу юлы Гөлсылу апа үзе дә уянып китте һәм... кәҗә урынында Сөләй Актны шәйләп һәм егетнең ни кылырга теләвен чамалап, кычкырып җибәрде. Бусында төшендә түгел, өнендә:

— Аһ-Һ... оятсыз, җир бит! Мин сине тышта катып үлмәсен әле бу дип, кызганып өйгә керттем! Ә син?.. Шушымы синең миңа рәхмәтен?!

— Ә-ә-ә?! — диде Сөләй Акт. Аның бөтен тәне калтырый, ә тешләре бер-берсенә шык-шык бәрелә иде. Ул, ниһаять, эшнең хикмәтенә төшенеп, әллә төшенеп җитмичәме, минем тарафка ахмакларча карап тора башлады. Ул минем хатын-кыз булуымны таныймы, танымыймы — белмим! Шулай да егет чиядәй кызарды. Аннары ике кулы белән дә башын тотты, һәм, ниһаять, чыгып ук китте...

Гөлсылу апа Сөләй Акт артыннан өйалды ишеген бикләп, минем янга әйләнеп кергәч, әйтеп куйды:

— Көзге каршындагы кыяр лосьонын да төнлә торып эчкән бит, явыз! — Аннары ул кыяр "суы"ннан бушаган савытны илтеп чиләккә салды һәм, минем башымдагы уйларны сизгәндәй, әйтте:

— И-и, Резеда сеңелем... шундый хәйләкәр бәндә ул! Ул әле үзен күрсәтергә әдәби сөйләшүгә дә ялт итеп, галстук тагып киләчәк, менә күрерсең, Резеда сеңелем, киләчәк!

Мин шунда Гөлсылу аланын өчтерме, дүрттерме көмеш теше барлыгын искәрдем.

## VI

...Резеда алсу йөзен таныш һәм таныш түгел кешеләр арасында утыручы Сөләйман Актугановка күрсәткәндә, әдәби сөйләшүнең инде бая ук башланып китүенә төшенде. Менә Йосыф Гали язуыннан тукталды да, бәсәргән мыек чуклары астыннан хәйләкәр елмаеп:

— Сез әле генә, — дип, аудиториягә мөрәҗәгать итте, — укып кителгән һәм өчесе өч төрле формада иҗат ителгән әсәрләрнең шаһитлары булдыгыз... Аларга карата бәяләмәләрне дә ишеттегез. Шулардай чыгып тагын ни әйтә аласыз бу өч әсәр турында?.. Ә-ә-ә... димәк, бүтән булдыра алмыйсыз... Шулай шул, чын мәгънәсендә дулкынландыргыч, мавыктыргыч яхшы әсәр иҗат итү ул — өстәл артында майлы ботка ашап утыру түгел! Инде, иптәшләр, әлеге әсәрләрне камилләштерү юнәлешендәниләр эшләргә кирәклекне әйтегез миңа. Конкрет тәкъдимнәр... Шул әсәрләрнең эчтәлегеннән читкә авышмыйча гына, ачыш булып саналырлык иҗади эзләнүләргә җирлек бармы? Әллә юкмы, иптәшләр?!

Тынлык. Ниһаять, бер-берсенә карашып алулар, пышылдашулар башланды. Әмма берәү дә басып сүз әйтергә теләмәде. Булдыра алмабыз, дип курыктылармы, әллә ялгышырбыз да көлкегә калырбыз, дип шүрләделәрме, шайтан белсен.

— Менә син — яшь шагыйрь — бас әле, — диде Йосыф Гали, беренче укылган әсәрнең авторына.

Илвир Чулманский нигәдер авырлык белән генә торып басты.

— Сиңа хәзер ничә яшь? Илвир Чулманский әйтте.

— Һммм... — диде Йосыф Гали. — Мин бу яшьтә инде өч повесть, егермеләп хикәя бастырган идем... Ничә яшьтә яза башладың соң? — Мин проза турында әйтәм. Армиядә хезмәт иттеңме? Белемең? Кайда эшлисең?

— Хикәяләрне, чынлап торып, егерме ике яшьтә яза башладым. Авиация частенда хезмәт иттем — бер ел! Университетның тел һәм әдәбият бүлеген тәмамладым. Газетта эшлим.

— Аңлашылды. Болай синең чын прозага да сәләтең сизелә кебек. Әмма бу әсәрең синең — дөресен әйткәнгә ачуың килмәсен — яшеңә, тормыш тәҗрибәңә, белемеңә хас нәрсә түгел. Зуррак, киңрәк колачлы әйбер язып кара әле: мәсәлән — роман!

— Уууу... — диде Илвир Чулманский һәм бурлаттай кызарып урынына утырды. Ә Гөлсылу аңа кызып-кызып нидер аңлатырга тотынды бугай.

— Икенче укылган әсәр безнең — Йосыф Гали үз алдында яткан кәгазьгә күз төшереп алды – Ризван Мөштәриеч дигән әфәнденеке бит әле.

Пеләш абзый торып басты.

— Йөзгә карап сезгә алтмыш яшьтән дә ким биреп булмый.

— Әйе, мин шул сез әйткән яшьтә, — диде абзый. — "Очкын"да редактор... Яшьлектә шигырьләр язып тилердем, хәзер — картаеп акыл югала башлагач — хикәяләр!

Йосыф Гали шаяртуны кабул итеп, үзе дә шаян тонга күчте.

— Бу хикәягез сезнең улыгыз яки кызыгыз турында түгелме?

— Юк, үзем турында үзем яздым мин.

Барысы да гаҗәпләнеп һәм кызыксынып абзыйга төбәлде.

— Сез... буйдак булып картайган ирмени?

— Юк, түгел! Монда буйдак булуның ни катнашы бар? Мин, просто үзем турында үзем хыялланып яздым.

Редактор янында утырган яшь кыз пырхылдап куйды.

— Сезгә, әфәнде, утырырга мөмкин... — Йосыф Гали аудиториягә карады. — Армадыгызмы, ялыкмадыгызмы?

— Юк!

— Түзәргә була әле!

— Дәвам итик!

— Ярый-й... — Йосыф Гали алдындагы кәгазьгә карап куйды. — Әйе, иптәшләр, хыял дигәннән... әдәбиятның төп сере шул инде, хыялланып язу һәм укучыны да хыялланырга өйрәтү. Ләкин хыял ничаклы гына үткен һәм канатлы булмасын, җирдән, тормыштан, кешеләрдән аерылырга тиеш түгел... Инде килик өченче укылган әсәрнең, парчаның авторына...

Сөләй Акт ясканып сикереп торды.

— Йосыф абый, мин! Менә мин...

— Сөйләгез (ул Сөләй Актка башы белән ымлады), сөйлә!..

— Элек шигырьләр яздым инде, хәзер парчалар яза башладым.

— Белемегез?

— Урта мәктәп тәмамладым. Армиядә хезмәт иттем. КАМАЗ да эшләдем. Хәзер Казанда эшлим инде.

— Укуны университетта дәвам итәргә иде бит сезгә, тел һәм әдәбият бүлегендә диюем.

Сөләй Акт күкрәген киерә төшеп, тавышын бөереннән чыгарып әйтте:

— Йосыф абый! Горький университетта укымаган әнә, СыСыСыРда аннан да бөек әдип юк!

— Дөрес анысы, — дип, Сөләй Акт белән килешергә мәҗбүр булды Йосыф Гали, — университет бетереп кенә язучы булып булмыйәле. Аның өчен анадан сәләтле булып туарга кирәк... мәгәр-р төпле, системалы белем дә алырга кирәк, шунсыз безнең эштә зур уңышка ирешеп булмаячак... Бигрәк тә безнең бу искиткеч катлаулы чорда! Аннары, минемчә, әдәби өлкәдә уңышка ирешү өчен, университет белеме дә ахыргы нәтиҗә булып тормый: тирән, бик тирән тормыш белеме кирәк! Горький бит юкка гына "Минем университетларым — тормыш!" — дип язмаган. Ләкин мин сезгә Горькийдан өйрәнегез, армый-талмый Горькийны укыгыз, Горький кебек булыгыз, дип әйтә алмыйм. Горькийның да хаталары аз булмаган. Сез вакытлы матбугатны укып барасызмы? Укыгыз! Аларда (илебездә һәм чит дәүләтләрдә басыла торган газета-журналларда) барысы да языла. Аларга ышансаң, хәтта Владимир Ильич (бөтен дөньяда коммунизм төзергә ашкынучы идеологиянең атасы) Ленин да гел сөттән ак, судан пакь кына булмаган бит. Чөнки большевиклар Россиядә властьне үз кулларына көч куллану юлы белән алалар... Хәзер инде безгә билгеле: көч куллану юлы белән башланган яңа тормыш гел көч куллануга гына кайтып кала икән ул, әй!

— Дөрес! Дөрес!

— Болар турында без дә укыдык!

— Яшәсен демократия-а!

Йосыф Гали әкрен генә көлеп куйды.

— Шулаен шулай да, ләкин сезнең әсәрләрегездә бит демократия күренми! Сезнең әсәрләрегездән бит торгынлык заманы исе килә!

— Торгынлык заманында булган хәлләр ич алар. Алар турында шулай язмыйча, тагын ничек язасың инде, Йосыф абый?!

— Бүгенге көн югарылыгыннан торып язарга кирәк, иптәшләр.

— Уңышсызлыкларыгызның сәбәбе дә, уңышларыгызның ачкычы да менә шунда!

— Алай, сәясәткә кереп батабыз ич без, Йосыф абый! Ә сәясәт ул бүген болай, иртәгә тегеләй... сәясәт ул гел яңарып, гел үзгәреп тора! Әйтик, кичә без капитализмны тар-мар итеп социализм төзегән булсак, бүген инде яңа социализмның астын-өскә әйләндереп, капитализм төзибез. Моның формуласы болай. Кичә без тунны бушлат иткән булсак, бүген инде бушлатны кабат

тун итәргә маташабыз!

Кемнәрдер көлә, кайсылардыр сызгыра иде. Аудитория гөж килде. Йосыф Гали уң кулын өскә күтәрде.

— Тынычланыйк, иптәшләр! Тынычланыйк... Без монда сәяси дискуссиягә җыелмадык, әдәби дискуссия үткәрергә килдек. Инде әдәбиятка әйләнеп кайтыйк. Менә уйлап карыйк әле, иптәшләр. Без, язучылар, үзебез яши торган җәмгыятьтән читләшә һәм тулысынча азат була алабызмы?

— Юк! Юк!

— Сәясәттән?

— Юк, әлбәттә!

— Шулай булгач, иптәшләр, бая укылган шома әсәрләрдә язылганча, мең мәртәбә чәйнәлгән мәхәббәт кыйссаларын мең дә беренче мәртәбә чәйнәү беркемгә дә уңыш китермәячәк. Андый әсәрләр беркемне дә дулкынландырмаячак, уйландырмаячак, сызлан-дырмаячак. Димәк, андый әсәрләр әдәбият өчен кирәкле түгел, чөнки андый әсәрләрнең әдәбият өчен кыйммәте дә, әһәмияте дә юк! Алай булгач, нинди әсәрләр кирәк соң әдәбиятка? Ә әдәбият, беләсез инде, кешелеккә хезмәт итә ул!

Чандыр гәүдәле яшь тәнкыйтьче торып басты.

— Проблемалы әсәрләр кирәк! — диде ул.

— Дөрес! Бик дөрес!

Йосыф Галинең сорауларына, барысы өчен дә диярлек, күзлекле яшь тәнкыйтьченең җавап биреп баруы — Илвир Чулманскийнын күңеленә үтә хуш килде. "Киләчәк өчен Ходай насыйп иткән татар

Белинские менә шушы үзедер инде", — дип уйлады ул. һәм аңа күңелле дә, рәхәт тә булып китте. Тормыш дигәнең кызыксыз түгел икән ул, шайтан алгыры, кызыклы икән! Шулай итеп, Илвир Чулманский бүгенге әдәби дискуссия барышында күп нәрсәләрнең серенә төшенде, күп нәрсәләрне аңлады. Димәк, әдәбиятның максаты бар икән. Димәк, язучылар үз алларына максат куеп эш итәргә тиешләр икән. Дөрес, Илвир Чулманский бу турыда элек тә белә иде инде, аңа бу турыда университетта укыганда да күп тукыганнар иде. Мәгәр ул чакта әле сүздә бер нәрсә сөйләп, ә эштә икенче бер нәрсә кыла торган заман иде. Чөнки 37 еллардагы дәһшәтле нәрсәләр һаман үзен сиздерә иде әле. Шуның өчен, әдәбият дөньясында тыныч кына яшәргә, кешеләрне шаккатырам, дигән булып шау-шу тудырып йөрмәскә, телне, артык озая башласа, богаулап куярга, колакка мамык тутырырга һәм олы гына кара күзлек киеп (халык танымасын, янәсе), партаппарат түрәләренең чүпләрен җыештырырга, юешләгән урыннарын сөртергә туры килә иде. Синең партаппарат түрәләре каршындагы үтәләсе олы бурычын һәм бернигә дә карамыйча үтәп чыгар өчен йөкләнелгән олы вазифаң әнә шул! Шул юлдан читкә тайпылдыңмы, инде сине ишегалдында кулына револьвер тоткан 37 ел сагалап торачак!

Безнең бөек элгәреләребез әйтеп калдырган: иҗатта барыннан да элек тулы ирек һәм хөрлек булырга, өстән кушуларга, көчләүләргә урын булмаска тиеш! Чынлыкта исә, безнең йөз процентлы реалистик әдәбиятыбыз булдымы соң? Безнең әдәбиятыбыз чын тормышны тулы канлы итеп чагылдыра алдымы? Юк, булмады һәм чагылдыра алмады. Ә ялган тормышка, алдап язуга корылган әдәбиятның гомере кыска аның. һәм андый әдәбиятның халыкка бер тиенгә дә кирәге юк! Юк! Үзебез шуны белдек, ә үзебез шуны һаман-һаман эшли тордык. Без, күрәсең, коммунизм дигән тәти уенчыкка алданып, иманыбызны да аяк астына салып таптый яздык, кешелеклегебезне дә җуя яздык. Безгә хәзер кире үз асылыбызга кайтырга кирәк. Безгә хәзер иң кешелекле, иң гуманлы идеяләр кирәк. Ә ул идеяләрнең төп чыганагы кайда булырга тиеш соң? Әлбәттә, әлбәттә, иптәшләр, ул — әдәбиятта!!!

Йосыф Галинең бәгыреннән ургылып чыккан ул сүзләре яшь әдәбиятчыларны чынлап торып уйга калдырды. Әйе, тормыш — көрәш ул. Димәк, әдәбиятта да көрәш булырга тиеш. Яшәү өчен! Яшәү өчен!..

Йосыф Гали арыган кыяфәт белән сәгатенә төбәлде һәм аннары аудиториягә карап сорау ташлады:

— Армадыгызмы, ялыкмадыгызмы?

— Перекур.

— Перекур кирәк.

— Перекурсыз булмый.

һәм Йосыф Гали тәнәфес игълан итте.

## VII

...Бүлмәдә утыручылар бердәм рәвештә торып, язгы ташкын сыман ишеккә ябырылдылар, коридорны тутырып, әллә кая чаклы сузылдылар.

Ирдан ниндидер танышын очратып, аның белән сөйләшә калды. Ә Резеда Илвир белән Гөлсылуны көтеп тора иде әле. Ләкин алар күренмәделәр, ташкынга ияреп чыгып киткәннәр булса кирәк. Резеда, коридорга таралган тәтен исләрен ихтыярсыз исни-исни, Илвир белән Гөлсылуны эзләп китте. Исемсез, тамгасыз бер ишек янында ул кинәт Илвирның тавышын ишетеп, туктап калырга мәҗбүр булды.

— Ие, минем хәләл җефет инде бу!.. Резеда ишекне ачып җибәрде.

Кеп-кечкенә бүлмә иде бу. Кара-каршы өстәл куелган. Өсләрендә — язу машинкалары. Элек Илвир, аннары Гөлсылу бүлмәдән чыгып, Резеда белән исәнләште.

— Исәнмесез, Резеда!

— Исәнме, Резеда сеңелем, бәгырем! Нишләп соңарып килдең, бер-бер хәл булдымы әллә?

— Курыкмагыз, булмады, берни дә булмады!

— Ә без сине югалткан идек инде. — һәм Гөлсылу ялт кына Илвирына карап алды. Ә Илвир Гөлсылуга күз кысты. "Ниһаять, килешкәннәр болар, яхшы..." — дип уйлады Резеда. Шул мәлне аларның каршында күктән төшкәндәй Ирдан пәйда булды:

— Исәнмесез-саумысез!

— Ә Ирдан... Исәнме!

— Исәнмесез! Без, ни... китәбез инде!

— Йосыф Гали үз әсәрләре өстендә ничек эшләвен, романнарны ничек язуын тәфсилләп сөйләячәк бит, — диде Илвир. — Беләсезме, ул "Иптәш" дигән беренче романын дүрт ел язса, "Дошман" исемле яңа романын исә утыз җиде көндә машинкада басып ташлаган икән!

— Ай-һай талантлы! — дип куйды Резеда төкселәнеп.

— Моның да бер-бер хикмәте бардыр әле, — диде Гөлсылу җитди генә итеп. — Исаак Ньютонмы әле, кемме, дөньяның тартылуы кагыйдәләренә юл салган бит башына алма төшкәч!

— Карагыз әле, карагыз... — диде аспирант егет исе китеп. Ул әдипләр йортында мондый гайре тамашаларга урын булмаска тиеш, — дип уйлый иде ахры... Барысы да ул күрсәткән тарафка карадылар. Анда Сөләй Акт, бая Ризван Мөштәриевич янәшәсендә утырган кара кызны, шәфкать туташын, сихерләгән сыман, ирененнән үбеп тора иде.

— Аhhh! Анжеликабызның да тормышын агуларга өлгергән икән инде бу вирус, — диде Илвир, кыргый алма капкандай, йөзен сытып. Аннары исә Резедага төбәлеп: — Кызык иттең син аны, сеңелем! — дип куйды. — "Нәгыймә" исемле парчаны чынлап та мин язган идем бит!

Шул мәлне "Әдәби сөйләшү"еннән Ризван әфәнде килеп чыкты. Ул да Сөләй Акт белән Анжеликаның дөньяларын онытып үбешеп торуларын искәреп, чал башын чайкый-чайкый коридор буйлады.

— Ярый, туганнар, без дә кыяклыйк инде, — диде Резеда һәм егетен култыклап алды.

— Ашыкмагыз! Тукталышка чаклы озатып куябыз әле үзегезне!

— Әлбәттә, әлбәттә... — диде Илвир.

Киенеп урамга чыктылар. Кар төшкәләп тора иде. Бераз баргач, Ирданны авылча киенгән бер түти туктатты.

— Энем, син шагыйрь Илвирны беләсеңме?

Таныш тавышны ишетеп, Илвир башта катып калды, аннары тиз генә исенә килеп, әнисенә ташланды.

— Әни-и-и!

— Әнеккәем, Илвир! Саумы, балам?

— Аллага шөкер, әни! Үзең нихәл соң! Бу тирәгә ничек килеп чыгарга иттең?

— Синең өчен борчылып инде, улым! Авылда халык: Илвир белән Гөлсылу аерылыша икән, дип сөйләшкәч...

Гөлсылу шундук кайнанасын кочаклап алды.

— И-и, юк сүз, әни! Берни дә юк! Әйдә... тормыйк монда урам уртасында, кайтыйк...

— Кодагый әби, җаным, безгә дә кунакка килеп чык! — диде Резеда сөенеченнән балкып.

— Чакыргач, бармый булмас инде, — диде Илвир шулай ук елмаеп, һәм сүзендә торды ул.

Бер көнне "Бу — кемнәр икән?" — дип, Резеда шөбһәләнеп кенә ишекне ачып җибәрсә, каршысында Илвир җизнәсе белән Гөлсылу апасы басып тормасынмы!

— Ә-ә, кодагый әби кайда?

— Ул... Илвира апаларда!

— һммм...

Шулай ук шатлыклы эндәшүләр, исәнләшүләр китте. Резеда кунакларны бүлмәсенә чакырды. Керделәр. Илвир портфелен ачты һәм ак, кызыл, ал чәчәкләр чыгарып, сеңелесенә сузды. Гөлсылу аларны шундук сулы вазага утыртып куйды.

Өстәл өстендә Ирдан һәм аның иптәше, иптәшенең сөйгән кызы калдырган сый-нигъмәтләр дә җыеп алынмаган иде әле. Илвир белән Гөлсылу кызыксынып сорашырга тотындылар. Резеда кыскача гына аңлатып, сөйләп бирде. Баксаң, сынау тапшырганнар икән. "Отличнога!" — ди. Аннары алар, Гөлсылу әйткәнчә, шампанский аттырдылар. Газлы шәрабтан барысының да йөзе алсуланып китте. Күңелләре күтәрелде. Телләре чишелде. Илвир озын кара чәчләрен артка таба сыпыра-сыпыра, кайнарланып шигырь сөйләргә кереште.

Резеда "браво-браво" дип кул чаба иде инде. Ә Гөлсылу мәхәббәтле күзен иренә төбәп, онытылып торган җиреннән кинәт исенә килеп, әсәрләнеп җырлап җибәрде:

Кайгыдан киптем, сагыштан саргайдым.
Йөрәктән кан тамды, юк чара...
Әйттеләр: вакытсыз шиңә бу,
И кызый... бичара-бичара...
Ишеттем шул чакны тылсымлы бер шигырь:
Унда да, сулда да мәдхия.
Кинәт мин уяндым,
"Тылсым"нан көч алдым,
Әйттеләр: булдырдың, — әүлия!
Акчарлаклар оча, бер-берсен куыша,
Ерак диңгездә — ак ярда.
Йөрәктә ут яна, сүнми ул сүрелми
Илвир, бәгырем, син барда!

Бу Гөлсылуның йөрәгеннән кайнап-ургылып чыккан үз җыры иде. Шунлыктан ул тыңлаучыларга икеләтә тәэсир итте.

Шатлыктан, Гөлсылуның "Мәхәббәттәге уңышлары" өчен куанудан, кызның күзенә хәтта яшьләр килде. Ул торып, Илвир белән бер үк вакытта диярлек, Гөлсылуга ташланды. Аны кулыннан эләктереп җилтерәтергә, муеныннан кочаклап, битләреннән үбәргә кереште. Гөлсылу исә көтмәгәндә генә үзенә ишелеп төшкән таудай бу бәхеттән нишләргә белмичә, әле Илвирына, әле Резедага карап, каш астыннан гына оялчан төстә елмаеп басып торды. Бу мизгелдә аннан да бөеграк, аннан да рәхәткә тиенгәнрәк кеше планетабызның бер генә төбәгендә дә булмагандыр! Шуннан соң Резеда канатлы Мәгъшукага, аңына да килергә ирек бирмичә, тормышында тагын да зуррак уңышларга ирешүләрен теләп шәраб эчәргә тәкъдим ясады. Эчтеләр. Аннары Илвир белән Гөлсылу, кунакның вакытында китә белүе хәерле дип, саубуллашырга тотындылар. Ә автобуска утырып китәр алдыннан алар үзләренә дә килеп (егете белән) чыгуларын үтенеп адресларын биреп калдырдылар. Чөнки Резеда Илвир җизнәсенең кайда торуын белми иде әле. Резеда барырга вәгъдә итте.

...Менә Резеда тәрәзә каршында басып тора. Ул үзенең тәрәзә каршында басып торуын белми дә кебек. Гүя аның бөтен кан тамырлары буйлап йөгерек-җитез дулкыннар тарала... Дулкыннар тарала... Кызга үзен бу минутта кемнәргәдер кирәкле, бик кирәкле икәнлеген тою рәхәт, искиткеч рәхәт иде.

Әнә Илвир Чулманский шәпләп ягылган җылы өйдә, өстәл янына утырып, ак абажур яктысында бик бирелеп нидер яза. Яза-яза да, эшеннән бүленеп кәгазьгә, төрлечә тәртипсез рәвештә сибелеп киткән сүзләргә маңгаен учлап, күзе талганчы, озак кына карап тора. Аннары, күз алдында хәрефләр сикерә-бии башлагач, карашын читкә, караңгылыкка, тәрәзәләргә таба юнәлтә. Ул тарафта дивар буенда, диванда Гөлсылу ята.

Гөлсылу да йокламый. Ул әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнә, башын калкытып ире утырган якка карый, аннары офтанып, авыр сулап стена ягына борылып ята.

Илвир сизә: Гөлсылу аның эше төгәлләнгәнен көтеп ята. Мәгәр— Иҗат — планлы нәрсә түгел. Аны теләгән вакытта бетереп тә, башка килгән кызыклы фикерләрне язмыйча иртәгегә калдырып та булмый. Иҗатчы кеше, чын мәгънәсендә, эш аты белән бер.

Илвир тәрәзә аша күренгән кышкы урамнан һәм андагы туктап торган, туктап тормаган машиналардан, үтеп-сүтеп йөргән кешеләрдән карашын алып язарга кереште.

...Менә Илвир Чулманский язуыннан туктады. Сәгатенә текәлде, өч тулып дүртенчегә киткән икән. Торып мич буена барды. Үрелеп эчкә карады. Күмерләр ут сулап яталар иде әле.

Илвир тартырга уйлап, кесәсенә тыгылды да, хатыны Гөлсылу исенә төшеп, ниятеннән кире кайтты. Нигә төтен чыгарып һаваны агуларга? Көйрәтәсе булгач, тышка чыгып кабызырга кирәк! һәм ул җиңелчә генә киенеп ишеккә таба кузгалды. Әмма чыгып китәргә өлгермәде, артыннан Гөлсы-

луның ялварулы тавышы ишетелде.

— Чыкма инде, картым, тәннәреңне туңдырып!

— Э-э-э... син йокламадыңмыни, карчык?

Илвир Чулманский чишенеп, хатыны янына килде, диванга утырды.

Гөлсылу эчке күлмәкчән көе юрганга төренеп, диварга сөялеп утыра иде. Соңгы вакытларда булып узган хәлләр, кичергән авырлыклар Гөлсылуга да үз тамгасын салып өлгергән. Аның күз төпләре сары йоккан сыман, ә йөзе җилдә йөреп киселгән-каралган кебек иде. Гомер дигән әрсез рәссам да читтә торып калмаган — яшь хатынның маңгаена беленер-беленмәс итеп кенә сыр-бизәкләр төшерә башлаган.

Илвир кинәт кенә хатынының муеныннан кочып, үзенә таба тартты. Гөлсылу карышмады. Иренең киң күкрәгенә ауды һәм йомшак шарф сыман муенына уралды... Алар өчен дөнья онытылмады... Мәхәббәт ничаклы көчле һәм ярсулы булмасын, шагыйрьгә дөньяны онытырга ярамый.

Йөрәк ул гомер буе — өйрәнмәгән тай, иректәге кош, судагы балык шикелле. Аны вакытында тыеп кала белү өчен хуҗасының акыллы, укымышлы булуы шарт.

Илвир хатынын кысып кочаклаган көе менә ниләр турында да уйлый иде. "Ә Гөлсылу сагынып көткәнме бу көнне? Ул моның шулай матур, бәхетле булып чыгачагы турында уйлаганмы? Ышанганмы ул Илвирның кайчан да бер үзен шашып-шашып сөячәгенә?..

Әйе, ышанган икән. Булган аның күңелендә андый ышаныч... Яхшы, нык хатын. Молодец ул минем Гөлсылуым"

Ә хатын болай уйлый:

"...Минем Илвирыммы соң бу? Ярый әле югалтмаганмын... Кил, кил, бәгырем... Карыйм әле бер туйганчы үзеңне. Кочыйм әле, иренеңнән үбим әле..."

Ире:

"...Каян килгән аңа мондый дәрт... Мондый кайнарлык? Элек болай ук... түгел идең бит син, Гөлсылу! Нинди үзгәргәнсең... яхшыргансың..."

...Хатын: "...Рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт, картым! Сөя беләсең икән әле... Янып сөю — икенче сөюне тудыруга сәбәп була, диләр. Мин дә сиңа гашыйк. Мин дә сине үлеп сөячәкмен. Тоясыңмы? Сизәсеңме? Илвир Гыйбадуллин-Чулманский, бәгырем!"

Илвир Гөлсылуның ягымлы нур белән тулган күзенә тутырып карады.

"Гөлсылумы соң бу? Әллә мин үзгәрдемме? Ничек якын ул миңа хәзер..."

Тышта буран, салкын...

Өйдә җылы, рәхәт.

Их! Нинди тылсымлы, нинди тылсымлы син — мәхәббәт!
— Картым, нәрсә яздың соң? Бик озак утырдың бит...
— Хикәя, карчык... хикәя яздым.
— Хикәяме? Менә әйбәт... әйдә, укыйбыз!
— Соң бит...
— Йокларга дисеңме? Йокларга да соң инде?..
— Әйдә, укыйм алайса, тыңла!
Гөлсылу кинәт Йосыф Галинең әйткәннәрен исенә төшереп, йомшак кына көлеп җибәрде.
— Хикәяң ниме соң, проблемалымы, картым?
— Проблемалы, әлбәттә! Шунсыз хәзер... мөмкин түгел... Шулчак Гөлсылуның эчендә нидер беленер-беленмәс кенә тибеп
куйды. Тынды. Әһә, тагын типте. Бала!!!
Хатын иренең муенына сарылды. Уттай кыза башлаган битен иренең битенә тидерде һәм колагына пышылдап:
— Тыңлыйм, укы! — диде.

## IX

...Борынгы һәм шанлы, данлы Казаныбыз татар халкының мәркәзенә әверелә алырмы? Бөтен дөнья татар җәмәгатьчелеген менә шул борчый хәзер... Бит Татарстан Җөмһүрияте узган ел сәяси мөстәкыйльлек игълан итте. Хәзер һәр татарның авызында тик шул изге сүз генә...
Көннәрнең берендә әнә шул уй, әнә шул фикер Илвир Чулманскийны да Сөембикә манарасы кырына китерде. Янында Гөлсылуы да бар!
Кешеләр, кая карама кешеләр, татар кешеләре! Араларында таныш һәм бик таныш йөзләр дә очрый... Әнә Ирдан белән Резеда да, Илвир Чулманский белән Гөлсылуга, елмаеп, кул болгыйлар! Үз чиратларында Гөлсылу белән Илвир да аларга елмаеп, кул болгадылар. Әйе, татарның бу чаклы күп булып бергә җыелганы, тупланганы юк иде әле. Егерме меңләп бардыр... Егерме бер үк булмаса!
Биредәге халык арасында тик мөселман байраклары гына җилферди. Ә бит арада коммунистлар, социал-демократлар һәм
христиан динле татарларның да булуы бик мөмкин! Булса, яхшы. Ә булмаса? Чөнки халыкның күпчелеге бирегә сәясәтчеләрнең "борчак сибүен" тыңларга түгел, ә гает намазын укырга дип килгән булырга тиеш. Ник дигәндә, халык коммунистлар ялганын тыңлап тәмам бурткән инде, гарык булган, һәм социаль-демократ дигәннәре дә татар халкына тик шовинистлар күзлеге аша гына карый шикелле. Ә христиан "туганнарга" килгәндә исә, алар да татар халкын ваклап-ваклап

кабып йота барырга әзерләнә сыман. Алайса кай якка карарга, кай тарафка төбәлергә? Кемнән үрнәк алырга, кемнән өйрәнергә, кемгә ияреrgә???

Илвир Чулманский мөнбәрдә, мөфти янәшәсендә басып торган Төркия, Әзәрбайҗан кунакларын, ерак океан артыннан килгән татар галимен һәм Татарстан хөкүмәте вәкиле сыйфатында баярак кына чыгыш ясаган татар галимен дә кызыксынып күзәтте; мөфтиебез боларның барысыннан да тирәнрәк һәм эчтәлеклерәк чыгыш ясый. Халкыбыз тарихының иң борынгы дәверләреннән башлап бүгенге чорга тикле үткән араны җентекләп сөйләп, тасвирлап һәм гаҗәп оста итеп сынландырып бирде бит ул! Шулчакта барысы да уйланды, дулкынланды һәм татарның тарихта тоткан урыны кечкенә булмавын, зур булуын аңлады. Моның белән тиешенчә горурлана белергә кирәк икәнлегенә төшенде. Шулай итеп, татарның милли аңы үскәннән үсә, ә күңелендә милләте белән горурлану тойгылары арта һәм көчәя бара иде.

Илвир Чулманский кинәт хатынына елышты һәм очлы карашын сөеклесенең күперенке корсагына төбәде. Менә ул да биредә ире күргәнне күрә, ире кичергәнне кичерә ләбаса. Аннары аның эчендә тернәкләнеп килүче җан иясе дә мондагы хәлләрне "күрә", "ишетә", "күңеленә сеңдерә" ич. Соңында ул җан иясе дөньяга чын татар баласы булып өлгереп туачак һәм гомере буе мәгърур татар исеменә тап төшермичә яшәячәк, Алла боерса!!!

— Без әле җиде миллион гына... Без инде йөз миллион чиген дә узып киткән булыр идек, әгәр дә...

Илвир сискәнеп китте һәм әкрен генә, үзенә ишетелерлек итеп кенә: "Улым!" — диде.

Мөфти тагын ниләрдер әйтте дә, ниһаять, кыйбла тарафына борылып басып, гает намазын укырга вакыт җиткәнлеген белдерде. Халык бердәм рәвештә кыйбла тарафка борылып басты. Илвир Чулманский да, манара очындагы алтын айга карап алганнан соң кыйбла тарафка борылып басты һәм: "Кол Шәриф мәчетен дә торгызырга вакыт җитте инде, мәчет янәшәсендәге атаклы мәдрәсәне дә..." — дип уйлады. Хәер, Казан елгасының теге ягына зур, бик зур мәчет салып куярга һәм мәдрәсә һәм кунак йорты һәм тагын әллә нәрсәләр төзеп куярга тиешләр тиешен дә... Халык теләгәч, корабыз дигәч, корырлар анысы... Кем белә, бәлки, Илвирның малаена шул мәчеттә укып белем алырга насыйп булыр.

Гает намазы тәмам. Халык ташкыны чыгуга таба агыла башлады. Чү! Илвирның күзенә Сөләй Акт чалынып китте. Әйе, ул үзе... башында (бу кытлык заманда кайдан юнәтеп кигәндер) укалап чигелгән өр-яңа хәтфә кәләпүш, өстендә әллә нинди ялтыравык тимерләр тагылган кара япма, аякларында әйбәт кара туфлилар.

Сөләй Акт елмайды һәм:

— Син дә мөселманлыкка язылырга йөрисеңме әллә, — дип, Илвир Чулманский белән күреште.

— Халкым кайда — мин дә шунда, халкым нишли — мин дә шуны эшлим инде, — диде Илвир Чулманский, шулай ук, елмаеп.

— Әйе, һич аңламассың безнең бу заманны: халык исеме белән нинди этлекләр дә эшләнә хәзер, — диде Сөләй Акт. һәм өстәп куйды: — Әнә... Гыйрак гарәпләре Кувейт гарәпләрен нишләтте ич! Алар бу җинаятьләрен бөтен дөнья гарәп халкы исеменнән эшләде ич!

Чак кына арырак, Сөләй Актны көтеп булса кирәк, кара чәчле, кара кашлы бер марҗа кызы басып тора иде... Сөләй Актның тел төбе аңлашылды хәзер. Димәк, ул безнең мөстәкыйльлегебезгә каршы... Ә ни

өчен бирегә килгән соң ул, бу марҗа кызын ияртеп? Бәлки аны бирегә марҗа кызы алып килгәндер? Әмма ни генә булмасын, алар бирегә яхшы ният белән килмәгәннәр. Алар бирегә шпионлык итәргә, татар халкының тырнагы астыннан кер эзләргә килгәннәр... И-и-и, әйбәт анадан яман булып туган, хайван, сатлык җан...

Шул мәлне Илвирлар янында гына диярлек, кулына тавыш көчәйткеч тоткан, кырган башлы, чалара башлаган сакал-мыеклы ир-ат пәйдә булды. Бу — Гаяз Исхакый бүләгенә иң беренче лаек булган әдип — Йосыф Гали иде. Ул саф, калын тавыш белән:

— Кремльдән чыккач таралмагыз, иптәшләр... барыгыз да, тәртип саклап, Ирек мәйданына таба юл алыгыз, Ирек мәйданына! Кичә, Югары Совет сессиясендә, шовинист депутатлар мөстәкыйльлегебезгә каршы нык тордылар. Мөстәкыйльлегебез куркыныч астында... Татарстаныбыз мөстәкыйльлеген без — татарлар саклап кала алмаса, кем генә саклап кала алыр, иптәшләр? Хәзер үк, барыгыз да Ирек мәйданына! Хәзер үк... Бүгенге мөмкинлекне кулдан ычкындырсак, тарих безне гафу итмәячәк, киләчәк буыннар безнең йөзләребезгә төкерәчәк...

Халыкны тәмам йокыдан уятырга, рухын күтәрергә тырышып, куркусыз әдип сөйләде дә сөйләде.

— Бүген, иптәшләр. Югары Совет сессиясендә, безнең язмышны хәл итә торган карарлар кабул ителәчәк... Югары Совет сессиясе барышына басым ясар өчен, барыгыз да Ирек мәйданына, барыгыз да!

Халык аңлады. Берничә минуттан инде Ленин урамы — киң, зур елгага кинәт килеп төшкән язгы ташкынга охшап калды.

Теге марҗасы каядыр китеп югалды ахры. Ә Сөләй Акт һаман бер сүзне кабатлаудан ары узмады:

— Безнең халыкның да Гыйрак белән Кувейт тарихы булачак әле, менә күрерсең, булачак!

— Ни өчен? — дип сорады Илвир ачуланып. — Кайдан алып әйтәсең син бу сүзләрне?..

— Рәсәйдән аерылырга ярыймыни инде, — дип мыгырданды Сөләй Акт, тирә-юньдәге кешеләрнең нәфрәтле карашын күрмәмешкә сабышып. — Рәсәй бит ул! Зур бит ул!

— Зур Рәсәйнең проблемасы да зур аның, — диде Илвир кыза төшеп. — Шуңа күрә, зур Рәсәйдә синең белән минем проблемага игътибар да итеп тормыйлар. Шулай булган, шулай булды һәм шулай булачак! Без үзебезнең проблемаларыбызны тик үз дәүләтебезне булдырып кына чишә алачакбыз...

— Бел-ми-им, — дип сузды Сөләй Акт, мыскыллы елмаеп. —Татардан юньле эш чыкса, әби-бабайларның авызларына яңа теш чыгар иде.

— Әби-бабайларның да авызларына яңа теш чыгар әле, барысы да булыр, барысы да! Шул вакыт куркусыз әдипнең көчле тавышы яңгырап ишетелде:

— Җөмһүриятебездәге барлык табигый байлыкларга: җир, су, урман, һава һәм завод-фабрикаларга без — Татарстан халыклары хуҗа булырга тиеш. Аның өчен, ягъни Рәсәй һәм СССР президентлары белән бөердән чыгарып сөйләшер өчен, безгә үз президентыбызны булдыру фарыз...

— Әйе, шул!

— Дөрес!

— Булдырырга кирәк!

Опера һәм балет театры бинасы янәшәсендә Сөләй Акт та юкка чыкты. Шүрләде кебек. Куркак җан!

Ә халык, куәтле ташкын булып, Ирек мәйданына таба агыла да агыла!..

Илвир Чулманский: "Боларнын һәммәсе турында газетка әйбәтләп язып бирәм әле, бассыннар! Халыкның аңлап житкермәгән өлешенә дә

хак сүзләр барып ирешсен!" — дип сөенеп уйлады. Аннары дәртләнеп, каты итеп Гөлсылуның кулын кысты. Гөлсылу да шулай ук, аның кулын кысып, җавап кайтарды.

## X

...Ризван Мөштәриевич Илвирга мәкаләсен кире бирде.

— Син нәрсә... бу "кызыл" мәкаләне бастырып, мине аттырырга йөрисеңме әллә?! — диде ул кашларын җыерып.

— Бу турыда хәзер барлык газетларда да курыкмыйча язалар инде, — диде Илвир Чулманскии, салкын канлы булырга тырышып.

— Ул газетларның редакторлары дөньядан туйгандыр! Минем әле яшисем килә...

— Куркаклык күрсәтеп, бу көрәштән читтә калу — халкым йөрәгенә төбәп аткан дошманның тегермәненә су кою белән бер ул, Ризван Мөштәриеч!

— Өйрәтмә мине... беләм... синең хәтле генә! Ә син менә мин белгәнне белмисең! — Ризван Мөштәриечнең муен тамырлары бүртеп килде, кулы калтырый: — Власть — ул, ике башлы таяк кебек: кем гарантия бирә ала: илебездә бер айдан яки бер елдан Сталин режимы урнашмас дип?!

Илвир Чулманскии аңлады: Ризван Мөштәриеч — сатлык җан! Сатлык җан белән бәлеш ашап тук булганчы һәм халык нәфрәтенә юлыкканчы, батыр белән ач торуың — чыныгуың һәм халык йөрәгенә юл сабуың мең изге!

— Китәм мин, Ризван Мөштәриеч, сез җитәкләгән газеттан! —диде яшь шагыйрь ныклы, төпле бер карарга килеп, һәм, алдан язып, әзерләп куйган гаризаны өстәлгә, редактор каршына куйды.

— Ярый, ярый, бик әйбәт, — диде редактор сөенеп, һәм ике дә уйламыйча, Илвирның гаризасына кул куя башлады. Чулманскии шаккатты. Әдәби сәләте "Сагыну" дигән мәхәббәт турындагы начар хикәядән ары уза алмаган карт бу кешенең икейөзлелеге аны тәмам чыгырдан чыгара язды. Ләкин ул үзен вакытында кулга алып өлгерде: "Хушыгыз!" — диде дә, ишекне каты ябып, күздән югалды.

Ә берничә көннән Илвирның "Халкыбыз мөстәкыйльлек даулый" дигән зур гына мәкаләсе "Хаклык юлы" газетасында басылды. Озак та үтми, "Очкын" газетасында Сөләй Актның "Мөстәкыйльлек — Татарстанда яшәүче бүтән халыкларга ни бирә?" дигән мәкаләсе күпләрнең күзен маңгаена менгерде.

***

— һәммә нәрсәгә бәянең еллап, айлап кына түгел, хәтта көнләп күтәрелүе — кешеләрдә тормышка мәхәббәт уятырга тиеш! — ди икән бүгенге экономистлар. Бу — әдип Йосыф Галинең: "Хикәяләрдә олы проблемалар күтәрелсә — әдәбият яшәячәк!" дигән гаҗәп хикмәтле сүзләрен хәтерләтә түгелме, соң? Илвир елмаеп куйды. Баксаң, хәзер тормышта бер генә дә проблемасыз нәрсә юк икән!

Әнә шундый бик авыр көннәрдә, Гөлсылу декрет ялына чыгарга әзерләнгәндә һәм шуңа күрә Илвир Чулманский билен тагын да ныграк кысып буып торганда, җилнең кай тарафтан исүенә үтә сизгер Сөләй Акт яңа газета чыгару эшенә кереште. "Демократия икән, демократия: газетны теләсә кем чыгара ала һәм анда теләсә нәрсә бастырып таратырга мөмкин", дип уйлавымы икән әллә?! Алай гына сай уйласа, ялгыша егет. Бит газет чаклы газет чыгарырга алынган кешенең максаты изге булырга тиеш. Ә Сөләй Актның күңелендә изгелек орлыклары бармы? Хәтта берәү генә булса да сакланып калганмы? Бит ул КАМАЗда тик үз мәнфәгатен генә кайгыртып йөрде. РКБда да...

Матбугат ул, РКБдагы яшь сестра шикелле, шаярганны яратмый, алдаганны кичерми. Матбугат — гадел кешеләргә генә ачык чырай күрсәтергә тиеш!

Шулай да Сөләй Актның газет чыгарырга алынуында ике хиснең өстенлеге бәхәссез. Беренчесе — акча сугу, икенчесе — шөһрәткә ирешү! Мәгәр тегесе дә, бусы да барып чыкмаячак: чөнки халык кичермәячәк Сөләй Актның бу әшәке эшен.

Ә Илвир Чулманский бу көннәрдә "Хаклык юлы" газетына эшкә урнашырга йөри иде. Сөләй Актның үз газетын чыгарырга маташуы яшь шагыйрьне тәмам ярсытып җибәрде. Әгәр дә Сөләй сыман графоман шагыйрьнең хыялы тормышка аша калса... ул газет ата коммунистларның гына җырын җырлап ятачак, демократик көчләргә җәелеп китәргә ирек бирмәячәк һәм шуның белән мөстәкыйльлегебезгә гаять зур зарар китерәчәк бит. Бүгенге көндә — мөстәкыйльлекне саклап калу, аның нигезендә инде зур-зур ташларны сала башлау өчен күз күреме җитмәстәй киңлекләрдә киеренке көрәш алып барган чакта, тылда, үз милләтебез эчендә, Сөләй Акт кебек дошманнар белән сугышу — безнең файдагамы?!

Ниһаять, Илвир Чулманский үзе милли демократик көчләргә таяныч булырдай газет чыгарырга кирәклегенә инанды. Исеме — "Сәләт". Программасы — киң колачлы! Максаты — үтә изге: әйдә, күрсәтсен әле татар милләте үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен! Бит моңарчы (булсын патша Рәсәендә, булсын коммунистлар Рәсәендә) һәммә сәләтләргә, һәммә талантларга киң юллар ачарга ирек бирмәделәр! Аларны теләсә ничек будылар, кыстылар, изделәр! Ә сүздә исә моның киресен сөйләделәр: "Бездә барлык сәләтләр дә, барлык талантлар да чәчәк ата!"

Атты... аттырдылар чәчәк: тот капчыгыңны! Милләтнең булган чәчәкләрен дә һәлак итеп бетерделәр. Менә хәзерге демократик шартларда милләт өр-яңадан чәчәк ата башласын өчен тырышырга, күп, бик куп тырышырга кирәк инде.

Илвир Чулманский эшне иң югарыдан башларга булды. Максатын, теләк-омтылышларын бәйнә-бәйнә аңлатып гариза язды да, китте эзләп тиешле оешманы.

Эзли-сораша торгач, ниһаять, тапты кешесен. Гаризасын укытты. Теле белән дә шактый гына нәрсәләр әйтте. Өмете зурдан иде. Ләкин: "Оештыручысы кем инде ул газетның?" — дигән сорауга төпле җавап бирә алмады. "Үзем!" — дип котылырга туры килде.

...Икенче оешмада Илвирның кулдан язган һәм татар халкына карата шактый ук җылы хисләр белән сугарылган гаризасын кызыксынып укыдылар, әмма алар да кабул итмәде. Гариза законның тугызынчы статьясына нигезләнеп язылырга тиеш икән. һәм, әлбәттә, мондый төр гариза рәсми һәм кырыс тонда язылырга тиеш. Аннары, газет чыгарырга рөхсәт язуы алу

өчен, машинкада сугылган гариза белән бергә, банк аша тәңкә акча күчергәнлеккә "платежное поручение" дә китерергә кирәк икән.

Илвирның дулкынланудан ике бите чия төсенә керде. Аның мондый акчасы да юк бит әле. Гаризаларны кабул итеп, теркәп утыручы ир яшь шагыйрьнең хәлен аңлап булса кирәк:

— Хәзер төрле-төрле җәмгыятьләр оешты бит, шуларның берәрсендә, бәлки сезне аңлаучылар табылыр, — диде.

Чынлап та! Илвир әлеге кешегә рәхмәт әйтеп, урыныннан купты.

"В" җәмгыяте президенты Йосыф Гали белән булган әңгәмәдә шул ачыкланды: алар үзләре зурдан кубып газет һәм журнал чыгарырга маташалар икән, әмма әле сәмән ягы сайрак икән. Шуңа күрә "Сәләт" газетасын чыгаруны киләчәккә калдырып торып, Илвирны үзләрендә эшли торырга чакырдылар. Әйе, аларның планнары зурдан, максатлары олыдан: җиңнәреңне сызган да — эшкә кереш!

Илвир күнде дә куйды. "В" җәмгыятенең президенты Йосыф Гали төпле фикерле, тирән уйлап эш итә торган һәм нинди генә кыен хәлләрдә калганда да, үз-үзенә хыянәт итми торган, көчле ихтыярлы кеше сыман тойгы тудырган иде шул. Мондый кешеләр белән канатланып эшләргә дә, мөстәкыйльлек өчен көрәшергә дә була! Аннары тора-бара Илвир үз планын, үз максатын тормышка ашыра башлар, "Сәләт" газетын чыгарырга керешер. Кем әйткәндәй, Казан тиз генә төзелмәгән бит!

Илвир кайтып кергәндә, Гөлсылу идән юып йөри иде. Корсагы да ярыйсы гына булган инде үзенең, ә ул һаман эш белән матавыклана.

— Ташла, әйдә... — диде яшь шагыйрь, һәм хатынын бәби тоткандай сак кына күтәрде дә, караватка таба алып китте.

— Җибәр-р, айгыр-р... кулымны да юмаган бит әле мин, — дип, юри генә киреләнеп маташкан булды Гөлсылу.

— Вакыт юк, — диде Илвир кабатланып, — эш көтә, эш...

— И, син һаман шул инде... Тәрәзәне корыйм, һич югы: күрерләр!

— Күрсеннәр! — Илвир колагын хатынының корсагына якын ук китерде: сөенеп, кычкырып җибәрде. — Тибә, тибә кизәнеп торып, мин сиңа әйтим, мөстәкыйльлегебезгә каршы көчләрнең эченә! Ай-һай-й каты тибә бу!

— Куй инде, карт... тилерми генә инде...

— Вакыт юк дим бит, эш көтә!

Иртәгесен Гөлсылу нигәдер тунарга, калтыранырга кереште.

— Ой... ой... — дип ыңгырашты ул, эчен тотып.

— Ашыгыч ярдәм машинасы чакырыйммы, карчык?!

— Ой-й-й... үлүем шушымы әллә...

Илвир утка пешкәндәй өтәләнеп, телефонга чапты.

...Бала тудыру йортында хатынын калдырып чыккач, яшь шагыйрь "В" җәмгыятенә барыр өчен трамвайга утырды. Күңеле

һаман тыныч түгел иде. Юк, аның йөрәге хатыны, туачак баласы өчен генә түгел, ә башка нәрсә өчен дә борчыла, хәвефләнә иде. Ләкин — нәрсә өчен? Мәгәр бу сорауга төгәл генә, кистереп кенә җавап та биреп булмый; аннары бүген, әнә, тирә-юньдәге кешеләрнең йөзләре дә кирәгеннән артык борчулы, киеренке шикелле.

Илвир, киләсе тукталышта төшәрмен инде дип, талонын тиштерергә теләгән иде, таза гына бер егет аның кулыннан тотып калды. Аннары яшел тышлы таныкламасын ачып, Илвирга күрсәтте. Таныкламадагы фотосурәт әлеге егетнеке иде.

— Сез транспортта йөрү кагыйдәсен боздыгыз, — диде егет.

— Моның булуы мөмкин түгел! — диде Илвир һәм талонын тиштерергә үрелде. Әмма аның кулыннан тагын икенче бер таза гына егет тотып калды.

— Әйдәгез... минем арттан!

— Нәрсә-ә?!

— Сез трамвайга утыргач ук тиштерергә тиеш идегез талонны, ләкин сез моны эшләмәдегез!

— Китегез, мин бернинди кагыйдә дә бозмадым!

— Киреләнмәгез, әйдәгез, әйдә, — диде яшел тышлы таныкламахуҗасы, Илвирның кулын эләктереп, ишеккә таба сөйри-сөйри. Икенче егет тә Илвирны ишеккә таба этәли, төрткәли башлады.

— Карышу мәгънәсез: эшегезне тик кыенлаштырасыз гына...

— Сезгә миннән ни кирәк? Кая алып бармакчы буласыз мине?

— Баргач, күрерсез, — диде яшел тышлы таныкламаның иясе.

— Бүлеккә! — диде икенче егет.

Өченче егет трамвай йөртүче кызга нәрсәдер әйтте. Трамвай туктады. Илвир, ярдәм эзләгәндәй, трамвайдагы кешеләргә төбәлде. Кешеләр һәммәсе дә, ни өчендер, күзләрен яшерделәр, йөзләрен читкә бордылар.

"Теге оешма!" дигән хәтәр уй Илвирның үзәген өзеп җибәргәндәй итте. Аның зиһене җуелып, аяклары атламас, күзе күрмәс хәлгә килде.

## XI

— Син кем яклы? — дип, әллә кем булып сорау бирде Сөләй Акт көзгедән ап-ачык күренеп торган Илвирга машина эчендә барганда.

— Мин — халкым белән! — диде яшь шагыйрь горурланып. Бүтән сүз әйтмәде.